
ISSN 0206—418

# КАЗАН УТЛАРЫ

1.1989



# ГАЛИӘСГАР КАМАЛ



Татар әдәбияты классигы, драматург
Галиәсгар Камалның тууына 110 ел

(1879—1933)

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ

ТАТАРСТАН
ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ
ОРГАНЫ

1922 ЕЛНЫҢ
МАЙ АЕННАН
БАШЛАП ЧЫГА

1989

1

(795)

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА
ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ

КАЗАН

## *Бу санда*

ӘДӘБИ МИРАС

**Идегәй.** *Татар халык дастаны (Ф. Әхмәтованың кереш сүзе белән)* . . . 3
**Файдаланылган чыганаклар** . . . 65

ПРОЗА ҺӘМ ПОЭЗИЯ

М. МӘҺДИЕВ. **Бәхилләшү.** *Моңсу повесть* . . 67

ФАТИХ КӘРИМНЕҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

З. МӘҖИТОВ. **Шагыйрьнең яралы җаны** . . 134
Ф. КӘРИМ. **Төрмәдә язылган шигырьләр** . . 137

ПУБЛИЦИСТИКА

М. ЗАРИПОВ, А. ПОДОЛЬСКИЙ. **Кайры туи кайгысы** . . . 141

БӘХӘС ДӘВАМ ИТӘ: «ЗАМАН ҺӘМ ШИГЫРЬ»

Н. АРСЛАНОВ. **Ачыктан-ачык әйтсәк** . . . 160
В. ЮНЫСОВ. **Кая киткән тыйнаклык?** . . . 163

БИБЛИОГРАФИЯ

Р. ГАНИЕВА. **Тукай ялкыны янара** . . . 165

РИЗАЭТДИН ФӘХРЕТДИНЕВНЕҢ ТУУЫНА 130 ЕЛ

Р. ФӘХРЕТДИНЕВ. **Болгар һәм Казан төрекләре** . . . 167

ГАРӘП ӘЛИФБАСЫ НИГЕЗЕНДӘ ТАТАРЧА УКУ-ЯЗУ

**Бишенче дәрес** . . . 184
Ә. ЕНИКИ. **Көтелмәгән хат** . . . 188
**Культура тормышы көндәлеге** . . . 190
**Тышлыктагы сурәтләр** . . . 192

*Баш редактор*

РЕНАТ ХАРИС

*Редколлегия*

МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВ

ӘХӘТ ГАФФАР

МИРКАСЫЙМ ГОСМАНОВ

АЯЗ ГЫЙЛӘЖЕВ

МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ

МӘДИНӘ МАЛИКОВА

САЛИХ МАННАНОВ
*(баш редактор урынбасары)*

ТУФАН МИҢНУЛЛИН

ФЛҮН МУСИН

РИНАТ МОХӘММӘДИЕВ

РӘФЫЙК НӘФЫЙКОВ

НУРИХАН ФӘТТАХ

РИЗВАН ХӘМИД

НИЛ ЮЗИЕВ

АЗАТ ӘХМӘДУЛЛИН

Безнең адрес: 420066,
Казань, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар:
баш редактор — 53-07-60,
баш редактор урынбасары —
53-07-09,
җаваплы секретарь — 53-07-65,
*бүлекләр:*
проза, поэзия, очерк — 53-07-61,
тәнкыйть, фән, сәнгать,
хатлар — 53-07-63.

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

«Литературное наследие». В журнале публикуется жемчужина устного народного творчества татарского народа — легендарный эпос **«Идегей»**, в основу которого легли реальные исторические события, происходившие в XV веке на огромных территориях от Волги до Кавказа. Эпос имеет сложную, порой парадоксальную судьбу. Он был впервые опубликован в журнале «Совет әдәбияты» в 1940 году и после известного постановления ЦК ВКП(б) от 9 августа 1944 года был незаслуженно предан забвению. Это второе рождение эпоса. Журнальный вариант подготовлен кандидатами филологических наук И. НАДЫРОВЫМ и Ф. АХМЕТОВОЙ.
Начало повести М. МАГДЕЕВА «Прощание».
К 80-летию Фатыха Карима: статья З. МАЗИТОВА «Раненое сердце поэта»; стихи Ф. КАРИМА, написанные в сталинских застенках.
«Публицистика»: М. ЗАРИПОВ, А. ПОДОЛЬСКИЙ. «Страсти вокруг дубленки».
«Литературная критика». Продолжение дискуссии «Время и поэзия»: статьи Н. АРСЛАНОВА, В. ЮНУСОВА.
В рубрике «Библиография» рецензируется книга Ф. Агзамова «Тукай — журналист».
К 130-летию татарского ученого-энциклопедиста, писателя и просветителя Р. ФАХРУТДИНОВА впервые публикуется отрывок из его труда «Булгарские и казанские тюрки», в котором рассматриваются различные аспекты истории татарского народа, приведена гносеология булгарских и казанских ханов.
Навыки чтения и письма на основе арабской графики. Занятие 5-ое.
А. ЕНИКИ. «Неожиданное письмо».
Дневник культурной жизни.
На наших обложках: тамбурная вышивка; вид Казанского Кремля в XIX веке. Репродукция картины английского художника Э. Турнерелли.

Җаваплы секретарь *Флүс ЛАТЫЙПОВ*
Техник редактор *Р. Сөләйманова*. Корректорлар *Т. Сибгатуллина*, *Г. Салихҗанова*.

Производствога бирелде 9.11.1988 ел. Басарга кул куелды 29.12.1988 ел. ПФ 05551. Офсет ысулы белән басыла.
Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8).
Тираж 78054. Заказ А-438. Бәясе 90 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1989 ел.

Ул Туктамыш син булсаң,
Курымны[9] эчкән син булсаң,
Сине баккан мин булсам,
Тугрына[10] кунган Төкле Аяк
Тугыз йортка дан булса,
Аны миңа тапшыргыл»,
Туктамыштай олы хан
Укыган соң бу хатны,
Уңына торып бер бакты,
Сулына торып бер бакты,
Эченә суык боз төште —
Туң тимердәй күк булды,
Эченә кызу ут төште —
Сум[11] тимердәй кызарды.
Кызарган соң ут булды,
Аннан да үтеп ак булды.
Азамат ир Туктамыш
Анда җавап хат бирде,
Ул хатында бу диде:
«Ул дәрья да бу дәрья,
Ул дәрьядан Сыр-Дәрья.
Сыр-Дәрьядан ары Сәмәрканд;
Сәмәркандта утырган
Аягы чонтык[12] Шаһ Тимер
Әмир Барлас син булсаң —
Аргы атасы Чыңгыз хан,
Бирге атасы Туйгуҗа,
Аннан туган Туктамыш,
Ул Туктамыш мин булсам,
Күк Түбәдә Ак сарай,
Анда утырган хан булсам,
Ил булганга ил булсам,
Яу булганга яу булсам —
Кара лачын Төкле Аяк
Сиңа булмас, Шаһ Тимер!
Тугыз йортка дан булган
Кара лачын ау кошым
Сиңа булмас, Шаһ Тимер!
Аннан кала Бүз Тойгын[13],
Ул да булмас, Шаһ Тимер!
И Шаһ Тимер, Шаһ Тимер,
Тешең житсә, таш кимер!
Сигез йортка сыймадың,
Тугыз йортны куймадың,
Сычкан типкән[14] бидаяк[15]
Сиңа булсын, Шаһ Тимер!»
Хат бетелде[16], сүз бетте.
Ай бетте дә көн бетте.
Ел артыннан яз килде,
Чирүле күлгә кош килде,
Күгәл[17] белән каз килде.
Оя баскан Төкле Аяк —
Ул да бала чыгарды,
Кош чөюгә мәл килде.
Ау кошларын караган
Котлыкыя* би иде,
Азамат ир Туктамыш
Аны үзенә чакыртты:

— Әй, Котлыкам, кил,— диде —
Тугыз йортка дан булган,
Оя баскан Төкле Аяк
Ике бала чыгарса,
Икесен бер сынап күрәем,
Аны миңа бир,— диде.

---

* Алтын Урдә — XIII-XV гасырлардагы феодаль дәүләт.

* Ак Урда — Алтын Урданың хәзерге Идел буе, Казахстан, Себер, Кырым һ. б. территорияләрне үз эченә алган өлеше.

* Данлы кыпчак җире — XI-XV гасырларда Иртештән алып Дунайга, Кырымнан алып Бөек Болгарга хәтле сузылган урыннарда яшәгән төрки халык — кыпчак (коман, русча половец) җирләре.

* Нугай иле — XIV-XVI гасырларда Алтын Урдадан аерылып чыккан төрки халык — нугайларның феодаль дәүләте.

* Туктамыш (?-1406) — Алтын Урда ханы (1380-1399), Чыңгыз хан нәселеннән.

1 күчә — урам.

* Сары — соры йә Сарай дигән сүздән үзгәрүе мөмкин. Сары мәрмәр булуы турында мәгълүмат юк.

* Алтын-Таш — ханның тору урыны. Аның алтын тәхете таш өстендә торган. Шуннан Алтын Урда һәм Алтын-Таш исемнәре.

2 йорт — биредә: өлкә, ил.

3 суна — 1) ата үрдәк, 2) фазан (кыргавыл).

4 Төкле Аяк — Туктамыш ханның ау лачыны исеме.

5 азамат — 1) батыр, кыю, үткен, 2) 20—30 яшьлек ир.

6 кош чөю — ау төре, өйрәтелгән кошны кулдан чөеп, кыргый җәнлек аулау.

7 дәүран сөрү — дәверләр үткәрү, гомер кичерү.

8 әмир — дәүләт башлыгы.

* Шаһ Тимер — Аксак Тимер (Тимур, Тамерлан, 1336-1405). Тарихта мәгълүм полководец, әмир. Чыңгыз нәселеннән булмаганга, хан исемен ала алмаган. Башкаласы Сәмәрканд булган дәүләт төзегән. Алтын Урдага, Иран, Кавказ, Һиндстан илләренә яу оештырган.

* Ак Түбә, Күк Түбә — Алтын Урда заманында Идел белән Сыр-Дәрья арасындагы җирләр.

9 кур — кымыз ачыткысы.

10 тугыр — иярдә ау кошы кундыру урыны.

11 сум — саф.

12 чонтык — 1) кыска, 2) койрыксыз.

13 Бүз тойгын — Туктамыш ханның икенче ау лачыны исеме.

14 Сычкан типкән — тычкан ала торган.

15 бидаяк — карчыганың бер төре.

16 бетү — язу.

17 күгәл — ала чумгалак (үрдәк).

* Котлыкыя — нугай халкының мангыт кабиләсеннән мәгълүм шәхес. Дастан буенча, Идегәйнең атасы.

Котлыкыя би килде.
Кыл ефәк бау муйнында —
Ике бер тиң бала кош,
Икесе дә кулында;
Ул кошларны биргәндә
Туктамыш хан алмады,
Бер артык күз салмады.
— Әй, Котлыка би,— диде.—
Болгар белән Сарайда
Мин Туктамыш хан икән,
Тугрыма кунган Төкле Аяк
Тугыз йортка дан икән,
Аны баккан син икән,
Аны көткән мин икән,
Аннан туган ике кош —
Аны миңа бир,— диде.
Котлыкыя би анда
Янә килеп йөгенде[18].
Ул икесен янә биргәндә,
Туктамыш хан аны алды,
Тырнак очына кундырып,
Берәвен чөйде тургайга,
Берәвен чөйде күгәлгә —
Икәве дә очмады,
Тырнагыннан купмады.
Шунда белде Туктамыш:
Ике бер тиң бала кош
Төкле Аяктан тумаган,
Томшыгы тома[19] яралган,
Төксез аяк — бидаяк.
Азамат ир Туктамыш
Анда күңеле бозылып,
Котлыкыя бигә моны әйтте:
— Тугыз йортка дан булган
Кара лачын Төкле Аяк,
Аны чөйгән мин икән,
Аны баккан син икән.
Аның ике баласын
Сорап торган мин икән.
Миңа сонып торганың —
Аягы төксез бидаяк,
Аны үзеңә ал! — диде —
Үз кошларым бир! — диде.
Котлыкыя би әйтте:
— Әй, хан-иям, хан-иям,
Тугрыңа кунган Төкле Аяк
Тугыз йортка дан булса,
Синең белән дан булды,
Кичә син дә чал булдың,
Бүген ул да чал булды.
Йомыркасын салганда
Картлыгыннан шил[20] булды,
Аннан туган ике кош
Бидаякка тиң булды,
Ул ике кош шул,— диде.
Туктамыштай олы хан
Уңына торып бер бакты,
Сулына торып бер бакты,
Күңеле боздай бузарып[21],
Күзе курдай[22] кызарып,
Анда торып моны әйтте:
— Сәмәркандта утырган
Әмир Барлас Шаһ Тимер;
Аргы утырган ул булса,
Бирге утырган мин булсам,
«Кара лачын Төкле Аяк
Тугыз йортка дан булса,
Аны миңа тапшыргыл»,— дип,
Боерып торган ул булса,
Аның телен алмаган[23]
Туктамыш хан мин булсам,
Ау лачыным караган
Котлыкыя син булсаң,
Салган ике йомыркасын
Оядан алган да син икән!
Кош бидаяк йомыркасын
Ояга салган да син икән!
Лачынымның токымын
Шаһ Тимергә биргән дә син икән!
Аягы төксез бидаяк —
Аны да булса күтәреп,
Минем каршыма килгән лә
Син икән, әй, син икән!
Җавабын бир, Котлыка!
Туктамыш хан янә әйтер:
— Әй, Котлыка, Котлыка!
Шаһ Тимер суккан сум алтын,
Сум алтынга сатылдың!
Бер башыңны ике иттең,
Ике ханга баш ордың,
Җавабың бир, Котлыка!
Котлыкыя би әйтте:
— Әй, хан-иям, хан-иям,
Кас[24] дошманың Шаһ Тимер;
Шаһ Тимергә сатылсам,
Бер башымны ике итсәм,
Ике ханга баш орсам,—
Сездән дәүләт киткәне,
Бездән дә ырыс[25] киткәне.
Башыбызга килгән уртак көн
Ул шул икән, ханым әй,
Ул шул икән, ханым әй!
Азамат ир Туктамыш
Әрләп-хурлап аны әйтте:
— Һай, Котлыка, Котлыка!
Коның[26] котсыз[27] Котлыка!

---

[18] йөгенү — тез чүгү, тезләнеп сәламләү.
[19] томшыгы тома — борын очы яссы.
[20] шил — күзенә ак төшкән.
[21] бузару — агару, буз (соры) төскә керү.
[22] кур — утлы күмер.
[23] тел алу — сүз тыңлау.
[24] кас — касд, явыз ният.
[25] ырыс (ураз) — бәхет.

Дәвер кемнең дәвере?
Туктамышның дәвере!
Заман кемнең заманы?
Туктамышның заманы!
Куш канатлы алтын таҗ,
Күз урнында гәүһәр каш[28],
Чыңгыздан* килгән дәүләт-куш[29]
Бу башымда түгелме?
Алты айлык агыр[30] йорт,
Итәгемдә яткан йорт,
Салыгыннан салыгын[31]
Салып алган мин икән,
Урдасыннан урдасын[32]
Уңгарып тоткан мин икән.
Түрәсез калган киң йортның*
Түрәсен көткән[33] мин икән,—
Үзем Чыңгыз түгелме?
Миннән дәүләт киткәннең,
Синнән ырыс киткәннең
Җүясен[34] әйтеп бир,— диде.
Котлыкыя би әйтте:
— Әйтмәк бездән, хан-ия,
Ишетмәк сездән, хан-ия.
Җир уртасы Күк Түбә,
Күк Түбәдә Ак сарай;
Шушы Сарай калада
Дүрт дәрваза[35] бар иде.
Икәве бикле булганда
Икәве ачык икәндер;
Береннән килгән кәрваны
Береннән чыгып бетә алмый,
Божрасы бөтен алкадай
Боралып[36] үтәр икән дә,
Ямгыр белмәс ямчыгыл[37]
Ям[38] юлында ям чапкан,
Ялгыз йөргән юлаучы
Ям юлында ял тапкан,
Юртса юлы киң булып,
Ятса җире киң булып,
Йорт-җир әман икән дә;
Үзе бинең заманы
Ил фәраван[39] икән дә,
Зәкяттән[40] алган зәкяте,
Казнасыннан казнасы,
Үзе* бинең сансыз мал,
Үзе дә белмәс икән дә;
Сансыз алтын бу казна
Гомер бетмәс икән дә,
Безнең көнгә килгәндә
Ул да җитмәс икән дә!
Били белсәң, хан-иям,
Икселмәс[41] дәүләт бу иде.
Алтын Урда, Ак Урда
Алтмыш йортка юл иде,
Индегенең[42] көнендә
Кәрван, дөя килә алмый,
Дәрвазаңнан иңалмый,
Дәрвазаңнан иңгәндә
Сиңа бүлеп бирә алмый,
Синнән дәүләт тайганы
Шул түгелме, хан-иям?
Әй, хан-иям, хан-иям!
Бер биядә ике имчәк —
Бере кипсә, беренең сөте юк,
Бер дөядә ике өркәч —
Бере китсә, беренең көче юк,
Йорттан йортым күчкәне —
Бездән ырыс киткәне,
Куштан[43] кушың күчкәне —
Сездән дәүләт киткәне.
Бер башымны ике итеп,
Ике ханга баш орсам,
Ул да булса, хан-иям —
Йорттан абруй киткәне,
Чабучы булсаң, баш — менә!
Түгүче булсаң, кан — менә!
Аны әйтеп, Котлыкыя
Хан алдында йөгенде.
Туктамыш хан анда әйтте:
— Һай син татар, һай татар,
Мангыттан азган чал татар!*
Син дә кичә бар булдың!
Син дә бүген юк булдың,

[26] кон — чырай, кыяфәт.
[27] кот — җан, ямь.
[28] каш — йөзек кашы.
* Чыңгыз — Монгол империясенең ханы (1155-1227 еллар тирәсе). Азия, Көнчыгыш Европа илләренә яулап алу походлары оештырган.
[29] дәүләт-куш — ил, биләмә.
[30] агыр — хөрмәтле.
[31] салык — салым.
[32] урда — ханның тору урыны.
* Түрәсез калган киң йортның — Туктамыш тәхеткә килгәнче Сарайда берара хан булмый торган. Шуңа ишарә.
[33] Түрәсен көтү — хөкем йөртү.
[34] җүя — логик нәтиҗә.
[35] дәрваза — шәһәр капкасы.
[36] боралу — 1) кычкыру, 2) борылу.
[37] ямчыгыл — почта йөртүче.
[38] ям — почта, ат алыштыру урыны.
* Үзе би (Үзбәк) — 1312-1341 елларда Алтын Урда ханы. Бу еллар Урданың иң төзек, бай, данлы бер вакыты булып санала.
[39] фәраван — муллык, иркенлек.
[40] зәкят — еллык керемнең 40 тан бер өлеше чамасы налог.
[41] икселү — кимү.
[42] индеге — хәзерге.
[43] куш — лагерь, гаскәр.
* Мангыттан азган чал татар — Туктамыш үзе монгол нәселеннән булганга Котлыкыяны татар дип тирги.

Бүген килеп син дә бер
Үлем белән тиң булдың —
Токымыңны ораен!
Азамат ир Туктамыш
Ике биен чакырды.
Чакмагыш би, Дөрмән би
Анда килеп баш орды.
Туктамыш хан анда әйтте:
— Әй, Дөрмән би, Дөрмән би,
Айбалтаңны тот,— диде.
Айпычагың так,— диде.
Котлыкыя ялган бине
Муйнын ора чап! — диде.
Пәридән алган хатыны,
Бишектә ятыр баласы;
Аны да ташлап калдырган
Пәридән булган анасы*,
Ул баланы тап! — диде.
Бишеген ора чап! — диде.
Син дә булсаң Чакмагыш,
Чакма чаккан Чакмагыш,
Котлыкыя ялган бинең
Чаңгырагын[44] чап, диде,
Чабып утка як! — диде.
Шунда торган Җантимер,
Киң кунычлы Җантимер —
Алты угыллы ир иде,
Атагы — өлкән аталык,[45]
Йортта өлкән пир[46] иде.
Туктамышның кашында
Киңәше киң, килбәтле,
Сүзе үткен би иде;
Котлыкыя би белән,
Кан тамызып ак сөткә,
Ант эчешкән ир иде.
Торып килеп Җантимер,
Хан алдында йөгенде:
— Әй, хан-иям, хан-иям!
Җир китәр дә, ни калыр?
Җиреннән тайган ил калыр.
Ил китәр дә, ни калыр?
Ил киткәндә йорт калыр;
Йорт китәр дә сөт калыр.
Ак күкрәктән сөт имгән
Сүзе татлы тел калыр.
Тел китәр дә, ни калыр?
Язганнан язган хат калыр;
Баш китәр дә ни калыр?
Буында типкән кан калыр;
Буыннан буын чабылса,
Ул чагында ни калыр?
Йорт урнында яу калыр;
Яу чапканда ни калыр?
Ялгыз башы каңгырап,
Куйдай булып маңгырап,
Чүл далада тинтерәп,
Дуадактай хан калыр.
Синең кошың асраган
Котлыкыя би иде.
Ул да булса ир иде,
Бер бабасы яу иде,
Бер бабасы ил иде,
Бер бабасы кол иде,
Бер бабасы би иде,
Аның да өлкән бабасы,
Баба Төкләс Хуҗахмәт*,
Әүлиялар пире иде.
Әй, хан-иям, хан-иям,
Кол язарда[47] би кичәр,
Би язарда хан кичәр,
Аталыгым хакына
Хаталыгын кич,— диде.
Аталыгым хакына
Хаталыгын кичмәсәң,
Бишектә яткан баласы —
Бер кашык каның кич[48],— диде,—
Буында типкән кан калсын,
Баладан кулың тарт,— диде,—
Каныннан аның кайт! — диде.
Җантимер би әйткәндә
Туктамыштай олы хан
Аның телен алмады,
Сүзенә колак салмады,
Ачуы аннан каты иде,
Кичүе аннан кайт[49] иде.
Котлыкайны тоттырды,
Кулына кыл-җеп тактырды.
Бер ягында аскылык[50],
Бер ягында чапкылык[51].
Чапкылыкка мендереп,
Чүң[52] бүкәнгә чүктереп,
Айбалталы Дөрмән бидән
Анда башын чаптырды.
Җантимернең алты угыл.
Алтынчы угыл Кобогыл,
Алып килеп ул аны
Котлыкыя өенә,
Салып куеп бишеккә,
Котлыкыя баласын
Киң кунычлы Җантимер,
Кунычында яшереп,
Үз өенә китерде.

[44] чаңгырак — киез өйнең түбә алкасы.
[45] аталык — хан балаларын тәрбия итүче.
[46] пир — 1) карт. 2) изге кеше.
* Баба Төкләс Хуҗахмәт — төрки эпосларда очрый торган изге, ыру башлыгы образы. Легендар суфи шагыйрь Әхмәт Ясәви белән дә кушылып сурәтләнә.
[47] язу — бирелә, ялгышу.
[48] бер кашык кан кичү — кан хакына кичерү, бик борынгы йоладан калган сүз.
[49] кайт(а) — кайтмыш, ким.
[50] аскылык — дар агачы.
[51] чапкылык — баш чабу урыны.
[52] чуң — зур.

Котлыкыя өенә
Анда Дөрмән би килде:
— Син дөньяда йөргәнче,
Хан боерыгы йөрсен! — дип,
Хан боерыгы йөргәндә,
Атаңа житкән айбалта,
Инде сиңа житсен!— дип,
Кыл муйныңнан үтсен! — дип,
Кобогылга кул салды.
Анда килеп Чакмагыш
Чаңгырагын сындырып,
Чакма чагып үрт салды[53].
Хан боерыгы үтмәде,
Хан боерыгы үткәндә
Тәңредән узып китмәде —
Атасына житкән айбалта
Баласына житмәде.
Балтасы чабып чапмады,
Кыл муйныннан үтмәде.
Ул үләсен бу үлде,
Ханның әйткән сүзе үлде.
Берәве үлде, берәү калды —
Тәңре хөкеме бу иде.
Ул баланы Жантимер,
Итегемнән алдым, дип,
Итегемнән алганда
Илсез-көнсез калдың, дип,
Атын куйды Идегәй*.

## II

## ИДЕГӘЙНЕҢ КОБОГЫЛ ИСЕМЕНДӘ ҮСЕП, ТУКТАМЫШ ХАН САРАЕНДА ТҮРӘ БУЛГАНЫ

Жантимернең алты угыл,
Алтынчы угыл Кобогыл,
Кобогыл дип беленеп,
Үсә куйды Идегәй.
Бер яшендә бер икән,
Баскан жире шил[54] икән.
Ике яшьтә ил булды,
Әйткән сүзе им булды.
Өч яшендә Жантимер
Остаздан китап башлатты.
Дүрт яшендә дан булды;
Фирасәте[55] йортка фаш булды.
Биш яшенә килгәндә
Жантимернең биш угыл,
Бишенә дә баш булды.
Алтысында ат менде,
Жидесендә жай[56] тартып,
Жиде тотам ук атты.
Сигез-тугыз булганда,
Сигез тукмак сындырып,
Туң тимергә кул орды.
Унга житте — ул булды,
Ул ни дисә шул булды,
Чүлгә чыгып басканда
Чүл ярылып юл булды,
Тауга чыгып басканда
Тау сыгылып уй[57] булды.
Унберендә бер булды,
Уйпыксыз чичән[58] ул булды.
Уникегә житкәндә
Алпамыштай ир булды.
«Ир булган соң жир булыйм,
Инсәм жиргә тисен, дип,
Ил игелеген күрсен дип,
Асыраган чал бабам,
Ул игелеген күрсен», дип,
Тауда ятты, тай бакты,
Кырда ятты, куй бакты,
Елкы бакты — кол булды,
Кигәне ямау тун булды.
Идегәй андый ир булды:
Аты юкка — ат булды,
Чүлләгәнгә[59] су булды,
Адашканга юл булды;
Ялгызга — ясак[60],
Жәяүгә — таяк,
Карны ачканга тамак ул булды.
Ундүртенә килгәндә
Ундүрт дауны бетереп,
Түрәсен биргән[61] ул булды.
Унбишенә килгәндә,
Туксан башлы Урданың
Туксан углы бер булып
Айдалага[62] килгәндә,

[53] үрт салу — корган үләнне жирендә яндыру.

* Идегәй — тарихи шәхес буларак 1352-1419 елларда яшәгән әмир, мангыт кабиләсеннән. 20 еллап Алтын Урданы идарә итә. Әмма Чыңгыз нәселеннән булмаганга, хан исемен йөртә алмый. Дастан каһарманы буларак, ул фантастика, идеаллаштыру рухында сурәтләнә: чыгышы — пәри хатыннан, исеме — итек сүзеннән, көрәштә алыплардан да көчле һ. б.

[54] шил — биредә: чокыр, иңкү жир.

[55] фирасәт — зиһенлелек, сизгерлек.

[56] жай — жәя.

[57] уй — уйсу жир.

[58] уйпыксыз чичән — тел остасы.

[59] чүлләү — чүлдагечә сусау.

[60] ясак — биредә: ярдәм.

[61] түрәсен бирү — хөкем итү.

[62] айдала — ачык жир, киң дала.

Алар белән ант тотты.
«Көрәшеп барыңны мин ексам,
Мин барыңа баш, диде.
Көрәшеп берең мине екса,
Улыгыз[63] миңа баш».— диде.
Кушагын алып ту[64] итеп,
Анда мәйдан күтәрде.
Туксан башлы Урданың
Туксан угылы җыелып,
Идегәй белән көрәш тотканда,
Екса ега белмәде —
Чалса чала белмәде —
Барын екты Идегәй;
Еккан береннән тун[65] алып,
Айдалага өйдерде.
Өеп салып Идегәй
Өстенә менеп тайчанды.
— Туктамыш хан тәхетенә
Мин мендем! — дип яр салды[66].
Аннан әйтте Идегәй:
— Анау килгән ак атлы —
Ул Туктамыш хан булса,
Алдында баш имәгез,
Үзе сәлам бирмәсә,
Башлап сәлам бирмәгез...
Туктамыштай олы хан
Акбүз аты — астында,
Лачыны — ияр кашында,
Анда күрде айдала,
Айдалада туксан бер бала,
Туксаны торып яланбаш,
Ул туксанның эчендә
Чалкаеп утырыр бер бала.
Азамат ир Туктамыш
Килә житеп килгәндә,
Ул туксан бер тик торды.
Торып бер баш имәде,
Иңкәеп сәлам бирмәде.
Туктамыштай олы хан
Анда торып моны әйтте:
— Туксан бала — айдала,
Туксан булып бүз бала[67],
Бүз балалык итә белмәдең —
Башлап сәлам бирмәдең.
Ханыгыз булган минме өлкән,
Әллә юкса сезме өлкән?
Анда әйтте Идегәй:
— Башта булсаң син өлкән,
Аякта[68] чыгар без өлкән.
Әйтеп бирсәм ник өлкән, —
Туксан башлы Урданың
Янымда туксан баласы,
Шушы туксан баланың
Яшен санап салсам мин,
Анда чыгар без өлкән.
Өлкәнне өлкән белмәгән,
Башлап сәлам бирмәгән
Ул да булса, хан-иям,
Син икән, әй син икән!
Азамат ир Туктамыш
Анда уңга әйләнде,
Анда сулга әйләнде,
Әйләнеп җавап тапмады.
Хан-сарайга кайтып килгәндә
Башыннан уе китмәде,
Урынында ятты-ятмады,
Өч көн күзен йоммады,
Өч төн йокы татмады.
Айбалталы Дөрмән би,
Дөрмән улы Урман би —
Туксан бала эчендә
Каракчылык кылган би.
Балалар менгән таяк ат,
Аны урлап тотылды...
Өч урлады — котылды,
Дүртенчедә тотылды.
«Түрәсен моның бир».— диеп,
Айдаланың туксан бала
Кулын килеп кушырды.
Урман бинең кашына
Тора килеп Идегәй,
Кулдан кылын тоттырды,
Кылдан кыл җеп тактырды,
Салкын ташка тарттырды,
Туксанның берен җәллад итеп
Анда башын чаптырды.
Хәбәр илгә фаш булды.
Җәллад булган ул баланы
Айбалталы Дөрмән би,
Кулын кулдан каерып,
Туктамыш ханга баш орды.
— Үзем булсам Дөрмән би,
Улым булып Урман би,
Урманымның башын чапкан
Шул баланың канын кайтием[69],
Әй, хан-иям, түрәм би?
Җәллад булган ул бала
Торып тагын аны әйтте:
— Кыр башында айдала,
Айдалада туксан бер бала,
Кобогыл безнең беребез,
Ул да булса башчыбыз,
Моның түрәсен ул биргән,
Аның аргысын мин белмәм.
Туктамыштай олы хан
Идегәйне алдырды:
— Әй, Кобогыл, Кобогыл,

[63] улыгыз — биредә: шул кешегез.
[64] ту (туг) — байрак.
[65] тун — гомумән кием мәгънәсендә (шуннан: эч тун-ыштан).
[66] яр салу — кычкырып әйтү.
[67] бүз бала — буй житеп килгән бала.
[68] аякта — азакта, соңыннан.
[69] кайтием (кай итим) — ничек итим.

Яхшы атаның баласы —
Җантимернең углы идең;
Елкы бактың, куй бактың,
Айдалага ут яктың;
Айбалталы Дөрмән би,
Дөрмән углы Урман би,
Аның башын ник чаптың?
Анда әйтте Идегәй:
— Илендә йөргән каракчы
Өч ат урлап котылса,
Дүртенчедә тотылса,
Синең түрәң буенча,
Дүртенчедә чабылса,
Дөрмән улы Урман би —
Ул да шулай тотылды,
Синең хөкемең буенча
Ул да шулай чабылды,
Аның аргысын мин белмәм.
Туктамыш торып анда әйтте:
— Әй, Дөрмән би, Дөрмән би,
Шушы торган Кобогыл
Туксан бала эчендә
Бәйге тотып дан алган,
Туксанына баш булган,
Түрәсен биреп фаш булган,
Ул ни кылса рас кылган,
Кобогылдай баланың
Түрәсенә чыгалмам.
Кобогылга аны әйтте:
— Әй, Кобогыл, Кобогыл,
Сараемда кал,— диде,—
Өстеңдәге иске тун,
Ул тунынны сал,— диде,—
Яурыннары[70] җактылы[71],
Төймә бавы тартмалы[72],
Ал кара кеш[73] тун бирим,
Бу тунымны ки,— диде,—
Чың-чың иткән чын йөгән
Чыңына борылып караган,
Токымы толпар яралган
Тимгел Чуар ат бирим,
Ул Чуарны мен, диде,
Күн давылбаз[74] так, диде,
Җил карамый җил, диде.
Тотар бавы сум алтын
Асыл шонкар кош бирим,
Күл әйләнә чөй,— диде —
Бер бите айдай балкыган,
Бер бите көндәй салкыган[75],
Болгардаен[76] болкыган[77],
Җофардаен[78] аңкыган,
Айтулы атлы ару[79] кыз
Җаның сөйгән яр булса,
Туеңнан туең кылдырып,
Аны да сиңа бирием,
Куйныңа алып сөй,— диде.
Анда әйтте Идегәй:
— Атың булса багамын,
Утың булса ягамын,
Мин яхшыга яхшымын
Мин яманга яманмын,
Кул биргәннең колымын —
Хезмәтеңдә каламын.
Торып килеп Идегәй,
Хан ни бирсә, аны алды:
Ал кара кеш тун икән —
Кияренә аны алды;
Тимгел Чуар ат икән —
Менәренә аны алды;
Күн давылбаз бар икән —
Төяренә аны алды,
Асыл шонкар кош икән —
Чөяренә аны алды;
Бер бите айдай балкыган,
Бер бите көндәй салкыган,
Болгардаен болкыган,
Җофардаен аңкыган,
Айтулы атлы ару кыз икән —
Туеннан туен кылдырып,
Сөяренә аны алды.
Туктамыштай олы хан
Идегәйнең көнендә
Яу белән даудан котылды.
Сарай дигән калада
Дүрт дәрвазa бар икән,
Икәве бикле булганда
Икәвен ачык куйдырды.
Береннән килгән кәрваны
Береннән чыгып бетә алмый,
Божрасы бөтен алкадай
Боралып килгән мал булды.
Туктамыштай олы хан,
Идегәйдәй ирнең көнендә
Ил казнасы бай булды.
Биләгәне кол булды,
Әйдәгәне мал булды.

---

[70] яурын — 1) калак сөяге, 2) арканың ян яклары.

[71] җакта (якта) — 1) читеш, 2) җиңел өскиием, 3) Тибет сыеры — як булуы мөмкин.

[72] тартмалы — тартыла торган.

[73] ал кара кеш — чем-кара кеш, баргузин. Ал —иң югары сыйфатлы дигәнне аңлата.

[74] давылбаз — бирeдә: барабан.

[75] салку — ялтырау.

[76] болгардаен — бирeдә: болгари — иң яхшы күн күздә тотыла.

[77] болку — 1) елкылдау, 2) ярым ефәк.

[78] җофар — ялтыравык мехлы, хуш исле җәнлек.

[79] ару — бирeдә: сылу.

* Кадыйрбирде — Туктамыш хан улы, 1419 ел тирәсендә Идегәй белән сугышта үлә.

Җәеп салса көмешен —
Җәйрәп яткан күл булды;
Өеп салса алтынын —
Әлдермештәй тау булды,
Ашаганы казы — ял булды,
Эчкәне сары бал булды.
Әмма Идегәй үзе кем? —
Анысын белмәс хан булды.
Кадыйрбирде* яшь солтан,
Туктамыштай хан улы,
Ул биләүдән чыкканда
Хан ханәше Йәникә
Анда игезәк кыз тапты.
Ул кызларны тапканда,
Туктамыштай олы хан
Аналыклар[80] алдырып,
Сан сөяген бактырды.
Хан казнаны ачтырды,
Көрәкләп тәңкә чәчтерде.
Ханнан ханны җыйдырды,
Бидән бине җыйдырды,
Ту бияләр[81] суйдырды,
Утыз көн уен кылдырды,
Кырык көн туен кылдырды,
Олы кызы айга тиң —
Атын куеп Ханәкә,
Кече кызы көнгә тиң —
Атын куеп Көнәкә,
Күңелен анда тындырды.
Туктамыштай олы хан
Куйдан куен суйганда,
Туйдан туен кылганда,
Идегәйнең алганы,
Кагып түшәк салганы —
Айтулы ару кыз икән,
Аның да житеп ай көне,
Ай ярлыкап көн туды,
Ат башыдай ул туды.
Ул туганда Идегәй
Аталыклар алдырып,
Сан сөяген бактырды.
Алтыннан чөмәк[82] уйдырды,
Көмештән төбәк[83] койдырды,
Кыр кураен семәк[84] иттерде;
Кыр курае каты булыр дип,
Алтыннан семәк кылдырды.
Ту бияләр суйдырды,
Туктамышның сансыз кол —
Барын, югын җыйдырды,
Ялгызыма[85] алкыш[86] тисен дип,
Өлкән бер туй кылдырды,
Хан кашында туды дип,
Атын Норадын* куйдырды.
Ул туганда Идегәй
Кам йөргесенә[87] будырды,
Кам йөргесе каты булыр дип,
Калкай[88]-камка[89] түшәтте,
Калкай-камка каты дип,
Сусарына биләтте.
Күкрәге яулы[90] үссен дип,
Качкан яуны кудырды,
Яуда явыр[91] булсын дип,
Яуны бергә кыдырды,
Күңелен шунда тындырды.

## III

## ТУКТАМЫШ ХАННЫҢ ИДЕГӘЙДӘН ШИКЛӘНЕП АНЫ ЭЗӘРЛӘГӘНЕ ҺӘМ КЕМЛЕГЕН БИЛӘРЕННӘН СОРАШКАНЫ

Хан ханәшә Йәникә
Бер көн ханга моны әйтте:
— Карачы, ханым, карачы!
Тауда ятып тай баккан,
Кырда ятып куй баккан,
Елкычыдан би булган,
Түрәң булган Кобогыл
Ни кылганын карачы:
Карачылар[92] эчендә
Булгандаен карачы —
Кадыйрбирде хан углы,
Ул тугандай туй кылып,
Хан углына углын тин куеп,
Ханәкә белән Көнәкә
Кыз тугандай сый кылып,
Хан сыена тиң кылып,
Хан казнаңны ачтырып,
Сан сөяген бактырып,
Туй кылганын карачы!
Чыңгыздан калган кара ту,
Кара туны кулга алып,
Яу кырганын карачы,

---

[80] аналык — тәрбияче хатын

[81] ту бия — колынламаган, кысыр бия

[82] чөмәк — 1) бишек астындагы тишек. 2) аның бөкесе.

[83] төбәк — бирегә: төнге чүлмәк.

[84] семәк — бишек уртасындагы чөй (бала шумасын өчен ике аяк арасына куела).

[85] ялгызым — биредә: ялгыз улым, бердәнберем.

[86] алкыш — яхшы теләк

* Норадын — Идегәйнең улы. Тарихи документларда Нуретдин. 1419 елда үлә

Хан түрәдәй утырып,
Дау кырганын карачы!
Кыл якалы кырык нөгәр[93]
Кылдай булып тартылып,
Хансарайга килгәндә,
Кыл-кыл чәчен үстергән
Кыл түбәле Кобогыл —
Ул килгәнен карачы!
Хан сарае ак ишек,
Иртә булса ачылып,
Туктамыш хан килгәндә,
Ал тәхеткә менгәндә,
Ал тәхетнең аркасы
Алтын егач[94] тутый кош
Сайрап телгә килгәндә,
Кыл якалы кырык нөгәр
Кылдай булып тартылып,
Сәлам биреп килгәндә,
Хан тәхетендә утырып,
Ул сәламне алганда,
Кырык беренче ир булып,
Ялгызына сан булып,
Идегәй килеп кергәндә,
Туктамыштай олы хан,
Үзе дә үзе сизмәстән,
Калкып та калкып торыр
икән урыныннан, ай.
Сынап торган Йәникә
Туктамышка моны әйтте:
— Тауда ятып тай баккан,
Кырда ятып куй баккан,
Елкычыдан би булган,
Түрәң булган Кобогыл
Өрәңгедән каты икән;
Килбәте синнән киң икән,
Коты синнән котлы икән,
Кырык беренче ир булып,
Ялгызына сан булып,
Кобогыл килеп кергәндә,
Хан башыңны кол итеп,
Калкып та калкып тордың
икән урыныннан, ай.
Азамат ир Туктамыш
Ханәшенә үпкәләп әйтте дир:
— Ян йөрәкне яндырып,
Ялганлама син, ханәш,
Сум йөрәкне сулкытып,
Сумгыллама[95] син, ханәш!
Тауда ятып тай баккан,
Кырда ятып куй баккан,
Түрәм булган Кобогыл
Өрәңгедән каты булалмас!
Өрәңгедән каты булганда,
Өрәге миннән каты булалмас!
Килбәте миннән киң булмас!
Килбәте киң булганда
Коты миндәй котлы булалмас!
Чыңгыздан булган затыма
Кол Кобогыл тиң булмас!
Ул килгәндә мин тормам,
Ул килгәндә мин торсам,
Туктамыш хан мин булмам!
Хан сарае ак ишек
Иртә булгач ачылып,
Туктамыш хан ингәндә,
Ал тәхеткә менгәндә,
Ал тәхетнең аркасы
Алтын егач тутый кош
Сайрап телгә килгәндә,
Хан ханәше Йәникә
Хан уңыннан утырып,
Итәген аның инәләп,
Ал тәхеткә чәнечте.
Кырык беренче ир булып,
Ялгызына сан булып,
Идегәй килеп кергәндә,
Туктамыштай олы хан,
Үзе дә үзе сизмәстән,
Калкып тай калкып торганда,
Инәләп куйган итәге
Инеченнән[96] тартылып,
Инә шартлап сынганда
Азамат ир Туктамыш
Үз гаебен аңлады,
Күнеле боздай бузарды,
Күзе курдай кызарды,
Борлыгып[97] карар тапмады;
Урынында ятты-ятмады,
Өч көн күзен йоммады,
Өч төн йокы татмады.
Йәникә ханәш анда әйтте:
— Борлыкмагын, Туктамыш,
Боекмагын, хан-иям!
Елкычыдан би булган
Кобогылның өрәге
Өрәгеңнән өстен булганда
Аны түбән кылаек!
Коты синнән котлы булганда
Аны да котсыз кылаек;
Кобогыл янә килгәндә

---

87 кам йөргесе — юл өчен көйләнгән биләүсә.
88 калка (халка) — монгол.
89 камка — кытай ефәге. Калкан-камка — монгол (ягы) ефәге.
90 яулы — яуга күнеккән, көрәшче рухлы.
91 явыр — яу ире.
92 карачы — министр.
93 нөгәр, нүгәр — өстен сыйныф вәкиле баласының дус егетләре, иптәшләре.
94 егач — агач.
95 сумгыллау — шомландыру мәгънәсендә.
96 инеч — кием эчлеге.
97 борлыгу — борчылу, уйлану.

Сусынга бал куяек,
Сусын балның эченә
Агу-зәһәр коек.
Ул яу микән, ил микән,
Аны шунда сынаек!
Яу булганда Кобогыл
Балны эчеп эчмәстән,
Пычагын алып кынабтан[98]
Безе белән бер болгар;
Ил булганда Кобогыл
Балны эчеп эчмәстән,
Пычагын алып кынабтан
Сабы белән бер болгар.
Аның күнелен сынаек,
Борлыкмагын, Туктамыш,
Боекмагын, хан! — диде.
Хан сарае ак ишек,
Бер ишектә Аңгысын,
Бер ишектә Тыңгысын —
Ике торган шыгавыл[99]
Туктамыш хан колы иде.
Ханның колы булганда
Идегәйнең кулы иде.
Хансарайда ни барын
Алар аша Идегәй
Белеп торган көне иде.
Хан сарае ак ишек,
Туктамыш хан ингәндә,
Ал тәхеткә менгәндә,
Кырык беренче ир булып,
Ялгызына сан булып,
Идегәй килеп кергәндә,
Ханга сәлам биргәндә,
Ирнәве[100] юка сараяк[101],
Сараякның эчендә
Агулап салган сары бал —
Азамат ир Туктамыш
Идегәйгә биргәндә,
Ишектәге Аңгысын
Тынгысынга аңдырып[102],
Башын кылдай игәндә,
Идегәй аны сизгәндә
Билендәге пычагын
Суырып алды кынабтан.
— Алмас пычак сабы алтын
Кайрылмаган майрылсын[103],
Агуы булса бу балның,
Агуын суырып алсын! — дип,
Пычагын балга батырды,
Безе белән дүрт кисте,
Бер болгады, бер эчте,
Аннан әйтте ханәшкә:
— Иләмле икән иләгең,
Куксымый[104] микән чиләгең?..
Аны әйтеп Идегәй,
Хансарайдан борылды.
Идегәй алай киткәндә
Хан ханәше Йәникә
Якасын ертып, аһ итеп,
Ал тәхеткә егылды.
Аннан әйтте Йәникә:
— Аңлаган булсаң, хан-иям,
Кобогылның кылганы —
Сине, мине хурлавы.
Пычагын алып кынабтан,
Безе белән болгавы —
Ил түгел, яу булганы.
Дүрт кисәккә бүлгәне —
«Идел, Җаек суларны,
Иртеш белән Чулманны[105],
Дүрт дәрьялы йортыңны
Дүрт бүләрмен»,— дигәне;
Уртасыннан болгавы —
«Сарай белән Болгарны
Бер болгармын»,— дигәне;
Иләк, чиләк дигәне —
Олы кызың Ханәкә,
Кече кызың Кәнәкә —
Берәвен тиңләп иләккә,
Берәвен тиңләп чиләккә,
«Берәвен углым тиң күрсә,
Аны да аңа сакла»,— дигәне, ай!
Ханәш аны әйткәндә,
Азамат ир Туктамыш
Йәникәгә аны әйтте:
— Ян йөрәкне яндырып,
Ялганлама син, ханәш,
Сум йөрәкне сулкытып,
Сумгыллама син, ханәш!
Яхшы ата Җантимер
Җандай күргән ир иде,
Яу да түгел, ил иде,
Аннан туган Кобогыл —
Ул да миңа яу булмас,
Дау бетереп яу кырган
Кобогыл миңа дау булмас.
Өрәге миннән каты булса да,
Кобогыл миңа үч булмас,
Синең дигән һич булмас,
Һич булмас, ая, һич булмас!
Йәникә ханәш анда әйтте:
— Яхшы атаның баласы
Җантимердән туган Кобогыл,
Ул сиңа яу булмаса,
Ул сиңа үч булмаса.

---

[98] кынаб — пычак, кылыч кыны.
[99] шыгавыл — ишек сакчысы, аудиенциягә кертүче.
[100] ирнәү (әрнәү) — савыт кырые.
[101] сараяк — биредә: савыт.
[102] аңдыру — искәртү, аңлату.
[103] майрылу — бөгелү, кәкрәю.
[104] куксу (кунсу) — исләнү.
[105] Чулман — Кама елгасы.

Мин дигән һич булмаса,
Тугыз ирең чакырткыл,
Ерауларын алдыргыл,
Сынчыларын сынаткыл,
Өлкән бер туй кылдыргыл,
Ул кемлеген сынаткыл,
Анда мәлем[106] кылдыргыл,
Кобогыл дигән кем икән?
Кем икән, әй, кем икән?
Туктамыштай олы хан
Аптырады, әйләнде.
Әйләнеп киңәш тапмады.
Тугыз ирен чакыртты.
Һичбер адәм базалмый,
Ханга җавап бирә алмый,
— Без белмибез,— ди торды,
Туктамыштай олы хан
Тугача бине чакырды:
— «Карангыда юл тапкан,
Хөфия[107] жирдә сүз тапкан,
Яурынын киң какбактай[108],
Айдарың[109] өлкән тукмактай,
Кулында сазы уйнаган,
Телендә сүзе уйнаган,
Анраучым[110] да минем, манраучым[111],
Яхшы көндә жырлаучым,
Яман көндә бузлаучым[112],
Туктар улы Тугача,
Син тулгачы![113] — дип иде.
Инкәеп өйгә кергәчтен,
Кул кушырып торгачтан,
Тулгай биреп аны әйтте:
— Әй, хан-иям, хан-иям!
Син дә белмәс эш икән,
Мин дә белмәс эш икән,
Тугыз батыр агасы
Кыпчак бие бар булыр,
Белсә белер Кыпчак би,
Миннән килмәс эш икән.
Туктамыштай олы хан
Кыпчак бине өндәде:
— Куш, куш пычак асынган,
Кушаллыклап[114] утау[115] тектергән,
Карагай буе ат менгән,
Мең чүкечле тимер тун[116]
Билен бишкә тарттырган,
Күгән[117] салып каптырган,
Сиксән сөям[118] сөңгене
Селтәмәстән кулга алган,
Адәм телен алмаган,
Үз раесы[119] булмаса,
Асу[120] жиргә бармаган,
Мөйтәннән туган Кыпчак би,
Син бер кереп тулгачы!—дип иде.
Мөйтәннән туган Кыпчак би
Инкәеп өйгә кергәчтен,
Кул кушырып, тез бөгеп,
Тез астына бүрек салып,
Уң кулына бал алып,
Тулгамага килеп иде,
Кәмалнын улы Кин Җанбай,
Кыпчакдаен батырны
Кире тартып ым итеп,
Изү кагып[121] утыртты.
Туктамыштай олы хан
Кин Җанбайга анда әйтте:
— Садагын[122] кырык нарга[123] тарттырган,
Хан алдында ат тоткан,
Тамагына алты хат тыккан[124]
Кәмалнын улы Кин Җанбай,
Киңәшен артык би Җанбай,
Киңәшемнен соңы син,
Кин сабамнын[125] куры син,
Кыпчакдаен иремне
Кире тартып утырттын,
Кобогылның асылын
Син тулгачы,— дип иде;
Анда әйтте кин Җанбай:
— Әй, хан-иям, хан-иям!
Син дә белмәс эш икән,
Мин дә белмәс эш икән,
Нугай иле тапмастай
Бу бер авыр төш икән.
Алты сунын буенда,
Камадай башы кашкарган,
Кондыздай төсе саргайган,

---

[106] мәлем — мәгълүм.
[107] хөфия — яшерен, серле.
[108] какбак — 1) ике якка ачыла торган ишек йә капка. 2) капкач.
[109] айдар — кырмый калдырылган чәч.
[110] анрау — 1) кычкыру. 2) ыңгырашу.
[111] манрау — 1) мөгрәү. 2) ухылдау.
[112] бузлау — 1) дөя кычкыруы. 2) кычкырып елау.
[113] тулгау — мактап жырлау йә шигырь әйтү.
[114] кушаллык — киез өй алдына күтәрелеп куя торган япма.
[115] утау — аерым өй, тирмә.
[116] тимер тун — панцырь кием, кобә.
[117] күгән — ачу-ябу өчен металл җайланма.
[118] сөям — аршын чиреге (18 см чамасы).
[119] рае — уе, унае.
[120] асу (ашу) — башка, ят.
[121] изү кагу — бирелә: якадан тоту.
[122] садак — ук-җәя куя торган савыт.
[123] нар — бер өркәчле дөя.
[124] тамагына алты хат тыккан — алты тел белгән.
[125] саба — кымыз йөртә торган күн савыт.

Азаулар теше бушаган,
Чубин аяк[126] ат менгән,
Яшьлегендә ир булган,
Судай булат[127] бәйләгән,
Арыслан, каплан аулаган,
Житмеш жиде ил гизгән,
Йөз туксан биш яшәгән,
Сусар бүрекле, суп[128] тунлы,
Субра* дигән ерау бар,
Кобогылның асылын
Ул белмәсә кем белер? —
Аны әйтеп Кин Җанбай
Тәгъзим[129] итеп туктады.
Кәмалның улы Киң Җанбай
Ханга моны дигәндә,
— Ерау хәзер булсын! — дип,
Хан боерыгын биргәндә,
Хан чабары[130] Байморат
Сыптай соры бүрек киеп,
Билен тартып бер буды,
Кыл койрыгын чарт төеп,
Чапкын атка бер менде,
Юрта-чаба бер жилде,
Алты суның буена
Алты көндә бер житте.
Сыпыра сынлы ерауга
Хан боерыгын белдерде.
Алты суның буенда
Йөз туксан биш яшәгән,
Азаулары какшаган,
Мөчәләре[131] йомшаган,
Чокчытлары[132] бушаган,
Төшәр дә торган янагын
Ак ефәк тартып бәйләгән
Сыпыра сынлы суп ерау
Атка менәр хәле юк,
Ерауны алып килә алмый
Кире кайтты Байморат.
Кәмалның улы Киң Җанбай,
Киңәше өлкән ир Җанбай
Туктамышка аны әйтте:
— Әй, хан-иям, хан-иям!
Сыпыра сынлы суп ерау
Сыбай[133] менеп килмәстер,
Менсә дә килә белмәстер,
Алтынлы көймә[134] жиктергел,
Арышка[135] сият[136] тактыргыл,
Арбага гөлләр түктергел,
Алты кара ат жиктергел,
Күп түшәкләр түшәткел,
Мамык ястыклар ясаткыл,
Ике яхшы нөгәрең ултырткыл,
Килмәс булгаймы икән, әй,
Килмәс булгаймы икән, әй?
Туктамыш хан боерды,
Алты кара ат тоттырды,
Алтын көймәсенә жиктерде,
Арышка сият тактырды,
Арбага гөлләр түктерде,
Күп түшәкләр түшәтте,
Мамык ястыклар ясатты,
Ике нөгәрен ултыртты,
Суп ерауга жилдертте.
Анда Субра ерауны
Биленә пута будырып,
Янакларын бәйләтеп,
Азауларын чиратылган[137]
Чи ефәк белән чырматып[138],
Алтынлы көймәгә менгезеп,
Култыгына жизле таяк сөятеп,
Кулына алмас кундырып,
Күзенә сөнбел сөрттереп,
Үтрек — ялган димәскә
Иман-шәһадәтен[139] искәртеп,
Ханга алып киттеләр.

## IV

# ТУКТАМЫШ ХАННЫҢ СУБРАНЫ ЖЫРЛАТЫП ИДЕГӘЙНЕ СЫНАГАНЫ

Сыпра сынлы суп ерау,
Алып бер житеп килгәчтән,
Иңкәеп өйгә кергәчтән,
Туктамыштай олы хан
Ике утырды, бер торды,
Эчке баштан юл бирде.
Анда өлкән туй ясап,
Күк түбәдәй түбәгә
Ак чатырлар кордырып,
Түрә-картын жыйдырып,
Кобогылны сыныем дип,
Дәрәжәгә чигием дип,
Анда хәбәр кылдырды.
Чапчагы белән сары бал,
Аны да кулдан күтәртеп,
Ак утауга китертеп,
Идегәйне аякчыга[140] куйдырды.
Сары баллар салдырып,
Субрадаен ерауга
Өч тустаган бал бирде.

Балны житеп алгачтан,
Алып бер аны салгачтан,
Чала бурлы[141] булгачтан,
Субра ерау анда әйтте:
— Тим-тим чуар, Тим Чуар,[142]
Чабылган аттан тир чыгар,
Ак мамыктан бүз чыгар,
Акыллы ирдән сүз чыгар;
Йөз туксан биш яшәгән,
Җаны-сөяге какшаган,
Азауларын тездереп,
Ак ефәк белән бәйләгән
Бер алжыган картыңмын!
Миндәй ирдән ни чыгар?
Ни чыгар, әй ни чыгар!
Әйтер идем, телем килмәс,
Әйтмәс идем, күңел тынмас;
Коры үләндә дым булмас,
Коры сөяктә май булмас,
Акыл кайткан картларда
Хан тыңлардай сүз булмас
Хан тотса да халык тотмас,
Халык тотса да хан тотмас;
Халык белән хан бозылышса,
Арадан үтәр юл булмас...
Ерау балны эчкәндә,
Бал йөрәккә төшкәндә
Туктамышка янә әйтте:
— Иделдә булды илле хан,
Җаекта булды ялгыз хан.
Карт бабаң да хан иде,
Алымы синнән аз иде,
Биреме синнән күп иде.
Тулга да тулга, дисез,
Җырла да җырла, дисез,
Ни җырлаек сезләргә?
Ни бирерсез безләргә?
Туктамыш хан анда әйтте:
— Ал кара кеш тун бирим мин сиңа,
Сайлап алып кияр булсаң, ераучым,
Кыңгыраулы күк карчыга бирием,
Күл кыдырып[143] чөяр булсаң,
ераучым!
Арбан да арбан[144] йөгертеп,
Адымын җирдә куыртып,
Аргамак ат бирием,
Камчы тартмый менәр булсаң,
ераучым,
Ханәкәдәй артык ару бар,
Кәнәкәдәй артык сылу бар,
Аны да алып бирием,
Уң җиреңә утыртып,
Аркасыннан сөяр булсаң, ераучым!
Аякчым булып утырган
Анау да торган Кобогыл,
Аның да нинди ир икәнен
Әйтеп тә бирер булсаң, ераучым!
Азамат ир Туктамыш
Субрадаен ерауның
Иңсәсенә кара сәмур[145] тун бирде.
Үз кулыннан бер саряк бал бирде.
Сыпра сынлы суп ерау
Тора бирեп тулгайдыр,
Тулгай биреп сарнийдыр[146],
Сарнийдыр да җырлыйдыр.
Бал бәйрәккә төшкәндә,
Бал белән йөрәк пешкәндә,
Субра аны җырлыйдыр:
— Мин картыңмын, картыңмын,
Күпне күргән картыңмын,
Ни күрмәгән картыңмын?
Башлык та башлык Башлык хан* —
Аны күргән картыңмын;
Аннан соңгы Абыл хан* —
Аны күргән картыңмын;
Аннан соңгы Кара хан* —
Аны күргән картыңмын;
Аннан соңгы Ала хан* —
Аны күргән картыңмын;
Олы бабаң Томавыл* —

126 чүбин аяк — агач аяк (женаза күтәреләсенә ишарә).

127 судай булат — саф корыч, кылычның иң яхшысы.

128 Суп, сып — 1) аек, саф. 2) тун, кием исеме.

* Субра (Сыпра) — төрки халыклар эпосында зирәклеге, алдан күрә белүе белән танылган чичән образы.

129 тәгъзим итү — олылау.

130 чабар — атка менеп чабучы.

131 мөчә — әгъза.

132 чокчыт — яңак сөякләре.

133 сыбай — атка атланган кеше.

134 көймә — өсте ябулы арба.

135 арыш — тәртә.

136 сият — бизәк әйберләре.

137 чирату — кату, берничә җепне берләштерү.

138 чырмату — кат-кат чорнап бәйләү.

139 шәһадәт — иман әйтү.

140 аякчы — савытка (аякка) бал салып торучы.

141 чала бурлы — ярым кызыл (ак белән кызыл катнаш төс).

142 Тим Чуар — Идегәй атының исеме.

143 кыдыру — бетергәнче әйләнеп йөреп чыгу.

144 арбан-арбан — ?

145 сәмур — кеш.

146 сарнау — көйләү, җырлау.

* Башлык хан, Абыл хан, Кара хан, Ала хан — бу исемнәр Алтын Урда ханнары арасында күренми.

* Томавыл — дастан белән бәйле риваятьләрдә Чыңгыз ханның бабасы итеп күрсәтелә.

Аны да күргән картыңмын;
Унике тотам ук тарткан,
Тартканында өзә аткан,
Аннан соңгы ир — Чыңгыз,
Мин аны күргән картыңмын!
Юклаусыз[147] үткән Яучы хан* —
Аны күргән картыңмын;
Баянду хан* — Саин хан* —
Аны күргән картыңмын;
Саин ханнар киткәндә
Аннан калган картыңмын;
Тартып булат бәйләгән
Бура солтан Бәркә хан*,
Аннан калган картыңмын;
Өзәңгесе өзмә алтын,
Бер өзмәсе мең алтын,
Үзбәк дигән хан үткән —
Аны күргән картыңмын;
Тибенгесе[148] тезмә алтын,
Тенибәк* дигән хан үткән —
Аны да күргән картыңмын;
Аргамак бавы сум алтын
Асылбәк* дигән хан үткән —
Аны мин күргән картыңмын;
Ябынчасы җәймә алтын,
Бар шаймані[149] чын алтын,
Манарасы кырык колач,
Җанибәк* дигән хан үткән —
Аны мин күргән картыңмын;
Бирдебәк* тә хан булган,
Биреме синнән күп булган —
Аны күргән картыңмын;
Олы ханнан тугыз хан,
Кече ханнан утыз хан,
Ыгына кергән[150] картыңмын.
Карт бабагыз Туктача*
Аның углы Туйгуҗа*,
Аны күргән картыңмын.
Әй, Туктамыш, Туктамыш,
Тик төнә көн син үзең
Яланаяк, яланбаш
Йөреп торган бала идең,
Бүген син дә хан булдың —
Сине дә күрә торамын,
Үтерә икәнең беләмен.
Үтерсәң җуяр ниемә бар?
Ахирәт өйгә барырмын,
Янә өйгә керермен...
Әҗәл туры килмәсә,
Азраил корык[151] салмаса,
Әле дә булса, Туктамыш,
Синнән калыр картыңмын!
Янә торып янә әйтсәм:
Күп батырны мин күрдем,
Күп батырны мин белдем,
Яшем йөз туксанга килгәндә,
Чыкмаган җан йөргәндә,
Миннән дәуран үткәндә,
Сезгә дәуран җиткәндә,
Утыз тешем беткәндә,
Шунча ирләр күргәндә,
Утыз ханның гомерен үткәндә,
Кобогылдай ирне мин
Бер күрмәгән картыңмын!
Кашларына карасам,
Каләмнән пәйда булгандай,
Күзләренә карасам,
Күгеннән пәйда булгандай;
Каршыннан торып карасам,
Каһәрдән пәйда булгандай;
Буйларына карасам,
Нурдай пәйда булгандай!
Шул читтәге шул угыл,
Аргы угылдан бирге угыл,
Уртадагы озын буйлы,
Ат җилкәле Кобогыл,
Комга беткән[152] коба тал[153],
Корык сайлар Кобогыл;
Кола — алалы күп елкыңны
Куып әйдәр Кобогыл;
Әйләнмәгән күп йортка
Билге текәр[154] Кобогыл;
Боты-савыры[155] көрән ат,
Ботка тартып менәр ат;
Ике саклык турыны
Олауга җайдак алыр ул;
Нугайлының агыр йорт,
Җәяү яткан хәйран йорт —
Ач көзәндәй бөгелеп,
Ач бүредәй чыелдап,
Ач арыслandай үкереп,
Иленә тавыш салыр ул;

---

* Яучы хан, Бәркә хан — Алтын Урда ханнары.

[147] юклау — сыктау, кеше үлгәч, әйтенеп елау.

* Баянду (Саин) — Бату хан (1208—1255), Чыңгыз хан оныгы, Алтын Урданың беренче ханы.

[148] Тибенге — ияр белән тирлек арасына салына торган әйбер.

* Тенибәк, Җанибәк, Бирдебәк — Алтын Урда ханнары.

* Асылбәк — исеме үзгәргән булуы мөмкин, андый исемдә Урда ханы юк.

[149] шайман — 1) корал, җиһаз, 2) ат сбруе.

[150] ыгына кергән — ышыгына кергән.

* Туктача, Туйгуҗа — дастан буенча Туктамышның атасы һәм бабасы. Тарихта: Тун Хуҗа, Котлы Хуҗа.

[151] корык — элмәкле колга.

[152] бетү — биредә: үсү.

[153] коба тал — ак тал.

[154] текү — кадап утырту.

[155] савыр — 1) арка, арт сан, 2) шул төштән ясалган күн.

Кырык көнлек чүлеңә
Айдынлы[156] болак[157] салыр ул;
Иделнең ике ягы кызыл яр,
Ысбадан[158] савыт алыр ул;
Иртеш башы Кара Тун,
Ике арасын куар ул;
Чиксез кузы[159], сансыз куй,
Күп гаскәре туйсын дип,
Суеп казан асар ул;
Батман[160] батман балыңны
Тартып алып эчәр ул;
Алтыннан суккан Ак урдаң,
Көмештән суккан ак ишек,
Төшсә тимер чукмары,
Ишегеңне ачар ул;
Кирәгәнне киртәр ул,
Киртеп урын итәр ул,
Кисмә, кисмә сары алтын
Кисеп улҗа[161] итәр ул,
Кашыклап җыйган малыңны
Чүмечләп чәчеп бетәр ул,
Бар Урдаңны алыр ул,
Тәхтеңә бау салыр ул,
Кола чәчен агартып,
Ике күзең кызартып,
Картайганда илеңнән
Сөрән салып куар ул;
Табаныңны теләр[162] ул,
Телеп кылын салыр ул;
Хур кызыдай күрекле,
Сандугачтай ирекле
Ханәкәдәй аруны,
Кәнәкәдәй сылуны,
Йәникәдәй бикәчне
Ат өстенә мендереп,
Алсу йөзен сулдырып,
Тиген[163] улҗа кылыр ул.
Камчы тияр муйныңа,
Кан соргылыр куйныңа,
Такыя олы башыңны
Кисәр булгай шул угыл.
Инде мин кеше танымам,
Әгәр кеше танысам,
Котлыкыя би улы
Идегәй ул — Кобогыл!

## V

## ИДЕГӘЙНЕҢ ТУКТАМЫШ ХАН ТАБЫНЫННАН ШАҺ ТИМЕРГӘ КАЧЫП КИТКӘНЕ

Субра моны әйткәндә,
Хан җыены зур табын
Бер сулады, бер шымды,
Туктамыштай олы хан
Бер утырды, бер торды.
Җантая биреп утырган
Җанбай анда моны әйтте:
— Идегәй андый ир икән,
Идел йортта бер икән,
Башыннан башы сау булсын!
Хан сынавын иткәндә,
Дәрәҗәгә чиккәндә,
Би түрәләр, агалар
Башыннан балны коячк,
Идегәй андый ир икән,
Берәр аяк куяек!
Анда табын шау килде,
Хан уңыннан утырып,
Хан ханәше Йәникә
Туктамышка аны әйтте:
Идегәй Котлыкыя улы булганда,
Эчеп эче биртелсен,
Башы моннан чыкмасын,
Биләр тоткан ак пычак
Би кулыннан төшмәсен!
Ирене юка сараяк,
Бер аякны баллап бир,
Бер аякны агулап бир!
Ханәш аны әйткәндә,
Хан хәйләсен иткәндә,
Тыңлап торган Тыңгысын
Аңгысынга аңдырды,
Аңдып[164] торган Аңгысын
Ак утауны калдырды.
Бәйдә торган атларның

---

[156] айдын — якты, саф.
[157] болак — сулык, инеш.
[158] ысбадан — ?
[159] кузы — сарык (куй) бәтие, бәрән.
[160] батман — 1) 4 потка якын үлчәү берәмлеге. 2) биек савыт.
[161] улҗа — сугышта кулга төшкән мал, трофей.
[162] табан телү — аяк табанын пычак белән телеп, ярага ат кылы җибәрү. Ул вакытның рәхимсез җәзаларыннан.
[163] тиген — бушка, түләүсез.
[164] аңду — аулау, көтү.

Өзәнге бавын кискәләп,
Идегәйнең Чуар ат —
Аны юлга калдырды.
Тыштан килеп ишеккә
Идегәйгә аны аңдырды:
— Туйга барсаң борын бар,
Борын барсаң урын бар,
Борын бар да, борын кайт.
Атаң белер мәгънәсен!
Тимгел Чуар, Тим Чуар,
Төн катуга көн сиңа,
Кара лачын канатыннан
Әзерләргә йон сиңа.
Миңа вакыт көйләргә,
Сиңа вакыт сөйләргә,
Өстендәге камка тун —
Түрдә утырган биләргә.
Минем атым Ангысын,
Барлагансың соңгысын.
Ангысын аңдып ни әйтсә,
Аны белде Идегәй.
Елкылдаган ак пычак
Биләрнең җиң очында
Чыгып кайтып тора икән,
Аны күрде Идегәй.
Агулап салган сары бал
Җанбай тотып килгәндә,
— Хан саркытын[165] эч! — диеп,
Идегәйгә биргәндә,
Агу салган сараяк
Борынына килеп тигәндә,
— Ай, борнымны кан кылдың! — дип,
Борынын басып Идегәй,
Бусагадан атлады.
Токымы толпар яралган
Тимгел Чуар ат икән;
Өзәңгегә бер тиде,
Җирдә яткан садагын
Иелеп алып бер киде,
Тим Чуарның янбашы
Җиргә ятып бер тиде.
Әйләнеп карап күргәндә,
Идегәй инде юк иде.
Сыпра сынлы суп ерау
Ни булганын аңлады
Тулгай биреп сарнады:
— Ай, бусага, бусага,
Бусаганы бер атлап,
Басар бугай шул угыл.
Тим Чуарын атланып,
Качар бугай шул угыл!
Исән-аман китсә ул,
Шаһ Тимергә җитсә ул,
Шаһ Тимерне алып килеп,
Сарайны харап итәр ул!
Азамат ир Туктамыш:
— Бу ни укыясы[166] булды! — дип,
Тугыз ирен торгызып,
Өй алдына чыкканда
Ни булганын аңлыйдыр...
— Кугын менеп атлан! — дип,
Хан боерыгын биргәндә,
Тузгып йөргән тугыз би
Тугыз атка килгәндә,
Атланыр ягын тапмады,
Баусыз ияр, бапсыз ат[167],
Көбәсен[168] киеп менгәндә
Ияреннән ауган батырлар
Җир басар җир тапмады,
Әйләнеп кире атлады.
Азамат ир Туктамыш
Гайрәтеннән бузарып,
Кин Җанбайга аны әйтте:
— Кәмалның улы Кин Җанбай,
Киңәшен өлкән ир Җанбай!
Котлыкыя би улы
Идегәйне белгәндә
Серен миннән яшерден,
Кулымнан агу биргәндә
Борынын сугып качырдың!
Атланып җиткел артына,
Алып килгел каршыма!
Тугыз иргә аны әйтте:
— Әй, тугыз ир, тугыз ир!
Җанбай белән бара күр!
Алдап-йолдап Идегәйне
Үз кашыңа ала күр!
Алдап-йолдап кашыңа ал!
Кашыңа ал да башын ал!
Тугыз ир китте зарланып,
«Бер алла» дип алданып;
Алар куа килгәндә,
Идел кичеп Идегәй,
Бер тел алып китим[169] дип,
Бер байтирәк төбенә
Ияреп салып төшәнде.
Идегәй анда ятканда
Җантимернең биш улы
Анда килеп кушылды,
Алар анда яттылар,
Ятып казан астылар,
Асып ашап яттылар.
Ул төтенне күргәндә,
Тугыз ир җитеп килгәндә
Тугызы да туктады.

---

[165] саркыт — өлкәннәрдән калган ашамлык, эчемлек (башка берәүгә хөрмәт йөзеннән тәкъдим ителә).

[166] укыя — вакыйга.

[167] бапсыз — әзерлексез.

[168] көбә — тимер кием.

[169] тел алып киту — сүз, яшерен хәбәр алып киту.

Кашына барып житмәде,
Сөйләшергә базмады,
Идегәй анда утырып какшаеп[170],
Тугызыннан курыкмады;
Анда килеп Кин Җанбай
Идел аша һайкарып[171],
Идегәйне чакырып,
Тулгай биреп аны әйтте:
— Ай калкып акрын туадыр,
Ир егет яуда үләдер,
Яудан качкан — ир булмыйдыр,
Ил алдында көн күрмидер.
Егет булып яу башладың,
Башладың да ник ташладың?
Бөркет куган куяндаен
Идел суын кичеп качтың?
Аваз бирде Идегәй:
— Ай калкып акрын туадыр,
Ир егет яуны куадыр,
Ир булсаң суны үткел,
Суны үтеп мине тоткыл!
Аваз бирде Кин Җанбай
— Көчле илгә син яу ачтың,
Батыр булып алга бастың,
Батырлыгың күрсәт, мордар[172],
Суны үтеп нигә качтың?
Аваз бирде Идегәй:
— Таймам баскан юлымнан,
Салмам сөңге кулымнан,
Салмам калкан инемнән,
Яу жыярмын илемнән,
Яуга тиңдәш яу жыйсам,
Идел суын кичәрмен,
Кем батыр да кем куян —
Шул чагында ил күрер...
Җакталы тунның эчендә
Җак җоннары чәчелеп,
Идел аша чакырып,
Җанбай анда тулгайдыр:
— Идегәй би, дусым, ай!
Идегәй би, дусым, ай!
Ханың-иян чакырадыр,
Борылып Идел кичсәнә!
Кайтсана, Идегәй, кайтсана!
Каерылып атың башын тартсана!
Кайтып өең тапсана!
Инсәсе биек Бүз Урдага[173]
Иңкәеп сәлам бирсәнә!
Ирене юка чынаяк,
Хан-иян бал бирәдер,
Ханәшләр тоткан сараяк,
Сурәтмәле[174] сөт-кымыз
Кулыннан коеп бирәдер,
Эчсәнә, Идегәй, эчсәнә!
Иярене кашы алтын,
Йөгәненең башы алтын,
Колагын бездәй кадаган,
Кәгелен[175] кыздай тараган,
«Чу!» дигәндә очкан кошны
Узып китмәгә яраган,
Йөргәндә әзен санаган,
Куш йөрәкле яралган,
Кысыр елан үзәкле,
Култыраудай[176] танаулы,
Сәхтияндай[177] иренле,
Сарымсактай азаулы,
Кыйган камыш колаклы,
Тустагандай тояклы,
Ал өркәче май баскан,
Арт өркәче дөядәй,
Арысландай күкрәкле,
Юлбарыстай сөйрәкле[178],
Чапкан чакта жил житмәс,
Табаны ял ак Тарлан бүз
Ат бирәдер хан-иян,
Менсәнә, Идегәй, менсәнә!
Якасы алтын, җиңе алтын,
Бер күрүе мең алтын,
Итәгеннән җиңе озын,
Кара кештән тун бирә,
Кисәнә, Идегәй, кисәнә!
Тотам бавы сум алтын
Кыңгыраулы күк карчыга бирәдер,
Кул әйләнә чөйсәнә!
Балдагы алтын уй булат[179]
Хан-иян кылыч бирәдер,
Бусана, Идегәй, бусана!
Бер чигәсе[180] мең кызылга[181] бетмәгән
Хан-иян көбә бирәдер,
Кисәнә, Идегәй, Кисәнә!
Идел белән Җаекта
Утыз тугыз хан иде,
Туктамыштай юк иде,
Зәукыңны анда сөрсәнә[182]!
Байталдан байтал бүлеп бирәдер,
Бәйләтеп кымыз эчсәнә!

---

170 какшаю — каршы тору.
171 һайкару — каты аваз салу, һай-һайлау.
172 мәрдар — әшәке, шакшы.
173 Бүз Урда — Ак Урда. Алтын Урданың бер өлеше.
174 сүрәтмә — саба, кымыз савыты.
175 кәгел — атның маңгай ялы, чук.
176 култырау — киемнең озын җиңе.
177 сәхтиян — сафьян, юка, нәфис күн. ✓
178 сөйрәк — үткен караш.
179 балдагы алтын уй булат — балдагы алтын белән уймалап эшләнгән кылыч.
180 чигә — 1) чигеш, 2) төен, 3) чөй, 4) чигәне каплый торган өлеше (көбәнең).
181 кызыл — бирелә: алтын.
182 зәвык сөрү — рәхәтләнү, күңел ачу.

Байтактан[183] байтак бүлеп бирәдер,
Падишаһлык сөрсәнә!

Ханәкәдәй артык ару бар,
Көнәкәдәй артык сылу бар,
Аны да алып бирәдер,
Уң тезенә утыртып,
Чыңгылдашып көлешеп,
Җиң очыннан ялгашып,
Чи[184] төбендә серләшеп
Сөйсәнә, Идегәй, сөйсәнә!

Туктамыштай хан-ияң
Сиңа үпкә кыладыр,
Үз авызыңнан әйтсәнә!

Анда килеп Идегәй
Идел аша аны әйтте:
— Кайтмам да, Җанбай, кайтмамын,
Каерылып атым башын тартмамын,
Инсәсе биек Бүз Урдага
Иңкәеп сәлам әйтмәмен,
Инеп күренеш итмәмен,
Иңсәмә имән чукмар тигәндә!

Ирене юка чынаяк
Хан-иям бал бирсә дә эчмәмен,
Ханәшләр тоткан сараяк,
Сурәтмәле сөт-кымыз
Коеп бирсә дә татмамын,
Иренем җиркә булганда[185].

Ияренең кашы алтын,
Йөгәненең башы алтын,
Колагын бездәй кадаган,
Кәгелен кыздай тараган,
«Чу!» дигәндә очкан кошны
Узып китмәгә яраган,
Йөрегәндә эзен санаган,
Куш йөрәкле яралган,
Кысыр елан үзәкле,
Култыраудай танаулы,
Сәхтияндай иренле,
Сарымсактай азаулы,
Кыйган камыш колаклы,
Тустагандай тояклы,
Ал өркәче май баскан,
Арт өркәче дөядәй,
Арысландай күкрәкле,
Юлбарыстай сөйрәкле,
Чапкан чакта җил җитмәс,
Табаны ялпак[186] Тарлан бүз
Ат бирсә дә менә алмам,
Аувым[187] котсыз булганда!

Якасы алтын, җиңе алтын,
Бер күрүе мең алтын,
Кара кештән тун бирсә,
Кия алмам, Җанбай, кия алмам,
Җилкәмә мөез беткәндә![188]

Тотам бавы сум алтын,
Кыңгыраулы күк карчыга бирсә дә,
Күн давылбаз бәйләнеп,
Кул әйләнә чөя алмам,
Канҗагам кансыз булганда!
Балдагы алтын уй булат
Кылыч бирсә дә буалмам
Билем котсыз булганда.
Бер чигәсе мең алтынга бетмәгән
Көбә бирсә дә кия алмам,
Буем шыксыз булганда.
Байталдан байтал бүлеп бирсә дә,
Бәйләтеп кымыз эчә алмам,
Эчем котсыз булганда!

Байтактан байтак бүлеп бирсә дә,
Падишаһлык сөрә алмам,
Алла үземә бирмәсә.

Ханәкәдән артык аруны
Көнәкәдән артык сылуны
Икәвен бердәй бирсә дә,
Уң җиремнән утыртып,
Чыңгылдашып көлешеп,
Янбашыннан ялгашып,
Чи төбендә серләшеп,
Яныма алып сөймәмен,
Синең тиңсез хан-ияң
Миңа үпкә кылса да,
Инде иңкәеп бармамын,
Үпкә-пинә сүземне
Күкне угым аралап әйтмәсә,
Үз авызымнан әйтмәмен;
Ир булып атка менгәчтен,
Бер юл алып йөргәчтен,
Хатындай булып кайтмамын!

Мин очаем дисәм, канат юк,
Кунаем дисәм, койрык юк,
Барырыма җирем юк,
Батарыма күлем юк,
Алдым биек, артым яр,
Әйләнергә җирем тар!

Бу киткәннән китәрмен,
Шаһ Тимергә җитәрмен,
Шаһ Тимер миңа кул бирсә,
Юртар атка юл бирсә,
Теләгемне мул бирсә,
Бу Идел дигән суыңны
Кайер ком[189] кылып кичәрмен,
Туктамыштай ханыңны
Аягыма бер мөсәххәр[190] итәрмен!

---

[183] байтак — 1) пайтәхет, 2) халык.
[184] чи — 1) камыш, 2) куаклык.
[185] җиркә булу — кибү.
[186] табаны ялпак — зур, яссы тояклы.
[187] аувым — чалбар төбе.
[188] мөез бетү — мөгез үсү.
[189] кайер ком — 1) ургыл (елганың каты аккан урынын) ком итеп, 2) каеры белән.
[190] мөсәххәр — сихерләнгән.

Җанбай янә тулгады:
— Кайтсана, Идегәй, кайтсана!
Каерылып атың башын тартсана!
Алганың Ал Гомәр ханның кызы иде,
Айтулының үзе иде;
Сагынып да саргаер,
Утырып калып картаер,
Салкын төшмәй барсана,
Ни дигәнен белсәнә!
Идегәй торып аны әйтте:
— Кайтмам да, Җанбай, кайтмамын,
Каерылып атым башын тартмамын,
Алганым Ал Гомәр ханның кызы иде,
Айтулының үзе иде.
Сагынсын да саргайсын,
Утыра гына торып картайсын,
Анда гына минем эшем юк!
Ни дигәнен мин белмәм,
Колагым саңгырау булганда!
Кәмалның улы Киң Җанбай!
Киңәше өлкән эт Җанбай!
Арырак торып сөйләче,
Бирерәк килеп тыңлачы!
Атаң кара кеше иде,
Мал биргәннең колы иде,
Анаң кара кеше иде,
Аш биргәннең күңе[191] иде,
Син дә шундый кешесең:
Аш биргәннең колысың,
Мал биргәннең улысың!
Ачма, күзең тишәрмен!
Сөйләмә, телең кисәрмен!
Таңлаеңа[192] тал кыздырып басармын!
Туктамышның тугыз ир,
Син тугызда мин ялгыз,
Дәрманың булса кил, дуңгыз!
Камчы тияр муеныңа,
Кан соргылыр куеныңа.
Бу киткәннән китмәсәм,
Киң чүлләрне үтмәсәм,
Ходай миңа юл биреп,
Шаһ Тимергә җитмәсәм,
Шаһ Тимер миңа кул биреп,
Теләгемне мул биреп,
Кырык түбәгә кырык басып,
Яу булып килеп җитмәсәм,
Нугайлының агыр йорт,
Җаяу яткан хәйран йорт,
Ач көзәндәй бөгелеп,
Ач бүредәй чыелдап,
Ил читеннән кыйкулап,
Ачы сөрән салмасам,
Кола-алалы күп елкыны
Куып әйдәп алмасам;
Боты-савыры көрән ат
Ботка тартып менмәсәм,
Ике саклык турыны
Олауга җайдак алмасам;
Алтынлап суккан урдасын,
Көмештән суккан ишеген
Бер бәрүдә ачмасам;
Кирәгәсен[193] киртмәсәм,
Киртеп утын итмәсәм;
Ханәкадәй аруны,
Көнәкадәй сылуны
Үз түрендә шул вакыт
Түш астыма салмасам,
Туксан башлы урдага
Тунамый[194] ия булмасам;
Угланнарны сатуга
Бер чигара куймасам,
Кырык көнлек юлына,
Кырык көнлек чүленә,
Кырык кое каздырып,
Кырык йорт-ям салмасам,
Әйткәнемне кылмасам,
Мин үчемне алмасам,
Баба Төкләс бабам биргән
Идегәй атым корысын!

VI

# ИДЕГӘЙНЕҢ ЮЛДА КАРА ТИЕН АЛЫП БЕЛӘН СУГЫШЫП, ШАҺ ТИМЕР КЫЗЫ АКБЕЛӘКНЕ ҺӘМ КЫРЫК КОЛНЫ КОТКАРГАНЫ

Идегәй үзе бер иде,
Җантимерның биш улы,
Алтынчысы Идегәй,
Аннан-моннан җыелып,
Бары булды унҗиде.
Чакыр-чокыр юлларны
Басып китеп барадыр,
Аскар[195], аскар тауларны
Ашып китеп барадыр,
Авызлыгын Чуар ат
Бирми китеп барадыр,
Барган саен шәбәеп,
Ярсып китеп барадыр.
«Чу!»— дигәндә чабадыр,

Авызлык белән алышып,
Очкан кош белән ярышып,
Камчы тартмый барадыр.
Идегәйнең йөрүе
Андый каты җил икән —
Җилә алмады унҗиде;
Аның капкан тамагы
Җиде көнгә бер икән —
Түзә алмады унҗиде.
Йөдәүләрен күргәндә,
Анда әйтте Идегәй:
— Әй, унҗиде, унҗиде!
Өчләп салсаң, өч булмас,
Кушлап салсаң, куш булмас,
Бишкә бүлсәң, бүленмәс,
Янгызга яндаш булмасам,
Бередә берен иш булмас.
Әй, унҗиде, унҗиде,
Унҗидебез бер кеше,
Мин кушылгач унсигез,
Унсигезнең бер эше.
Сусадым дип карыкма [196],
Ачыктым дип камыкма [197],
Юл озак дип ялыкма.
Тамагың синең ачыкса,
Тамак табып бирәем,
Киемең синең ертылса,
Кием табып бирәем.
Атың үлсә, түләем,
Үзең үлсәң ни дияем?
Ярен әйтмә, борын әйт,
Мин исәндә үлмәссең!
Үлмәссең дә белмәссең,
Авырлыклар күрмәссең!
Арын әйт тә, бирен әйт,
Барын әйтмә, берен әйт:
Унҗиде дус, сөенче,
Өстең-башың киенче,
Биленә кының буынчы,
Битең-кулың юынчы.
Мин бу кичә төш күрдем,
Яхшылык төш шул булса,
Яхшылыкка юрачы!
Яманлык төш ул булса,
Ул унҗиде кешене
Түгәрәкләп курачы! [198]
Мин бүген кич төшемдә
Алтынлы ияр акбүз ат
Ялыннан тотып менепмен;
Ак шоңкар кош булыпмын,
Күккә таба очыпмын;
Күктә йөргән фәрештә —
Аларга барып сөйләшеп,
Аннан аша очыпмын;
Түбәдә йөргән коңгыр каз
Күк өстеннән алыпмын;
Тур [199] тавына куныпмын,
Түш итенә туепмын.

Ул ни булыр, унҗидем?
Унҗиде ир уйлады,
Уйланып уйпак [200] тапмады,
Юранып юрау тапмады.
Унҗиде ирнең эчендә
Бере күпне күргән карт икән,
Анда торып ул әйтте:
— Әй, Идегәй, Идегәй,
Таяк тайга җиткерер,
Тай дүнәнгә [201] җиткерер:
Дүнән атка җиткерер,
Ат морадка җиткерер.
Алтынлы ияр, акбүз ат,
Төшеңдә тотып син менсәң,
Ат-морадка җиткәнең!
Күккә табан син очсаң —
Йорт алдына чыкканың!
Күктә йөргән фирештә,
Аларга барып сөйләшсәң —
Иреннәр [202] култыклап йөргәнең!
Аннан да ашып син очсаң,
Түбәдә йөргән коңгыр каз
Күк өстендә син алсаң,
Тур тавына син кунсаң,
Түш итенә син туйсаң —
Сине йорттан аерган,
Байтак куган [203] Туктамыш
Туксан башлы Урдасына
Тунамый ия булырсың,
Таҗын-тәхетен алырсың,
Айтулыдай аруны
Янә бер житеп кочарсың.
Идегәй ир әйтте дир:
— Әй, унҗиде, унҗиде,
Атланыек, ятмаек!
Адәм җитмәс кола чүл,
Колач салып атлаек!
Туп-туп баскан, туп баскан,
Тоягы җирне тумырган,
Тумырылып яткан юл булса,

---

[191] күң — кол хатын
[192] танлай — аңкау
[193] кирәгә — киез өйнең аскы рәшәткәсе
[194] тунамый — тере, исән көе мәгънәсендә
[195] аскар (ашкыр) — биек
[196] карыгу — караңгылану
[197] камыгу — боегу
[198] курау — әйләндереп алу, чолгау
[199] Тур тавы — Палестинадагы Синай тавы. Изге санала.
[200] уйпак — уй, уйдырма
[201] дүнән — дүрт яшьлек ат
[202] ирән — ир, дәрәҗәле кеше
[203] байтак куу — пайтәхет тоту, патшалык кылу

Ул юл белән буйлаек,
Утлы-утлы, утлы учак,
Анда житсәк утлаек,
Капкасы калын таш кала,
Анда житсәк кунаек.
Юнәлә бирде унжиде,
Унсигезенче Идегәй,
Туп-туп баскан, туп баскан,
Тоягы жирне тумырган,
Тумырылып яткан юл күрде.
Ул юл белән юл алды.
Утлы-утлы, утлы учак,
Ут урнында көл күрде:
Капкасы ябык таш кала,
Аны юлда бер күрде,
Әйләнеп илен тапмады,
Ясанып [204] явын тапмады,
Ачтан карны юрылды [205],
Сусыздан бөере борылды,
Адәм житмәс кола чүл,
Янәдән йөреп юл алды.
Барып бер күрде таш тияк, [206]
Таш тиякка житкәндә,
Анда тапты соргавыл. [207]
Соргавылны күргәндә
Идегәй ир аны әйтте:
— Әй, соргавыл, соргавыл,
Туп-туп баскан, туп баскан,
Тоягы жирне тумырган,
Тумырылып яткан юл күрдем;
Утлы-утлы, утлы учак,
Анда житсәм, көл күрдем;
Капкасы ябык таш кала,
Аны юлда бер күрдем,
Әйләнеп илең тапмадым,
Ясанып явың тапмадым;
Әй, соргавыл, соргавыл,
Сыргыең [208] бар, соргавыл,
Саркытың юк, соргавыл!
Кузалак арба [209] йөрмәстәй
Каргаулымы иде илегез?
Терәкле арба йөрмәстәй
Тиргәүлеме иде илегез?
Гарип бер юлчы килмәстәй
Хәерсезме иде илегез?
Каласын күрдем анда,
Йортын күрдем юлда,
Тияге монда, үзе кайда?
Жир кемнеке, тел кемнеке,
Дин кемнеке, әйт! — диде.
Анда әйтте соргавыл:
— Балта салсаң башы каерылмас,
Болгап кылыч чапсаң, муйны
биртелмәс.
Баһадирлар батыры,
Алпагытлар [210] Алыбы,
Андый ирне бер белсәң,
Кара Тиен Йосынчы ул булыр;
Тумырылып яткан юл күрсәң,
Ул юл белән син килсәң,
Кара Тиен Алыпның
Йөргән юлы ул булыр.
Сәмаркандта утырган
Әмир Барлас Шаһ Тимер,
Шаһ Тимер кызы Акбеләк,
Акбеләктәй аруны
Ак сарайдан аерып,
Ак беләген каерып,
Ат өстенә мендереп,
Алсу йөзен сулдырып,
Аны да көчләп алып киткән —
Кара Тиен ир булыр.
Каласын күрсәң анда,
Тияген күрсәң монда,
Үзе агар суның буенда,
Кырык бия бәйләтеп,
Кырык дөя әйдәтеп,
Кырык кушчы [211] кол куеп,
Кыз куйнында ятадыр;
Башы беткән артыннан барыр,
Юлы беткән юлыннан барыр,
Күрәсе килгән күреп үләр,
Күрмәгән — исән жиләр.
Соргавыл аны әйткәндә,
Кара Тиен юлыннан
Жилә бирде Идегәй,
Жилә житеп килгәндә,
Агар суның буенда
Жиленен жиргә сөйрәткән,
Сыртын көнгә көйрәткән,
Утыз башлы ак утау,
Аны күрде Идегәй.
Утыз утау янында
Туп-туп бия бәйләгән,
Һу, һу дөя әйдәгән
Кырык кушчы кол икән —
Аны күрде Идегәй.
Унжиде ирен ярга яшереп,
Ялгызы житеп якынлап,
Сәлам биреп Идегәй,
Ул кырыкка аны әйтте:
— Әй, кырык ир, кырык ир!

---

[204] ясану — кораллану.

[205] юрылу — ару, хәлсезләнү.

[206] тияк — биредә: тукталу урыны.

[207] соргавыл — гаскәрнең артта калдырылган күзәтчесе.

[208] сыргый — 1) колга. 2) ниндидер кош.

[209] кузалак арба — бүрәнә ташый торган арба.

[210] алпагыт — алпавыт. Элекке мәгънәсе — алыптан. Көчле сугышчы.

[211] кушчы — кәрванда атларны (дөяләрне) караучы.

Кырыгың кырык ир булып,
Кырык жирдән җыелып,
Үзеңдәен туфракка
Кара башың кол булып,
Күргән көнең ни икән,
Ни икән, әй, ни икән!

Кырыкның бере Колчура,
Колчура карт аны әйтте:
— Кырыгым кырык ир булып,
Кырык жирдән җыелып,
Үземдәен туфракка
Кара башым кол булып,
Күргән көнем ни булсын.
Кол кайгысы бер качмак,
Би кайгысы бер чапмак!
Кара Тиен Алыпның
Кулыннан адәм качмак юк.
Бу Йосынчы гаверне [212]
Адәм заты чапмак юк!
Башы исән икәндә
Безгә ирек тапмак юк!
Ятимнәргә яр булган,
Кол-чурага дус булган,
Аты юкка — ат булган,
Чүлләгәнгә — су булган,
Адашканга — юл булган,
Ялгызга — ясак булган,
Җәяүгә — таяк булган,
Карны ачканга тамак булган
Идегәй ир бар икән,
Аны каян алаек?

Колчура карт аны әйткәндә
Ул кырык ир елады.
Идегәйне аяныл,
Колчура карт янә әйтте:
— Чәчең айдай күренгән,
Битең нурдай түгелгән
Асыл егет икәнсең,
Бу гавернең юлына
Юл яңылып кергәнсең.
Күрәсе килгән — күреп үләр,
Күрмәгән — исән җиләр,
Исән-аман икәнсең,
Ирекле баштан кол булма,
Безнең көнгә тарыма,
Яр ышыктан үт! — диде.

Колчура карт әйткәндә
Идегәй ярга иңмәде,
Яр ышыктан үтмәде,
Ашыкмый басып, ир булып,
Ялгызына сан булып,
Утауга карый юнәлде.

Ул утау да, бу утау,
Уртасында ак утау
Аны күрде Идегәй.

Чаңгырагы киртештән [213],
Увыгы [214] бар көмештән,
Бусагасын бурлаткан,
Кирәгәсен сырлаткан
Утауга килде Идегәй.

Үз башыннан ваз кичеп,
Чуар атыннан төшеп,
Атының башын күтәртеп,
Тирәккә тартып бәйләде.
Шам кылычын [215] кулга алып,
Кара Тиен Алыпның
Кайсындай ир икәнен
Үз күзем белән күрим, дип,
Үлсәм дә алышып үлим, дип,
Ишеге ачык ак утау —
Килеп басты Идегәй.

Анда яткан Алыпны
Күрә калды Идегәй.
Кара Тиен Алыпның
Андый иде ятышы,
Туңып калды «бррык...» итеп
Идегәйдәй Идегәй.
Таудай ятып ишелгән,
Бүксәсе ярдай бүселгән,
Үзе яман килбәтле,
Кайнаткан тимер сыйфатлы,
Күпердәй ята күкрәге,
Бурадай ята беләге,
Колаклары калкандай,
Куллары бар жобадай, [216]
Аяклары маладай, [217]
Йөзенә туры карасаң,
Туры килгән бәладай;
Башы түрдә ятыр,
Аягы ишеккә житеп артыр...
Андый яткан Алыпны
Идегәй күреп сискәнде.
Җаны башына чәчрәде,
«Әҗәлем шул», дип уйлады.

Янә бер торып бакса,
Ак чыбылдык алдында,
Күк чыбылдык авызында,
Ак утауның түрендә,
Тутый коштай таранган,
Аккоштаен ясанган,
Суна коштай сыланган,
Яулыгын кыя [218] салып,

---

212 гавер — кяфер, динсез

213 киртеш — 1) киртелгән, 2) мамонт теше

214 увык — киез өйнең кирәгәсе өстендәге кабыргасын тәшкил иткән бөгелмәле колгалар.

215 шам кылыч — иң яхшы корычтан ясалган кылыч. Шам (Димәшкъ) шәһәренә бәйле.

216 жоба — кап, капчык.

217 мала — тырма.

218 кыя — кыек.

Күргәннең исен алып,
Хур кызыдай утырган
Сылуны күрде Идегәй.
Алтын башлы чаң-кубыз [219]
Кыз кулында чыңгыйдыр:
Кыл кубызын чыңгытып,
Елый биреп җырлыйдыр:
— Атам булды Шаһ Тимер,
Үзем булдым Акбеләк;
Ак беләкле кыз булдым,
Ак беләгем каерылып,
Бер гавергә кол булдым,
Аягымда йоклаган
Алып баба Йосынчы,
Йосынчыга күң булдым.
Анда әйтте Идегәй:
— Атаң булса Шаһ Тимер,
Үзең булсаң Акбеләк,
Ак беләкле кыз булсаң,
Ак беләгең каерылып,
Бер гавергә кол булсаң;
Шул бабага күң булсаң,
Исән-аман коткарып,
Атаңа сине җиткерсәм,
Атаң миңа ни бирер?
Акбеләк кыз анда әйтте:
— Син Алыпны үтерсәң,
Мине исән коткарып,
Шаһ Тимергә җиткерсәң,
Атам сиңа ат бирер,
Атам сиңа тун бирер,
Байталдан байтал бирер,
Байтактан байтак бирер,
Сине миңа ир кылыр,
Чирүенә баш кылыр,
Ни сорасаң — ул бирер!
Акбеләк кыз янә әйтте:
— Чәчең айдай күренгән,
Битең нурдай түгелгән,
Асыл егет икәнсең;
Бу гавернең юлына
Юл яңылып кергәнсең;
Исән-исән икәндә
Исән-аман кит! — диде.
Анда әйтте Идегәй:
— Тимгел Чуар атым бар,
Шул атыма мениem,
Шайман таккан сыным бар,
Шайман тагып килием;
Киерелмәле җәямне
Киереп-тартып күрием;
Карга йонлы кузымны, [220]
Яурын башак [221] угымны —
Аны да тартып килием.
Син Алыпның сул кулын
Күтәреп алып тота тор,
Җиз түшлеген ача тор,
Кизәп бер атып күрием!
Идегәй аны дигәндә,
Тим Чуарын менгәндә,
Шайман тагып килгәндә,
Киерелмәле җәясен
Киереп тартып күргәндә,
Карга йонлы кузын,
Яурын башак угын,
Аны да тартып килгәндә
Акбеләк кыз ул ара
Алыпның кулын күтәрде.
Җиз түшлеге ачылды —
Ак башлы ирнең түше, дип,
Тап йөрәкнең өсте, дип,
Унике тотам сәрпи ук [222]
Идегәй төзәп атканда,
Һавадан килгән сәрпи ук
Йөрәген үтеп Алыпның,
Астында яткан кара таш,
Кара ташны ярып кадалды,
Кара Тиен уянды,
Күпердәй яткан күкрәге
Бер калкынып каранды,
Җибәрмәде сәрпи ук,
Бүксәсен тартып ала алмый,
Канына батып каралды.
«Һай!» — дип анда һайкырып,
Аягын атып бер типте,
Алтмыш терәкле ак утау,
Алтмыш җирдән кубарып,
Алтмыш терәге шарт сынып,
Босагасы бер кубып,
Киезе көлдәй тетелеп,
Буе — буйдин сүтелеп,
Башыннан аша актарды,
Утавы анда «дөрс!» итте,
— Туп-туп баскан атыңның
Тубыгыннан тотып карыйм! — дип,
Бер селтәнде Йосынчы,
Тубыгы кулга төшмәде,
Куйрап барган төтендәй
Койрыгы озын Чуар ат —
Койрыгы кулга уралды,
Йосынчы аны җибәрми
Тотып артка тартканда
Алып та алып калалмый,
Ал аякка бер торды,
Беркая да баралмый.
Алып та алып Чуар ат
Алыпны тартып алмады,
Күпердәй яткан күкрәге
Кара таштан купмады.

---

[219] чаң-кубыз — музыка коралы.
[220] куз — биредә: ук койрыгы.
[221] башак — ук очы.
[222] сәрпи ук — 1) ук очы, 2) кургашын.

Ул суырылып чыкмады.
Кара Тиен Йосынчы
Канына батып аны әйтте:
— Китмә, китмә, Идегәй!
Китә белеп китсәң дә
Белми китмә, Идегәй!
Өч йөз алтмыш яшь күрдем,
Мең-мең казан аш күрдем,
Дугадан җәя мин бөктем,
Арыштан булган ук аттым;
Түмән-төрле хан күрдем,
Берсен хан дип белмәдем,
Берсен күзгә элмәдем,
Туйгуҗа улы Туктамыш
Тукыш [223] белән хан булды,
Аны бар дип белмәдем,
Барлас улы Шаһ Тимер
Шайманы белән шаһ булды,
Аның да кызын күзләдем,
Үзен бар дип белмәдем,
Гүрем кайда — белмәдем,
Үлемем кемнән — белмәдем,
Бакчыдан багым бактырдым,
Фалчыдан фалым ачтырдым,
Сынчыдан сыным сынаттым,
Анда белдем бу эшне:
Мине үтергән ир булсаң —
Ул син икән, Идегәй!
Китмә, китмә, Идегәй:
Ике туган пәри кыз,
Апасыннан мин тусам,
Сеңлесеннән син туган!
Мин дә мин дип масайма,
Син дә тудың пәридән —
Мин дә тудым пәридән —
Аганны атып үтердең,
Белми китмә, Идегәй!
Ана сөтен туя имсәң
Булыр идең миребан [224],
Бауриң каты ярaлдың,
Илне белми үтердең,
Белсәң, агаң мин идем,
Ялгыз калдың, Идегәй!
Ал ияргә сарылып,
Анда әйтте Акбеләк:
— Йорт батыры Идегәй!
Айдай йөзле Идегәй!
Арысландай күкрәкле,
Юлбарыстай сөйрәкле,
Йортны таңга калдырган
Батыр егет Идегәй,
Кулым булсын ястыгын,
Алтын чәчем — түшәгең,
Чебен җаным саклап кал —
Үз куйныңа мине ал!
Асыл егет Идегәй,
Атам сиңа ат бирер,
Атам сиңа тун бирер,
Сине миңа ир кылыр,
Чирүенә баш кылыр,
Китик, китик, Идегәй!
Идегәйнең Чуар ат
Үкерә биреп омтылды,
Йосынчының кулыннан
Үзен тартып ала алмый,
Алын аякка бер торды,
Беркая да бара алмый.
Гырлый бирде Йосынчы:
— Китмә, китмә, Идегәй,
Китә белеп китсәң дә,
Белми китмә, Идегәй!
Туганда кара туганны
Сабынлап юсаң, агармас.
Туганда кыек туганны
Түбыкка салсаң, турaймас;
Туктамыштан җәк күреп,
Шаһ Тимергә барсаң да,
Ул да сиңа турaймас!
Йортыңны талап кан эчеп,
Токымыңны кол итеп,
Йортың йорттан күчереп,
Иленне җирдән аерып,
Үз кулың белән кол итеп,
Мең хәйләгә юл итәр,
Ул да синдәй була алмас!
Аны да белеп кит, Идегәй!
Каргышым аткыйучтан [225] очлыдыр,
Кара таштан үтәдер,
Сине каргап нитием?
Каргамый ак китием,
Инанмасаң сүземә,
Бер билгесен әйтием:
Синең балаң Норадын,
Һич бирмәсен морадың!
Балаң белән ызгышып,
Үң күзең чыксын, Идегәй!
Кара Тиен Йосынчы
Аны әйткәндә җан бирде,
Җанын кулдан җибәрсә дә,
Чуар атның койрыгын
Җибәрмәде кулыннан.
Идегәй атын типкәндә,
Тимгел-тимгел Тим Чуар
Анда алай омтылды,
Анда болай омтылды,
Беркая да бара алмый,
Ал аякка бер торды.
Идегәй аны күргәндә,
Сузылмалы шам кылыч,
Суырып алып кыныннан
Киерелеп артка бер чапты.
Чуар атның койрыгын

---

[223] тукыш — сугыш.
[224] миребан — миһербан, шәфкать.
[225] аткыйуч — укның бер төре.

Анда чабып өзде дә
Ычкынып китте кулыннан.
Кара Тиен Алыпның
Үлгәнен житеп күргәндә,
Яр артына яшеренгән
Унжиде ир житеп килгәндә,
Йосынчының ирләре:
Ясавылдан ясавыл,[226]
Тоткавылдан тоткавыл,[227]
Иравылдан иравыл,[228]
Чагдавылдан чагдавыл,[229]
Бөкәвелдән бөкәвел[230] —
Башына донья тар булды,
Атланып чүлгә таралды.
Туп-туп бия бәйләгән
Кырык кушчы — кырык ир,
Кырыгы бердән жыелып,
Идегәйгә йөгенде.
Колчура карт анда әйтте:
— Кара Тиен Йосынчы
Ир коллаган ир икән,
Андый ирне үтердең;
Мондый кыен күргәндә,
Безгә ирек китердең!
Аты юкка — ат булган,
Чүлләгәнгә — су булган,
Адашканга — юл булган,
Идегәй ир — син икән!
Юлыңда тузан булыек,
Юл догасын кылыек:
Юырткандa юлың булсын,
Юлдашың Хозыр* булсын,
Бәлаң качык булсын,
Юлың ачык булсын —
Бездән теләк ул булсын! — дип,
Анда теләк бирде кырык ир.
Кырык ирдән теләк житеп,
Идегәй анда ир булды,
Елкы малга пир булды.
Койрыгы кисек Чуар ат —
Яңадан койрык үсмәде,
Үскәне дә чак булды.
Әле дә булса Чуар ат
Идегәйнең чапкан билгесе —
Койрыгы чонтык ат булды.
Анда калып Идегәй
Кырык атын жиктереп,
Кырык колачлы кыл аркан,
Кырык үгез тактырып,
Кара Тиен Алыпны
Киезгә салып тарттырып,
Агар суның буена
Гүр казытып күмдерде.
Гүре корган тау[231] булды.

## VII

## ИДЕГӘЙНЕҢ АКБЕЛӘК КЫЗ БЕЛӘН ШАҺ ТИМЕРГӘ БАРГАНЫ

Кырык кушчы — кырык ир,
Кырык толпар ат менеп,
Шаһ Тимергә юнәлде.
Кырык ир житеп килгәчтән,
Иңкәеп сәлам биргәчтән,
Шаһ Тимергә аны әйтте:
— Әй, Шаһ Тимер, сөенче!
Балта салсаң, башы каерылмас,
Болгап кылыч чапсаң, муйны биртелмәс,
Баһадирлар батыры,
Алпагытлар алыбы —
Кара Тиен Йосынчы
Ир коллаган ир булса,
Кызың булган Акбеләк,
Акбеләктәй аруны
Ак сарайдан аерып,
Ак беләген каерып,
Ат өстенә мендереп,
Алсу йөзен сулдырып,
Зурлык[232] беләν алган ул булса,
Ялгызга — ясак булган,
Җәяүгә — таяк булган,
Аты юкка — ат булган
Идегәй дигән ир чыгып,
Кара Тиен Алыпны
Бер атуда үтереп,
Кызыңны кулдан коткарып,
Безне колдан коткарып,
Акбеләктәй кызыңны
Айлык жирдән алып килер.
Әмир Барлас Шаһ Тимер
Акбеләк килә дигәндә
Айлык юлдан каршылап,
Идегәй белән кызымны
Көнгә, жилгә тигезми
Каршыма алып килең, дип,
Өч сан[233] илче жибәрде.
Ул дәрья да бу дәрья,
Бу дәрьядан Сыр-Дәрья.

Сыр-Дәрьядан ары Сәмәрканд:
Өч ай ун көн дигәндә
Житеп килде Идегәй.
Шаһ Тимердәй олы ир,
Утыз биен унга алып,
Илле биен сулга алып,
Дәрвазадан чыгып каршы алды.
Ир өстенә ир күргән
Әмир Барлас Шаһ Тимер,
Идегәйдәй бер ирнең
Килешенә карады.
Тимгел Чуар. Тим Чуар,
Тим Чуары астында,
Салтанатлы [234] ай бүрек,
Бөркет кыяк башында,
Ал караука [235] ак алтын
Кигән туны өстендә;
Унжиде ире кашында,
Яурыны киң олпатлы [236],
Суймырыктай [237] сымбатлы [238],
Арбадан киң күкрәге,
Арыслан юан беләге.
Тим Чуарын уйнатып,
Ашыкмый мәйдан буйлатып,
Шаһ Тимергә килгәндә,
Каршылап атын туктатып,
Иелеп сәлам биргәндә,
Яндаш жирән ат менгән,
Айдай йөзе балкыган,
Көндәй йөзе салкыган
Акбеләк кыз килгәндә,
Атыннан кызны иңдереп,
Кул очыннан житәкләп,
Акбеләкне Идегәй
Шаһ Тимергә кулдан биргәндә,
Әмир Барлас Шаһ Тимер
Иләкләп алтын чәчтерде,
Көрәкләп көмеш чәчтерде.
Идегәйне Шаһ Тимер
Корбагына [239] чакыртты.
Ике чыртан [240] яктырды,
Идегәйне йөгентеп,
Арасыннан үткәрде.
Сорнай-кәрнай [241] уйнатып,
Чаң-чалгылар [242] чалдырып,
Күн давылбаз дыңкытып,
Дум-думбаклар [243] ордырып,
Туй-тамаша кылдырып,
Каласына юнәлде.
Шаһ Тимернең сансыз кол —
Барын-югын жыйдырды,
Ту биялəр суйдырды,
Утыз көн уен кылдырды,
Кырык көн туен кылдырды,
Кырык беренче көнендә
Әмир Барлас Шаһ Тимер
Идегәйне алдырып,
Кайсындай ир икәнен сорады.

Анда әйтте Идегәй:
Энжү дәрьяң* — киң дәрья,
Бәнжү дәрьяң* сай дәрья.
Идел белән Җаектан,
Бөктәргеле [244] Адырдан,
Саралтын суккан Сарайдан,
Әзгәри [245] суккан Болгардан,
Нугайның нурлы йортыннан
Чыгып килә ятырмын.
Үз атамны сорасаң,
Котлыкыя би иде,
Туктамыш хан чапканда
Ул атамнан аерылдым.
Идел эче имин йорт —
Иделемнән аерылдым,
Үз илемнән аерылдым,
Ир Норадын улымнан,
Күз нурымнан аерылдым.
Инде кабул күрмәсәң,
Кайлардан кая китием?
Арбакәш [246] булып су ташып,

---

226 ясавыл — 1) яса (карар) үтәүче. 2) атлы каравыл.

227 тоткавыл — 1) ярлык саклаучы. 2) каравыл куючы.

228 иравыл — 1) алдагы отряд артыннан баручылар. 2) ике яктан бермә-бер сугышларга сайлап чыгарылган батырлар.

229 чагдавыл — сакчы.

230 бөкәвел — 1) ризык татучы (ханга бирер алдыннан). 2) тамгачы. таможня чиновнигы.

* Хозыр (Хозер Ильяс) — дини мифология буенча ярдәмчел. изге пәйгамбәр.

231 корган тау — җирдән өеп ясалган корылма. курган.

232 зурлык — көчлек. җәбер.

233 сан — ун мең.

234 салтанатлы — солтанатлы. дәрәҗәле.

235 караука — тимер кием.

236 олпатлы — мәһабәт. килбәтле.

237 суймырыктай — ?

238 сымбат — сыйфат. буй-сын.

239 корбак — ?

240 чыртан — ?

241 сорнай-кәрнай — өреп уйный торган музыка кораллары.

242 чаң-чалгы — чалып (чиртеп) уйный торган музыка кораллары.

243 думбак. давылбаз — кагып уйный торган музыка кораллары.

* Энжү дәрья — Аму-Дәрья.

* Бәнжү дәрья — Сыр-Дәрья.

244 бөктәрге — 1) саз карчыгасы. 2) ак койрыклы бөркет.

245 әзгәри — Болгарда сугылган акча.

246 арбакәш — арба йөртүче.

Әукатемне [247] итием.
Анда әйтте Шаһ Тимер:
— Чын тарханым [248] син булып,
Корбым [249] булсаң ни булгай?
Минем өчен чабылган
Котлыкыя ир иде,
Аннан калган бер угыл,
Ул син икән, Идегәй,
Синдәй ирне санламый,
Туктамыштай каба [250] хан
Үзе миңа биргәндә,
Үз янымда кал,— диде.
Ягасы алтын, җиңе зәр, [251]
Хасиятле кара тун,
Аны өстеңә ки,— диде.
Син булырсың би,— диде.
Дау булганны өз,— диде.
Яу булганны кыр,— диде.
Йосынчыны үтереп,
Акбеләктәй кызымны
Коткарып калган син икән —
Аны да сиңа бирием,
Кабул күреп ал,— диде.
Анда торып Идегәй,
Шаһ Тимер ни бирсә, аны алды.
Идегәй анда би булды,
Шаһ Тимер аңа ил булды,
Әмма Идегәй үзе кем? —
Анысын белмәс ир булды.

## VIII

## ТУКТАМЫШ ХАННЫҢ НОРАДЫННЫ МӘСХӘРӘЛӘП СӨРГӘНЕ

Идегәйнең көнен белгәндә,
Азамат ир Туктамыш
Көннәрдән бер көн әйтте дир:
— Әзәлдән [252] дошман Идегәй,
Ул да миннән качты, күр!
Тугыз ирем базалмый,
Әйләнеп кире кайтты, күр!
Сәмәркандта утырган
Аягы чонтык Шаһ Тимер
Елдан елга яу булды,
Мин дә аңа яу булдым.
Асылсыздан туган Тимер би
Сәмәркандка шаһ булса,
Унике йортка баш булса,
Янә мин шаһ дип белмимен.
Ярлыгым белән тамгамны
Янә бер аңа бирмимен,
Кәмалнең улы Киң Җанбай —
Киңәш биргән бием бар;
Мөйтәннән туган Кыпчак би —
Андый батыр ирем бар.
Сансыз татар урдам бар:
Алтын егач тәхетем бар,
Шаһ Тимер янә яу булса,
Алышырга дәртем бар!
Әзәлдән дошман Идегәй
Ул да миннән киткәндә,
Сәмәркандка җиткәндә,
Асылсыздан туган Шаһ Тимер
Шатланып кабул иткәндә,
Идегәй белән янә бер булса,
Янә миңа яу булса,
Чыңгыздан булган затыма
Икесе бер тиңалмас.
Ике яман берекмәс,
Берексә дә ил алмас.
Индеге көн Идегәй
Шаһ Тимергә би икән,
Аның да калган ялгызы —
Норадын дигән улы бар.
Ул угылын нитәем?
Ул араның эчендә
Үсә бирде Норадын,
Бүз угланнар янында
Йөрә бирде Норадын,
Токымы Чыңгыз угланнар
Норадынны күргәндә,
Буйларын басып буй үскән
Ир буласын белгәндә,
Ачуыннан агарып,
Көнчелектән күгәреп,
Яникә ханәш сүз салды:
— Ханыбыздан баш тартып,
Казак киткән [253] Идегәй —
Аның улы Норадын
Арабызда көн итә;
Ханәкәгә кул сала,
Хан ыруын тиң итә:

---

[247] әукать — азык
[248] тархан — салымнардан азат феодал
[249] корбы (кореб) — якын дус
[250] каба — кара, тупас
[251] зәр — ука, ефәккә тукылган алтын
[252] әзәлдән — мәңгелек
[253] казак киту — качак булып киту

Көнәкәгә кул сала,
Кыз-җуанга мәел итә;
Туктамыштай зур ханнан
Бабамның канын алсам дип,
Атамның үчен алсам дип,
Урнына хан булсам дип,
Үтенеп алып ут ягып,
Кам йөргесен бәйге итәр.
Азамат ир Туктамыш
Норадынны чакыртты,
Чакыртып алып янә әйтте:
— Бай баласы байга охшар,
Би баласы бигә охшар,
Балабан[254] шоңкар кошка охшар,
Идегәй миннән баш тартып,
Шаһ Тимергә киткәндә
Аннан калган Норадын —
Аның көне кемгә охшар?
Анда әйтте Норадын:
— Әй хан-иям, хан-иям!
Бай баласы байга охшар,
Бәйләнми үскән тайга охшар;
Би баласы бигә охшар,
Биек-биек тауга охшар;
Хан баласы ханга охшар,
Ояда шоңкар кошка охшар,
Туктамыш хан барында
Җисер[255] хатын, ятим ул,
Аксак, гарип, ярлы, кол —
Аларның көне кемгә охшар?
Йортны бозды йорт биең,
Илне бозды ил биең,
Бозгынлыкта калган ил —
Аның көне кемгә охшар?
Кичәге киткән атамның
Менгәне кеше аты икән,
Сауганы кеше биясе,
Җиккәне кеше дөясе.
Алты айлык агыр йортыңнан
Урын тапмый, атамның
Киселеп китте җөясе[256],
Аның көне кемгә охшар?
Әй, хан-иям, хан-иям,
Маңлайдан аккан ачы тир
Табанга житсә, тоз булыр,
Колакка төшкән суык сүз
Йөрәккә житсә, боз булыр,
Агач башын җил борыр,
Адәм башын сүз борыр,
Бар мактанса — табылыр,
Юк мактанса — чабылыр.
Би бигә ялыныр,
Бинең күңеле алыныр,
Аның көне кемгә охшар?
Көнем сиңа төшкәндә,
Минем көнем кемгә охшар?
Әй, хан-иям, хан-иям!
Кол сагышын би белмәс,
Би сагышын хан белмәс,
Ярлы көнен бай белмәс,
Яуның серен яу белмәс,
Ач кадерен тук белмәс;
Сырхау кадерен сау белмәс,
Ым белмәгән тел белмәс,
Тел белмәгән ил белмәс,
Зир[257] кадерен зирәкләр белер,
Ир кадерен ирәннәр белер,
Күп яшәгән ни белер,
Күп кадырган ул белер!
Норадын алай дигәндә,
Туктамыштай олы хан
Ике утырды, бер торды,
Янына алып Җанбайны,
Анда киңәш-уй корды:
— Котлыкыя би икән —
Аның башын чапканда,
Идегәйне чабып чабалмый,
Бер башыма бәла алдым;
Кобогыл дип белгәнем
Ул Идегәй булганда,
Җитеп башын алыйм дип,
Үз башыма яу алдым.
Идегәйнең ир углы
Инде калды Норадын,
Норадыннан куркамын.
Бүгеннең таңдагысы бар,
Таңдагының кыямәте бар,
Җисер хатын, ятим ул,
Аксак, гарип, ярлы, кол —
Шуларның бер шәре[258] бар;
Норадынга кул салсам,
Шул шәреннән куркамын.
Шаһ Тимердәй явым бар,
Ул явымнан курыкмыйм;
Идегәй белән давым бар,
Ул давыннан куркамын;
Баласын исән калдырсам,
Бу давыннан куркамын.
Җанбай анда моны әйтте:
— Норадынга кул салсаң,
Идегәй сиңа яу булыр;
Норадын башын буш куйсаң,
Үз башыңа дау булыр.
Аның башын алмагын,
Йортыңда да тотмагын,
Атаңа миннән кит, диеп,
Исән-аман җит, диеп,
Җабага тайга мендереп,
Чүл-далага озаткыл;

---

[254] балабан — лачынның бер төре.
[255] җисер — ятим, тол.
[256] җөя — биредә: эзлеклелек, нәсел җебе
[257] зир (зәр) — 1) алтын, 2) өс, җир өсте
[258] шәр — явызлык.

Сау калса үзеннән,
Сау калмаса, синнән калмыйдыр.
Җанбай алай дигәндә
Азамат ир Туктамыш
Унике биен чакыртты:
— Алты айлык йортымны
Бер каләмнән үткәргән
Диван бием[259] Байназар,
Тиң кордашым, кош бием,
Кушагың алтын Кушназар,
Норадындай баланың
Киемнәрен сез бирең!
Алангасар Алман би,
Айбалталы Дөрмән би,
Норадындай баланың
Бар шайманын сез бирең!
Кенәгәсле Кәрим би,
Уймавыттай Үмәр би,
Норадындай баланың
Дирбиясен[260] сез бирең!
Янгурадай йорт бием,
Илтәрәстәй ил бием,
Норадындай баланың
Менәренә аты юк,
Качса, котылып китәрдәй,
Куганда куып җитәрдәй
Аргамак сайлап сез бирең!
Әйткәнемне тиз бирең!

Туктамыш хан анда әйтте:
— Һай, Норадын, Норадын,
Алла бирсен морадың!
Атаң икән Идегәй,
Башлы урдамнан баш тартып,
Башын алып киткәндә
Башың исән калдырдым;
Менәреңә ат бирдем,
Кияреңә тун бирдем,
Барыр юлың буш куйдым,
Атың арык, үзең яшь,
Ерак йортка җиләсең,
Атаңа барып җиткәндә
Бездән сәлам диярсең!
Анда атка менгәндә
Уңнан-сулдан «һай» салып,
Хан янында ялчылар
Ябага тайны органда
Кузгалып китте Норадын,
Чыгып китте каладан.
Тибенгесен бер тибеп,
Саурыга камчы органда
Алып качты ябага.
Өч көн үткән арада,
Дүртенче көн булганда,
Идегәй менгән Тим Чуарның
Токымы икән бу Сарала!

## IX

## НОРАДЫННЫҢ АТАСЫНА КИЛГӘНЕ, ИДЕГӘЙНЕҢ ШАҺ ТИМЕР БЕЛӘН БЕРЛЕКТӘ ТУКТАМЫШ ХАНГА ЯУ ЙӨРГӘНЕ

Бу дәрья да ул дәрья,
Ул дәрьядан Сыр-Дәрья;
Саралатын йөздереп
Сыр-Дәрьяны чыкканда,
Атның ялы ятканда,
Кабаклары катканда,
Атка салган ак башлы ияр
Ак күбеккә батканда,
Ай да ун көн дигәндә,
Сәмәркандтай шәһәргә
Җитеп килде Норадын.
Шаһ Тимердәй әмирнең
Биектән суккан каласы,
Бизәкләп суккан капугы[261]
Монарланып[262] күренде.
Капуда торган тоткавыл,
Тоткавыллар белән сөйләшеп,
Үтеп керде Норадын.
Идегәйнең ак сарай,
Җитеп килде Норадын.

Азамат ир Идегәй
Норадынны күргәндә,
— Норадын углым, синмесең?— дип,
Атыла килеп алдына,
Күзләреннән үбеп улының,
Маңлаеннан искәп сөйгәндә,
— Ялгыздан ялгыз киләсең,
Йөргән юлың аманмы?
Алтай[263] язлар аманмы?
Замандашым, тиңдәшем,

---

[259] диван би — хан канцеляриясе башлыгы
[260] дирбия — җиһаз, әсбап
[261] капуг — капка
[262] монарлану — көннең рәшәләнеп, мираж кебек торуы
[263] алтай — 1) алты ай, 2) кызыл төлке, 3) төлке тун

Тиң-корбылар[264] аманмы?
Аны да сорап Идегәй
Хәл-әхвәлен белгәндә,
Анда әйтте Норадын:
— Идел белән Җаектан,
Сарай белән Болгардан,
Нораның кара комыннан,
Уел белән Кыелдан,
Каргалы, Эләк[265] буеннан,
Татарның тулы йортыннан
Сиңа килдем, атаем!
Айтулыдай анамнан,
Комкәнт дигән каладан,
Сине белгән илеңнән,
Сары Тауны җәйләгән
Кәкре кубыз, ай мөез,
Китмән койрык куеңнан,
Маң-маң баскан, маң баскан,
Дүрт аягын тиң баскан,
Өркәчләрен май баскан,
Кабырга озын, карыны киң
Каранар дигән дөяңнән
Сөенче әйтеп киләмен.
Анда әйтте Идегәй:
— Идел дигән ирнеңнән,
Илемне күргән күзеңнән,
Уел дигән авызыңнан,
Татарны әйткән телеңнән,
Сары Тау дигән сүзеңнән
Миндәй атаң әйләнсен[266].
Азамат ир Идегәй
Хәл сорашып белгәндә,
Норадынның ат-тунын,
Бар шайманын күргәндә,
Туктамышның нияте
Ни булганын аңлады.
Норадынга өй бирде,
Үз кулыннан сый бирде.
Менәренә ат бирде,
Уеннан уен калдырып,
Норадынга ял бирде,
Айлар-көннәр үткәчтән,
Норадынны чакыртып,
— Газизем, сөйлә,— дигәндә,
Ир Норадын аны әйтте:
— Ат сөренми җир танымас,
Ир сөренми ил танымас,
Иделдәй илем барында
Шаһ Тимер иле тартмыйдыр,
Һич күңелемә ятмыйдыр,
Таңы таң булып атмыйдыр,
Суы су булып акмыйдыр.
Анда әйтте Идегәй:
— Әй, Норадын, Норадын,
Нидер синең морадың?
Анда әйтте Норадын:
— Әйтсәм әйтим морадым:
Ат та туйган җиренә,
Ир дә туган җиренә,
Кендек каным тамган җир —
Көмеш сулы Идел булганда,
Сине дә куган Туктамыш,
Мине дә куган Туктамыш,
Бабамның башын чаптырган
Әзәлдән яу Туктамыш,
Туктамышта кигем[267] бар,
Кик алганда кинә[268] юк,
Үч алганда үпкә юк,
И газизем, и атам,
Каерылып атны тартыек,
Ана Иделгә кайтаек,
Идел болында ятыек,
Ул Туктамыш хан икән,
Ук-садак билдә булганда,
Угыбызны анда атаек,
Ата-ата ятаек!
Анда әйтте Идегәй:
— Әй Норадын, Норадын,
Сагынсам да илемне,
Санласам да санымны,
Туктамыштай бер ханны
Хан итеп белгән ул илгә
Янә бер кире кайтмыймын.
Илемә ул хан булганда
Ил күңелемне тартмыйдыр,
Таңы таң булып атмыйдыр,
Суы су булып акмыйдыр.
Анда әйтте Норадын:
— Әй, газизем, әй атам,
Сарай белән Болгарның,
Чулман белән Нократның[269]
Иделдәге илеңнең
Халкы ханнан өректе инде,
Татарың белән нугаең
Ханга каршы купты инде,
Идегәй безгә кайтсын дип,
Башыбызда торсын дип,
Сөт белән юган кылычын
Кан белән янә юсын дип[270],
Болгариның Бодайби
Артымнан куа җитеп әйтте инде,
Әй газизем, әй атам,
Каерылып атны тартыек!
Идел чыгып ятыек!
Ук-садак билдә булганда,

---

[264] тиң-корбы — дус-иш, тиңнәр.
[265] Нора, Уел, Кыел, Каргалы, Эләк — җир-су, урын исемнәре.
[266] әйләнү — борынгы йола: шатлыктан кеше тирәсеннән әйләнеп чыгу.
[267] кик — үч.
[268] кинә — гаеп.
[269] Нократ — Вятка елгасы.
[270] кан белән юу — кан үче алу.

Ил-халык бергә булганда,
Угыбызны анда атыек,
Ата-ата ятыек!
Анда әйтте Идегәй:
— Газизем, асыл икәнсең,
Рас сөйләрсең, морза улым,
Сарай белән Болгарның,
Чулман белән Нократның,
Иделдәге илемнең
Халкы ханнан өреккәндә,
Өркеп мине көткәндә,
Без дә анда булалык,
Ил сүзен тоткан ир булыр,
Ил сүзен кабул кылалык! [271]
Анда килеп Идегәй
Шаһ Тимергә сүз салды:
— Атам Котлыкыя би икән —
Аны суйган Туктамыш,
Йортым йорттан күчереп,
Аны куган Туктамыш,
Идел белән Җаектан,
Бөктергеле Адырдан,
Саралтын суккан Сарайдан,
Әзгәри суккан Болгардан,
Татарның тулы йортыннан
Мине куган Туктамыш;
Индегенең көнендә
Норадын углым булганда,
Аны да илдән куганда,
Чулман белән Нократның,
Иделдәге илемнең
Халкы ханнан өреккәндә,
Өркеп мине көткәндә,
Илеңдә артык калалмам,
Рөхсәт боер, әй әмир,
Иделгә кире кайтаем,
Халкым җыеп алаем,
Туктамышның өстенә
Туп туплап ук бараем;
Угымны анда атаем,
Ата биреп ятаем.
Әмир Барлас Шаһ Тимер
Идегәйгә аны әйтте:
— Рас әйтерсең, Идегәй би.
Атаң Котлыкыя би иде,
Аны да суйган Туктамыш,
Йортың йорттан күчереп,
Сине дә куган Туктамыш;
Норадындай углың булганда
Аны да куган Туктамыш;
Сыр-Дәрьяның сыртыннан
Сәмәркандтай калама
Баса килгән Туктамыш;
Минем кулдан тай алып,
Атка менгәч мас булган, [272]
Минем кулдан нан җиеп, [273]
Такка [274] менгәч мас булган
Туйгуҗа улы Туктамыш,
Әзәлдән сиңа яу икән,
Әзәлдән миңа яу булды,
Кайта чапсам көн килде.
Синдәй ирем барында
Ул көн миңа бер килде.
Шул Туктамыш өстенә
Кыргын [275] җыеп бараем,
Әзәлдән кигән кигемне
Туктамыштан алаем.
Аны әйтеп Шаһ Тимер
Сырлатып хат яздырды.
Ерагына хат юллап,
Якынына ат юллап,
Чирүен җыеп алдырды.
Уң кулында — Ир Каплан,
Сул кулында [276] — Кыйгырчак,
Маңлай башы [277] — Идегәй,
Кыргын юлга юнәлде.
Боларып яткан күлләрнең
Балыгын алды дулатып,
Сыланып яткан суларның
Суларын эчте болгатып;
Күгәреп үскән куксавыл [278] —
Куксавылны кыдырып,
Кыларып [279] үскән кау кылган —
Кау кылганны [280] кыдырып,
Килә бирде яу кыргын.
Чүлләгәнгә су булып,
Адашканга юл булып,
Арыган юлда калдырмый,
Аксак атны маермый,
Сансыз чирү, кара яу —
Кылавыз [281] булып, юл башлап,
Идегәй аны апкилде.
Энҗү дәрья — киң дәрья,
Бәнҗү дәрья — сай дәрья,
Аннан ары Актүбә,
Аннан ары тар Җаек,
Мәкергә оста Шаһ Тимер,
Анда килеп туктады.

---

[271] булалык, кылалык — була алыр идек, кыла алыр идек мәгънәсендә.

[272] мас — исерек.

[273] нан җию — ипи ашау.

[274] так — тәхет. Алга таба: хан тагы — хан тәхете.

[275] кыргын — кыручы, кисүче яу.

[276] уң кул, сул кул — гаскәрнең уң, сул флангылары.

[277] маңлай башы — гаскәрнең алда баручы өлеше, авангарды.

[278] күксавыл — далада үсә торган каты агач, чавыл.

[279] кыларып — кыл шикелле булып.

[280] кау кылган — кипкән кылган.

[281] кылавыз — юл күрсәтүче.

Чүлдән килгән чирүе
Жаектан килеп су эчте —
Жаек кайтып бер төште.
Куышын корып кунышлап,
Кыргын анда мәл тапты.
Жаектан ашу Актүбә,
Актүбәгә менгәндә,
Идел-йортын күргәндә,
Туфрагын үбеп ярсулап,
Идегәй анда тулгады:
— И Идел Йорт, Идел Йорт,
Идел эче имин йорт,
Атам кияү булган йорт,
Иелеп тәзем[282] кылган йорт;
Анам килен булган йорт —
Иелеп сәлам әйткән йорт;
Кендегемне кискән йорт,
Керем-коңым юган йорт,
Бия сауган сөтле йорт,
Кымыз эчкән котлы йорт;
Идел-Жаек арасы
Елкы белән тулган йорт,
Казан-Болгар арасы
Кала белән тулган йорт,
Ашлы белән Ибраһим*
Ашлык белән тулган йорт,
Ата-бабам тоткан йорт,
Котлы булсын туган йорт!
Айдан якты нәрсә юк,
Кара болыт басмаса,
Адәм гарибе шул булыр —
Кайтып илен тапмаса!
Мин барамын, барамын,
Үз илемне аламын;
Агачы айбар[283] күренгән,
Маллары суга иелгән,
Яфраклары калкадай,
Ботагы көмеш алкадай,
Алмасы бар йөрәктәй,
Балтырганы беләктәй,
Син түгелме туган йорт,
Ач тамагым туйган йорт?
Котлы булсын туган йорт!
Утыра идек жайлашып,
Күк тугайга бия бәйләшеп,
Колын-тайдай уйнашып,
Иязәшеп утырып,
Иделдән саба тутырып,
Тиң-кордашка кушылып,
Монда кымыз эчкән без идек.
Яфракларың саргаеп,
Күк тугаең каралып,
Хан Туктамыш кулында
Син ни булдың, туган йорт?
Синдәй илдән аерылган
Мин ни булдым, туган йорт?
Оч-албаты[284] өлкән су
Унике йортны сугарган,
Суы түмен салмаган,
Эчмәгән жан калмаган
Идел белән Жаегым,
Чулман белән Нократым,
Синдәй йортым булганда
Сине миннән аерган,
Мине синнән аерган,
Бай йортымны кол иткән,
Тук йортымны ач иткән
Туктамышны чабыйм дип,
Үз йортымны алыйм дип,
Сиңа килдем, туган йорт!
Идегәй килә яткапда,
Ябырылып килгән яу кыргын
Жаекка ятып ял тапканда
Туктамыштай олы хан
Сараенда ятып төш күрде,
Уянып уйлап бакканда
Юранып юрау тапмады.
Төш юраучы карт хужа
Сараенда бар икән,
Аны чакырып алдырып,
Туктамыш хан аңа әйтте:
Әй юраучы, юраучы,
Мин бу кичә төш күрдем:
Алдымда барган бүз куян,
Бүз куянны качырдым.
Иделнең буе ашлы су,
Ашлы суга ат салдым,
Акбүз атым батырдым,
Бер чак аннан котылдым,
Өйгә кайттым, туй бирдем,
Тулай йортны жыйнадым.
Алтын ләнгәз[285] эчендә
Оча[286] белән түш итен
Мин табынга чыгардым.
Ул дигәндә, бу дигәй:
Кыелып төшеп бүз кыйгыр,[287]
Оча белән түш итен
Кагып алды кулымнан.
Ишек алдым байтирәк,
Байтирәгем егылды;
Туксан икән яфрагы —
Туксаны да коелды.
Баулы торган кара кош
Өркеп очты һавага.
Далбай[288] алып чакырдым,

---

[282] тәзем — тәкъзим, олылау.
* Ашлы белән Ибраһим — борынгы болгар шәһәрләре.
[283] айбар — биек.
[284] албат — ?
[285] ләнгәз — бирелә: ләгән, поднос.
[286] оча — арканың билгә хәтле өлеше
[287] кыйгыр — карчыганың бер төре.
[288] далбай — кош чакыра торган быргы.

Әйләнеп кошым кайтмады,
Һавалап китеп юк булды —
Ул ни булыр, әй хуҗам?
Төш юраучы карт әйтте:
— Кугалы[289] күл, Ку күлне[290]
Кусыз булыр дип мидең?
Чагалалы[291] Чалкар күл [292],
Чаңсыз[293] булыр дип мидең?
Идегәй исән икәндә
Җунҗыгалы[294] башыңны
Даусыз булыр дип мидең?
Ул[295] күрәсең булмасын!
Алдыңнан качкан бүз куян,
Бүз куянны качырсаң,
Чыңгыздан калган дәүләтең —
Ул китәре булмасын.
Иделнең буе ашлы су,
Тоныкк булса — ул кайгы.
Акбүз атың батырсаң,
Атыңны тоткан балчыгы —
Татарның каны булмасын.
Төшендә биргән олы туй
Өнеңдә гауга булмасын.
Оча дигән — Ханәкә,
Түше дигән — Көнәкә,
Кыелып төшкән бүз кыйгыр —
Килә җиткән Идегәй,
Ике бер тиң кызыңны
Тиген улҗа кылмасын.
Айый торган җаным юк.
Әйтсәм янә әйтәем:
Байтирәгең егылса,
Ул байтирәк — синң үзең,
Туксан яфрак дигәнең —
Туксан башлы урдаңның
Туксан туы булмасын.
Өркеп очкан кара кош —
Бер чебендәй җаныгыз,
Ул чыгарга булмасын!
Туктамыштай олы хан
Төш юраучы юрау биргәндә
Төсе китте, ак булды,
Ак булган соң аны әйтте:
— Син Идегәйнең ире икән,
Аның остаз пире икән,
Үле бүренең башы белән
Тере атаңны куркытма,
Токымыңны орасы!
Аны әйтеп Туктамыш,
Җәлладларын чакыртып,
Юраучыны тоттырып,
Таш зинданга яптырды.
Идегәй килде, дигәндә
Идел Йорттан кот китте.
Кәмалның улы Киң Җанбай
Киңәшен биреп килгәндә
Туктамышка аны әйтте:
— Идегәй андый ир иде —
Үзеннән бер яшь олыга:
«Без тораек, газизем.
Сез белерсез», — дир иде;
Үзеннән бер яшь кечегә:
«Син тора тор, газизем,
Без белербез», — дир иде.
Идегәйнең остазы
Пир Галәттин ир иде,
Пирдән узып эш кылмас,
Пирен аңа күндерик,
Җаекка килеп ятканда
Явын кире дүндерик,
Ул тоткарлап торганда
Урда корып торыек.
Азамат ир Туктамыш
Бу киңәшне хуп күреп,
Пир Галәттин остазын
Җаекта яткан Идегәйгә
Илче кылып ия бәрде [296].
Мулладан мулла ияртеп
Пир Галәттин килгәндә
Идегәй бик сәламләп,
Кулыннан үбеп каршы алды.
Куй симезен суйдырып,
Тугыз төрле аш биреп,
Хезмәтендә кол булды.
Ахшам ятты, таң атты,
Таң агарып атканда,
Көн кызарып чыкканда,
Муллаларын ияртеп,
Пир Галәттин купканда
Идегәй аңа йөгенде:
— Без тораек, газизем,
Сез сөйләгез, — дип торды.
Пир Галәттин анда әйтте:
— Илләштермәк — илчедән,
Яулаштырмак — яучыдан;
Туксан башлы урданың
Ил эчендә мулланың,
Рәсүл нәселе сәетнең,
Туктамыштай патшаның
Ни языгы бар булса,
Теләп килдем, әй балам!
Каерылып атың тарт, балам,
Бу сәфәрдән кайт, балам,
Бу сәфәрдән кайтмасаң,

---

[289] кугалы — камышлы
[290] Ку күл — күл исеме. Ку — аккош.
[291] чагала — акчарлак
[292] Чалкар — 1) күл исеме, 2) очсыз-кырыйсыз киң
[293] чаң — тузан
[294] җунҗыга — таҗ
[295] ул — биредә: аны
[296] ия бәрү — җибәрү

Әүвәлгедәй ил булып,
Туктамышка би булып,
Ак сарайга кайт, балам!
Анда әйтте Идегәй:
«Илләштермәк илчедән,
Яулаштырмак яучыдан»—
Яхшы әйттең, остазым!
Йортым йорттан күчереп,
Котлыкыя атамны
Чүң бүкәнгә чүктереп,
Туктамыш хан чапканда,
Пирем, анда кайда идең?
Алты угыллы Җантимер —
Ул да синдәй пир иде.
Атамны җолып ул торды,
Мине җолып ул торды,
Миңә ул карт — пир иде.
Мин биләүдә ятканда,
Туктамыш мине чапканда,
Җантимер салып үз углын,
Туктамыш аны чапканда,
Гөнаhсыз сабый баланың
Бишектә каны акканда,
Пирем, анда кайда идең?
Идел белән Җаектан,
Татарның тулы йортыннан,
Байтак куган җиремнән
Туктамыш хан мине куганда,
Пирем, анда кайда идең?
Туктамыш ханның көнендә
Җисер хатын, ятим ул,
Аксак, гарип, зарлы кол —
Аларның салган бер аhы
Күк белән җирне тотканда,
Пирем, анда кайда идең?
Туктамыштай ханыңның
Язгы бүген йолынмас,
Теләгең бүген бирелмәс,
Каерылып атың тарт, пирем,
Бу сәфәрдән кайт, пирем!
Аны әйтеп Идегәй,
Остазын кире җибәрде.
Тора килеп урыныннан
Шаh Тимергә аны әйтте:
— Идел белән Җаектан,
Нократ белән Чулманнан,
Әзгәри суккан Болгардан,
Бөктәргеле Адырдан,
Нораның кара комыннан,
Уел белән Кыелдан
Халыгым кубып килгәндә
Каршы барып алаем,
Син кузгалып чапканда,
Туктамышны басканда,
Мин дә бер сугып багаем,
Багымны[297] сынап караем,
Рөхсәт биргел, әй әмир!
Аны әйтеп Идегәй,
Углын алып уңына,
Кырык ирен алып сулына,
Төнгә карый юнәлде.

## X

## ШАҺ ТИМЕРНЕҢ ТУКТАМЫШ ХАН БЕЛӘН ОРЫШ БАШЛАП ХУР БУЛГАНЫ

Пир Галәттин кайтканда,
Идегәйнең җавабын
Туктамышка әйткәндә,
Туктамыштай олы хан
Урдасына яр салды[298].
Ул да атланды каладан,
Бу да атланды каладан,
Алпан-тилпән атлаган,
Заты Чыңгыз ни ир бар —
Бар да атланды сарайдан,
Ат менгән дә калмады,
Тай менгән дә калмады,
Куңалтак[299] киеп күн итек,
Җайдак менгән сыбайның,
Җәяүләп төшкән явырның[300],
Исәбе-саны булмады.
Чыңгыздан килгән кара ту,
Кара туны күтәртеп,
Чирүен әйдәп атланып,
Кара туп сөйрәп, «гөрс» итеп,
Азамат ир Туктамыш
Каладан чыгып туктады.
Әмир Барлас Шаh Тимер
Туктамышның хәлен күргәндә
Хәйләгә талып уй кылды,
Уй кылганда бу диде:
— Идегәй торып китте инде;

---

[297] бак — бәхет

[298] яр салу — биредә: фәрман, боерык, хәбәр

[299] куңалтак — ялан аякка итек кию

[300] явыр — яу ире, сугышчы.

Иленнән кайта килгәнче
Мин дә аны көтмәен;
Эшемне күреп калаем;
Туктамыштай тукал[301] хан
Иделдән кубып килгәндә,
Җаектан кубып бараем.
Кизәгемне[302] биргәнче,
Кизәнеп сугып калаем.
Йорт-казнасын алаем...
Идегәй кайтып килгәндә,
Аны уртакчы итмәен,
Аның да Идел йортына
Мин баш булып алаем.
  Аны әйтеп Шаһ Тимер
Аламанын[303] торгызып,
Сул кул бие Кыйгырчык,
Аны сулдан торгызып,
Алдына филләр тездереп,
Теше кайраулы ак филне
Төшәр юлга куйдырып,
Өстенә чатыр кордырып,
Эченә үзен кундырып,
Җаектан алып Иделгә
Яу кыргынын торгызып,
Ул да килеп туктады.
Ике чиру кара яу,
Ике яктан бер килеп,
Кылдай мәйдан тартылды,
Беравык мәйдан тын булды.
Шаһ Тимердән бер батыр —
Уң кул бие Ир Каплан,
Кигәне көмеш ак савыт[304],
Көн ярыктай[305] балк итеп,
Тугыз батман, тугыз теш[306]
Туң чукмарын кулга алып,
Ат сикертеп уртага,
Мәйдан тотып туктады.
Туктамыш хан ягыннан
Карагай буе ат менеп,
Мең чукечле тимер тун —
Биген биккә тарттырып,
Кугән салып каптырып,
Сиксән сөям сөңгене
Селтәмәстән кулга алып,
Мөйтәннән туган Кыпчак би
  Чыга куйды «гөрс» итеп!
  Каршыга килеп бер торды,
Карагай буе сөңгесен
Ир Капланга бер орды:
Органы карь итмәде[307],
Сиксән сөям сөңгесе
Ак савыттан үтмәде,
Үтеп тәнгә җитмәде.
  Аван[308] икән Ир Каплан:
Кармак булып каешып[309]
Җиз бармагы маешып[310],
Кыпчак бигә елышып,
Туң чукмарын бер орды.
Сиксән сөям сөңгене
Сындырып куккә кыйратты.
Мең чукечле тимер тун,
Чукмар төшеп, «шаңк» итте.
Тугыз батман, тугыз теш
Тугыз җирдән батканда
Ат саурысы селкенеп,
Сан сөяген тартканда
Селкенмәде Кыпчак би.
Житеп килеп Ир Каплан
Җиз якасын бер тотты,
Җиз элмәген бер тартты.
Карагай буе кола аты
Аелдаен айкалды,
Бурадаен[311] чайкалды,
Буралып утырып атына,
Чайкалмады Кыпчак би.
Утыра биреп арсаеп[312],
Калканы кулда калкаеп[313],
Ир Капланга бер житеп,
Иңсәсеннән бер тотты.
Как сөяген каерып,
Куйдай итеп маерып,
Ир Капланны өереп,
Туктамыш хан кашына
Саугатка[314] алып китерде.
  Анда әйтте Кыпчак би:
— Йортым Идел йорт икән,
Үзем Кыпчак би икән,
Йортым яудан чаптырмам,
Шаһ Тимергә баш ормам!
Батыры булса Ир Каплан,
Бакыртып егып атыннан,
Башы белән китердем,
Фәрман синең, хан-иям!
  Азамат ир Туктамыш
Анда торып аны әйтте:

---

[301] тукал — ?
[302] кизәк — биредә: нәүбәт, чират.
[303] аламан — кара халык.
[304] көмеш ак савыт — көмештән ясалган көбә.
[305] көн ярыктай — кояш яктысыдай
[306] теш — биредә: чукмарның чыгып торган тешләре.
[307] карь итү — тәэсир итү.
[308] аван — зур, авыр.
[309] каешу — каерылу.
[310] маешу — бөгелү.
[311] бура — ата дөя.
[312] арсаю — бәрү, егу.
[313] калкаю — 1) калку, 2) талгын хәрәкәт итү.
[314] саугат — аудан һәм яудан алып кайтыла торган бүләк.

— Салкын казан, суык су,
Ир йөрәге басылсын —
Суырып алып йөрәген,
Суык суга баса бир;
Үпкәсе калкып үсмәсен,
Өстенә таш сала бир!
Ир Капланны үтереп,
Карагай буе аг менеп,
Сиксән сөям сөңгене
Селтәмәстән кулга алып,
Мөйтәннән туган Кыпчак би
Янә чыкты «гөрс» итеп.
Иртәдән тоткан мәйданын,
Кичкә шаен бирмәде.
Унике сөңге сындырды,
Уналты балта кыерды.
Ир Капланнан күп өстен
Утыз тугыз пәлванны
Кайсын алып инсәдән,
Кайсын алып якадан,
Бакыртып егып атыннан,
Башы белән түтәрәм [315],
Туктамыш хан кашына
Илтә бирде саугатка.
Теше кайраулы ак филдә
Төшмәенчә утырган
Шаһ Тимердәй әмирнең
Башына дөнья тар булды,
Күрә-күрә күр булды [316],
Ике күзе кан булды.
Хәйран жиргә дан итеп,
Хан урдасы кордырып,
Азамат ир Туктамыш
Ал каршында торганда
Унбиш чура арталмас [317],
Унике атан [318] тарталмас,
Чыңгыздан калган кара ту —
Аны уңнан бастырып,
Салкын казан, суык су —
Аны сулдан астырып,
Думбак салып органда,
Утыз тугыз пәлванны
Бер Кыпчак би кырганда,
Тустагандай тулы күз
Туктамыштай Чыңгыз зат
Калкая биреп утырып,
Каңкая [319] биреп көлгәндә,
Кизәк көткән ирләре
Кизәнмичүк торганда,
Әмир Барлас Шаһ Тимер
Иренен тешләп күк булды:
— Туктамышның бер ире
Кырык иремә тиң икән,
Как башымны күк орды [320],
Туфрагым тарткан жир икән,
Ни шомлыгым булды?— дип,
Иманын әйтеп утырды,
Утырганы шул төсле —
Бер утырды, бер торды.
Көн кызарып батканда,
Ай агарып чыкканда,
Әмир Барлас Шаһ Тимер
Кайтып кунды кунышка.
Кунып тәгам капмады,
Уңына торып әйләнде,
Сулына торып әйләнде,
Башыннан уе китмәде,
Бер дәм йокы татмады.
Агарып таң атканда,
Күгәреп көн чыкканда
Шәһре Сарай астында,
Айдаланың башында,
Сансыз татар, кара яу;
Хан урдасы корылып,
Кылдай мәйдан тартылып,
Ун мең казан аш салып,
Ун мең төтен ут ягып,
Һай-һу тагын башланды.
Унбиш чура арталмас,
Унике атан тарталмас,
Чыңгыздан калган кара ту —
Аны уңнан бастырып,
Салкын казан, суык су —
Аны сулдан астырып,
Алтын башлы чаң-кубыз,
Саз-сорнаен чыңгытып,
Күн давылбаз төйдереп,
Дум-думбагын ордырып,
Заты Чыңгыз Туктамыш
Анда тәхет кордырып,
Калкая биреп утырды.
Әмир Барлас Шаһ Тимер
Ак филенә менгәндә,
Кыргын явын торгызып,
Каршыдан торып килгәндә,
Күңеле үскән Кыпчак би
Карагай буе ат менеп,
Тагын килеп мәйданга
Чыга куйды «гөрс» итеп!
Әмир Барлас Шаһ Тимер:
— «Мәйданым тоткан кем калды?»— дип,
Уңына торып бер бакты,
Сулына торып бер бакты,
Йөзе сүнеп каралган
Аламанын күргәндә,
Калтырап иман укыган

---

[315] түтәрәм — 1) әйбернең дүрттән бер өлеше. 2) зур кисәк.

[316] күр — сукыр.

[317] арыту — аркылы бәйләп тояу.

[318] атан — печелгән дөя.

[319] каңкаю — горурланып киерелү.

[320] күк орды — ходай орды мәгънәсендә

Муллаларын күргәндә,
Эче янып ут булды,
Тышы катып боз булды,
Анда торып моны әйтте:
— Сәмаркандтай шәһәргә
Сырлап мәчет салдырдым,
Бохарадай шәһәргә
Бурлап мәчет салдырдым;
Житмеш ханны үтердем,
Житмеш йортны яндырдым,
Житмеш житеп килгәндә
Явырдан явырым калмады,
Яу башлар ирем калмады,
Йөрәгенә сыймаган
Саф азамат батыр ирләрем
Салкын казан эчендә
Йөрәге судан шешенде.
Туктамыш чапса, кем калды?
Ни шомлыкка тарыдым?—
Аны әйтеп Шаһ Тимер,
Күмердәй кара киселде.

## XI

## ИДЕГӘЙНЕҢ ТУКТАМЫШ ХАН УРДАСЫ БЕЛӘН ОРЫШКАНЫ

Ул дигәнче бу булды:
Кара болыт якынлап,
Көн урынына төн булды.
Бөркелеп чыккан тузаннан
Жир белән күк бер булды.
Яшене-уты ялтырап,
Таңредән ут килде, дип,
Күк ярылды, жир ауды,
Бер фәләкәт[321] инде, дип.
Ханнар катып торганда,
Яулар посып торганда,
Анда тузан ачылып,
Илле төрле ту белән,
Илле меңлек яу белән,
Житеп килде Идегәй.
Унжиде ире кашында,
Кырык ире артында,
Чуар атын уйнатып,
Ашыкмый мәйдан буйлатып,
Үтеп керде Идегәй.
Туктамыштай зур ханнар,
Тук богадай[322] тарханнар,
Заты Чыңгыз солтаннар,
Атаның булган баласы,
Аганың булган энесе
Идегәйдәй бер ирнең
Йөрешенә карады.
Тимгел Чуар, Тим Чуар,
Тим Чуары — астында,
Салтанатлы ай бүрек,
Бөркет кыяк башында,
Ал караука ак алтын —
Кигән туны өстендә;
Яурыны киң олпатлы,
Суймырыктай сымбатлы,
Арбадан киң күкрәге,
Арыслан юан беләге;
Ашыкмый йөреп атлатып,
Кыпчак бигә килгәндә,
Озактан сәлам биргәндә,
Кыпчак бине Идегәйнең
Өрәге басып, агарып,
Буыны бетеп, таралып,
Тыны бетеп, каралып,
Берауык өнсез торгачтан:
— Бүген каста булдым! — дип,
Бакырып качты даладан.
Ялгызы тотып бер мәйдан,
Яу батыры Идегәй
Сузылмалы кылычын
Кармап алып сабыннан,
Суырып алып кабыннан,
Оран салып айкады.
Күк капугы ачылып,
Күз камашып калгандай
Дала йөзе «балк» итте.
Чуар атын бер типте,
Тибенгедән тир чыкты,
Каршыда торган кара яу
Туксан башлы урданың
Каршыннан килеп акырып,
Маңлаена[323] бер сукты,
Таңлаеннан ут чыкты.
Андый итеп бер сукты —
Туксан урда бер купты!
Анда купты бер орыш —
Идегәйнең орышы,
Доньяларда булмаган
Ир Идегәй сугышы.

---

[321] фәләкәт — зур бәла, бәхетсезлек.
[322] бога — үгез.
[323] маңлай — биредә: гаскәрнең алгы өлеше, авангард.

Румнан купкан Искәндәр*
Ул да андый орган юк,
Дарап улы Рөстәм*
Ул да андый орган юк.
Шан-шаң иткән шам кылыч —
Идегәйнең кылычы.
Төндә балкыр ут булган,
Көндә балкыр су булган,
Ут елдырым яшен таш —
Чын булаттан корычы,
Аждаһадай сулаган
Ул кылычның сулышы.
Бер селтәде, бере ауды,
Бере ауганга уны ауды,
Ун ауганның җиле бар,
Уны белән йөзе ауды,
Йөзе ауганга мене ауды.
Караны кара[324] димәде,
Бине күзгә элмәде,
Үлем дигән казаны
Чебендәен күрмәде.
Боркырап[325] чыккан төтенен,
Кайнап торган казанын,
Корулы торган чатырын,
Барын бердәй аударып,
Үлән ярган бүредәй,
Адәм егып юл ярып,
Килә бирде Идегәй.
Салкын казан, суык су —
Аны җитеп аударып,
Чыңгыздан калган кара ту —
Аны җитеп аударып,
Ат астында калдырып,
Тоякка салып сындырып,
Юлда барын таптатып,
Сөрә бирде Идегәй.
Идегәй килә дигәндә
Аны белгән ни ир бар —
Урда бозып таралды.
Азамат ир Туктамыш —
Унике ире алдында,
Тугыз ире артында,
Туксан башлы урдасын
Тәңре хөкеменә тапшырып,
Дәрвазасын яптырып,
Шәһәренә кереп камалды.
Кылычын елан уйнатып,
Бара бирде Идегәй,
Үлесен күзгә элмәде,
Тересенә көлмәде,
Туктамышның дәрвазына
Туры барды Идегәй.
Кул яссуы тимердән
Унике колач дәрваза.
Килеп җитеп Идегәй,
Кул табанын бер орды,
Дәрвазасын кубарып,
Һавага атып җибәрде.
Ул да булып булмады,
Маңлайлары ялтырап,
Тулы кашы калтырап,
Саралатын уйнатып,
Җитеп килде Норадын.
Дәрвазадан юл ярып,
Үтеп керде Норадын.
Атадан күргән һөнәрен
Җитеп күрде Норадын.
Янтаеп кылыч органда
Әҗәллесен үтерде,
Имгәклесен бөлдерде.
Алаңгасар Алман бине
Акыртып кисте Норадын;
Байназардай Диван бине
Бугалак салып муйнына,
Бакыртып кисте Норадын;
Айбалталы Дөрмән бине
Дәрвазага бәйләтеп,
Дулатып кисте Норадын;
Кинегесле Кәрим бине
Кикертеп кисте Норадын;
Уймавыттан Үмәр бине
Үкертеп кисте Норадын;
Чакмалы би Чакмагышны
Чалкайтып кисте Норадын;
Янгурадай йорт биен
Яндырып кисте Норадын;
Илтәрәстәй ил биен
Илертеп кисте Норадын.
Ата улны белмәде,
Ана кызны белмәде,
Кем урдасы кем якта,
Явыр явын белмәде.
Азамат ир Туктамыш
Күккә бакты — ут күрде,
Җиргә бакты — кан күрде.
Ук атканда ук үтмәс,
Сөңге салсаң, сөңге үтмәс,
Тугыз күзле кирәүкә
Туктамыш хан кигәндә,
Карагай найза[326] таянып,
Тукмак ялы турыны
Актачыдан[327] тоттырып,
Туктамыш хан менгәндә,
Хан ханәше Йәникә
Тезгенгә килеп асылды:
— Чыга күрмә далага,
Җунжыгалы башыңны

---

* Искәндәр — Александр Македонский
* Рөстәм — Фирдәусинең «Шаһнамә» әсәрендәге үзәк герой, батыр.
324 кара — түбән сыйныф
325 боркырау — бөркелү.
326 найза — сөңге.
327 актачы — атлар башчысы.



Егып алыр Идегәй,
Чыга күрмә далага.
    Анда килеп Киң Җанбай
Йәникәгә аны әйтте:
— Елама, ханәш, елама,
Күчәрчелек[328] булганда
Катардагы[329] нарга көч,
Яугәрчелек булганда
Уң яктагы кызга көч:
Яу якадан алганда
Бер чебендәй җанга көч,
Баш исәндә җан исән,
Ханның башы калсын,— дип,
Тезген башын кулга алып,
Атның башын каерып,
Йәникәдән аерып,
Ас күчәгә юл алды.
Ас күчә дә өс күчә —
Биләр йөргән буз күчә[330].
Яшерен бикне ачтырып,
Йөздән артык ир белән
Туктамыштай олы хан
Киң далага юнәлде.

## XII

## ТУКТАМЫШ ХАННЫҢ САРАЙДАН КАЧЫП КИТКӘНДӘ ТУЛГАП ӘЙТКӘНЕ

Әй егетләр, чуралар!
Урманбит би үлгәндә,
Ун сан нугай бөлгәндә,
Шаһназар батыр яудан
Яралы барып килгәндә,
Аяз да көннәр монарланып,
Гарасат уты янганда,
Бура боздан тайганда,
Бутасы[331] баш күтәреп торганда,
Каз очып шоңкар куганда,
Ханнан гайрәт киткәндә,
Бигә мидәт[332] иңгәндә,
Ханнар качса би куып,
Хан йөрүгә төшкәндә,
Идегәй морза талашып,
Ил соңына төшкәндә,
Хан Туктамыш гарьләнеп,
Байтагым дип зарланып,
Аны әйтеп тулгады:
— Әй, байтагым, байтагым,
Сине алдырдым мин тагын,
Дошман талар килгән соң,
Әл-аман бул миннән соң!
    Байтагымның эчендә
Ун сан минем нугаем;
Синнән тагын аерылдым,
Әл-аман бул миннән соң!
Ун сан нугайдан азак,
Өч йөз алтмыш йорт казакъ,
Синнән тагын аерылдым,
Әл-аман бул миннән соң!
Унбиш чурам арталмас,
Унике атан тарталмас
Чыңгыздан калган кара ту,
Сине яуга калдырдым,
Әл-аман бул миннән соң!
Башлы, башлы, башлы урда,
Башта сине алдырдым;
Байтагы эчеп бетермәс
Бал чапчактан аерылдым,
Әл-аман бул миннән соң!
Кушалык өйгә баш булган
Ханәкәдәй аруны,
Көнәкәдәй сылуны,
Йәникәдәй бикәчне
Капыллыкта тиген улҗа кылдырдым,
Әл-аман бул миннән соң!
Тулыксыган ана Идел,
    Тулыксып урдам кунган йорт,
Байтагымның баласы
Туып-үсеп уңган йорт,
Уңышыңны алдырдым,
Әл-аман бул миннән соң!
    Кундакка урдам кундырып,
Хан сараен салдырып,
Артыма чатыр кундырып,
Алдыма базар кордырып,
Алтыннан акча кистереп,
Шул алтынның мөһрене
Үз исемемә суктырып,
Тагы аз гына мин анда
Хан булыем дип идем,

---

[328] күчәрчелек — күчәргә туры килү.
[329] катар — янәшә.
[330] буз күчә — 1) туры урам. 2) каты җир.
[331] бута — дөя баласы.
[332] мидәт (мәдәт) — ярдәм, булышу.

Сине тагын алдырдым,
Әл-аман бул миннән соң!
Иртән торып кош чөйсәм,
Каз белән ку алдырган Идел йорт.
Ат башыдай сары алтын
Сандыгымда яткан йорт.
Иңләү тирән Идел йорт,
Җәйләү салган котлы йорт;
Кечкенә җаным Йәникә
Киленчәк булып төшкән йорт,
Йөгенеп аяк[333] алган йорт,
Иелеп сәлам биргән йорт,
Күрекле туган сылуны
Бикәч итеп алган йорт,
Ак бөркәнчек салган йорт,
Ал иннеген яккан йорт,
Кызыл мәрҗән таккан йорт,
Акбүз атка менгән йорт,
Ялгыз да каргам Кадыйрбирде,
Кадыйрбирде солтан туган йорт,
Каплы камка ерткан[334] йорт;
Ун сан нугай җыйган йорт,
Өлкән бер туй кылган йорт;
Ялгызыма алкыш[335] тисен дип,
Арак[336] белән шәрабка
Шунда ямаи туйган йорт,
Юыктан[337] синә килә алмам,
Юык булса да җитә алмам,
Алыстан[338] сине күрә алмам,
Җәяүлек башка төшкән соң,
Әл-аман бул миннән соң!
Аны әйтеп Туктамыш
Йөз батырын янга алып,
Киң Җанбайны уңга алып,
Янә юлга юнәлде.
Янә бер көн барган соң,
Киң Җанбайга аны әйтте:
— Бу барганнан барырмын,
Йөгереклеге сыналган,
Куш йөрәкле яралган,
Тукмак яллы туратым
Үз астымда булганда,
Идегәй мине куганда,
Айлык юлым алдан алырмын.
Болгардаен калам бар,
Болгар йортын алырмын,
Болгарда да тынмасам,
Куе урманның төбендә
Куерып аккан Ашыт су,
Кара урманым төбендә
Каралып аккан Казан су,
Казан суның буенда
Капкасы биек таш Казан,
Ул каламны алырмын,
Инде анда да тынмасам,
Чулманны кайта кичәрмен,
Җүкәтаудан үтәрмен,
Җүкәтавым аръягы
Ышыктан аккан Ык суы,
Аның да чыгып башына,
Даладан дала үтәрмен.
Туктамыш аны әйткәндә,
Кача биреп киткәндә,
Илен алды Идегәй.
Сарай дигән каласы
Сиксән күчә арасы,
Сары мәрмәр Алтын-Таш,
Туры барды Идегәй.
Алтыннан суккан Ак Урда,
Көмештән суккан ак ишек,
Төсе суык чын булат
Очы белән ачтырып,
Инә бирде Идегәй.
Анда инеп Идегәй
Шаһ Тимергә аны әйтте:
— Сары мәрмәр Алтын-Таш —
Сарайны саклап торгайсың;
Алла үземә биргәндә
Туктамышның үзеннән
Үз чыгарып алыем,
Башына кылыч чабыем;
Ил күнелен тындырып,
Ир күнелен табыем.
Аны әйтеп Идегәй
Шаһ Тимердән аерылды.
Норадынны янга алып,
Ирәннәрен уңга алып,
Болгардаен шәһәргә
Туры барды Идегәй.
Килә җитеп Идегәй
Болгарны танып танымый,
Хәйран калып туктады:
Алтынлап сүрә яздырган,
Ал бизәкле Айкапу[339] —
Айкапуны тапмады,
Айкапуның тупсасы,
Куш манара — ак яңак,
Ак яңакны тапмады.
Калага аяк басканда,
Каерылып яткан таш күрде,
Көйрәп яткан көл күрде,
Адәм заты тапмады.
Шәһре Болгар уртасы
Өсте мәрҗән, асты таш;
Алтмыш колач манара.

---

[333] аяк — савыт, касә

[334] каплы камка ерту — йола

[335] алкыш — яхшы теләк

[336] арак — аракы

[337] юык — якын

[338] алыс — ерак

[339] Айкапу — 1) шул исемдәге бина (мәчет?), 2) шул бинаның капкасы

Күз өстендә гәүһәр каш.
Анда житеп килгәндә,
Түтеннән чатнап ярылган
Манараны күргәндә,
Ул манара төбендә
Башын учлап утырган
Чәче челдәй[340] агарган
Бодайбине күрде Идегәй.
— Көлгә-ташка болганып,
Болгарыңа ни булды?
Челдәй чәче агарып,
Бодайбигә ни булды?
Анда әйтте Бодайби:
— Көлгә-ташка болганып,
Болгарыма ни булган —
Чыңгыз улы Жучи хан
Ул да ватып ватмаган,
Жучи улы Байду хан
Ул да бозып бозмаган
Болгарым бүген бозылды.
Талха, Зәбир сәхәбә[341]
Аягын баскан Айкапу —
Айкапусы егылды.
Челдәй чәчем агарып,
Бодайби булып ни кылыйм?
Син дә булып ир булдың,
Баба Төкләс улы пир булдың,
Сыенганым син идең,
Бу жиһанның фетнәсе —
Аксак Тимер дошманны
Сарайга алып китердең.
Йөз баһадир иреннән
Йорт жиренә бастырдың.
Әзгәри суккан Әтрәчне*
Эргәсенән [342] актарып,
Нократ [343] суккан Болгарны
Ниргәсеннән [344] куптарып,
Алтын койган учагым
Ал кирпечен туздырып,
Көмеш койган учагым
Гөл кирпечен туздырып,
Төнгә үтте Туктамыш.
Ул да үтте дигәндә
Бу күрәсем бар икән:
Урысның бер гавере
Төлкедәй кызыл чырайлы,
Авызы төкле княже —
Ул килеп басты йортымны;
Изге Шәһре Болгарны,
Астаналы[345] Сиварны,
Капкасы биек Казанны,
Чулмандагы Жүкәтау,
Урмандагы Сабаны,
Ашлыгы иксемәс Ашлыны
Яндырып та сындырып,
Көрәкләп тәнкә жыйдырып,
Күн сәхтиян таптырып,
Ундүрт шәһәрле йортымны
Көлгә-ташка болгады.
Моннан да ары Бодайби
Челдәй булмый ни булсын?
Аны әйтеп Бодайби
Янә башын учлап утырды.
Анда әйтте Идегәй:
— Борлыкма син, Бодайби!
Болгарынны болгатып
Туктамыш хан үткәндә,
Сакалын ала кан итеп,
Аның да башын алыем;
Урысның бер гавере
Авызы төкле княже
Ундүрт шәһәр йортыңны
Көлгә-ташка болгап үткәндә,
Авызын-борынын кан итеп,
Аның да башын алыем,
Көрәкләп алган тәңкәсен
Батманга тартып алыем;
Ундүрт шәһәрең көл булса,
Аның да кунын [346] түләтеп,
Урнына шәһәр салыем,
Борлыкма син, Бодайби!
Аны әйтеп Идегәй
Туктамышның эзеннән
Эз чыгарып юнәлде.
Куе урманның төбендә
Куерып аккан Ашыт су,
Кара урманның төбендә
Каралып аккан Казан су.
Казан суның буенда
Капкасы биек таш Казан —
Капкасын янә тапмады,
Кыранташ [347] белән көл күрде.
Сабакүлгә атлады.
Сабасы зипа [348] Сабакүл
Сабасын татып татмады,
Туктамыш белән княжне
Анда янә тапмады.
Анда туктап Идегәй
Норадын белән уй кылды.
Уй кылганда аны әйтте:
— Әй, Норадын, Норадын,

---

[340] чел — божыр.

[341] Сәхәбә — Мөхәммәт пәйгамбәрнең үз заманындагы тарафдарлары.

[342] эргә — нигез.

[343] нократ — көмеш акча.

[344] ниргә — агачтан салынган корылманың һәрбер рәте.

[345] астана — изге дип санала торган урын йә корылма.

[346] кун — кан үче.

[347] кыранташ — ?

[348] зипа — зифа.

Әмир Барлас Шаһ Тимер
Сараемда торганда
Әйләнеп анда кайтыем,
Шаһ Тимерне ризалап,
Үз йортына озатаем.
И Норадын, Норадын,
Чулман буе Җүкәтау,
Җүкәтауның аръягы
Ышыктан аккан Ык булыр.
Аның да чыгып башына,
Даладан дала үтәрсең,
Менгән атың Сарала,
Саралага атланып,
Ат койрыгын чарт тәеп,
Сүтелгәнче шул койрык
Туктамышны куа бир:
Хан кашында йөз кеше,
Һәммәсе дә сум кеше,
Зәһәрнең азы да бер, күбе дә бер,
Һәммәсен дә суя бир.
Әй Норадын, Норадын,
Бу эшемне үтәсәң,
Кабул кылдым морадың.
Ханәкәдәй аруны,
Көнәкәдәй сылуны,
Йәникәдәй бикәчне
Тиген улҗа кылганда,
Ханәкәдә күнелең бар икән,
Аны да сиңа саклап торгаймын,
Тынычлап ханны куа бир!
Аны әйтеп Идегәй
Норадыннан аерылып,
Сарайга кайта юнәлде.
Калага җитеп килгәндә
Каласын янә тапмады —
Кыранташ белән көл күрде.
Алтын-Ташка атлады,
Хансарайга килгәндә,
Хансарайның ишеген
Каһәр белән ачып кергәндә,
Тимердән суккан шаң[349] киеп,
Вәзирләр белән куршанып[350],
Түрдә утырган Кыйгырчык*,
Аны күрде Идегәй.
Идегәй анда ингәндә,
Шаһ Тимер кая? — дигәндә,
Кыйгырчык хан аны әйтте:
— Шаһ Тимерне сорасаң,
Шаһ Тимердәй олы хан,
Алтын егач тутый кош,
Ал тәхетне алдырып,
Ак филенә мендереп,
Эченә үзен кундырып,
Бар казнаны алдырып,
Алы тулы мал белән,
Арты тулы чаң белән,
Айдарлы коллар белән,
Толымлы күңләр белән,
Сәмәркандка юнәлде.
Илең-йортың аныкы,
Калгай[351] булып калганмын;
Мине монда баш кылды,
Кулымны мөһере белән нык кылды:
Ун мең чиру алаен[352]
Кулыма биреп, хан кылды;
Бөркет кыяк башыңны
Буйсынып сал, Идегәй!
Ай бүрекле башыңны
Ай кылып сал, Идегәй!
Заты Чыңгыз мин икән,
Син дә минем бием булгайсың!
Анда әйтте Идегәй:
— Аягы чонтык әмирең
Аямый илне екканда,
Идел йортны бозганда,
Ил казнамны алганда,
Заты Чыңгыз син үзең
Тимердән суккан шаң киеп,
Калгай булып калганда
Яхшы тукмак булырсың!
Анда килеп Идегәй,
Кыйгырчыкның аягын
Сыйрагыннан тотып күтәрде.
Кыйгырчыкның кигәне
Тимердән суккан шаң икән
Аягын кулга сап итеп,
Башы белән бер орды,
Уналты вәзир, утыз би
Аллалап төшеп егылды.
Кырын атлап Идегәй,
Хансарайдан чykканда,
Ун мең алай купканда,
Барын бердәй өереп,
Тукмагы белән чүкереп,[353]
Һәлак кылып ташлады.
Азамат ир Идегәй
Анда илгә яр салды:
— Дәвер кемнең дәвере? —
Идегәйнең дәвере!
Заман кемнең заманы!
Идегәйнең заманы!
Яр салдырды калага,
Яр салдырды далага.
Туктамышның сансыз кол,
Барын-югын җыйдырды,
Җыеп азат кылдырды.
Угылларны сатуга

---

[349] шаң — тоташ металлдан суккан кием.
[350] куршану — чолгану.
* Кыйгырчык (Куюрчак) — Алтын Урда ханнарыннан
[351] калгай — урынбасар, наиб.
[352] алай — полк мәгънәсендәге гаскәри берәмлек.
[353] чүкерү — бәрү.

Бер чигара кылдырды.
Кисмә-кисмә сары алтын
Кисеп улҗа кылдырды.
Идел йортны җыйдырып,
Өлкән бер туй кылдырды.
Агаларны алдырып,
Киңәшсез үскән бу йортны
Киңәшле йорт кылдырды,
Каланы кайта торгызды,
Илне илгә тутырды,
Уртасына ару урда кундырды.

## XIII

## НОРАДЫННЫҢ ТУКТАМЫШ ХАННЫ ҮТЕРГӘНЕ

Азамат ир Туктамыш
Качып бара ятканда,
Чулманны кайта кичкәндә,
Ыкның башы — җил башы,
Җым далага[354] җиткәндә
Җиз бүрекле йөз ирем
Җым далада күренер дип,
Йөз иреннән аерылып,
Киң Җанбайны янга алып,
Икәүләп юлга юнәлде.
Янә бер көн баргачтан,
Кәмалның улы Киң Җанбай
Атыннан иңеп торганда,
Колагын җиргә куйганда
Норадын менгән Сарала
Үкерә биреп кешнәде.
Җанбай анда сискәнде,
Туктамыш аны күргәндә
Күңеле боздай бузарып,
Киң Җанбайга аны әйтте:
— Кашымдагы юлдашым
Чыбыр-чыбыр итәдер,
Җанына кыен килгәндә
Мине ташлап китәдер;
Бу барганнан барырмын,
Төлкелегә[355] барырмын.
Төлкеледә курыксам мин,
Ку-күлленең күлендә
Баса биреп ятармын.
Теләвемне теләп торгайсың,
Аллам-иям иш булса,
Унөч ел үтте дигәндә
Янә кайтып килермен.
Аны да әйтеп Туктамыш
Киң Җанбайдан аерылды.
Төлкелегә юл тотты,
Төлкеледә кунганда,
Колагын җиргә куйганда,
Норадын менгән Сарала
Үкереп янә кешнәде.
Аны ишетеп Туктамыш,
Анда җаны бер курыкты,
Ку-күллегә юл тотты.
Ку күленә барганда,
Җир-сулары калганда,
Тулгай биреп аны әйтте:
— Иделдән чыккан ирмешәл
Ирмешәлдән чыккан Колторган[356],
Колторганнан аерылдым,
Кошны кайда чөярмен?
Көбәмнең бикләренең
Бавын ничек чишәрмен?
Колача аттан йөк ауды,
Куышны кая артармын?
Санаулы бүзем егылды,
Сынаусыз ал белмәгән
Бидәүгә[357] ничек мением?
Сер белмәгән башларга
Серемне ничек түгием?
Күп нөгәрдән аерылдым,
Киңәшемне инде кемнән сорармын?
Туктамыш алай барганда,
эченнән эче янганда,
Тугыз күзле кирәүкә[358]
Инсәдән басып барганда,
Бүз юшанга[359] җиткәндә,
Бигеннән чишеп ул туньн,
Калдырырга уйлады:
«Бер билгесе юк икән
Кирәүкәмне салмага.
Караң[360] калыр кара, тун,
Бүз юшанга салыем,
Алла үземә биргәндә
Кайтып синнән алыем», дип,

---

[354] җым дала — үлән үсә торган дала, чүл түгел.

Төлкеле — күл исеме.

[356] Ирмешәл, Колторган — җир-су, урын исемнәре.

[357] бидәү — дөя.

[358] кирәүкә — көбә, металл бозҗралардан ясалган кием.

[359] бүз юшан — ак әрем.

[360] караң — күренмәү

Тугыз күзле кираүкәне
Анда салып калдырды.
Туктамышның артыннан
Эзеннән эзен чыгарып
Баса килде Норадын.
Бүз юшанга житкәндә
Караң калган кара тун
Тугыз күзле кираүкә —
Аны да табып Норадын,
Өстенә киеп корганып,
Ку күленә юнәлде.
Ку-күлленең күлендә
Кау камышта[361] ятканда
Туктамыштай зур ханның
Дөрселдидер йөрәге,
Ку күленнән курыкканда
Туктамыш хан аны әйтте:
«Дөрс, дөрс» итеп, «дөрс» итеп,
Дөрселдәмә, сум йөрәк:
Тынычлыкка зар чакта
Дөрселдәвең ник кирәк?
Идегәй икәү, мин ялгыз,
Ирекәән җирдә тынармын:
Сулкылдама, ак найза,
Суешкан җирдә сынарсың!
Боркырама, каба ком,
Яңгыр яуса ятарсың.
Көлберәмә,[362] көн ана!
Болыт килсә батарсың.
Тулыксыма, тоных су!
Мине өшеткән суык су!
Туксанның бере[363] туса катарсын!
Тыңламасаң сүземне,
Өстеңә елкы әйдәрмен,
Бер суырса — корырсың,
Бер батлавык[364] булырсың.
Кыйкулама, кызгач кош,[365]
Канатың куш, муйның буш,
Авызың-борының мөгез кош,
Авазың яман зарлы кош!
Батлавык тулган елкым юк,
Оян таптар малым юк;
Оя тулган йомыркаң
Итәкләп алыр углым юк!
Күл иясе син булсаң,
Мин күпләрнең иясе,
Баш очымда әйләнеп,
Кыйку салып йөрмәче!
Сине күлдән аерган,
Мине илдән аерган,
Идегәй улы Норадын,
Минемдәен саргаеп,
Казак чыксын иленнән!
Садаклары салбырап,
Һич төшмәсен биленнән!
Азамат ир Туктамыш
Янә торып, янә әйтте:
— Хан булып ни иткәнмен?
Халыгыма, илемә,
Өлге булган морзамын.
Сары Мәрмәр Алтын Таш —
Идегәй аны басты, күр!
Идегәй анда торды ла,
Иңеп сөрән салды ла,
Алтын башлы чаң-кубыз
Аманлыкта әйбәтле,
Яу килгән көн тынды ла!
Туралы[366] кошның баласы
Тумагы[367] күзгә төште лә!
Минем газиз байтагым
Тубыктан канга батты ла!
Тугыздан үрмә кыл аел
Аргамакка батты ла!
Өзәңгесе өзмә алтын,
Коешканы[368] койма алтын,
Нукталары сум алтын,
Азаулары бер карыш
Аргамаклар бауда катты ла!
Әзәлдән яу Идегәй,
Малымны алып куймадың,
Кәникә[369] кочып туймадың,
Минем башымны кискән көндә
Син тынарсың, Идегәй!
Ку-күлленең күленә
Норадын житә килгәндә,
Туктамыштай зур ханның
Дөрселдидер йөрәге:
«Анау кара күренгән
Идегәй улы Норадын,
Һич бирмәгән морадын!
Үлми кулга тотылмам,
Әнә житте Норадын,
Мин үзем бу көнемдә
Жиргә сеңсәм, котылмам!»
Килә житеп Норадын
Ку-күллене күргәндә
Азамат ир Туктамыш
Качса кача белмәде,
Куба килеп урыныннан,
Тора килде Туктамыш.
Бер-беренә сәлам биргәндә
Анда әйтте Туктамыш:
— Атның бары толпар булмас,
Кошның бары шоңкар булмас,

---

[361] кау камыш — кипкән камыш.
[362] көлберәү — ялтырау.
[363] туксанның бере туу — 90 көнлек кыш туу.
[364] батлавык — суы кипкән җирдә үсеп чыккан яшь чирәм.
[365] кызгач кош — тәкәрлек.
[366] туралы — кулга өйрәтелгән ау кошы.
[367] тумак — ау кошы башындагы калфак.
[368] коешкан — иярнең арт каешы.
[369] кәникә — биредә: кәнизәк, җария.

Ишәк дөя булмас,
Сыер бия булмас,
Коешканы юкәдер,
Бинең аты би булыр,
Коешканы көмештер,
Колның аты кол булыр;
Син ич минем колымсың,
Мин Чыңгызмын, беләмсең,
Хан улымын, ханыңмын,
Үлми кулга тотылмам,
Үлтермәмен мин сине,
Үлтермәссең син мине!
Анда әйтте Норадын:
— Мин бер колың түгелмен,
Син дә Чыңгыз түгелсең,
Мин кырмыска булып та,
Син Сөләйман* түгелсең!
Мине колым димәче,
Сине беләм димәче!
Мин бабамнан сораган:
Дүшәмбенең көнендә,
Сишәмбенең төнендә,
Ай белән көн яурылып,[370]
Ике нурдан ялгашып,
Чын газиз канның үзеннән
Пәйда булган морзамын.
Ялан кылыч кулга алып
Яу кайтарган морзамын;
Борак[371] сынлы ат менеп,
Билек сөргән морзамын,
Кыен күргән егетнең
Кыйбатын артык белгән морзамын;
Кыйналып эш күрсәткән егетнең
Алапасын[372] артык язган морзамын,
Билгеле балта кулга алып,
Билге чапкан морзамын;
Биргән малын кире алмас
Белекле газиз улымын.
Атасын сорамый нөгәр ияртмәм,
Аслын сорамый мал бирмәм,
Биргәндә мең дә биш йөз
Сары алтынга туктамам;
Дусымның утын сүндермәм,
Дошманым утын яндырмам;
Идегәй улы Шаh Норадын
миндермен,
Шушы йөргән Чыңгызның
Кайсы улыннан кимдермен?
Туйгуҗа улы Туктамыш
Аслы Чыңгыз булса, ни булды?
Чәчле-төкле Хуҗа Әхмәт,
Аннан туган Ир Әхмәт,
Аннан туган Тимеркыя,
Аннан туган Котлыкыя,
Аннан туган Идегәй,
Идегәйдән туган Норадын,
Алла юмарттыр,
Аңа бирде морадын!
Ант кылычка җиткәндә
Әйтерең булса, әйтеп кал,
Кылырың булса, кылып кал.
Анда әйтте Туктамыш:
— Ком җыелып таш булмас,
Кол җыелып баш булмас,
Ачтан туйган ялчымас,[373]
Патша булып Идегәй,
Нәселе Чыңгыздан булган
Бу башымны алса да,
Ул да Чыңгыз булалмас;
Нинди түрә бирсә дә,
Миндәй түрә бирә алмас;
Яхшы белән яманның
Ул да кадерен белә алмас!
Азамат ир Туктамыш
Җаныннан өмет өзгәндә,
Кыелып очкан кошларга
Баш күтәреп анда әйтте:
— Кыйгышлар да казгышлар,[374]
Белә алмысез, байгышлар,
Сезне күлдән аерган,
Мине илдән аерган
Идегәй улы Норадын,
Бер алладан сораек,
Һич бирмәсен морадын!
Казак чыгып жиреннән,
Садагы төшми биленнән,
Минемдәен аптырап,
Куркуыннан калтырап,
Баш куярга жир тапмый,
Куылып йөрсен иленнән!
Анда әйтте Норадын:
— Андый, андый казгышны
Анда куып качырттым!
Андый, андый каргышны
Монда бастым, бакырттым!
Җиде тауны яңраттым,
Каргышың кара башыңа!
Баш кисәрмен кайгысыз!
Атамны йорттан син кудың!
Мине йорттан син кудың!
Казак чыктым илемнән,
Илдән илгә күп үттем,
Садагым төшми билемнән,

---

* Сөләйман (Соломон патша. Безнең эрага кадәр 965-928 еллар) — хайваннар, кошлар телен белүче зирәк дип саналган.

370 яурылу —?

371 Борак (порак) — дини мифология буенча, пәйгамбәрне күккә ашырыр өчен махсус иңдерелгән ат.

372 алапа — гаскәргә бирелә торган хезмәт хакы.

373 ялчу — көрәеп үсеп киту.

374 казгыш — каз-кош.

Үз кылганың үзеңә кайта,
Икърар юктыр телеңнән!
Арын әйт тә бирен әйт,
Беренче кизәк кемнеке?
Яшең өлкән ир икән,
Син ат, кизәк синеке!
Анда килеп Норадын
Каршыдан торып басканда,
Азамат ир Туктамыш
Өч катар угын атканда,
Атканы карь итмәде,
Тугыз күзле кирәүкә,
Бер күзеннән үтмәде.
— «Үз коралыма юлыктым»— дип,
Җонҗыгалы чал башын
Сона бирде Туктамыш.
Ир Норадын сукканда,
Кылычы белән чапканда,
Туктамышның чал башы
Җиргә төште «алла»лап.

Кан урнына сөт акты,
Башны җитеп артыннын,
Ак найзага кыстырып,
Аны да өскә күтәреп,
Норадын анда сорады:
— Колдан вәзир куясызмы?
Кол теленә инанасызмы?
Сөңгедә торган хан башы
Телгә килеп анда әйтте:
— И балам, балам, балам,
Колдан вәзир куйсак та,
Колның телен алсак та,
Гәүдә түбәндә калды,
Баш әле дә синнән югары.
Норадын башны җиргә атты.
Аннан аны янә алды,
Янә алган соң атланды,
Сараласын бер типте,
Кайта бирде Норадын.

## XIV

## НОРАДЫННЫҢ ҖАНБАЙГА ОЧРАП ӘЙТЕШКӘНЕ, ҖАНБАЙНЫҢ ИДЕГӘЙ БЕЛӘН НОРАДЫН АРАСЫН БОЗГАНЫ

Юлдашлары кушылып,
Алар юлга киткәндә,
Юлда торып байтирәк,
Байтирәккә төшкәндә,
Кара аргамак каңтарып,[375]
Йоклап яткан берәүне
Күрә биреп килгәндә,
Үлтерергә уйлады,
Аннан кулын кире алды:
— Йоклаганны үтергән,
Коралсызга кул салган,
Хатын булыр, ир булмас!
Аны әйтеп Норадын,
Ул адәмне уятты.
Уяна биреп берауык,
Тора килде Киң Җанбай.
Тора килеп сарнады:
— Әй Норадын, Норадын,
Һич бирмәсен морадың!
Тукмак яллы турыны
Кайда мендең, Норадын?
Тугыз күзле кирәүкән,
Кайда кидең, Норадын?
Саурык[376] бия сөте иде,
Тыныч йортка кот иде,
Туктамыштай хан-иям,
Аны ниттең, Норадын?
Анда әйтте Норадын:

— Тукмак яллы турыны
Тунаган җирдә менгәнмен:
Тугыз күзле кирәүкәне
Үлтергән җирдә кигәнмен!
Саурык бия сөте булса,
Тыныч йортка кот булса,
Туктамыштай ханыңны,
Синең якын каныңны,
Төлке күлдә эзләнеп,
Эзен чыгарып алганмын;
Ку-күлленең күлендә
Баса барып җиткәнмен,
Уклашып көрәш иткән соң,
Иңкәйтеп җанын алганмын.
Кәмалнның улы Киң Җанбай,
Сине ерау диделәр,
Сине чичән диделәр;
Мине мактап җырласаң,
Ярлыкармын, Җаныбай.
Үзеңне син мактасаң,
Үлтерермен, Җаныбай.
Башыңны баудай кисәрмен,

---

[375] каңтару — тезгенне ияр кашына бәйләп, атның тирен суындыру.

[376] саурык — 1) 4-5 яшьлек, 2) ярсу.

Канжагама[377] йөлде[378] ясап буармын!
Анда Жанбай әйтте лә:
— Аптыраган ахмакмын,
Нине табып әйтием?
Мин ерауча түгелмен,
Мин чичән дә түгелмен,
Ерауҹылар килгәнче,
Чичәннәр сиңа иргәнче,[379]
Беразрак мин синең
Күнелең аулап тораем:
— Көярсең, ирнең баласы,
— Көярсең дә янарсың!
Норадын анда әйтте лә:
— Көяр утка янмага
Мин кауданлы[380] җир түгел;
Син үзеннең тапканыңны,
Жанбай, аны жырлагын!
Анда Жанбай әйтте лә:
— Тапканымны жырласам,
Белгәнемне жырласам,
Күнелең бераз аулансын:
Түбәгә чыккан дүртәүгә
Түрә булыр көн туармы?
Аркада торган алтауга
Ага булыр көн туармы?
Идегәй белән Норадын
Көне батар көн туармы?
Калган-каткан ил булып,
Кадыйрбирде хан булып,
Борынгыдай дан булып,
Ту җилкелдәр көн туармы?
Жанбай алай дигәндә,
Тау иленең Мәмәткол —
Атлы егет килде лә!
Жанбайга атын тибендереп,
Алмас кылыч күтәреп,
Жанбайны чапмак булды ла.
Норадын аны күргәндә
Аралап торып килде дә,
Анда Жанбай әйтте лә:
— Карга кунмас карагач,
Каз кундырдың, Норадын;
Козгын кунмас ку агач,[381]
Ку кундырдың, Норадын!
Жиргә тамар канымны
Жиннән тоттың, Норадын!
Жилкәмнән төшәр башымны
Жөйләп тоттың, Норадын!
Сиңа ияргән колларга
Гомер бирдең, Норадын!
Ир Норадын анда әйтте:
— Әй Киң Жанбай, Киң Жанбай,
Син үлгән белән жир тулмас,
Үлмәгән белән кубәймәс!
Сине үтереп ни итием?
Үтерми ак китием.
Туктамыштай ханыңа
Нинди хезмәт кылгансың,
Атама да шуны кыла йөр!
Сарайга кайтып житкәндә
Туктамыштай хан башын
Канжагасыннан чыгарып,
Идегәйнең алдына
Ташлап әйтте Норадын:
— Төннәр, көннәр куган соң,
Төлке күлдә эз алып,
Төлке күлдән Ку күлгә
Юнәлгәнмен сүз алып.[382]
Ку күленә барган соң,
Күз йөгертеп алган соң,
Казгышларны кычкыртып,
Тукмак ялны пошкыртып,
Поса-поса баргалап,
Туктамышны тапкан соң,
Ул миңа да мин аңа
Күп сүзләрне әйткән соң,
Иңкәйтеп башын алганмын,
Алдыңа китереп салганмын!
Анда әйтте Идегәй:
— Әй Норадын, Норадын,
Бу хезмәтем үтәдең,
Кабул кылдым морадың,
Сиңа булсын Ханәкә.
Урда башы Биш Уба,[383]
Жанбай житеп килгәндә,
Биш Убада елаган
Ханның кызы Ханәкә,
Жанбай аны күргәндә,
Тулгай биреп аны әйтте:
— Елама, Ханәкәм, елама,
Атаң иде Туктамыш,
Атсыз идем, ат бирде,
Тунсыз идем, тун бирде,
Асыл туннар кидерде,
Гарәби атлар мендерде;
Ул көннәр инде безгә юк,
Елама, Ханәкә, елама!
Туктамыштай ханымны,
Синең дә булган атаңны
Идегәй улы Норадын
Куып та житеп барганда,
Кагып та башын алганда,
Атасының алдына
Аны да китереп салганда,
Бу эшенә дан итеп,
Сине дә сорап торганда,

[377] канжага — ияргә җинел йөк бәйләр өчен куелган каеш.
[378] йөлде — бүләк, приз.
[379] иру — ирешү, очрашу.
[380] каудан — кипкән үлән.
[381] ку агач — корыган, ку (соры) төскә кергән агач.
[382] сүз алу — сүз тыңлау.
[383] Биш Уба — Урданың бер өлеше. Уба — калкулык.

Идегәй улы Норадын,
Һич бирмәсен морадын!
Әй Ханәкәм, Ханәкәм,
Хансарайга килгәндә
Тар карныңны киңәйтеп,
Киез бәйләп керсәң әй!
Сине дә күреп Норадын,
Ай-көнле дип белсә әй!
«Бу кем кылды»— дигәндә,
«Атаң кылды» дисәң әй!
Атасы белән бозылып,
Икәве бердәй түнсә[384] әй!
Алар да китеп тәхеттән,
Синең энең яшь солтан
Кадыйрбирде хан булып,
Әүвәлгедәй дан булып,
Дәүран гомер сөрсә әй!

Җанбай алай дигәндә,
Ханәкә торып килгәндә,
Киез бәйләп карнына,
Хансарайга иңгәндә,
Норадын аны күргәндә—
— «Бу ни?»— диеп торганда,
Ханәкә солтан аны әйтте:
— «Атаң белер мәгънәсен!»
Моны ишетеп Норадын,
Күмердәй кара киселде.
Атасын күреп тәхеттә
— А!— дип анда җикерде.
Кулындагы думбыра
Кулында түзми сикерде.
Анда чыгып уң күзе,
Күзсез калды Идегәй.

## XV

## ИДЕГӘЙНЕҢ НОРАДЫНГА РӘНҖЕП ӘЙТКӘНЕ, НОРАДЫННЫҢ БҮЛЕНЕП КИТКӘНЕ

Идегәй анда рәнҗеде,
Рәнҗегәндә моны әйтте:
— Норадын булсаң, булсана!
Болытка җиткән Нарс тауны
Җилеп үк үтсәң үтсәнә!
Таңда чыккан Чулпандай,
Яна да яна торсана!
Шул теләк белән тудырдым,
Дүрт кырлап учак өйдердем.
Кызылдан[385] бишек кылдырдым,
Алтыннан чөмәк уйдырдым,
Көмештән төбәк койдырдым,
Уен осталардан уйдырдым,
Сырын сырлаучылардан сырдырдым;
Әй тумагыр, тумагыр,
Сине каян тудырдым?!
Син туганда, Норадын,
Ту бияләр суйдырдым;
Алты көнләп аш биреп,
Галимнәрне туйдырдым.
Җиде көнләп аш биреп,
Ятимнәрне туйдырдым.
Хан кашында туды дип,
Атыңны Норадын куйдырдым.
И тумагыр, тумагыр,
Сине каян тудырдым?!
Син яманны тудырып,
Калкаи-камка түшәттем.
Калкаи-камка каты дип,
Сусарыма биләттем;
Сусарым суык булыр дип,
Күк тиенгә биләттем,
Күк тиенне тиң күрми,
Кара кешкә биләттем;
Кара кешнең эчендә
Аначылар хурлар дип,
Бавырыңны күтәртми,
Биленә садак ураттым.
Гарәби китап укыган
Галимнән мәгънә сораттым,
Кочаклап Корьән укыган
Мулладан мәгънә сораттым.
Әй колыным, мин сине
Бигә нөгәр алдырдым,
Ханга лаек туды дип,
Ханнан кәбәч[386] алдырдым;
Астың атка кансын дип,
Аргамак сайлап менгердем,
Иңең тунга кансын дип,
Атлас сайлап кидердем;
Күкрәгең яулы үссен дип,
Качкан яуны кудырдым,
Башлап ханны кудырдым,
Аны да синнән үтерттем,
Картайган да көнемдә
Үз башыма көч иттем!
Каудан җиргә ут салдың,
Утны[387] кайдан утларсың?

---

384 түну — 1) төшү, 2) юкка чыгу.
385 кызыл — кызыл агач.
386 кәбәч — түбәтәй.
387 ут — үлән.

Кара суга кан койдың,
Суны кайдан эчәрсең?
Кара аргамак катырдың,
Атны кайдан менәрсең?
Кара лачын кау иттең,
Кошны кайдан чөярсең?
Катифәне[388] хурладың,
Тунны кайдан киярсең?
Калың[389] нөгәр таркаттың,
Нөгәр кайдан тотарсың?
Ханәкәне алҗыттың,
Сылу кайдан кочарсың?
Кардай чәче агарган,
Курдай күзе кызарган,
Син дигәндә җан аткан
Ялгыз атаң мин идем,
Күзем орып чыгардың,
Кайда барып уңарсың?
Кайда барсаң, тынарсың?
Языгы белән гөнаһысын,
Кайда ла барып йоларсың?
Ир Норадын анда әйтте:
— Язгы кауга ут салсам,
Үртән[390] сайлап утлармын;
Кара суга кан койсам,
Су тоныгын эчәрмен;
Кара аргамак катырсам,
Толпар сайлап менәрмен;
Кара лачын кау итсәм,
Шоңкар сайлап чөярмен;
Катифәне хурласам,
Турка [391] сайлап киярмен.
Калың нөгәр таркатсам,
Хан-солтаннан тотармын!
Ханәкәне алҗытсам,
Сылу таңлап [392] кочармын.
Кардай чәче агарган,
Курдай күзе кызарган,
Мин дигәндә җан аткан
Ялгыз атам син булсаң,
Син сүзеңнән тангансың,[393]
Килененне алгансың!
Күзең орып чыгарсам,
Тәңре өе Кәгъбәне
Бер әйләнсәм уңармын,
Өч әйләнсәм тынармын;
Языгы белән гөнаһысын,
Җиде әйләнсәм, йолармын!
Аны әйткәндә Норадын
Елдырым ташлы[394] пычагын
Суырып алды кынаптан.
Кабына сыймый йөрәге,
Кайтыр микән каһәрем дип,
Атылып чыкты сарайдан.
Елдырым ташлы пычагын
Кара ташка бер орды,
Кара ташны как ярды.
Каһәре кайтып Норадын
Кайтып килде сарайга,
Атасына аны әйтте:
— Уй[395] дигәндә кыр[396] дигәй,
Уйны баскан морзамын!
Ханнар белән, биләр белән
Коемлашкан[397] морзамын;
Коемлашым беткән соң,
Алыс-алыс җирләргә,
Үзгә телле илләргә
Илче кылып игәнмен.[398]
Йөлте белән үссен дип,
Яфрагы нурдан яралган,
Байтагымның алдына
Бостанлы[399] тирәк булганмын!
Ай кашында Зөһрәдәй
Балкый-балкый туганмын;
Таңда чыккан Чулпандай
Яна-яна торганмын.
Сүзле адәмне сөйләтмәс
Инәдән чичән туганмын!
Тешле адәмне тешләтмәс
Инәдән тешле туганмын;
Булыр җирдән булганмын!
Арысландай биншем[400] корышып,
Ат ярышта узганмын;
Кылыгым[401] кемгә яраса,
Кысмәтен [402] аның кылганмын!
Китәрмен, атам, китәрмен,
Шаһ Тимергә җитәрмен,
Тимер биргән кир атны[403]
Тирләткәнче менәрмен;
Тимер биргән тимер тун
Сүтелгәнче киярмен!
Унике тотам укларны
Бетергәнче чөярмен!
Тимер белән антым бар,

---

[388] катифә — хәтфә.

[389] калың — күп.

[390] үртән — даланы яндырганнан соң үсеп чыккан үлән.

[391] турка — кытай ефәге.

[392] таңлау — сайлау, соклану.

[393] тану — таю, сүз тотмау.

[394] елдырым ташлы — биредә: үткен мәгънәсендә. Елдырым — яшен.

[395] уй — уйсу, сазлы җир.

[396] кыр — биредә: калку, коры җир.

[397] коемлашу — мәҗлестәш, утырдаш булу.

[398] игү — җибәрү.

[399] бостанлы — бакчада үскән.

[400] бинеш — атка менгәндә кияр өчен махсус рәсми кием.

[401] кылык — холык.

[402] кысмәт — хезмәт.

[403] кир (чир) ат — сугыш аты.

Тимер белән шартым бар:
Тимер биргән сылуны
Алдыма алып сөярмен!
Алтыннан байса[404] сuктырып,
Өгемә[405] шоңкар чөярмен,
Алты арбага ак ябып,
Алтысына нар җигеп,
Исәнемдә, савымда
Тутыра алтын төярмен.
Анда торып Норадын
Атына менеп атланды.
Айтулы ару анасы
Норадынга анда әйтте:
— Әй Норадын, Норадын!
Каз төшермәс күлләргә
Каз төшереп уйнаттың,
Каздай башын агарткан
Атаңны нигә уилаттың?
Әй Норадын, Норадын,
Ку кундырмас күлләргә
Ку кундырып уйнаттың,
Кудай башын агарткан
Анаңны нигә уилаттың?
Кара суга кан койсаң,
Суны кайдан эчәрсең?
Халык белән даулашып,
Яхшыны кайдан табарсың?
И, Норадын, Норадын,
Каулы җиргә ут салып,
Утны кайдан утларсың?
Халык белән яулашып,
Яхшыны кайдан табарсың?
Җавап бирде Норадын:
— Әй инәкәм, инәкәм,
Кара суга кан койсам,
Балдан ширбәт эчәрмен,
Халык белән даулашсам,
Йорт яхшысын табармын.
Әй инәкәм, инәкәм,
Каулы җиргә ут салсам,
Ут яхшысын табармын,
Халык белән яулашсам,
Йорт яхшысын табармын!
Янә әйтте анасы:
— Әй Норадын, Норадын,
Идел дигән су килер,
Аны ничек кичәрсең?
Итәгендә ил булыр,
Аны ничек үтәрсең?
Әй Норадын, Норадын,
Җаек дигән су килер,
Аны ничек кичәрсең?
Ягасында ил булыр,
Аны ничек үтәрсең?
Җавап бирде Норадын:
—Әй инәкәм, инәкәм,
Ике ташны култыклап,
Идел кичкән улыңмын;
Иделдән яуга төшеп,
Исән чыккан улыңмын;
Идел дигән су булса,
Ике чумсам кичәрмен,
Итәгендә ил булса,
Ике орсам үтәрмен.
Әй инәкәм, инәкәм,
Ялгыз ташны култыклап,
Җаек кичкән улыңмын;
Янгыздан яуга төшеп,
Исән чыккан улыңмын,
Җаек дигән су булса,
Бер чумганда кичәрмен,
Ягасында ил булса,
Бер органда үтәрмен!
Янә әйтте анасы:
— Әй Норадын, Норадын,
Бер агачта мең ботак —
Аны кисим диденме,
Бер үзенә мең кеше —
Аны изим диденме?
Җавап бирде Норадын:
— Әй инәкәм, инәкәм,
Бер агачта мең ботак,
Бер ботактан нисе артык?
Атның аттан нисе артык?—
Бер атлаган боты артык!
Ирнең ирдән нисе артык?
Бер сөйләгән сүзе артык!
Бер үземә мең кеше,
Бер кешедән нисе артык?—
Аны әйтеп, Норадын
Чыгып китте баш тартып.

## XVI

## НОРАДЫННЫҢ КАЙТЫП АТАСЫН КУГАНЫ, ИДЕГӘЙНЕҢ КАЗАК ЧЫГЫП КИТКӘНЕ

Кәмалның улы Киң Җанбай
Көннән бер көн Идегәйгә
Бер килмәсә бер килде,
Бер килгәндә аны әйтте:
— Идегәй, син таңдагы көн,
Яу өстенә яу килсә,

Ялгыз нигә ярарсың?
Дошманың аулай үләрсең;
Норадын яман улың түгел иде,
Кендегеңне борырсың!
Анда әйтте Идегәй:
— Яхшы әйттен, җанәкәсе,
Бик хуш әйттең, яу нәкәсе[406]!
Яу өстенә яу килсә,
Ялгыз нигә ярармын?
Дошман аулай үләрмен,
Йә дошманга калырмын.
Норадын яман углым түгел иде,
Кендегемне борырмын!—
Норадын дала кичкәндә
Айлар, көннәр үткәндә
Ялгыз угылын сагынып,
Сагынып та зарыгып,
Идегәй аны җырлады:
— Алыстан кара күренсә,
Әйләнешкән морза углым,
Юыктан кара күренсә,
Тулганышкан морза углым,
Бурай-бурай кар яуса,
Буз киерешкән морза углым,
Бура сынлы ут килсә,
Булат калкан — морза углым.
Читтә солтан булудан
Илдә олтан булу артык;
Күктә чулпан булудан
Суда чуртан булу артык.
Әй Норадын, улым әй,
Сагындырдың мине артык!
Анда торып Идегәй
Ил өлкәне биләргә
Киңәш-уңаш иткән соң,
Норадынны чакыртып,
Илчеләрен җибәрде.
Илчеләр җитеп килгәндә
Норадынга аны әйтте:
— Ирекле ир атаңнан[407]
Өндәү килде «кайтсын!» дип,
Кугын килде «кайтсын!» дип,
Үпкәләсә, үпкә сүзен әйтсен, дип.
Ике канат, бер койрык,
Иңеп шоңкар чөйсен, дип;
Ирнәве алтын сараяк,
Ир саркытын эчсен, дип;
Ай кашында бер йолдыз
Зөһрә балкый торсын, дип;
Таң алдында бер йолдыз,
Чулпан балкый торсын, дип;
Кызыл канлы кылычын
Ак сөт белән юсын, дип,
Иргә сәлам биргәндә
Иңкәеп тәгъзим кылсын, дип,
Асыраган атасын
Ата диеп белсен дип,
Аз гына гаебе булса да,
Анасы аша кичсен, дип.
Анда әйтте Норадын:
— Ирекле ир атамнан
Өндәү килсә дә кайтмасмын;
Үпкәм булса да әйтмәсмен,
Ике канат, бер койрык,
Иңеп шоңкар чөймәсмен;
Ирнәве алтын сараяк,
Ир саркытын эчмәсмен;
Иргә сәлам бирмәсмен,
Иңкәеп тәгъзим кылмасмын.
Ирнең күңеле ефәктәй —
Бер төйнәлсә чишелмәс,
Таразуга[408] салсаң тиңәлмәс,
Мыскалга[409] салсаң, ким килмәс.
Норадын алай дигәндә,
Илчеләрнең мулласы
Пир Галәттин аны әйтте:
— Бер дигәч тә ни яман?
Ходаны белмәс — ул яман.
Икенчеләй ни яман?
Фарыз[410] укымас — ул яман.
Өченчеләй ни яман?
Өзелеп чыгар җан яман;
Дүртенчеләй ни яман?
Төркене[411] юк кыз яман;
Бишенчеләй ни яман?
Бишектәге оланнар
Атасыз калса, ул яман;
Алтынчылай ни яман?
Атадан ялгыз туган ул яман;
Җиденчеләй ни яман?
Җитәкләшеп ятимнәр
Елый-да калса — ул яман;
Сигезенчеләй ни яман?
Ир кулыннан сирпелеп,
Дәүләт тайса — ул яман;
Тугызынчылай ни яман?
Тур бала,[412] кош баласы;
Ояда елый калса ул яман;
Унынчылай ни яман?
Утырган җире җофарлы,[413]

[404] байса — аерым хокук бирелүе турында язылган тактачык.
[405] өге — 1) ябалак, 2) каурый.
[406] нәкәс — куркак.
[407] ирекле ир — Идегәйнең титулы. Чыңгыз нәселеннән булмагач, ул хан була алмый, ә ханнарны куярга, хөкем йөртергә иреге чикләнми.
[408] таразу — көянтәле зур үлчәү.
[409] мыскал — 4,26 граммга тигез авырлык үлчәве.
[410] фарыз — тиешле, мәҗбүри.
[411] төркен — ир хатынының туганнары.
[412] тур бала — ауга өйрәтелергә тиешле кош баласы.
[413] җофарлы — бирелә: хуш исле.

Ун бармагы кыналы,
Төнбоектай күкрәге
Күперep өскә калкыган
Ханәкәдәй арулар,
Кәнәкәдәй сылулар
Елый да калса — ул яман.
Илчеләр алай дигәндә
Кайтып килде Норадын,
Кашка көрән ат менеп,
Ата-анасын үз санап,
Үзгәләрне ят белеп,
Чаба кайтты Норадын,
Атасына ялынып,
Язычы белән гөнаһысы
Үз муйнына алынып.
Идегәй аны күргәндә,
Маңгаен искәп сөйгәндә,
Норадынга аны әйтте:
— Уяу, батыр баламсың,
Уяныклы морза углым!
Буз аргамак баласыдай
Буйлы-сынлы морза углым!
Алсу-кара битле углым!
Ипләләргә ипле углым!
Һавадан очкан алты аккош,
Ун канаты сырлы углым!
Пәйгамбәрнең кияве
Галидәен нурлы углым!
Фирештәдәй битле углым!
Ямәннән[414] кеше җыйсам,
Уртага агач тексәм,
Сине дәрәҗәгә чиксәм,[415]
Саф алтынсың, морза углым!
Идегәй алай әйткәндә,
Дәрәҗәгә чиккәндә,
Ир азамат Норадын
Хан булам дип уйлады.
Атасы хан итмәде,
Үзе дә хан булмады.
Норадын моны күргәндә,
Каһәреннән кыйналды.
Идегәйгә анда әйтте:
— Әйткәнеңнең барысын
Кылганың хак, и ата!
Әйткәнемнең берсен дә
Кылганың юк, и ата!
Йә син үзең хан булгын,
Йә син мине хан кылгыл!
Йә син мине үтергел,
Йә мин сине үтерим!
Йә күземә күренмә,
Казак чыгып кит!— диде.
Анда әйтте Идегәй:
— Әй, Норадын, Норадын,
Аңламыймын морадың!
Туктамышның илендә,
Туган-үскән җиремдә,
Ач бүредәй караштым,
Эт-мешәктәй[416] талаштым.
Биле-савыры көрәнне
Боракка охшаш менгәнмен.
Алтын тауга баргамын,
Түрә булып алганмын,
Халкын җыеп алып килеп,
Ак Урдага салганмын.
Урда өчен тырышкан,
Ягалашып орышкан
Батырларның кайберен
Ил нөгәре кылганмын;
Минем белән бер булып,
Халык өчен тартышкан,
Ягалашып көрәшеп,
Дошманнар белән чәкәшкән
Ыруларның батырын,
Кайсын бием кылганмын,
Кайсын ханым кылганмын,
Нинди юан булса да,
Ялгыз агач өй булмас.
Нинди ятыш булса да,
Ялгыз егет би булмас.
Хан булыем димәче,
Дан булыем димәче,
Ялгыз башың халыксыз,
Сан булыем димәче.
Әй Норадын, Норадын,
Нидер синең морадың?
Идегәй аны әйткәндә,
Ир Норадын моны әйтте:
— Фирештәдәен атам!
Һәр эштә даим атам!
Нигә мине хурлыйсың?
Нигә мине җырлыйсың?
Җырласаң мине, атам,
Җырлавыңа чыдамам.
Хурласаң мине, атам,
Хурлавыңа чыдамам!
Буранлы көн туганмын,
Борыч бирсәң еламам;
Борычтан яман ачымын,
Шикәр түксәң, төчемәм;
Арыслан булып туганмын,
Төрткәнеңә коламам;[417]
Буралкы[418] аттан ярышмын[419]
Бугалак[420] салсаң, туктамам!
Йә син үзең хан булгын!
Йә син мине хан иткел!
Йә күземә күренмә,

---

[414] Ямән — ?
[415] чигү — чөю, мендерү.
[416] мешәк — мәче.
[417] колау — егылу.
[418] буралкы — ?
[419] ярыш — биредә: ярсу.

Казак чыгып кит!— диде.
Норадын алай дигәндә
Азамат ир Идегәй,
Җиде кат күктәй күкрәде,
Авазы калкып, яңгырап,
Норадынга аны әйтте:
— Кузагачтан[421] биекмен,
Болытка җитми тынмасмын;
Башымнан давыл өрсә дә,
Мин аңардан сынмасмын!
Киреләнсәм, йокың бозармын,
Көрәшсәм, сине егармын,
Йөгерсәм, сине узармын,
Каргышым кара таштан үтәдер,
Аһым җирне-күкне тотадыр,
Күтәрә алмассың, Норадын!
Анда Идегәй аһ орды,
Норадын артка егылды,
Авызы-борыны кыйшайды.
Анда әйтте Киң Җанбай,
— Норадын бердәнбер баландыр,
Каргыш итмә, Идегәй,
Алкыш иткел углыңа!
Анда углын аяды,
Алкыш бирде Идегәй,
Норадын янә терелде,
Авызы-йөзе төзәлде.
Тора килеп Норадын
Идегәйгә янә әйтте:
— Кисәкчә чыккан болытмын,
Яумаенча таркалмам,
Анадан кара туганмын,[422]
Сабынлап юсаң агармам!
Булаттан кыеш чыкканмын,
Алдыңа алсаң, төз булмам!
Йә син үзең хан булгын!
Йә син мине хан иткел!
Йә күземә күренмә,
Казак чыгып кит!— диде.
Анда торып Идегәй
Норадынга аны әйтте:
— «Ялгыз баланың кылыгы
Яудан яман»,— дисә, бу булгай.
Җанбайдаен җанбазның[423]
Языгын алып муйныңа,
Җаның исән калдырдың,
Яныңа яучы алдырдың,
Ул да җитәр бер көн җаныңа!
Яфанга[424] чыгып яу җыйдың,
Яудан тынган йортымны
Яу астында калдырдың,
Атаң корган каланы
Күчмәләрдән алдырдың!*
Яу өстенә яу килсә,
Ул да җитәр бер көн башыңа!
Карчыгадай морза углым!
Каулаганың мин булсам,
Мин качаем, син каула,
Һәрбер көндә дошманың
Миндәй качсын, морза углым!
Анда торып Идегәй янә әйтте:
Торымтайдан[425] елгыр кош булмас,
Тургай да тибеп, каз алмас!
Аткыдан[426] йөгереп ук булмас,
Атса көбә бозалмас.
Һөнәрсез сине күрә алмас,
Илдән-илгә җилеп үтсәң дә,
Бу дөньялар сиңа да калмас!
Аны әйтеп Идегәй
Иделдән чыгып юнәлде.

## XVII

## НОРАДЫННЫҢ КАДЫЙРБИРДЕ КУЛЫНА ТОТСАК[427] БУЛГАНЫ

Идел йорт ике булганда,
Ил берекми торганда,
Идегәй белән Норадын
Ике яры булганда,
Ир Норадын ил-йорттан
Үз атасын куганда,
Хансарайда Норадын
Хан булдым дип торганда,
Кадыйрбирде яшь солтан
Бу хәлләрне күргәндә,
Минем дә көнем житте дип,
Яу-ярагын торгызды.
Калган-каткан ирләрен
Үз янына җыйдырды.
Анда житеп яз килде,
Чирүле күлгә кош килде.
Кадыйрбирде яшь солтан
Чирүен алып алдына,
Чирүле күлгә кундырды.
Алтын сарай, хансарай,
Хан сарае ак ишек,
Ир Норадын килгәндә,
Ал тәхеткә менгәндә,
Ал тәхетнең аркасы
Алтын егач тутый кош
Сайрап телгә килгәндә,
Азамат ир Норадын
Киң Җанбайга анда әйтте:
— Әй Киң Җанбай, Киң Җанбай!
Син дә минем би икән,

Мин дә синең хан икән,
Чирүле күлдә ау юкмы,
Барып байка!— дип иде.
Кәмалның улы Киң Җанбай:
— Ул да бездән булды,— дип,
Аргамагын атланды.
Чирүле күлгә килгәндә
Кадыйрбирде солтанның
Посуда яткан чирүе,
Корык ташлап артыннан,
Җанбайны егып атыннан
Кулын анда каерып,
Тотсак итеп маерып,
Кадыйрбирде солтанның
Чатырына апкилде.
Кадыйрбирде анда әйтте:
— Нугайлының агыр йорт —
Туктамыштай атамның
Байтак куган җире иде;
Тугыз солтан атасы
Туктамышның бие идең,
Бүген кемгә би булдың?
Алтын ташлы тәхтемә
Бүген кем углын мендердең?
Анда әйтте Киң Җанбай:
— Тулай йортның иясе
Туктамыш хан көнендә
Мин дә аның бие идем;
Туктамыштай хан улы
Кадыйрбирде син идең...
Бүген син дә ни булдың?
Бүген мин дә ни булдым?
Кадыйрбирде солтаным,
Бер кашык каным багышла,
Идегәй улы Норадынны
Кулыңа китереп бирием!
Җанбай сүзен биргәндә
Кайдырбирде яшь солтан
Аны кулдан җибәрде,
Кайта килеп Киң Җанбай
Норадынга аны әйтте:
— Әй Норадын, хан-ия!
Мин дә бүген би икән,
Син дә бүген хан икән,
Багыңнан багың сынасаң,
Сыярлыгың бар икән.
Ау лачының ала йөр,
Чирүле күлдә яу икән...
Атланыек, хан-иям!
Җанбай алай дигәндә,
Норадын белән икәүләп
Чирүлегә килгәндә,
Күз ачып күз күргәндә,
Җанбай анда юк булды,
Идегәй улы Норадынның
Әйләнәсе яу булды.
Күз ачып күз йомганчы
Корык ташлап артыннан,
Норадын, авып атыннан,
Аягы-кулы бау булды;
Төшкән җирен караса,
Бер караңгы баз булды;
Базына таш ябылды.
Кадыйрбирде яшь солтан,
Анда сорнай чалдырып,
Чыңгызларын[428] җыйдырды.
Олыс[249] бие Барынны,
Орыш бие Шырынны,
Төмән башы[430] Туйбакны,
Аждарканнан Мулайны,
Мөйтәннән туган Кыпчакны,
Кәмалның углы Җанбайны,
Тугыз ирен янга алып,
Анда киңәш кылдырды:
— Әзәлдән дошман Норадын
Такка менгән көнендә
Тагыннан базга егылды,
Инде аның да атасы
Идегәйне каян тотыек?
Туйлап киңәш иткән соң,
Тугыз чыңгыз — тыгыз ир,
Тугызы да уллы икән,
Тугыз улын торгызып,
Тугыз илче кылдырып,
Иделне үтә кичереп,
Идегәйгә җибәрде.
Тугыз илче — тугыз ул,
Идегәйгә җитеп килгәндә,
Тугыздан бере аны әйтте:
— Синең углың Норадын,
Тәхетеннән язып хур булды,
Кулыбызда тотсак, кол булды,

---

420 бугалак — буу өчен элмәк

421 кузагач — чикләвек агачы, кедр

422 кара туу — чыгышы түбән сыйныфка ишарә

423 җанбаз — җан белән уйнаучы

424 яфан — япан, кыр, дала

* күчмәләрдән алдырдың — бу урында сүз Идегәй яуда чагында Норадынның күчмә халыклар ярдәмендә Сарайны басып алуы турында бара.

425 торымтай — лачын тәреннән кечкенә кош

426 аткы — төз колаклы ук

427 тотсак — тоткын

428 чыңгызлар — чыңгыз нәселе

429 олыс (өлеш) — өлкә, территория

430 төмән башы — ун мең сугышчыдан торган гаскәр башлыгы

Аны да жолып алмагың
Әле синең хәдендә,[431]
Углың кунын бирерсең;
Кадыйрбирде солтанга
Безнең белән килерсең;
Углың ясак, башың сау булыр,
Ясагына күнмәсәң,
Үлтерелер Норадын.
Тугыз илче — тугыз ул
Идегәйгә аны дигәндә,
Ул тугызның җидәвен
Идегәй тотып бәйләтте.
Икәвен кайта җибәрде:
— Кадыйрбирде солтанга
Кайта житеп әйтегез,
Норадынны нитсә дә,
Анда үзе белгән эш,
Монда калган җидәүнең
Җидәвен дә юк кылам!
Ул тугызның икәве
Кайта житеп килгәндә,
Җиденең җиде атасы
Кадыйрбирде солтанның
Аягына егылды:
— Җидебез дә чыңгызлар,
Җидебезнең җиде угыл,
Җидәвен дә коткаргыл!
Киңәш-уңаш кылган соң,
Кадыйрбирде Идегәйгә
Кайтадан илче күндерде:
«Тотсак иткән җидеңне
Җидәвен дә кайтаргыл.
Норадындай баланы
Мин дә сиңа кайтарыйм».
Илче кылып игән соң
Кадыйрбирде анда әйтте:
— Кулга төшкән дошманны
Кайтадан буш күндерсәк,
Безгә лаек эш булмас.
Бер хәйләсен кылыйк,— дип,
Норадынны баздан алдырды.
Аягын анда салдырып,
Ялангачка калдырып,
Тимер чөй каккан кара идән —
Кара идәнгә бастырды.
Норадын анда кергәндә
Ни булганын аңлады,
Буй-буй такта, буй такта,
Тимер чөй каккан буй такта,
Пычаклап суккан урындык,
Ир Норадын курыкмады.
Басып атлап узганда
Йөзен бер дә чытмады,
Пычаклап суккан урынга
Тайчанмастан утырды.
Кадыйрбирде сорыйдыр:
— Аркадан күчкән алты арба,
Алтавы да казна арба,
Аны ниттең, Норадын?
Җавап бирде Норадын:
— Аркадан күчкән алты арба,
Алтавы да казна арба.
Тулгашканда[432] мин аны,
Адашканым бардыр дип,
Адашканда мин аны
Сәдака итеп биргәнмен!
Кадыйрбирде сорыйдыр:
— Тулгый-тулгый йөгергән,
Йөгергәндә жир бавырын кыдырган,
Тустаган күзле турыны,
Аны ниттең, Норадын?
Җавап бирде Норадын:
— Тулгый-тулгый йөгергән,
Йөгергәндә жир бавырын кыдырган,
Тустаган күзле турыны
Тукыш иткән көннәрдә
Үз астыннан менгәнмен.
Менеп алып, сугышта
Үзеңә каршы йөргәнмен!
Анда утырып Киң Җанбай
Норадынга аны әйтте:
— Тулгамалы айбалта,
Аны ниттең, Норадын!
Кыннан чыкса, сыналган,
Туры чапсаң баш кискән
Алжасман дигән кылычны*
Аны да ниттең, Норадын?
Тугыз солтан атасы,
Тулай йортның иясе,
Туктамыштай хан ирне
Аны ниттең, Норадын?
Ханәкәдәй күреклене,
Көнәкәдәй сылуны,
Аны ниттең, Норадын?
Кисмә-кисмә сары алтын,
Мөһер суккан саф алтын,
Энҗе-гәүһәр якутны,
Аны ниттең, Норадын?
Җавап бирде Норадын:
— Тулгамалы айбалтаң,
Тукыш иткән җирләрдә
Уң кулыма алганмын,
Алып кайрап салганмын,
Карыны юан биләрнең,
Иңкәйтеп, башын алганмын!
Тугыз солтан атасы,
Тулай йортның иясе
Туктамыштай хан ирне
Төнәй-төнәй куганмын!

---

[431] хәд — мөмкинлек.

[432] тулгашу — буталу

* Алжасман дигән кылыч — эпос каһарманнарының коралы, киеме дә, аты, кошы кебек үк исемле була.

Иртеш башы Кара Тунда*
Куа барып житкәнмен;
Кыннан чыкса сыналган,
Туры чалсаң таш кискән,
Каерып чалсаң баш кискән
Алжасман дигән кылыч белән
Туктамыштай хан ирнең
Сакалын ала кан итеп,
Башын кисеп алганмын...
Канлы башын атаның
Канжагама такканмын,
Канжагама такканда,
Карындыкка сарганмын,
Атам алдына китереп салганмын.
Ханәкәдәй күреклене,
Көнәкәдәй сылуны,
Тәңре үзе миңа биргәндә,
Тиген улжа кылганмын.
Кисмә-кисмә сары алтын,
Мөһер суккан саф алтын,
Энже-гәүһәр, якутны
Халыгыма мин барын
Кисеп улжа кылганмын!
Кәмал углы Киң Жанбай,
Кире сүзгә эт Жанбай!
Арырак китеп сөйлә син,
Бирерәк килеп тыңла син!
Колан[433] коега төшкәндә,
Корбага[434] айгырлык кылыр,
Норадын турга[435] төшкәндә
Жанбай аударлык[436] кылыр!
Ачма күзең, тишәрмен,
Сөйләмә, телең кисәрмен!
Эчеңә кереп мин синең,
Кара жылан булып гизәрмен!
Аш биргәннең улысың,
Мал биргәннең колысың!
Коллык кылып жиде балаң,
Жиде буының корысын!
Кадыйрбирде яшь солтан,
Норадынны өнсез табып торасың;
Озын угы, киң жае[437]
Төшми тора кулыңа,
Озын угы, киң жае
Төшә куйса кулыңа,
Синдәй әйткән солтанны
Жибәрмәсме иде ир үзе
Атаң барган «кайтмас йорт»ның
юлына?
Алчылар[438] белән алдатып,
Садак-савыт ташлатып,
Хәйлә белән кулга алып,
Кадыйрбирде яшь солтан,
Чөй үткәреп[439] торасың:
Заманында белеп әйткән үкенмәс.
Кузагачтан биекмен,
Болытка тисәм бөгелмәм,
Кайнашып беткән ботакмын,
Өермә сукса, иелмәм;
Буралкы аттан ярсумын,
Борыныма чөй үткәрсәң, чыдармын.
Бусгынчыктан[440] кыешмын,
Тезгә салсаң, төз булмам,
Ак диңгездән ачымын,
Шикәр түксәң, төчемәм,
Тулай йортның иясе
Туктамыш атлы атаңны
Кисә кырыккан арысланмын!
Йөрәгемә пычак тыксаң да,
Әйтермен, һич курыкмамын;
Коралсызларны кыйнау,
Йоклаганнарны үтерү
Көчсез кеше эше ул,
Юньсез кеше эше ул!
Норадын алай дигәндә,
Пычаклап суккан урындык
Ботын ярып кергәндә,
Аягыннан кан саркып,
Йөзлегенә иңгәндә,
Кымшанмастан утырып,
Турыдан жавап биргәндә,
Кадыйрбирде яшь солтан
Норадынга таң калды.
— Андый батыр ир булдың,
Атаңа миннән сау юнәл!
Аны әйттеп яшь солтан,
Норадынның кулын чиштерде,
Эчерге,[441] ияр салдыртмый,
Менәренә ат бирде,
Жайдак атка мендерде,
Иделгә туры китерде.
Тирләп килгән атыннан
Ярасына үтеп кара тир,
Ягыр[442] булып Норадын,

---

* Иртеш башы Кара Тун — тарихи чыганакларда Туктамыш Себер (Төмән йә Томск) якларында үлгән дип күрсәтелә. Әмма аның Идегәй яисә Норадын тарафыннан үтерелүе турында хәбәр юк

433 колан — кыргый ат.

434 корбага — гөберле бака.

435 тур — ?

436 аударлык — тылмачлык.

437 жае — жәясе.

438 алчы — алчак, түбән кеше.

439 чөй үткәрү — борынга божра, бау үткәрү өчен тишек ясау.

440 бусгынчык — ?

441 эчерге — ат ияре астына куела торган киез.

442 ягыр — кеше ярасына ат тире үтеп агулану.

Торалмаслык булсын дип,
Атны кызу җилдерде.
Иделгә килгән Идегәй
Идел аша кычкырды:
— Кани[443] углым Норадын?
Аны миңа җибәрсен,
Бу җидәүне җибәрим!
Кадыйрбирде бу яктан
Норадынны салга артлап,
Идел үтә җибәрде.
Ике яктан ике сал
Икәве бергә килгәндә,
Арыдан торып Идегәй,
Норадынга тулгап аны әйтте:
— Ку канатын сал итеп,
Идел кичкән морза углым!
Каз канатын сал итеп,
Җаек кичкән морза углым!
Салны салга бәйләче!
Сал эчендә җидәүне
Яхшы уңгарчы, морза углым!
Идегәй алай дигәндә,
Саллар салга килгәндә,
Норадын салны сөздереп,
Салны салга бәйләде.
Салда утырган җиде угыл,
Җидәвен дә үтереп,
Ана Иделгә колатты.
Иделне кичеп Норадын,
Идегәйгә килгәндә,
Гозер-гафу үтенеп,
Кулыннан үбеп йөгенде.
Ярасына үтеп кара тир,
Ягыр булып Норадын
Ул сәгатьтә егылды.

## XVIII

## КАДЫЙРБИРДЕ СОЛТАННЫҢ УРДА ТОРГЫЗЫП ИДЕГӘЙ ӨСТЕНӘ БАРГАНЫ, ИДЕГӘЙНЕҢ ОРЫШТА ҮЛГӘНЕ

Кадыйрбирде яшь солтан
Анда утырып яр салды:
— Дәүран сөргән көнемдә
Идегәй исән икәндә
Идел йорт миңа ил булмас,
Күргән көнем көн булмас,
Йә Идегәй, йә дә мин!
Атланыек, ятмыек.
Аны әйтеп яшь солтан
Оран салып атланып,
Бар урдасын җыйдырды.
Атадан калган кара ту
Сынган икән, сап куеп,
Аны уңнан бастырып,
Дум-думбагын ордырып,
Хан урдасын торгызды.
Кәмал улы Киң Җанбай
Кадыйрбирде солтанга
Киңәшен биреп, анда әйтте:
— Тулыксыган ана Идел
Тулкына биреп ятканда
Иделдән чирү күчерү
Кыен булыр, солтаным.
Идел туңсын, боз тотсын,
Юл ачылсын, солтаным.
Идегәй инде карыган,
Алтмышыннан яше узган,
Куя торсаң, ни булыр?
Җанбай алай дигәндә,
Кадыйрбирде солтанга
Ул сүз анда якмады,
Үз уеннан кайтмады:
— Идел туңса, кем кичмәс?
Идегәй үлсә, кем алмас?
Иделне туңмас борын кичмәк кирәк,
Идегәйне үлмәс борын алмак кирәк.
Һәй моңаймаң, беләрем!
Кайта чапсам, көн килде!
Каерып чапсам, баш килде!
Идегәй улы Норадын
Ягыр булып калганда,
Идегәйнең урдасы
Иген-тару алганда
Ул көн миңа бер килде!
Атланыек, ятмыек!
Тулыксыган Иделне
Туңмас борын кичиек!
Үләр булса Идегәй,
Үлмәс борын алыек!
Кадыйрбирде алай дигәндә,
Алты йорты юк булган
Алты йорттан алты би,
Җиде углы юк булган
Җиде ырудан җиде би,
Ярлыгыннан аерылган
Ярты тархан, ярты би,
Җир-суыннан аерылган
Ярты вәзир, ярты би:
— Рас әйтерсең, ханым! — дип,
Аның сүзен җөпләде.

Аттан атын җыйдырды,
Ирдән ирен җыйдырды.
Кадыйрбирде яшь солтан
Чирүен әйдәп кузгатып,
Ана Иделгә китерде,
Иделне аша кичерде.
Кадыйрбирде килгәндә,
Идегәй аны сизгәндә,
Тора биреп корганып,
Яндашларын янга алып,
Ул да купты урыныннан.
Тарлан бүзне атланып,
Сугышка дип барадыр.
Гайрәте судай ташадыр,
Ачуы чиктән ашадыр.
Атына камчы салган соң,
Яуны килеп басадыр,
Кайда садак тартадыр,
Кайда мылтык атадыр;
Кайда кылыч селтәләп,
Кайда сөңге белән батадыр.
Ул читеннән керәдер,
Бу читеннән чыгадыр,
Куйга кергән бер бүре,
Бүре куйны кырадыр.
Иртә булды, кич булды,
Калын сугыш — эш булды.
Көн тотылып чаң булды,
Ике чирү бер килеп,
Ике Иделнең арасы
Икесенә тар булды.
Аттан тояк калмады,
Баштан колак калмады,
Тапталып яткан үлекнең
Исәбе-саны булмады.
Сансыз татар, кара яу
Якадан якага алышып,
Берсенә берсе капланып,
Теш-тырнагын актарып,
Бугазга-бугаз чәйнәшеп,
Ни булганын белмәде.
Кайсы башын актарды,
Кайсы җирдә тапталды,
Кич булганда шул булды —
Һәр ике як аз калды.
Идегәй андый ир булды:
Үлем, үлем дигәндә,
Үлем килеп йөзенә
Үле тынын өргәндә
Чигенмәде Идегәй.
Үлем, үлем дигәндә,
Ун мең төмән сан кеше
Үлемгә баш игәндә
Иелмәде Идегәй.
Кадыйрбирде солтанга
Җанбай анда моны әйтте:
— Алтмыштагы Идегәй
Хәлдән хәле киткәндә,
Ике чирү бер килеп,
Кан заяга киткәндә,
Бермә-бергә бер чыгып,
Бер чүкерсәң, ни булыр?
Җанбай алай дигәндә,
Кадыйрбирде яшь солтан,
Гайрәте килеп, анда әйтте:
— Идегәй андый ир икән,
Идел йортта бер икән,
Ирекле кеше ул булып,
Илне тоткан ир икән;
Идегәй илдә бер икән,
Ил сыртланы ир икән:
Бүре булып барыем,
Бурбаеннан[444] алыем!
Арслан булып барыем,
Арвагын[445] басып алыем!
Бер давыл булып барыем,
Бер чүкереп багыем!
Атагы[446] өлкән ул булса,
Аның да булган атагын
Үземә тартып алыем!
Аны әйтеп яшь солтан,
Суырып алып кылычын,
Чаба килеп ул анда
Идегәйгә тулгады:
— Түбәдәге дүрт йолдыз
Таң атар көн тугандыр!
Көрән туры ат койрыгы
Дүрт чалуга тулгандыр!
Калган-каткан ил булып,
Кадыйрбирде хан булып,
Элгәргедәй дан булып,
Яшәр көннәр тугандыр!
Көбәләр белән корганып,
Чөйдәле[447] балта кулга алып,
Чөйдәгезгә бер менеп,
Чабар көннәр тугандыр!
Анда әйтте Идегәй:
— Түбәдәге дүрт йолдыз,
Таңы атар көн туалмас!
Көрән туры ат койрыгы
Дүрт чалуга тулалмас!
Калган-каткан ил булып,
Кадыйрбирде хан булып,
Туктамыштай дан булып
Яшәр көннәр туалмас!
Көбәләр белән корганып,
Чөйдәле балта кулга алып,
Кадыйрбирде, чөйдәмә
Чабар көннәр туалмас!

---

[443] кани — кая, ничек.
[444] бурбай — тезнең аскы сеңере.
[445] әрвах — рух.
[446] атак — дан.
[447] чөйдәле —?

Кадыйрбирде тагы әйтте:
— Каңтарда[448] яуган болыттай,
Зәһәрле суык төсем бар,
Эзләп килдем үзеңне,
Суеша торган эшем бар!
Җавап бирде Идегәй:
— Кабагыннан кар явып,
Керпегенә боз туңып,
Эзләп килгән Кадыйр белән
Ярышырга көчем бар.
Аны да бел, Кадыйрау,
Арыслан хәлдән тайса да,
Бер сарыклык көче бар!
Анда алай әйтешеп,
Ике таудай ике ир,
Типке биреп атына,
Беренә бере юнәлде.
Җиз көбәсе шаңгырап,
Калканы чыгып калкаеп,
Беренә бере «шаңк»... итте.
Җир селкенде, ярылды,
Ярылганнан аз калды;
Алатау белән Колатау
Беренә бере бәрелде,
Бәрелгәндә сау калды!
Алты батман чукмарын
Идегәй тулгап алганчы,
Чөйдәле балта кулга алып,
Кадыйрбирде бер сукты.
Идегәйнең калканы
Анда шыңлап ярылды.
Идегәй анда чукмарын
Янә бер тулгап алганда,
Аван куллы Кадыйрбирде
Янә килеп бер сукты,
Көбәсе сынып, кан чыкты.
Янә бер сугыйм дигәндә,
Анда инде Идегәй
Алты батман чукмарын
Өч тулгады, бер сукты,
Андый итеп бер сукты,
Ат саурысы «чырк»... итте,
Кадыйрбирде бер чүкте,
Түбәсеннән кан чыкты,
Кан чыкканда җан чыкты!
Ул атыннан ауганда,
Биләр шаша калганда,
Атын сөреп Идегәй
Кача бирде арадан!
Барын морза аны әйтте:
— Әй Туктамыш биләре!
Туктамыш буыны киселде.
Хан булыр хан калмады.
Ханнан калган карышкы,[449]
Карышкысын кем алыр?
Хан тагына кем менәр?
Тулай йортны кем биләр?
Идегәй исән калганда,
Халкын җыеп алганда
Иңсез яткан Идел йорт —
Ил Идегәйгә калганда,
Туктамышның биләре
Би булыр көн бер тумас!
Әй, Туктамыш биләре!
Хан тагына кем менәр?
Идегәйне кем җитсә,
Җитеп башын кем алса —
Хан тагына ул менәр!
Җәт булыек, биләрем!
Эзеннән баса барыек.
Ярты җаны киткәндә,
Ярты җаны калганда,
Калганын да алыек!
Барын аны әйткәндә,
Унике түрә, алты би
Идегәйне эзләп төшкәндә,
Ары чабып карады,
Бире чабып карады,
Кергән җирне айкады,
Чыккан җирне байкады,[450]
Якыннан тота алмады,
Ерактан күр алмады.
Унике түрә, алты би
Эзеннән эзен чыгарып,
Куа килеп артыннан,
Күлгә җитеп туктады.
Камышлыкка килгәндә,
Тояк эзен күргәндә
Биләр аны карады:
Чыккан эзен тапса да,
Кергән эзен тапмады.
Унике түрә, алты би,
Идегәй янә булмады дип,
Әйләнеп китмәк булганда,
Барын морза аны әйт е:
— Һәй, алданмыйк, биләрем!
Инде киткән юлы юк,
Ат чиктереп камышка
Арты белән кергәндер!
Моннан ары бармыек!
Идегәй исән ир булса,
Шул камыштан алыек.
Җавап бирми булмастыр,
Тулгап сорап карыек.
Камышлыкка якынлап,
Барын анда тулгады:
— Идегәй өлкән ир иде!
Үзеннән бер яшь кечегә:
«Син тора тор, газизем,
Мин атыем» — дир иде.

---

448 каңтар — декабрь.

449 карышкы — асылташлар белән бизәлгән таяк, хан билгесе, скипетр.

450 байкау — чамалау, игътибарлы булу.

Үзеннән бер яшь олыга:
«Мин торыем, газизем,
Син атсаңчы»,— дир иде...
Барын аны әйткәндә,
Калка биреп камыштан,
Идегәй торып аны әйтте:
— Сездәен сөлтекләрдән[451]
Курка торган Идегәй юк!
Көтә торың, чыгармын,
Сөңгем канга тыгармын!
Күк күкрәтеп кылычым,
Яшен уйнатып сугармын!
Аны әйтеп урыныннан
Куба килде Идегәй.
Шам кылычын кулга алып,
Чыга килде Идегәй.
Сул кулыннан кан агып,
Уң кулыннан җан алып,
Калган хәлен бар итеп,
Ора килде Идегәй.
Унике түрә, алты би —
Идегәй анда камалды;
Алар атта, ул җәяү,
Унике сөңге, алты ук
Идегәйгә кадалды.
Анда булды бер сугыш,
Камыш башын кан алды.
Анда әйтте Идегәй:
— Үлем белән куркытмаң,
Курка торган уем юк!
Үлем туры килә икән,
Котыла торган буем юк.
Илем өчен илсенеп,
Җирем өчен җирсенеп,
Халыгым өчен яхшы уем.
Күкрәк тулып җилсенеп,
Көрәшкәнне халыгым
Аңладымы — белалмам!
Аңламаса халыгым,
Аңлатмастан үлалмам!
Барсын бердәй аралап,
Аттан атын яралап,
Анда батыр Идегәй
Унике ирне үтерде.
Кан ярасы ачылып,
Идегәй хәле беткәндә
Барыш морза бер җитеп,
Идегәйне бер чапты.
Башы тәненнән аерылып,
Тәгәри биреп аны әйтте:
— Барын, сиңа ни кылдым?
Берең ике булмасын![452]
Йортың-караң калмасын!
Ханнан ханны мин ектым,
Хан булып син дә калмассың!
Сөт урнына кан койдың,
Канымны түгеп ни кылдың?
Казан, Кырым, Аждаркан,
Кунымны сорап купканда,
Ни булганын анда күрерсең.
Идегәй башы аны әйтеп,
Көнгә табан әйләнде,
Әйләнгәндә янә әйтте:
— Алдагы көн агырга[453]
Без барабыз, ул килмәс!
Аны әйтте дә җан бирде.
Идегәйнең башын кискән Барын* булды,
Башын китергән Шырын* булды.

* * *

Идел йортны дау алды,
Яу өстенә яу килде,
Идегәй әйткән өн килде,
Чыңгызның куйган хан тагы,
Кан тагына әйләнде;
Хан сарае камалды,
Казан, Кырым, Аждаркан
Башлы-башлы ил булды,
Алтын Урда таралды.

---

451 сөлтек — тире эченә үлән тутырып ясалган карачкы.

452 берең ике булмау — үрчүдән туктау.


453 агыр — хөрмәт.

* Барын, Шырын морзалар — тарихта исемнәре мәгълүм нәсел кешеләре. Мәсәлән, Ширинский фамилиясе Шырыннан.

# ФАЙДАЛАНЫЛГАН ЧЫГАНАКЛАР


1. Образцы народной литературы тюркских племен, живущих в Южной Сибири и Юзунгарской степи, собраны В. В. Радловым. ч. IV. СПб., 1872, 27—45; 125—136; 195—204 бб.
2. Идегәй дастаны. Н. Хәким варианты. СССР Фәннәр академиясе Казан филиалы Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты фәнни архивы. 52 ф., I тасв., 167, 176, 178 эшләр.

3. Татар халык дастаны «Идегәй». Н. Исәнбәт җыйнамасы.— Совет әдәбияты. 1940, 11 сан, 39—76 бб.; 12 сан, 34—82 бб.
4. «Идегәй» дастаны. 1941 елда Н. Исәнбәт төзүендә, Х. Ярми һәм Ш. Маннур редакциясендә матбугат өчен әзерләнеп тә басылмый калган җыйнама вариант.— СССР Фәннәр академиясе Казан филиалы Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты фәнни архивы. 52 ф., I тасв., 219 эш.



*Әсәрнең журнал вариантын һәм аңлатмаларны филология фәннәре кандидатлары Илбарис Надиров һәм Флора Әхмәтова әзерләде.*

*Тавил Хаҗиәхмәтов рәсемнәре.*

## ПРОЗА

**Мөхәммәт Мәһдиев**

# БӘХИЛЛӘШҮ

МОҢСУ ПОВЕСТЬ

### 1

*Сез моннан әхлакка файда булмый бит, диярсез. Гафу итегез. Кешеләргә татлы әйберләрне җитәрлек ашаттык; монардан аларның ашказаннары бозылды; ачы дарулар, яндыра торган хакыйкатьләр кирәк.*

М. Ю. Лермонтов, «Безнең заман герое».



Исламгали колхозның менә дигән тракторчысы иде, сугышта ике кулын беләзектән өздереп кайтты. Казан ортопедлары могҗиза ясады: ике кулының икесен дә урталай ярып, җәплекә эшләделәр, кашык тотарлык, каләм тотарлык уентык әмәлләделәр. Исламгали гомер буе җор булды, аның бу сыйфатына гарип калу да зарар китермәде. Ике ордены бар иде, ә медальләрне гел өсти тордылар. Сугыштан да дүрт медаль белән кайткан иде, хәзер исә түгәрәк дата саен өстәп баралар. Исламгали ишетеп яши: шәһәрдә эчүчелек юлына баскан адәмнәр медальләрен саталар икән. Кайберәүләр шуны өч, ун, егерме сумга сатып алалар да тугызынчы май көнне күкрәкләренә тагып урамга чыгалар икән. Исламгали — сугыш гарасатын күргән кеше — бу турыда уйларга да, сөйләшергә дә җирәнә. Ут эченә кергән өчен бирелгән медальне берәү дә сатмас; ут эченә үзе кереп, үлем белән бер генә тапкыр булса да күзгә-күз очрашкан кеше беркайчан да башка берәүнең медален такмас...

Исламгали сугыш, госпиталь, өйгә кайту вакыйгаларын әнәсеннән җебенә кадәр хәтерли. Ул кайткан көннәрдә аларның өеннән кеше өзелмәде. Берәүләр аның җәплекәле кул белән ничек итеп ашаганын күрергә, икенчеләр аның сугыш турындагы хикәяләрен тыңларга киләләр иде. Ләкин үзенең ничек кулсыз калганын сөйләргә яратмый иде ул.

Аңа ходай бирмеш һәр җәйне район тәэминат бүлегеннән санаторийга бер путевка җибәрәләр. Сочига тимер юл билетын өенә китереп

---

Мөхәммәт МӘҺДИЕВ *(1930) — прозаик, әдәбият галиме, «Фронтовиклар», «Кеше китә, җыры кала», «Торналар төшкән җирдә» һәм башка роман, повестьлар авторы. Казанда яши.*

бирәләр иде. Малае Хәмит, әтисен житәкләп, Сочи каласына ничә тапкыр барды икән? Ун яшеннән шулай йөрде, юл йөри торгач, русчага да байтак шомарды, моның исә — алдарак күрербез — Хәмитнең биографиясендә роле гадәттән тыш зур булды.

Берсендә, Тифлис — Мәскәү поезды белән кайтканда, әтисенең пиджак кесәсеннән акчасын урладылар. Дөньяда ике кулсыз сугыш инвалидын талаучылар да була! Исерек бер адәм, төнлә кереп, бер-ике станция арасы гына утырып барган иде. Иртән ул купеда юк инде инде — акча янчыгы да табылмады. Чәй өчен түләрлек тә акча юк иде. Ә көньяк юлындагы проводницалар шулай: биш тиенлек чәй өчен егерме тиен бирәсең икән — алай ярый, әмма дә ләкин синең инде бер тиенең житмәсә... Алла сакласын. Ул очракта инде «Безнең бригада фәлән-фәләнчә хезмәт күрсәтә, фәлән исемне йөртә» дип язганнарының хәрефе дә калмый.

Шулай да, кесә төпләреннән егерме тиенләп акча кырыштырып алдылар — анысы метрога кирәк булды. Малае Хәмит шунда әчтән бик нык елады; бер тиен акчасыз, билетсыз Мәскәү хәтле Мәскәүдә калып кара әле син... Әтисе нишләр икән? Бер әмәл бар-барын. Ул елларда инвалидлар вагон, вокзал тирәләрендә алларына кепка яки калай кружка куеп утыргалыйлар иде. Исламгали агай да, аягын бөкләп вокзал идәненә утырса, кайтырлык акчаны ике-өч сәгать эчендә туплый алыр иде. Халык сугыш инвалидларына карата ихтирамлы. Кемдер — әлеге шәхеснең гарипләгән күреп, кызганып, кемдер сугыштан кайтмый калган туганы, әтисе-бабасы өчен сәдака бирә; күзен түбән каратып, шул хәлгә риза булып утыра алган инвалидлар байтак кына акча жыя. Малай әтисен шул хәлдә күз алдына китерде. Менә, актык тиеннәрен түләп, метродан Казан вокзалына килделәр. Нишләргә? Дошман гаскәрләренә каршы танк белән барган, Кызыл Йолдыз орденын, Дан орденының өченче дәрәжәсен алган батыр сугышчы хәзер нишләр? Малай ялварулы-кызганыч караш белән әтисенең күзләренә текәлде. Нишләргә?

Әтисе исә һич тә асфальтка утырырга жыенмады.

— Улым, кара әле кесә төбеңне,— диде.— Анда күпме бакыр калган?

Габделхәмит моны күңелдән белә иде. Тирләп беткән ике тиенлек ике акча аның уч төбендә иде. Исламгали әйтте:

— Әйдә әле, улым, берәр жирдән телефон табыйк, шалтырату жаен карыйк,— диде.

...Сугыш ветераннары Советының жаваплы секретаре Алексей Маресьев кечкенә малай житәкләгән инвалидны ишек ачып каршы алды, шундук ике стакан чәй китертте, Исламгали агайның, кайсы тирәдә сугышканын сораштты, үзе гел нәрсәдер язды да язды. Нәзек үкчәле туфли кигән нәзек билле секретарь кыз керде дә чыкты, керде дә чыкты. Шулай ярты сәгатьләр чамасы вакыт узды. Габделхәмит телсез калды: Борис Полевой язган очучы Мересьев бит инде бу! Авылга кайткачмы? Малайларны күргәчме?..

Маресьев исә алай шаккатмады, өстәл тартмасыннан бер китап алды да, аның тышлыгын ачып, беренче битенә нидер яза башлады.

— Исемең ничек? — дип сорады ул телсез калып утырган малайдан. Һәм бераздан аның вак, әлегә көчсез, шертләмә бармаклы кулын кысты:

— Бу китап минем турыда,— диде.— Әлбәттә, инде, Борис Полевой бераз арттырган. Мин андый ук герой түгел. Ләкин бер нәрсә факт — ике аягым да юк. Менә мин моны сиңа адреслап язып бирдем. Миннән теләк шул: солдат хезмәтен уз. Билләһи! Шуны уз! Шуны узмаган егетләр белән узган егетләр арасындагы аерманы белеп бетерсәләр икән...

Казан вокзалына аларны Маресьевның машинасында әлеге секре-

тарь кыз озатты. Купе вагонына алынган билетлар инде кесәдә иде; шуның өстенә, вагонга кергәч, теге кызый бер тартма куйды:

— Мәнә монысы — сезнең хатыныгызга, Алексей Петровичтан күчтәнәч,— диде.— Ә менә монысы,— кызый янә бер конверт чыгарды,— Комитеттан. Сезгә тәүләккә якын кайтасы бар бит әле.

Конвертта акча иде.

Әнә шулай итеп Исламгали асфальтка утырмыйча калды.

Поезд кузгалгач, улына әйтте:

— Менә, улым, кешеләр шундый булырга тиеш. Ә теге, кичә төнлә безнең купеда барган адәм ул — кеше түгел. Ул үзенең тормышын барыбер чәнечкеле чыбык эчендә чикләячәк. Аның әнә ике кулы, ике аягы бар иде. Ә безнең — Алексей Петрович белән икебезнең дә — ике аяк, ике кул житешми. Недостача! Менә бит ничек ул...

Халыкка исә Исламгали, сугыш турында бер генә дә чын нәрсә сөйләмәгән кебек, бу очракны да сөйләми калды. Ничә тапкыр аңа төрле газеталардан хәбәрчеләр йөрде, һәр орденының тарихы белән кызыксындылар — юньле бер материал да ала алмадылар. Сөйләмәде. Сөйләгәне исә — гел мәзәк булды. Кичен капка төбендә бераү сугыш турында хикмәтле хәлләр сөйләп утырса — Исламгали агай; үзенең имандәй таза, яшь вакытында ике кулсыз калу фажигасен искә төшермәс өчен һәрвакыт көлкеле бер вакыйга тудыра, эзләп таба, кыскасы, гел ялган сөйли.

— Танкка кадәр разведротада булдым. Фашистлардан белмәгән кеше юк иде мине. Гитлер әллә ничә тапкыр әйткән ди: Мәскәүдән — Левитанны, Беренче Украина фронтыннан Яһудинны тотып китерегез, һәр икесенең башына йөзәр мең марка түлим дип әйткән, ди. Шуларны пирвый усакка асам дип әйткән, ди.

Хатын-кыз кызыксына:

— Ул йөз мең маркага нәрсә алып була?

— Аңамы? — ди Исламгали, бераз уйга калып.— Аңамы? Ике центнер арыш (икмәксез ел), аннан килеп — бер кибән печән (мал азыгы әзерләү крестьянның үзәгенә үткән!). Аннан килеп — ике пар күнитек. И һәм дә бер тальян гармун. Өстәмәсенә.

Халык аһ итә. Әңгәмә аның саен кыза гына.

— Бервакыт Днепрны кичкәндә «разведка боем» ясадык. Камышлык тегендә. Чаш үләне. Жилдә чашылдап хәтәр шаулый. Сизәм: шул камышлыкта фашистлар утыра. Миңа нәрсә: мин инде орденлы сугышчы, фашист белән йөзгә-йөз очрашкаладым. Автоматымны кысып тоттым, такылдатып корып куйдым, иптәшләремне ул-бу булмаска кисәтеп, камышлыкка ташландым. «Һенди һоһ, минәйтәм, такой-такой майтьлар», дим! Ие. Сугышта сүгенергә өйрәндем мин. Менә әле дә бизеп булмый. «Һенди һоһ, фәлән майтьлар, ганслар, фрицлар, куртлар һәм башка сволочьлар», дим. Шуннан ни булды дип уйлыйсыз? Камышлыктан чаштырдап сигез фриц килеп чыкмасынмы? «Яһудин, атма, биреләбез!» — дип ялвара ыстаршийлары.— Атма, Яһудин!» ди... Ыстаршийны алар үзләре «обер» дип йөртәләр.

Шулвакыт күрше хатын Хәерниса, жай белән генә, Исламгалине бүлдерә:

— Карале, Исламгали, алар да татарча белә диген, ә? Үзе немеч бит инде, немечнең дә бигрәк чие — «убыр» дигәне безнеңчә белә диген, ә?

Мәсьәләнең мондый юнәлештә куелуы Исламгалигә ошап бетми, ул өстән генә, мыскыл итеп, Хәернисага карап ала. Ләкин ул кызган инде, кызган...

— Ә бервакыт, урман аланында чолганышта калгач, сигез йөз фашистны әсирлеккә алдым.

Ирләр елмаешты, хатын-кыз таң калды.

— Кит инде!.. Ул тиклем халыкны нишләттең? — сугыш темасын

аеруча яратучы Хәерниса чын-чынлап тел шартлатты.

— Нишләтим? Эш таптым. Бер колхозга алып бардым да, атна буена чөгендер чүбе утаттым. Аннары ике көн буена бәрәңге басуында колоратурный жук чүплаттек. Эшләсеннәр. Талый белделәр ич.

— И, ходаем, теге корткыч коңгыз шул вакытта ук булган икән...

— Булмыйни! Шул фашист-собакаларга ияреп килде дә инде ул безнең илгә.

Габделхәмит үсеп килгән саен, Исламгали агай мондый «капка төбе лекцияләрен» сирәгәйтте. Лекциянең соңгысы менә монысы булды, ахры. Авылда сугыш ордены икәү булган кеше бер Исламгали генә иде, көннәрдән бер көнне «Кызыл йолдыз» орденын кайда, ничек алуын сораша башладылар.

Монысында ул бөтенләй башкача сөйләде:

— Маршал Жуков үзе бирде, күкрәккә адъютанты такты,— диде.— Украинаны азат иткәндә. Тел алып кайттык — шәп күркә әләкте, офицер. Тилмерепме тилмергән идек инде телгә. Һөҗүм алды бит — Мәскәү үзе фронт командующиен кыса, тегесе — дивизия штабын. Давай, тел, диләр. Шуннан башка һөҗүмгә тотынырга ярамый. Тел кирәк, тел, диләр. Ә аларның кысуы, түбәнгә төшә-төшә, миңа килеп терәлде. Миңа һәм дә бер урыс егетенә. Костромадан — Федор Шарапов. Таза инде менә — бер ашаганда дүрт табак боткасын, бер кирпеч ипине ишеп кенә куя. «Полтора Иван» дип йөртәләр иде үзен. Шуның белән чыктык теге якка. Шәп «кош» алдык. Кайтканда Федор яраланды, аны кыр госпиталенә озаттык. Сөйләделәр: маршал Жуков үзе кереп, тегеңә орденны палатасында ук биреп чыккан. Менә нинди кеше! Ә миңа бөтен рота алдында бирде. Маршал киләсен бер сәгать алдан белдекме, юкмы — аның килүен алдан әйтергә дә ярамый бит әле. Шулай да юындык, кырындык, төймәләрне, итекләрне чистарттык. Бер урман аланы сыман җирдә без. Менә бервакыт капитан — рота командиры — бөтен бугазына кычкыра:

— Рота-а-а! — Ул гел шулай сузып әйтә иде.— Рота-а-а! Станови-и-и-сь! — Шулай сузып әйтә:— Ста-а-но-о-вись!

Ул арада урман юлында яшел-чуар газик күренде. Комбат каушый калды, сузып торырга вакыт юк, чак-чак әйтеп өлгерде:

— Рота, равняйсь, равнение — на середину,— диде дә, машинага каршы йөгерде. Машина кырт кына туктады, ишеге ачылды да маршал үзе килеп чыкты. Буйга бик биек түгел, әмма дә ләкин калын гәүдәле. Кызу-кызу атлап капитан янына килеп тә җитте, рапорт-мазар тыңлап тормады, кул биреп күреште дә безнең каршыга килеп басты. Тагын бер машина төялеп килгән зур офицерлар читкәрәк коелдылар. Күз кырые белән генә карыйм: солдатларның күзләрендә яшь. Менә бит солдат нинди нечкә күңелле була ул. Ул арада маршал көр тавыш белән кычкырды:

— Сержант Яһудин, выйти из строя!

Менә шунда, билләһи, каушадым. Тез буыннарымның хәле китте. Чыга алмыйм — бетте-китте вәссәлам! Комбат та куркып калды, тик-томалдан гына йөткеренә башлады. Ул арада маршал күзләре белән бөтен стройны ялап алды — ә мин торам.

— Сержант Яһудин!

Монысы үзебезнең комбат икән, бу тавыш минем аякларны ычкындырды. Чыктым, бастым. Ул арада — командующийның адъютантыдыр инде — яшь кенә майор йөгереп килеп җитте. Калганын мин хәтерләмим. Шунысын гына тойдым: иллә дә мәгәр маршалның кулындагы куәт! Ул учларының зурлыгы, ул минем кулны кыскандагы көч! Мин дә бит инде таза (ул үзенең кулын күтәреп куя, әмма кул урынында кызганыч җәплекә генә...), шулай да ул миннән куәтлерәк иде. Кеше йөрәгенең зурлыгы йомарлаган йодрыгы кадәр була, диләр. Монын да

шулайдыр, йөрәгендә бер хикмәт булгандыр. Ул бит теге сугышта ук инде Георгий тәресенең тулы кавалеры... Ә андый кеше Россиядә бармак белән генә санарлык. Менә шулай орденны маршал үзе бирде миңа. Бер генә җөмләсе хәтердә калган:

— Молодец, Яһудин, татар солдатларын мин беләм, алар белән сугышка керергә була,— диде. Тагын бер сүзе истә. — Син,— диде,— Шараповның хәлен бел, аны бүген тыл госпиталенә озаталар,— диде.

Исламгали агайның бу хикәясен халык рәхәтләнеп тыңлады — ирләр монысының чын икәнен аңлыйлар иде. Сугышка кагылышлы мәсьәләдә һич кенә дә сүзсез калмый торган Хәернисаның соравыннан соң, Исламгали элеккеге «дулкынына» кире кайтты. Хәерниса ип белән генә сорады:

— Карале, Исламгали, ул маршал дигәнегез ничек киенгән инде? Өстенә-башына, дим.

Ирләр көлеште. Шунда Исламгали элеккечә сөйләп китте:

— Ничек дип... Аларның билгеле инде. Сугышта иң зур кеше бит — ул инде яхшы киенергә тиеш. Шунсыз нинди ул сиңа автарит? Ничек киенсен? Өстендә — чем-кара кәчтүм-чалбар, аягында — кап-кара лаклы ботинкалар. Башында — яхшы эшләпә...

Ирләр читкә борыла, Хәерниса да, ышанган сыман, риза була. Әмма Исламгалинең хатыны Рәшидәдән башка берәү дә белми: шулай кеше барында уен-көлке сөйләшеп утыра да, аннан юрган астыннан ике җәплекәсен чыгарып төне буе ыңгыраша, сызлана Исламгали. Бигрәк тә көп болытласа. Анысын кеше белми. Үзенең дә белдертәсе килми.

...Исламгалинең, Япония белән сугышта катнашмаган көе, олыгайгач, Ватан сугышында җиңүнең кырык еллыгында, ул өр-яңа «Отечественная война» ордены белән бүләкләнгән җәйдә «Япун Яһудин» кушаматы алуының тарихы бик гыйбрәтле булды.

...Кайчандыр аны житәкләп Сочига йөргән Габделхәмит укып, югары белем алгач, профсоюз эшенә сайланды. Өйләнеп, матур гына гаилә корып җибәрде. Шәһәр кызы авыл малаен гел шәһәрчә яшәргә өйрәтте. Профсоюз малай инде көньякка үз хатыны белән йөрде — әтисе Исламгалигә хәзер кардиологлар рөхсәт итми иде. Профсоюз малай бераздан гади ял итүчедән чит илләргә йөрүче туристка әйләнде. Ул сиңа кирәкме Урта Диңгез буенча круиз, ул сиңа кирәкме Төньяк круизы. Йөреп кайткан саен, күргәннәрен әти-әнисенә сөйләп таң калдыра малай. Профсоюз эше кызык бит ул — анда гел алга барсаң гына яшәп була. Профсоюз малай бераздан чит илләргә баручы туристлар төркеменә житәкче буларак йөри башлады. Шундый сәяхәтләрнең берсендә, Исламгали агайның күрәчәгенә каршы, Япониягә барып чыккан. Туристлар төркеменә житәкче булып. Менә шуннан малай гел икенче кеше булып кайтты да инде. Ул анда барганчы ук, Япония турында күп әдәбият укыган (малай пединститут тәмамлаган иде), тегендә баргач та гел мәктәп, балалар тәрбиясе мәсьәләләре белән кызыксынган. Кая гына барса да, нинди генә сорау бирсә дә, мәсьәлә гел бер тирәдә әйләнгән: Японияда балаларны аерым бер методика белән тәрбиялиләр, кечкенә вакытта бала тулысынча ирекле — нәрсә теләсә, шуны эшли. Нинди генә зарар салса да, кыйнайсы, җәза бирәсе түгел. Бары тик акрын-акрын гына теге яки бу эшнең яманмы, яхшымы икәнен аңлата килергә. Бала тулысынча ирекле булып үссен.

Профсоюз малай дүрт яшьлек улы Рабисны (малайның исем тарихын Габделхәмит болай аңлатты: «Рабоче-крестьянское искусство» сүзеннән кыскартып ясалган,— диде.— Сез,— диде,— миңа иске исем кушып, биографиямне кыенлаштыргансыз,— һәм визит карточкасын күрсәтте. Анда фәлән-фәлән хезмәт кешесе «Ягудин Хәмид Галеевич» диелгән иде) ата-ана йортына җәй уздырырга кайтарып куйгач, шуларны сөйләде:

— Без инде япон методикасына күчтек, сез дә шуны дәвам итегез, без энисе белән ике атнага бер кайткалап торырбыз, кирәк-яракны үзебез кайгыртырбыз,— диде.

Исламгали, тирән сулап, үзенең сугыш алды һәм сугыштан соңгы еллардагы тормышын баш мие аркылы уздырды. Балаларга каты куллы булды ул. Шаярышып узынсалар, чыгырдан чыксалар, Исламгали агай биргәләп алырга да күп сорамый иде. Профсоюз малай сугышка кадәр үк туган иде — этисе, әле сугыш чыгасы ел язында гына тупыл башындагы сыерчык оясына кулын тыгып актарынган өчен малайны пешерде. Малай, ике-өч сәгать буе елап, шыңшып, этисенә рәнҗеп, абзар артында утырды.

...Госпитальдә аңына килгәндә ике кулы да беләзектән киселгәнен күргәч, Исламгали ыңгырашып куйды:

— Һай-й,— диде ул, күз яшьләренә тыгылып.— Һай-й-й... Сабыем Габделхәмит рәнҗегәндер. Юкка гына кызып китеп яңакладым бит үзен шул чакта. Ул бит сыерчык оясына зарар салам дип менмәгән. Аның бит, оядан яшькелт-зәңгәр кабыклы бер генә йомырка алып, өйдәге гөл төбенә куясы килгән. Аңа бит элеккеге язда үзем шулай күрсәткән идем: тупыл төбеннән табып алынган ул йомыркага малай никадәр шатланган иде. Сабый. Шул рәнҗегәндер.

Оныгы Рабисны алып калган көнне аның йөрәге энә шул истәлекләр белән телгәләнде. Профсоюз малай шәһәренә китеп барды: дәү эти белән дәү әни исә, оныкны японча тәрбияләргә вәгъдә биреп, капка яныннан хәтәр борылып шәһәргә таба чапкан «Волга»га карап калдылар.

— Габделхәмит акыллы шул,— диде Исламгали карчыгына. Бер җәплекәсен оныгының җылы, йомшак муенына куйган иде — шул көе басып тордылар.— Акыллы. Энә мин ни үкендем каты куллы булганым өчен. Дөрес, минем бала әйбәт булып чыкты. Әмма дә ләкин минем тәрбия дөрес корылмаган булган. Әйдә, улым, мультфильм башланган-дыр. «Заяц, погоди»ны яратасыңмы? Мин үзем бер дә калдырмыйм аны.

Ләкин «погоди»ны карарга туры килмәде аларга ул көнне. Өйгә кереп, диванга урнашып, рәхәткә чумабыз дип кенә торганда, малай үҗәтләнеп стенадагы герле сәгатьне сорый башлады (ул аңа бая этисе белән ашап-эчеп утырганда ук күз төшереп, сәгатьнең эченнән баш тыгып күкелдәгән кош малайны шаккатырган иде). Сәгатьне стенадан алып бирергә туры килде; моннан ун еллар элек, Җиңү бәйрәме көнендә, колхоз парткомыннан бүләк иткәннәр иде бу сәгатьне. «Погоди» башланырга ун-унбиш минутлар бар иде әле, малай сәгатьнең калай ишеген зур дәрт белән каерып ачты, бәләкәй куллары белән теге хикмәтле кошны элэктереп, җан-фәрманга бугазлый, тарта башлады. Исламгали бу бәләкәй залимгә бераз гына рәнҗеп, ләкин япон методикасына зур ихтирам саклаган хәлдә, урыныннан торып, ишегалдына чыгып китте.

— Ярар инде, күкесез булса да йөреп торыр әле, берни эшләр хәл юк,— дип чоланга сөялде: сәгатен кызгана иде, ул аңа һич тә сәгать булып түгел, ә гаиләдәге бер җан иясе, дус, ышанычлы иптәш, бергәләп картаючы фронтовик булып тоела, шулай уйлап күнегелгән иде.

Карчыгы әле өйдәге хәлләрне белми. Ул, гадәттәгечә, «һай, җүнсезләр, көш, дим, көш, азынып калыгыз, киләсе елга берегезне дә калдырмыйм, чисти үзәкләремә үттегез, гомерләрем әрәм узды»...— дип, тавык-каз белән абзар-кура тирәсендә мәж килә иде. Исламгали агай сугыштан кайтканнан бирле ишетеп яши инде мондый «чыгыш»ларны; ләкин ул белә, карчыгының сукрануы болай гына: хуҗа хатын барыбер ике ана каз, бер ата каз, егермеләп тавык белән тубал кадәр зур әтәч, ике баш үрдәк калдыра кышка. Болай гына сукрана инде ул, болай

гына. «Тукта, ярар, «Погоди» вакыты житкәндер...»— дип өйгә керсә, теге бәләкәй залим, сәгать чылбырының очын учына чорнап, гер сел-тәп, идән уртасында әйләнеп уйный иде. Исламгали агайның шунда кул бармаклары чымырдап сызлап алды. Гернең бер әйләнүендә тәрәзә төбендәге яран гөл идәнгә төшеп чүлмәге-ние белән көл булды, икенче селтәнгәндә гер өстәлдәге электр чәйнегенә килеп бәрелде; чәйник, бичара, күз алдында яньчелде, әле аннан соң да чыкыр-чыкыр итеп эчтән ватылып утырды.

— Чү, улым, чү, алай ук ярамас!..— дип чак әйтә алды Исламгали агай, үзенең һаман кул бармаклары сызлый, үзе һаман эшнең төбен аңлап бетерми иде әле. Андый вакытта ир кеше һәрчак хатынына сыена, шуңа күрә ул ишекне этеп кенә ачып чыкты да, абзар якка карап кычкырды:

— Син, дим, син!.. Кер әле тиз үк! Кер әле, дим...

Өйдә нәрсәдер шартлап ук ватылды, чәлпәрәмә килде. Монысы инде чамадан тыш иде һәм Исламгали агай өйгә таба атылды. Ишекне жәһәт кенә ачып өйгә керим дисә — бәрәч! — ишек тоткасын тотарга куллары юк бит аның! Кырык елдан артык инде аның кулсыз калганына. Ник шулай кычыта соң бу кул, ник шулай кычыта? Ул, ишек киндеренә үзе өчен кагылган каеш элмәкне хәтерләп, жәплекәсенә кидерде дә аты-лып өенә керде. Керсә... телевизорның экраны юк, идән тулы аксыл-зәңгәр пыяла, ә малай ике кулы, башы белән телевизор эченә кереп киткән иде. Исламгали агай, ыңгырашып, ишек бусагасына утырды.

...Кичен капка төбенә жыелган ирләр арасында өр-яңа тема күтәреп, болай сөйләде:

— Безнең тәрбия дөрес түгел ул. Без балага кычкырабыз, жикеренәбез. Сугабыз да. Әнә японнар. Алар балага берни әйтмиләр. Бала өйдә теләсә нәрсә эшли: гөлләреңне йолка, чынаяк вата — аларда әйбер әйтелми. Бала үсә төшкәч үзе аңлый. Әнә минем Габделхәмитнең малае. Яңача тәрбиялиләр. Шулкадәр тере бала. Һич кенә дә тик тор-мый. Шулай кирәк, японнар — акыллы халык алар. Аларның эшләгән әйберләрен генә кара син: бишенче каттан асфальтка ыргыталар икән — шайтаным да булмый. Ә телевизорларын...

Шулвакыт ул эчтән ыңгырашып куя, ләкин кешеләргә белдерми.

Берәр атнадан исә күрше хатыннары сизә: Исламгалиләрнең түр тәрәзәсендәге яран гөлләр гел кими, гел сирәгәя. Исламгали агай исә һәр кичне японча тәрбия турында «лекция» сөйли. Яңа тема бит, агай-эне рәхәтләнеп тыңлый.

Инде ике атна тула дигәндә, малайның әти-әнисен бик тә, бик тә көткәндә, Исламгали агайның өендә инде телевизор, күкеле сәгать, кырыну машинкасы, электр чәйнеге һәм зур көзгә ватылган, исән калган ике чүлмәк гөл мич башына мендерелгән, кухня якка чыга торган аралыкка яшелчә бакчасының рәшәткәле капкасы кертеп сөялгән һәм хужа хатын, кергән-чыккан саен, японнарны каргый-каргый, шул кап-каны күчереп куеп иза чиккән көннәр иде...

Шулай да, бер көнне малай кухняга уза алды. Һәм, дәү әнисе күрмәгәндә генә, кулына шырпы кабы электерде. Исламгали агайның нервылары актык чигенә кадәр тартылган, күрше-тирә дә инде бу бәләкәй афәтнең болар хужалыгына күпме зыян салганын чамалый иде. Житмәсә, күрше Хәерниса, иртә белән радиода көлкеле бер тапшыру тыңлаган да, кичке капка төбе «жыелыш»ында шуны сөйләде.

— Әй, дим, ну шушы Казанның тапшырулары. Кем булды икән ул, танымадым, әллә Равил Шәрәфиев инде, әллә Ренат Тажетдинов. Әллә Ирек Баһмановмы? Мин, үзләрен күрмәгәч, тавышларыннан аера алмыйм. И дә кызык итеп сөйли инде. Бер малайны, ди, Таҗикстаннан монда, Казанга алып кайтып, әби-бабасына калдырганнар. Жәйне, дигәннәр, сездә торып торсын, безнең монда, дигәннәр, жир тетри, бала куркып бетте. Шуннан соң, берәр ай узгач, әби белән бабай Таҗикстанга

хат язганнар, ди: «Малаегызны кайтып алыгыз, безгә сез лутчы җир тетрәүнең үзен җибәрегез».— дип әйтеп әйткәннәр, ди...

Исламгали агайдан башка барысы да хахылдап көлә.

...Нәкъ унбиш көн үткәч, японча тәрбиянең нәтиҗәсен карарга авылга ак «Волга» кайтып төште. Әмма... урамнан тыкрыкка таба борыла алмады. Техника — бензовоз, сөт машинасы, аммиак сыекчасы ташый торган машиналар тыкрыкка бөялгән. Һавада — кисәү, көйгән салам, тагын әллә ниләр исе. Урамда тынлык. Кешеләр төркем-төркем җыелганнар. Сөйләшмиләр.

Профсоюз Габделхәмит машинасыннан чыкты, арткы ишекне ачып, кулыннан сак кына тотып, чибәр бер ханымны чыгарды — бу инде, бер дә шиксез, теге бәләкәй ташбашның әнисе иде. Сак кына атлап, техниканы әйләнеп, үз капкаларына таба юнәлделәр. Капка төбендә милиция формасы, хәрби форма кигән ике-өч кеше нәрсәдер язалар, сорашалар, киңәшәләр иде.

Шыр ачык урыс капка аша ишегалдына карагач, профсоюз Габделхәмит имәнеп китте: бәрәңге бакчасының түренә тезеп, бурап салынган келәт, корт өе һәм ак мунча урынында кисәү өеме пыскып утыра, ишегалды ермачланган, урыс капканың бер баганасы төптән кырт өзелгән, бер торык койма ауган, бөтен әйләнә-тирә су, кисәү, изелгән балчыктан тора иде. Халык — ни гаҗәп — янгын турында түгел, Исламгали агай турында сөйли иде. Келәт артында чытырдап ялкын күтәрелүгә, урамда «Пужар, пужар!» дип кычкыра башлаганнар. Шунда Исламгали агай ишегалдында кыләп сарып гел йөгереп йөргән. Нәрсә эшләргә белмәгән. Хатыны Рәшидә шундук оныгын күтәреп алган, икенче кулына иренең орден-медальләре тагылган пинжәген эләктергән дә, аһ-ваһ килеп, күршеләргә кергән. Исламгали агай исә, янып яткан келәткә кереп нәрсә алырга белми аптырап торгач, майланып, балавызланып беткән бер иске бишмәтне култыгына кыстырып, авыл башына чыгып йөгергән. Каралты-кура янып беткәч, аны җитәкләп алып кайтканнар. Бишмәт дигәннәрен таныганнар: кырык бишенче елны киеп кайткан солдат бушлаты, ди. Элек яшел төстә булган, ди. «Мин моны белеп эшләмәдем», дип әйткән, ди.

...Шул көнне авылда «Япун Яһудин» дигән яңа кушамат туды.

Йомшак, җылы муенлы, аяклары-куллары чебиләгән бәләкәй ташбашны ул көнне кич кире үз оясына — Казанына алып киттеләр.

Теге каралтыларның страховкасы бар иде, аннан байтак чыкты, тагын профсоюз малай белән профилакторийда баш врач булып эшләүче килен байтак ярдәм иттеләр. Хәер, теге каралтылар тузган, аларны барыбер яңартасы бар иде инде.

Шулай да, Исламгали агай бу вакыйгадан соң житдиләнеп калды. Аның күңелендә — күпмегәдер — юмор үлде. Шулай, шулай, дип уйланды агай. Шулай... Габделхәмит, менә ничә ел инде, ашау-эчү әйберсен ничек юнәтергә, транспорт каян табарга, фатирны ничек ремонтларга, врачка ничек эләгергә дигән тормыш мәшәкатьләреннән азат. Аның бөтенесе әзер, транспорты баскыч төбенә килә, врачка чакырып алалар, ашау-эчү әйберсен кухнясына китереп китәләр. Ул моны үзе белми дә. Шулай, андый тормыштагы кешенең чынбарлыктан аерылмый хәле юк. Ул бит инде синеңчә уйлый алмый. Аның инде баш миендәге андый күзәнәкләре үлгән була...

Шулай, бу вакыйгадан соң Исламгали агай эченә батты, уйчанланып калды.

Габделхәмит исә ярты ел буена авылга кайтмады. Дөрес, ара-тирә хатлары килә иде. Мәшәкате булган икән, соңгы хатыннан шул аңлашылды: «Көннәр эчендә чираттагы ялымны алырга уйлыйм... Моннан өч атна арттан яңа квартирага күчтек, дүрт бүлмәлегә... Әле ун көн генә арттан туйда булдык: минем шефның малае гаилә теркәде...»

Исламгали агай хатны кат-кат укыды, укыган саен, үзенең надан-

лыгын ныграк сизә барды. Утызынчы елларда ул башлангыч мәктәптә, аннан ТБУМда укып йөргән иде: иллә дә туган телгә өйрәтмәгәннәр икән аны укытучылар ул елларда!

Менә бит ничек сөйләшәсе икән. Менә бит культуралы кеше ничек шәп сөйләшә ул. Һай, һай, һай, һай... Идрит-кудрит...

## II

*Ләкин, әгәр бүгенге заманны күрсәтәсең икән — син инде алдашма. Һәм кешене, ничек бар, шулай сурәтлә.*

М. Горький, «Фома Гордеев»

...Утыз алтынчы еллар тирәсендә Хәерниса, кинәт кенә җиткән кызга әйләнде дә, берьюлы күп егетләрнең күзенә чалына башлады. Мул гына күкрәкле, янбашлары түгәрәк, дымсу иренле бу кыз көннәрдән бер көнне, кемнән күреп-өйрәнептер, кашларын кырып җибәрде дә ай урагы кебек кенә сызыклар сыздыртты. Тормышлары бик үк мулдан булмаса да, кызый матур булып тулды, башка кызлар куеп йөри торган ясалма мамык күпертмәләр бер җиренә дә кирәк булмады. Аның белән кичке якта уенга барганда-кайтканда егетләр бөтенләй телдән кала иде. Ни хикмәт, авылдагы йөзләгән кыз белән ике дә уйламыйча сүз сөйләшә алган егетләр — Хәерниса белән очраштылармы — каушыйлар, тыннары буыла. Бигрәк тә Хәернисаның битеннән кершән-вазелин исе бәрелеп калса — егетләр бетә, сукырая, сөртенә. Ул вакытта тракторда эшләүчеләрнең дәрәҗәсе зур иде, хатын-кызларны да трактор курсларына ала башладылар. Авылдан тракторга киткән өч кызның берсе Хәерниса иде, болардан кышкы курсларда вакытта ук хәбәр килде: эти-әниләре аларга язгы сабанга чыккан көнгә кызыл косынка (кыек яулык) юнәтергә тиеш икән, шунсыз тракторга утырып колхоз басуына чыгу яз көне бер дә килешмәячәк икән. Хәернисага анысын да юнәттеләр. Апрельнең мул сулы, ташу ташыган, боз өстендә ут җибәргән, кичтән әтәчләр кычкырган җир исле җылы төннәренең берсендә ялга кайткан Хәернисаны тыкрыкта тракторист Исламгали туктатты. Сөйләшә алмады, кызның дәрт тулы гәүдәсен якын килмәгән көе тойды: теге исерткеч кершән исе килеп бәрелеп, тынны буды. Шулай да, Исламгали кыш буе әзерләнгән батырлыгын беренче мәртәбә эшкә җикте: кулындагы кечкенә төргәкне кызыйның кайнар уч төбенә салып, учын йомарлатты да, үзе куркуыннан кире якка таба торып йөгерде. Кызлар янында гомергә куркак булды Исламгали. Югыйсә, су буеннан менгәч, гадәттәгечә, капка төбенә өелгән бүрәнәләр өстендә гармун белән утырасы бар иде әле. Хәерниса әлеге кечкенә төргәкне өенә алып кайтты, мунчага кереп, андагы җиделе лампаны яндырып карады: төргәктә кысып чыгара торган хуш исле вазелин һәм язу кисәге иде. Анда яңалиф хәрефләре белән, бер дә хатасыз һәм матур итеп, болай дип язылган иде: «Хәерниса, минем сиңа сөйлисе сүзләрем бик күп, минем акчам да бар, йорт-җиребез дә таза, мене сиңа миннән бүләк: алтмыш биш тиенлек вазелин. Алла боерса, әле тагын булыр. Исламгали. Укы да, җыртып ташла».

...Шул язны, кыз авылга эшкә кайткач, беренче атнада ук авылда кинәт бер хәбәр таралды: төнге сменада ялгыз калып эшләгәндә Хәернисаны харап иткәннәр. Бу хәбәр яшь егет Исламгалинең саф йөрәгенә кара кан булып укмашты. Хәернисаны харап иткәннәр... Хәернисаны харап иткәннәр... Иткәннәр...

Хәернисаны харап иткән егет күршедән генә иде: мир көтүе көткән Сәмигулла. Куе кашлы, түбәнгә юнәлгән карашлы, зур ашаулы. Укыйяза белми, мәктәпне яратмады, ат җигеп эшләде, ирсез йортларның атлы

эшләрен карусыз башкарып килде; эш беткәч аш-суга чакырып утыртканда ике-өч тәлинкә токмачлы аш, бер-ике тәлинкә майлы коймак, яшел суган турап коштабак төбенә әзерләнгән бәрәңге боламыгын «ә» дигәнче карусыз гына җимереп бирә; эшләгәне өчен акча өмет итми, ашаганы өчен рәхмәт әйтми торган бер адәм иде.

Сәмигулланың үзе белән сөйләшүче булмады — Хәерниса фаҗигасен авыл халкы гафу итә алмады. Көннәрдән бер көнне авылга хикмәтле исемле бер кеше килеп төште; җилкәсеннән биленә кыеклап аскан, чын күннән эшләнгән кызгылт-чия сумкасы бар иде, моны авыл-колхоз житәкчеләре «Оргнабор» дип аңлаттылар. Мәгънәсен беркем дә аңламады, әмма иртәгесен бу кеше янына Сәмигулла килеп житте. Сумкалы кеше «Казмашстрой» дигән зур төзелешкә эшчеләр туплый икән, хезмәт хакы әйбәт, эшчеләр өчен ашханә бар (Сәмигулла «щи», «борщ»ны күз алдына китереп, мул гына итеп төкерек йотып куйды), «семьюм» килгәннәргә баракта аерым бүлмә бар икән. Сумкалы кеше әйтте: «Бу,— диде,— зур төзелеш, илебез оборонасын ныгыту өчен»,— диде.

...Икенче көнне Сәмигулла Хәернисалар өенә барды, бер сүз дәшмәде, кызның әтисенә сумкалы иптәш биргән кәгазьне күрсәтте.

...Алар төянеп чыгып киткәндә ярты авыл елады. Бичара бөтен авыл егетләренең күз явын алган Хәернисаның битенә тут төшә башлаган иде.

Йә инде, колхоз идарәсен әйтериең: теге төнне тракторга су, май илтергә нигә инде Сәмигулланы чыгарырга? МТС бригадирына нәрсә әйтәсең? Болытлы кап-кара төндә язгы җир, куктәге язгы болыт кебек тулган уңсигез яшьлек бер кызның ничек үзен генә сменага чыгарырга?

Хәерниса киткәч авыл тынды, алар кайтып йөрмәделәр, кемдер әйтте, аларның, имеш, кызлары туган икән. Чыннан да, баракта яшиләр икән.

Сәмигулла сугышлар һәм тагын әллә ниләр күреп, озак йөреп, 1946 елда гына кайтты. Аңарчы хатыны Хәерниса белән кызы Энже авылда күренеп алдылар (теге елда Хәерниса ишетеп-күреп белә иде: Казаннан килгән коммунист, МТС директоры Әхмәтовның кызы Энже исемле иде. Кыз тугач, Сәмигуллага әйтте: «Шулай куйыйк»,— диде. Сүзсез Сәмигулла шунда телгә килде: «Аның инде рәте-тәртибе бар бит,— диде.— Синен исемен Хәерниса икән, моныкы — йә Хөббелниса, йә Шәмсениса булырга тиеш. Әнә безнең күрше Җиһанша абзыйлар да...» Бу — ихтимал, Сәмигулланың бергә тора башлаганнан бирле хатыны янында иң озын итеп сөйләгән сүзләреннән берсе булгандыр.

Сәмигулла сугыштан кайтканда Энже мәктәптә укып йөри иде инде.

Озак еллар үтте. Күпмедер еллардан соң алар, шулай ук «семьюм», авылга кунакка кайттылар. Сигезенче классны тәмамлаган гүзәл кызлары Энжедән соң тагын ике ташбаш малай үсеп килә икән, алары җай буена рогаткадан чыпчык, кош-корт аттылар. Олысы — Раскул исемлесе — алты яшьтә икән, дәү әтиләренең гаилә әгъзасы ала мәченең быел майда гына туган балаларын оядан алып, сукыр сабыйларны өйалды идәненә йөз иллеле кадак белән кадаклап куйды.

Сәмигулланың әти-әнисе инде беткән, төп йортта икенче кешеләр яши иде. Кичләрен ул Исламгалиләр тирәсенә килеп утыргалады. Халык, бигрәк тә яшьләр, бернинә кич рәттән сугыш хәлләрен сораштылар, кайда әсирлеккә төшүе, кай илләрдә булуы белән кызыксындылар. Һәм шаккаттылар: Сәмигулла берни дә белми иде.

— Ничек инде ул алай? Әнә бит Исламгали абый барысын да белә: ничәнче полкта, нинди җирләрдә сугышкан, немецләрнең нинди армиясенә каршы... Ә син кай төштән башладың?

Сәмигулла авыр сулый, газаплана:

— Ну инде, сугыш чыккач повестка килде. Шуннан товарныйга төяп алып киттеләр. Ярты тәүлек тә бармадык — караңгы нарат урманы.

Бер дә атучы юк. Әй, дим, Казаннан чыгып нибары ике ашау арасы бардык...

— Суслонгермы? Мари урманымы?

— Аны кем белсен инде?..

— Йә, йә, шуннан?..

— Шуннан көзгә кадәр шунда яттык. Землянка казыдык. Атучы юк.

— Шуннан?

— Шуннан, кар төшә башлагач, әпәйт-теки товарныйга төяп озаттылар. Монысында озак бардык.

— Шуннан?

— Шуннан без туктаган урында сугыш иде инде. Мине атлы эшкә — прадухты ташырга куйдылар. Ике көн йөрдем микән — плен.

— Кыйнадылармы?

— Юк, болай сүгенделәр генә. Урысча. Гел «швайнмайть» диделәр.

— Аннары?

— Аннары, ыстыруйга тезеп алып киттеләр дә, товарныйга төяп озаттылар.

— Кая, кайсы шәһәргә?

— Аны кем белсен инде...

— Аннары?

— Аннары инде, ни... Төн уртасында бер прахутның аскы ятажына тутырдылар. Шуннан соң әллә ничә көн буе Изел кичтек [1].

Кешеләр шакката. Авыл тарихында мондый билгесезлекнең булганы юк. Авыл тарихында мондый наданлыкны күргән кеше юк. Олылар хәтерлиләр, сөйлиләр: 1905 елда авылга рус-япон сугышында катнашкан ирләр, бер нәселдән ике туган — Вәли белән Гомәр кайтып төшкән. Һәм көз буе, кыш буе авылда сүз менә болай гына барган:

— Без Чемульпога килеп житкәндә...

— Ә янарал Кондратенко әйтә икән япун янаралына...

— Комендант Стессель хыянәт итмәсә, без арт сабакларын укыта идек инде ул макакаларга. Путартур (Порт-Артур) шуның аркасында гына ычкынды инде...

Менә бит ничек булган. Бераздан халык боларга кушамат та таккан: путартур Гомәр, Чемульпо Вәли. Бу кушаматлар нәселдә әле дә дәвам итә. Шулай да, Сәмигулла...

— Ие, шуннан — ике атналап булдымы икән — Изел кичтек. Аннары безне бушатып эшкә куштылар. Жылы як, күлмәкләр бирделәр, башка — киндер эшләпә.

— Анда нишләдегез соң?

— Нишләдегез дип... Эш беткәнмени дөньяда? Чалгы шикелле озын пычаклар бирделәр дә, камыш чабарга куштылар. Ул камыш — тәмле. Нәкъ тә шикәр тәмс килә инде. Тешне дә бик чистарта. Тамакка да хәл кертә. Сугыш беткәнче шунда булдык.

— Аннары ничек? Сугыш беткәнен каян белдегез?

— Автомат аскан, кыска зимнәчтүркә, кыска ыштан кигән кешеләр килеп әйтте. Барысы да кара күзлекле. Урыс егетеннән мин дә аңладым: Гитлер капут, диде.

— Аннары?

— Аннары яңадан парахутка төяделәр. Ә тегеләр кызык: хәтерегездә микән, утыз бишенче елны мәктәп балаларына шундый чалбар киерткәннәр иде? Кыска шундый... Бу юлы инде карап бардык. Мин белмәгән телдә сөйләшә торган пленныйлар бар иде. Алар учия [2] саен төшеп кала бардылар.

---

[1] Саба ягы сөйләше. «Идел» дигән сүз. Зур су мәгънәсендә.

[2] Учия — Ватан сугышына кадәр татар халкы Казанның иске елга портын шулай атап йөртә иде. Устье — елга тамагы дигән сүздән (Казан елгасының Иделгә кушылган тамагы). Жыр да бар иде: «Килә-китә, гуләйт итә учиядә парахут, мәңге сүнмәс утлар булмас, сүнәр әле бервахыт». Учия — порт һәм елга, фарватер мәгънәсендә.

— Шуннан?

— Бер унбиш-егерме көннән үзебезнең әрмисләрне күрдек. Бөтенесе яшь, матур, бөтенесендә кызыл погон.

— Аннары?

— Аннары шул: сораштырдылар, кәгазь яздылар, кул куйдырдылар. Нәрсә язганнардыр инде. Аннары — үзебезнең ил диделәр — күе чыршылы нарат урманы эчендә бер ел урман кистем. Менә шул... Анда инде гел үзебезнекеләр булды.

Болар гаиләсендә үскән ике малай бик тә юньсез булып чыкты. Ата-ана тәрбиясе барысын да хәл итә, имеш, дип язалар, сөйлиләр әнә. Алай булгач — Энже? Йа, дөньяда акыллы бала булды да инде! Мәктәбендә мактап бетерә алмадылар, активистка булды. Комсомол секретаре булды, алтын медаль алып, ун класс тәмамлады. Шуннан туп-туры медицина институтына керде — анда да шул: студентлар төзелеш отрядының комиссары булды, ул отрядлар эле беренче тапкыр гына төзелеп ята иде. Чат иткән теге елллардагы Хәерниса инде...

Малайлар исә, кече яшьтән үк, Нагорный бистәсенең таллык камышлыкларына карта уйнарга йөрделәр, шунда тәмәкегә, бераздан — аракыга өйрәнделәр. Сигезне бер-бер артлы өчкә-көчкә тәмамлап гидайлыкка чыктылар, мичкә ясау заводында бондарь булып эшләгән Сәмигулла да, төзелештә сумала кайнату машинасында эшләгән Хәерниса да ни дип тә әйтергә белмәделәр. «Кичен — эш, көндез — эш, бер минут юк гынич». Ничектер бала тәрбияләргә аерым вакыт юк иде. Сәмигулла исә һәр шимбә көнне кич мунчага китә һәм, кайтышлый бер шешә алып кайтып, шыпырт кына кәефләнә дә ятып йоклый. Теге эшлексезләр моны сизәләр, яшәгән саен, шул көннең өлешенә тыкшына баралар иде. Үзләре эле бер кибеттә, эле икенче кибеттә йөкче булып эшлиләр, әмма бер-ике атнадан ары түгел: беренчедән, әзлексез эчәләр, икенчедән... Сиксәнешәр килолы дөге капчыкларын күтәрерлек мускуллары юк. Егетлек куәтен тәмәке белән аракы эчтән кимереп бетергән. Шуңа күрә бер кибеттә дә озак эшли алмадылар. Армиягә яшьләре керде, ләкин юньле характеристика бирүче оешма табылмады. Хәерниса, яшь чактагы тәвәккәллеген туплап, военком янына үзе барды. Военком — чибәр йөзле, киң күкрәкле татар егете, полковник — ике малайның да «личное дело»сын китертеп карап чыкты да, авыр сулап, болай диде:

— Апа... Сезнең хәлегезне мин аңлыйм. Ләкин бит Совет Армиясе — төзәтү колониясе түгел. Минем янга мондый йомыш белән килүчеләр байтак хәзер. Ләкин бит Кораллы Көчләргә без егетләрнең каймагын гына алабыз. Менә безнең Төп Законыбыз — Конституциядә дә аерым статья бар. Анда әйтелгән: Ватанны саклау эше — намус һәм вөҗдан эше, диелгән. Инде, сезнең сөйләвегез буенча, үз этиләренә кул суза башлаган ул егет калдыкларын мин нинди төр войскага җибәрим? Чик буе гаскәрләренәме? Хәрби Диңгез флотынамы? Десанткамы? Элемтәгәме? Юк бит, туры килмиләр. Әтисенә кул күтәргән малай Ватанга да кул күтәрә ала бит.

— И-и, әйтмәгез инде, — дип кушылды шунда Хәерниса. — Әйтмәгез инде. Әтиләреннән һәр көн аракыга акча сорыйлар, тавыш-сугыш чыгаралар. Син пленда булгансың, дезертир син, син сугыштан соң сөргендә булгансың, каторжан син, дип бәйләнәләр. Әтиләре кычкырып җылый.

— Әсирлек турында ул сары авызлар нәрсә белә соң, апа? Әнә генерал Карбышев та, шагыйрь Муса Җәлил дә шул фаҗигагә очрадылар. Гаепләп кара син аларны. Әсирлеккә эләгү эле ул — һич тә Ватанны сату дигән сүз түгел. Ул малайларның бу турыда сөйләшергә хакы юк. Әтиләре бүгенге көндә безнең җәмгыятебезнең әгъзасы икән, хезмәт итә икән, димәк, Совет Ватаны алдында аның гаебе юк. Әсирлеккә эләккән, Ватан өчен сугыша алмаган икән, димәк, аның бәхете булмаган. Ә бәхетсез кешене

кыерсытырга ярамый. Без беләбез: әсирлеккә үз теләкләре белән чыгучылар да булды; анда эләккәч Ватанны сатучылар булды. Әмма алар тиешле җәзаларын алдылар. Әсирләрнең барысын бергә бутарга ярамый, апа...

— Анысы шулай инде. Тик менә армиядә кеше булмаслармы, дигән идем...

Полковник «личное дело»ларны тагын актарды. Тагын авыр сулады.

— Иһи-һи-һи, апа... Моның бит берсе инде өч тапкыр унбишәр тәүлек утырып чыккан. Кечесенең делосында милициягә дүрт тапкыр чакырылуы турында кәгазь теркәлгән. Ә мин монда милициягә бер генә тапкыр чакырылган егетләрнең дә «дело»ларын бер читкә куеп утырам. Бик изге урын, бик җаваплы урын бит ул Кораллы Көчләр, апа...

Военком янына Хәерниса ул елны ике тапкыр барды. Полковник инде көнен тә житкән, егетләрне чакыртырга булган иде. Әмма, шимбә кичләренең берсендә, кызып алган егетләр әтиләренең саклык кенәгәсен сорап тавыш чыгардылар. Хәерниса ул көнне үзенең дус хатынына чәйгә кергән иде. Ул кайткач сөйләделәр: ишегалдындагы хатыннар шырыйлап кычкырганнар:

— Үтерәсез бит әтиегезне! Үтерәсез бит!

— Кара син аны, жулик! Бавырына тибә бит!

— Милиция чакырабыз! Коткарыгыз! Үтерлегез бит!

...Хәерниса чәй мәҗлесеннән чыкканда Сәмигулланы баскыч төбенә сузып салганнар, ул аңсыз, житү чәчле егетләрнең күзен кан баскан, авызларында тәмәке иде. Әниләренә дәшмәделәр, әниләре милиция чакырырга дип әзерләнгән күрше хатынын гозерләп туктатты, ләкин «ашыгыч ярдәм» машинасы чакыруны үтенде. Телефон будкасы байтак ерак иде...

Сәмигулла больницада, операциядән соң үлде. Бавыры эштән чыккан, ярылган, кара кан эчендә иде. Егетләргә әйбер булмады, әтиләренең васыяген үтәп, авылына кайтарып күмделәр, кайткач дус-ишләре белән «поминчка» оештырдылар, кыздылар. Тик Хәернисаның гына боларга бер дә исе китмәде: йөрәге туңган иде. Авылда аның әти-әнисеннән калган йорты, бакчасы бар, үзенең туксан биш сум пенсиясе бар иде. Егетләр шәһәргә кайткач, әтиләренең өчесен, җидесен шәпләп билгеләделәр, иске телевизорны, әтиләренең мех эчле «техническая куртка»сын саттылар. Соңгысын — дүрт яртыга. Җидесен билгеләгән көнне, Казан елгасы буендагы камышлыкта иптәшләре белән эчеп, сукмак буйлап дәрестән өйгә кайтып барган мәктәп малайларын рәхәтләнеп кыйнадылар... Ике айдан соң суд булды һәм Сәмигулланың малайлары рәшәткә артына эләкте.

Хәерниса, кайгысы эчендә янып бетеп, тынычланып калды. Кызы Энҗе — шәһәр клиникасында палата врачы, дәрәҗәле. Хәерниса күңел жылылыгын шуңа салды да, аның киңәше белән авылга кайтып, бикле ишекне ачты. Үзәк өзгеч хәлләрне онытырга тырышты.

**Сәмигулланың миңа сөйләгән соңгы хикәясе:**

— Син яшь инде, ул заманны белмисеңдер. Авылда миңа ул чакта дан тактылар бит. Имеш, мин төнге сменада... Рәхмәт Хәернисага, ул миңа дөресен әйтте. Мин, диде, алдандым. Шуны кичерерлек булсаң гына барам, диде. Баласы тугач та әйтте: үзеңнеке кебек кара, диде, чәчем белән җир себерермен, диде. Миңа нәрсә — сабый ич ул. Хатын-кызны аны уважайть итеп яшәргә кирәк. Ул бит сиңа ашарга пешерә, күлмәк-ыштаныңны юа. Алай ярамый ул. Кызыбыз Энҗе хәзер врач — минем өчен җанын бирергә әзер. Мин аны үз балам итеп карадым. Хәерниса да моны аңлый, аңа рәхмәт. Миңа хәзер гел әйтә: «Мин,— ди,— сиңа кияүгә чыкканда пачти кыз идем», ди.— Миңа нәрсә, бер-береңне уважайть иткәч...

Аннан бирчәйгән кулларына карап әйтте:

— Менә тиздән пенсиягә инде. Безнең агайнегә дә эш бетеп килә. Без бит — бондарьлар. Имән мичкә ясаучылар. Кавказ безгә рәхәтләнде инде. Ну, хәзер — юк. Имән бетте. Безнең эшкә өйрәнүчеләр — яшьләр юк. Авыр эш, кул эше. Кәҗә маеңны чыгара. Хәзер без бөтен шәһәренә ун-унбиш кеше калдык. Әнә базарда имән мичкә күргәнең бармы синең?

Юк, анын имәне дә юк, кешесе дә бетте, ыструминты да юк. Барысы да пластмасса хәзер. Ә имән мичкә... Анда салынган әйбер начар була алмый. Квасмы ул, сырамы, коньякмы. Тозлау өчен дә шул гына әйбәт: пластмассада тозланган кыяр булдымы ризык? Ә гөмбә? Имән мичкәдә тозланмаган әйберне мин ашамыйм да... Юк инде, барысы да бетте. Имәнне син, елап эзләсәң дә, грамм таба алмыйсың. Им өчен таба алмыйсың син аны...

Менә шулай гомеренең соңгы елларында:

— Мичкә ясарга имән юк,— дип зарланды Сәмигулла, бичара.

## III

*Иртән торып тышка чыксам,*
*Сәләм баганага;*
*Нишләтермен бу башымны,*
*Әйләнсә диванага?*

Халык җыры

...Трамвай бик озак барды, яшь кыз — тәҗрибәсез, һәр кызыл утка килә дә туктый, килә дә туктый. Карт-коры (иртәнге ун белән унике арасында шәһәр транспорты — картларныкы), трамвай туктап озаграк торса, йөткеренә башлый. Димәк, мондый коры йөткерү һич тә суык тиюдән яки авырудан түгел, бары тик нервлар эшчәнлеге генә. Ә трамвай гел туктады, гел көтте. Бераздан Энже үзенең дә йөткергәләп алуын сизде. Үзе белми дә икән. Шәһәр транспорты — кеше характерын өйрәнү өчен искиткеч мәйдан, лаборатория. Энже, соңгы ике елда врач-социологлар группасына йөреп, «дөньяны өйрәнде». Шуннан бирле ул һәр кешегә бары тик «гыйльми материал» дип кенә карый башлады. Үзе моннан читенсенә, кешегә алай карарга ярамаганлыгын белә, ләкин — ни хәл итәсең? Йә, кызык түгелмени? Берәү синең белән трамвай эчендә кысылып, сыңар аягына басып бара, газаплана, аның үткен почмаклы портфеле синең тез астыңны каезлый — икенә дә читен. Асылынып барасың, кулъяулыгыңны кесәдән алып борын сөртерлек дә мөмкинлек юк. Ләкин шул вакытта синең янда гына бер урын бушый: үзенең төшәр вакыты җиткәч кенә, бер яшь егет яки кыз олы кешегә урын тәкъдим итә, «ихтирамлы кеше» булып, вагоннан чыга. Ә теге, синең тез астыңны портфель белән кыргычлаган юан гәүдәле абзый (яки авыр хуҗалык сумкасы күтәргән апа), әлеге урынга ларыс итеп утыруга (трамвай инеп ала!) сумкасын яки кесәсен актарып талон ала, сиңа — сыңар аякта басып, сыңар кул белән тотынып-асылынып баручыга талон бирә. Бер янчык ихтирамлы сүз сибә:

— Әгәр мөмкин булса...— ди.— Үтенәм, рәхим итеп шушы талонны гына суктырып бирегезче! Авыр булмаса...— ди,— алдан ук рәхмәт әйтеп!..— ди.

Син газапланасың, бөтереләсең, сөрлегәсең, ә ул рәхәтләнеп тәрәзәдән карап бара. Казан шәһәренең пассажирлары шулай, бары тик шулай гына.

Бүген исә трамвай эчендә өстәмә мәшәкать — халыкка нотык сөйләүче бер ир дә бар иде. Энже андый кешеләрне дә белә: гадәттә, мондый кешеләр алтмышны узган пенсионерлар була. Эш юк, оныкларны моңа тапшырмаганнар, ә энергия бар әле — менә ул, кызып алган да, трамвайга кергән, сөйләшәсе килә. Сүз сөйләү өчен тыңлаучы да кирәк, өендә аны тыңлап тормаячаклар, ул моны белә! Тротуарда да кеше туктап тормый, димәк иң җайлы урын — трамвай! Бүген менә нотыкчының шундые туры килде: куе чия драп пәлтә кигән, изүе ачык, башында — алтмышынчы елларда модага кереп чыккан яшел велюр эшләпә; анысын да, пәлтәсен

дә көя ермачлаган, иптәшнең күзләре елтырый, бит-муеннар кызыл, сөйләшәсе килә...

Алга килеп баскан да, кергән бер кешене игътибар күрсәтеп каршы ала, сүгенми, ялгыш сүз сөйләми.

— Менә, менә монда утырыгыз, иптәш инвалид! Менә урын бар. Вәт, шулай. Ә шту сез? Ул бит Ватан өчен кан койган! Ну безнең халык та күрде инде ул елларда! Безме? — ул, борылып, артка таба карый.— Безме? Һи-и, ул елларда...

Янә тукталыш. Алгы ишектән өлкән яшьләрдәге бер ир керә: калын күзлекле, мәһабәт борынлы, зур портфель тоткан. Һичшиксез, профессор, йә булмаса, консерваториядә фәлән класс алып баручы. Теге «лектор» исә моңа да игътибар бирә:

— Иптәш яһүт, монда таба утырыгыз, менә бу яшь иптәш сезгә урын бирә хәзер. Һи-и, безнең яшьләрме! Безнең яшьләр БАМ төзи, КамАЗ төзи, чаңгыда җәяүләп төньяк полюска бара. Тормыш бик шәп бит хәзер. Менә мин үзем сиксән алты сум алам пенсияне. Кая куйыйм мин аны? Әйдә, әйдә, гражданнар, чыгучыга юл бирегез! Иптәш негр, сезгә алдагы тукталышта төшәргә. Шту сез? Безнең университетта кемнәр генә укымый хәзер...

— Ә, әйдә, әйдә, агай-эне, менә яшь иптәш сиңа урын бирә. Уз, дим, уз, монда таба! Иптәш алкоголик! Менә яшь иптәш сиңа урын бирә. Ә шту сез? Ул бит законнар катылангынчы ук эчә башлаган. Аерып карый белергә кирәк. Ул бит сугышмый, бәйләнми. Иптәш алкоголик, менә монда утырыгыз. Әйе, аерып карый белү кирәк...

Халык көлешә. Вагон эчендә көлмәгән өч кеше булса — шуларның берсе Энҗе, икенчесе — олыгаеп юанайган Хәерниса иде. Ә өченчесе?..

Ике малайның кечесе Әхтәмҗан төзәтү лагереннан алдарак кайтты. Каядыр база тирәсенәме йөкче булып урнашты да, озак та үтми, өйләнеп тә куйды. Үз йортларында әнисе белән икәүләп тыныч кына яшәп ятучы, инде бер тапкыр кияүгә барып кайткан склад мөдире Феня (йә Фәниядер инде) буйлы, чибәр, ләкин ак чырайлы ябык Әхмәтҗанны бер атна эчендә үз кулына алды. Феня үткен, Әхтәмҗан исә бик басынкы иде. Атна үткәндә ул инде Жорага әйләндерелеп, ЗАГСка гариза язылган иде... Тик... Юаш Жораның алга таба тормыш корып, хуҗалык итәргә бер дә исәбе юк икән. Нагорный поселогындагы ак кирпеч йорт, бакча, мунча, өйгә кергән су, йөз башка бетмәс бройлер аны берсе дә кызыктырмады. Ә Феня белән әнисенә шушы хуҗалыкка ышанычлы бер хуҗа кирәк иде. Жораның исә бар белгәне эчү булды. Бер елдан абыйсы да кайтты, энесе йортына килде — яшәү рәвешен күрде дә авылына, әнисе янына кайтып китте. Анысы акыл алып чыккан икән, өч-дүрт көн ял иткәч, туп-туры Уренгой-Помары трассасына китеп барды. Һәм шунда төпләнеп урнашты да. Әмма дә килеп Әхтәмҗан-Жора инде... Феня аны ике тапкыр гына ЛТПга салып карады — юк, егет үзен кулга алырга теләмәде. Ниһаять, Феня аны, төзәлгәч кайтып керерсең, дип, өеннән куды. Жора яңадан Әхтәмҗанга әйләнде дә (хәер, «җан» инде бөтенләйгә төшеп калган иде), Энҗе апасына күренергә оялып, әнисе авылына юл тотты. Кешеләр аны күзәттеләр: нечкә, үтә күренмәле хәлсез куллар, тән тиресе саргылт, күзләрдә май беткән. Сөйләшкән вакытта күз карашлары катнашмый, күзләре аерым яши.

Хәерниса башта гел елады.

— Монысын бигрәк кызганам, җаныкаем,— дип яшь түкте, киемсалымын карады, акча биргәләде. Дөрес, Әхтәм әнисеннән акча өмет итми иде: эчү мәсьәләсендә ул шулкадәр талымсыз, җайлы кеше икән — рәттән барысын да эчте. Каяндыр килгән лосьонны да (Энҗе калдырып киткәндер инде), шампуньны да эчте, әтисе Сәмигулла заманыннан ук сакланган затлы одеколонны да ялт иттерде, мунча тәрәзәсе төбендәге теш порошогы, пасталар да юкка чыкты. Кибеткә сум да ун тиенлек, тирләүгә каршы бер сыеклык кайткан иде — аңа рәхәт-

ләнде, аннан — көя даруына.

Антимоль — сиптерә торган итеп, аэрозоль рәвешендә эшләнгән иде. Хәерниса бервакыт мунча алдының ярыгыннан карап торды: Әхтәм мунча артына чыкты, кесәсеннән бер кадак алып, антимольнең астын тиште, стаканга чыжылдап аксыл бер сыеклык акты. Як-ягына карангалап алгач, малай стаканны әйләндереп куйды да, дару савытын бәрәңге сабагы арасына ыргытты. Аннан ишегалдында энисе белән бераз сөйләшеп утырды. Бичара, беткән. Хәйләкәр үзе, ә беткән. Гел алдый, гел үз ягына алдый. Кичке якта ул, кинәт кенә торып, аръякка кибеткә чыгып китте.

— Борис Федорович килгән, шуны күрәсем бар,— диде. Хәерниса башватты: кем икән бу урыс?

Кичен улы шактый кызып кайтып керде. Иртәгесен кибетче кыз сөйләде:

— Үләм, җаным, Хәерниса апа. Кләй кайткан иде кичә, шуны әллә ничәне алды. Суга болгатып, шуның кләен аерып алып, сыеклыгын эчә икән,— диде.

Бер-ике көннән малай тагын алдады:

— Әни, өч кенә сум акча биреп тор, Бакудан Әдһәм исемле бер дустым килгән, тегендә бергә булган идек,— диде. Өчлек юк иде, энисе биш сум бирде.

Малай төнгә тагын кызмача кайтты. Иртәгесен кибетче кыз сөйләде:

— Карар чыкты бит, Хәерниса апа. Авыл кибетләрендә эчемлекне бетерәбез. Складта калган бер ящик «Агдам» бар иде, кичә шуны саттым. Сезнеке шатланды да инде — ике шешә алды...

Ял итеп ятучы академикмыни — шәһәрдән әллә кемнәр килә үзенә. Ике тапкыр ике кеше килеп тапты аны. Мунча баскычына утырып озак сөйләшәләр. Тәмәке кабалар, ашарга да кермичә, китеп тә баралар. Әхтәм үзе боларның кем икәне турында энисенә бер сүз дә әйтми, ләкин аңлашыла инде — тегеннән болар, тегеннән. Алар киткәч, Әхтәм ике-өч көн буе ашамый-эчми, баш астына кулларын куеп, мунча алдындагы сәкедә көннәр буе ята, беркем белән аралашмый.

Тик күршеләр генә тынгысыз:

— Шайкада булган ул,— диләр.— Аңа иреккә чыкканда тегендәге башлыклары эш кушып чыгарган. Бу шуны үтәми икән. Соңгы килүләрендә әйткәннәр: фәлән вакытка кадәр шуны үтәмәсәң, җыештырабыз, дигәннәр...

Ул шикле кешеләр, ахрысы, шәһәрдә Феня янына да килеп киткәннәр. Менә бер көнне, Энҗегә ияреп, авылга Феня да кайтып төште. Әхтәмнең каяндыр, нәрсәдер табып эчкәнен белүче юк иде, әмма алар кайткан көнне «Жора» ләх иде.

Йортта өч хатын төн буе киңәштеләр.

Иртәгесен колхоз автобусын белештеләр. Хәернисаның йорт-җирен, вак-төяк кош-кортын Исламгалиләргә ышандырып, Әхтәм-Жораны шәһәргә алып киттеләр.

Төнлә, энисенең өендә Энҗе болай сөйләгән иде:

— Моны гадәти медицина ала алмый, әни. Мин бер психиатор белән сөйләштем. Ул тәҗрибә уздырып карарга булды. Ләкин бу — фәнни ысул түгел. Моның методикасы эшләнмәгән. Һәм ул метод әле дөресме икән? Монда безнең югалтыр әйбер юк, бу малай барыбер беткән, әйдә шуны эшләп карыйк әле... Тик бу турыда кешегә сөйлисе түгел. Теге докторның харап булуы бар.

...Юка, үтә күренмәле, аксыл чырайлы Әхтәмне ялтыравыклы ак буяу белән буялган, елкылдап торган җиз тоткалы биек ишекне ачып, биек түшәмле мәһабәт бер бүлмәгә керттеләр. Кырып эшләнгән юан аяклы зур калын өстәл янында башына зур ак калфак кигән, ак халатының җиңнәрен сызганып, йонлы беләкләрен өстәлгә салган калын кырыйлы күзлеген таза борынына төшереп элгән олы ир утыра иде. Әхтәмгә

күтәрелеп карамыйча гына, кул хәрәкәте белән утырырга кушты, үзе берөзлексез кәгазь актарды, ниләрдер укыды. Әхтәмнең борыны йомшады, муены тирләп китте. Теге һаман дәшмәде. Шундый зур борын, йонлы таза беләкләр белән врач булып була микәнни?

— Тәк, тә-кс...— Йа, ходай, тавышы да калын икән! Әхтәмне инде бөтенләй курку басты.— Ярар... Менә миңа монда ике гариза килеп керде. Синең өстән. Тәкс-с. Йә?

— Н-нинд-ди? — дип чак әйтә алды Әхтәм.— К-кем язган?

— Нинди, нинди...— тавыш тагы да калынайды.— Кемнәр язган... Язганнар менә...

— Н-нәрсә дип? — Әхтәмнең иреннәре калтырый иде. Тегенең тавыш тагы да көчәйде.

— Менә нәрсә дип: «Мин, фәлән-фәләнева, аның хатыны, сездән үтенәм: бу кеше миңа кирәк түгел. Бу кеше безнең җәмгыятькә дә кирәк түгел. Җир йөзендә моны яшәтүдән файда юк. Сез моңа берәр төрле укол бирегез».

Әхтәмнең тамагы кипте. Шул вакыт ул доктор өстәлендә тәгәрәп яткан зур бер шприц күрде. Коточкыч! Тегендә вакытта аларны бер совхозда эшләткәннәр иде, шунда ул нәсел үгезенең муенына укол кадаганнарын күргән иде: сыеклыгы йөз грамм булгандыр. Үгез шунда, муенына шартлатып энә тыкканда, чайкалып киткән иде. Ә монда! Шприц савытына бер стакан сыеклык керәдер! Моның белән, дару түгел, квас җибәрсәләр дә үләрсең!

Ул арада тукмак борын икенче бер кәгазьне укый башлады. Әхтәмнең күз алларында әллә ниткән ак болытлар йөзеп йөри, доктор да аңа инде кеше булып түгел, алланың нәкъ үзе булып күренә, алланы ул балачактан ук шундый ак халатлы, күзлекле була дип күз алдына китерә иде.

— Ә менә монысы — әниеннән. «Мин, фәлән-фәләнева»... Тәк-с... Әнисе... «Сездән үтенәм шул хакта: минем улым Әхтәмҗан Сәмигулла улы... гел эчә. Ул инде төзәлә алмый. Аңа бу дөньяда яшәүдән бер мәгънә дә юк. Шуңа күрә аңа берәр...— доктор өстәлендәге беләк юанлыгы шприцка карап алды,— аңа берәр төрле укол биреп...»

Әхтәм аңын югалта башлады. Ул арада, биек ак ишекләр ике якка таба ачылып китте дә, дөбер-шатыр килеп, дүрт таза ир ишек тирәсен тутырды, бәрелә-сугыла зур, таза носилка алып кереп, идәнгә куйдылар. Барысы да ак халаттан, ак калпактан, барысы да җиңнәрен сызганган һәм таза беләкле иде. «Студентлар, медиклар,— дип уйлап алды Әхтәм, аңына килеп.— Мине алырга килгәннәр. Ну, болар имансыз халык инде. Әллә чыгып качаргамы?

— Йә, доктор, әзерме? — диде егетләрнең берсе. Аннан ак урындыкта агарып утырган Әхтәмгә ымлап:

— Ник, сез бит безгә нәкъ ун тулып ноль-нольдә керергә куштыгыз? — дип, докторга сораулы караш ташлады.

— Хәзергә чыгып торыгыз. Өч минуттан керерсез,— диде доктор һәм, папканы ябып, шприцны кулына алды. Таза егетләр сөрлегеп чыгып киттеләр. Доктор урыныннан торды.

— Ну, тәк-с, агай-эне,— диде ул, бармак башларын спиртлы мамык белән сөртеп.— Мин аңладым. Сезнең бу дөньяда кеше төсле итеп, аек баш белән яшисегез килми икән. Иң якын кешеләрегез сездән баш тарткан. Бер оешмадан да сезне сорап-аклап язылган кәгазь юк. Димәк, сез берәүгә дә кирәк түгел. Шулай булгач, без нишлибез? — Ул, Әхтәм янына килеп, аның уң беләген сызгандыра башлады. Шприц эченә әле сыеклык салынмаган иде. Доктор, ашыкмыйча гына барып, ак шкафны ачты. Шкаф эче тулы дару шешәләре иде. Үзе сөйләнде:

— Шулай булгач, шулай булгач...— үзе көйләде:

А жене скажи
Слово прощальное.

Передай кольцо
Обручальное.

Шул чак ишектән тагын теге егетләр күренде. Идәндә, ыржаеп, адәм гәүдәсе көтеп, теге носилка тора иде:

— Йә, доктор, әзерме? Тизрәк булсагыз иде. Безнең теге палатадан бер авыруны машинага озатасы бар. Баш врач әйтте: тиз булсын, диде.

Шулай диделәр дә ишекне яптылар, ә доктор шприцына сыеклык суырта иде, үзе һаман борын эченнән шыңшыды:

Напрасно старушка ждет сына домой,
Ей скажут, она зарыдает...

Шулвакыт Әхтәмнең тын юлы ачылып китте:

— Юк! Юк! — дип шырыйлап кычкырды ул.— Юк! Минем яшисем килә! Мин моннан соң грамм да эчмим! Минем якты дөньяда сезнең кебек яшисем килә!

Биек ишек тагын ачылды һәм, тыгылышып, тагын теге егетләр керде. Тегесе — сөйләшә торганы — әйтте:

— Доктор, баш врач сездән риза-бәхил түгеллеген белдерергә кушты. Кая, ник сузасыз? Үзебез ярдәм итикме? — ул Әхтәмнең беләгенә килеп кагылды.

Әхтәм исә, дер калтырап, чын йөрәктән елый иде:

— Доктор! Зинһар, дим! Доктор абый! Абый җаным! Миңа яшәргә рөхсәт итегез! Чәчем белән җир себерәчәкмен! Теге гаризаларны ертыгыз! Мин кирәк әле, кирәк кешеләргә...

Ул аңын җуйгандай итте.

Аңына килгәндә, беренче тойгысы шул булды: җылы, йомшак кул аның иягеннән тоткан да, авызына салкын су коя. Стаканнан хлороформ исе килә. Хатыны Феня икән. Ә олы борынлы доктор, йомшак елмаеп, Феняга нидер сөйли. Әһә, болай дип сөйли икән:

— Менә, ханым, мин сезнең гаризаларыгызны ертып урнага ташладым. Бу егет бүтән бер грамм да авызына алмаячак. Сезнең бәхет басты: бу — менә дигән ир, хуҗа булачак. Тик берәр ел балага узмый торырга киңәш бирер идем. Аның организмы алкоголь белән бик тузган. Аңа ял кирәк. Бәлки берәр айга авылга җибәреп торырсыз?

Әхтәм август аен авылда уздырды. Әнисенә печән әзерләште, бәрәңге бакчасында колорадо коңгызын җыйды, тавык кетәклеген рәтләп куйды, бакча капкасының баганасын яңартты. Аз сөйләште, эчү турында сүз кузгатучылар булган җирдән тиз генә читкә тайпыла иде. Феня һәр шимбәдә шәһәр күчтәнәче төяп, авылга кайтып йөрде, шатлыгына чикчама булмады, кайтуга җырлый-җырлый су китерә, дуылдатып идән юа, мунча яга, парлап мунча керәләр. Йортта гел шатлык иде. Тик ире генә бер тапкыр да елмаймады, караусыз гына эшләде дә йөрде.

Ай чамасы үтте, бу атна ахырында Феня кайтып, аны инде шәһәргә, үз янына алып китәргә тиеш иде. Хәерниса җиңги, авыр сулаштыргалап, төенчекләр әзерли башлады. Әхтәм киткәч күңелсез булачак иде аңа.

Тик Әхтәм шәһәргә, Фенясы янына китә алмады. Атна кич көнне ул кичтән юкка чыкты. Җомга көн төш вакытына кадәр Хәерниса җиңги авыл буйлап сорашып йөрде. Йөрәгён шөбһә алды: әллә ходаем, тагын «тегеннән», «тегеләр» кайтып киткәнме? Җитмәсә, нәкъ ул югалган кичтә телевизордан Шукшинның «Кызыл балан» дигән фильмын күрсәткәннәр иде. Хәернисаның йөрәге парә-парә килеп телгәләнде. Йа хода, нишләргә? Ни булды икән? «Тегеләр» кайтып берәр хәл эшләмәделәрме икән?

Җомга көн төш вакытында күрше Исламгали хатыны Рәшидә аны үз коймалары янына чакырып алды.

— Әйтергә телем әйләнми, Хәерниса, миннән булмый, әнә Исламгали су буена төшеп китте, шуны тыкрыкта көтеп тор,— дип, үкереп, сикәлтәле итеп елап җибәрде.

...Әхтәмҗан, бичара, әтисенең чардуган почмагына язу кыстырган: «Әти! Мөмкин булса, үз яныңа ал мине. Син мине гафу ит. Минем бу дөньяда яшәвемнең бер мәгънәсе дә юк. Мин яшәмәкче булып караган идем, барып чыкмады. Нигә дип кешеләрне җәфаларга. Гафу ит тә ал мине. Синең белән бергә, бәлки, җиңелрәк булыр. Улың Әхтәмҗан.»

Малай әтисенең кабере өстенә капланып яткан, йөзе бер яктан күренеп тора; теле, каралып, авыз эченнән салынып чыккан, кул бармаклары зәңгәрләнеп янган, бер аягыннан ботинкасы салынган, ә икенчесе белән, тырнаштырыптыр инде, кабер өстеннән байтак чирәм, кәс, кызыл балчык ишкән.

Чардуган кырыендагы биек үлән арасыннан Исламгали агай майлы, кара калын пыялалы бер шешә табып алды; моннан ике көн элек кенә аның кече малае капка төбендә үзенең мотоциклын сүтеп, ремонтлап яткан иде, әйберләрен җыештырганда «Аккумулятор электролизы салган шешәм кая китте соң?!» — дип, әтисенең-әнисенең тәмам үзәгенә үткән иде.

— Синең кислотаң чуртыма кирәкмени, кем алсын аны, үзең алама син, әйберне кая куйганыңны белмисең,— дип, әтисе аны сүккән иде. Инде менә бушаган шешәне таныдылар.

...Әхтәмҗанны күмгән көнне Хәерниса җиңги сулыгып-сулыгып елады:

— Монысын бигрәк тә ярата идем, җаныкаем, монысы бигрәк тә сабый күңелле иде,— дип яшь койды.— Шулай, ходай күпсенгәндер инде. Күрәчәкне күрми, гүргә кереп булмый, диләр шул. Монысын бигрәк тә ярата идем шул, бәбкәем...

## IV

*Без кечкенә вакытларда*
*Биек иде манара...*

Халык җыры

Кешенең иң зур, көчле хисләреннән берсе — алдан сизү.

Кеше әле үзенең нәрсә көткәнен белми, ләкин күңеле өзгәләнә инде, тыпырчына. Мондый сизү балачактан ук башлана.

...Безнең колхоз утыз алтынчы елның язына бик начар чыкты: аерым хуҗалыктан китереп берләштергән атларның бөтенесе дә дип әйтерлек, язгы ташу вакытында ачлыктан кырылып беттеләр. Җирле-сулы, игентарулы бер төбәктә атларның ачтан үлүе бары тик урындагы җитәкчеләрнең тавык мие булуыннан гына иде — ләкин ул вакытта алай уйларга ярамый иде: колхоз җитәкчелеге нәрсә эшләсә дә дөрес, атлар кырылган икән — димәк, шулай кирәк булган, алар урынына корыч атлар — тракторлар килер. Хәер, ат турында, имеш, Сталин болай әйткән дигән сүзләр йөри иде. «Атлар — колхозның алтын фонды». Әмма, утыз алтынчы елның язында «алтын фонд»ны колхозчылар, үзләре үк ат арбасына салып, «үләт зираты» дигән үзәнлеккә ташыдылар. Язга колхозчы да бик коргаксып чыкты: утыртырга бәрәңге калмаган, бура төпләрендә он юк иде. Исән калган атларга озын арбалар җигеп, исемлек белән шуңа кешеләр төяп; тегеләй итеп, болай итеп юнәткән акчага орлык бәрәңгесе, аз-маз он алып булмасмы дип, халык Чепья базарына юл салды. Һәр атнада, яз буе, җәй уртасына кадәр Чепья базары безнең як өчен ул елларда шәфкатьле ана булды. Аннан безнең авылга мари бәрәңгесе, удмурт-татар арышы, солысы, оны кайтты. Чепья базары халыкны ач үлемнән саклап калды. Ул арада утыз җиденче елның уңдырышлы җәе килде, ул җәй игенле, җиләкле, печәнле, күп каз бәбкәле, тилгәнле булды; урманы мул кура җиләкле, күшәле, еланлы, бурсыклы булды — халыкның эше күп иде, әмма тамагы кара ипигә туйды, ара-тирә әле бодай

кабартмасы да пешергәлиләр иде; кабартма пешкән көнне ул йортның хуҗасы, капкасын киң ачып, урамга чыгып карангалап тора, өенә кереп китә, тагын чыга. Авыз тирәсе майланган, колак тишекләренә шалкан чәчәрлек булган, ямаулы ыштан кигән, сагызланган чәчле малаеның кулына кабартма кисәге тотып урамга чыкканына тап булган әти кеше болай гына, бәхете ташыганнан гына әлеге сагызлы башка берне биреп — ризыкның кадерен бел! — як-ягына карангалап та ала: менә күрдегезме, без — шулай, кабартма да ашыйбыз, малайга да «пущады» бирмибез...

Ул җәйне Чепья базары, анда сатулашып алган ярты пот арыш оны, ике чиләк вак утырту бәрәңгеләре онытылды. Тамак шулай, ачса — туяр күк түгел, туйса — ачар кебек түгел...

Гомер — узган. Нәкъ илле ел — ярты гасыр узган! 1986 елның кышында мин, бер төркем язучылар белән, Чепья авылына барып чыктым. Максатыбыз — бу авылдагы уникаль музей белән танышу иде. Язучылар төркемендә бу як төбәгендә туып үскәннәрдән мин берүзем идем һәм музейда йөргәндә, экспонатлар караудан бигрәк, тәрәзә тирәсендә йөренгәләдем: теге базар урыны кайда? Кайда ул минем әтиләр, әниләр таптаган сукмаклар, кайда ул безне ач үлемнән саклап калган базар эзләре, кайда ул безнең авылның ябык, хәлсез атларын бәйләп торган киштәләр? Моннан илле ел элек авылга вак бәрәңге, эре итеп тартылган яртышар пот арыш оны озаткан Чепьяның ашханәсенә кердек. Безне Чепья сыйлый: өстәлдә «Боржоми» шешәләре тезелеп киткән. Шәһәрдә им өчен таба алмыйсың. Коштабакларда — Болгария помидорлары. Авызга капканда ук эреп китә. Мин бу өстәл ризыкларының барысын да язам, утызынчы елның язында, җәендә ике чиләк утырту бәрәңгесе эзләп алтмыш чакрымнан килгән ач әтиләр, әниләр рухына бер истәлек булсын дип язам. Фарфор тәлинкәләрдә — кисәкләп-кисәкләп тозлаган кәбестә, салатлар. Сельдерей, петрушка сабаклары өскә куелган. Салкын тавык ите, сыер ите, горчица. Түшкәсе белән кыздырылган каз өч-дүрт урынга куелган, ә без — егермеләп кеше. Аш китерелде, токмачы яшь кызлар кулы белән нечкә итеп киселгән. Аны ашап бетерер-бетермәс, чынаякчокырларга салынган шулпа, сарык ите белән пешерелгән, тышлары кызарып киткән пөхтә өчпочмаклар килде. Аннан дүрт-биш урынга бәлеш килде. Аннан — ширбәт. Һинд чәенең хуш исеннән баш әйләнде (шәһәрдә юк!), чәй янына кәрәзле бал куелды, Венгрия алмалары өстәлгә аерым бер затлылык биреп торалар иде. Хуҗалар ыгы-зыгы килде:

— Менә монысы — балан вареньесы!

— Менә чәйгә кадәр моны авыз итегез инде: безнең урман гөмбәсе. Бездә генә шулай тозлыйлар...

— Чепья казын кабып карагыз инде. Бездә каз ите бик тә тәмле була.

...Минем тамактан үтмәде. Аш мәҗлесеннән соң, иптәшләрдән аерылдым да, Чепья базары булган урыннарны карарга киттем. Элеккеге лавка урыннарын, ат бәйләү урыннарын. Мәшһүр базарның эзләре әлегә калган. Ихтимал, киләчәк буын бу урынны да халык тарихының бер кисәге — музей итеп оештырыр әле. Менә бит — бер үк җирдә атларны ачтан үтерергә була, ярты потлап кибәкле арыш оны эзләп йөреп була, ләкин шул ук җирдә, өстәл тулы ризыкны тегеннән-моннан гына авыз иткән көе, өеп калдырып чыгып китеп була... Шул ук җир. Чепья урамнарында йөргәндә минем күзләремдә гел яшь булды.

Ә теге елга — игенле-печәнле тук елга килсәк — ул елның да көзе авыр булды. Көзен каз суяр вакыт кына җиткән иде, газеталар аша һәм шәһәрдән кайткан кешеләр авызыннан дәһшәтле хәбәрләр ишетелде: илдә корткычлар күбәйгән икән, узган елгы ачлыклар, атлар һәлак булу — барысы да шулардан икән. «корткыч» дип агалган халык дошманнары әлегрәк Кировны, аннан Горькийның малаен үтергәннәр икән. Әйе, Киров үлгәч, шундый җыр авылга килеп җиткән иде:

Политбюро члennары
Атучыны кулга алды;
Сергей Миронович Киров
Арабыздан югалды...

Менә хәзер шул эшләргә «бәйле» кешеләрне жыя башлаганнар. Авылга көн саен хәбәр килә: кичә төн уртасында Көтек башлангыч мәктәбенең мөдире Зәки Галиевне алганнар (ул еллардагы сөйләм телендә: «апкиткәннәр»). Бер-ике көннән — тагын хәбәр: Казанда Абрамовны, Лепаны «апкиткәннәр» — Татреспубликада болар иң зур шәхесләр иде кебек; Яңа Чүриледә ат карауччы Савелий Петровичны алганнар: халык дошманнары кушуы буенча бер атны агулап үтергән. Халык тынсыз калды. Менә бервакыт мәктәп дәреслекләреннән Блюхер, Тухачевский рәсемнәрен ерттырдылар. Уку китапларыннан кинәт кенә Галимжан Ибраһимовның рәсемен һәм «Аждаһа» дигән хикәясен (хәзергечә: «Яз башы») ерттырып, мәктәп миченә ташлаттылар. Ә бер төнне очлы шлем кигән (безгә мәктәптә аны «шлюм» дип өйрәттеләр; ни хикмәт, татар баласы әле дә шулай әйтә) ике кеше, колхозның бригадиры Ризван Хисамиев белән кибетче Әхмәуны ияртеп, безнең өйгә дә керделәр. Ул елны төнлә кергән кешеләр буш китми иде...

1937-38 елның кышы шулай узды.

Утыз сигезнең җәенә чыксак — тагын ачлык, мохтаҗлык. Кибеткә әллә нигә бер ипи кайта, аңа чиратны кичтән үк алып, уч төбенә зәңгәр карандаш (бездә: хәрендәш) белән номер суктырасы. Таң атканда берәү, чиратны яңадан барлап, очын лач итеп төкереклән, бу юлы инде кызыл хәрендәш белән кул аркасына яңа номер суга. Мендәр тышы, тәрәзә пәрдәсе, галош-фәлән кайтса да шулай. Тәмәке — язгы чәчүдә эшләгәннәргә генә...

Ипи ашыйсы килгән вакытның иң үзәк өзгече — язын үлән типкәндә. Җил исә, ул җил басудан арыш саламы, урманнан ылыс, су буеннан балык тәңкәсе, ләм исе алып килә, борынны кытыклый — һай шул вакытта авыз тутырып бер ипи кабарга да күздән яшь килгәнче рәхәтләнеп сытып чәйнәргә... Чәйнәргә, аңкаулардан, теш төпләрендәге селәгәй бизләрен актык чутына кадәр эшләтеп, чылатып, тамак юлын тутырып, бер тапкыр ипи йотарга... Юк, ике тапкыр... Юк, өч тапкыр, дүрт тапкыр... Нигә юк соң бу ипи, әнә бит басу-кырлар, әнә бит авеслек янында салам эскертләре, алардан бит инде ипи чыккандыр? Нигә бу тамак төбе бизләре берөзлексез ипи сорый, нигә басудан искән язгы җил гел ипи ашасын китереп тора? Ул җил соратмый бит синнән кызыл яки кара икра, тамак төбе өмет итми бит авызда эреп торган шулпалы өчпочмакларны, таләп иттерми бит ул җил кайнар калҗалы итләрне, алтынсыман лимоннарны, исерткеч исле шоколадларны, яки җиңелчә горчица сөрткән каз итен, йә шашлыкның баш әйләндергеч исле кисәкләрен! Нибары бер сынык (телем) кәрәзле ипи кирәк бит адәм баласына...

Без, сигез-ун яшьлек малайлар, аңлашылмый торган бу хәлдән югалып калган, без моңа төшенә алмыйбыз. Безнең ашыйсы килә, колхоз җитәкчеләре исә шуны белмиләр. Концерт куябыз (кайбер картлар әйтә: үзең ач бул, үзең хаҗ кыл!), шунда лозунг кычкырабыз:

— Бәхетле балачагыбыз өчен иптәш Сталинга рәхмәт!

Әнә Гыйлемҗан Җәмиле дигән малай алай лозунг кычкырмый. Аның әнисе үги, келәтләрендә азмы-күпме он запасы бар, алар аратирә ипи салалар, ләкин үгез кебек таза Җәмилгә (аңа уникe яшьләр чамасы иде) үги әнисе ипи телемен бик юка итеп кисеп бирә икән. Безнең авылда шулай иде: урамда, кырда, тау битендә, су буенда уйнап йөргәндә малайлар, кинәт кенә уеннан чыгып, беркемгә дә, хәтта уен башлыгына да әйтеп тормыйча, өйләренә торып йөгерәләр дә, кайтып кергән шәпкә:

— Әни, бер телем ипи бир! — дип, йөгерүдән туктамаган көе генә сорап алалар. Бу гадәт малайларга шулкадәр сеңгән ки, инде ипигә туйгач та шул дәвам итә. Мин авылда укытучы булып эшләгәндә күрше фатирда бер гаилә яши иде, аларның беренчеме, икенчеме класста укый торган йомшак борынлы малайлары, клубта балалар өчен барган фильмны үзенчә урталай өзеп, өенә торып йөгерә һәм чоланнан кирә-керешли: «Әни, ипи бир!» — дип кычкыра иде. Ашыйсы киләсен алдан белсә дә, ул малай бер сеанска да кесәсенә ипи тыгып бармады.

Бу гадәт — өйгә торып йөгерү — үзенә күрә борынгы патриархаль тормышның бер чагылышы булган, күрәсең. Безнең буын өенә ипи сорар өчен генә түгел, башка мәсьәләләр буенча да торып йөгерә иде. Әйтик... сугышып алгач. Без үскәндә «сугышу»ның ирләрчә бер поэтикасы бар иде (хәзер ничектер, әйтә алмыйм). Сугыш ике төрлегә бүленә. Беренчесе — кызлар карап торганда. Монда ике якның берсе елый башлаганчы сугышасы, шунсыз ярамый. Икенчесе — үзара. Кыз-кыркын юк, бәргәләшеп аласың, егыласың, сикереп торасың да болай дисең:

— И-и-и... Мин егылмыйдыр идем, үзем юри егылдым...

Сугыш шул хикмәтле дипломатик нәтиҗәдән соң туктый.

Инде дә килеп, кызлар карап торганда авыз-борынга аз гына тиеп алгач егылгансың һәм гарьлектән елыйсы килеп тамакка төен утырган икән, анда бер генә юл: елауны мондый урында эрәм итәсе түгел. Тиз генә торып йөгерәсең дә, елауны тутырык килеш (тулы көе) үз өеңә алып кайтасың, аны алып кайтканда синең тизлек шундый була ки, шайтанның үзе дә сине куып җитә алмый! — капкадан керүгә рәхәтләнеп бер ычкынасың, анасын аучы атып үтергән көчек кебек, күккә карап, бер елап җибәрәсең! Бу — ике яклап файдалы. Беренчедән, синең бу гарьлегеңне теге яланаяклы пычтык кызлар күрми калды, икенчедән — елыйсы килә бит, елыйсы килә бит... Нәкъ ипи ашыйсы килгәндәй — елыйсы килә...

Ә теге Җәмилгә (ул бик таза, беркем белән дә сугышмый, берәүне дә рәнҗетми иде), ипи сорап кайткач, үги әнисе ипине бик юка кисеп бирә икән. Җәмил әйтә иде:

— Әни миңа ипине үзен-үзе күтәреп тормаслык зур итеп кисеп бирде...

Җәмилне үги әнисе гел кыйный иде. Кыйнап, келәтләргә ябып куя иде. Без моны белә идек һәм, аңа ярдәм итә алмаганыбызга кыенсынып, аның белән очрашканда гел читкә карый идек. Җәмил тамак турысында аеруча хирес булды, шуңа күрә утыз сигезенче елның шыксыз ач җәендә без гел аның тирәсендә әвәрә килдек.

...Басу тулы кояш. Күк йөзендә, өстә, бик өстә тилгән тирбәлә. Без — борчак басуында. Чабып алганнар, төяп, ындырга ташыганнар; бер баштан инде, пар сука белән кереп, сөрә дә башлаганнар. Кояш шулкадәр мул, еракта-еракта әллә ничә офык ясалган. Кыр — тып-тын. Күк йөзендә тибрәлгән кайнар һава дулкынында тилгәннең пыс-пыс килеп сулыш алганы ишетелә сыман. Басу, күк йөзе, катлы-катлы ерак офыклар моң тибрәтә, бөтен дөньяны ниндидер сагыш, ачлык катыш сагыш баскан, безнең күңелләр нидер көтә, дөньяда ниләрдер бар кебек. Без, кара туфрак арасыннан чүпләп, борчак ашыйбыз. Нургали (минем күрше) әйтә: «Корт ашаганын әрәм итмә, корты-ние белән чәйнәп йот, теш сызлаганга иң тучный дәва шул», — ди. Шулай, корты-ние белән ашыйбыз. Ашап бераз хәл кергәч, межага чыгып тәгәрибез, күккә карап ятабыз. Кечкенә ефәк кулъяулыктай болыт кисәге, ашыкмый гына Казан ягына таба йөзә. Менә аңа рәхәттер. Кая теләсә, шунда китә ала. Ул әле юл өстендә әллә ниткән тук җирләрне узадыр, ипи салып яшәгән авылларны күрәдер. Шулай хыялланабыз. Ул арада Җәмил җыр башлый. Куркыныч булып китә. Бу җырның сүзләреннән җан өши, Җәмилнең үзенең дә күзләре яшьләнә. (Җырның бер генә строфасы хәтердә иде, ләкин мин аның тулыга якын текстын нәкъ илле ел

узгач таптым, бу турыда алда язачакмын). Жыр болай:

Пивнойга кердем ашап чыгарга,
Пивнойдан чыктым эчеп-исереп
Их! Югалдым мин, егет, калтырый куллар,
Үтәдер айлар, үтәдер еллар.

Соңгы ике юлны Җәмил ике тапкыр кабатлый, ул төшен аеруча дулкынланып, бераз кычкырыбрак җырлый.

Өебезгә кайттым, капканы кактым,
Ишекне мин ярдым, тәрәзне ваттым.
Их! Югалдым мин, егет...

Әткәйне будым, әнкәйне чалдым,
Кечкенә сеңлемне суларга салдым.
И-и-х! Югалдым...
Агыйдел өстендә ак парахут,
Озаталар мине на Дальний Восток.
Их...

Берсе судить итә мине асарга,
Берсе судить итә мине атарга.
Их...
Өстемдәге күлмәгем кернәнеп туза,
Минем яшь гомерем төрмәдә уза.
Их...

Бу җырга без дә кушылмакчы булабыз, ләкин курку, дәһшәт шул дәрәҗәдә ки, күзләрне яшь баскан, тамак төбенә төен утырган, тәнгә каз итләре чыккан — беркем берни эшли алмый. Җәмил инде исә үзен-үзе кыздырган, утырган урыныннан торып, межага басып җырлый:

Болар миңа бирә «ипи, тоз» белән,
Йөрәгемне яра усал сүз белән.
И-и-х!

Башыма кигәнем — серый фуражка...

Җан өшеткеч бу җырдан соң инде борчак та ашыйсы килми, дөньяда яшәү ничектер мәгънәсезлек булып тоела, бу ямьсез җыр тәэсиреннән, ачлыктан әллә кайларга качасы, әнә теге ак ефәк кулъяулык болытка тотынып, бу җирләрдән еракка-еракка китәсе килә. Әнә үги малай Җәмил, бездән аерылып, билчәнле межа буйлап, өенә кайтып китте, үзе һаман җырлый иде, тик бу юлы инде башка җыр, озын көйле җыр.

Без кечкенә вакытларда
Биек иде манара,
Без үсеп буйларга җиткәч
Авырайды замана.

Бичара, бүген дә гел ашады гына ул, «Өйгә алып кайтмагансың», дип, үги әнисе тагын кыйнаячак инде аны, тагын аркасын төячәк, аннан ул тагын төнлә астын юешләтәчәк. Әнә шуңа күрә ул вакыт-вакыт гел бер җыр җырлый:

Уйлый күңлем, уйлый күңлем,
Уйлый күңлем шашарга.
Уйлый күңлем Татреспублικадан чыгып качарга.

...Шундый кояшлы, борчаклы, тилгәнле моңсу бер көндә межага утырган гына идек, Җәмил инде «Югалдым мин, егет»не башлап та жи-

бәргән иде, кинәт авыл ягыннан Җир-ананың тешен суыргандай шөбһәле бер шыгырдау ишетелде. Бераздан тагын, тагын. Ни булганын аңламастан, авылга торып йөгердек. Авыл уртасында, мәктәпкә әйләндерелгән мәчет янында, кара болыт булып халык җыелган иде. Без әле һаман аңламадык. Теге шыгырдау тагын яңгырагач кына төшендек: ике кеше мәчет манарасының итәгендәге такталарны каерып йөриләр иде. Күпмедер вакыттан соң манараның түбәгә тоташкан урыны ачылып китте. Бичара! Эчендәге такталары сап-сары икән, тыштан гына җилдә, кояшта каралып утырган икән. Бераздан түбәдә йөргән ике кеше манара эчендә юк булдылар; күп тә үтми выж-выж килгән пычкы тавышы ишетелә башлады. Халык дәшмәде. Дөрес, хатын-кыз ыгы-зыгы килде, әмма ирләр, карт-коры түбән карап, карасына коелып басып торды. Картлар арасында уникенче елда бу мәчетне салуда катнашканнар да бар икән. Берсе мыгырданып кына сөйләде:

— Һи-и, моның үзәгенә агачны эзләдек тә инде. Ыстарший остага һич ошатып булмады. «Манара үзәгенә дигән агач ботаксыз кара чыршы, йә булмаса төз нарат булсын», ди. Дүрт буйлык агачны каян табасың тиз генә. Ботаксыз агач буламыни? Атна-үн көн эзләп тә таба алмагач, пушмистергә бардык. Ул «ә» дигәнче Сорнар өстендәге бер наратны әйтте, юлын өйрәтте.

Моны тыңлап торганда хәтергә бер җыр килде. Бу җырны кичен авыл егетләре бер дә җырламый калмыйлар иде инде.

Кистем каен, кистем каен
Манара үзәгенә;
Бит уртаны алыр идем
Шәльяулык бизәгенә.

Манараны кисүчеләр кемнәр соң? Күрше Сикертән җидееллык мәктәбендә математика укытучысы Фәезов дигән егет белән үзебезнең авыл мәктәбе укытучысы Гатият Әсәдуллин икән. Менә бераздан манара эчендә балта тавышы яңгырады, манара ыңгыраштьı, аның күккә ашкан алюмин ае чайкалып куйгандай булды. Карчык-коры елаша башлады. Кемдер, Гайшәттиме, карлыккан тавыш белән әйтә куйды:

— Ярабби ходаем, бу ике әтрәк-әләмнең кулларын корыштыр, ярабби, кеше кулларына калып, ризык өмет итеп тилмереп ятсалар иде...

Бу — авыр каргыш иде. Әтрәк-әләм дип безнең авылда иң актык кешегә, нәсел-нәсәбе буенча атсыз-тунсыз яшәп, кешегә ялланып тамак туйдыручыга әйтәләр иде. бу ике егеткә карата ул сүз туры килгәндерме, юкмы — аның Фәезов дигәне Кукмара ягы Ядегәрдән, Әсәдуллин дигәне күрше авыл Яңа Масрадан иде. Берәр сәгать шыгырдап-чайкалып утырганнан соң манара, соңгы тапкыр үзәк өзгеч тавыш чыгарып ыңгырашып алды да, авыр гөрселдәп, мәчет бакчасына барып төште. Кояшны тузанмы, болытмы каплады, манара төшкән урынга халык бармады, авыр гына таралыштылар.

Авылның яме китте. Соңгы елларда, мәчетне мәктәп иткәннән соң, манара, бичара, гел яңа тормышка ярдәм итә иде. Монда еш кына күтәрелеп, күрше авыллан күренгән төтенне күзәтәләр, шуннан ук кычкырып: «Фәлән авыл яна, тизрәк насослы арбаларны җигегез»,— дип хәбәр салалар, юл өзегендә Ташлытау юлындагы атларны күзәтеп-көтеп алалар, бәйрәм көннәрне кырыйлары ука белән чигелгән флаг эләләр иде. Манара — авылның хуҗасы, күрке иде. Дингә каршы көрәшәбез дип авыл халкының сәнгать әсәрен юк итүне вәхшилек дип атамыйча, нишлисең?

Ул көнне Җәмил мәктәпкә килмәде: аны, нииндидер бер узгынчыга ияреп, авылдан чыгып качкан дип сөйләделәр. Күнелсез көннәр китте: ул арада кыш керде, коточкыч салкыннарда бакчадагы алмагачлар шартлап ярылды, өй астында бәрәңге өшеде, ач бүреләр төнлә, салам

түбәле абзарларны тишеп, сарык буып йөрделәр, акфиннар белән сугыш башланды.

Безнең сабый көннәргә бер генә көн дә шатлык китермәде. Балалык вакытының очы югалды. Без, нәкъ Җәмил җырындагы кебек, югалып калдык.

Җәмил дигәннән...

Аның үзен һәм җыр сүзләрен мин ярты гасыр узгач таптым. Моңа әле дә булса ышанып бетә алмыйм, ләкин бу — шулай, бу — чыннан да хак.

1986 елның кышы. Муса Җәлилнең тууына 80 ел тулуга багышланган фәнни-теоретик конференция бара. Конференциягә илебезнең зур галимнәре килгән. Шунда тәнәфес вакытында минем янга галим Әбрар Кәримуллин килде дә кесәмә бер кәгазь тыгып китте. Эре тешләренең бөтен булганы белән елмая иде. Кәгазьне ачып укыдым: «Бүген кич минем өйдә бик кызыклы бер мәҗлес була, килми калма» дип, адресын, сәгать-минутын күрсәткән иде. Кичен, әлбәттә, зур кызыксыну белән шунда киттем. Дөресен әйтим, ирләр генә булган мәҗлесне бик яратам мин. Ата-бабалар мәҗлестә шулай аерым утырганнар. Бу — һич тә артталыктан, «татарлыктан» түгел, бу — киресенчә, бабаларыбызның американча эшлекле булуларыннан килгән. Йә инде, хатын-кызлы мәҗлестә эш турында, дөньяны алып бару турында нәрсә сөйләшеп була? Анда бит тәкәллеф сакларга кирәк. Кем янында кем утырасы, салатны башта үзең салып аласымы, әллә яныңдагы үз хатыныңа алып бирәсеме, әллә каршыңдагы тол хатынгамы? Аңа алдан алып бирсәң, үз хатының нәрсә әйтер, кинәт кенә кара коелса, нишләрсең? Бер өйгә кайтасы бар бит! Хуҗа хатынга мактау сүзе әйтергәме, юкмы? Җиткән кызларының кайда кем булып эшләве белән кызыксынсаң, килешеп бетәрме? (Ә хатының өйгә кайткач, «Нәрсәгә, авызыңны җырып, шул... белән сөйләшкән буласың?!» дип зилзилә куптарса?)

Шулай, Әбрар Кәримуллин бабайлар акылын эшкә җиккән. Үз хатыны да үрелеп кенә, ризыкны ишек аргыннан биргәләп торды. Сүз кызды, галстукларны салып диванга ыргыттык, монда барысы да диярлек галимнәр, фән докторлары иде. Мин докторлар белән утырырга яратам. Аларда бер сыйфат була: наданмы ул (докторлар арасында алар байтак), гыйлемлеме — сөйләшкәндә алар ышаныч белән, җирдә үз урыннарын нык тоеп сөйләшәләр. Мин аларның шул сыйфатларына сокланам, кызыгып, матур итеп көнләшеп сокланам.

Бу юлы мәҗлеснең игътибар үзәгендә Дагстаннан килгән кумык галиме Солтанморат Акбиев иде. Тау халыкларына хас булганча таза борынлы, нык маңгайлы Солтанморат фән өлкәсендә дә үзен шулай тау кыясы кебек нык сизә. Ул, менә ничә еллар инде, татар-кумык әдәбиятларының элемтәсен, бу өлкәдәге тарихи традицияләрне өйрәнә, бу турыда эшлекле-игелекле мәкаләләр яза, китаплар чыгара. Сөйләшә торгач, Солтанморатка мин бер сорау бирдем:

— Безнең әдәбиятка, безнең халыкка шундый җылы мөнәсәбәтнең башы кайда? Син ничек бу юлга кердең? — дидем.

Акбиев уйга калды. Ярым татарча, ярым кумыкча сөйләп китте. Белмим, башкалар ул сөйләгәндә ниләр кичергәндер, әмма мин колакларыма ышанмыйча утырдым.

— Сугыш вакыты иде. Безнең авыл тимер юл разъезды янына урнашкан, биек тау итәгендә. Поезд таулар арасыннан чыгып безнең яннан узганда тау-таш чыңгылдап кала. Сугыш вакыты, әти — колхоз председателе, төн уртасында гына өйгә кайта. Авыл көтүе белән колхоз көтүен бергә кушып йөртәләр, көтәргә чиратлап чыгабыз. Әти җәй буе көтүче таба алмыйча җәфаланды. Ләкин бер көнне әти соң гына кайтты, без әле йокыга китмәгән идек, аш янында әнигә сөйләп утырды: Шөкер аллага,— диде,— көтүче таптык. Иртәгәдән эшкә чыга». Әни көтүчене каян табуы белән кызыксынды. «Казан ягыннан, татар малае,—

диде эти.— Ачлыктан качып, өеннән чыгып киткән. Булмаган җире калмаган. Әле монда да пассажирскийның түбәсеннән тимер юл милициясе алгач кына туктап калган. Ашаттык, урнаштырдык. Бик булган егеткә ошый, унбиш яшьләр булыр...»

Иртәгесен төш вакытында, көтү тупланган чакта, авылның бөтен малае көтүче янында иде. Татар — ул нинди була икән? Татарның Тукае булган дип сөйлиләр иде. Менә без чын татарның үзен күрдек. Саргылт кашлы, сипкелле, таза куллы төп шикелле бер малай. Кулында үткен пәке. Юньләп сөйләшми. Әллә ни арада гына бер чыбыкның кабыгын кәпшә итеп салдырды да сыбызгы ясап бирде. Бер малайның бил каешын сорап алды да шуны бишкә ярып телде, күз ачып йомганчы бишле камчы үреп, шуны сапка утыртып та куйды. Кыскасы, безнең күңелләрне яулап алды бу. Икенче көнне дә шунда җыелдык. Ул безгә үзенең туган ягы, калын урманнары турында сөйли, тик анда ашарга гына юк, ди. «Бездә,— ди,— колхоз председателе җәй буе халыкка вәгъдә бирә, хезмәт көненә өч килодан да ким бүлмибез, ди, ә көз җиткәч, бер грамм да бирмиләр. Менә ничә ел инде шулай...»

Без, аны кызганып, һәр көн өебездән нәрсә дә булса алып килә идек: йә алма, йә слива, йә кипкән балык. Ә бер көнне безгә ул татарча җырлап күрсәтте.

Солтанморат елмайды:

— Менә шул малай, шул җыр аркасында мин сезнең халыкка гашыйк булдым. Мин сезнең соравыгызга җавап бирдем кебек.

— Теге малайның өйрәткән җыры нинди иде соң? Хәтереңдә калмаганмы?

— Җыр гына түгел, ул малай өйрәткәннәрнең барысы да хәтердә. Ул карта уйнарга бик оста иде, гәзит кәгазен турап, шәмәхә кара белән сурәтләр ясап, барыбыз да картага өйрәндек. Моның өчен этидән эләкте эләгүен, ләкин татар малае безне авызга бармак тыгып сызгырырга, теш арасыннан чертләтеп төкерергә өйрәтте, «кәҗә мае чыгару» дигән уенга өйрәтте, тагын әллә нәрсәләргә. Бервакыт ул инде безнең агаманга әйләнде, аның сүзе безнең өчен закон була иде.

— Нинди җыр өйрәтте соң ул сезгә? — минем ерак Дагстанга барып җиткән татар җырын ишетәсем килә иде.

— Ә... ул болай.— Солтанморат күзләрен йомды, таза маңгаен учлары белән каплады. Ишетелер-ишетелмәс нәрсәдер көйләде, ритмга керде, селкенә башлады һәм, кулларын маңгаеннан алып, кискен хәрәкәтләр ясап, кинәт кенә җырлап җибәрде.

Агыйдел өстендә ак парахут,
Озаталар мине на Дальни Восток.
И-их! Югалдым мин, егет,
Калтырый куллар.
Үтәдер айлар, үтәдер еллар...

Мин тынсыз калдым. Ярты гасырдан соң бу җыр белән кабат очрашу бик гаҗәп иде. Солтанморат исә ритмга тәмам кергән иде инде.

Өебезгә кайттым, капканы ачтым,
Ишекне мин ярдым, тәрәзне ваттым.
Их! Югалдым мин, егет...

Мин ашыга-ашыга салфетка кәгазенә бу җырны яздым. Җыр тексты докторларны да әсәрткән иде.

— Ни исемле иде соң ул малай, анысын хәтерләмисеңме? — дип сорады арадан берәү.

Солтанморатның күзләре тау бөркетенеке кебек елтырап алды:

— Ник хәтерләмәскә! Мәңге онытмыйбыз без аны. Аның исеме Җәмил иде. Әйе, Җәмил. Сугыш беткән елны китеп барды. Бөтен авыл сагынып сөйли аны. Ул бик гадел иде. Бер генә малайга да

тырнак белән дә чиртмәде. Күпме җыр белә иде! Бөтенебезне чиратлап җырлата, өйрәтә, дөресли иде. Менә минем татар халкы белән беренче танышуым шул,— дип, Акбиев сүзен тәмамлады.

Мәҗлестән таралганда бөтенләй чуалган, саташкан кеше мин идем. Җәмил! Син исәнмени, ту анкай? Кайларда йөрисең син югалып? Син эшкә бик булган егет идең бит! Синең жаның чиста, пакь күңелең җәрәхәтле иде. Кайларда югалып йөрисең син? Син бит гаделлек, тамак туйдырырлык ризык эзләп киткән идең. Син бит авылда бара торган хәлләргә түзеп тора алмыйча чыгып киттең. Синең күз алдында ачлыктан атлар кырылды, авыл житәкчеләре, колхозчының тамагын туйдыруның төп мәсьәлә икәнен онытып, гел җыелыш җыйдылар, динне, мулланы сүктеләр, мәчет манарасын кистеләр, авылның хуҗалыгын тәмам китереп терәделәр. Син бит шундый рухсыз, имгәтелгән авылны ташлап киттең. Без ул чакта күңелләребез белән сизә идек, болар — вакытлы адашулар, болар — акыл житмәүдән. Алда безне сыный торган әллә ниләр булыр әле дип, шик катыш көтә идек без. Һәм безнең сабый күңелләр ялгышмады: безне кырык беренче елның июне айнытты...

Рәхмәт сиңа, Акбиев, син миңа яшьлегемнең сракта күмелеп калган бер кисәген кайтардың, өстеннән пәрдә ачып бирдең. Рәхмәт сиңа, Кәримуллин, син бик матур, галим докторлар мәҗлесе оештыргансың бүген...

## V

*Чыпчыклар — бөртеклеләрнең явыз дошманнары; агуланган җим куеп, алар белән көрәш алып барыла.*

Зур Сов. Энц. 5 нче том, 1971, 359 бит

Халкыбызның җырларын тикшереп карасаң, аларда — искитәрлек фәлсәфә һәм табигать белән бердәмлек. Ата-бабаларыбыз беркайчан да үзләрен табигатьтән аерып куймаганнар. Алар терлек-туар, күбәләкләр белән киңәшеп, серләшеп, кайгы-шатлык уртаклашып, эвәрә килеп яшәгәннәр. Бу инде — рухи тормышның бөтенлеге.

Ата-баба сандугач, карлыгач, күке, тургай, кыр казы белән серләшеп гомер кичергән. Бу кошларның һәрберсе кеше күңеленә үзенчә тәэсир иткән, кеше күңеленең аерым халәтенә аерым кош булган. Йә, нинди урман инде ул — карт юкә башында бәрәңге тукмагы кебек тып-тын гына утырган ябалагы булмаса? Май аенда урманга керүнең ни яме бар, әгәр анда вакыт-вакыт күке кычкырып синең гомереңне санап алмаса? (Бер күке кычкырган вакытта икенчесе катышмый, ялгышып катышса — шундук төзәтәләр. Безгә гыйбрәт!) Нинди ужым басуы инде ул — ук булып ыргылып, күккә күтәрелеп тургай сайрамаса, нинди кыр инде ул — биектә-биектә тилгән тибрәлмәсә?

Авыл халкы шулар белән бай. Кошлар аның рухи дөньясына шулкадәр сеңгән, җәйге җылы кичләрдә куркыныч кара кулъяулык булып очып йөргән ярканат та аның күңелендәге кош булган. Кырыгынчы елларда агач материалы табу бик кыенлашкач (урман әле калын иде, ләкин диаметры үндүрт сатиметр булган агач киссәң, прокурордан, судлардан башың чыкмый иде), авылда урыс капка аз калды. Әмма, бер дә шиксез инде, аларның түбәсендә эчтә, ярканатлар яши иде. Җәйге караңгы кичләрдә дәһшәтле чыпылдап синең колак төбеннән генә ярканат очып уза, төннәрен эсселе-суыклы булып кала. Халыктан килгән ышану бар: аның канаты яңагыңа кагылса, һичшиксез, чукрак каласың.

Хәзер, тилгәннәр, тургайлар белән бергә, ярканатлар да беткән икән. Әллә нинди парадокслар бар: урман бетеп бара, ләкин авылда урыс капкасыз кеше юк хәзер. Аны шундый итеп эшлиләр, әйтерсең

ул — бер нгытма. Урыс капкасы булмаган хуҗалыкның дәрәҗәсе бик түбән. Безнең халык шулай, шәп итеп, күзгә бәреп яшәргә ярата. Тик... ул капка башларында ярканатлар гына юк инде. Кара син аларны, фәнни-техник революцияне аңлаганнар, каядыр таю ягын караганнар. Хәзер әлеге шәп капкаларда алар кереп йөрер өчен түбә кыегында тишек тә калдырмыйлар икән...

Татар халык иҗатын өйрәнгәндә мин, халык җырларында бик еш телгә алынган кәккүк, сандугач, карлыгач «образлары» белән шөгыльләнеп, кечкенә бер фәнни хезмәт тә язган идем. Хәзер үкенеп куям: нигә җырда телгә алынганнары турында гына язганмын? Халык күңелендә безнең тирәдәге кошларның барысы да урын алган бит! Алар әкиятләрдә, мәкаль-әйтемнәрдә, йола-юрауларда, кушаматларда яшәгән бит. Димәк, нинди дә уртаклыгыбыз бар алар белән безнең. Нинди? Нинди? Баксаң, кошлар да нәкъ кешеләр кебек икән. Алар да юньлеләргә, юньсезләргә, тәртипле-әдәплеләргә һәм әдәпсезләргә бүленеп яши икән. Кешеләрдәге, гаилә мөнәсәбәтләрендәге, хезмәт бүленешендәге бөтен уңай һәм тискәре яклар аларда да бар икән. Безнең белән бик тә якын яшәгәнлектән, без аларны бөтенләй күзәтмибез икән.

...Авыл язы. Мартның унбише. Күк тулы кояш, авыл урамындагы бульдозер өйгән кар диварлар хәлсезләнеп калган, юлда юка боз элпәләре тирләгән, биек зәңгәр күктә яз шавы. Шундый көнне абзар түбәсендә кечкенә малай ясап куйган уенчык җил тегермәне дә келдерәп әйләнеп утырса, җилсез күктә агач башлары да шауласа — яз шул инде, шул инде.

Шулай язгы җилгә әсәрләнеп басып торганда агач башларында кинәт кошлар чыркылдаша башлады, тупыл ботаклары хәрәкәткә килде: әллә ниткән ыгы-зыгы бар иде. Ерак сәфәрдән әле генә кайткан сыерчыклар үз ояларыннан чыпчыкларны куалар икән. Сугыш бик көчле һәм тавышлы булды. Сыерчыклар (ахырдан белгәнчә, барысы да ата сыерчыклар икән), ЖЭКны да борчымадылар, депутатлар да эзләмәделәр, милиция дә чакырмадылар. Ата сыерчыкларның сугышу рәвешен карап тордым: кан чыгару, имгәтү юк, чыпчыкны оя тирәсеннән бары тик күкрәк белән генә бәреп төшерәләр. Үзләре тавышланмый, чыркылдау тавышы гел теге «тәртип бозучы» чыпчыклардан икән. Менә бер оядан кудылар чыпчыкны, менә икенче оядан, өченчедән. Тегесе нәрсә тагын? Анысы нинди оятсыз, ник бер әйтүгә чыкмый? Монысы өй түбәсенә куелган ояда иде, чыккач та, оя авызын бирмичә, озак тарткалашты. Ләкин монысын инде коллектив белән хәл иттеләр: әрсез чыпчыкны кара-корыч күкрәкләре белән шундый итеп тәгәрәтеп йөрттеләр, кош тырнакларыннан түбә шиферы чыр-чыр итеп торды. Аннан һәр йорт хуҗасы үз оясына юнәлде (оялар дүртәү иде), һәр хуҗа тиз генә оя эченә кереп чыкты да, оя өстенә кунып, томшыкны күккә юнәлтеп сайрый башлады.

Биш минутлык бу бәрелеш-җиңеш, тормышның әллә кай төшләрен актарып, хәтерне яңартты.

Беренче хатирә шул: күз чагылырлык якты язгы бер иртәдә ишегалдындагы, урамдагы халык шау итте: сыерчык килгән, сыерчык! Әй кешеләр, күрдегезме, сыерчык килгән! Авыл гөж килә. Халык — урамда. Яшь кызлар, киленнәр шунда ук карга ятып ауныйлар. Борынгы бабалардан килгән матур бер йола бу. Шунда аунаган кыз-кыркынның, киленнең җәйге урак вакытында биле авыртмый. Сыерчык килгән көн — авылда бәйрәм көне. Моның ни хикмәте бардыр, халык нигә моңа шатлана, кем белгән? Һәрхәлдә моның тирән мәгънәсе булмый калмагандыр...

Икенче хатирә:

...Йөз квартиралы йортыбызга күченгәндә төзүче оешмалар, кулыбызда ордер булуга карамастан, безне кертмәделәр. Янәсе, ордерлар

артык бирелгән, тезүчеләргә дигән ун процент истә тотылмаган. Йөк машинасы белән әйбер төяп килеп, урамда кунучылар булды. Апрель ае, көннәр җылы иде. Икенче көн житте, югары оешмаларга делегатлар китте, кемнәрнедер, «Кызыл билетыңны чыгарып салачаксың!» дип, телефон аша өркетүләр булды, әйбер төягән, бала-чага утырткан машиналар килә торды, подъезд янына куелган каравылчылар безне якын да җибәрмәделәр. Һәр подъездда бозау башы кадәр йозак һәм каравылчы иде. Икенче көн кичкә таба авышты, халык (интеллигенция) иза чикте. Төзелештән калган таш-тимер өстенә утырып кына өйлә ашын ашап алдык. Инде нишләргә? Арадан берәү табылды: ул, подвал тәрәзәсеннән аска төшкән дә, подъезд эченнән кереп, каравылчы абзыйларның берсенә ишек каккан. «Чыгар мине, мин монда бикләнеп калганмын»,— дигән. Абзый ачкан. Теге иптәш аны эчкә чакырган да, «Менә, агайне, кашың кара, күзең кара, үз җаеңны үзең кара, мин моннан чыгучы түгел, тик син дә кеше бул, менә бу стаканны яңа йортны котлап күтәреп җибәр»,— дигән. Абзый һәм күтәргән. Ыхы-мыхы килеп колбаса капкалаган арада, тагын бер стакан моның мыек астына ук terәлгән.

Ун минут үттеме икән? Подъезд каравылчылары нигәдер шул тәрәзәгә җыелып беттеләр: озак та үтмәде, бөтен подъезд ишекләре ачылды, ачкыч өләшү китте, каравылчыларның берсе инде бакча эчендә җан-фәрманга «По диким степям Забайкалья-а-а...» дип кәеф-сафа корып утыра иде...

Сыерчыклар чистарак эшли икән. Шулай уйлап куйдым. Оя өсләрендә алар томшыкларын сыердылар, карт өянке башында рәтсез-чиратсыз чыркылдап чыпчыклар тыпырчынды. Мин боларны да кеше теленә күчереп тыңладым.

Сыерчыклар сөйли:

— Мен, без дә Ватанга кайтып кердек. Без узган якларда дөньялар тыныч түгел. Без узган Урта диңгез өсләрендә, көпшәләрен ыржайтып, зур хәрби кораблар, самолет төягән зур аэродромнар йөзә. Товар төягән, кеше төягән көймәләр өстендә кунып ял итә идек, ә быел ял итә алмадык, чөнки су өстен корал баскан. Африка ярлары буенда куркыныч хәрби кораблар йөри, без юлга чыкканда гына самолетлар гарәп халкы өстенә бомба ташлады... Без, юлга чыгар алдыннан гына, үлем күрдек. Без Мәрмәр диңгез өстеннән уздык, анда су астыннан йөри торган куркыныч көймәләр күрдек. Без, ерак юллар узып, туган илебезгә кайттык, без хәтәр юлда вакытта исә мондагылар безнең яхшы фатирларыбызга кереп алганнар. Сугыш вакытында тылда калган кайбер намуссыз түрәләр шулай эшләгәннәр дип ишеткәнебез бар иде...

Чыпчыклар исә вак гайбәт эчендә чыпырдаштылар:

— Син башлап чыктың, син! Син чыкмасаң, мин ике аягымның берсен дә атламый идем!

— Ә үзең! Ә үзең! «Чык!» дип миңа кем чыркылдады?

— «Чык! Чык!» имеш! Чыктың инде, чыктың! Чык! Чык!

Ата чыпчыклар аскы ботакларда тыныч йомгак булып утырдылар, хатын-кыз әрләшенә катнашмадылар. Аларда шулай: алар тол хатыннарны да кайгырталар, безнең шикелле «Менә монысы — минеке, монысы — синеке, теге хатын — ирсез, үз көнен үзе күрсен» дигән бүленештән алар баш тартканнар, шуңа күрә хатыннар талашканда ирләр карап кына тора, «Хатын-кыз булдымы ке ле?» дигән сыман, әллә кем булып кукраеп утыра. Аннан соң монысын да белмиләр түгел: күп хатын белән яшәгәндә тормышта нинди рәт булсын. Әле аны, рәтне, бер хатын белән яшәгәндә дә булдыруы шактый кыен.

Ата чыпчыклар шулай уйлый иде, ахрысы.

Ләкин... ләкин... гадәттән тыш тирән, тарихи бер мәсьәлә бар. Кешеләрнең бит бөтен хатасы шунда: алар тарихтан гыйбрәт алмый-

лар, көндәлек тормышта, тарихны онытып, бик зур ялгыш җибәрәләр. Ата чыпчыклар, мәсәлән, йоннарын кабартып, күп санлы хатыннарына болай гына тәнбиһ ясап (кисәтү ясап), «тим! тим!» дип утырганда тарихны хәтерлиләр: Борынгы Чыңгыз ханнар, аннан соң килгән төрки ханнар, картаюдан куркып, организмның тонусын тиешле дәрәҗәдә тотар өчен, гомер ахырында гел ата чыпчык ите ашаганнар. Бу турыда китапларда язылган. Хәзерге кешеләр (ярый әле, безнең бәхеттән!) андый китапларны укымыйлар. Хәзер тонус күтәрер өчен Трускавецка, Ессентукига, Урал таулары астындагы тоз санаторийларына йөриләр. Йөрсеннәр! Профсоюз бай! Әнә кытайлылар... Безгә, чыпчык халкына каршы көрәш ачып карадылар. Янәсе, без орлык ашыйбыз. Чуртым да дөрес түгел! Без, беренче чиратта, орлык көшеләндәге нәкъ арыш, бодай, борча төсле курчакларны ашыйбыз, безгә дә ара-тирә итризыгы кирәк. Бездә, чыпчыкларда, сездәге кебек, гастрономнар юк, без үзебез эзләп тапсак кына...

— Тим-тим! Тим-тим!

— Чыпчыкларга каршы көрәш — дөньядагы иң пүчтәк көрәш!

— Чыпчыклар, нигездә, кешеләрнең дуслары. Чын! Чын! Шулай дим! Тим! Тим!

Ул арада ата сыерчыклар юкка чыкты. Юк, вәссәлам! Мин курка калдым. Теге рәтсезләр тагын фатирларга басып керсәләр? Әйтик, берәр ана чыпчыкның бик ашыгыч кына йомырка саласы булса? Йөкле, балалы хатынны урамга куып чыгарырга ярамый бит! Ләкин ата сыерчыклар бик нык кисәтеп киткәннәр, ахры: чамалагыз аны, әгәренки тагын бер мәртәбә... Шулай да, кая киткәннәр соң алар? Унбиш, егерме минутлар үтте. Менә урман ягыннан шатлыклы чырылдау белән бер төркем сыерчыклар кайтты. Аңлашылды, фатир әзерләп бетергәнче, йорт башлыклары хатыннарын урманда калдырып торганнар икән. Ә тегеләрен күрсәң! Каурыйлар — кара-зәңгәр корыч, күкрәкләр елтырап тора, гел диңгез арты киемнәрен генә киенгәннәр. Бала чыгарырга утырганчы гел шул «диңгез арты фирмаларында тегелгән кием» белән мактанып йөри инде алар. Ояга утырганда гына үзебезчә киемгә күчәләр. Ерак юлдан арып-таушалып кайткач, бу көе авылга кермибез, бераз ял итеп кеше төсенә керик, өс-башны рәтлик дип, атна буе урманда яшәгәннәр икән. Һәр хуҗа хатын тиз генә үз өен җыештыра башлады, әле салам, әле кыш кабып чыгып, оядагы чыпчык чүпләрен һавага очыртты. Әти сыерчыклар исә, кыска-кыска гына сайрап, оя түбәсендә утырдылар, өй җыештыру эшенә — хатын-кыз эшенә катнашмадылар; шулай кирәк, безнең ата-бабалар идән-сәке юмаганнар, аш пешермәгәннәр. Ирләр төп, мөһим мәсьәләләрне генә хәл итәргә тиеш. Авылда яз шулай башланды.

Ләкин яз сыерчыклар өчен генә түгел икән. Менә беркөнне карт алмагачның каты ботаклары арасында ике саескан тыркылдап ыгы-зыгы килде, нәрсәгәдер ярты көн буе бәхәсләштеләр. Бу бәхәстән беренче көнне берни дә аңлашылмады. Инде апрель кергән, җирдә кар бетеп килә иде. Талаш икенче көнне бераз тынган сыман булды, ләкин хәрәкәт кимемәде: алма ботаклары арасында өзлексез сөйләшү барды.

— Кра, кра-кра! Как, как, ца-тка!

— Тра-тра-тра! Ца-ца-ца!

Кичкә таба аңлашылды: ир белән хатын, быел өйне кайда салабыз, дип бәхәсләшкәннәр икән. Ир әйткән, урманга салыйк, дип; хатын каршы торган: сезнең караңгы урманыгызда минем матурлыгымны берәү дә күрми, шушы затлы киемнәрем белән минем якты дөньяда яшисем килә, авылга күчеп утырыйк, дип тавыш чыгарган. Бу — таныш хәл. Авыл егете дә кайчакта нәкъ шулай була: әйләнә-тирәдәге менә дигән бер гүзәлне ала, тормыш кора, әмма теге гүзәлнең авылда каласы килми. Анда шул ук кешеләр инде: Әхмәтхандыр, Нургалидер, Мәхмүттер. Кайсы шофер,

кайсы тракторист. Үз хатыныннан башканы белмиләр, сиңа ник кенә бер матур, мәгънәле сүз әйтсеннәр! Әнә, ичмасам, шәһәрдә, бер генә көнгә барып кайтасың, трамвайда очраган, дипломат, портфель тоткан ирләр бер дә белмәгән көе нинди генә матур сүзләр әйтеп бетермиләр, каушаудан башларың әйләнә. Авылыннан кузгатып, сыерын, йорт-җирен саттырып, зур шәһәргә алып китә ул үзенең ирен.

Монда да шулай булды: ата саескан көне буе каршы килде, авыл жирендә төзү әйберләре бик кыйбат, аны табып та булмый, урманда әнә бушлай, тулып ята, диде. Ләкин гаилә бәхәсе шуның өчен бәхәс дип атала инде ул: анда, һичшиксез, хатын җиңеп чыга.

Апрель ае беткәнче төзү материалы эзләү, йорт салу эше барды. Ата кеше бик ыңгырашып эшләде, чыннан да, якында гына материал юк иде. Үзенең бу көнгә калуына, күрәсең, бик нык хурлана, әмма, тешен кысып түзә иде:

— Ну, ярар, синеңчә булсын. Ну, бирермен әле мин, күрсәтермен...

Йорт житлегеп бетмәстән үк, ана саескан авырайды. Әле аска балчык, ләм ташыйсы бар иде, ләкин табигать законнары ашыктырды. Әни кеше, көн аралаш утыргалап, йомырка сала башлады. Ябыгып, ямьсезләнеп китте, менә, көннәрдән бер көнне, йомырка салган жиреннән утырып та калды. Әти кешенең әле төзү эше бетмәгән иде, холкы тагы да начарланды, үзен тәмам күрсәтеп бетерде. Тупыл башындагы сыерчыкларны куып йөрде, ризык табып кайткан чәүкә, каргаларның юлларына төште, бу дөнья миңа гына дигән сыман, бөтен кош-кортка юл бикләде. Нәкъ кешеләрдәгечә инде, кешеләр арасында да шундыйлар очрый бит: барысы да — акча да, абруй-дәрәҗә дә, иң яхшы фатир да аңа гына булсын, күккәкә тага торган билгеләр дә бары тик аңа гына булсын! Дөнья миңа гына, миңа гына, дип яшиләр андыйлар. Без яшь чакта авылда шундый бер жыр бар иде (ахыры гына хәтердә калган):

Кояш булсаң, кеше өстенә
Чыкмас идең, паразит!

Кайбер кешеләрдәге тар күңеллелек саесканнардан килә икән. Бу — минем өчен ачыш иде.

Бераздан кар явып китте, салкын жилләр исте. Халык моны «сука суыгы» дип йөртә. Табигатьнең үзенчә яшәү рәвеше бу. Ягъни кинәт җылытып язны житкерә, жирне чыгара. Кышлаган бик күп кортлар, жир жылынуга терелеп, өскә, яфракка үрмәлиләр, яши башлыйлар. Һәм — көтмәгәндә генә — салкын. Корткычлардан жир әнә шулай үзен-үзе арындыра. Чыбык-чабыклы җилле ояда тын да алмыйча утырган ана саескан кызганыч иде. Житмәсә, соңгы көннәрдә бөтенләй урыныннан кузгалмый башлады. Димәк, вакыты житә. Менә шул чакта теге явыз үзен күрсәтте дә инде! Азмыни хатыны бала тудыру йортында ятканда «ужымга чыгып» алучылар! Азгын ирләр өчен иң уңай вакыт инде ул, хатын кинәт кайтып кермәячәк. Монысы хак! Безнең ата саескан да, урманга китеп-сүтеп йөри торгач, бер ялгыз, яшь чибәр саесканга иялә нде. Үзенең гаилә бурычын үтәп хәл белергә килгәндә дә шул сөяркәсен ияртә, әмма аны йорт артындагы сарай түбәсендә калдырып тора. Хатыны янына килеп, иренеп кенә сөйләшә:

— Йә, кайчан чыга инде балалар? Тка, тка, тка...

Тегесе авыр эндәшә, аның инде температурасы күтәрелгән,ябыккан, йончыган. Фу, шайтан, авызлары зурайган, күзләре тонган.

... Дөрес, ир хатыны буларак тегесе — сөяркә-саесканы да әллә кем түгел иде. Күзе гел читтә булды, ояда гаилә җылылыгы юк иде. Ата саескан исә характерга йомшак булып чыкты, мәхәббәт юклыгын белде дә, озак баш ватмыйча, урман артындагы бер поселокка юл салды. Поселокта спирт заводы бар иде, завод артындагы чүплеккә исә канаудан ниндидер сыеклык саркып чыга, ул сыеклык өстенә кешеләр азык-төлек калдыкларын чыгарып түгәләр, ә теге хәтәр сыеклык ул калдыкка сеңә...

Шулай, гаилә таркалды. Шайтан, баштарак кадерен белсәң, әйбәт

кенә егет иде, тормыш итәргә була иде. Ә монысы? Юк, хатынын ташламаячак бу. Бу мине болай гына файдалана.

Сөяркә-саескан, эче пошып, сарай түбәсендә тырнак тавышы чыгарып йөренгәләде. Тегене борчыды. Тегесе исә нервлана, оя янынннан алай ук тиз китә алмый. Йә, нигә аз гына мөмкинлек бирми инде? И-и-и... Үз иренең кадерен белмәгән хатын сөяркә кадерен беләмени ул?

— Йә, ярый, мин киттем. Срок буенча синең иртәгә чыга башларга тиеш. Ца, ца, тка... — шулай өй артындагы сарайга оча да, яшь, елтыр сөяркәсен ияртеп, иркен урманга кача. (Үзе уйлый: сөяркәләр, табигый инде, эгоист була. Ул инде синең никахлы хатыныңна ярата да, аны кайгырта да алмый).

Берничә көннән оя кырыенда иләмсез озын томшыклы, кызыл эчле авызлар күренде, нәкъ өчәү иде. Декрет ялының икенче яртысы — бала тәрбияләү башланды. Монысына инде теге эгоист та катнашты. Күрше-тирәдәге бөтен халык саесканнардан зарланды: шулар аркасында быел карлыгачлар да күренмәде, диделәр. Мин дә катгый карарга килдем: ана саесканның тиешле ялы бетеп, балаларын ияртеп урамга таба очуы булды, сәнәк алып, теге ояны туздырдым. Оя каты чыбыкларны бер-берсенә аралаштырып, бутап, беркетеп ясалган иде, тиз генә сүтелмәде. Шулай да корыч сәнәккә чыдамады, биреште. Җиргә төшкән оя төбендә бер пәке һәм арзанлы гына кул сәгате дә күренгәч, мин гаҗәпкә калдым. Кайбер галимнәр шулай бит! Кеше табышын урлый-урлый «фән» ясыйлар, кайберсе — яшь, исемсез галимнекен, кайберсе — үзенең аспирантының, студентының табышын урлый. Димәк, саесканнар белән кардәш алар.

Сүткән ояны, йортсыз калган саесканнарны мин кызганмадым. Бу турыда халыкта бик мәгънәле мәкаль бар: «Киеменә карап каршылыйлар, акылына карап озаталар».

Юк, гаилә башлыгы буларак шәп кеше түгел иде саескан. Киемнәре шәп булгач (ак нейлон күлмәк, кара фрак — нәкъ менә халык артисты, мәшһүр дирижер инде), мин аны юньле заттыр дип уйлаган идем.

Ире — хатыны ялда вакытта типтереп йөрсен, хатыны — ире урлаганны йортта сыйдырып барсын, ул гаилә юньле буламыни? Аның бит балалары да шуны күреп үсә.

Безнең күрше Исламгали агай мең кат хаклы: саесканны бакчадагы агачына түгел, күрше-тирәнең абзар өстенә дә кундырмый — шундук тавыш чыгара, таш ыргыта, каргана башлый:

— Саескан такылдаганы фашист автоматын исемә төшерә,— ди ул.— Йөрәгемә ярамый шул тавыш. Болай да, төннәрен шул тавышны ишетеп, саташып уянам.

Саескан вакыйгасы мине кошлар дөньясына тирәннәнрәк карарга өйрәтте. Һәм мин бер нәтиҗәгә килдем: кошларда бер генә очраклы хәрәкәт тә, бер генә кирәксез аваз да булмый. Һәр кошның үз-үзен тотышында билгеле бер максат бар. Дөрес, без моны инстинкт дип атыйбыз, тереклек дөньясындагы кайбер катлаулы күренешләрне маймыллар, еланнар, дельфиннар, әрләннәр, китлар, ат һәм эт белән мәчегә генә кайтарып калдырабыз. Янәсе, болар — катлаулырак организм. Менә әтәч — бүген иртәдән бирле бер тавыкны талый, табак яныннан куа. Хуҗа хатын тегеләй сүгеп карый әтәчне, болай сүгә, тибеп тә җибәрә, ләкин әтәч теге тавыкка үчегепме-үчегә. Аптырагач, төнгә теге тавыкны аерым яптылар. Янәсе, онытсын бүгенге хәлләрне. Юк, иртәгесен кунакчадан төшүгә, канатларын, бугазын да көйләп тормастан, әтәч тагын теге бәхетсезне талый башлады. Чирәм арасында аңын югалтып, ыңгырашып яткан тавыкны алып карасалар — теге тавыкның бер күзе сукырайган, бер аягы шешеп маташа икән. Алай-й... Димәк, элек, таза вакытта — яраган, хәзер — чирләгәч — ярамый? Карале, минем таныш бер ирне сөйләгәннәр иде: авырып киткән хатынын ике баласы белән аерып җибәргән дә, үзе яшь, тазаны алып кайткан. Сукыр тавык та, бичара, эгоизм корбаны булды.

...Җәй шулай үзды. Кышын мин һаман да язу өстәле янына утыра

алмадым. Күңел бушлыгы сизелде. Кошлар белән шулай аңлашып яшәү ярыйсы булган икән әле. Әмма табигать монда да миңа ярдәмгә килде. Каты суыклар башлануга, ярдәм сорап, урманнан шәһәргә песнәкләр килде. Килгәннең беренче көнне үк болар йортның тәрәзәләрен шакып чыктылар.

— Әй, сез, иптәшләр-әфәнделәр, термометрга карагыз: утыз сигез градус салкын. Мондый температура моннан йөз унбиш ел элек... фәләнтөгән,— диешәләр. Нәкъ Казан радиотапшыруларының дикторы инде.

— Безгә суык вакытта азык белән бераз ярдәм итегез,— диделәр.

Миңа эш табылды. Кибеткә йөгердем, дуңгыз мае сатып алдым да, җеп белән бәйләп, тәрәзә калаена төшердем. Беренче көнне үк «разведкага» килеп, карап, чукып киттеләр. Сизеп торам, ошатмадылар. Икенче көнне иртән сыер ите кисәге бирдем. Майсыз җирен. Монысының да тикшереп кенә китүе булгандыр инде: бик чиста сары-яшькелт атлас күлмәктән, пөхтә жилеткадан иде, кабып караган сыман итте дә китеп барды, ул көнне башкача килүче булмады. Куйган ризыкны нигә ошатмадылар икән? Кинәт минем исемә төште: кышкы каты суыкларда бит әни аларның, ниндидер юллар табып, өйалдына кереп, элеп куйган каз түшкәләрен яратып чукулары турында әйтә иде. Һәм безгә алып кереп күрсәтә иде: песнәкләр бик чиста итеп, әдәп белән генә, каз түшкәсенең тиресен чукыйлар. Күрәсең, анда ит тә бар, май да бар. Кичтән мин, җепкә асып, каз ите төшердем. Иртән, тәрәзә пәрдәсен ачмаган көе генә, ярыктан карыйм: аксыл алтын булып ялтырап, тәрәзә калаенда каз түшкәсе кисәге ята, ләкин әле аны авыз итүче булмаган. Пәрдәне, форточканы ачтым да гантельләремне күтәрдем. Бер тапкыр күтәреп төшерүгә, ит янына ялт итеп песнәк килеп утырды. Елтыр бөртек күзе белән миңа яннан караш ташлады, сул тәпие белән ит кисәгенә басып, тәмләп чукырга тотынды. Күпмедер чукыгач, туктап калды. Шулчак икенче берсе килеп утырды, беренче песнәк очып китте. Аннан — өченчесе, дүртенчесе. Берничә көн күзәтүләрдән соң мин песнәкләрнең ашау-эчү, үзара мөнәсәбәт мәсьәләләре бөтен бер системага корылып, аерым кагыйдәләргә буйсынган булуын төшендем.

Иң беренчесе шул — песнәкләр, бу азыкның үзләренә махсус куелганлыгын белеп алгач, хуҗага ихтирам йөзеннән, пәрдә ачылгач кына, хуҗаны күргәч кенә тәрәзә янына очып киләләр икән. Шуны көтеп, алар каршы йортның балкон киштәсендә тезелеп утыралар икән. Без — карак түгел, без — намуслы, димәкчеләр.

Икенчесе — боларның кагыйдәсе буенча, өч тапкыр чукыгач карап аласы: форточкадан мәче сикермәсен, күрше балконда ябалак саклап тормасын. Шуңа күрә тәрәзә калаендагы тавыш монда бер ритм тудыра: тек-тек-тек, тек-тек-тек. Әнә шулай дүрт яки биш цикл (алты түгел) текелдәп алгач, алмаш килеп төшә. Урын бернинди бәхәссез тапшырыла. Монда бернинди тәртип бозу юк. Казан егетләренең нәкъ Төмәнгә йөреп вахта алмаштырулары инде. Төп-төгәл...

Тагын бер сыйфат: һич тә беткәнче ашыйсы түгел, ә иртәнге аш вакытында бер кат тамак ялгап алгач, туктыйсы. Көндез, көн авышкач, тагын бер тапкыр шундый «визит». Кичке якта, гадәттә, алар күренми.

Вәт, менә безгә — кешеләргә ашау турысында үз-үзеңне тотарга кемнәрдән өйрәнергә! Югыйсә, өстәл артында үзен начар тотучылар очрап кына тора бит. Бу — һич тә белемгә, дәрәҗәгә карамый. Ата-анасы оясында бирелгән тәрбиягә карый ул. Шул тәрбияне алмаган бәндә өстәл янында лач-лоч китереп комагайланып ашый, кеше алдындагысын тартып ала, кеше ризыгы өстеннән кул йөртә, авызыннан шулпа агыза, голдырдап кикерә, теш казый, авызын ачып иснәп куя, үкереп үк исни. И-и-х, мондый кешене песнәкләр янына тәрбия сәгатенә җибәрергә! Һич югы — ике генә атнага!

Көннәр җылытуга, песнәкләр юкка чыкты. Элеп куйган ит язга кадәр торды, алар башкача күренмәделәр. Кышкы салкын иртәләрдә, томанлы-бәсле көннәрдә алар миңа рухи юлдаш, сердәш булдылар, тәртип, әдәплә-

ре белән минем күңелдә матур истәлек калдырып китеп бардылар.

Ләкин бу җылыту — адаштыргыч җылы гына булып чыкты — бер көн иртән, кинәт суытып, утыз градусны бирде. Һәм ни шатлык — тәрәзә төбенә таныш песнәкләр килде. Бу юлы — янача. Берничәсе берьюлы килеп утырдылар, әллә ни ашамадылар да, шаярышкан булып, калай өстендә теке-теке йөрделәр, төш вакытында дәррәү күтәрелеп очып киттеләр. Шуннан соң инде бөтенләй күренмәделәр. Бу — аларның миңа рәхмәт әйтергә килүләре булган икән. Рәхмәтегезгә рәхмәт төшкере!

... Минем юка гына, ләкин үзем өчен бик кадерле китабым чыккан көннәр иде ул. Егермеләп кешегә почта аша салдым, кәнәфиле кешеләрнең алгы бүлмәләрендәге секретарьшаларына калдырып чыгып киттем. Гаҗәп, безнең татар түрә булса — иң беренче эш итеп, кешегә рәхмәт әйтмәскә өйрәнә. Бәләкәй генә креслосы булган кешеләрнең берсе дә миңа рәхмәт әйтмәде. Минем өчен бу яңалык түгел иде. Мин моңа күнгән инде. Безнең интеллигенция шулай, анда песнәк тәрбиясе дә юк... Тик мин ялгышканмын: нигә әле халыкта «милләтнең каймагы» булмый калсын? Халыкның культурасы кайчан әле «кресло»лар белән үлчәнгәне бар? Атна эчендә миңа әллә никадәр шатлык килде: эшкә киләм, эш урынымда — автографлы калын китап. Кечкенә бүлэгемә җавап итеп, рәхмәт сүзләрен язып, академик Мирза Мәхмүтов үз китабын калдырган. Икенче көнне эшкә киләм, әйтәләр: «Профессор Рәфыйк Нәфиков сине бик озак эзләде, таба алмагач, миңа бу китабын калдырды»,— диләр. Карыйм, калын китабына рәхмәт сүзләре белән автограф язылган. Өйгә кайтам — берьюлы ике хат. Шамовтан: «Хөрмәтле туган, китабыңны бик җентекләп, яратып укып чыктым, рәхмәт... Афзал абыең». «Укыдым. Сокланып. Рәхәтләнеп. Кайбер галимнәрнең коры сүздән торган калын монографияләрен укып тәмам тын кысылып беткән булган. Сезнекен яратып, бер тында укыдым. Сулыш юлларым ачылып китте. Рәхмәт. С. Хәким».

Юк, мин ялгышканмын, халыкның культурасын тегеләр түгел, ә менә болар — кеше күңеле булудан курыкмыйча, кешегә рәхмәт әйтә белүчеләр билгели.

... Менә яз килде. Балкондагы кар бер көн эчендә җебеп тама башлады, балкон чистарту дигән яз мәшәкате туды. Китә башлагач кыш та кызганыч! Ул да кеше гомереннән нәрсәнедер алып китә, ниндидер мизгелләрне истәлеккә әйләндерә. Быелгы кыш шулай эшлексез узды, истәлеккә — нибары песнәкләр, йомшак яшькелт-сары йомгаклар, чистапөхтәләр. Алар белән яшәү күңеллерәк иде.

Ә бер көнне күктә кыр казлары тавышы ишетелде. Сихри аһәңле бу тавыш, яз һавасы белән бергә, форточкадан бәреп керде. Мин балконга ашыктым. Мәрхүм Мин Шабай әйткәнчә, күктән кыр казы исе килә иде. Шәһәрдә кыр казлары килгәнен ишетү, күрү — сирәк очрый торган бәхет. Трамвай, КамАЗ, КрАЗ, трактор тавышында кая инде кыр казлары тавышы ишетелсен? Әле ярый шәһәрнең өстеннән очалар диген, шунысы өчен рәхмәт. Минем исә бәхет басты! Авыл иске төште, йөрәк сулыгып-сулыгып алды. Һай, нинди зур бәйрәм — җан, рух бәйрәме була иде ул кыр казлары килгән көн!.. Алар килгәнне күргән беренче бала авыл өстенә шәрран ярып кычкыра, ул тавышны олылар эләктереп алалар, бөтен кеше, ишек-капкаларын ачып, урамга, абзар артындагы бакчага — кар өстенә күтәрелә, карт-коры, кулларын каш өстенә куеп, күзләрен күккә юнәлтә. Тамак төбенә төен утыра, күзләр яшьләнә. Өлкәнрәк кешеләр, казлардан күзне алмыйча гына (йола шулай), аяк астыннан салам иелеп ала (аны каз оясына салсаң — бәбкәләр мул һәм сәламәт булып чыга). Шул йола искә төшкәч, мин дә балконда әйбер иелеп ала яздым, тик аяк астымда сигезәр килолы гантельләр генә иде; балконны көрәгән көнне үк, иртәнге зарядканы мин шунда күчергән идем.

Күк йөзеннән, бәгырьне телгәләп, киек казлар тавышы ишетелә иде.

— Саумысыз, туганнар! — дип исәнләштем мин алар белән эчтән генә. — Саумысыз, агайнеләр? Ерак юллардан исән-сау кайтуыгыз белән

тәбрик итәм сезне! Минем күңелемне соңгы елда сагыш басты бит әле. Бәлки сез шуңа дәва булырсыз. Сез кайлардан уздыгыз? Ерак океаннар өстеннән узганда сез минем улым йөзгән корабны очратмадыгызмы? Ул да шул якларда, тропик суларда йөзә. Хатлар өч-дүрт айга берәр генә килә. Сез аны күрмәдегезме? Ул миңа яз сәламе җибәрмәдеме?

Сез, күктәгеләр, әллә нинди, серлеләр. Менә без җирдәге кошлар белән аңлашып, тәҗрибә уртаклашып яшибез. Ә сез өстән генә карап узасыз. Сез бәлки безнең бөтен кимчелекләребезне күреп йөрисездер, шуңа күрә безнең янга төшмисездер? Әллә сез, кайчандыр безнең белән бергә яшәп тә, безнең тәрбиясезлекләрне күреп, безне ташлап киттегезме?

Ләкин бит без дә гел кимчелекләрдән генә тормыйбыз. Безнең монда, җирдә, эшебез күп, безнең шушы җирне матурлыйсыбыз, шушы Җир-анабыз, Ватаныбыз турында җырлар чыгарасыбыз бар. Без — эшлексезләр түгел, Ватан безне хезмәт яратучан итеп тәрбияләде.

...Мин инде язу өстәле янына утырган идем.

Тәнкыйтьче. Болар турында ник яздың, инде язар нәрсәң беттемени?

Автор. Язар нәрсәм бетмәде, моңа исә Тукай сәбәп булды.

Тәнкыйтьче. Саесканнар, сыерчыкларга Тукайның ни катнашы бар? Ялгышмасам, Тукай күгәрчен, сандугач һәм карлыгач турында гына язган. Әле аның алары да тәрҗемә. Әнә «Карлыгач» дигән шигыре рус шагыйре Иван Никитиннан булып чыкты. Шуны исбатлап биргән өчен син бәхетсезне тукайчы галимнәр күпме кыйнады. «Тукайны талап бетерәсең бит, надан!» дип күпме-күпме сүктеләр...

Автор. Юк, ялгышасыз. Тукайның «Карга» дип исемләнгән шигыре дә бар.

Тәнкыйтьче. Нәрсә, бу бүлекне язарга шул шигырь сәбәпче булдымы?

Автор. Юк, башкасы. «Дин вә гавам» дигән шигыре.

Тәнкыйтьче (саф, бүгенге татар телендә). Причем монда дин?

Автор (шулай ук бүгенге татар телендә). Ә притом, анда бик кызыклы фикер әйтелгән. Хәзер мин аны сезгә укып күрсәтәм.

Тәнкыйтьче. Нәрсә, Тукай китабын кесәңдә йөртмисеңдер ич?

Автор. Мин Тукай шигырьләренең алтмыш процентын яттан беләм. Кайчакта кайбер сүзләрен бутыйм. Шулай ышанып язганда хаталар да киткәли.

Тәнкыйтьче. Гаҗәп! Тукай шигырьләрен яттан белгән бер генә галимне дә очратканым юк әле.

Автор. Мин бит галимнең чынысы түгел.

Тәнкыйтьче. Әдәбият өлкәсендә чын галим кем соң ул?

Автор. Әйтә алам: Җамал Вәлиди, Фатих Әмирхан, Галимҗан Ибраһимов, Галимҗан Нигъмәти, Гали Рәхим, Газиз Гобәйдуллин.

Тәнкыйтьче. Ә башкалар?

Автор. Алар — кандидат, доцент, профессорлар.

Тәнкыйтьче. Бу — яңа фикер түгел. Яшь бер язучының иң беренче повестенда бу турыда әйтелгән иде инде. Йә, ярар, тыңлап карыйк.

Автор (яттан укый).

Дин — хәзер иске, аварга торгучы чергән дивар,
Аз гына, уйнап кына бармак белән төртсәң — авар.
Билгеле, һәрбер агачлар да корырга башлыйлар,
Былбыл урнына оя тоткач башында каргалар!

Мин бу турыда күп уйландым. Тукай табигатьнең бу серле закончалыгын каян белгән? Башына карга оя коргач, мәсәлән, каеннар үлә. Өянке чыдый — каен үлә. Менә безнең яктагы кечкенә генә бер авыл гасырлар буена каен урманы эчендә, табигать кочагында яшәгән. Бер урам икенче урамны күрмәгән — авыл уртасында каен урманы. Менә

шунда, сиксәненче еллар башында, каргалар килеп оя корган. Халык моңа әйбер әйтмәгән. Әмма, ике-өч ел узуга, затлы каен урманы корып кара көйгән. Хәзер ул авыл дошман оккупациясеннән әле генә азат ителгән бәхетсез хуторны хәтерләтә. Корган каеннар күңел каралтып утыра. Ике җирдә туктап, ике карчыктан сорыйм:

— Бу каеннар ни өчен корыды?

Берсе әйтә:

— Карга каенның бөресен ашый. Бөреләнмәгәч, каен үсә алмый,— ди. Икенчесе:

— Оя ясаганда карга каенның иң очындагы нечкә, яшь чыбыкларын өзә. Очы үсмәгәч, каен корый,— дип җавап бирә.

Шәһәргә кайткач, биология фәннәре докторы булган бер профессордан сорыйм:

— Карга оялаган каен ник корый?

Профессор әйтә:

— Минем бу турыда уйлап караганым юк. Каен агачы — минем өлкә түгел, минеке — чыршылар, наратлар.

Вәт сиңа мәдрәсә белемле Тукай! Тәмам зиһенне чуалтып бетерде бит шул шигыре белән...

Бу бүлекне язарга, әнә шулай, Тукай сәбәпче булды.

## Бу бүлеккә сүз ахыры

Биология фәннәре докторы минем әлеге сорауны республиканың орнитологлары алдына куйган. Каен урманы каргалар оялагач ник корый? Мәдрәсә белемле Тукай нәрсәдән чыгып мондый нәтиҗәгә килгән?

Орнитологлар Тукай шигыренең тәрҗемәсен дә биргәннәр. Алар уйга калган. Әзерләнеп, махсус утырыш җыйганнар. Утырышның нәтиҗәсен миңа укып күрсәттеләр. Миңа ул нәтиҗә ошады, галимнәрчә фикер йөртелә иде, ләкин мин, нигәдер, бик үк канәгать калмадым. Анда болай диелгән:

а) каргаларның оя коруы агачларның һәлак булуына китерә алмый. Казанның К. Маркс урамындагы каеннарның башына ничә еллар инде карга оялый, агачларга исә моның зыяны сизелми;

б) Тукай шигырендә бу — поэтик метафора гына булырга мөмкин.

Дөрес, шулайдыр, шулайдыр. Ләкин бу хәлләрдә мин диалектик бер эзлеклелек, бәйләнеш күрәсем килә.

...Кар өстендә палас кагып яткан күршем янына килеп исәнләштем дә, боларның барысын да сөйләп бирдем. Аның зоолог түгел, ботаник икәнен белә идем. Шулай да, җавап көттем. Ә ул үзе миңа сорау бирде:

— Ул авыл тирәсендә су режимы үзгәрмәгәнме?

— Үзгәргән, бик үзгәргән,— дидем мин,— колхоз территориясендә нәкъ биш урында әкәмәт зур сулы буалар төзегәннәр.

— Менә, менә... Димәк, бу тирәдә су күтәрелгән һәм туфракның дымлылыгы арткан. Ә каен агачы дымлы урында үсә алмый, корый.

— Анысы шулайдыр да, ә каргалар?

— Карга — акыллы кош. Каен бит әле кинәт кенә корымый. Берике ел авырый. Авыру агачны корт баса. Сәламәтлеген югалткан каен исә бу корткычларга каршы көрәшә алмый. Агач корты — карганың яраткан азыгы. Карга ояны һәрвакыт азыкка якынрак урында кора. Димәк, бу очракта каенның коруына карга сәбәпче түгел.

— Ә Тукай?

— ...?

— Тукайны әйтәм. Ул моны белгәнме?

— Юк, ул игътибарлы күзәтүче булган. Димәк, ул яшәгән урыннар-

да да шундый хәлләр очрагаң: урман авырый башлый, аны корт баса, аннан инде карга оялый.

Акыллы кеше белән сөйләшү — җан рәхәте! Шул уңайдан мин күршемә чыпчыкларның авыл хуҗалыгына зарар салуы турында язылган, аларны агулы җим белән бетерергә өйрәткән энциклопедия хакында да әйттем. Бу турыда әле 1954 елда ук язылган икән — ул елларда андый шаукым дөньяда булып алган иде шул...

Сөйләшә торгач без мондый фикергә килдек: 1986 елның җәендә Татарстанда ашлык бик уңды. Гектарыннан утыз, кырык центнер алган хуҗалыклар күп булды. Колхоз ындырларында икмәк таулары ясалды. Бик күп колхоз, район җитәкчеләренең мул икмәкне планнан тыш тапшырасылары килде һәм, ашыга-ашыга, ул икмәкне колхозларның түбә ябылган ындыр табакларыннан заготзерно, элеватор ишегалларына — ачык күк астына ташып өйделәр. Өстән яңгыр ява торды, юеш ашлыкны кат-кат өйделәр. Колхозлардагы түбәле ындыр табаклары бушап калгач, районга ашыгыч рапорт бирделәр: «Без... фәлән тоннага арттырып тапшырдык». Аннан районнар рапорты китте: фәлән район фәлән процентка арттырып...

Ә көзге яңгыр исә туктыйсы итмәде — тишек иләктән аккан кебек, күк йөзеннән җиргә су коелды. Менә бер заман заготзерно, элеватор тирәләрен күмешкә исе басты. Ул тирәдән биткә җылы пар бәрә иде. Аңладылар: меңләгән-меңләгән тонна икмәк яна. Моңа бер чара күрергә кирәк иде. Һәм күрделәр: янар тауларны, экскаватор белән машиналарга төяп, ерак чокырларга ташып күмделәр.

Чыпчыклар, имеш, бөртекләләрнең явыз дошманы... Ну язалар да инде кабинет галимнәре кайчакта!..

## VI

*Исән булсам, бер кайтырмын*
*Язлар кебек әйләнеп.*

Х. Фәтхуллин

Утыз җиденче еллар кышындамы, авылга колхоз-совхоз театры дигән игелекле коллективлар килеп, әллә нинди хикмәтле пьесалар куеп, халык күңелен дер селкетеп киткәләделәр. Болардан берсе хәтта «Академия» дип тә аталган иде әле. «Академия килгән», «Бүген кич Сикертәндә академия була бит, колхоз идарәсе исемлек белән кертә икән!» кебек хәбәрләр ишетелә иде. (Ягъни, колхоз хисапчысы сиңа билет бирә, ә ел ахырында, хезмәт көнеңә тиешле икмәкне акчага әйләндереп, «академияң»не синең исеңә шундый итеп төшерәчәкләр!). Бу коллективлар шур чорда, хикмәтле әсәрләр белән килеп, халык күңелен селкетеп алдылар инде! Болар — Хәбибулла Фәтхуллинның «Күзләр» драмасы, Мөхәммәт Әблиевның «Шәмсекамәр»е, Фатих Хөснинең «Урманда»сы.

Бу спектакльләрдәге сүзләр, җырлар авыл өйләрендә озак яшәде. Алардан берсе — Шәмсекамәр җыры. Көе әле дә хәтердә. Бала тирбәткәндә җырлый Шәмсекамәр:

Сандугачым-былбылым,
Быел кайгылы елым;
Кайгырмас идем бу елда
Ятка кала былбылым.
  Әлли-бәлли итәрем...

Моны җырлап, кич утырганда елыйлар иде. Сугыш башлангач, Шәмсекамәр җыры онытылды. Хәер, сугыш башланырга бер-ике ел кала, сәхнәдә гел Тажи Гыйззәт әсәрләре генә иде инде. Элеккеге еллар сәхнәсеннән тик бер генә җыр, ничектер, сакланып калды. Ул — халыкка

билгесез автор Х. Фәтхуллин пьесасыннан иде. Халык аның Салих Сәйдәшев музыкасы икәнен бөтенләй башына да китерми, әмма шушы үзәк өзгеч бу моң яшәде һәм яши иде. Шундый концертлар бара сәхнәдә — клубка авыл халкы сыймый, бөтен программа сугыш, үлем, аерылышу турында, кан-яшь турында; шул арада берәр өлкән кеше, яраланып кайткан ир яки тол калган хатын сәхнәдәге концерт алып баручы кызга җаен табып кычкыра:

— Сеңелем, «Хуш, авылым»ны җырлагыз инде бер!

Сугыш чорының һәр концертында бу — шулай...

Дистәләрчә еллар үтте, ярты гасыр үтте — күпме-күпме модалы җырлар үлде, тик әлеге җыр калды. Сугыш һәм аннан соңгы елларда, без педучилищеда укыганда, һәр җомгада берәр класс чиратлап концерт бирә иде. «Хуш, авылым» җыры башкарылмаган концерт кичәсен мин хәтерләмим; кайсыдыр класста Балтач ягы Дорга авылыннан килеп укучы Нина Арыкова дигән бер кыз бар иде, бу җырны ул гына шулай җанына тиярлек итеп җырлый һәм без һәр концерт ахырында залда үзебезчә бер вак «скандал» чыгарып ала идек.

— Нина Арыкова чыксын!

— «Хуш, авылым»ны җырласын!

Нинаның (керәшен кызы) тавышы, менә бер дә арттыргысыз, көмеш иде; без шулай дип йөртәбез, безнең оркестр-фәлән күргән, тыңлаган юк, әмма дә ләкин көмеш телле тальян тавышын җиз телледән генә аера алабыз, анлык кына грамотабыз бар.

Бу җыр — хикмәтле, сихерле җыр булып чыкты. Бу җыр безне — авылны үз теләге белән ташлап киткән буынны эзәрлекли, бу җыр безне төннәрен уята. Безнең буын — авылда шул җырны сәхнәдән тыңлап, кычыткан ашы ашап үскән буын кешеләре — хәзер инде шәһәрдә генеральный директор, министр, СССРның халык артисты, өч-дүрт тапкыр лауреат, алдынгы шахтер, нефтьче, врач, газ үткәрүче, укытучы, Социалистик Хезмәт Геройлары. Әллә ниткән, әллә нинди исемнәргә лаек булган язучылар, композиторлар — барысы да диярлек, әнә шул җыр моңында тибрәлеп, авылдан шәһәргә күчеп, җайлы тормыш корганнар.

Шулар арасында — бу әсәрнең авторы да. Җайлы квартирасы, ике телевизоры, күп санлы китаплары, балконы һәм... каршыдагы ипи-сөт кибете белән. Начармыни? Утын, «мал курмысы» кайгысы юк, налог түлисе юк, кигәвен тешләми, иртәнге дүрттән торып фермага иртәнге савымга йөгерәсе юк, сентябрь янгырында бәрәңге чүплисе юк. Ә аның җанын теге елларда, педучилищеның партадан өеп ясалган сәхнәсендә яңгыраган Нина Арыкова тавышы телгәли:

> Кай илләрдә яшәсәм дә,
> Он(ы)та алмам гомергә...
> Хуш, авылым, сау бул...

Һәм бәгырен шул җыр телгәләгән көннәрдә автор, бөек материя, зур эстетик идеаллар, Казан шәһәренең зур гыйльми ачышлары, күренекле галимнәре, зур сәнгать әһелләре белән тулы киеренке мәдәни, гыйльми югары бер мохиттәннән китеп, авыллыгына кайтып ала да, вак кына итеп рәхәт чигә, кечкенә генә бер нәрсәдән дә канәгатьлек таба. Ә чагыштырып бәяләрлек хәлләр бар...

Әйтик, автор — дәрәҗәле бер гыйльми совет утырышында. Трибунада төрле кеше чыгыш ясый. Профессор, декан, кафедра мөдире. Болар бит инде культура-сәнгать һәм фәннең иң югары дәрәҗәдәге вәкилләре, боларны тыңлап утыру — үзе бер гомер. Менә бер яшь ир сөйли: затлы пиджак, килешле галстук, пиджакның түш кесәсеннән аз гына күренеп торган, пиджак белән галстукны ачып җибәрүе алдан уйланган бер материя кисәге; һәр җөмләсе уйланган, һәр сүзе гыйльми бер саллылыкка ия, һәр фикерендә шушы аудиториядә утырган гыйлем ияләренә зур ихтирам

һәм шул гыйлемне алга таба үстерү мәсьәләләре. Тыңлавы рәхәт. Бу инде — авылда кычыткан ашап исән калган буын түгел, автор моңа кызыгып карый, көнләшеп (яхшы мәгънәсендә) тыңлый. Янында утырган деканга, пышылдап кына, автор болай ди:

— Бу инде, слушай, мин түгел. Бу инде иртән йокыдан торгач, һичшиксез, илле грамм ак күмәч өстенә егерме грамм май ягып, бер бал кашыгы джем кабып, тиз эри торган бразилия кофесын эчеп эшкә килә торган кеше. Күрдеңме — культура? Бу инде, минем шикелле, иртән калган аш җылытып, шопыр-шапыр ашап эшкә китүче түгел...

Шулчак кинәт кенә декан иптәш өстәлгә башын салып, тавыш чыгармаска тырышып, сыгыла-сыгыла көлә башлый. Теге интеллигент егет әле һаман сөйли. Бераз тын алгач, ләкин шыпырт кына болай ди:

— Бүген иртән үзем дә нәкъ шулай, калган аш ашап килгән идем...

Автор бәхетле, деканны ул белә: сабый вакытта ул ятим калган, әнисе — күп балалы солдатка — бер оя баланы авырлык белән үстергән, малай хәзер мәшһүр Казан университетының зур бер факультетында декан! Ләкин авыл гадәтен онытмаган...

Тагын шул: автор җәйнең яңгырлы бер көнендә мәшһүр университетның колонналары янына чыга да, аптырап кала. Зонтикны һич кенә дә тиз генә җәеп, баш өстенә күтәрә алмый: әле бер энәсе, әле икенчесе пиджак җиңенә үрелеп кера, җәяргә комачаулый. Ә яңгыр коя, университет түбәсеннән әле ул икеләтә-өчләтә артык коя. Автор инде «юеш тавык» хәлендә, шул арада күрә: зонтик астында тыныч кына бер доцент бара, татар малае, Африка илләрендә француз телендә физика укыта, әле ялга гына кайткан, сугыш вакытында әтисез калып кычыткан ашы ашап үскән, университет тәмамлап зур кеше булган, Казан арты Әтнә кызына өйләнгән, Африкадан кайтышлый Афины — Будапешт — Париж аэропортларында булган, бүген ул (автор аны, ун минут элек кенә, университетның парткомы тирәсендә очраткан иде) үзенең туган ягы Иске Кишеткә печән чабарга кайтып китәргә тиеш иде; авторның зонтигына буталып, яңгыр астында чыланып торуын күреп елмайды. Автор исә, аңа болай дип җавап бирде:

— Һи-и, агайне... Яңгыр килгәндә без бит арыш капчыгы каплый идек баш түбәсенә!.. Безгәме соң зонтик?

Угандаданмы, Алжирданмы, Нигериядәнме кайткан егет тагын елмайды: ие шул, авыл халкында зонтик юк, ләкин арыш капчыгы бар иде. Ул хәлне аңлады. Юеш автор исә үзенчә, вак бәхет белән бәхетле иде. Шул көнне автор газетадан укып белә: «Впервые зонтик величаво проплыл по улицам Лондона в 1750 году, свидетельствует журнал «Эксвайр» («Комс. правда», 1986, 12 август). Яңгырдан саклану чарасы буларак, капчык бөркәнү авыл халкына кайчан килеп керде икән?

Тагын бер истәлек. «Ленин бакчасы» дигән матур бер тукталышта трамвай көтеп торам. Бу тукталышны мин бик яратам, чөнки монда — студентлар, галимнәр. Трамвай, троллейбус тулы гыйлем йөри. Менә шуларны уйлап трамвай көтеп торганда, җиңемнән берәү тотты. Мин ул көнне өр-яңа дипломат белән идем. Шул көн өчен генә киелгән өр-яңа плащым да әйбәт кенә иде, яшь студентлар арасында инде чәченә чал кереп барган, бай биографияле, серле бер ир сыман, бераз гына үземә-үзем сокланып, кукраеп басып тора идем — шунда җиңемнән берәү тартты. Бәрәч! Үзебезнең авылның Шәйдулла, яшьтәш. Гомере буе ат карый, үзеннән, киеменнән ат исе килеп тора, олыгая төшкән, үзе дә ничектер алты-җиде яшьлек «ат уртасы» бер атка охшый башлаган Шәйдулла.

— Ни хәлләр? — диде ул, атка башак бирә-бирә яргаланган, ярыкларына фураж оны тулган каты кулын сузып.— Бу кем икән дип торсам, син икәнсең. Кая барыш?

— Эштән кайтам, яшьти,— дидем мин бер тын алгач. Студенткалар да, дипломат та, яңа плащ та кинәт кенә онытылды, авылыма кайттым да төштем.— Эштән кайтыш, яшьти.

— Син кайда эшлисең соң? Син язучы түгелме соң?
— Мин, яшьти, университетта укытам.
— Кайсысында? Алар әллә ничә бит Казанда?
— Юк, яшьти, университет — бер генә. Тегеләре аның институт дип атала.
— Алаймыни...— ул арада бишенче трамвай килеп житте, Шәйдулла Арчага кайтыр өчен «Компрессорная»га барып утыра икән, сүз арасында әйтеп куйды: «Аннан утырсаң, билеты илле биш кенә тиен»,— диде.— Алаймыни... Ник, син язучылык өчен дә аласыңдыр ич?
— Нәрсә?
— Акча.
— Юк, агайне, язучылык өчен акча түләмиләр. Язган өчен генә. Анда да, басылып чыкканы өчен генә түлиләр.
— Ә монда эшләгәнең өчен күпме аласың?
— Безнеке ташка суккан тамга инде: аена өч йөз егерме сум. Мин — доцент.
— Профессор түгелмени син?
— Юк, анысын булдыра алмадым.
— Ә профессор күпме ала? Аена?
— Аларның шәп: аена дүрт йөз илле сум.
— Ну, синеке дә начар түгел инде.
— Юк, зарланмыйм. Күп акча нәрсәгә ул?
— Ә көненә ничә сәгать эшлисез? Сигезме, артыграк тамы әллә?
— Безнең алай көнләп түгел. Еллап исәплиләр.
— Ничек алай?
— Менә мин елына сигез йөз сәгать укытырга тиеш.
— Ә ул көненә күпме чыга?
— Ничек дип әйтергә... Менә бу яртыеллыкта минем атнага ике лекция.
Шәйдулланың авызы ачылды да... ябыла алмады. Мин дә, шул форсаттан файдаланып, кесәдән талон эзләү мәшәкатенә керештем:
— «Советская площадь» дигән җирдә төшәм мин, әйдә, безгә кер. Сөйләшеп утырырбыз. Кирешкән юк бит. Чәй эчәрбез.
Шәйдулла аңына килде:
— Юк, рәхмәт, поезд каршына бензовоз килеп торасы иде Арчадан, малай бензовозда эшли,— диде.— Әле мин ак буяу булмасмы дип кенә килгән идем.
Үзе сөйли, үзенең күзләре бөтенләй икенче нәрсә турында уйлый. Әйе, уйлый иде Шәйдулланың күзләре! Ул тагын телгә килде:
— Атнага ике лексияң ничә сәгать була ул?
— Ничә дип... Бер лекцияң сиксән минут инде. Ягъни, бер сәгать тә егерме минут.
Шәйдулла бераз гына күзләрен йомып торды. Нидер (беләм инде!) исәпләде.
— Сиксән дә сиксән... Йөз алтмыш минут... Шуңа күпме түлиләр дисең?
Мин кабатладым. Шәйдулланың, бичара, битеннән кан качты. Ул арада «Әбҗәлилов» тукталышына килеп җиткәнбез икән. Мин дә, ниһаять, үреле-бәреле ике талон тиштем дә берсен Шәйдуллага тоттырдым:
— Мин алдан төшәм бит, мә, кесәңә салып куй,— дидем.
«Әбҗәлилов» белән «Искра» арасын трамвай бик озак уза: адым саен светофор, ялыгып бетәсең. Ләкин бу юлы ялыгырга туры килмәде. Чөнки Шәйдулла, бөтен вагон халкын нуль урынына да күрмичә, кычкыртып, минем кулларны боргычлап (сумкасын идәнгә куеп торып), кесәгә өч тиен акча салды.
— Шту син?! — дип шәррән ярды ул.— Шту син? Нишләп кеше акчасына йөрим ди мин? Колхозчы дигәч тә, син әллә безне бер тиенгә мохтаҗ дип беләсеңме? Юк, минем олы малаемның, әнә, комбайнда эшли,

айлык акчасы нәкъ синеке кадәр. Ул синең шикелле чәч агартып гомер буе укымады. Сигезне бетерде дә, СПТУга китте, аннан — армиягә. Кайтышына — комбайн. Нәкъ синең кадәр ала.

Өч тиенлек акчаны плащ кесәсенә салгач, Шәйдулла минем кулны ычкындырды. Шау итте:

— Нишләп синә әҗәтле булып калыйм мин? Өч тиен бит ул — акча.

...Минем башка да кайвакыт дәһи фикерләр килеп ала. Мәсәлән, менә болай:

— Йә, ярар, яшьти, мин монда төшим әле, гастрономга керәсе бар икән,— дип, тиз генә саубуллашып, бер тукталыш алдан төшеп калдым. Дөрес, куркыныч зур түгел иде: университет студентлары безнең бу күрәшне күрми калды, алар «Әбҗәлилов»та төшеп бетәләр, бу якка таба КХТИ, «Пед» һәм «Мед» студентлары гына кайта — алар, шөкер, мине танымыйлар.

Мин бишенче трамвайның артыннан карап калдым. Ул трамвай, әллә ничек кенә шунда, нindiдер сагышмы, борчумы, самимилекме калдырып, яшьлекне алып китте сыман. Мин нәрсәнедер югалттым бу минутта. Шунда күңелемә теге җыр килде:

— Хуш, авылым...

## VII

*...ул елап җибәрде һәм балаларына: «Тыныч кына утырыгыз, ә мин зиратка барып килӛм»,— диде. Мин аны озатып куярга теләдем. Ә барыня: «Мин үзем дә юлны беләм»,— диде. һәм миңа биш тиен көмеш акча бирде — шундый яхшы барыня!..*

А. С. Пушкин, «Станция карачкычы».

Без улым белән Кесмәс болынында йөрибез. Икебез дә велосипедта. Ул, әлбәттә инде, миннән җәһәтрәк йөри, тауга да менеп китә, яр буеннан да выжылдап уза. Болын дигәне — каралган ярлар, үлимме-калыйммы дип чурлап аккан инеш, моңсу куаклыклар. Улым, тау битеннән менеп, колхоз басуында салават күпере ясаган «Фрегат» җайланмасы суы астына да кереп чыкты; әйдә йөрсен, әтисе туган җирнең суын да, туфрагын да күрсен, күреп калсын, киләсе җәйдә ул кырыс солдат хезмәтендә булачак. Анда велосипед эләкми, мин анысын гына беләм. Велосипед дигәннән...

Без бала вакытта (утыз сигезенче еллар) өч-дүрт авылга бер була иде ул могҗизалы машина, ул — йә укытучы егеттә, йә финагентта була, урамнан велосипед узганда без, малайлар, дөньяны онытып, шуның артыннан чаба идек. Аннан тын кабып егыласың да, хәл алгач, мактанышта башлыйсың:

— Ә мин бер җир буе арттагы калаена тотынып бардым.

— Һи-и... Ә мин! Ә мин! Мүгезен тотып карадым. Шундый шома! Эче куыш аның, беләсегез килсә!

Велосипед бала вакыттагы матур хыял, татлы бер төш сыман булып калды. Башка малайларның ничектер, минем үземнең, велосипед турында уйласам, күземнән яшь чыга иде. Адәм баласы ник үзенең сәламәт ике аягына сокланып, шатланып яшәми икән? Тиз йөрү аңа нәрсәгә кирәк икән? Кая дип гел ашыга икән ул?

Велосипед турындагы хыяллар безне тилертә. Кемдер, лапас астында көне буе тук-тук килеп ята да, менә бер заман, бөтен урам малайларын шаккатырып, агач колгаларга кагылган аркылы чүркиләргә басып, биектә йөри башлый. Бөтен малай өенә торып йөгерә, һәркем шундый «озынаяк» ясый. Ләкин бер-ике көннән ул да туйдыра. Ул арада та-

гын бер лапас астыннан такылдаган тавыш ишетелә, карыйсың: икенче бер малай урамга тачка ясап чыккан, элдертә генә, тачка тәгәрмәче гөрелдәп әйләнә, житмәсә, аркылы тактасына үзенең ике-өч яшьлек ыштансыз энесен — аш ашап, сөт эчеп күперенгән юеш борынлы малайны да утырткан, моны күреп бөтенебез өйләргә йөгерәбез, кулларны канатып тачка ясыйбыз, бер-ике сәгатькә бәхетле булабыз, ләкин, аһ... Шул вакытта урам уртасыннан теркелдәп кенә, көмештәй «биялэй энәләрен» ялтыратып, ак мөгезле велосипед уза, тачканы ташлыйсың, бугазга төен утыра, күзгә яшь тула...

Балачак шулай велосипедлы хыялда үтеп китте, бу хыялларны бераздан сугыш каплады һәм үтерде. Сугыш кешене, тереклекне генә түгел, хыялларны да үтерә. Хыяллар шулай үлде. Хәер, берсе калды: сугыш бетсә, бәлки, туйганчы бер ипи ашар идек. Әйе, ананас түгел, омар, йөзем, балык уылдыгы, өчпочмак, шашлык түгел, ә гап-гади кара ипи.

— Бер савыт катык белән кыерчык ипи ашасам, үлсәм дә үкенмәс идем...

Моны әйтүче малайлар яшьтәшләр арасында байтак иде.

Ә бер көнне сугыш бетте. Ач булсак та, чиксез шатландык. Сугыш бетеп бер ел торгач, абый армиядән кайтты. Кайтышлый, Казандагы Сорочи базарына кергән дә, коточкыч киң мөгезле, туфракта әллә ниткән эзләр калдыра торган тәгәрмәчле немец велосипеды сатып алган. Педальләре калын резинадан, аның яннары күзеңнен явын алырлык сары ахак челтәрле пыяла белән бизәлгән, үзе мәһабәт, серле. Ярты урам карарга җыелды.

— Өч мең дә алты йөз сум тора,— диде абый.— Хәзер шунсыз — транспортсыз — ярамый. Заманы ул түгел...

Велосипедның кургаш эмблемасына заводның исеме язылган иде: «Steuer». Мин моны, еллар үткәч, сүзлектән эзләп таптым: нибары «руль» дигән сүз икән.

Шулай икенче дөнья, велосипедлы дөнья башланды.

Аңа утырып, җәйге кояшка карап, авыл юлыннан чабулар, урман буйларыннан элдертүләр, кырдан барганда борынга бәрелгән чәчәк исе — барысы да башны дивана итә иде. Әле бит велосипедның үз исе бар, анысына затлы лак, резина, машина май исе бергә кушылган. Ах, үләм, бетәм, яшьлек дәрте мине кая алып бара?!

...Күрше Исламгали агай сөйли. Аның һәрвакытта да бераз арттырып, өстәп, кызык итеп сөйләү гадәтен беләбез. Ул әйтә, кышын җылы абзарда ирегеп яткан яшь бозауны ишегалдына беренче чыгарганда сак булырга кирәк, аяк астында балта, пычкы, чалгы булмасын, ул, ди, үзенең кая чапканын белми. Күрше хатыны әйтә: әнә без бер елны шулай чыгарган идек, капкабыз ачык булган, урамга ук чыгып китте, чак алып кердек, күзләре тонган, ди. Исламгали агай мондый гына сүзгә риза булмый, тамагын кырып ала да, әйтә:

— Һи-и... Сезнең нәрсә ул! Урамга чыккан... Урам нәрсә ул? Әнә безнекен быел беренче тапкыр чыгарганда, капка ачык булган,— ул, бер-бер хикмәт көткәннәрен сизеп, бераз тын бирә.— Яңа Масрадан чак алып кайттылар (дүрт чакрым ераклыктагы авыл).

Велосипедта йөргәндә мин дә шул яшь бозау хәлендә идем. Бу — бер-ике елга кадәр шулай барды, ахрысы.

Ул елларда авыл кибетләренә бераз хәл керде, реформадан соң шикәр кайта башлады, аннан, конфет урынына яшел «драже», бераздан — пыяла банкалы «конфитюр» дигән затлы ризык. Кибет шүрлегендә — «Краснооктябрьские», «Казбек» исемле шәп тартмалы папирослар, «Анага», «Вакири», «Ративани» дигән хикмәтле шәраблар (беркем дә алмый!), кыскасы, кибеттә конфитюр, хәлвә, крендель исе — баш әйләндергеч ис. Бер почмакта китаплар — Сталинның биографиясе, ВКП(б) тарихының кыскача курсы, Карпинскийның «Совет дәүләте турында

аңгәмәләр», М. Калининның «Коммунистик тәрбия турында» дигән әсәре. Тагын бер почмакта исле майлар: «Кара-ново», «Сирень», «Мои грезы»...

Яшисе, мең, миллион ел яшисе килә!

Кичләрен — су буенда яшьләр уены, бөтен фронтовик егет монда велосипед белән килә, без велосипед саклыйбыз, утырып йөрибез, мактанабыз. Ул ел җәенең үз җырлары туды, болар — «Шомыртым» һәм «Уяна таңы илемнең...» Болар тынычлыкка гимн булып яңгырадылар. Ул елда сәхнәгә «Этнә» көе менде, агитбригада концертларында, һичшиксез, шул яңгырый иде:

Җырлыйк Әтнә көйләренә,
Җырчыларга таралсын;
Мул уңышлар үстерүдә
Безнең Әтнә дан алсын...

Бу җырларны ишеткән саен, кыр юлларыннан велосипедта җилдереп узган саен, сугышның мәгънәсезлеге, афәте, фаҗигасе тирәнрәк сизелә иде. Нигә сугыш башлады икән бу немецлар, шундый велосипедлары була торып?

...Велосипедка мәхәббәтем шул кадәр көчле булган, балаларым үсә башлагач, бөтен рәхәт мәшәкатем аларга велосипед алу иде. Бераздан аларны ишегалдындагы такта сарайга, дачага урнаштырдык, шәһәр, поселокның бәләкәй хулиганнары аларны урлап бетерделәр, шулай да, өчдүрт зур велосипедны авылда саклыйм әле.

Алар миңа яшьлегемне искә төшерә.

...Шулай, Курса тавына мендек, аннан Курса болынына төштек. Курса — әдәбият тарихында Курсави Габденнасыйр исеме белән мәшһүр. Безнең заманда — көрәшчеләре белән. Хәтер: 1938 елның кырыс-матур җәе. Узган көз һәм кыш авыллар аркылы куркыныч утыз җиденче ел узды. Авыл укытучылары, элеккеге мулла, хәлфә балалары дәһшәтле тынлыкка сеңеп, чүгеп калдылар. Ләкин тормыш алга бара: утыз сигезнең җәендә «сайлау» узды, безнең авылның мәктәпкә әйләнгән мәчете ишегалдына өстәл-парта чыгарып, өстенә кызыл җәймә капладылар, аннан патефон куйдылар. Патефон — хикмәт, сихер иде. Кечкенә сандык эченнән мәчетмәктәп ишегалдына көй сибелде.

Әрәмәләр арасында
Сайрый тургай баласы,
Туган җирем — гөл бакчасы,
Үзем совет баласы.

Бер-ике атнадан сабан туйлары башланды. Шуның берсенә — Курса сабан туена — без, малайлар, кыр юлы буйлап элдерттек, ун чакрым ара малай вакытта арамыни ул?

Дөньяда күп сабан туйлары күрдем, күп көрәш күрдем. Хәзер сабан туе мәйданына үлчәү категориясе белән кертәләр, фәнгә нигезләп көрәштерәләр. Әмма, Курсалар кадәр көрәшкән, шуны сәнгать дәрәҗәсенә җиткергән башка көрәшчеләрне белмим мин. Курса көрәшчеләренең берсен «Коры» дип йөртәләр иде, көзен яки кышын аны, бәлки, мулла кушкан исеме белән дә йөрткәннәрдер, инде дә сабан туе атналары җиткәндә ул кеше «Курса корысы» дип кенә йөртелә иде.

— Фәлән сабан туйга Курса корысы барырга җыена икән...— дигән дәһшәтле хәбәр тарала иде бервакыт.

Менә сугышка кадәрге бер сабан туенда мин шуны күрү бәхетенә ирештем.

Авыл сабан туенда хәзерге көрәшү — көрәшмени ул! Мәйдан уртасына керәләр дә, иң башта, бил ала алмыйча, халыкның бәгырен телгәлиләр. Көрәшчеләр таза — арка-җилкә калын, корсак та саллы. Менә түгәрәк уртасында берсен-берсе этеп, сөзешеп йөриләр дә, бервакыт инде халык дәрте бөтенләй сүнгәч, бер-берсе өстенә ишелеп төшәләр. Кем җиңгән дә, кем җиңелгән — шайтаным да аңламый.

Әмма теге сабан туенда...

— Курса корысы керде,— дип, бераү шырыйлап кычкырмасынмы!

Сабан туе бит ул елларда күп тавышлы була иде. Мәйдан тирәсендә төрле авыл егетләре гармунга җырлап йөриләр, һәрбер төркемнең үз көе, үз җыры. Болар тавышына мәйдан читендәге тукранбаш тушәлгән арбаларга, ал арбасы гына салдырылып, тугармыйча бәйләп куелган сабантуй атларының шөлдер, кыңгырау тавышлары, малай-шалайның чыр-чу килеп куышып йөрүләре, кызларның көмеш табакка энҗе чәчкән тавыш чыгарып челтер-челтер көлүе — бөтенесе бергә кушылып, баш әйләндергеч сихри бер оркестр тәшкил итә иде. Шуның өстенә — ат исе, камыт күне, яңа чапкан печән, кыш буе сандыкта нафталинлап яткырылган ефәк шәл исе, авыл кибетләреннән чыккан пряннек, конфет исе, сабан туена дип кенә каратып, келәйләтеп, лаклатып алган тальян исе — болар барысы да кешене табигый халәтеннән күпмегәдер аерып ала, исәрләндерә... Кешене бит шулай элек-электән төсләр, биеклек, киңлек, тавыш, гөмбәз әсәрткән. Чиркәүгә, храмга кергән кеше, үзенең тар алачыгы белән чагыштырганда могҗиза булып күренгән биек купол астында торып, андагы төсләргә, музыка яңгыравына шаккатып, тынып калган, үзен бер тузан бөртеге генә итеп сизгән. Мәчеттә дә шулай: яп-ялангач диварлар, биек түшәм, шомлы тынлык сине өнсез итә. Монда кеше рухи киеренкелектән исергән, жирдән бераз гына аерылган. Кеше исәрләнгән.

Әнә шундый исәрлекнең иң кызган бер мизгелендә сабан туе мәйданында кисәтүле, тирән мәгънәле ачы тавыш ишетелде:

— Көрәшкә Курса корысы керде!

Вәссәлам! Бу инде — чын сәнгать башлана дигән сүз иде һәм сабан туе шым калды. Без, малайлар, кысылыша-кысылыша, түгәрәк эченә табарак юл алдык, кактылар-суктылар, җикеренделәр, ләкин теге сәнгатьне карамый калырга хакыбыз юк иде безнең, ун чакрым араны ялантәпи йөгереп юкка гына киленгәнме?

Хәтердә барысы да сакланган: менә мәйдан уртасына, җиңел-җиңел генә атлап, какча гәүдәле бер кеше керде — без шаккаттык! Бик җиңел сөякле күренде ул безгә, битләре кояшта янган, яңак сөякләре бераз чыгынкы, сакалы сирәк кенә, тәбәнәк кенә гәүдәле бер карт. Үзара пышын-шашын китте:

— Картайган... Юк, болай гына, авыгын басар өчен генә кергән инде ул...

— Кара син андагы йөрәкне! Гыйззәткә каршы керде бит. Бетерә бит моны Гыйззәт...

Курса корысы каршында тирә-як сабан туйларында батыр калып йөрүче буй-сынлы Гыйззәт басып тора иде — Гыйззәтнең утыз яшьләр чамалы выкыты.

Халык сизми дә калды, саргылт сакаллы «Коры» Гыйззәтнең билен кызыл башлы сөлге белән урап алды да шундук һөҗүмгә күчте.

Мәйдан өстендә, читтәге ат шөлдере тавышын исәпләмәгәндә, чебен очканы ишетелерлек үле тынлык урнашты. Ләкин озакка түгел. Корының башы бөтенләй күренми дә, ул Гыйззәтнең култык астына кереп беткән сыман иде. Менә бер мизгелдә мәйдан уртасына иске тегермән җимерелгәндәй әллә ниткән тавыш таралды.

— Кор-кор-кор-кор-рык!— дигәндә Гыйззәт ике-өч метр читтә, яшел үлән өстендә, ике аягын, ике кулын күккә күтәреп, сырты белән ята иде. «Коры» үзе дә, тезләнгән җиреннән торып, чалбар балагын каккалап маташты, озак юанмады. «Менә, көрәш шундый була ул» дигән сыман, әйләнәдән чыгып китте; комиссия әгъзалары, ситсымы, күлмәкме күтәреп, аның артыннан чаптылар — «Коры» бүләкне үзе алмый, гадәт буенча, аны нәсел-нәсәбеннән берәр кеше җыеп тора иде.

Шуннан бирле минем чын сәнгать булырлык көрәш күрә алганым юк.

...Курса басуында «Фрегат» һаман эшли иде. Курса басуы, Курса тавы. Шул исемдә бер юнәлештә — көнбатыштан көнчыгышка таба тезелгән

биш авыл: Югары, Урта, Түбән Курса; Почмак Курса; Курсабаш... Бу нинди хикмәтле исем соң, нигә илебезнең башка якларында очрамый, нигә менә нәкъ шушы урында гына ул? Бу исем каян килгән, ничек ясалган? Туган җирнең авазын тыңлыйк әле: Курса, Кур-са... Ку-орысы. Ку — акку — аккош — борынгы заманда —«ку». Оры — тау. Әйе, Югары Курса дигән авыл тау битенә урнашкан. Аста — болын. Кесмәс суы. Бабайлар килеп урнашканда монда кара урман булган. Кесмәс ярлары җимерелгәндә сөяккә әйләнгән юан-юан агач кәүсәләре чыга, моны бездә «кискә» дип йөртәләр. Биеклекләре утыз метрдан да ким булмагандыр аларның. Әнә шул урман, тау, болынлы җиргә борынгы заманда гел аккошлар килгән. Аккошлар безнең җырларыбызга да килеп кергән. Фазан, фламинго, кондор яшәмәгәндер бездә, яшәгән булсалар җырга керми калмаслар иде. Ә аккошлар — җырда гел телгә алына.

Аккош аталар микән
Мамыгын саталар микән...

Яки:

Аккош күлләрдә була,
Борыны суларда була...

Курса авылының заманында үз җырлары бар иде. Ә үз җыры булган авыл — ул инде юк-бар авыл түгел:

Каласың, Курса, каласың
Каршы тауларың белән.
Чылтырап аккан чишмәләрең,
Сөйгән ярларың белән.

Ку орысы басуында салават күперле яңгырда коенып, без авылыбызга юнәлдек. Августның икенче яртысы иде, кояш мул, ләкин инде моңсу. «Казаклар» дигән авылның ындыр арты юлыннан, велосипедларыбызны җитәкләп, җәяү атлыйбыз. Коры тузан баскан юлга карап туктап калабыз: аяк астындагы юл селкенә. Хәрәкәт итә. Берни аңламый басып торабыз. Каршыга килгән җәяүле бер абзый аңлата: колхозның бәрәңге басуыннан авылга кайтучы коңгызлар бу, ди. Колорадо коңгызы. Кызыл коңгызлар көзгә таба саргылт пута белән бизәнәләр икән. «Алар,— ди абзый,— хәзер капка-коймаларга сырышалар, кояшта җылыналар. Ни хикмәттер, кышлау өчен, бөтен басуны иңләп, авылга кайталар, өй астына тулалар, бәрәңге бакчасының балчыгына, тирәнгә кереп йоклыйлар».

Велосипед шиннарының челтәрле сырлары сытылган коңгыз белән тулды. Мин улыма туган як матурлыгын күрсәтермен, әллә нинди җылы истәлекләр сөйләрмен дип уйлаган идем — кайтабыз, коңгыз таптыйбыз.

Шулай газаплы юл кичеп, авылыбыз зиратына кайтып җиттек. Безнең зират матур! Ул тау өстенә урнашкан, кояшлы көньякка йөз тотып, каен, нарат, чыршы, миләш агачлары белән алга — Кесмәс уйсулыкларына таба моңсу-сихри караш ташлаган. Хәзер гел шулай: көньякка таба үстереп, зиратны зурайта баралар. Соңгы елларда яңа мода: кайчандыр ачлыкка, фәкыйрьлеккә чыдый алмыйча авылны ташлап киткән егетләр-кызлар үләр алдыннан васыять әйтәләр икән: «Мине үз авылымның зиратына алып кайтып күмегез»... Кайберләре, чыгып киткәннән бирле, бер генә тапкыр да авылга эз басмаганнар. Ә шундый васыять әйткәннәр. Без каберләр карап йөрибез, мин улыма сөйлим. Менә монысы — Зариф кабере. Ул, сугыш бетәргә бер ел кала армиягә алынып, тоташ җиде ел хезмәт итеп кайтты. Сугыш вакытында колхозда эшләгән иде, көн димәде, төн димәде. Илленче елларда, шәп киенеп, Германиядән кайтса — авылда ачлык. Колхоз — хәлсез. Зариф, башка бик күп егетләр кебек, Казанга китте, заводка урнашты, тулай торактан аңа караватт бирделәр, өйләнгәч — бaрактан бер почмак. Шәһәрдә акча, ипи, шикәр, сөт, колбаса бар иде. Еллар узды, Зариф өч бүлмәле фатир алды, үз машинасы белән сабан туйларына кайтып йөрде, ә менә әҗәл килгәч, балаларына әйткән:

— Авылыма кайтарып күмегез...

Зариф биш-алты класстан ары укый алмаган иде. Германиядә озак еллар хезмәт иткәндә, солдат хезмәтенең акрын бара торган сәгатьләрен кыскартырга теләпме, җыр дәфтәре башлаган. Солдат шулай инде, бер-берсеннән җыр күчерә. Рус егетләреннән алган җырлар арасында бик гадиләре белән бергә әллә ниткән хикмәтлеләрен дә күчергән.

— Менә монысы нинди җыр икән аның? — диде ул, солдат дәфтәрен миңа өч-дүрт көнгә биреп торганда. Җыр «Неаполитанская песня» дип исемләнгән иде. Мин, каушый-каушый, аны үз дәфтәремә күчердем.

И когда вся природа в покое,
Когда слышится шелест прибоя,
Когда ветер влечет за собой —
Я был возле моря один.
Взгляд ваших глаз был понятен на тысячу фраз,
В тот дивный час я готов был отдать жизнь за вас...

Авыл малае, колхозда ат җигеп эшләгән, җиде ел солдат хезмәтен узган Зариф кемнеңдер матур күз карашы өчен гомерен бирергә җыенмый иде.

— Күргән бер кыз өчен алай булмый бит инде ул, малай,— диде ул, миннән җавап көтеп.

Ләкин миңа әле нибары унтугыз гына яшь иде.

Хәзер Зариф, барысын да аңлап бетереп, җир астында ята инде.

Ә монысы — Сәлих кабере. Колхозда бергә эшләдек. Без яшь, сөякләр сыек, ачлык изә. Сәлих исә, җитмешәр килолы бодай капчыгын күтәреп, арбага төйи, аннан заготзерного илтә, анда кертеп аудара.

Аларның өе аргы якта, тау башында. Ә амбар янында йөк төяр алдыннан хәл җыеп утырганда Сәлих бәхәс куптара:

— Менә шушы бер капчык бодайны миңа бушлай бирсәләр, түлке өенә кадәр бер дә ял итмичә сыртыңда алып кайтасың, дисәләр, мин алып кайтам. Ә сез?

Андый бодайны беркем дә берәүгә дә бирмәде, әлбәттә; Сәлих шул ач елны армиягә китте һәм ул да җиде ел хезмәт итте. Ахырдан сөйләделәр: шул кырык өченче елда чыгып китүеннән авылга бер тапкыр да кайтмаган, армиядән кайтышлый ук Казанның авиация заводына урнашкан, бер үк цехта утыз елдан артык эшләгән, шәп квартиралар алган, оныкларын күргән. Ә менә үлем авыруы эләккәч, балаларына әйткән:

— Авылыма кайтарып күмегез,— дигән.

Зиратның бер почмагы — яшьләрнеке. Монда трактор, автомашина, электр аварияләрендә һәлак булганнар — егерме ике, егерме биш яшьлек егетләр. Барысын да ата-аналары авылга алып кайтып күмгән.

Яшьләр почмагына «Хәмид»не дә алып кайтып күмгәннәр. Анысы, әлбәттә, иртә киткән, ләкин аның тормыш юлы шулай ук дөрес сызык буенча барып, дөрес финалга чыккан. Монда бернинди хата да юк. Исламгали агай — күзәтүчән, шәһәрләрдә, больницаларда күп йөргән, инвалидлыгы аркасында военкомат, тәэминат бүлеге, райком, сәламәтлек саклау министрлыгы тирәсендә күп тапкыр булган кеше — белә, күрә иде. Кешенең чырае, йөзе-бите, һичшиксез, эш урынына карап үзгәрә.

Җентәс кенә, сөякчел генә Хәмит, мәсәлән, институтны бетергәндә дә шулай сөякчел, йонлач муенлы бер егет иде. Башта аны институтта калдырдылар. Шуннан кинәт күтәрелде. Әтисенә:

— Приметили (күреп алдылар),— диде.

Бер-ике ел эчендә егетне тагы да югарырак күтәрделәр. Монысына инде Хәмит үзе дә көч куйды, акылын җикте. Шулай итеп, персональ машинага кадәр күтәрелде. Һәм әтисе шул чакта сизде: малайның битендәге тиресе затлы тирегә алмашынды. Тавышы үзгәрде. Затлыга, салмакка. Хәрәкәтләре үзгәрде. Ияк астында йомшак кына бер катлау ясалды. Күз карашында ничектер үзен кешеләрдән аерып куя торган бер пәрдә хасил булды. Әмма иң үзгәргәне — бит тиресе иде. Бу тире крестьян Исламгали агайга

минә нәрсә сөйли иде: минә синең, әти, битең кытыршы, йөнтәс, яңакларың киртләч-киртләч, ә бит бу — ашау рәтен белмәгәнлектән. Менә син инде, иртән торгач, сөтле чәй эчәсең, күп булса — калган аш җылытып ашыйсың. Ашка әллә кайчан суйган малның сыйфатын югалткан итен саласыз. Җәйгә әле аны тозлап та куясыз. Ә бит бу — дөрес түгел. Дөресе бит менә болай: иртән кофе эчәргә кирәк, пешкән чөгендер, пешкән кишер һәм бер-ике кашык чи кәбестә ашарга кирәк. Бер стакан к и ч ә  а е р т к а н каймак. Аннан кайнар гарнир белән йөз илле грамм чамасы ит. К и ч т ә н с у е л г а н малныкы. Аннан — бер стакан сок. Көндезгесен, кичкесен дә шулай, фәнгә нигезләп корасы. Кич ятар алдыннан, һичшиксез, бер стакан кефир эчәсе. Ә сез, сөттән эремчек ясыйсыз да, тавык чебиләренә бирәсез. Үзегезне карый белмисез...

Менә шуларны уйлап йөри торгач, Исламгали агай кешеләрне милләте, шөгыле буенча бүлеп караудан бөтенләй баш тартты, битләре буенча гына бүлеп йөртә башлады. Ул күргән битләр менә мондый кешеләргә бүленә иде: авыл хуҗалыгында эшләүче бите; район җитәкчесенең бите; шәһәрдә шәп эштә эшләүче бите; министр бите.

Санаторийда ятканда шул турыда бер кешегә сөйләгән иде, анысы язучы булып чыкты һәм, Исламгали агайны шаккатырып, тагын да тирәнгәрәк алып кереп китте.

— Ә менә мин кешенең битен түгел, ә бәлки эш урынына, креслосына карап, эчке органнарының эшләү дәрәҗәсен өйрәндем,— диде.— Димәк, болай: берәү гадәти генә эштә эшли, аны тиргиләр, сүгәләр, мактыйлар, аңа елмаялар, кул бирәләр, яки күрмәмешкә салышалар. Бу иптәшнең бер көнне йөрәге чәнчи, икенче көнне ашказаны авырта, өченче көнне — башы. Ә бер көнне бөтенесе берьюлы авырта. Менә хикмәт — шул кешене бервакыт кинәт кенә күтәрәләр, урындыклы итәләр. («Урындагы кеше» — шуннан алынган.) Һәм бу урындыкны иң беренче булып эчке органнар сизә. Менә болай: бу иптәш өстә, президиумда утыра, аста — аның белән элек бертигез булып, бергә эшләгән танышлары. Алардан өстә утырганда ул күзәтә: менә ыгы-зыгы киләләр, урын тапмыйлар, ире — хатынын, хатыны ирен ияртеп килгән, урын эзлиләр. Иптәш тә күреп утыра: залда ул төшеп утырачак урын кызыл бәрхет бау белән арканлап саклана. Астагы кешеләр, урнашып бетүгә, сәгатьләренә карый башлыйлар һәм уйлап куялар: унбергәчә сузылса, трамвай булмый инде, бүген тагын йокы туймый инде. Әлеге иптәш анысына да борчылмый: бу җыелыш ничәдә генә бетсә дә, урамда аны машинасы көтеп тора. Менә шуларны уйлау ашказаны эшләвен яхшырта. Һәм ашказаны яхшы эшли дә, чөнки табигать аны яхшы эшләсен өчен булдырган.

Инде иртән эшкә килгәч, урындыкка кереп утыргач, башка органнар активлаша. Элек монда  с и н е  чакыртып кертәләр иде, с и н е сүгәләр, с и ң а эш кушалар иде. Ә хәзер  с и н  чакыртасың, с и н сүгәсең, с и н эш кушасың. Бу бик ләззәтле шөгыль, чөнки кешене чакыртып алу, аны ачулану, аңа эш кушу хокукы бары тик акыллы кешеләргә генә бирелгән, димәк, син — болардан акыллырак, өстенрәк. Менә бу хис йөрәк эшчәнлеген яхшырта. Һәм йөрәк яхшы эшли башлый, чөнки табигать аны яхшы эшләсен өчен булдырган.

Ә калган органнар ничегрәк? Аларга да рәхәт мизгелләр килә. Әйтик, бөергә, бавырга, үт куыгына. Болар бик мәкерле органнар. Йөрәк, ашказаны авыртканын кеше шул секундта ук тоя, белә, аңлый. Әмма дә инде тегеләр... Алардагы микроблар, сиңа сиздермичә генә, эчтән кимерә-кимерә киләләр дә, бервакыт — кинәт кенә — сине операция өстәленә салдырталар. Үкенергә дә өлгермисең — шабаш! Бу әгъзаларны ничек яхшы хәлдә тотарга? Әмәл бар: түрә булып алырга кирәк. Менә шунда инде әлеге «иптәшләр» гөрләп эшли башлый. Ләкин, гомумән түрәлектән түгел, ә түрәлекнең аерым бер, аеруча ләззәтле мизгелендә яшәреп, сафланып китәләр алар. Кайчанмы? Кайчандыр сине түбәнсеткән, рәнҗеткән, сиңа өстән генә караган, сиңа кул бирмәгән, игътибар күрсәтмәгән, гозереңне

тыңламаган бер кеше хәзер *үзе сиңа гозер*, йомыш белән килә, ялварулы караш белән *синең* каршыңда утыра. Ә синең әле кызыл, әле зәңгәр, әле яшел төсле телефоның чылтырый, әле ишектән шөпшә билле секретарьша кереп кәгазь калдырып чыгып китә, синең бер колагыңда — бер телефон, икенчесендә — икенче. Ә өченчесе, кыштыр-кыштыр килеп, өстәлдә көтеп ята, син исә күрсәтмәләр бирәсең, кыска гына җөмләчекләр белән кемнедер тиргисең, ыхы-мыхы киләсең, ә теге гозерле иптәш — кайчандыр сине рәнҗеткән яки кайчандыр сиңа кул бирмәгән иптәш — көтеп утыра. Әйе, *көтеп* утыра. Менә нәкъ шул вакытта бөер, бавыр, үт куыгы гөрләп эшли башлый һәм бу табигый да, чөнки табигать аларны шулай гөрләп эшләсен өчен яраткан.

Урындыклы кеше әнә шулай рәхәтләнеп эшләп кайта, аны машинада кайтаралар, иртәгә ничәгә киләсен сорап-белешеп китәләр.

Бөтен тәндә рәхәтлек, канәгатьлек, күтәренкелек. Болай яшәве шәп, болай яшәү — шатлыклы бер хәл.

Ләкин, ләкин...

Иң ләззәтлесе болар түгел. Иң шәбе, иң ләззәтлесе шул: кайчандыр студент елларында сиңа карамаган, сине «чабата» дип, саңга сукмаган, бер группада укып та, биш ел буе сиңа бер тапкыр да игътибар бирмәгән, институт кичәләрендә юрфак яки консерватория студенты белән генә биергә кергән шәһәр кызы — группаның йолдызы!— менә хәзер инде синең эш бүлмәңә килеп керә; теге Эдик яки Жориктан аерылган, квартира мәсьәләсен хәл итеп йөрүдән йончыган — теге вакыттагы буй җитмәслек кызның, хәзер бәхетсез тол хатынның — *сиңа* гозер белән килгән минуты. Ә алаймы? *Теге* елларда мин *чабаталы* идемме? Эдик, Жориклар белән култыклашып, безнең яннан терсәк очын гына бәреп узып киткәндә безгә карамый да идеңме? Тулай торакта безнең бер почмакка җыелып, «Әтнә», «Шомыртым» көенә җырлап авылны сагынып утырган кичләребездә, керфекләреңне калын майлап, Эдик, Жорик белән безгә кереп, мыскыллы караш ташлап, «Иоланта», «Травиата» тыңларга барганыгызны әйтеп чыгып китә идеңме? Алаймы, алаймы?

Ә менә хәзер ничек соң? Бәлки, син минем дачага килерсең иртәгә? Хатын — Баграда, санаторийда. Бәлки, синең гозерне иртәгә минем дачада икәү генә калып уйлашырбыз, хәл итәрбез? Ризамы? Киләсеңме? Ә шулаймы? Хәзер инде барысына да ризамы? Менә шул-шул. Менә без кем булдык та, син нинди хәлдә калгансың. Менә шулай ул, җанкисәгем...

Тик... дөнья куласа, бер әйләнә, бер баса.

Законнар яңара, заманнар үзгәрә. Гел бер төрле яшәп булмый, бер вакыт сине дә, кимчелекләреңне табып, эштән алалар һәм... кинәт кенә син элеккеге хәлеңә кире кайтасың. Ә бу — бик кыен хәл. Ничек инде ул, шушы башың белән, башка кешеләр кебек базарда чөгендер, ит, тозлы кәбестә алып йөрисең? Сезнең игътибар иткәнегез бармы базарда теге «элекке»ләрнең ничек йөргәненә? Яки трамвайда? Алар бит мондый хәлләрдә үз-үзләрен бөтенләй тота белмиләр, оялалар, кыенсыналар, кызаралар. Ул арада теге, элеккеге дуслар да читләшә башлый, инде телефоннан чылтыратмыйлар, туган көнең белән котларга оныталар, каршыңа килгәндә урамның теге ягына чыгарга тырышалар... Шуларны сизгән организмда да кинәт кенә үзгәрешләр башлана. Иң беренче чиратта күз астына «капчыклар» ясала, аннан бит тиресенең элеккеге яме китә һәм, көннәрдән бер көнне, «тук! тук!» итеп, йөрәк үзен сиздерә. Ә бер көнне кинәт кенә аппетит бетә, ул арада күз алмасында сары төс сизелә, бетте баш — калды муен тырпаеп! Күп тә үтми, синең элек эшләгән ялгышлыкларың, аңлы рәвештә башкарган хаталарың, бозык иҗтимагый эшчәнлегең турында газетада мәкалә күренә, җыелышларда, пленумнарда синең элеккеге эшчәнлегеңнең хаталарын телгә алалар... Һәм бер көнне газетада белдерү чыга: зуррак постта булгансың икән — матәм мәкаләсе, зур постта булып та, хаталарны күп ясагансың икән — биш-алты юллык шакмак: «...гаиләсенең кайгысын уртаклашабыз».

Хәмиткә, бичара, җиде юллык шакмак бирелгән иде.

Аны кайтарып күмгәч, озак та үтмичә, фронтовик Исламгали Яһүдин дә агачлыкка тыныч кына барып урнашты.

Исламгали агайның йорты авылның кыл уртасында иде. Теге очтан да унбиш хуҗалык, бу очтан да унбиш. Хәзер исә ул йорт, кырый хуҗалык булып, тынып калган. Карчыгы бакчасын карап тота икән: өй түрендәге кечкенә бакчада — җитмеш-сиксән төп помидор куагы. Һәрберсе авырлыктан сыгылып утыра. Тик алар барыбер җиргә кадәр бөгелә алмыйлар. Чөнки... килен Хәмитнең бер кочак галстукларын авылга бирен кайтарган. Йа, хода! Нинди генә төсләр юк, нинди генә модалар юк! Һәр помидор нинди дер бер тарихлы галстук белән бәйләп күтәрелгән. Авыр, авыр...

Урамда тып-тын. Бакча киртәләре кичке кояшта җылынган, аларны теге, юл-юл кабыклы әрсез коңгызлар сырып алган.

Бушап калган урамнардан без, җәяүләп, велосипедларны җитәкләп бардык. Авылның — сугышка кадәрге ике урамына сыя алмыйча, өченче урам ясый башлап, киерелеп утырган авылның — кан тамыры корыган. Авылның бетүен сугыш нәтиҗәсенә генә кайтарып калдыручылар ялгышалар: сугыштан соңгы кырык алтынчы, кырык җиденче елларда әле су буйларындагы түгәрәк уеннар икешәр әйләнә була, ә кышын клубларга халык сыймый иде. Халык әле көтә иде: менә-менә эшләгән өчен күзен уңыш бирерләр. Ләкин, юк. Бирмәделәр. Авылны гел бушка диярлек эшләттеләр. Бераздан, дөньялар үзгәреп, колхозчының тамагы тук булырга тиешлеге турында гап-гади бер законны күтәреп чыкканнар иде, карасалар — авыл коргаксып калган. Авыл үлеп ята икән. Ә үлеп ятканда могҗиза би-и-к сирәк була...

Без, улым белән, ул төнне мунча алдындагы ике кешелек диван-караваттта йокладык. Анда сыткый сагыз, каен миллеге исе, яфрак, көзге үләннең баш әйләндергеч исе иде. Йокы кермәде: мунча алдының ап-ак сагызлы такталарында кетер-метер иткән вак тавыш ишетелә. Белеп торабыз инде, бу — колорадо коңгызы урмәли.

— Әти! Әти! Син, чего-то, авыл, авыл дип бик мактанасың. Мин моңа ышандым. Ә бит синең авылыңда иң таза хуҗалык — зират. Калганнары бит беткән. Зират бит ул яшәү өчен түгел. Ә син миңа... «Авылны яратырга кирәк... Авылны сакларга кирәк... Авыл хуҗалыгы институтында укырга кирәк...» Ну, ничек?

Мин аңа җавап бирә алмадым. Кичен, йокыга ятар алдыннан сөйләгәннәр иде: шәһәрдән бик матур бер кыз кайткан, ак «Жигули»га утырып кайткан. Ап-ак чалбар кигән, хикмәтле кофта, ди, аягында биек үкчәле хикмәтле туфли, ди. Зур кара күзлеген бер дә салмый, ди.

— Безнең дедның могиласын кем күрсәтә, расходын түлим,— дип, кып-кызыл унлык чыгарган, ди. Бер малай тапкан каберне. Теге матур апа берүзе зиратка кергән һәм, үләнгә газета җәеп, Сәмигулла кабере янында озак-озак утырган. Имеш, ул — Энҗенең кызы, студентка икән.

Аннан, авылга кермичә үк, китеп тә барган.

...Төнлә, без йоклый алмыйча әйләнгәләп ятканда, авылның борынгы ата-бабасы тавышыдай, зәгыйфь, хәлсез бер моң ишетелде. Кемдер иске тальян тартып азаплана, нидер әйтмәкче, җырламакчы була, ләкин, ни үзенең, ни гармунының моңа хәле җитми. Шулай да, бу хәлсез тавыштан мин кайбер авазларны тотып алам, ишетмәгән өлешен үземчә тутырам.

Җырлыйк әле, җырлыйк әле,
Без Гөберчәк бит әле.
Җырлау түгел еларсың да
Авылыңнан кит әле...

Хәмдүневләрдә бүген туй мәҗлесе булган икән, туйга килүчеләрдән берсе — кода — Курсадан икән, шул җырлый икән. Дөресрәге, җырларга тырышып карый икән.

Төнгә чык төшкән, иренеп кенә көзге чикерткәләр чурлый, көз килә, көз

килә, жиргә моңсулык иңә, шул моңсулыкны кемдер, йөрәк ярасын ачып, канга сеңдерә, теге тальянның иске моңында авыл, аның тарихы ыңгыраша, авыл үзенең үткәне, бүгенгесе белән хушлаша, елый-елый аерылыша иде.

## VIII

*Или, Или, ләма савахфани?*

Сентябрьнең ундүрте көнен картлар элегрәк «Симән көне» дип йөртәләр иде. «Симән көне»— христиан динендә «Җәйне озатучы Симеон көне». Элек 1 сентябрьдә булган, хәзер яңа календарь буенча — ундүртендә. Арыш урагы беткән, кыяр тозлый башларга вакыт, авылда аулагөйләр башлана, бәрәңге әле алынмаган.

Хәзер бәрәңгене беренче сентябрьдән ала башлыйлар. Бу — хата. Шуңа күрә бәрәңге складларда чери, бозыла. Чөнки ул, сентябрь балчыгы астында ятмый торып, тәненә куәт җыя алмый. Ә сентябрьдә бәрәңге ныгый гына әле.

Сентябрь башы, гадәттә, кояшлы була, ләкин инде каяндыр салкынча җил исеп куя, кешеләрне кисәтә: көз килә, әзер булыгыз, ди. Никадәр генә җылы булмасын, ашын ашаган, яшен яшәгән картлар сентябрь башында өсләренә җиңсез сырма киеп куялар, ара-тирә авылның төньягына караштыралар: салкын, кисәтүчән һава дулкыны шул яктан килә. Кояш әле җылыта җылытуын, әмма теге җил гел бәргәләп тора:

— Мин — Төньяктан! Мин — Төньяктан!— ди.

Моны карт-коры бик нык сизә.

Моны авыл мәктәбенең география укытучысы да сизә. Сизә генә түгел — ул аны фәнни яктан аңлый: Төньяк Котып белән безнең Татарстан иле арасында таулар юк. Инде дә килеп, Котыптан бер дулкын көньякка таба уздымы, ул безгә туп-туры килә. Кояш аны, ул дулкынны, юл барышында күпме генә җылытмасын, теге шималь һавасы барыбер безнең авылга килеп керә. Шималь (төньяк) белән безнең авыл арасында котыпның салкын һавасын тоткарлап калырлык бер генә тау кисәге юк...

Шул җылы көннәрнең, инде «салкын кергән» төннәрнең берсе узганда иртән торып ишегалдына чыксаң... Йа, хода! Кичәге ямь-яшел бәрәңге сабагы егылган да калган.

Дөньяда — икенче закон, дөньяда — икенче тәртип. Бәрәңге сабагы исе. Моны аңлый белергә, моны сизә белергә кирәк. Бәрәңге сабагы әле кичә генә ямь-яшел диңгез иде, ләкин сентябрьнең котыптан алган бер көче бар, шул көч сентябрь төненә корал биргән, куәтле ул корал халык күңелен яктыртып нурландырып утырган теге яшел диңгезне — бәрәңге сабагын еккан да салган. Әле кичә генә өскә таба ашып утырган яшькелт бәрәңге сабагы дулкыны кара-кучкылланып, саргаеп калган.

— Сау булыгыз, туганнар, без инде китеп барабыз. Без тырышмадык түгел, тырыштык, ләкин бит яшәүнең дә чиге бар. Без төнге кыраудан егылдык. Бу әле һич тә тормыш туктады дигән сүз түгел. Безнең тамырларда таза, тук бәрәңгеләр. Алар сезгә яшәү өчен куәт бирер. Яз җиткәндә сез ул бәрәңгеләрнең «борынын алырсыз— утыртырга әзерләрсез. Алар — безнең дәвамчылар. Без шулай, җайдан-җайга, көздән-көзгә яшибез. Хәер, сез дә шулай бит. Кешеләр дә үзләре үлгәндә балаларын, оныкларын калдырып, тынычлап үләләр бит. Без менә бу атна буе сезнең белән саубуллашабыз. Бәхил булыгыз, безгә рәнҗемәгез. Без саубуллашабыз...

Саубуллашабыз... Авыл халкы бик яхшы аңлый аны. Сентябрьнең алтын кояшлы бу көннәрендә дөньяны бәрәңге сабагы исе баса.

Инде! Шул ис дөньяга таралган көннәрдәме? Ул көннәр гел кояшлы була, басу-кыр өсләре гел зәңгәр рәшәдә тирбәлә, һавада, баш очында пәрәвез җепләре оча. Авыл тынып калган, анда — урамда — чыр-чу да, тальян тавышы да ишетелми. Дөньяда бер генә нәрсә бар: ул — бәрәңге сабагы

исе. Ул ис башны әйләндерә, йөрәккә кан куа, ул исне ни икәнен белмәгән халыклар сина иң бәхетсез кешеләр булып тоела, ул ис — исертә, бераүләрне шагыйрь, философ, дәрвиш итә, икенчеләрне министр, генераль директор, баш режиссер, ректор, үз дәрәҗәсен үзе белеп яшәүче лауреат итә.

Бәрәңге сабагы исе...

Менә син, җәяүләп, көзге кояш астында, бәрәңге басулары уртасыннан авылыңа кайтасың. Тып-тын. Сентябрь кояшының язгы, җәйге кояшлардан ни белән аерылганын беләсезме? Белмисезме? Сентябрь кояшы башка барлык кояшларга караганда да юньлерәк, юмартрак, әхлаклырак ул. Яз кояшы — кыланчык, җәй кояшы — рәхимсез. Сентябрь кояшы — әдәпле, мөлаем була. Шифаханәдән беренче бәби алып чыккан яшь ана кебек ул: менә мин инде яшь, җилбәзәк кыз түгел, ләкин мин әле яшь, минем әле кешеләргә, җиргә яхшылык эшлисем бар, игелек күрсәтәсем бар, ди ул.

...Мин, Казаннан Ташлытау станциясенә кайтып төштем дә, караңгы төндә юлга чыгарга куркып, вокзал идәненә тәгәрәп йокладым. Ул заманнарда вокзал идәненә тәгәрәп йоклау мөмкинлеге бүгенге көндә башкалага килеп төшеп үзәк кунакханәдән өч бүлмәле «люкс» алу дәрәҗәсеннән зуррак иде. Мин шул бәхеткә ирешеп, рәхәтләнеп йокладым. Дөресе — йоклаганмын. Татар телендә сабыйлар йокысы дигән гыйбарә бар. Тагын әле яшьләр йокысы була, картлар йокысы була. Тагын әле бик карт кешеләр йокысы була. Яшьләр йокысы белән йоклый алган кешеләр, гадәттә, йокы турында сүз алып бармыйлар. Карт кешеләр бу темага бик тәмләп гәп коралар: кем ниндирәк дару йоткан, кем йоклар алдыннан ничә минут һавада йөргән, аннан соң ничек шәп итеп йоклаган... Бик карт кешеләр исә (сиксәнне узган) бу темага бөтенләй кермиләр; алар, режим саклап, сабый баладай шәп итеп, үз вакытында йоклыйлар. Әйе, мин дә ул чакта сабыйларча йоклап уяндым. Идән бераз бушаган иде, рәхәтләнеп киерелеп алдым. Кәеф гадәттән тыш шәп, мина уналты яшь тулды, әле кичә беренче мәртәбә Казан күрдем, менә хәзер, «әһ» тә итмичә, көзге кояш астында егерме чакрымны атлап авылга кайтам, иртәгә — ял көне, шәт, бакчада бәрәңге казый башларбыз. Баш астына салынган киндер капчыкның төнлә үткен пәке белән ярылган булуы да, аннан сыңар күн чүәкнең урланган булуы (шәһәрдә чабата белән йөрмәс өчен алган идем) һәм ни өчендер сыңары гына урланган булуы да мине кызыксындырмады, борчымады.

Кесмәс буеннан югары басуга күтәрелдем дә авылга таба юл тоттым. Мин вокзал идәнендә төн кичергәндә бәрәңге басуларына кырау төшкән икән. Җете, җылы кояш астында алтынсыман басулар тынып калган, дөньяны күе, тыгыз ис — кырау тигән бәрәңге сабагы исе баскан. Күк йөзе чип-чиста, зәңгәр, күк гөмбәзе бик биек, анда-санда тилгәннәр күренә, алар бәрәңге басуларыннан күтәрелгән тыгыз һава дулкынында җай белән генә тибрәләләр. Бәрәңге сабагы исе бөтен дөньяны баскан — бу инде, бер дә шиксез, көз башы дигән сүз иде. Нәкъ менә шул иртәдә — хәтерлим, сентябрьнең уртасы иде — кешеләр бәрәңге казырга чыкканнар, басуларда инде ут та ягып җибәргәннәр. Кызгылт-чия, кызгылт-сары бәрәңге басуы өстеннән, затлы хатын-кыз муенында язгы җилдә тибрәлгән юка ефәк өрфия яулык кебек сыек төтен үрмәли, бәрәңге сабакларыннан аерыласы килмәгәндәй, буразналар өстенә ятып шуыша. Кояш нуры, җир өстенә сыя алмагандай, тыгызланып, бәрәңге басуларын җиргә кыскан, ул басулардан аның саен теге хикмәтле ис күерәк булып, катлам-катлам булып күтәрелә. Мин әле Галимҗан Ибраһимовның «Диңгездә» хикәясе барлыгын белмим, ләкин күңелдә шундыйрак бер фикер, җөмлә уйный, җырлый: «Яшисе, мең, миллион ел яшисе килә...»

Ләкин моңарчы булган кызганыч тән яшәве, тереклек итү белән түгел, башка бер яшәү белән, матур, изге, бөек яшәү белән яшисе килә!

Шул көнне мин, кырау шиңдергән иксез-чиксез бәрәңге басуларыннан таралган затлы иска исереп, бу бәхеткә ирешә алмаган шәһәр малайларын, зур-зур яхшы фатирларда яшәп, йомшак диваннарда тәгәрәп үскән кеше-

ләрне кызгандым. Алар бу бәхеттән мәхрүм бит! Нигә язмыш аларны бу бәхеттән мәхрүм иткән? Аларның ни гаебе бар? Шул вакытта мин тормыш юлында очраган юньсез кешеләрне (алар инде миңа очраштыргалаган иде) уйлап алдым. Алар ни өчен юньсез? Кайсы — хөсетле, кайсы — карак, кайсы — затсыз, тәртипсез. Иң күп очраганнары — хөсетлеләр булды. «Әл-хөсед — мәхрүм» ди гарәп мәкале. Ягъни, кешедән көнләшеп яшәүче кеше — бәхетсез. Бу кешеләр, мөгаен, үз гомерләрендә бер тапкыр да беренче кырау белән егылган бәрәңге сабагы исен кояшлы иртәдә иснәмәгәннәр. Болар әбиләр чуагы көннәрендә зәңгәр күктән очкан ап-ак тожым жепләрен күрмәгәннәр.

Бу иртәдән соң кырык елдан артык вакыт узды инде, теге ис әле дә хәтердә. Әйе, хәтердә. Һәм шул иртәдә яшь миемдә туган теге фикер дә һаман исән әле. Берәр кешенең юньсезлеген күрәм дә, уйлап куям: юк, агайне, син шундый бер иртәне күрми калгансың. Дөрес, студент елларында син бәрәңге казырга колхозга кайткалагансың, әмма бит син ямь-яшел басуда, кырауга кадәр эшләгәнсең. Сез бит бәрәңге басуында учак якмагансыз, әле генә җирдән чыккан бәрәңгене көлдә пешереп ашамагансыз. Сез беренче кыраудан соң басу өстендә бураздаларга ятып шуышып йөргән зәңгәр төтен челтәрләрен күрмәгәнсез. Сезнең күңелегездә, тәнегездә, яхшылык өчен ачылырга тиеш булып та, ачылмый калган күзәнәкләр кибеп калган. Югыйсә... Менә син, агайне, шундый булыр идеңмени? Менә син укыгансың, гыйльми дәрәҗәләр алгансың, ләкин бит үзеңнән соң гыйлемфән дөньясына беркем дә килмәсен дип, дер селкенеп, астан көрәшеп яшисең. Менә син, туганкай, зур урындыкка утыргансың, ләкин бит үз тирәңә ярдәмчеләр итеп гел йомшакларны, булдыксызларны җыясың. Сәләтле кешегә юл бирмисең, үз дәрәҗәңне шул юл белән күтәрергә уйлыйсың. Менә син, яшьтәш, язучы булып киткәнсең, исемнәр, лауреатлыклар алгансың. Ләкин бит һәр хода бирмеш елның өч-дүрт аен икенче бер язучыга шуларны бирдертмәс өчен көрәшкә сарыф итәсең. Гомер бит исәпле! Әй син, иптәш профессор! Син бит «Моны эшләсәм, болай әйтсәм, дәрәҗәм төшмәсме икән?» дип, һәр секундта үзеңне контроль астында тотып, газаплы гомер кичерәсең. Син бит печәнлектән урланган йомырканы бәрәңге бакчасы башында чукып ятучы карга кебек: чукыйсың да, як-ягыңа карап аласың. Халык әйткәнчә: карганың бер күзе укта, икенче күзе... Әй син, иптәш директор...

Хәер, җитәр. Дөньяны болар алып бармый. Дөньяны, җәмгыятьне юньле эчле кешеләр алып бара. Шулай да, минем тирәдә тегеләре — юньсезләре гел очраштыргалап тора. Шуларга карыйм да, гел уналты яшемдәге саф һавалы, тилгәнле, бәрәңге басуындагы затлы исле, зәңгәр төтенле, кояшлы иртәне искә алам, сагынам.

Или, Или, ла́ма савахфа́ни?[1]

И, Язмыш!.. Нигә генә инде син безне әнә шундый иртәләрдән аердың?

## X

*Кил, өйрән, и туган, бер башка телне,*
*Бүтән телләр белү яхшы һөнәрдер.*
*Катыштырма вәләкин телгә телне,*
*Тел уйнатмак наданлыктан әсәрдер.*

Дәрдмәнд.

Фәләхетдин белән без бергә үстек. Ул миннән, күп булса, ике яшькә яшьрәктер. Авыр тормыш кичердек, ачлыкны, киемсезлекне кайсыбыз күбрәк күргәндер — хәзер инде әйтүе кыен. Тик минем аннан бер өстенлегем бар иде — мин бала вакытта ук бик күп китап укыдым.

---

[1] Гайсә пәйгамбәрнең җәзаланып үлгәндә әйткән соңгы сүзләре, имеш: «Йа алла, йа алла, нигә мине ташладың?»

Матур әдәбият миңа яр.ылыкны, гаделсезлекне кичерергә ярдәм итә иде, мин киләчәккә гел якты өметләр белән карап яшәдем. Тарих мине алдамады: 1956 елда партиянең мәшһүр егерменче съезды булып, тормышка яңа сулыш өрде; аннан, мин инде байтак олыгайгач, егерме жиденче съезд һәм Апрель пленумнары кебек тарихи-революцион жыелышлар булды.

Мин әле һаман яшим.

Тик Фәләхетдиннең генә гомере киселгән икән. Ул шактый надан иде, ихтимал, үз гомерендә ул бер генә әдәби әсәр дә укымагандыр. Тормыш авырлыгын сәбәп итеп, ул дүртенче класстан ары мәктәпкә йөрмәде дә кебек, һәрхәлдә, безнең авылдагы башлангыч мәктәптән жидееллык мәктәпле күрше авылга күчү вакытында байтак кеше «юлда югалып» кала иде.

Фәләхетдин этисе белән йә хужалык көтүен көтте, йә жәй буе колхоз басуын мал-туардан, каз-үрдәктән саклады. Инде дә борчак кузакланган чорда... Көннәрдән бер көнне авылда хәбәр тарала: Хөлләбетдин абзый үзенең малае Фәләхетдин белән борчак басуына шалаш корганнар. Димәк, колхоз идарәсе аларга борчак саклауны йөкләгән. Шалаш сүзен безнең авылда үзебезчә әйтәләр: чалаш. Мин уйлыйм ки, безнең авылныкы дөресрәктер: агачларны туры итеп түгел, чалыш итеп утырткач ясала бит ул.

Безнең авыл басуы шул көннәрдә шигъри, өметле бер нурга чума иде. Яшел борчак басуы зәңгәр күккә кояш нурлары аша тоташа да, басу өстендә баш әйләндергеч яшькелт-зәңгәр һава катламы ясала. Шундый көннәрдә борчак басуы жирдән һәм кояштан куәт алып туена, калыная, киерелә. Менә, көннәрдән бер көнне, Хөлләбетдин абзыйның шалашы янында сыек кына төтен күренә; без инде белеп торабыз: Фәләхетдин йомшак, яшел борчакны жыйган да, этисе шуның боткасын пешерә; димәк, аларның бүген тамагы туя. Бәс, шулай икән, димәк, безнең тамак та, шәт-иншалла, туя башлар; бүген төнгә борчак басуына кайсы тыкрыктан, кайсы межадан шуышып сәяхәт ясарга икәнлеге турында көндездән үк планнар корыла, киңәш-табыш ителә. Инде моңа күп еллар узды, яшьтәшләрем миңа бер серне ачкан өчен үпкәләмәсләр дип уйлыйм. Мин үзем төнлә борчак ашарга барганда һәрвакыт «дошман тылына» (борчак басуына) алдавыч һөжүм оештыру планын яклый идем. Ягъни бер-ике малай борчак басуына авыл ягыннан килеп керәләр дә, кычкырып сөйләшә-сөйләшә, ашый башлыйлар. Акрын йөри торган Хөлләбетдин абзый белән юаш Фәләхетдин шул якка китеп, шул тирәне саклыйлар. Әмма шул вакытта отрядның төп өлеше бөтенләй икенче яктан — урман буеннан кереп, иркенләп кузак яра, ашап туйгач, күлмәкне чалбар эченә нык кыстырып, кузакны шунда тутыра. Ашказаны да, күлмәк эче дә калынаеп, авыраеп алгач, әйләнгеч юл белән авылга кайта. Тик бер шарт намус белән үтәлергә тиеш: теге «провокатор»ларга һәркем берәр кулшуч борчак кузагы бирергә тиеш. Бу хәтәр эш — котырту — чират буенча башкарыла иде.

Тук карын белән ятып йоклау... Хәзер әнә медиклар язган була, тук карын белән йоклау зарарлы, «кичке ашыңны дошманыңа бир» дигән булалар...

Теләсә нәрсә әйтегез, теләсә нинди киңәш бирегез, хөрмәтле докторлар, әмма дә ләкин безнең буын кешеләрен андый эшкә этәрмәгез! Беләбез без ач кунуның нәрсә икәнен! Ә менә борчак басуыннан кайтып йоклаган көнне иртәгесен йокыдан торып, атмы, үгезме жигеп, басу юлыннан эшкә барып карагыз әле сез! Дөньяның матурлыгын шунда күрерсез. Әнә ул теге яшькелт басу, әнә аның түрендәге серле шалаш, әнә шалаш янындагы теге төтен. Тамак тук булганда бөтен әйбер ямьле күренә, әле узган төн генә сине куркыткан Хөлләбетдин абзыйның таякка салынган бөкре гәүдәсе дә, нинди материалдан һәм нинди төстә икәнлеген әйтү мөмкин булмаган күлмәк-ыштан кигән

Фәләхетдин дә шул сихри шалаш янында халык әкиятләрендә генә очрый торган серле каһарманнар булып күренәләр. Ә куктән борчак басуына иксез-чиксез кояш нуры агыла: бу нурга, җылылыкка чыдый алмыйча бүртенеп чәчәк аткан билчәннәр, баллы куәтләр һәм кукчәчәкләрдән дөньяга затлы конфет исе таралган, бу ис тәмак төбен җыера, күзгә дым куа.

Безнең авылның урманга таба җәелеп яткан басуында борчак кузакланган кояшлы көннәре кадәр ямьле вакыт, рухи күтәренкелек, хөрлек, матурлык тагын кайда була икән?

Фәләхетдин үсеп буй җиткәнче әнә шунда булды. Ел саен кояш астында — йә шалаш янында, йә басуда.

Унҗурт яшемдә мин авылдан чыгып киттем, озак вакытлардан соң, картайган егет булып, авылга кайттым. Яшьтәшләр турында сораштым. Дөнья безне кырган: сабакташлардан ике егет, колхоз ашлыгын урлауда гаепләнеп, төрмәгә озатылган, берсе шунда үлгән. Тагын берсе йөрәк чире белән инвалидлыкка чыккан; берсе, товар поездына утырганда, аска эләгеп, ике аягын өздергән; берсе, нахак бәлагә тарып, үзенең гөнаһсызлыгын исбат итәр өчен, формалин ашап үлгән... Ә берсе, күп еллардан бирле инде Казан психиатрия шифаханәсендә икән. Тагын берсен үпкә авыруы бәреп еккан...

Фәләхетдин турында сораштым. Армия хезмәтенә алынгач, Фәләхетдин Мәскәү гарнизонына эләккән. Шунда өч ел хезмәт иткән. Менә бәхет! Берәүләр өч ел сопкалар арасында, җансыз чүлдә, тарлавыкта, калын тайга эчендә, бозлы утрауда хезмәт итә, ә Фәләхетдин — Мәскәүнең үзендә. Ничектер командировкага эләгеп, Ленинградны да, Риганы да күргән. Менә бәхет!

Ләкин... борчак басуыннан зур шәһәргә кисәк сикереш аның башмиенә авырга туры килгән һәм Фәләхетдин хезмәт срогы тәмамланганда әти-әнисен дә, туган авылын да онытып. Мәскәү тирәсендәге шәһәрчекләрнең берсендә ашханәдә эшли торган бер кыз — Валентина белән танышкан. Ә тегесе әйткән:

— Ул фәкыйрь авылыңа кайтып нишләрсең? Әйдә, минем абзый сине экскаваторчылар курсына урнаштыра, укып чыккач, акчаны көрәп алырсың, безнең квартирабыз якты, телевизорыбыз бар,— дигән.

Фәләхетдин «телевизор» дигәнне аңламаган, әмма беркөнне, увольнение алып боларга килгәч, өй эчендәге тере киноны күреп телсез калган.

Валентина һәм аның тол әнисе Фәләхетдин моңарчы күрмәгән, ишетмәгән окрошка дигән аш «пешергәннәр», ни хикмәт, әлеге ашны аның алдына суытып куйганнар. Аш алдыннан дип кара пыялалы шешә белән эчемлек биргәннәр, «Мартовское пиво» дип язылган, ди. Һәм егет төп мәсьәләдә ризалыгын белдергән.

Аннан соң Фәләхетдин, үзенең бу карарын хәбәр итәр өчен, авылга картлар янына кайткан. Кайтса — тегеләрнең икесе дә авыру, ди. Ягарга утын исәпле, абзар-кура тузган, капка җимерелгән. Өй дә авышкан, почмаклары черегән, матча башларыннан яңгыр үтә, ди.

Фәләхетдин картларга бүләкләрен биргән: ирләр күлмәге, шыгырдап тора, төрелгән, ди. Галстук (Валентина оештырган бүләкләр), яхшы хром перчаткалар, карчыкка — һәйбәт йон фуфайка һәм... яхшы исләмай.

Хөлләбетдин абзый да, карчыгы да бер мәлгә тынсыз калалар. Шуның өстенә малай бер авыз сүз эндәшми, икенче көн үткәндә нибары бер җөмлә әйтә:

— Я ваш язык забыл,— ди.— Я женился,— ди,— скоро уеду от вас,— ди.

Карт белән карчык телсез калалар.

Малай авылына хатыны кушуы буенча гына кайткан икән.

Хөлләбетдин абзый иртәгесен, таягына таянып, күрше Масра авы-

лына чыгып киткән. Ә анда аның апасының улы, гайяр егет, ил-җир күргән Фәтхулла яши. Ташлытауда финагент булып эшли, торуы — гаиләсе белән — Масрада икән.

...Фәтхулла шул көнне кичке якта ук атка утырып килеп җитә. Атын җимерек капканың ходай ярдәме белән исән калган баганасындагы күгәргән боҗрага йөгән тезгененнән бәйли дә йортка керә. Какшау өстәл кырында ата белән малай утыра. Хәмдениссаттәй ыңгырашып ян сәкедә ята.

Дүрт ел авиация частьләрендә хезмәт итеп, дөнья күреп кайткан Фәтхулла хәл-халәтне шундук чамалап ала.

— Ну-ка, чыгып сөйләшик әле,— ди ул кырыс тавыш белән.— Ә син, дәү абый, җиңгине борчымыйча гына, самавыр куя тор.

Чоланга чыгып, тәмәке кабызалар. Тынлык. Фәтхулла Фәләхетдин сыен — «Метро» сигаретын еш-еш суыра. Аннан риза булмыйча, кесәсендә капшанып, ачыргын — «Аврора»ны чыгара. Анысын кабыза. Фәләхетдин дәшми. Бер-ике минут шулай төтен чигәләр. Ләкин гел болай торып булмый бит инде. Фәтхулла кинәт кенә сигаретының очына төкереп табан астына баса да, таза кулы белән Фәләхетдиннең күлмәк якасыннан чытырдатып умырып-җыеп ала, битен биткә терәп ырылдый:

— Син нәрсә... (боларын язып булмый), син нәрсә, ә?! Син нәрсә? Атаң-анаң телен оныттыңмы? Нигезеңне оныттыңмы? Каян чыкканыңны оныттыңмы? Мин сине... Майть! Изәм мин сине! Үз телеңдә сөйләшергә хурланасыңмы? Майть! Үтерәм! Бетерәм мин сине, халык моның өчен мине судка бирмәс! Ата-анаңны оныткан син падланы бетергән өчен миңа чуртым да булмас!..

Фәтхулла дер-дер килә. Фәләхетдин агарына, ләкин дәшми.

Шул вакыт чоланга, ыңгырашып, Хәмдениса түти чыга һәм җыерылып, сыкранып Фәтхулланы ачулана.

— Ай-й-й... Син килеп кергәч тә йөрәгем сикергән иде аны. Ник бәйләнәсең малайга? Бөтен нәселегез шундый булды. Безнең якка кара дошман булдыгыз. Ник кул күтәрәсең син аңа? Бала бит әле ул. Ачылыр, теле дә ачылыр. Бик кара эчле нәсел шул сез. Гомер буе безнең якка дошман булдыгыз...

Фәтхулла, өйгә дә кереп тормыйча, төкеренеп чыгып киткән һәм атны Масрага җиткәнче, күбеккә батырганчы куган, ди.

...И гомер! Хөлләбетдин абзый белән Хәмдениса җиңгинең каберен дә белүче юк инде хәзер. Кышын аларның нигезе аркылы бураны төягән трактор узган да, соңгы истәлек булган карт шомыртны изеп киткән. Җәен инде тигәнәкле, чокырлы бу урынга бозау да арканламыйлар икән. Кемдер, каядыр — санаторийгамы барганда, әллә шул ук Масра Фәтхулламы — имеш, белешмәләр бюросыннан эзләтеп, Фәләхетдинне тапкан. Сүнеп, Хөлләбетдин абзыйның исемен дә онытып барган авылга хәбәр кайткан. Хәбәр — шаккатырлык.

Имеш, Фәләхетдин экскаваторда эшләп бик күп акча туплаган, Мәскәүнең «Юго-Запад» дигән районында өч бүлмәле яхшы кооператив фатир алган. Ни хикмәт — ике баланың икесе дә укуга хирес булып чыкканнар. Беренче улы, Мәскәү университетының биология факультетын кызыл диплом белән тәмамлаган да, Фәннәр академиясендә эшли, ди, торналар буенча инде ил күләмендә танылып килүче яшь галим, ди. Кызлары исә — артык чибәр, тыйнак һәм әхлаклы зат — курслар тәмамлап, халыкара авиалиниядә стюардесса булып эшли, ди. Фәләхетдин белән энисе Валентинага бер кайтканда — ананас, кокос чикләвеге сөте, икенче кайтканда — эчена тере елан тыгып ясалган файдалы эчемлек, өченче кайтканда Цейлонның үзендә үстерелгән, үз фабрикасында эшкәртелгән чын чәйне яшел калай тартмада килолап алып кайтып тоттыра, ди.

Фәләхетдин чын мәсквич, ди, ял көннәрендә стадионга йөри, ди,

футбол караганда гомер буе ЦСКА өчен «авырган», ди. Адрес бер ачылгач, ярты еллардан соң Мәскәү аркылы үзганда Фәләхетдиннәргә тагын кемдер кереп чыккан.

Бичара Фәләхетдин... Терелмәслек авыру эләктергән дә, кинәт кенә урынга егылган, ди. Авылдашына мөлдерәтеп карап, саф татарча әйткән ди:

— И, туганым... Безнең авылның урман юлындагы басуда үскән бер генә уч яшел борчак җибәрә алмассыңмы, сәламы-билчәне белән,— дигән.— Шуны ашасам, терелермен кебек. Төшләремдә гел шуны ашыйм, иртән торгач утырып елыйм.

Туганы моны эшли алмаган: карлы көз икән инде.

Фәләхетдин салкын декабрь көненде үз өендә, янында хатыны һәм балалары утырганда җан биргән.

— Бәхил булыгыз,— дип саф татарча әйткән, ди.

Нәкъ безнең авылча әйткән.

## XI

*Со мной следуй,*
*И обретай в пути,*
*И ведай*
*За далью — даль.*
*За далью — даль!*

А. Твардовский, «За далью — даль»

«Казан — Шәмәрдән поезды» дигән игелекле бер поезд барлыкка килде. Кайчак илле дә акыллы, игелекле эшләр эшләнеп куя! Элеккеге елларда Арчада, Курса разъездында, пассажир поездларының баскычларына асылынып, товар составының тормоз баскычларында туңып-өшеп, ревизорлардан тотылып, штрафлар түләп, шпаналардан таланып, алардан куркып сикереп, шунда авыз-борын канатып, тез башларын суйдырып, кулларны каймыктырып йөргән көннәремне исемә төшердем дә — җәйге болыт арасыннан кояш караштыргалаган җылы, парлы бер көндә, шул поездга утырып, Шәмәрдәнгә киттем. Бер йомышым юк, бу дөньяда минем бер эшем юк, мин ялда, бүген мин беркемгә дә кирәк түгел, бүген мин — үземә-үзем хуҗа. Тукай әйткәнчә: «Тик икәү без: уй да мин».

Тарих! Дөньяда иң бөек нәрсә — син! Син тузмыйсың, байыйсың гына. Мин элекке, үткәндәге истәлекләрне, борынгы корылмаларны яратам. Тормыш бик тиз үзгәрә, кешеләр дә бу дөньядан бик тиз китәләр. Кеше дөньяга туып аңлы рәвештә яши башлаганда, дөнья аны биетә башлый.

Мосафир, кем җиһанга басты ботны —
биетте ажгыртып аны замана...

Дәрдмәнд

Менә бу тимер юлда 1936 елдан нинди истәлекләр бар? Ул елны эти, безне туйдырырга дип, Казаннан ипи ташый иде. Урманнан яз көне ылыс алып кайта да, пасха бәйрәмендә ылыс сата. Шуның акчасына ипи ташый. Анысы — язгы су, юл өзеге вакытында. Көзен — шалкан өлгергәч, шуны күтәреп китә. Ул вакытта дөньяда иң арзан нәрсә — шалкан иде. «Арзан» дигән сүз урынына ул елларда «шалкан бәясе» дигән гыйбарә йөри иде. (Әле мин юлга чыгар алдыннан гына базарга кердем. Кечкенә генә бер шалканның бәясе 70 тиен. Ягъни бер шалкан бәясенә өч кирпеч «Орловский» ипи алып, калган акчага бер стакан катык яки сөт алып эчәргә була). Чак күтәреп барган ярты капчык шалкан акчасына өч-дүрт ипи килә, дип сөйли иде кешеләр. Ул чордан ниләр калган тимер юл буенда? Әнә алар — Биектау, Арча вок-

заллары. Курса разъезды. Шәмәрдән станциясенең корылмалары — тарихка чумып, моңга уралып, поездларны дәшмичә генә озатып калалар. Болар утызынчы елларда ук салынган, мондый биналар Мәскәүдән алып Чита, Хабаровск, Владивостокка кадәр сузылган юлларда бик күп. Болар безнең ипи ташыган этиләрне хәтерлиләр, бер дә үзгәрмәгәннәр, аларның тик тышкы буяулары гына яңарып тора. Менә юл өстендәге чиркәүләр — Иске Чуриле, Төбәк Чокырча чиркәүләре. Усал Иван патша Казан елгасы буендагы мул суны, болынлы урыннарга шулай чиркәүләр сала-сала килгән. Бу авыллар заманында гөр итеп — йорт сырасы, сало ясап, гөмбә тозлап, пасха, троицаларны билгеләп, чиркәүләрдә җырлап, әйләнә-тирәдәге татар белән әвәрә килеп яшәгәннәр дә, бөек Ватан сугышыннан соң кинәт җегәрсезләнеп калып, бушаганнар. Хәзер инде анда күрше-тирәдән күчеп килгән татарлар яши. Авылларның калку урынында ятим чиркәүләр моңаеп утыра. Әйтерсең лә, Усал Иван бабайга рәнҗиләр алар: «Безне ник монда китереп салдың да, үзең үзәктә яшәдең, менә без хәзер нишлик?» — дип еламсырап утыра сыман алар. Хәтерлим, авыл агайлары сөйләшә иде: «Берзаман, томан басылгач карасак, Төбәк Чокырча чиркәве күренә. Әһә, без әйтәбез, Арча стансасына килеп җиткәнбез икән». Яки: «Арчада билет сатмыйлар гына бит, малай, ылыс белән гүпчим дә вагонга кертмиләр. Шуннан, Иске Чурилегә таба китеп... Чуриле чиркәве турысыннан стансага ярып төшеп. Һи-и, бу ипи ташыйм дип инде-е...» Чиркәүләр дәшми. Аларның иске гөмбәзләре безгә карап, дәшмичә генә, безне сынап утыралар: «Менә сезнең бабайларыгыз мәчетне агачтан салган. Ул мәчетләр җилдә, яңгырда тузган, янгында янган, аларның манараларын да кисеп төшерү җиңел булган. Ә менә без — чиркәүләр — таштан, кирпечтән. Безне заман да, мәгънәсез, аңсыз кешеләр дә җиңә алмый. Безне салганда поплар приход халкыннан фәлән мең данә тавык йомыркасы җыйганнар, измәгә шуны кушканнар. Менә без утырабыз да утырабыз»,— диләр сыман карт чиркәүләр.

— Беләбез, беләбез, синең этиеңне. Бөкрәя төшеп, аркасына уналты-унҗиде кирпеч ипи күтәреп поездан чыкканда без аны: «Йә, шулай казганасың инде син, әмма ул балаларыңнан картлыгыңда игелек күрерсеңме?» — дип кызганып кала идек.

Чиркәү гөмбәзләре шулай сөйли. Эти үз балаларыннан игелек күрер көнгә кадәр яшәмәде.

Алар гына түгел, Арча станциясендә ул заманнан калган су башнялары, элеватор, купец Стахеевларның икмәк амбарлары да бар икән әле. «Арча станциясеннән кышкы буранда чана тартып ипи алып кайтканда хәл алырга туктагач, мин — ярты ипи ашыйм, Әхмәдулла ике кирпеч ярым ашый»,— дип сөйли иде эти. Шуңа күрә безнең өйгә ундүрт ярым, яки унбиш ярым ипи кайта иде (исәп белән тотканда ике атнага), Әхмәдулла абзый өенә утыз ике ярым (ул гел утыз бишне ала икән) кайтып торды. Атна беткәндә ул тагын юлга чыга иде. Аның өендә малайлар күп: барысы да, оядагы саескан балалары кебек, дәү авызларын ачып, көннәр буе этиләрен көтеп, Арча юлына карап торалар.

— Чуматай тавын менгәндә Әхмәдулланың борыныннан кан китте,— диде эти бервакыт, буранда кайтып кергәч.— Кар жепшек, чана астына тыгыла.

Җитмеш алтынчы елдамы икән, райком, редакция кешеләре белән, Арча элеваторына кердем. Баштарак ышанмыйча тордым: элеватор ишегалдында, шәһәрнең кечерәк кенә бер урамы кадәр җирдә, зур, биек тау — бодай тавы.

— Элеватор директоры чәчен йолкый, икмәкне кая куярга белгән юк,— диделәр.— Мондый булып уңган икмәккә элеваторың да чыдамас, моны ташырга вагонның да җитмәс,— диделәр.

Өстә сыек болыт йөзә: соры болытлар, заманча кызларның туз-

гыган чәчләре кебек рәтсезләнеп, элеватор һәм су башняларына кагылып узалар: кара, майлы шпаллар, тирләгән сыман булып, яңгыр тамчыларына бизәлгән, дөньяны дым баскан иде. Без бала вакытта, яңгыр килә башласа, бөтен авылны аякка бастыралар, ындыр табагындагы соңгы бөртек түбә астына кереп беткәнчә, халыкны кайтармыйлар иде. Ә монда? Колхозчы тир түгеп үстергән икмәк шулай яңгырда әрәм буламы? Бу ни хәл бу?

Икмәккә байлык — зур шатлык. Бодай тавы янында мин шуларны уйлап тордым. Шул арада элеватор янында үзем туган авылның колхоз председателен очраттым. Колхоз кешесенең бер гадәте бар: икмәк көшеле янына килгәч сүз башлаганда ул, һичшиксез, башта бөгелеп учына орлык ала (бодаймы, арышмы, борчакмы — барыбер) һәм, бер дә шиксез, шуны теш арасына кабып кетердәтеп карый. Ашлык көшеле янына җәен күп затлы машиналар килә, ул машиналар эченнән, шома битле, пөхтә киенгән чибәр ирләр чыга — икмәк көшеле янында үз гомеремдә, бигрәк тә бала чакта, күп булырга туры килде — әнә шунда бу чибәр егетнең авылданмы, әллә шәһәрдәнме икәнен күрсәтүче бер генә хәрәкәт бар: шәһәрдән чыккан кеше икмәк көшеленә беркайчан да үрелми һәм үзенең чиста, матур авызына орлык бөртеген алып теш арасында сытып карамый; авылдан чыкканы — ник шунда президентның үзе булсын,— һичшиксез, иелә һәм орлыкны кабып карый; шуны эшләмәсә, көшел янында ул сүз башлый алмый. Безнең председатель дә иелде, ул да бодайны керт-керт итеп тешләп карады, әйтерсең, йөз меңләгән тонналы шушы бодай тавының бөтен сыйфатына ул җаваплы иде...

Мин форсаттан файдаланып калдым:

— Колхозчыларга икмәк сатасызмы? — дидем. Председатель сөйли:

— Колхозчының быелгы кадәр икмәкне моңарчы алганы юк иде,— дип елмая.

Шунда минем хәтеремә утыз алтынчы ел һәм Чуматай тавында борыны канаган Әхмәдулла абзый килде. Аның өч улының колхозда эшләгәнен белә идем. Кызык өчен сорап куйдым:

— Әхмәдуллиннар күпме алды, әйтә алмассыңмы?

— Ник әйтмәскә, әйтәм. Кичәсе ике тонна ярым бодай алды.

Шул урында председательне райком секретаре бүлдерде. Хәер, мина да инде әлегә башкача бер информация дә кирәк түгел иде. Әхмәдулла абзыйның кичә малае ике тонна ярым бодай алган! Нәрсә бу? Безнең авылның җире киңәйгәнме? Теге еллар белән чагыштырганда артыграк, хикмәтлерәк яңгырлар яуганмы, кояш башкачарак җылытканмы? Ник теге вакытта Казаннан ипи ташылган, нигә хәзер Әхмәдулла малае алган бодаен кая куярга белми җәфалана? Мин моңа җавап биреп бетерә алмыйм.

«Чишмә» колхозы председателе Ясәви Хөсәенов сөйли:

— Узган ел бик явымлы килде. Комбайннар чыга алмый. Комбайнчыларның ишегалдындагы кош-корты иянләнгән: хуҗа кайтып кереп аяк киемнәрен салганда, баскыч төбендә гел шуның тирәсендә бөтереләләр. Аяк киеменә иярәп кенә булса да ярты кило орлык кайта, күнитек булганда — артыграк та. Тавыклар иянләнгән, хуҗаны шатланып каршы алалар. «Иптәш Хөсәенов, чыгыйк инде уракка,— ди бер көнне бер комбайнчы.— Тавыклардан оят,— ди.— Кайтып керәм, итекне салам, бичаралар, кычкырып җылыйлар...» — ди.

Мин, әлбәттә, тагын бер хәлне хәтерлим: дөнья юньлесе, эшлекле, әдәпле чисълыклы (бу сүз Казан артында чисталыкны яраткан кешегә карата кулланыла) Шәргыя җиңги бар иде. Кырык өченче ел җәенең эссе, тынсыз, ач бер көнендә председатель, районнан килгән вәкил, прокурор хатын һәм сәламәтлеге буенча армиягә алынмаган, ләкин дә колхоз амбары тирәсендә бик әйбәт көн итеп яткан Фәсхетдин урактан кайтучы хатыннарны ат абзары янында тентеп, Шәргыя

җиңгинең... фәлән-фәлән урыннарыннан бер кушуч арыш бөртеге табып алдылар. Амбарга алып кереп үлчәделәр, ике йөз грамм килде. Шәргыя җиңги, бичара, шул көнне юк булды. Малае фронтта иде. Малай кайтты, әнисе — шул юктан юк булды...

...Поезд Арчаны чыгып киткән икән. Төбәк Чокырчаның җимерек чиркәве, Казан арты тимер юлы буендагы соңгы чиркәү булгангамы, аеруча ятим иде; әллә инде поезд ашыгып чапканга үпкәләп, әллә инде үз язмышына рәнҗеп, моңсу карап, артта калды. Сул ягымда Курса болыны, Курса басулары иде. Поезд никадәр ашыгып чапса, хәтер шулкадәр тизрәк эшләде... Әйе, 1943 елның котчыккыч рәхимсез, эссе, коры ач җәе. Курсалар аеруча ач, алар һөнәрле түгел, урманнары юк, суда балык беткән. Хәер, Казан артында балык тоту кәсебен бөтенләй белмәгән авыллар байтак. Шул көннәрдә район газетасында хәбәр күренә: «Батыр Курса» колхозында игеннәрне суктырганда югалтуларга юл куела, орлык башакта кала». Ул елларда мондый хәл Ватанга хыянәт дәрәҗәсендә зур итеп карала иде. Берничә көннән ишетелде: район җитәкчелеге, ашыгыч рәвештә, Курса колхозына дүрт җаваплы иптәштән торган бригада җибәрә. Болар, бөтен халыкны аякка бастырып, сугылган ашлык эскертләрен сүттереп, биш көн-төн буена атлы молотилкадан саламны кабат уздыралар. Халык эшли, сүз әйтми. Һәм эшнең нәтиҗәсе дә күренә: көне-төне суккан саламнан уналты килограммга якын бөртек җыеп алына. Бу бит инде икмәк! Бу турыда хәбәр ителә. Ләкин агай-эне монысын да уйлап куя: районнан килгән вәкилләргә колхоз, тегеләй итеп, болай итеп, ашына он, бәрәңге, җан башына сигез йөз грамм ипи бирми калмый иде. Алай-й... әгәр исәпләсәң, дүрт җаваплы иптәшнең биш көн буена ашаган икмәге нәкъ уналты мең грамм, ягъни төгәл бер пот килеп чыга икән бит. Аш онын, бәрәңгене исәпләмибез, биш көн-төн буе кабат сугуга киткән кеше көчен, ат көчен исәпләмибез...

Икмәк мәсьәләсен алай хәл итеп булмый.

Аны кырдагын «башак җыю» белән дә хәл итеп булмый. Утызынчы еллардан алып алтмышынчы елларга кадәр, безнең матбугат «Башак җыялар» дигән дистәләрчә мең мәкалә бастырып чыгарды.

Бу болай эшләнә. Була зур бер урта мәктәп, ул елларда өч йөз балалы урта мәктәп иң кечкенәләрдән санала иде. Әйе, була шундый мәктәп, чиста киемнәрен киеп мәктәпкә дәрескә җыелган балаларга кинәт кенә әмер бирелә:

— Кырга башак җыярга чыгабыз!

Биш йөзләгән бала, егермедән артык укытучы, фәннәрне бер читкә куеп торып, сентябрь кояшы астында көне буе башак җыя. Зур коллективның зур инде: көне буе эшләгәч, басу уртасында печән чүмәләсе кадәр башак өеме күтәрелә. Пионервожатый, межага утырып, район газетасы өчен мәкалә дә язып ташлый: «Башак җыялар» дип атала бу мәкалә. Икенче көнне, директор карап торганда, әлеге башакны ындыр табагына алып кайтып сугалар. Бөтен бер урта мәктәпнең, ярты мең кешенең хезмәт җимеше — алты кило ярым ашлык бөртеге. Ә алдагы елда югары уку йортына кабул итү имтиханында утыручы — чесуча күлмәк, ак киндер чалбар, акбурга буялган киндер ботинка кигән, күне таракан ашаган сыман шадраланып тузган иске портфельле, таушалган, илленче еллар доценты — кырда башак җыйган әлеге абитуриент егет-кызның канын эчәчәк:

— Ничек инде, сез, «Евгений Онегин» әсәре турында Виссарион Григорьевич Белинский фикерләрен белмәгән көе, филфакка киләсез?

Яки:

— Бер центнер бодай ясалсын өчен җирдә ничә килограмм азот, күпме фосфорит һәм калий булырга тиешлеген белмәгәч, мин сезгә нинди билге куйыйм? Ә бит сез авыл хуҗалыгы институтына килгәнсез...

Шулай инде, акыллы кешеләр икмәкне гомер буена алга, киләчәккә карап үстергәннәр: җиргә ашлама кертергә, җирне яхшырак эшкәртергә, вакытында чәчәргә, вакытында урып-җыярга. Арт якка карасаң, шул: башак җыясы, иген басуына чыккан каз-үрдәкне куып алып кайтып, колхоз подвалына ябасы, теге каз-үрдәк ике-өч тәүлек акырып ятып эштән чыккач, бөтен авыл хатын-кызы шуны тыңлап кешелектән чыккач, подвал янына кемнедер бастырып, зур, әһәмиятле бер эш эшлисе:

— Шәмсиевләр? Унсигез баш каз. Яздым.

— Җиһановлар? Ике оя. Егерме алты баш. Яздым.

Казлар — «Га-га-га!», үрдәкләр «Бак-бак-бак!» килә.

— Ногмановлар? Утыз сигез үрдәк! Ал-ла! Вәт штраф!

...Поезд инде Курса почмак басуыннан бара икән. Хәтер... Ярый әле, кеше тормышында син бар. Син булмасаң, кешеләр азынып, әллә ниләр эшләп бетәрләр иде. Ярый әле син — Бөек Тәрбияче бар. Әйтик, менә моны искә төшерер өчен.

1947 елның җилле-сулы шыксыз апреле. Суык дигәнең ач кешегә аеруча каныгучан була. Хәер, суык кына түгел. Ач кеше янында һәрвакыт, якын күрше булып, бет йөри; тиф, корчаңгы, парша (таз) авырулары яши. Соңгыларыннан, бөтенләй үк булмаса да, без әле азат, әмма — ачлык. Тамак ачуның иң үзәк өзгече — язын су киткәндә, тау башларыннан җир исе чыкканда. Салкын җил исә — күрәсең, сука суыгы җиткәндер, төньяк җиле вокзал артында җыелып торган мазутлы суларны шадраландыра, сабакташым Мансур белән минем ач үзәкне өзеп, муеннан кереп, балактан чыга торган шәфкатьсез җил исә. Без әле генә станция ларегыннан сатып алган черек бәрәңге күмәчен ашап утырабыз. Без моны биш сумга алдык. Без аның исемен кыскартып сөйләшәбез — ЧБК. Моны тигез итеп бүлү минем өскә төшкән иде: чөнки биш сумның өч сумы миннән булды. ЧБКне кыл урталай ярып бүлгәндә бер матавык чыкты — нәкъ үзәктә, түгәрәкнең эченә аркылы ятып, озын бер корт җәйрәп пешкән иде. Моны бүлгәндә мин югалып калдым һәм, ичмаса үзем генә күреп калыйм дип, читкә борылып утырдым. Мансур исә барысын да күргән икән: гадәттәгечә, чикы-чикы килеп көлде.

— Барыбер бит инде, әйдә ашыйк.

Аннан, товар поездының тормоз баскычына эләгеп, ач, коры басулар аша, Арчадан Курсага таба җилләп кайттык. Курса почмак басуында товар поезды үр менә, йөрешен акрынайта, шул урында без, сикереп, чуерташлар, узган елгы тигәнәкләр арасына тәгәрибез. Битбашны кагабыз, без — исән, тамак та... ну, тук дип әйтик инде.

Басу аша түбәнгә — Кесмәс үзәненә таба җырлый- җырлый атлыйбыз. Җир өстендә тузанлы коры җил исә, төньяктан кара-корыч болытлар безгә таба килә. Дөньяда апрель ахыры суыгыннан да шыксызрак суык юктыр. Һәм шулай уйлап барганда, җылы җәйләр, туячак тамаклар турында матур хыяллар эчендә атлап барганда, җете күзле Мансур кинәт кычкырып җибәрә:

— Борчак!

Мин әле аңламыйм, чөнки безнең якта «борчак» сүзе «ялган» сүзен алыштырып килә. Тагын шунысы бар: узган җәйдә, бик ач бер көндә, бөтен урам малае җыелып, ипи нинди була, аны тешләп алганда авыз, борын, теш, тел ни хәлдә була — шуны сөйләшеп утырганда, Мансур кинәт кенә «Дисәнә» көенә (бу көйне 1938 елда авылга беренче тапкыр патефон кергәч ишеткән идек) кычкырып җырлап җибәргән иде:

Кайчан борчак кузакланыр, дисәнә;
Кайчан борчак кузакланыр, дисәнә...

Кушамат тагарга аеруча зур сәләткә ия булган безнең авыл малайлары, шул көннән башлап, иренмәгән вакытта Мансурны, үз исеме белән түгел, «Кайчан борчак кузакланыр» дип йөртә башлады.

— Борчак! — дип шатланып чикылдады Мансур тагын бер мәртәбә. Җиргә иелсәк — балчык катмарлары арасында, чыннан да, борчак! Без борчак чәчелгән җирдән барабыз икән, яңгыр булмаганлыктан, чәчкән җир җиллә гән, борчак күмелеп бетмәгән. Бәхет басты!

Һәм без, очып барган көтүеннән имгәнеп төшеп калган чәүкә балалары шикелле, мәрхәмәтле җиргә кадалдык. И ашыйбыз тузанлы борчакны, и ашыйбыз! Бу бит — бәхет. Инде сусата да башлады. Теге кара-корыч болытлар да Шәмәрдән урманы ягына кереп югалды, салкын җил дә туктады, кояш та җылыта башлады. Җир — мәрхәмәтле, җир — үзебезнеке. Тик менә... колхозда орлыкка калган борчакны язын формалин сыекчасы белән эшкәртәләр иде. Формалин — яңа нәрсә, ул колхоз башлангач кына авылга керде, ничәмә ничә кешенең саксыз эш итүе аркасында, формалинлы орлык ашап, сарыгы, казы-тавыгы үлде. Туктале, без дә харап булсак?

Кыр уртасына басып, тиз генә үләргә план кора башладык. Тә-әк... Мансур кайгырмый — ул дөм ятим малай. Син үлгәнгә кайгырып җыларлык әти-әниең булмагач, үлүнең нәрсәсе бар аның? Арчада үлдең ни дә, Курса почмак басуында — ни? Мин исә, бу дөньяда бик күп хәсрәт күргән әнине кызганам. Инде минем дә фаҗигалы үлүемне ул күтәрә алмас. Алмас...

Шулай, минем тормышны гына булса да саклап калу максатында түбәнгә, Кесмәс елгасына — су эчәргә торып йөгерәбез. Курса Почмак авылына кермибез. Авыл урамында кеше барында үләсе килми. Ләкин юл өстендәге Иске Му авылына кермичә Кесмәскә чыгып булмый. Бу авыл урамына кереп үлү куркыныч түгел, болар ачлык белән туклыкның нәрсә икәнен бу тирәдә иң яхшы аңлаган халык. Кырык икенең җәендә болар һич тә аптырап тормыйча... туп-туры бака ашый башладылар. Ә Кесмәстә бака күп. (Анда бака әле дә күп, суы бетсә дә күп). Иске Му халкын удмуртлардан чыккан дип сөйлиләр, аларны «ар» дип йөртәләр. Бака ашаулары турында хәбәр таралгач карчык-корчык сөйләнде:

— И, ходаем, аларның диннәре икенче шул. Аларга ярый шул... (Кая инде икенче булсын, мәчетләре, мулла-мөәзиннәре булган элек).

Шулай курыкмыйча, Иске Му авылына кердек. Елгага таба кызу-кызу атлап барыш. Тик... елгага төшеп җитә алмадык без. Бер капка төбендә, эскәмиядә, күрәбез — алты-җиде кыз, чыркылдашып, уен-көлке сөйләшеп утыра. Тә-ә-эк... Унбиш-уналты яшьлек кызлар. Безгә күпме? Уналты, унҗиде. Тә-ә-эк... Андый вакытта нишлисе? Кызлар күргәч? Казан артында гадәт бер генә — кепканы, бүрекне кырынайтыбрак киясе. Егетлекнең иң беренче билгесе ул бездә. Һәм без, иске кепкаларны кыйгайтып куйдык та, туп-туры кызлар ягына юл алдык. Китте сөйләшү, көлешү, төрттерү, мыскыллау, ихахайлау...

Без кузгалып киткәндә кояш батып килә иде, бер-ике кыз безне әле авыл башына кадәр озата да барды. Өйгә кайтып җиткәндә генә искә төште: фу, шайтан, Кесмәстән су эчәргә онытканбыз бит, эчкә формалин кергән булса нишләрбез инде?

> ...Поезд ыргый таныш урманнардан,
> Тәгәрмәчләр шаулап баралар,
> Уйлар һәр очраган ак каенның
> Ботагына асылып калалар...
>
> Һ. Такташ

Еракта Сикертән басуы күренеп калды. Сугыш вакытында без бу авыл мәктәбендә укыдык. Сикертән халкы ул елларда аеруча кыен хәлдә иде — колхоз сугыш чорына хәлсез керде. Иртәнге салкында без,

үрдәк бәбкәләре кебек тезелешеп, карлы юлдан мәктәпкә таба атлыйбыз, кырда безнең каршыга сабакташыбыз Сәләхи очрый. Капчыгын аскан, түбән караган. Без — әшәке:

— Сәләхи, кая барасың? — дип сорыйбыз.

— Минә теш сызлый, совхозга врачка барам.

Без сабактан кайткач әниләр сөйли:

— Сәләхи йөрде бүген авыл буйлап. Он бирүче булмады, бәрәңге биргәләдек.

Ата-ананың бөтен курыкканы шул иде ул елларда:

— Балаларны хәер эстәргә генә чыгармасак иде...

Сәләхи белән без хәзер сабан туе саен күрешәбез: таза йорт-җирле, келәтендә берничә тонна запас бодайлы, бура тикле сыер-таналы, йөзләгән кош-корт асрап яшәүче бай колхозчы ул. Мин аның байлыгына бик шатланам.

Укучы! Казан — Шәмәрдән юлыннан узарга туры килсә, урман эчендәге бер разъездга игътибар ит әле. Ул разъездның әйләнә-тирәсендә инде поселок барлыкка килгән. Буяулы, верандалы, умарталы, мунчалы хуҗалыклар. Хуҗалар йорт салалар, байыйлар, бала очырталар, үләләр. Йортка икенче хуҗа килә, йортны үзгәртә, борып куя, сүтә, сата, яңаны сала. Ә вокзал — мәңгелек. Барысын да хәтерли ул. Курса разъезды бик күп хәсрәт-кайгыны көнбатышка да, көнчыгышка да уздырган. Сугыш вакытында монда паровоз топкаларына утын төяделәр, урман чыгардылар, монда озын авыр хәрби составлар пошкырып узып торды. Сугыштан соң монда леспромхоз эшләде, аның исә ике җирдә ОРС кибете, мәктәбе, буфеты бар иде. Разъездга халыкны ипи тартты. Авыллар бушады, разъезд үсте. Билчәнле басуларны, кара, дымлы урманны кичеп чыккан авыл кешесенең борынына иң башта разъезд кибетендә карточкага бирелгән, карточка бетерелгәч ОРС кибетендә исемлек белән бирелгән ипи исе бәрелә иде; аннан соң гына күз, колак эшли башлый. Күз — тау-тау агач өемнәрен, кара майлы паровозларны, җилкәсенә мендәр куеп авыр бүрәнә күтәргән, бөгелә төшкән ябык ирләрне күрә, колак исә паровозларның чаж-чож килеп урман яңгыратканын ишетә. Ләкин болар — болай гына. Төп көч — ипи исе. Монда ипи бар, димәк, яшәү чыганагы бар.

Разъезд шулай үсте.

Менә берзаман ипи колхозның үзенә килде. Акыллы карарлар кабул ителде, күп итеп иген үстерү, ит-сөт җитештерү өчен колхозчының үз тамагы тук булырга тиешлеге әйтелде, колхозларга шул хакыйкатьне партиячә аңлаган җитәкчеләр килде. Разъездның да йөзе үзгәрде: аның элеккеге «метрополь» дәрәҗәсе кимеде. Йортлар саны артудан туктады. Хәзер анда — элекке елларда шәп итеп салынган йортлар, умарталыклар, мунчалар, урыс капкалар, буяулы коймалар. Халкы — пенсионерлар. ОРС кибетләре, буфетлар, мәктәп бетте, кое күмелде. Ә вокзал бинасы һаман моңаеп утыра: берәүләргә — көнбатышка, икенчеләргә көнчыгышка билет өләшә. Капчык белән ипи аскан кешеләр юк анда хәзер. Разъезд һәр көнне йөзләгән кешене көнчыгыштан һәм көнбатыштан кабул итә һәм ике якка — Арча һәм Саба ягына кара урман эченә озатып тора. Ул кешеләр, разъездга төшкәч ике як урманның күпсанлы караңгы сукмакларына кереп югалалар да, ярты, бер сәгать атлагач, ишелеп иген уңган ипиле басуларга чыгалар. Һәр авылның бу кырларга алып чыга торган үз сукмагы бар. Хәтта, аерым кешеләрнеке дә бар. Көлеп сөйлиләр: өч ел солдат хезмәте узып төнлә разъездга кайтып төшкән бер егет (ул бераз сакаурак булган), караңгыда авылдашларын танымыйча сорый икән:

— Где эждись чукмак? Эждичь чукмак должен быйть...

Мин аны аңлыйм: бер телдән икенче телгә кинәт күчеш вакытында ул гадәти — «кайда», «булырга тиеш», «монда» кебек сүзләрне тиз генә таба алмаган. Ләкин теге, иң газизе аның баш миендә шул көе сак-

ланган. Сукмак. Ул аны, үзебезнең илнең татарча сөйләшмәгән ерак почмакларында гына түгел, Японияда, Франциядә яшәсә дә, һич тә тәрҗемә итмәс, комити, хосомити (японча: сукмак) яки сантиер (французча) дип мәшәкатьләнмәс, барыбер, үзенең ходай биргән кимчелеге — сакаулыгы белән:

— Чукмак,— дип әйтер иде.

Чөнки ул сукмак — газиз. Кешенең балачактагы сукмагы күчми дә, тәрҗемә дә ителми.

Разъезд хәзер буш, анда ямансу. Тагын Дәрдмәнд искә төшә:

> Гасырлар кичте китте ... кичте еллар!
> Нәбиләр, падишаһлар сөрде дәвран...
> Гомерләрдер күчеп карван вә карван,
> Килеп кичте җиһандан канча илләр!..

Урман артында — разъезддан ике чакрым гына ераклыкта — Чөмә-Елга авылы. Халкы гомер буе разъездга бәйле булды. Сугыш вакытында безнең класста шушы авыл малае Рафаэль укый иде. Гармунчы, сүз ярата торган. Гармунда ул шашып уйный, икенче дөньяга күчеп уйный. Рафаэльнең апасы Курса разъездында пекарняда эшли иде, өйләрендә ипи бар. Мәктәпкә килгәндә Рафаэльнең сумкасында калын бер телем ипи була. Моны бөтен класс белә, шуңа күрә аңа ихтирам аеруча зур. Исемен дә зурлап әйтәбез: Раф. Тәнәфестә өлкән класс малайлары без — кечкенәләрне ил-умач итеп кыйнап ташлаганда (ачның ачуы яман) Рафка кул күтәрүче юк. Чөнки аның кесәсендә — галиҗәнаб ипи телеме. Раф — юньле, шәфкатьле малай, акыллы малай. Класста иң нык ачыккан малайларны ул белми түгел. Иң ач биш-алты малайның берсе — мин. Раф, көн саен диярлек, миңа чеметеп кенә ипи кисәге бирә. Башкаларга да бераз өлеш тия. Кызып беткән уен, кызарга исәпләгән сугыш бу вакытта туктап тора. Беренче бөтендөнья сугышында, имеш, шулай булган: яралыларны җыйган вакытта туплар атмаган, ике якның да солдатлары, бер-берсенә бәрелә-бәрелә, мәетләрне, яралыларны җыеп йөргәннәр. Без дә шулай: авыз эчендә, гадәттән тыш мул чылатып, теге ипи кисәген озак тотабыз. Күзләрдән яшь килә, сугыш, бәхәс онытыла. Рафаэль! Шул елларда безгә биргән ипи кисәгең өчен мең вә миллион рәхмәт сиңа! Мин сине гел яхшылык белән генә искә алам. Ләкин бер хәлне язмый кала алмыйм.

Авыл укытучысын мәктәп дирекциясе гомернең гомер буена «ата-аналар белән эшләү җитми» дип каһәрләп тора. Ә менә Чөмә-Елга авылына укытучылар көн аралаш йөреп тордылар. Каты эшләделәр. Рафаэльнең әнисе, бичара, бик юньле хатын иде. Укытучыларның хәлен аңлап, аларга ипи турап, чәй эчертә иде. Укытучылар — яшь кызлар, кайсы — җидене, кайсы унны тәмамалаган, арада педучилищедан чыкканнары да бар. Ипи карточкасына кибәкле, көрпәле он бирәләр, аннан өйдәге ачларга да өлеш чыгарасы бар, унбиш көнгә — өч кило алты йөз грамм он; Совет хөкүмәтенә рәхмәт — шундый авыр вакытта да укытучыларга, укучыларга игътибарлы булды. Әмма, теге яшь кызларның бер тапкыр булса да авыз чылатып ипи тешлиселәре килә һәм алар, «ата-аналар белән эшләү өчен», Чөмә-Елга авылына барыштыргалыйлар. Класста бу хәл — билгеле эш. Арада явыз малайлар байтак. Кабат әйтәм: ачның ачуы яман. Күз алдына китерегез: математика укытучысы, дәрес вакытында бастырып куеп, корчаңгылы һәм чабаталы ач бер малайны сүгә:

— Мәннәнев, нужәли шуны да аңламыйсың инде? «А» плюс «б» не квадратка күтәреп, радикал астына төшергәндә нәрсә чыга?

Мәннәнев дигән ач малай исә «радикал астын» бик тиз чыгара:

— Әйдә ярар, миңа каныгыгыз инде. Без инде, Рафлар шикелле, сезгә ипи белән чәй эчереп чыгара алмыйбыз...

Әле дә хәтердә: укытучы кызларның берсе, дәрес вакытында шун-

дый сүзне ишеткәч, акбурын идәнгә ыргытып, үкереп-үкереп елады. Ул бик кызганыч хәлдә иде: без, ахрысы, моны аңладык, ул дәрестә тәртип бозулар булмады.

Курса разъездына сигез чакрым ераклыкта — Сикертән авылы. Классташым, эре, таза гәүдәле Хуҗин Сәлих шул авылдан иде. Гәүдә таза, ул аеруча каты ачыга. Тәнәфес вакытларында ыңгырашып куя. «Юк, безнең тамак беркайчан да туймаячак, ачтан үләчәкбез»,— ди. Ул өметсезлеккә бирелә. Зур гәүдәле егеткә аеруча авыр.

Сәлихны соңгы тапкыр илле бишенче елларда күрдем: солдат гимнастеркасыннан, көләч йөзле. Йорт янартып йөри, колхоз тернәкләнеп килә. Сәлих — кладовщик. Хезмәт көненә икмәк алганнар. «Ипи салабыз, кабартма-коймак пешерәбез»,— ди. Икебез дә шат. Сөйләшеп сүз бетми.

Ләкин бәхетсезлек чыккан: ревизия вакытында амбарда ике центнер арыш, өч центнер солы җитмәгәнлеге беленгән. Бөтен амбар ашлыгын ике кат үлчәгәннәр — Сәлих шулай таләп иткән. «Граммына да тигәнем юк»,— дип үкереп-үкереп елаган. Мин шикләнмим — класста иң чиста күңелле малай иде ул. Өченче тапкыр үлчәгәндә дә шулай чыккан. Өметсезлеккә бирелгән Сәлих, кешеләр карап торганда формалин мичкәсе янына килгән дә, кашык тутырып формалин йоткан:

— Менә, ипидер, ант итәм, граммына да тимәдем,— дигән. Аннан тагын өч-дүрт кашык йоткан. Кешеләрне якын китермәгән. Аннан, амбарның арыш салган бүлеге өстенә менеп яткан да, үкерә-үкерә, кычкыра-кычкыра газапланып җан биргән. Җитмәүчелеге дәүләт бәясенә әйләндергәндә алтмыш тәңкәгә дә тулмаган. Бичара, бик намуслы иде шул.

Кайбер кешеләр әйбер исенә гадәттән тыш сизгер булалар. Кайбер кешеләр — битараф. Нигә алай? Соңгыларының берәр төрле физиологик кимчелекләре бармы әллә? Һич юк! Балачакта ипи исләкне кичергән кеше генә искә аеруча сизгер була. Бүре нигә шулай искә сизгер? «Сарык абзарының исен ике чакрымнан сизә, эт исен алтыжиде чакрымнан сизә»,— дип сөйлиләр иде бездә элек. Чөнки бүре — гомере буе ач. Аңа беркем дә әбәт, кичке аш әзерләп тормый. Бәхетсезлегенә каршы, табигать бүрене җир йөзендәге иң калорияле, дефицит ризык — ит ашый торган итеп яраткан. Сарык исен, эт исен дә сизмәсә, ачтан тәпиен суза бит ул. Аның бит гастрономга талоны юк. Шулай да, моңарчы берәүнең дә ачтан үлгән бүре түшкәсен күргәне юк әле.

1944 нче елның көзе. Урман эчендә без укыган училище. Тулай торактан уку бинасына барганда юл өстендә пекарня кала. Әлегә аның ишеге янында чи усак утыны яралар. Эчтә камыр басалар. Без укудан кайтканда исә моржадан, сизелер-сизелемәс, кенә кайнар һава күтәрелә (мичне томалап, ипи тыкканнар), һавага... аңны саташтырырлык ипи исе чыккан. Күздән яшь килә, тамак төбе җыерыла, адымнар ялгыша, тел көрмәкләнә...

Борынгы шәрыкта җарияләр төн җиткәндә үзләренең тәннәренә иң затлы чәчәк майлары сөрткәннәр; патшалар, солтаннар, фиргавеннәр кереп ятасы йокы бүлмәсендә, дөньяның иң затлы гөлләре кебек татлы ис таратып һәм ефәккә чорналып, яшь хатын, җария, кәнизәк көтеп торган. Французлар тәнгә сөртер өчен хушбуй уйлап тапкан. Шәрык илләрендә әле дә кунакханәләрдә искә зур игътибар бирәләр: сандал агачы исе, арахис исе һәм башка затлы исләр чыгарып бүлмә әзерләү кунакка ихтирам билгесе булып санала.

Әмма яңа пешкән арыш ипие исе дөньяның бер генә почмагында да юк. Арыш ипие — тик бездә генә...

...Мин инде, Шәмәрдәнгә төшеп тә тормыйча, шул ук поезд белән Казанга таба кайтып барам икән. Мин инде Курса тукталышын кабат узганмын икән: әйтәм аны, күңелгә янадан сагыш ургылып тулды,

мин инде Арчага якынлашып киләм икән. Әнә, Арчада элеккеге заманның ике-өч кенә истәлеге калган. Болар — элек, ерак-еррактан күренеп, күңелгә шөбһә катыш мәһабәтлек өреп торган Арча чиркәвенең гөмбәзе. Хәзер яңа биналар каплап килә инде аны. Икенчесе — тау башындагы борынгы Арча крепосте. Иске, иске... Казан арты тарихын үзенә сеңдергән дә, әле һаман утыра, туза, искерә, картая. Өченчесе — Арчаның мәшһүр крахмал заводы. Ачлык елларда халык шуннан «барда» алып кайтып, шуңа көрпә кушып, ипи пешерә, ул ипи ачы була лычкылдап тора иде, аның исе дә сизелми иде.

Әнә, Арчаның үзәк урамы — Покровка, бу урамдагы йорт хуҗалары авыл халкын аты-нөге белән квартирага алалар иде. Ипигә бәйле тагын бер истәлек: авыл мәктәбендә укытучы, укыту бүлеге мөдире булып эшләгән чагым. РОНОга эш белән барам. Мәктәпнең хуҗалык бүлеге мөдире, дөнья бәясе торырлык юньле кеше Сәүбән абый ат җигеп бирә, чанага печән катыш солы саламы тутыра, толыпны җайлый.

— Тау менгәндә аркалыгын бераз төшерерсең,— дип, дугага уч төбе белән бер сугып ала, дуга бөҗрасы «Булды, шәп, молодец Сәүбән! дигән сыман «зың» итеп тавыш бирә, мин юлга чыгам. Мәктәп капкасын узганда ишетеп калам:

— Кайтырга чыгар алдыннан бер-ике кирпеч ипи ашат. Аннан чанага сузыл да ят, йокла. Ат ул шундый: тамагы тук булса, беркайчан да сине кыен хәлгә куймый.

РОНОда эшләрем беткәч, Арча ашханәсенә кереп, төшке аш ашадым. Щи, солянка, бәрәңге боткасы әзерләү буенча Арча ашханәсе Татарстанда беренче урында тора дип уйлыйм мин. Менә шуларны Сәүбән абый сөйләвенчә «хәл итеп» чыккач, мин, Ф. Әмирхан әйткәнчә «фатирыма юнәлдем». Иртән, килеп кергәч тә, фатир хуҗасы — сиксәнне узган урыс бабай белән бергә чәй эчкән идек инде. Патриархаль гадәткә шунда мин сокланган идем: малай (илле яшьләрдәге ир) иртән эшкә киткән, оныклар — мәктәптә, килен дә мин килеп кергәндә эшкә китеп бара иде, йортта — карт белән карчык. Мич ягылган, пирог исе чыккан, өй — мамыклы (Казан артында шулай: өй җылынса — «мамыкланган», «мамык кергән» диләр). Рәтле, ипле урыс агай белән без сөйләшеп утырдык. Ул дингә ышана, алла, аның улы, изге рух төшерелгән (троица) — почмакта, лампада астында шәм янып тора.

Дөнья күргән, солдат тормышын, сугышларны узган карт — таза, авыруны телгә алмый. Өйдә власть зур. Тарантас лапасында (Казан артында утын, печән урнаштырылмыйча буш көе саклана торган ябулы каралты тарантас лапасы дип атала) тулы тәртип. Карт миңа, яшь кешегә, әйтеп куя:

— Атыңны сугарып ал, юлга чыгар алдыннан гына ярамый ул, берәр сәгать кирәк,— ди.

Мин шунда мич буендагы сумканы искә төшерәм. Анда ике бөтен кайнар ипи. Киенеп, ат янына чыгып китәм. Ат мине көтә икән.

— Оһ-һы-һы,— дип дәшеп үк куйды. Тагарагына салынган солылы печән беткән — ул, атларда һәм персональ машина шоферларында гына була торган сабырлык белән, тып-тыныч калып, хуҗасын көтә иде.

Сумканы ачтым да ике кирпеч җылы ипи алдым. Ат хәрәкәткә килде, авызлык тимерен зырылдатты, мин тураган ипине ашыгып, төкле ирене белән хымтыр-хымтыр китереп, эвәләп йота башлады.

Шулвакыт... шулвакыт минем борынга ипи исе килеп бәрелде. Миң тугыз йөз утыз алтынчы, утыз җиденче, утыз сигез һәм утыз тугызынчы, кырык өч һәм кырык дүртенче, кырык җиденче еллар белән, тарих белән китереп бәрде ул ипи исе. Уналты ипи күтәреп буранлы юлдан атлаган әти истәлеге белән, Чуматайда ипиле чанасын тар-

тып газапланганда борынынан кан килгән Әхмәдулла абзый истәлеге белән, безнең авылга хәер эстәргә йөргән сабакташ Сәләхи истәләге белән китереп бәрде. Мин хәрәкәтсез калдым. Ат та, моны аңлаган кебек, вакыт-вакыт миңа карап, зур кара күзләрен уйнаткалап, ипи чәйнәүдән туктап торды. Һәм мин... соңгы кирпеч ипине ат белән бергәләп умырып ашадым. Бу вакытта, әлбәттә, мин күпмедер дәрәҗәдә акылдан читкә чыккан идем, медицинада мондый хәлне «отклонение» дип атыйлар.

Әйдә, ярар, хәерлегә булсын... Тик мин ярым караңгы лапас эчендә гаять бәхетле идем...

Арчаны узып, Кәче, Чулпан разъездлары поезд тәрәзәсеннән атылып очып калганда мин туган яктан аерылган идем инде. Мине нindидер битарафлык биләп алды: Коркачык станциясендәге заготзерно янынннан узганда да күңелем тыныч иде.

Коркачыкны узгач, поезд элек мин белмәгән әллә ниткән номерлы разъездларга тукталды. Хәзер «разъезд» дигән матур сүзне бетергәннәр, аның урынына җансыз, нурсыз «остановочная платформа» дигән тимер-бетон исем кертkәннәр икән. Әнә шул «ОП»ларның берсен узгач, карап бардым: Казаннан килә торган поездның тәрәзәсеннән капчык-капчык йөк түбәнгә, иген басуына оча. Аста — велосипед җитәкләгән малай-шалай, мотоцикл мөгезен тоткан егетләр. Кызыксындым.

— Ипи алып кайтучы әниләрен каршылыйлар,— диде дөнья күргән агай.— Әниләре иртәнге поезд белән сөт сатарга бара.

Сөтнең чиреге — өч литр — базарда бер сум илле тиен. Яхшы хуҗаның сыеры унике литрны бирә инде ул. Димәк, җәйнең көнендә сыер үзенең хуҗасына алты сумны эшләп тора. Хуҗа хатын бу алты сумның өч сумына унсигез кирпеч ала; кайтышлый, станциягә җиткәнне дә көтеп тормастан, поезд тәрәзәсеннән капчыкны ыргыта, малай, кияү, кыз, килен велосипед белән аста каршы алып тора, тәгәрәп төшкән капчыкны багажнигына сала да авылга элдертә[1]. Апай исә, кул селтәп, билбау астына яшькелт өчлекләрне кыстырып (ул берничә көн сауган сөт белән барган иде) зур эш кырган кыяфәттә, уҗым арасыннан авылга таба атлый. Кайтып керсә — тавык-чебеш шат, әтәч гөлдерәп йөри, бозау тагарагында ипи, хуш исле, кызгылт кетердәвек тышлы, кәрәзле ипи, ишегалды тулы ипи.

Шундый ишегалларына керәсең, елыйсың.

— Әйдә, әйдә, хуш киләсең,— ди йорт хуҗасы яки шуның хатыны, «Орловский» ипине сындыргалап-угалап бозауга тураган җирдән.— Әйдә, чәй куям...

Синең күңелеңдә авыр хис. Хуҗалар моны белми.

Элегрәк, без бала вакытта, мәктәп дәреслекләрендә бер табышмак була иде: «Суясың, туныйсың, тунаганда елыйсың. Нәрсә ул?» Җавабы — суган. Хәзер бу табышмак үзгәрергә тиеш. Хуш исле кара ипине сыерга турыйсың, тураганда... еламыйсың. Итнең килограммы базарда биш сум, ипинеке — пүчтәк... Уналты тиен булдымы акча? Бер килограмм иткә утыз ипи! Яшәргә була...

Элек ипи югарырак дәрәҗәдә иде.

Без ач вакытта «хөкүмәт ипие» менә мондый була иде:

1. Кара ипи, кирпеч формасында, кызгылт булып кетердәп пешкән, аның хуш исенә бер дә чыдап булмый иде, ул — күзәнәкле, кәрәз кебек. Хәзер андый ипи юк, күрәсең.

2. «Серый» ипи. Авыл халкы аны һич тә «соры» дип түгел, «Серый» дип йөртте. Бу — көрпәсен иләмичә, бодай онынннан пешерелгән ипи. Андый ипинең исе өйгә килеп керсә, бетте баш — төкерегең еш-еш

[1] Хәзер Казан-Арча-Шәмәрдән юлына яңа вагоннар бирделәр. Ул вагоннарның тәрәзәсе өске яктан бик аз гына ачыла, аннан инде капчык белән ипи ыргыту мөмкин түгел.

йотылып, ашказаның бәхетле сулкылдый башлый.

3. «Пукләвәнни» — русча «пеклеванный» сүзеннән алынган. Бу — бик вак итеп тартып иләнгән мәгънәсендә булдымы икән, һәрхәлдә ул бик үзенчәлекле ипи иде, бала-чага беренче чиратта шуңа ябыша иде. Бу ипинең составында солы оны да булгандыр дип уйлыйм.

4. Каравай, түгәрәк ипи. Монысы шәһәрдә булгандырмы, белмим, халыкка ул ипи «Үрнәк» совхозы пекарнясыннан килә иде. Диаметры кырык сантиметр чамасы, алты кило авырлыгындагы түгәрәк ипи, өсте кызарып бераз ялтырап тора, мичкә тыгар алдыннан каурый канат белән өстенә бераз йомырка сыегы сөртәләр икән. Күкрәккә терәп кисәргә хатын-кыз өчен бик авыр, шуңа күрә аны ирләр турый иде. Өйдә мондый бер ипи булу — байлык, хәсрәтсезлек дигән сүз. Мондый ипине урман эшендә йөргән кешеләргә бирәләр иде. Ун-унбиш көн эшләгәч, фәлән көнне совхозга ипигә барасы дип хәбәр тарала. Бала-чага, совхоз юлына чыгып, эти-әнинең баеп кайтканын көтеп тора.

Болар тарихта инде. Шулай да кара ипи ашау бәхете бары тик безнең илдә генә. Менә дөньяның мин булган шәһәрләреннән берничәсе: Каһирә, Никозия, Алжир, Истанбул, Рим, Неаполь, Искәндәрия, Фамагуста, Хомс, Дәһли, Бомбей, Мадрас, Калькутта, Коломбо, Париж, Марсель, Авиньон, Хельсинки, Тампере, Тәһран, Карачи... Бу шәһәрләрнең берсендә дә кара ипи юк. Булганы — ак ипи, аны да юка итеп телеп, майда кыздырып кына бирәләр. Бу шәһәрләрнең рестораннарында син өстәмәгә тавык ите, балык, апельсин, кофе сорый аласың, китереп бирәләр; әмма инде бер кабарлык ипи сорама, аны бирмиләр.

Көнбатышка баруымның берсендә мин, кучтәнәч итеп, Мәскәүдән ике ипи алдым. Үземне кунак итәргә җыенган ике гаиләгә боларны бүләк иттем. Шул гаиләләрдә ике кич бер-бер артлы кичке ашка чакырылдым, өстәлдә нинди генә затлы ризык юк иде! Әмма берсе дә теге ипине табынга чыгармады. «Үз илләрендә алар моны теләгәнчә ашый ала» дип уйлап, әрәм итмәскә булганнардыр инде...

Соңгы елларда, халыкның көнкүрешен яхшырту максатында, авыл җирендә пекарнялар салынды. Хатын-кыз рәхәтләнә: сумка тотып кибеткә торып йөгерә дә, «ә» дигәнче, ике баш ипи алып та кайта. Теләсә нинди яңалыкка бик тиз ияләшә торган Казан арты халкы пекарня ипиенә ныклап ябышты. Берәр сәбәп аркасында кибеткә ипи кайтмый калса, хатын-кыз кара кайгыга бата. Көне буе шул турыда гына сөйләшәләр, хуҗалык-йортның рәте китә, сугыш башланганмыни! Актаныш якларында, бәхеткә каршы, хатын-кыз әле дә өендә ипи сала икән. Берәр кеше турында яман сүз әйтәсе булса, актанышлылар менә болай диләр:

— Һи-и, әллә кем булып утырган була, әҗәткана. Ул хатынын гына белсен: кибет ипие ашап торалар бит соң алар...

Бу — бик зур хөкем икән.

*Ахыры киләсе санда*

# ШАГЫЙРЬНЕҢ ЯРАЛЫ ҖАНЫ

Фатих Кәрим әсәрләрен миңа еш кына кулга алырга туры килә. Инде күбесен белсәм дә, ихтыярсыз кайберләренә кабат күз салам. Карап торуга гади, ләкин гаҗәп самими шигырьләр. Бернинди шигъри хәйлә юк. Әмма һәркайсында шагыйрьнең җаны, күңел халәте бар. Менә бик билгеле «Кереш җыр» шигыре. Ф. Кәрим аны бер китабына ачып җибәрә торган шигырь итеп язган.

*Мин рядовой солдат бу сугышта,*
*Тик бер нәрсәм белән аерылам:*
*Рядовойлар төнен йоклаганда*
*Мин йокламыйм шатлык, кайгыдан.*

*Бер минут та башка тынгы бирми,*
*Окоп почмагында утырам.*
*Аламын да куен дәфтәремне,*
*Янып җыр язарга тотынам.*

Шигырьнең авторы тере сыны белән күз алдына килеп баскандай була. Өстендә күпне күргән соры солдат шинеле, янында корулы автомат. Йөзендә уйчанлык. Күзләрендә иҗат януыннан кабынган нур чаткылары яшеренгән. Ул яза, һәм, әйтерсең, якында гына гөрселдәгән туп тавышлары да, үзәккә үтәрлек көзге җилләр дә, авыр сугыштан соң күз керфекләренә асылынган арыганлык та аны тукта-та алмый. Ә бераздан, кыска вакытлы ялдан соң, автоматын тотып үзе дошман өстенә ташланган вакытта, аның шигырьгә әйләнгән хисләре окопташлары йөрәген җылытыр. Шуңа күрә дә шагыйрь «окопларда язган җырларымны хөрмәт белән дуслар укырлар» дип ышана. Аның үзе ясаган куен дәфтәрләренә язган җырлары татар совет поэзиясенең иң күркәм казанышларыннан берсе булып танылды.

Ф. Кәрим поэзиягә 20 еллар ахырына таба (1927—28 елларда) Һади Такташ, Хәсән Туфан авазлары көчле яңгыраган чорда килеп керә, алар сафына кушыла, аларның һәм иҗади, һәм шәхси дусына әверелә.

Ф. Кәримнең әдәби сиземе, зәвыгы, дөньяга карашы гаҗәп тиз үсә, чыныга, иҗат офыгы сизелеп зурая, политик темалар янына лирик-интим хисләр өстәлә. Шагыйрь зур темаларны да лирик хис белән сугарып язу юлларын эзли. Ф. Кәримнең чордашлары әлегә кадәр аның хезмәт сөючән, эшлекле табигате, өлгерлеге, пөхтәлеге, үз-үзенә дә, иптәшләренә дә таләпчән олы җанлы кеше булуы турында сокланып сөйлиләр. Ф. Кәрим югары культуралы, бай эрудицияле, сизгер йөрәкле шагыйрь булып житешә, күп укый. Горький һәм Маяковский, Такташ һәм Байрон, Пушкин, Лермонтов һәм Тукай, Белинский һәм Чернышевский, Шекспир һәм Беранже әсәрләре аның өстәл китаплары булган.

Фатих Кәримнең табигатенә бик яшьли үк тынгы белмәү, иҗтимагый активлык хас. Казан Җир төзелеше техникумында укыганда ук (1925—29 еллар) Ф. Кәрим комсомол активисты була, укып бетерер-бетермәстән республика яшьләр газетасының редколлегия члены итеп сайлана, аннары журналист булып китә, мәктәп әдәби түгәрәкләренә җитәкчелек итә, балалар әдәбияты турында докладлар белән чыга, күп йөри, күпне күрә.

Утызынчы елларда Ф. Кәрим татар поэзиясендә мактаулы урын алган әсәрләр иҗат итә. «Җиденче мич», «Яшен яктысы», «Тавышлы таң», «Илле егет», «Аучылар», «Аникин» кебек поэмаларында шагыйрь яңа кешенең рухи үсешен сәнгатьчә күрсәтү дәрәҗәсенә күтәрелә.

Фатих Кәрим яшьләрчә ялкын белән көрәшнең иң кызган җиренә омтылучан

шагыйрь булып үсте. Аның поэзиясе вак хисләрне белмәде. Аны ил тормышының бөтен яклары кызыксындыра, борчый һәм шатландыра иде.

Ләкин ул җиңүләр тантанасына исереп, тирә-ягына ал күзлектән карап яшәүче шагыйрь түгел иде. Аның поэзиясе һәртөрле эрәмтамакларга, ялкауларга һәм гамьсез бәндәләргә, ил эчендәге һәм ил тышындагы дошманнарга да утлы ук булып кадалды.

*Карбыз кебек кап урталай*
*Ярыр идем дә бу җир шарын,*
*Ике ярым шарны бер-берсенә бәреп,*
*Кояр идем бөтен чүп-чарын,—*

дип язды ул бер шигырендә.

Үзенең күп санлы каләмдәшләре кебек, Фатих Кәрим дә Бөек Ватан сугышында шагыйрь булып кына түгел, солдат булып та катнашты. 1941 елның ахырыннан алып 1945 елның 19 февраленә — батырларча һәлак булуына кадәр Ф. Кәрим Мәскәүдән алып Көнчыгыш Пруссиягә хәтле сузылган солдат юлын узды һәм шуның көрәш юлын үз поэзиясендә сокландыргыч шигъри көч белән гәүдәләндерде.

Фатих Кәрим Бөек Ватан сугышында катнашуын намус эше, дан эше итеп саный. «Киләсе җиребезгә килеп җиттек, эшкә башладык. Хәзер инде кулга корал тотып Туган ил өчен көрәшәбез. Эш күп, вакыт юк. Тәүлекләр буе аякта торырга туры килә. Болар бар да дан эше»— дип яза ул фронттан җибәргән беренче хатында. Икенче бер хатында Ф. Кәрим фашизмга каршы корал белән дә, җыр белән дә көрәшүе турында әйтә:

«Бөтен көчемне фашизмга каршы көрәшкә юнәлдерәм. Миллионлаган кызыләрмеецлар белән бергә — бер сафта Бөек Ватанымның, синең, сөйгән балаларымның бәхетен даулыйм. Җырларымның ялкыннарын да ун тапкыр көчәйтеп, илем өстенә җиңү шатлыгы чәчәкләрен сибү көненә ышанычлы адымнар ясыйм...» Шул ук омтылыш, шул ук ялкынлы хис Ф. Кәримнең сугыш чоры лирикасында да үзәк урынны ала:

*Мин ант итәм: соңгы тамчы каным,*
*Күкрәгемнең соңгы сулышын,*
*Бөтенесен сиңа, сиңа бирәм,*
*Ватанымның изге сугышы!*

дип белдерә ул беренче тапкыр яралангач язган шигырендә.

Бу сүзләрдә барлык совет шагыйрьләренең уртак авазы чагыла. Шушындый патриотик карашлар белән рухланган һәм татар халкының гасырлардан килә торган батырлык традицияләрендә тәрбияләнгән татар шагыйрьләре дә сугыш кырларындагы көрәшчеләрнең йөрәгенә тиз юл таптылар, солдатның күңел түрендә сакланган уй һәм хисләрен дә бөтен йөрәкләре белән сиздfestәр, күңел күзләре белән күрделәр. Шуңа күрә солдат йөрәгендәге моңны һәм сагынуны да, шатлык һәм җорлыкны да, кешелек хисләренең бөтен нечкәлекләрен дә тулы итеп шигырьдә гәүдәләндерә алдылар. Поэзиядә шагыйрь һәм солдат әнә шулай берләште. Поэзия халык тавышы дәрәҗәсенә, миллионнарның йөрәк хисләрен яктыртучы җырлар дәрәҗәсенә күтәрелде. Фатих Кәрим шул шагыйрьләр колоннасының алгы сафында барды, туп гөрселдәп торган җирләрдә гаҗәеп активлык белән иҗат итте, югары идеяле чын поэзия тудырды. Сугыш чорында язылган беренче әсәрләреннән «Ант» шигырендә ул «мылтык тотып баскан җиремнән бер адым да артка чигенмәм» дип ант итте, «Дусларга» шигырендә «ышанычлы сөйгән улың булып мин сугышка барам, Туган ил» дип белдерде, «Туктатыйк» шигырендә «Котырган эт өстеңә ташланса, маңгаена атып миен чәчрәтмичә, котылуны исеңә кертмә» дип кисәтте, «Мин — гуманист» шигырендә фашист автоматчыгын агач башыннан бәреп төшерүдә сугышчан гуманизм күрде. Бүген иң мөһим булган, иң кирәк булган сүзне әйтү Ф. Кәрим поэзиясенең идея ягыннан үткенлеген билгеләде. Шуның белән бергә Ф. Кәрим һәр әсәрендә үзенең олы фикерен бер укуда ук күңелдә уелып калырлык, афоризм дәрәҗәсендә тыгыз һәм кристаллдай саф, ачык итеп шигъри яктан чарлауга иреште.

*Фашист илгә үлем генә китерә,*
*Фашизмның таңы, язы юк...*

*Илең турында уйласаң,*
*Гомерең озын була,—*

кебек афористик юллар бер йодырыкка төйнәлгән куәтле сүз булып яңгырадылар.

Ф. Кәрим сугыш елларында чын мәгънәсендә иҗади батырлык үрнәге күрсәтте. Өч ел вакыт эчендә ул һәркайсы әдәби казаныш саналырлык 150 ләп шигырь, 8 поэма, 2 прозаик повесть, «Шакир Шигаев» исемле зур драма әсәре иҗат итте. Аларда совет кешеләренең күп санлы образлары гәүдәләнде. Ф. Кәрим сөйгәнен фронтка озатучы кызның хисләрен дә, фронттагы егетнең сөйгәне турындагы сагынып уйлануларын да, әтисенең тизрәк кайтуын көтүче нәни кызның йөрәк тавышын да ишетте. Аның әсәрләрендә Василий Теркин белән бертуган җор күңелле солдат Фазыл да, броня йөрәкле тимерче Саттар да, сапер, связной, санитарка, тупчы, врач образлары да тулы чагылды. Һәр очракта да Ф. Кәрим совет кешесенең рухи дөньясын сурәтләүне беренче планга куя. Әмма Ф. Кәримнең сугыш чоры әсәрләрендә төп сыйфат — лирик җылылык. Аның әсәрләренең һәркайсында төп урынны лирик геройның уйлары һәм хисләре алып тора.

Фронттан җибәргән бер хатында Фатих Кәрим: «Стройда шунысы кыйммәт, бөтен нәрсәне йөрәгең үтә үткәрәсең. Минем язган әйберләрем уңышлы икән, моның төп сәбәбе шушы: канымны коеп сугышам, шуның турында шул хис белән язам»,— дип хәбәр итә. Бу сүзләр хакыйкать иде. Ф. Кәрим Ватан сугышында чыннан да зур батырлыклар күрсәтә. Сугыш дәвамында ул ике тапкыр каты яралана, ләкин госпитальдән соң яңадан сугышка омтыла. Оста сугышуы өчен ул күп тапкыр язма котлаулар ала, фронтта рядовойдан взвод командиры дәрәҗәсенә күтәрелә, 1945 елның 6 февралендә ул Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләнә.

1945 елның 18 февралендә Фатих Кәрим үз взводы белән соңгы сугышка керә. Взводның бу сугыштагы батырлыгы турында Ф. Кәрим хезмәт иткән частьтан Татарстан Язучылары союзына җибәрелгән хатта түбәндәге сүзләр бар:

«Ф. Кәримовка фашистларны 37,8 биеклегеннән бәреп чыгарырга һәм шунда ныгып калырга дигән бурыч куелды. Бу бурычны үтәүнең бөтен сугыш нәтиҗәсе өчен зур әһәмияте бар иде. Кече лейтенант Ф. Кәримов үзенә төп хәрби бурычны үтәү йөкләтелгәнне яхшы аңлады, ул үзенең взводы белән көчләре күп өлеш артыграк булган дошманга каршы кыю рәвештә сугышка ыргылды. Ул җитәкчелек иткән взвод дошманның көчен сындырды һәм биеклекне яулап алды. Фашист бандитлар, бу аз санлы кыюларны биеклектән куып төшерергә теләп, биш тапкыр каршы һөҗүмгә күчтеләр. Ләкин, зур югалтуларга дучар булып, артка тәгәрәделәр. 18 февральдән 19 февральгә каршы бер тәүлек эчендә фашистларның 45 солдат һәм офицеры үтерелде. 120 кешесе пленга алынды».

Фатих Кәрим шушы сугышта һәлак була. Соңгы батырлыгы өчен аңа икенче орден — «Беренче дәрәҗә Ватан сугышы» ордены бирелде.

Шагыйрьнең бу соңгы сугышта өч тапкыр яралануы турында мәгълүмат бар. Дошман угы аны тик өченче тиюендә генә үтерә. Бу да аның яшәүгә нык омтылышлы табигате турында сөйли кебек.

Ләкин Фатих Кәрим алган яраларның аз билгеле булганы, әмма шагыйрь җанын иң тирән җәрәхәтләгәннәре дә бар. Әле Казан Җир төзелеше техникумында укыган елларда ук ул, «мулла баласы» исеме тагылып, комсомолдан чыгарыла. Тик ВЛКСМ өлкә комитеты катнашып кына аны комсомол сафында калдыралар. Икенче яраны Ф. Кәримгә чордашларыннан берсе яшь шагыйрьнең беренче җыентыгына язган рецензиясендә ясый. Менә рецензент сүзләре: «Ф. Кәрим хәзерге көндә кызыл сүзләр кыстыргалап язып баручы, төптә буржуага хезмәт итәргә хәзерләнгән бер шагыйрь». «Аның күп шигырьләре яшьләр өчен иң зарарлы нәрсәләр». «Ул — солтангалиевчә, җидегәнчеләрнең юлдашы» һ. б.

Ф. Кәрим өстенә килгән кара болыт 1936 елдан башлап тагын да куера. 1937 елда ул эшеннән чыгарыла һәм 1938 елның 3 январенда, «халык дошманы» исеме тагылып, Кремль төрмәсенә озатыла. Шагыйрьнең төрмәләрдә, сөргеннәрдә күргәннәре әле өйрәнелмәгән. Әмма бу турыда мәгълүматлар да юк түгел. Аерым алганда, башта 10 елга хөкем ителгән шагыйрьнең 4 елдан соң яңадан суд ясалып, 1941 елның декабрь башында аклануы билгеле. Фатих Кәримне аклауга кемнәрнең ярдәме тигәнлеге дә якыннарына мәгълүм. Алар атаклы генералыбыз Якуб Чанышев һәм Ф. Кәримнең дусларыннан берсе Кави Нәҗми була.

4 елга сузылган газаплы төннәр һәм көннәрнең иң ышанычлы дәлилләре — шагыйрьнең үзе ясалган дәфтәрләрендә теркәлеп калган шигырьләре. Алар 1938—1941 еллар дәвамында кәгазьгә төшерелгәннәр. Күбесе каралама хәлендә калган. Аларның тәгаен датасын да күрсәтү кыен. Кайберләренә шагыйрь елын куйган. Кайберләрен эчтәлектән белеп була. Мәсәлән, «Кыр казы» шигырендә «Тынчу төрмәдә каршылыйм дүртенче язны» диелгән. «Сагынып кайтам сине», «Уйга калып тау башында утырам», «Онытма» кебекләр Ф. Кәрим Казанга — яңадан судка кайтарылгач, әле суд карары билгеле булганчы язылганнар. Димәк, алар 1941 елгы әсәрләр.

«Сагынып кайтам сине» шигырендә Ф. Кәрим үзенең дусты Хәсән Туфанны телгә ала, аңа үпкә белдерә. Димәк, Ф. Кәрим әле бу вакытта Хәсән Туфанның да, халык дошманы исеме тагылып, төрмәдә утыруын белми. (Нинди аянычлы хәл!)

Бөек Ватан сугышы елларында Ф. Кәрим төрмә чорына караган күп кенә шигырьләрен үзгәртеп яза, аларны сугыш чорына ярашытыра. Ләкин алардагы шигъри табышларын югалтмаска тырыша. Шагыйрьнең хәзерге китапларында шул үзгәртелгән вариантлар бирелгән. Төрмә чоры хакында турыдан-туры сүз булмаган 1938-1941 елгы күп кенә шигырьләрне мин Ф. Кәримнең өчтомлык әсәрләренә 1954 елда беренче тапкыр урнаштырган идем.

Бирелә укучыларга Ф. Кәримнең төрмә чорындагы куен дәфтәрләреннән күчереп алынган шигырьләр, вариантлар тәкъдим ителә. Алар, һичшиксез, шагыйрь тормышының һәм җанының кайбер яңа якларын ачар дип ышанам.

Зәет **МӘҖИТОВ.**

# Фатих Кәрим

## ТӨРМӘДӘ ЯЗЫЛГАН ШИГЫРЬЛӘР

### Ант

«Менә балам, мин — әнкәсе аның,
Балабызны тотып ант итәм:
Син китәсең ерак, ристан булып,
Сау-исән бул, ә мин... мин көтәм».

Бәлки соңгы тапкыр... күрештек,
Кочаклашып озак үбештек.

Сизә бала, карый күзләремә,
«Сау бул, әткәй», ди ул күңеленнән.
Ана күкрәгеннән суырып алган
Сөт тамчысы алсу иренендә.

### Кадрия

Тәрәзәмә кунган ак күгәрчен
Гөрли-гөрли канат кагына.
Кагына да уйнап очып китә
Син яшәгән өйләр ягына.

Ә мин калам тынчу таш төрмәдә,
Тимер рәшәткәгә баш иям.
Өзелергә җитеп сыкрый күңелем
Сагынудан сине, Кадриям!

Нигә мин дә ак күгәрчен түгел,
Ярсып очар идем шул якка,
Очып барып иркәләнер идем,
Сыеныр идем синең кочакка.

Озын төннәр буе уйланамын,
Сине канат итә бу уем.
Тышта яз бит, бәгърем, яз бит тышта,
Күз алдыма килә Дим буе.

Дим буенда хәзер язгы ташкын
Ярларына кире кайткандыр.
Балалыгым үткән болыннарда
Инде шомырт чәчәк аткандыр.

Шомырт чәчәгедәй ак, ягымлы,
Саф һәм йомшак синең күңелең.
Язгы кояш кебек ялкынланган
Йөрәгемнең хисләр гөле син.

Бәхетем син минем, шатлыгым син,
Әрнетүле тирән кайгым син,
Адам белән Ләйләм әнкәсе син,
Кояшым син минем, аем син.

Көнем үтә, озын төнем үтә
Хыялый бер сагыш эчендә.
Ничек Дим соң?
Тау буена бар син
Язның серле, айлы кичендә.

Тау буенда чәчәк арасына
Утырып тыңла чишмә агышын.
Көмеш чишмә бөтен моңы белән
Җырлап бирер минем сагышны.

Ә мин шулай уйлап моңаям да,
Тимер рәшәткәгә баш иям.
Өзелергә җитеп сыкрый күңелем
Сагынудан сине, Кадриям.

*1938 ел, май.*

❀

Көзге яңгырлы төн, җил чәмләнеп
Калай түбәләрне туздыра.
Телеграф чыбыклары бу төн
Шашкан елан кебек сызгыра.

Диңгез төбендәге корабсыман
Караңгыга чумган таш төрмә.
Таш төрмәнең цемент идәнендә
Йоклап яктан ристан төш күрә.

Гүя чиккән яшел күлмәк кигән,
Яшел гармонь, имеш, кулында.
Сабыйларча гамьсез, гармонь уйнап,
Җырлап йөри яшел болында.

Аркылыга кисеп берсе-берсен,
Ага чылтырап салкын чишмәләр.
Чәчәк тешләп очкан сандугачлар
Су эчәргә килеп төшәләр.

Иркен сулап җиргә ята егет,
Нинди рәхәт! Ләкин бер нәрсә
Әй чыжылдый үлән арасында,
«Бу нәрсә?» — дип башын күтәрсә,

Көзге яңгырлы төн, җил чәмләнеп
Калай түбәләрне туздыра.
Телеграф чыбыклары тышта
Шашкан елан кебек сызгыра.

Хурланудан калтырана ристан,
Язмыш, язмыш, аны нишләттең? —
Башын япса, аягына җитми
Тик ямаудан торган бишмәте.

Маңгаена терәп ике тезен
Керпе кебек йомарлана да,
Күргән төшем кабатланмасмы, дип,
Ул күзләрен йома яңадан.

Чыннан да ул тагын бер төш күрә,
Яшел болын түгел бу юлы,
Ике яшьлек кызы кулын кискән,
«Әттә, кулым бу-бу» — дип елый.

Көзге төндә салкын тамчы тама,
Сабый кулын кискән — кан тама,
Мөлдерәп аккан сабый яшен күреп
Ата йөрәгенә ут каба.

❀

Я көн генә була, я төн генә,
Мин яшәгән җирдә ямансу.
Салкынлыктан сөяк әрнесә дә,
Сагыш ялкынында янасың.

Ярып чыгалмаслык чиксез тайга,
Җәй дә монда ике ай гына.
Тын алмыйча тоташ улаган җил
Сала мине кара кайгыга.

Кош, хайваннар да бар бу җирләрдә,
Диган уйлар төшсен, диптерме,
Күзгә чалына кайчак ала карга,
Башка берни монда күренми.

Бөтен тормыш — көн-төн сыкрап эшләү,
Кәгазь дә юк монда, каләм дә.
Килеп җитми анаң, балаларың
Сагынып язган кайнар сәламнәр.

Меңләп саналса да ристан башы,
Тере бер кеше юк бу якта.
Тик гәүдәсе йөри, күз карашы,
Уе, күңеле аның еракта.

## Кыр казы

Тимер рәшәткәләр аша
Карыйм югары,
Челтәрләнә күкрәгемдә
Кояш нурлары.

Тынчу төрмәдә каршылыйм
Дүртенче язны,
Яз саен сагынып бу якка
Кайта кыр казы,

Кайта диңгез артындагы
Ерак иллардән
Һәм яши ул төнбоеклы
Тонык күлләрдә.

Әй, кыр казы! Түбәнәйт тә
Очкан юлыңны,
Бүләк итеп китче миңа
Бер каурыеңны.

Каләм ясап каурыеңнан,
Язгы ялкында,
Каныма манчып языйм бер җыр
Сөйгән халкыма.

Җырым аша белсен халкым,
Айнытсын аңын,
Дошманнар богаулап куйган
Улы мин аның.

Атсалар да, ассалар да,
Сөйгән халкымның
Мин кояшым итеп үләм
Йөрәк ялкынын.

Атсыннар, куркытмый чөнки
Мине бу җәза,
Сабыйлар күз яше кебек
Вөҗданым таза.

Үлсәм җырларымда калыр
Сөю, сагышлар,
Кыр казы йөзгән күлләрдә
Шаулар камышлар.

## Сагынып кайтам сине

Казан! Казан! Сагынып кайтам сине.
Килеп җиттем менә Иделгә.
Ә шулай да якынайган саен
Нәрсәдер ят тоела күңелгә.

Кайда гына барып күз салсам да
Кул бирерлек кеше табылмас,
Элек бергә җитәкләшеп йөргән
Дуслар инде хәзер танымас.

Иске капчык асып, конвой белән
Урамнарың аша узганда
Очраса, күрмәгәнгә салышып
Узып китәр хәтта Туфан да.

Паровозның озын, моңлы тавышы
Хыялымнан мине уята.
Рәшәткәләр аша карыйм тышка,
Талгын гына язгы таң ата.

Язгы таңның зәңгәр яктысында,
Йомшак аксыл томан үтәли,
Казан... Казан күренә.
Ул бит минем
Яшьлек чәчәгемнең түтәле.

Әле иртә. Тик карчыклар гына
Пышын-пышын намаз укыйдыр.
Кичен кафия эзләп хәлдән тайган
Шагыйрьләрең әле йоклыйдыр.

Туфан гына торган булса кирәк,
Бакчасына чыгып ялгызы
Уйга талгандыр ул, озакламый,
Җизни, дигән булып балдызы

Чыгып чакырыр аны чәй эчәргә,
Бүләр язгы тирән уйларын,
Ул буйсыныр, салмак кына торып
Кесәсенә тыгар кулларын,

Өйгә керер. Аңлыйм, аңлыйм,
шагыйрь,
Өйдә сиңа шатлык бер генә,
Кош тавышы белән, эткәем, дип,
Йөгереп чыгар кызың Гөлгенә.

Чәчәк аткан үрмәле гөл кебек
Кочагыңа менеп сарылыр,
Шунда гына уйчан шагыйрь өчен
Елмаерлык бер ямь табылыр.

Ә соң минем Адам, нәни Ләйләм,
Син белмисең булыр, аларны.
Белмисеңдер, юкса түзмәс идең,
Шагыйрь күңеле чөнки яралы.

Түзмәс идең, авыр көннәрендә
Барып сыйпар идең башларын.
— Беләм, дисең... Ә соң, белә торып,
Ник аларны читкә ташладың?

Тупас вөҗдансызлар көннәрендә
Син тезләнеп мескен булдыңмы,
Дусларыңның авыр язмышына
Чирканмыйча кулың куйдыңмы?

Соң әллә син, медаль алмак булып,
Кафияләр сайлап йөримсең?
Шагыйрь өчен үзе язган җырдан
Бөек бүләк югын белмисең?

Көттем сине, еллар буе көттем,
Ник килмәдең, нигә ташладың?
Нигә минем нәни кызларымның
Барып сыйпамадың башларын?

Курыктыңмы? Булыр, бик ышанам,
Курку безгә гаять хас нәрсә,
Өстәвенә берәү арт ягыннан
Кинәт тамак кырып җибәрсә,

Беттең инде, кәфен генә кирәк,
Каберен үзең барып казыйсың,
Җаның кебек якын күргән дусны
Иблискә тиң дошман ясыйсың.

Ялгыш икән, акчаң йөз сум түгел,
Дусларың йөз булсын дигән сүз,
Йөз генә дә түгел, артык иде,
Хәзер калдым менә бер үзем.

Дусларым юк хәзер, тик бер генә
Дустым булды авыр көнемдә,
Тик ул гына мәрхәмәтсез кышның
Җил-буранлы кара төнендә.

Сабыйларын алып кочагына,
Ишек ачып чыкты, түзмәде,
Тик ул гына тимер капкаларны
Кага-кага мине эзләде.

Дусларым юк хәзер, тик берәүгә
Мин кулларын үбеп баш иям.
Торгандыр ул сагыш ялкынында —
Яфрак кебек кипкән Кадриям.

Еллар буе ерак хыяллардан
Мине эзләп талган күзләрен
Балаларга текәп әйтә булыр
Йөрәген өзеп чыккан сүзләрен.

Һәм балалар моңсу караш белән
Сарылалардыр аңа, әнкәй! дип,
Сорыйлардыр: — Кай җирләрдә йөри,
Нигә кайтмый безнең эткәй? — дип.

Күз нурларым!
Сагынып кайтам сезне,
Белмим, ничек каршы алырлар.
Шигырь өчен туган эткәгезне
Тагын дамы утка салырлар?

Ни булса да булыр, мин ашкынам,
Ник, машинист, әкрен барасың?
Бөтен парың биреп омтыл алга,
Үртәләмә йөрәк ярасын.

Гамьсез гомер өчен тумадым мин,
Ялкынланып яшәү теләгем.
Шаулы шигъри хисләр диңгезенең
Дулкынчысы минем йөрәгем!

Паровозның озын, моңлы тавышы
Уйларымнан мине уята.
Рәшәткәләр аша карыйм тышка,
Талгын гына язгы таң ата.

Язгы таңның зәңгәр яктысында
Йомшак аксыл томан үтәли,
Казан... Казан күренә,
Ул бит минем
Җырлар чәчәгемнең түтәле.

*Әсәрләрне «Казан утлары» өчен шагыйрьнең кызы Ләйлә Кәримова әзерләде.*

Редакция.

# ПУБЛИЦИСТИКА

**Марсель Зарипов,**
**Анатолий Подольский**

# КАЙРЫ ТУН КАЙГЫСЫ

Язманың исеменә күз салу белән үк укучының хәтерендә Такташның мәшһүр «Тун трагедиясе» яңарып. Шагыйрь аны:

Быел мин тун алып кидем,
Шаккаттылар,
«Дошманнар»дан
Бик күп көнләүчеләр булганнар,
Ләкин
Юкка гына,
Уңмадым мин туннан, туганнар,—

дип башлап китә. Һәм шунда ук әлеге тунның бик начар тегелгән булуын, аны һәр көнне кич утырып ямарга кирәклеген тасвирлый. Әмма бүгенге укучы моңа игътибар итеп тормас, аны, мөгаен, башка сорау биләр: кайдан, ничек ала алды икән Һади агай ул тун дигәнен? Хәер, шигырьнең исеме астына ук: «Казандагы мех фабрикаларына багышлыйм»,— дип тә куелган. Димәк, моннан алтмыш еллар элек Казанда үзең теләгән тунны сатып алу мөмкин булган. Ә хәзер? Нигә без, теләсә кайсы кибеткә кереп, сайлый-сайлый тун ала алмыйбыз? Безнең шул сорауларга җавап эзләп китеш...

Без — дөнья базарларын тоткан Казан мехчыларында кунакта. Фабрика директоры — сүзгә саран, эшкә юмарт бер абзый — цехлар буйлап барды-барды да өстәл өстендә яткан өемнән бер кочак елкылдап торган мех күтәреп алды. Күз алларыбыз кинәт әлҗе-мөлҗе килеп китте. Нинди генә җәнлек юк монда?! Җете ак котып төлкесе, селәүсен, усал каплан, камчат, чем-кара диңгез мәчесе, шунда ук — буй-буй юлбарыс, тимгелле жираф, сусар, кондыз, су күсесе... Күз явыңны алырдай әлеге бизәкләр... гап-гади сарык тиресенә төшерелгән! Затлы мехларга төренергә яратучы купшы мадам, валютага сатып алып, «чуар каплан» яки «юлбарыс» тиресеннән тегелгән тун киеп караганчы, беләсезме, сарык тиресе никадәрле юл уза?

Мех барлык дәверләрдә алмаз һәм якут кебек асылташлар белән бер бәядә йөргән. Ул хәзер дә йомшак алтын санала. Дөрес, табигатьнең үзендә дә затлы тирегә ия җәнлекләр бар: җофар, сусар, кеш. Ләкин алар хәзер бик сирәк очрый. Алар белән халыкның ихтыяҗын һичничек канәгатьләндереп булмый. Элекке заманда, кеш тиресе биреп, ясак түләгәннәр, кеш тиресен патшаларга, ханнарга бүләк итеп җибәргәннәр. Ә сарык тиресе крестьян агайга кайры тун, олаучыга җылы толып тегүдән бүтәнгә ярамаган.

Моннан кырык-илле еллар элек, Казан мех комбинаты сарык тиресенең данын дөнья аукционнарына хәтле күтәрә алыр, дип беркемнең дә башына килмәгәндер. Ә хәзер берләшмә үзе башкарган зур эш өчен СССР Дәүләт премиясенә лаек булды. Моңа ничек ирешелде соң?

Бу сорауга җавап бирер өчен без «алтын тире»гә бәйле әкиятләр дөньясына әйләнеп кайтыйк әле!

Тапкыр һәм зирәк акыллы Эллада улларының — аргонавтларның тылсымлы маҗаралары хакында кемнең генә ишеткәне юк икән? Шулай да риваятьне искә төшереп үтик. Күк

йөзендә кояш балкып торган бер көнне, җырчы Орфейның җырлары тирә-юньне яңгыратып торган бер мәлдә, Пелопонес бухтасыннан көчле беләкле ирләр гүзәл корабны җилдавылларга каршы алып чыгалар, алтын тире эзләп китәләр. Бу сәяхәт аларга — дан, кешеләргә — бәхет һәм муллык китерергә тиеш.

Каһарман аргонавтлар гөл бакчалы Лемно шәһәренә килеп туктаган. Шәһәрдә аларны берсеннән-берсе чибәр хатын-кызлар каршылап, мәҗлесләр, күңел ачу кичәләре оештыра, гүзәллекләре белән сихерләп, батыр сәяхәтчеләрне аздыра, аларның бурыч һәм намус тойгыларын онытсыра башлаган. Әмма аллалар алласы Геракл беренче каһарманлыгын эшли — гамьсез баһадирларны оялта, аларның нинди максат белән юлга чыгуларын исләренә төшерә, шуннан соң аргонавтлар тагын корабларына кереп утыра, кулларына ишкәкләрен алалар.

Бу әле кыенлыкларның башы гына. Аргонавтларга алты куллы әзмәверләр белән көрәшергә, чит-ят адәмнәрне үтереп торучы баһадирлар белән бил алышырга, көчсез бер картны ерткыч кошлар тырнагыннан коткарырга, барлык кораблар бәрелеп ватыла торган Симплагат кыяларын хәвефсез узарга туры килә. Кавказга килеп җитәрәк, алар бакыр каурыйларын кораб өстенә коеп, кыюларны һәлак итәргә теләгән кошлардан да котылалар.

Менә, ниһаять, Эот патша җире Колхида. Патша бакчасында, аждаһа саклый торган агач ботагында —«алтын тире». Патша аргонавтлар башлыгының гозерен кабул итә, тик ул аларга тау хәтле шарт куя: ул шартлар аргонавтлардан кыюлык, тапкырлык, гайрәт таләп итә, бу сыйфатлар булмаган сурәттә һәлак булуың да бик ихтимал. Куркусыз Ясон авызларыннан ут бөркеп торган үгезләрне сукага җигеп, шулар белән изге җирне сукаларга, җиргә аждаһа тешләрен чәчәргә, аннары бу җирнең уңышы тишелеп, тимер көбәле сугышчыларның үсеп җиткәнен көтәргә, ниһаять, аларны сугышып җиңәргә тиеш. «Алтын тире»нең бәясе шундый, син аны сатулашмый-нитми түләп ал...

Баһадир Ясон колхлар патшасының барлык сарайларын карап-өйрәнеп чыга, шуларның берсендә патшаның гүзәл кызы белән очраша. Патша кызы Медеяның йөрәгендә каһарманга карата мәхәббәт ялкыны кабына, гүзәлкәй Ясонга гашыйк була, аны төнлә елга суы белән юынырга, өстенә кара киемнәр киеп алырга, елга буена тирән чокыр казып, шул урында аллалар намена кара сарыкны корбан чалырга, аны балга манарга өйрәтә. Күрдегезме нинди шартлар?

«Алтын тире»гә ия булу, бер уйлап баксаң, бүген дә җиңел түгел. Тире эшкәртү — адәм баласының икенче һөнәре. Хәзерге казанышларга адәм баласын шул һөнәр алып килде. Ләкин бүген аның чынлап та шулай икәнлегенә кешеләрне ышандыру кыен. Космоска очу кебек гаҗәеп хәлләр, казанышлар булды, ә менә гап-гади эшләрне башкаргандагы кимчелекләребез безне төп башына утыртып калдыргалады. Әйтик, аяк киемнәрен без җан башына Америкага караганда, өч мәртәбә артыграк җитештерәбез. Шул ук вакытта аякка киярга юньле әйбер юк, импорт ботинкаларга, урам тулып, чират тезелә. Шул ук вакытта үзебезнең аяк киеме кибет киштәләрендә тузан җыеп ята. Икенче бер кытлык безне интектерә башлады: кайры туннар юк бездә. Чит илләрдә турист булып сәяхәттә йөргән кешеләр «дубленка» алып кайтулары белән мактаналар. Тире эшкәртү бит элек-электән безнең төп һөнәрләребезнең берсе булып килгән. Искә төшерик: кем Россия мужигыннан алдарак сарык тиресен эшкәртә башлаган? Кем сарык тиресеннән кыска тун, җылы бүрек, бияләй теккән? Иң зур табышны безгә әнә шул һөнәребез бирә иде түгелме?!

Менә ни өчен сарык көтүләре, иләгән тиреләр, кайры туннар кызыксындыра безне! Менә ни өчен «алтын тире» эзләүчеләр юлыннан кабат үтү мавыктыра безне!

Тынгысыз җанлы әдипләр, тормышның ашкынулы кайнар агымыннан калышмас өчен, кайларга гына барып чыкмыйлар?! Аларның иҗат-эзләнү сәхифәләре чын мәгънәсендә батырлык адреслары буенча языла. Ә гап-гади кайры тунны проблема итеп күтәрү зуррак эш-мәшәкатьләребезне оныттырырлык нәрсәмени соң?!

Яшерен-батырын түгел, күңелгә әнә шундый уйлар да килә. Әгәр дә баһадир аргонавтлар — батырлыкка, намуска һәм вазифа үтәүгә җан-тәннәре белән омтылган кешеләр — күңел түремдә утырмаса, юлга чыгар идем микән мин... Өстәвенә, юлдашларым — «Советская Россия» редакциясе кушуы буенча, минем белән бергә сәфәр чыккан хәбәрчеләр Анатолий Подольский һәм Владислав Селеверстов,— эшкә җаптәшлек ягыннан булсын, максатка ирешүдәге үҗәтлекләре ягыннан булсын — аргонавтлардан калышырлык түгелләр иде. Без бер экспедиция материалларын газетага тапшыру белән шундук икенчесенә чыгып китә тордык.

«Советская Россия» газетасында басылган беренче мәкаләбез тиречемехчыларны техника белән тәэмин итү турында иде. Ул 1970 елны басыл-

ды. Икенче мәкаләбезне, зурлап, ике санда басып чыгардылар. Тагын дүрт елдан өченче мәкаләбез дөнья күрде. Болар барысы да сарык тиресе, кайры тун, «алтын тире» турында. Азакта, газета тулып җавап хатлары чыкты. Беренче мәкаләбез басылганга унсигез (!) ел узып киткән. Тарих өчен ком бөртеге кадәр генә булса да, адәм баласы өчен бу — аның гомереңең байтак зур өлеше. Еллар узган, туннар тузган, дигәндәй, нинди файдалы эш эшләнгән соң?

Әгәр эшләгән эшебез язып тутырылган кәгазь битләре белән исәпләнелә торган булса, безнең илдән дә бай ил булмас иде. Кәгазь таулары күп, эшләнгән эш азрак шул. Шуңа күрә «алтын тире» дигән мәңгелек теманы тагын казып чыгарырга туры килә.

Эллин каһарманнары аллалар һәм явыз көчләр белән сугышканнар, ә аларның хәзерге токымнарына исә бөтенләй башка нәрсәләр — ялкаулык, сәрхәнтәйлек белән, халык байлыгына төкереп карау, түрәләрнең вәгъдәсезлекләре белән сугышырга туры килә. Бу кимчелекләргә без шул хәтле күнеккәнбез инде, аларны шулай булырга тиешле нәрсәләр итеп карыйбыз. Өндәмәләр бер якка чакыра, әмма алардан да көчлерәк тәбәлдерекләр икенче якка таба алып китә, шуңа күрә бер кешенең генә түгел, меңнәр, миллионнарның эш нәтиҗәсе дәүләт өчен зыянлы булып чыга. Әкиятләрнең ахыры шатлык-сөенеч, бәйрәм-туйлар белән бетә, ә тормышта иң әйбәт башланган нәрсәнең дә кайгы-хәсрәткә тоташуы ихтимал.

Хәзерге заман «алтын тире» сәяхәтен без сарык көтүләреннән башладык. Бер сарыктан ничә «тун» алып була? Безнең әңгәмәбез Бөтенсоюз фәнни тикшерену институтында шундый сораудан башланды. Институт Төньяк Кавказ сарык үрчетү төбәгенә — Ставрополь шәһәренә урнашкан. Илебезнең мех фабрикалары нинди чималга исәп тота ала? Кибетләр, кооператорлар, тышкы сәүдә хезмәткәрләре нәрсә көтә? Без бит чит илләрдән сатып алырга гына түгел, үзебезнең товарны да чыгарырга тиеш. Мех — ул — киемнең матурлыгы һәм җылылыгы, аның белән бернинди «химия» дә ярыша алмый.

Институтның ярым нечкә йонлы сарыклар үрчетү бүлеге мөдире Иван Иванович Селькин, йон һәм тире бүлегенең өлкән фәнни хезмәткәре Анатолий Захарович Гребенок, директор урынбасары Николай Борисович Теребиленко безнең язучылар дружинасы белән бик теләп сөйләштеләр.

— Мөмкинлекләрне кайсы вариант буенча исәплибез: гамәлдәгесе беләнме, булачагы беләнме?

— Гамәлдәгесе белән исәпләсәк — аз, бу фән кушканча булмас. Ирешә алу мөмкинлекләреннән чыгып эш йөртергә кирәк.

— Ярый, килештек, шулай булсын. Ил күләмендә 140 миллион баш сарык бар, көтүләрдәге бәрәнле торган сарыклар шуның 70 проценты дип уйлыйк. Ул буладыр — 98 миллион баш.

— Әгәр алар барысы бәрәнләсә?

— Уһу! Моны хәтта иң яхшы компьютер да төгәл исәпләп чыгара алмас кебек. һәр көтүнең үз эш нәтиҗәләре. Карачай-Черкесиядә 1985 елны «Ильичевский» совхозыннан Хөсәен Гочаиев чемпион булып чыккан — йөз баш сарыктан 170 бәрән алган. Моннан да зуррак уңышка ирешүчеләр бар. Монысы инде Кавказда түгел, Урта Азия якларында. Казахстанда Луговской ат заводы чабаны Социалистик Хезмәт Герое Надир Бигазиев һәр йөз баш сарыктан 171 әр бәрән алуга ирешкән. Болар, әлбәттә,рекордчылар...

Шулай да сарык үрчетү — уңышка тиз китерә торган тармак, быел туган бәрән йон да бирә, тун да. 98 миллион бәрән — бу инде 98 миллион тире дигән сүз.

— Мөмкинлекләрне ачыкладык. Ә чынлыкта күпме тире әзерләнә?

— Планда бирелгән сан — 45 миллион тире, әмма 40 миллион гына чыга. Шуннан 10 миллионын — түбән сортларны, стандартка яраксызларны, йон гына бирә торганнарны чигерик. Димәк, өч сарыктан бер генә тире алабыз булып чыга. Ел саен 60-70 миллион тире югала.

— Әйдәгез, комбинатка килми калган сарык тиреләрен базар бәясе белән санап карыйк!

— Табыш бит ул нәрсә тегүгә дә бәйле: бүрек белән бияләй тегәсеңме, әллә затлы тунмы?

— Иң дефицит товарларны алыйк: Казан, Киров, Мәскәү, Касыйм шәһәрләрендә тегелә торган затлы туннарны, 600-700 сум акчаны да кызганмыйча алып була торган товарларны!

— Урта үлчәмдәге тунга алты-җиде сарык тиресе китә. Димәк, дәүләткә керми калган тиреләрдән елга бер миллион чамасы затлы тун — «дубленка» тегәргә мөмкин булыр иде. Уртача исәптән генә дә — 6 миллиард сумлык мал!

— Бу акчага ике ВАЗ, яки бер КамАЗ, яки 300-400 мең кеше яши алырдай яңа шәһәр салып була!..

— Хикмәт табышта гына да түгел. Исәпләүне башкачарак та дәвам итәргә мөмкин!

Сан яратучылар рәхим итеп язып алсыннар — дөньяда барлыгы 1 миллиард та 150 миллион сарык бар. Шуларның тугыздан бере — безнең илдә. Халык санына бүлеп караганда, ике кешегә бер сарык туры килә, ә җир йөзендә бер сарык дүрт кешене киендерә булып чыга.

Сарык тиресеннән тегелгән тун озак вакытка исәп тотып эшләнә, гадәттә, бабаларның туны һәм толыплары оныкларга кала. Шунлыктан безнең илдә кайры тунга кытлык булмаска тиеш иде кебек. Әмма... Ставрополь фәнни тикшеренү институтында безгә әйттеләр: Советлар Союзының мех фабрикаларына чит илдән ел саен 10 миллион сарык тиресе кереп тора. Аңа үзебездә җитештерелгән тиреләрне кушып исәпләсәк, мех әйберләре бездә сайлап алырдай күп булырга тиеш бит. Чынлыкта һич кенә дә алай түгел: затлысы да, эшкә кия торган кыска тун да, балалар киеме дә кибетләрдә сирәк очрый. Аларны Бөтенсоюз авыл хуҗалыгы күргәзмәсе залларында гына очратып була. Кайры тун кигән кешене танышлары: «Каян алдың бу хәтле затлы киемне?» дип алҗытып бетерәләр.

Сүз дә юк, кышкы һәм көзге салкыннар җидешәр айга сузыла торган Төньякны, Себерне, Ерак Көнчыгышны исәпкә алмыйча булмый. Барыбыз да яхшы беләбез, ерак җирләрне үзләштерергә дип урта полосадан да, көньяк өлкәләрдән дә, гомумән, илнең барлык якларыннан 10 миллионнан артык кеше китеп, шунда торып калды. Аларны җылы киемнәр белән тәэмин итми хәлең юк. Шулай да, сарык үрчетү буенча планетада тоткан урыныбызны, мөмкинлекләребезне белгәнгә күрә, җылы туннар мәсьәләсе безне аптырашта калдыра, бу безгә гайре табигый бер хәл булып тоела, булган мөмкинлекләребездән чын хуҗаларча файдалана белмәвебез җанны әрнетә. 140 миллион баш сарык! Сарык күп, көтүләр кимеми, ә менә тире елдан-ел кими бара. Бу ни хикмәт?!

«Союзмехпром» берләшмәсенең производство начальнигы Владимир Васильевич Тюрин безгә менә нәрсәләр сөйләде:

— Болай: 1971 елны тире эшкәртүчеләр тунга яраклы 12 миллион данә тире алдылар. Башка төрлесе — 22 млн. данә — тун тегәргә ярамый. Ә 1985 елны — 8 миллион данә генә. 1971 елны түбән сортлы чимал 4 миллион данә чамасы булса, ундүрт елдан соң ике ярым мәртәбә артты — 9 миллион 600 мең данә булды. Унберенче бишьеллыкта чимал кытлыгы булу сәбәпле сәүдә челтәренә 570 мең данә кыска тун, 714 мең данә балалар туны, бик күп колакчын бүрек биреп җиткерелмәде...

Сарык өстендәге тун «алтын тун»га әйләнгәнче кешеләр башыннан ниләр генә кичми! Кыю җанлы аргонавтлар кичергәннән дә күбрәк кыенлыклар уза: башта сарыкның үзен үстереп җиткерергә, үстергән чакта ярамаган нәрсәләр ашатып йонны һәм тирене бозмаска, базарлыклы итеп чалырга, тиресенә пычак-мазар тидермәскә кирәк. Аның белән генә эш бетми әле, туналган тирене тозларга, саклау урынына куярга кирәк. Ул анда бер атна гына түгел, ай гына да түгел, бер ел, ике ел ята, бу вакытта аңа көя, тире корты тимәскә тиеш. Калганы — фабрика, конвейер, тире осталары эше. Бередә тирене сортка аералар, чылаталар, киптерәләр, химикатлар белән эшкәртәләр, буйыйлар, станоклар аркылы үткәрәләр. Күрәсез, бу хәтле мәшәкать белән чагыштырганда, явыз аждаһаны җиңү чүп кенә булып кала кебек. Әле тиренең эше бетте дигән сүз түгел, мондый эшләрдән соң да ул әле ярымфабрикат булып кына исәпләнә. Менә шуннан соң инде рәссам-модельерларга чират җитә. Әнә шул озакка сузылган ахыргы эшләрдән соң гына сарык туны «алтын тире»гә әверелә, затлы кием булып, кешеләрне сөендерә.

Чамадан тыш төгәл компьютерлар, куәтле лазерлар, заманның башка күп төрле ачышлары безне шул кадәр үзгәрттеләр ки, без көндәлек вак эшләргә бөтенләй кимсетеп карый башладык. Әмма ул «вак» эшләрдән башка иң камил техника да көчсез. Колхлар патшасының кызы Медея аргонавтлар башлыгы Ясонны юкка гына сак булырга өйрәтәме? Әгәр соңгы эшләрне башкарган чагында Ясон сак кыланмаса, аны берниндн тылсымнар да коткарып кала алмаган булыр иде. Киресенчә, техника никадәр камилрәк, технология никадәр югарырак булса, эшне башкаручыдан шулкадәр күбрәк осталык, төгәллек таләп ителә.

Дәүләт банкының сейфларын алты миллиард сумнан кемнәр мәхрүм иткәнне уйлый башласаң, иң беренче сәбәпчеләргә — мал көтүчеләргә килеп төртеләсең.

Илдә үрчетелә торган барлык сарыкларны ике төркемгә бүлеп карарга була — йонлыларга һәм тирелеләргә. Бер иш сарыклар йонны күп бирә, ә эре йонлы токымнар тиреләренең нык һәм чыдам булулары белән аерылып торалар. Революциягә кадәр Россия тунга яраклы сарыкларны күбрәк үрчеткән, сарык көтүләренең 95 проценты җылы киемгә, каты калын постауга

яраган, тик аз өлеше генә нечкә, нәфис йонлы сарыклар булган. Юккамыни ул заманда кайры тун һәм толып иң таралган кием була?! Олысы-кечесе, ир-аты, хатын-кызы да кышын өстеннән тунны төшермәгән.

Ләкин ул ерак заманнардан бирле инде сарык көтүләрендә бик күп үзгәрешләр булды. Барлык төбәкләрдә нечкә-нәфис йонлы мериносларны асрый башладылар. Хәзерге көтүләрдә нечкә-нәфис йонлы сарыклар — 90 процент, тупас йонлылар — 10 процент кына. Базарның сарыкчылыктан нәрсә таләп иткәнен онытып җибәрдек. Фән-техника прогрессы, яңа машиналар һәм станоклар, химия могҗизалары технологларга тирене башкача эшкәртергә мөмкинлек тудырдылар. Эстетик яктан да кыйммәтле, затлы товарлар барлыкка килде. Юккамыни соңгы елларда кайры тунны көтүчеләр түгел, башка социаль төркемнәр — кибетләргә, базарларга махсус хокуклары булган кешеләр генә кия ала.

Карганып-тиргәнеп утырудан, әлбәттә, мәгънә юк, моның сәбәпләрен ачарга кирәк. Хикмәт шунда — нечкә-нәфис йонлы сарыкларны, заманында кукурузны керткән кебек, алар өчен шартлар уңайсыз булган өлкәләргә дә көчләп тага башладылар. Әйтик, дымлы, яңгырлар гел булып тора торган көлсу туфраклы өлкәләрдә, тау-ташлы көтүлекләрдә нәфис йонлы сарыклар бик тиз авырый, ябыга, эштән чыга. Төньяк Осетиядә, мәсәлән, тау җәйләүләрендә җирле токым сарыклары ансатрак үсә иде, анда нигәдер җирле сарыкларны мериноислар белән бергә куштылар. Себердә калын йонлы кулунда токымы юкка чыкты. Россиянең үзәк өлкәләрендә бөтен дөньяга атаклы роман токымы бетү алдында тора. Ярославль өлкәсендә (роман токымы дөньяга шуннан таралган) 1976 елның январена андый сарыклар 220 мең баш булса, ун елдан соң 100 мең башка кимегән. Моннан егерме еллар элек тиресе тунга яраклы сарыклар 26 миллион булса, хәзер алар 13 миллионга гына калды. Хәл шуңа барып җитте ки, геннар фондын саклап калу турында кайнар сүзләр ишетелә башлады, чөнки элиталы роман токымы көтүләрдә нибары ике мең генә калган. Бу инде — чын һәлакәт!

Ә бит бу — безнең илдәге иң атаклы токым, аны заманында Петр патша үрчетә башлаган, шул эш өчен сарык үрчетүчеләрне Селизиядән Россиягә махсус чакырып китергән. «Роман токымлы сарыклар ике, хәтта өч бәрән имезеп үстерергә сәләтлеләр»,— диелә галимнәр биргән характеристикада. «Роман сарыклары бик үрчемле, дөрес тәрбияләгәндә алар елына уртача 4-6 бәрән үстерә алалар,— диелә икенче бер характеристикада. — Роман сарыгы үзенең үрчү сәләтен башка токымга да күчерә ала. Роман токымлы тәкәләр белән каплатканда төрле токымдагы сарыкларның үрчү сәләте 153-170 процентка җитә». Хәзинә бит бу!

Үкенечле хәл: сарык көтүләрен киң колач белән яңарту анык бер план белән алып барылмый, токымнар аерым төбәкләр өчен каралмый. Нечкә-нәфис йонлы сарыклар үрчетү белән мавыккан төбәкләр дә, тупас йонлы сарыклар үрчеткән яклар да — җирле шартларны исәпкә алмау сәбәпле,— берсе дә уңышка ирешмәде. Йон белән дә, тунга яраклы тиреләр белән дә мактана алмыйбыз.

Унынчы бишьеллык азагындарак сарык һәм кәҗә үрчетү Бөтенсоюз институты, ниһаять, токымнарны төбәкләргә билгеләп чыкты. Укымышлылар Ставрополь төбәгенә йонлы мериноислар үрчетү өчен шартлар юк икәнне әйткән чагында, ул төбәктә инде барлык сарыкларны нәфис йонлыга әйләндереп бетергәннәр иде. Шул сәбәпледер, бу төбәктәге төп тармак инде менә ничә еллар бер урында таптанырга мәҗбүр...

Өстебезгә киеп йөри торган тун хакында сүзгә керешкәнче, әйдәгез, сарык бәрәнен ничек үстерергә кирәклеге хакында сөйләшик әле. Сарыктан ничә бәрән алырга? Никадәр күп булса, шулкадәр яхшырак. Сыер елга бер бозау китерә, бүтәнчә булдыра алмый. Сарык гомер буе кешене ике яки өч бәрән белән шатландырып килгән. Ә менә без йөргән якларда — Кавказда, Идел буйларында, көлсу туфраклы өлкәләрдә, Уралда, Байкал арьягы көтүлекләрендә бер сарыкның ике яки өч бәрән ияртеп йөргәне сирәк, киресенчә — ике сарыкның бер бәрәнне «бакканнарын» күбрәк күрергә туры килде. Хәзерге заман гаиләсендәге төсле үк — бер баланы бабасы белән әбисе дә, әнисе белән әтисе дә карыйлар.

Тагын шунысы бар: сарык үрчеменең азлыгына бераунең дә исе китми. Татарстанның Биектау районы партия оешмасын Әптерәхим Мортазович Мортазин инде менә егерме өч ел буена җитәкли. Шушы чирек гасыр ча-

масы вакыт эчендә Биектау районы көтүчеләре бер гаҗәеп «казанышка» ирештеләр: алар көтүендәге ике сарык елына бер бәрән биреп килә. 1985 елны «Татарстан» колхозында 1613 сарык 447 бәрән китергән. «Красная Заря» колхозында 2 000 баш сарыгы булган көтүдән 313 бәрән алдылар. «Дөбьяз» совхозында, «Маяк» һәм «Алга» колхозларында сарыклар бәрән китерүне бөтенләй онытып баралар. Ләкин, әйтергә кирәк, бу — Биектауга гына хас күренеш түгел. Йөз баш сарыктан Менделеев районында — 37, Әлкидә — 44, Тәтештә 40 бәрән алалар.

Биектау районының беренче секретаре Ә. Мортазин моның сәбәпләрен үзенчә аңлатты:

— Бездә тире-мазар кайгысымыни? Ит, сөт, икмәк, яшелчә, бәрәңге әзерлисе бар. Башлар каткан...

Белэм: секретарьның хәсрәте сарык тиресе түгел, аның күңелендә кешеләр. Шуңа күрә мин сорауны башка яктан китереп бирәм:

— Ә нигә районның политик штабы терлек караучыларны, көтүчеләрне, бригадирларны, зоотехникларны, председательләрне һәм директорларны тәртипкә чакырмый? Ни өчен политик штаб кешеләрдә җаваплылык хисе, намус һәм вазифа үтәү хисе тәрбияләми? Хәзерге рәвешле барса, районда, гомумән, сарыклар калмас бит...

Эстониядә йөз баш сарыктан 130 бәрән алалар, дидек. Башкаларда хәлләр ничегрәк икән, аларга да күз салыйк. Грузиядә, сарык итеннән гомер буе шашлык ясый торган республикада, мәсәлән, йөз баш сарыктан 85 бәрән алалар. Азәрбайҗанда аннан бераз кимрәк. Белоруссиядә, Казахстанда, Төньяк Кавказда да шул ук хәл. Карачай-Черкесиядә, сарык үрчетү таулыларның мактанычы булган урында, 87 бәрән алалар. Әгәр РСФСРдагы терлекчеләр һәм зоотехникларның эш нәтиҗәләрен Балтик буе республикаларының уңышы белән чагыштырып карасак, һәр йөз баш сарыктан өч дистә бәрән кимрәк алуыбыз ачыклана. Табигый ки, сарык көтүләре ничек артсын да кибетләргә затлы туннар каян килсен?!

Инде исәпләп чыгардык: бер сарыктан өч тире алырга да, өч сарык асрап, бер тиресез калырга да мөмкин. Мех фабрикаларына исә ел саен 10 миллион данә стандарт булмаган тире килеп тора. Алардан тун тегеп булмый, бер уч йон гына кыркып алына. Ә ул 10 миллион данә тире безнең чималның чиреккә якынын тәшкил итә.

Моның сәбәбе нәрсә соң — сукырларча эшләүме, эшне үз агымына куюмы, әллә чимал әзерләүнең уйлап җиткерелмәвеме?

Элегрәк сарык тиресе нигәдер тиен генә тора иде, хәзер яхшы тирегә ун, унбиш, хәтта егерме сумга хәтле түлиләр. Моңа дәүләт бәясе белән 10 килограмм ит алып була ич! Ягъни ярты сарык. Ул гынамы? Әгәр колхозлар тире сатуны 95 процентка үтәсә, 30 процент күләмендә өстәмә акча ала. Зоотехниклар, бригадирлар, көтүче-терлекчеләрне дә онытмыйлар. Беренче сортлы тире тапшырган өчен һәрберсенә бүләк бирелә. Кооператорларга бу акчаны җиңел промышленность министрлыгы түли. Төп бәя, өстәмә бәя, премияләр... Бер сарыктан елга өч бәрән үстерсәң, алар өч тире бирсә, шуңа итеннән чыккан табышны да кушсаң, череп баерга була! Әмма бозылган тирегә бик аз түләнә. Тирене әрәм иткән кешеләрдән штраф базар бәясе белән алына. Бу дөрес, минемчә: дәүләткә югары сыйфатлы тире тапшырган өчен — рәхмәт сүзе, өстәмә түләү, зыян китергән өчен, ягъни сарыкларны бәрәнләтә белмәгән, тирене бозган, үз вакытында тозламаган өчен — штраф, бәяне киметеп түләү. Тегүче кулына килеп кергәнгә хәтле тире яхшы тун өчен кирәкле барлык сыйфатларын сакларга тиеш. Моның өчен шушы өлкәдә эшләүчеләр мораль яктан да, материаль яктан да җавап бирергә бурычлылар.

Сүздә шулай да бит, эштә гел алай булып чыкмый.

Бервакыт кызу җәй көнендә Балтач районы хәзерләүләр конторасы коммунисты Шакирҗан Гайсинның ничек эшләгәнен карап торырга туры килде. «Туры килде» дигән сүзем мәҗбүри кебегрәк ишетелә. «Карап тору бәхетенә ирештем» дип әйтү дөресрәк булыр. Балтачта сабан туена әзерләнәләр иде. Табын тулы ризык-нигъмәт булмаса, нинди сабан туе була ди ул! Җәйнең челләсендә сыер яки тана сую яраган эш түгел, тавык белән генә дә кеше көлдерергә килешми, мондый чакта иң әйбәте — тәкә чалу. Тәкәне алдан ук симертеп куялар. Мин Балтачка килеп төшкәндә дә лапасларда яшь тәкәләрне суеп, тиреләрен өрлекләргә элеп куйганнар...

Нәкъ шул чакта авыл урамнары буйлап, пар атта түгел, ялгыз ат җигелгән

арбада тире-яры белән эш итүче Шакирҗан Гайсин йөри. Кешеләр бәйрәм тойгысы белән канатланган, ә ул гаять дәрәҗәдә җаваплы эш башкара: яңа гына суйган тәкәләрнең тиреләрен җыя, бәясен түли.

— Кемгә бәйрәм, миндә тире кайгысы! — дип җавап кайтарды Гайсин, минем бәйләнчек сорауларыма каршы. Ә мин аңа:

— Нигә, кешеләр рәхәт чиккәндә, бәйрәм итмисез, бу эш беркая да качмый бит ул,— дигән идем.

— Ничек качмый?! — дип каршы төште Гайсин. — Көнен-сәгатен уздырып җибәрдең, тире юкка чыкты дигән сүз. Бәйрәм мәшәкате белән башлары әйләнгән хуҗалар аны ашык-пошык кына тозлыйлар, кайчагында онытып ук калдыралар, ә иртәгә инде соң була — тире эштән чыга. Сарыкның тиресе ике сәгать эчендә эшкәртеп куелган булырга тиеш, аннан соң инде аңа микроблар ябыша, хәзерләүләр конторасында андый тирене дүртенче сорттан гына алалар...

Салавыч авылы Советына кергән хуҗалыкларда 900 ләп сарык бар. Үзе эшли торган төбәктән Шакирҗан Гайсин ел саен бер мең тире җыя. Сарык башына бер тиредән артыграк. Бу сан Шакирҗанның күңеленә күптән кереп утырган, әгәр шуннан ким җыйса, аның йокысы йокы булмый.

Татарстанның тагын бер тире җыючысы — Рәфкать Галиуллин зонасы — Мари чигендәге Казаклар авыл Советына кергән өч авыл. Колхозчылар хуҗалыгындагы сарыклар шулай ук 900 баш чамасы. Галиуллин ел буена 300 тире җыя. Гайсин белән чагыштырсак, өч мәртәбә кимрәк. Нишләп? Нилектән бу? Ялкаулыктан, эшләргә иренгәнлектән. Галиуллин хуҗалыкларга үзе чыкмый, китергәнне көтеп ята. Эштән соң, көннәр буе фермада яки уттай урак өстендә басуда булганнан соң колхозчының Галиуллин янына барырга каян вакыты калсын? Тире лапас өрлегендә асылынып тора да тора, аны инде кортлар кимереп бетерә язган...

Менә шушындый мисалларны кайда да очратырга була. Кабарда-Балкариядә тау җәйләүләреннән «Заюк» колхозына төштек. Заюк — бер генә урам булып уникe километрга сузылган авыл. Зур шәһәрдәге төсле кибетләр, мәктәп, больница, Культура сарае тезелеп киткән. Авылның бер ягыннан шаулап-гөрләп тау елгасы ага, икенче ягында — ямь-яшел болыннар, Эльбрус түбәләрендә күзне камаштырып ак кар ята. Колхозның иң зур байлыгы — карачәй токымлы калын йонлы сарыклар. Тирә-як колхозларда нечкә-нәфис йонлы мериносларбелән шашканнар, аларның тау җәйләүләренә чыдамаслыкларын башларына китереп карамаганнар. Ә менә «Заюк» колхозының үзсүзле председателе Барасби Карданов мериноска алданмаган, калын тунлы сарыклар үрчеткән.

Беренче ачыклыйсы сорау: чимал ресурсларын арттырган өчен председатель һәм чабаннар дәүләт билгеләгән өстәмә түләүне алалармы? Бүләккә бирелә торган акча — 30 процент, берәүнең дә эчен тишми бит.

— Нинди бүләк? Нинди өстәмә ул тагын?! — дип гаҗәпләнде председатель Карданов.

— Яхшы эшегез өчен. Калын тунлы сарыклар үрчеткән өчен,— дидем мин һәм, куен дәфтәремне чыгарып, анда язып куйган сүзләрне укыдым: «һәрбер хуҗалык туксан биш процент сарык тиресе тапшырса, утыз процент өстәмә түләү алырга хаклы».

Барасби Карданов шундук телефонга ташланды. Аның кул астына нәкъ шул мәлдә Баксан районының хәзерләүләр конторасы директоры Абессин Мәриев эләкте. Ярсуы бугазына менеп җиткән председатель аны һәм аннан башка кооператорларны алдакчылар, караклар, шулерлар дип сүгеп ташлады. Ләкин район хәзерләүләр конторасындагы документларны карагач, күзем маңгаема менде. Баксаң-күрсәң, ни булдыклы председательләр дә хуҗалык-экономика механизмын начар беләләр, эшләрен әйле-шәйле генә башкаралар икән.

Ике-өч сүз белән генә аңлатыйм. «Заюк» колхозында сарыклар 20 меңгә якын. Саткан һәр тире өчен колхоз кооперациядән бер сум илле тиен акча алган. Бәясеннән үк күренә — түбән сортлы тиреләр, димәк. Ә башка колхозларга тире саен биш сум да сиксән тиен түләгәннәр. Димәк, гаеп тирене алучыларда түгел, тапшыручыларда. Колхоз җитәкчеләре, димәк, тирене товарга санамый, бүләк аларны кызыксындырмый, һәм алар җәза алудан, шелтәләрдән дә курыкмыйлар. Тугыз ай эчендә «Заюк» колхозында төрле сәбәпләр белән 2 мең 330 сарык суйганнар. Ә шуннан 1 мең дә 160 кына тире тапшырганнар. Калганы, күрәсең, яраксызга чыгып беткәндер...

Мех белән эш итүчеләргә тиренең яхшысы, бозылмаганы кирәк. Каян алырга андый тирене? Дөресрәге, андый тирене ник хуҗалыкларның барысы да тапшырмый? Материаль кызыксындыру, дәртләндерү кебек нәрсәләр төгәл эшләнми: эшнең нәтиҗәләренә карап түгел, конторада, өстәл янында утырган өчен акча түләнә. Тиренең беренче сортлысы бармак белән генә санарлык килә, бозыгы тау-тау. Тау-тау өелгәненнән затлы кием тегеп булмый, алар җилем кайнатырга гына ярый. Хәзерләүчеләрне дә тире түгел, йон кызыксындыра. Сарыктан йон гына түгел, тун да алу кирәклеген уйлаучы юк.

Йон планы дәүләт документларында аерым, басым ясап күрсәтелгән, йон планын үтәгәннәргә — дан, бүләк, юмарт түләү. Тире планда юк. Ничек бәяләргә соң тире тапшыруны? Барлык ресурсларның туксан-туксан биш проценты үтәлсә, тиренең яхшымы, начармы булуына карап түгел, аның нинди дә булса бер сортка эләгүенә карап, барысы бергә исәпләнә, кызыксындыру бүләге барлык тапшырылган тире өчен бирелә. Шулай булгач, үзеннән-үзе мәгълүм: колхоз һәм совхозлар тиренең сыйфатлы булуы өчен тырышмыйлар, аның өчен җавап тотмыйлар. Әйтик, кагыйдә буенча, сарыкны суяр алдыннан ике ай элек йоны алынырга тиеш. Алтмыш көн эчендә сарыкның өстендә тунга яраклы куе йон үсеп җитә. Ә чынында ничек? Бер генә председательнең дә, бер генә директорның да сарыкны суяр алдыннан кыркытмыйча җаны түзми. Нигә әле мин ит комбинатына сарыкны йоны белән җибәрим, анда бит аны барыбер суялар, дип фикер йөртә җитәкче иптәш. Бу нәрсәнең тыелганын да белә ул, әмма эшли. Чөнки материаль як һәртөрле күрсәтмәләрдән көчлерәк. Әлбәттә, ул моннан әллә ни йон да ала алмый, шулай да кемнәрнедер тунсыз калдыра.

Болар барысы да итәк астыннан, яшереп эшләнгән эшләр, аларны беркем дә сөйләп йөрми, әмма ит комбинатына тапшырыр алдыннан Төньяк Кавказда, Идел буенда, Урта Азиядә, Себердә, Балтик буе республикаларында, Украинада сарыкларның йонын бөтенләй кыркып алалар. Илебезнең мех фабрикаларын аерым йортлардан тапшырылган тиреләр түгел, колхоз-совхозлар тапшырган тиреләр һәлакәткә китерде бит. Өстәвенә әле тагын белешмә китапларда буталчыклыклар яшәп килә. Бер уставта, сарык, суйганга тикле, ике ай алдан кыркылырга тиеш, диелсә, икенче урында исә, тиредәге йон биш миллиметр калса, җитә, дип белдерелә. Кайсы председательнең биш миллиметрдан артык йонны бушка җибәрәсе килсен?!

Һәр төрле гамәлне аңлатып була, тик аклап булмый. Тире тапшыру кагыйдәләренә менә шундый кечкенә генә бер өстәмә язасы иде: тиредә калган йонның озынлыгы күпме булырга тиеш? Шуңа карап тиренең сыйфаты билгеләнсә, тиречеләр бер уч йонга кызыкмас иде, беренче сорт тиреләрнең саны бермә-бер артыр иде.

Мех промышленносте белән чимал хәзерләүче колхоз-совхозлар арасында кооператорлар арадашлык итә. Тун тегәргә яраклы беренче сорт сарык тиресенең ун квадрат дециметры 2 сум да 99 тиен, икенче сортныкы — 2 сум да 62 тиен, өченчесенеке — 1 сум да 88 тиен, дүртенчесенеке — беренче сорттан ике мәртәбә кимрәк. Туннар «королевасы» булган роман сарыгы тиресенә бермә-бер артык түлиләр. Беренче сортлы шундый зур тире өчен 40 сумга хәтле акча алып була. Ресурсларны булдырган өчен түләнә торганны, бүләккә бирелә торганнарны да кушсак, кооператорлар кулыннан ел саен күпме акча узып тора!

Ил буенча исәпләгәндә хосусый секторда 26 миллион сарык бар. Бу, әлбәттә, тотрыклы сан түгел, ел килешенә карап, ул үзгәреп тора, әмма әлеге санны нигез итеп алырга була. Үз хуҗалыкларында йөз сарыктан йөз бәрән алып үстерәләр, дип уйласак, ел саен хосусый сектор, уртача, 20 миллион сарык тиресе тапшыра ала. Татарстанда эшләүче Шакирҗан Гайсин мисалын гына искә төшерик. Ләкин аның тәҗрибәсен ни үзебездә, ни башка республикаларда файдалана белмиләр.

Колхоз һәм совхозлар тапшыра торган тирене онытып җибәрә язганбыз. Алар да ел саен 20 миллион тире тапшыра. Димәк, барлыгы — 40 миллион тире дигән сүз. Шулай булгач, аңлашыладыр: кооператорлар үзләре генә дә бүгенге тире тапшыру планын үти ала. Ә чынында хәлләр ничек? 1971 елны кооператорлар «Союзмехпром» фабрикаларына 18 миллионнан аз гына артык тире җыеп тапшырдылар. 1985 елны — 22 миллион тире. Шундук бу санга игътибар иттем: үсеш — стандарт булмаган тиреләр бәрабәренә. Әгәр 1971 елны шундый «чүп-чар»ны кооператорлар 3 миллион данә тапшырсалар, 1985 елны инде 8 миллион чамасына җиткергәннәр.

Мехчылар, базарлардагы «чүп-чар»дан ничек котылырга белмичә, тире тапшыручыларга үпкә белдерәләр, ә тегеләре үз чиратларында явыз көндәшләр хакында сүз кузгаталар: авылларда тире иләүче аерым коллективлар барлыкка килгән, имеш. Ләкин, көндәшләре белән көрәшкә чыккан чакта да,

кооператорлар тирене яхшы чагында, алданрак эләктереп калырга тиешләр иде, ләкин алар ашыкмыйлар, тәртип сагында торучы органнар аркылы эш йөртергә яраталар. Прокуратура, милиция, халык контролерлары, совет һәм партия органнары аларны якласын, хосусый җирлектә эшләүчеләрнең юлын ябып куйсын, имеш! Бу хәл илгә җиңеллек китерәме? Юк, әлбәттә. Аерым ведомстволар, министрлыкларның гына мәнфәгатен яклый. Татарстанда, мәсәлән, кооператорлар, Бөгелмә шәһәре прокурорына мөрәҗәгать итеп, Карабаш поселогында эшләгән бәләкәй фабриканы ябуны таләп иттеләр. Прокурор ярдәмчесе С. Бабичев ул фабриканы ябу өчен җирлек юк икәнне аңлатып хат язды. Көрәшкә Центросоюз килеп кушылды, алар СССР Эчке эшләр министрлыгына мөрәҗәгать иттеләр: янәсе, авылда тиреләрне читкә шудыручылар табылды, «туннар», янәсе, дәүләт конвейерыннан читкә агыла, «әрәм-шәрәм итү фактларына чик куелсын»...

Килделәр, тикшерделәр, күңелләрендә яңа бер уй туды: булган фабрикаларны туктату түгел, яңаларын ачарга кирәк! Булган тиреләрне әрәм-шәрәм итмәсәң, мех комбинатларына да, авыллардагы кечерәк остаханәләргә дә эш — муеннан!

Кавказдагы сарык көтүләре янында булган чакта тире-яры белән эш итүчеләрне күп күрдек без. Алардан да гамьсезрәк, алардан да ялкаурак тагын берәүне табып булыр микән? Тире җыймас өчен нинди генә хәйләләр уйлап тапмыйлар алар!

Карачай-Черкесиянең Зеленчук районы Ленин исемендәге колхозында кооператорларга тапшырыла торган тиренең сыйфаты өчен амбарчы Иван Максимович Овчаренко җавап бирә. Колхозның сарык көтүе 10 мең башка җитә. Барлык тиреләрне дә беренче сорттан тапшырсаң, бу хуҗалыкка 60 мең сум премия тия.

1983 елны Иван Овчаренко, көтүчеләр белән дуслашып, тиреләрнең сыйфатлы булуын гына кайгыртып калмаган, сарыкларның көр булуын, тизрәк үсүләрен дә тәэмин иткән. Кооператорлар колхоз тапшырган өч тиренең берсен беренче яки икенче сортка кабул иткәннәр. Колхоз һәр тире өчен 7 сум 20 тиен акча алган. Менә кайда ул табыш!

Уңышка сөенүче генә түгел, эче пошучылар да табыла. Бер мәлне колхоз председателе В. Мишуринский тире җыючының исәп-хисап кенәгәсенә күз сала. Председательне тиреченең кенәгәсенә язылган 3 мең дә 96 сум премия акчасы таң калдыра! Бу бит председательнең бер еллык хезмәт хакы! Китә шуннан хәлләр! Югарыдан күрсәтмәләр ташкыны агыла башлый. Карачай-Черкесия агропромы председателенең беренче урынбасары И. Бизиков, автономияле өлкәнең хәзерләүләр буенча баш инспекторы Д. Бошко өлкә потребительләр союзына мөрәҗәгать итәләр: «Хәзерләүләр конторасына, колхоз һәм совхозларның җитәкчеләре, профсоюз оешмалары белән килешенмичә торып, премияләр бирүне туктатырга!..»

Кызык хәл бу. Дәүләт кооператорларга зур акча белән эшләү хокукын тапшырган. Бу әле бер генә кешегә премия тоттырып җибәрү дигән сүз түгел, ул акча бу эштә катнашы булган һәммә кешегә дә бүленергә тиеш. Ә кемгә күпмерәк тиешле икәнен кем хисаплап чыгарыр? Карачай-Черкесия өлкә потребительләр союзының хәзерләүләр идарәсе начальнигы М. Карданов, кисәтүле шундый кәгазьне алганнан соң, күп баш ватып тормаган, «махсус күрсәтмә бирелгәнче премияләр түләүне туктатырга» дигән телеграмманы барлык контораларына җибәргән.

Бәхәс күпергән. Премияне бүлеп бирә башлыйлар. Сарык тиресенә бернинди дә катнашы булмаган кешеләр акчалата бүләк ала. «Ленин» колхозында 7 мең дә 86 сум акчаны 96 кешегә бүлеп бирәләр. Берәүгә — ике сум, икенчесенә — 10 сум, өченчесенә — 200 сум. Тире җыючы Овчаренкога — 79 сум. 5 мең 60 тире тапшыра, шуның 3 мең дә 56 данәсе — дүртенче сорт, калганнары — аннан да түбәнрәк бәягә кабул ителә. «Түбәнрәк» дигәнебез — бозылган тире. Тире башына түләү өч сумга кимрәк булып чыга, колхоз мондый түләүдән 15 мең сум акча югалта. Хәзер Карачай-Черкесиядә бүләк акчаны күмәк исемлек белән бирәләр. Мәсәлән, Зеленчук районының XX партсъезд исемендәге колхозында председатель һәм баш белгечләр 1200әр сум, баш бухгалтер 1023 сум, аның ярдәмчесе 840 сум алган.

Күрсәтмәләр бирүче чиновник законнан өстен булып чыкты! Хәзер мех фабрикаларына Карачай-Черкесиядән килгән тиреләр арасында уннан бере генә тун тегәрлек, ә дүрт тиренең берсе йонын кыркырга гына яраклы. Унберенче

бишьеллыкта автономияле өлкәнең хуҗалыклары, тиреләрнең сыйфаты түбән булу сәбәпле, дүрт миллион чамасы табышларын югалттылар. Ә дәүләткә, сатып алучыларга тагын да зуррак зыян китерделәр. Күпме тун, күпме затлы бүрек тегелми калды.

Кооператорлар, дөресен әйткәндә, үзләренә тигән өлешне генә әзерлиләр. Тиренең күпчелеге ит комбинатларыннан килә. Ит конвейерында нәрсә безне аптыраштa калдырды? — Хуҗасызлык! Валлаһидыр, әгәр, колхозчылар хәтта тирескә дә сугымчылар сарык тиресенә караганнан әйбәтрәк карыйлар.

Ерактагы кәтүләрдә, сугымчылар өчен берninди дә шартлар юк, аргонавтлар заманында, моннан меңнәрчә еллар элек, ничек булса, хәзер дә шулай. Сарыкларны кулдан суялар, кулдан туныйлар. Ә ит комбинатларында эшне техникага корырга мөмкин, барлык кагыйдәсен саклап, чиста-пөхтә итеп эшләргә мөмкин, тиренең төрен-төргә аралап, нафталин сибеп, кәгазь белән төреп, пломбалап куярга була. Ул чагында тире бозылмый. Мех осталары, чынында, ит комбинатларыннан нәрсә ала соң?

Без Татарстанның Хөсәен Ямашев исемендәге Ленин орденлы мех берләшмәсендә тире сайлаганнарын карап тордык. Ай азагы җитеп килә, планны тутырыр өчен мехчылар илле данә тун тегеп өлгертергә тиешләр, үкенечкә каршы, кул астында — череп, ертқаланып беткән тире кисәкләре генә.

— Чимал базасы түгел, чүп базасы бу,— дип зарланды безгә база директоры Дания Сафиуллина, үзләренең тау-тау запасларын күрсәтеп. Биредә биш мең кеше эшли. Шуларны шөгыльләндерерлек тире кирәк. Чит илләрдә мондый зур масштаблы предприятиеләрдән куркалар, ә биредә биш мең кеше, югары квалификацияле осталар гадәти сарык тиресен «алтын тун»га әйләнделәр. Кеше саны никадәр күбрәк булса, шулкадәр оешканрак эшләү таләп ителә.

Очерк — документаль жанр. Монда автор фактлар, саннар, мисаллар белән эш итә. Менә мисалга рәсми документлар китерәм.

«... Сибай ит комбинатыннан (Башкортстан) 21009022 нче вагонда, 1986 елның 15 сентябрендә 71 нче таныклык белән 10472 данә сарык тиресе килде. Чимал кызган, эче кызарган, мурган, ис аңкып тора. Изоляторга бушаттык. Иокне җибәрүчеләргә телеграмма сугылды».

«... Шушы елның 24 сентябрендә Архангельск ит комбинатыннан 22970776 нчы вагонда 913 нче таныклык белән йөк алдык — 10095 данә тире. Чимал бик нык кызган, тиренең эче кызарган, мурган, ис аңкып тора...»

«1986 елның 27 сентябрендә Георгиевск ит комбинатыннан (Ставрополь өлкәсе) 22300040 нчы вагонда 188 нче таныклык белән 9075 данә сарык тиресе килде. Чимал нык кызган, тиренең эче кызарган, бозылу алдында».

«1986 елның 11 сентябрендә 73-60 ВДЗ автофургонында 112751 нче накладной белән Белгород ит комбинатыннан сарык тиресе килде... Чимал кортлаган, игән. Аны эшкәртерлек түгел. Автофургонны, пломбалап, киредән җибәрергә туры килде».

Казан мехчыларының СССР Халык контроле комитетына җибәргән документында мондый юллар бар:

«... Мех берләшмәсе эшчеләрне төп эшләреннән аерырга мәҗбүр булды: чималны кабаттан сортларга аерырга, төрергә һәм яраксыз чималны кире җибәрергә туры килә. Моның өчен вагоннар алуга акча тотылды. Фабрикаларыбыз ел саен черегән-мурган бик күп тире ала, алардан берninди дә кием тегеп булмый. Шундый яраксыз чимал хәзер базада 800 мең данәдән артыграк җыелды...»

Хәзер безне чабаннарның ике сарыктан бер бәрән алулары да, кооператорларның мурган-игән тире җибәрүләре дә гаҗәпләндерми, ә мехчыларның шул черек чималдан азмы-күпме кием тегүләре шаккатыра.

Бу мәсьәләне унсигез ел буена өйрәнәбез, ләкин бу өлкәдәге тәртипсезлекләрнең очы-кырые күренми әле. Һәртөрле өндәмә-чакырулар, директивалар, халык контролерлары ярдәм итми икән инде, нигә прокурорлар кул кушырып утыра? Әйдәгез, Россия Федерациясенең Җинаятьләр кодексын актарып карыйк. Бөек комбинатор Остап Бендер булып ул да җинаятьләр кодексын таныган бит! 172 нче статьяны карыйк. «Предприятие яки оешма җитәкчесе тарафыннан... дәүләт яки җәмәгать милкен файдаланган чакта, зур зыян китерелә икән, ул бер елга чаклы ирегеннән мәхрүм ителә яки төзәтү эшләренә җибәрелә яки аңа 300 сум күләмендә штраф салына, эшеннән азат ителә...»

Кыскасы, җәзага тартыла!

Ачыктан-ачык әйтелгән бит. Тәртип сагында торучыларга тагын нинди күрсәтмә кирәк? Гаҗәп: прокурорлар күзгә бәрелеп торган хуҗасызлык белән көрәштә үзләре инициатива күрсәтмиләр генә түгел, алар әле башкалар башлаган эшне дә якламыйлар.

Черкесск каласында, өлкә газетасы «Ленин байрагы»нда «Бер сыердан ярты бозау» дигән мәкалә басылып чыкты. Анда колхозларның берсендә сыерларны баш саны өчен генә асраганлыклары фаш ителә. Мәкалә түгел, тулы бер гаепләү сүзе! Карачай районының прокуроры Б. Марченко колхоз председателен җавапка тартырга теләгәч, райбашкарма комитеты җитәкчесе аны туктата, чөнки теге гамьсез председатель район Советы депутаты икән. Халык депутатларының статусында: «Законнарны, хезмәт дисциплинасын саклау буенча депутат башкаларга үрнәк күрсәтә»,— диелгән. Шул ук газета тагын бер принципиаль мәкалә бастырып чыгарды. Анысы «Миллионнар — аяк астында» дип атала. Сортлы тиреләр җибәрмәү аркасында Н. Бударин җитәкләгән колхоз меңнәрчә сум зыян күргән. Бик тә җитди сигнал инде югыйсә, әмма андый мәкаләләрне хәзер председательләр бар дип тә белмиләр, чөнки яклаучылары бар.

Хәер, игътибар ителгән бер факт булган икән. Премия «реформаларыннан» соң Зеленчук район прокуроры В. Братсков гаеплеләргә 11 мең дә 96 сумга дәгъва белдергән. Район суды дәгъваны кире каккан, сәбәбен колхозда «тиешле шартлар юк» дип аңлаткан. Көлке түгелмени бу? Кичә ул шартлар булган, бүген, димәк, ул шартлар юкка чыккан! Ниһаять, ул шартларны кем тудырырга тиеш соң? Халык байлыгын әрәм-шәрәм итүчеләргә каршы кем көрәшергә тиеш?

Беренче дәгъваны, әлбәттә, мехчылар башлый. «Союзмехпром» предприятиеләренә ел саен 10 миллион данә сарык тиресе керә, әмма алар, үкенечкә каршы, эшкә ярамыйлар. Бозык бер тиредән бер кадак «үле» йон алалар, ул киез сугудан бүтәнгә ярамый. Тире саен — бер сумлык зыян. Тире үз-үзен акламый, йонын кыркып алганнан соң ул җилем кайнатырга китә. Ел саен 10 миллион сумлык зыян! Бу бит — халыкка ирешмәгән бер миллион тун. Затлы тунның бәясе — 800 сум. Димәк, сәүдәдән тагын күпме табыш керми кала? Мәрхүм Аркадий Райкин әйтмешли: «Уһу-һу!»

Фабрикага килгән чималны җәен — егерме, кышын утыз тәүлектә кабул итәргә тиешләр. Шушы вакыт эчендә чималны алучы аны саклый белергә тиеш. Монда да гел бәхәс чыга.

1985 елның 28 августында Татарстан кооператорлары Киров тире-чимал заводына 4 мең дә 300 тире җибәрә. Чималны өч айдан соң кабул итәләр. Бу вакыт эчендә 1200 тирене корт ашаган, 300 е күгәргән. Сортларны кабат барлап чыгу — 5 меңне чигерә. Шушы ук елны Түмән мех фабрикасында Кайбыч хәзерләүләр конторасы җибәргән сарык тиресен ике айдан соң гына алалар. Беренче сорт — бер йөзгә, икенче һәм өченче сорт тиреләр 350 данәгә кимегән, дүртенче сорт тире бөтенләй булмаган, хәзер ул сортлар да барлыкка килгән, өстәвенә әле 50 тирене стандарт түгел дип саныйлар.

Мондый чакта чималны алучы, кабул итүне сузганы өчен, штраф түли, ә товар бирүчеләр партнерларына бәясе төшкәннең суммасын 200 процент итеп түлиләр.

Эшләр шулай бара. Ил буенча бер кесәдән икенчесенә, миллионнар күчерелә, әмма чимал яхшырмый, туннар кибетләргә килми.

«Тире эпопеясы»н аңлау өчен чылбырның очына ук чыгып карыйк әле. Әгәр мехчылар чималны ит комбинатларыннан ук кабул итеп алсалар, ничек булыр иде икән? «Союзмехпром» берләшмәсенең генеральный директоры Раиса Барулина, әлеге фикерне әйткәч, күтәрелеп бәрелде:

— Сарык тиресе эзләп йөрмәсәк, башка эшебез беткән иде!

Күрдегезме, нинди эре сөйләшәләр! Начар чимал килгәнгә күз яше түгәләр, хәлне яхшырту өчен, аркылыны буйга алып салмыйлар. Хөрәсәннәр, дими, кем дисең инде боларны?!

Элекке еллардагы документларны актарып карадык. Әле партиянең XXV съездында ук халык хуҗалыгыннан чимал алу, партнерлар арасындагы мөнәсәбәтләр хакында стратегик программа кабул ителгән — чимал җыюны производствоның үзендә булдырырга, диелгән. Күпме еллар узды — үзгәреш юк. Бюрократлар аппараты таш кыя кебек: ике бишьеллык узып китте, мех һәм тун өчен кирәкле чималны кабул итү өлкәсендә кыл да

кыймылдатылмаган. Кайбер заводлар сөтне фермалардан килеп алалар, чөнки сөт әчесә, алар файдасына түгел, итне дә сыер-сарык көтүләреннән килеп алу гадәткә кереп бара, ә мехчыларның, сугым җиренә барып, бер генә тире дә алып кайтканнары юк әле.

Партиянең XXVII съезды революцион үзгәртеп кору программасын кабул итте. Үзгәрешләр адым саен, алар хезмәт коллективларыннан уйлана белү, кыюлык таләп итәләр. Мехчылар да, тире хәзерләүчеләр белән үзара килешеп, эшләрен үзләренә җайлы юнәлештә җәелдереп җибәрә алган булырлыр иде, ләкин чималның директив юллар белән китерелүенә генә исәп тоталар. Мехчылар өлкәсез дәгъвалашканга күрә, чимал тапшыручыларны стимул белән эшләтү кире кагылды. Моңа карап бераү дә отмады. Сарык тиреләре ишегалларында, лапасларда аунап ята башлады, череде. Дөрес, тире эшкәртү тармагы, бердән, барлык тиреләрне дә эшкәртеп бетерәбез, дип йөкләмә алды, икенчедән, тире тапшыручыларга чимал бәрабәренә әзер киемнәр белән дефицит товарлар сатарга вәгъдә итте.

Нәтиҗәдә фабрикалар яраксыз тирегә батты, хәзер мехчылар ул чималдан ничек котылырга белми аптырыйлар. Тире тапшыручылар да алданган икән: затлы киемнәрне, бөтен бер төбәктә тире тапшыруны тулысынча үтәгән суратта гена бирәселәр икән! Егерме яки кырык районның берәве генә план үтәмәсә дә, туннан колак кагасың.

Яңадан эшкә тотынып, өр-яңа кагыйдәләр уйлап чыгардылар: туктатылган бәләкәй фабрикалар, мастерскойлар эшкә җигелде, урыннардагы сарык тиреләренең бер өлеше яңадан төбәкләрнең үзләрендә эшкәртелә башлады. «Союзмехпром»ның фабрикаларын стандарт булмаган тиреләрдән тизрәк коткару өчен ашыгыч рәвештә яңадан-яңа көчләр тартыла, дәүләт агропромы, кооператив артельләр эшкә җигелә. «Тизрәк, кызурак!» дигән чакыру авазы һәркайда ишетелә.

«Союзмехпром» фабрикалары гына ашыкмыйлар, уңайлы шартлар туганны көтеп яталар. Зарланып, күз яше коеп кына берни дә майтарып булмаганны, күз яшен сөртеп ташлап, эшкә тотынып вакыт җиткәнне алар әле һаман аңламыйлар.

Россиядә кайры тун тегә башлаганга гасырлар узган, әмма гап-гади сарык тиресеннән затлы мех эшли башлауларына әллә ни күп түгел әле. 1958 елны Брюссельдә үткәрелгән Бөтендөнья күргәзмәсендә Казан мехчылары күрсәткән затлы мех киемнәргә — селәүсен, ягуар, юлбарыс, жираф тиресе төсендәге туннарга Европа кешеләре сокланып таң калып тордылар.

Вакыт әкиятләрне чынга әйләндерә. Кыю аргонавтларның «алтын тире» эзләп газап чигүләре бушка китмәде, димәк. Затлы тунга затлы акча түләнә! Тик Брюссельдә күрсәтелгән туннарны кайчан күпләп тегәрләр икән? Хәсәен Ямашев исемендәге Казан мех берләшмәсе белгечләренә беренче сорау:

— Көнбатыш Европа чибәрләрен көнләштергән затлы киемнәребез кайчан үз кибетләребезгә чыгар да, кайчан аларны һәркем сатып ала алыр?

Берләшмәнең баш инженеры Илфар Кәримович Сабиров җилкәсен сикертеп куйды:

— Әй, юк әле, тиз генә булмас. Күргәзмәләр, конкурслар — бер нәрсә, күпләп җитештерү — бөтенләй икенче нәрсә бит ул. Безнең тәҗрибә мастерскоенда булдыгызмы?

— Юк әле.

— Күргәзмәгә куелган аерым үрнәкләр белән без хәзер дә теләсә кемне шаккатыра алабыз. Ә менә базарларда... үзебездә һәм чит илләрдә сәүдә итәрлек тун тегү хыялда гына йөри. Безнеке төсле гигант конвейерда елына ике мең йөнтәс тун, бер мең кайры тун тегү нәрсә ул? Кечерәк бер каланы киендерергә дә җитми.

Икенче сорау да әзер:

— Нигә? Сарык көтүләрендә, терлекләр өстендә 60 миллион тире бар ич. Шуның өстенә тагын читтән ун миллион тире алабыз. Чимал әнә нихәтле, кисеп-тегеп кенә өлгерт!

— Хикмәт сарыкларда гына булса икән!— Сабиров моңсу гына баш чайкап куйды.— Сарык өстендәге тунга алданырга ярамый. Җылы, җайлы, әмма безнең өчен түгел әле ул. Аны безгә яраклы итәр өчен тегү машиналары да кирәк, буяулар, химикатлар. Алардан башка иң зур оста да берни майтара алмый. Корал эшләр, ир мактаныр, диләр.

Бар иде шундый заманнар, Казан мехчылары җиде-сигез миллион сарык тиресен эшкәртеп өлгерәләр иде. Сугыш вакытында алар тәүлек саен бөтен бер полкны баштанаяк киендерә иделәр. Хәзерге нәтиҗә ике мәртәбә кимрәк — дүрт миллион тире эшкәртәбез. Иң зур кыенлык — белгечләр җитешми. Унберенче бишьеллыкта фабрикаларыбыз бер мең ярым эшче югалтты, станокка наркология диспансерына йөрүчеләрне куябыз. Алардан нинди оста чыксын инде?! 1985 елны вакытлыча алынган эшчеләр 4876 га җыелды. Ягез, алар ни кыра ала? Мехчыларның тәҗрибәсе мең еллар буена тупланып килгән. Бер-ике атна эчендә бирәү дә осталыкка ирешә алмый. Әнә шулар аркасында Казан мехчылары 1985-1986 елларда илгә унбер миллион сумлык товарны биреп җиткермәделәр. 460 мең сум штраф түләдек. Кеше факторы — менә нәрсә ул!

— Ә реконструкция?

— Безнең планнарда бар анысы. Производствоны тамырдан үзгәртеп корырга исәп. Хөкүмәт безгә кырык миллион сум акча бирде. Шулай да техник революция булмаячак. Цехларга нәрсә куярбыз соң? Роботлар, автоматлар, компьютерлармы әллә?

— Ә нигә? Автоматлаштыру, кибернетика — прогрессның төп юнәлешләре ич?

— Үкенечкә каршы, андый юнәлешләр безнең фабрикаларны әйләнеп уза. Проектлары белән таныштык: шул ук иске машиналар...

Без ярты юлда туктап калмаска, мәсьәләне ачыклап бетерергә тиеш идек. Мех конвейерына юнәлдек — файдалы әйләнешне арттыра торган түгел, киметә торган конвейерга, югалту, төшенкелек, офтанулар конвейерына.

Сабиров — шушы берләшмәдә үскән инженер. Хезмәтен эшче буларак башлаган. Мех эшкәртү серләрен биш бармагы кебек белә, шунлыктан сарык тиреләрен чаннарга ничек тутырудан алып, тунны ничек тегүләренә кадәр, профессиональ осталык белән төп-төгәл аңлатып бирде.

— Минем беренче эш урыным менә шушында, конвейерның башында ук,— дип, Сабиров зур чаннарга күрсәтте. Резин алъяпкычлы эшчеләр авыр тиреләрне чангa тутыралар иде. Һәммә нәрсә беләк көченә таяна әле монда. Икенче корпуста тире майлый торган машиналарны карадык. Берсе эшли, икенчесе тик тора.

— Нигә берсе ял итә?

— Эшләми торганын җиңел промышленностьның махсус заводында ясадылар, хезмәт итеп торганын Казан самолет төзүчеләре, сүз тыңлап, ясап бирделәр. Эшләми торганы ике мәртәбә кыйбатрак...

Конвейер буйлап алга узабыз. Иөзләгән пулемет атып торган җир бар дип уйлагыз. Дөпелдәү-дөбердәү шул хәтле көчле, кеше тавышы бөтенләй ишетелми. Тегүче Евдокия Гайсина, безнең белән сөйләшер өчен, машинасын туктатырга мәҗбүр булды.

Шушы тегү машиналарында инде без сугыш вакытында Ленин ордены яулап алдык. Сугышка катнашкан танклар кебек тыкырдыйлар.

— Тавышсыз машина юктыр инде ул.

— Бар шул.— Ул безне башка бер тегү машинасына алып килде. Машина, һичнинди тавыш чыгармыйча, тип-тигез «юл тезә».— Импорт буенча алынды. Бездә болар бик аз. Дөбердәп утыручы «пулеметлар» буа буарлык! Конструкторларыбыз сүз туглаудан ары узмыйлар...

Күңел ачыргалана, моңсу уйлар баш калкыта. Мехчыларның эш урынында озаграк булган саен, алар куера гына төшә. Агач аерым ботаклары корудан корый башлый. Җимерелеп килүче, беркем да ярдәм итә алмый торган бу предприятие дә шундый агач кебек.

Татарстан мех берләшмәсе фабрикаларында 3 мең дә 612 җиһаз бар. Биш ел элек куелган машина һәм аппаратлар саны — 873, ун еллыклары — 1370, унике еллыклары — 1107, бик борынгылары, амортизация вакыты чыккannары — 262 данә. Фән-техника революциясе чорында исә станоклар паркын яңартуның оптималь чоры ун елдан да артмаска тиеш. Димәк, Казан мехчыларының искергән станоклары һәм аппаратлары 1300 дән артык. Күбрәк түгелме бу? Хыял һәм теләкләр кайчан гамәлгә ашар? Кайчан яңарыр борынгы комбинат?

**Кайчандыр илебездәге сарык тиреләренең яртысын эшкәртеп торган, инде менә чигенә башлаган борынгы мех гигантыннан туп-туры Мәскәүгә юл тоттык. Җиңел промышленностьның Бөтенсоюз институтына килдек. Сораулар мәгълүм: реконструкция үткәре-**

сез, миллионлаган акча тотасыз, ә конвейерларда берни үзгәрми, кичәге үк машиналарны һәм станокларны гына арттырырга ният кыласыз икән бит? Шулай ярыймыни инде?

— Әллә сез безнең профессиональ горурлыгыбыз юк дип беләсезме? Автоматлар һәм компьютерлар кем бәхетенә ясала соң? Егерме беренче гасыр производствосын күрү әллә безгә күңелле түгелме?— дип каршылады мине Татарстан мех берләшмәсен реконструкцияләү проектының баш инженеры Светлана Александровна Прошкович.— Элеккеләреннән яңарак машиналарны промышленность чыгармый, импортныкыларга исәп тотып булмый, андый проектны беренче экспертиза ук кире борачак. Шуңа күрә проектка элекке машиналар салынды. Дөрес, алар беребезгә дә шатлык китерми. Әйтегез, нишлик?

«Легпищмаш» буенча Союз министры Лев Васильевның Мәскәү «Неделя»сында чыккан әңгәмәсен иске төшерик. «...Без үзебез чыгарган техника эшли торган тармакларда кешеләрнең аз булуын, продукциянең күбрәк житештерелүен, сыйфаты ягыннан дөнья чыгарган машиналар дәрәҗәсенә күтәрелүен генераль бурычыбыз дип саныйбыз... Җиңел промышленность тиз арада автоматлашкан заманча җиһаз алачак. Ул җиһазлар инде уникенче бишьеллыкта ук хезмәт җитештерүчәнлеген шактый югары күтәрергә ярдәм итәчәк, алдагы эш завод-автоматларга йөз тота...»

— Без — җитди оешма,— диде проектның баш инженеры, министрның әңгәмәсенә ачыклык кертеп.— Проектларга һәм сызымнарга хыяллар түгел, гамәлдәге машиналар салына. Ә сез сызымнарга өмет-хыялларны күчерергә кушасыз...— Прошковичның елмаюы моңсу һәм кайгылы тоелды.

Алдан күреп эш итүче легендар аргонавтлар сарык тиресенә байлык җыю чыганагы дип караганнар. Алар аны алтын бөртекләр йөзгән елга төбенә төшәргә исәп тотканнар. Су тире өстеннән агып ята, ә кыйммәтле алтын бөртекләре йон арасына утыра. Ягъни тире фильтр хезмәтен башкара. «Алтын тире» дигән исем дә шуннан калган!

Гап-гади бер сарык тиресен кыйммәтле киемгә әйләндерү өчен йөзләгән катлаулы технологик эш башкаралар. Аргонавтлар ролендә бу юлы берничә кеше түгел, барлык дәүләт катнаша.

Җиңел промышленность министрлыгы составында Бөтенсоюз фәнни-тикшеренү институты бар. Ул — Мәскәүдә, «Союзмехпром» белән бер үк бинада. Производство белән фән кулга-кул тотынып эшлиләр, дип курыкмыйча әйтергә була. Бу тармакка ел саен 4 миллион сум акча бирелә. Фән-техника революциясе заманында моны әллә ни зур акча дип әйтеп булмый, шунлыктан тармак фәненең мех производствосына йогынтысы азрактыр да әле.

Ләкин хикмәт шунда: галимнәрнең ачышлары мехчыларга барып җитми. Ник? Нилектән? Җавабы бик гади. Һәрбер технологик идеяне гамәлгә ашырыр өчен машина, агрегат, аппарат һәм химик препаратлар кирәк. Боларны исә башка предприятиеләр җитештерә. Мех индустриясен җиһазлар белән тәэмин итү СССР Җиңел һәм азык промышленносте машиналарын төзү министрлыгына йөкләтелгән. Ә ул министрлык үз фәнни институтларына таяна. Аларның заводлары да аерым. Нәкъ Крылов мәсәлендәгечә килеп чыга: аккош күккә омтыла, чуртан елгага сөйри, кысла артка чигенә.

Ачуны бер читкә куеп, документлар теленә күчик. Грибановскида Казан мех берләшмәсенә майлау машинасы ясап бирделәр. Җитешсезлекләре шундый: «циркуляция җайланмасы начар эшли», «аерым кисәкләрен алмаштырыр өчен ярты агрегатны сүтәргә кирәк», «тулаем алганда, машина ышанычлы түгел»... Йон кыркый торган машинага мондый бәя бирелгән: «җилләткече көчсез», «пычакны көйләү кыен», «тулаем алганда, ышанычсыз». Андый машиналар, агрегатлар төрле экспертизалардан ничек узадыр, фабрикаларга ничек килеп җитә торгандыр, аңлавы кыен.

Техника килә, карыйсың — брак, башлана шуннан төзәтү, камилләштерү, җиренә җиткерүләр, алар унар елга сузыла. Шул вакыт эчендә бичара мехчылар хезмәт җитештерүчәнлеген ничек күтәрергә дә ничек итеп алгы сафка чыгарга тиешләр инде?! Җитмәсә, әле аның чималы да — иске-москы, йолкыш, бозык тиреләр!

Илне үзгәртеп коруга китергән «могҗизалар» әнә шулар!

Төрле-төрле механизм, станок, аппаратлар, гомумән «тимер-томыр» белән эш итүне безнең илдә күбесенчә ир-атка тапшырып килә. «Союзмехпром» главкасында, ниһаять, баш механик вазифасын хатын-кызга — Галина Лесниковага тапшырганнар. Ахыры хәерле булсын, дип әйтик. Әгәр аның урынында берәр ир-ат булса, машина төзүчеләр белән мехчылар ара-

сындагы мөнәсәбәтләр турында төгәл мәгълүмат ала алыр идең микән? Ул сүзен зарланудан башлады:

— Мехны бик яхшы эшкәртү, барлык технологик процессларны узып чыгу өчен безгә 62 төрле машина һәм станоклар кирәк, заводлар шуның яртысын гына ясый. Безнең таләпләргә 17 машинадан бары тик сигезе генә җавап бирә...

Һәр яңа бишьеллык алдыннан СССР Җиңел һәм азык промышленносте машиналар төзү министрлыклары мех берләшмәләрен тәэмин итү өчен килешү язалар. Менә соңгы 25 ел эчендә илебез экономикасындагы ике тармак арасындагы килешүләр статистикасы. Сигезенче бишьеллыкта машина төзүчеләр мехчыларга, 16 машина ясап бирәбез, дигәннәр. Ведомстволар комиссиясе шуның 11ен кабул иткән, конвейерга 6ны биргәннәр. Тугызынчы бишьеллыкта 17—11—8. Унынчы бишьеллыкта 8—3—1. Унберенче бишьеллыкта да шундый ук күңелсез саннар. СССР Җиңел һәм азык промышленносте министрлыгы чыгарган 4 машинаның бары тик берәве генә дөнья стандартына туры килүен дә әйтик. Бернинди җәзасыз калган җавапсызлык, вәгъдәсезлек күпме еллар буена сузылыр?

«Союзмехпром»ның зур фабрикаларыннан тыш илдә сарык тиресен Җирле промышленность, Көнкүреш хезмәте күрсәтү министрлыкларына, дәүләт агропромына, «Центросоюзга» караган тагын 300 дән артык предприятие эшкәртә. Һәвәскәр кооперативларның тиречеләре дә кул кушырып утырмыйлар. Ләкин аларга чималның, техниканың, башка төр тәэминатның зур конвейердан калганнары гына эләгә, гамәлдән чыккан машиналар кайта, химикатларны, буяуларны ничек кирәк шулай табалар.

Казанның Мех берләшмәсеннән соң без Көнкүреш министрлыгы системасына кергән бәләкәй генә «Зима» фабрикасына киттек. Монда ун-унбиш белгеч бар. Мондый мастерскойлар республикада дистә ярымлап исәпләнә. Матбугаттан укып беләбез: андый бәләкәй предприятиеләр башка төбәкләрдә дә эшли икән.

Гигант комбинатлардан аермалы буларак, мондый мастерскойларга яхшы тире китерәләр, әмма эшкәртелүе начар, алардан затлы тун тегеп булмый, эшкә җайлы кайры тун гына чыга.

Һәвәскәрләр цехы башлыгы Королева дөрес әйтә:

— Нигә сез алар белән безне чагыштырасыз?! — ди. — Аларда иң оста белгечләр эшли, нинди машиналар, химикатлар, буяулар! Бездә тоташ һәвәскәрләр тырыша. Кыска кайры тун тегә беләбез, ә затлысы — булмый.

Шулай да нәтиҗә чыгарырга ашыкмыйк. Мех — уникаль нәрсә, кыйбат нәрсә, дәрәҗәләре буенча түбәнрәк булган фабрика-мастерскойларга аерым кисәкләр хәлендә килеп кергән очракта да ул шактый файдалы, үзен-үзе аклый, үзенә абруй яулап ала. Чимал белән кем эшли, үз эшенең остасымы, аның кул астында нинди машиналар, нинди дару-химикатлар бар, ниһаять, эшләүченең профессиональ әзерлеге ни дәрәҗәдә — барысы шуларга бәйле. Мөгаен, башка барлык материаль производствога караганда да мех индустриясендә, к а п и т а л  у л — б а р ы н н а н  д а  э л е к  х е з м ә т, а н ы ң  с ы й ф а т ы  һ ә м  к ү л ә м е дигән марксистик экономика кагыйдәләрен раслый торгандыр.

Кабарда-Балкариядәге Баксан мех фабрикасы директорының сүзләрен мисалга китерәсе килә. Әлбәттә, зурлыгы ягыннан Баксан фабрикасын Казан мех берләшмәсе белән чагыштырып булмый, анда нибары ике йөз кеше эшли. Анда елына стандарт булмаган чирек миллион тире эшкәртәләр. Кызыксындыру тәртибендә бу фабрикага 40 мең данә югары класслы тире бирәләр. Дүртенче сортлыны! Биредәге мехчыларның теккән киеме — тышлы, кыска туннар, якалыклар, бүрекләр, буяучы пумаласы, автомобиль һәм мотоцикл япмалары.

Әлбәттә, күңелгә килгән беренче сорауны бирәбез:

— Теләп алалармы соң сезнең товарны?

— Алуын теләп алалар, ләкин бик сөенмиләрдер. Безнең мөмкинлекләр зур фабрикалардагыдан күп тапкыр кайтышрак. Мәскәүдә безнеке төсле тун күрдем — бөтенләй башка: тышлыгы яхшы тукымадан, эләктермә-каптырмалар, ялтыравыклы сәдәфләр белән бизәлгән, әллә ничә кесәсе бар. Дөрес, ике мәртәбә кыйбатрак. Алалар, алмый торучы күренми. Аңламыйм: нигә безне ямьсез тукыма, ямьсез төймәләр белән интектерәләр?

Фабриканың баш инженеры Светлана Павловна Васильчук та сүзгә кушылды:

— Барыбыз да бер үк дәүләткә эшлибез бит, нигә безгә аяк чалалардыр? Моннан унбиш еллар элек безнең фабриканы бик зур өмет белән ачканнар иде. Безнең әлегәчә кешеләрне куандырырлык бер генә дә матур тун теккәнебез юк. Иске җиһазлар китереп тутырдылар, өч бишьеллыкта нибары дүрт яңа машина алдык, алары да тирене ерта торган булып чыкты. Киттек Казанга, өйрәнергә! Ә анда сер ачарга яратмыйлар икән, йөрттеләр, сәяхәтче кебек, фабрикалар, цехлар буйлап, шуның белән вәссәлам — хуш, сау булыгыз! Бу тигезсезлек кайчанга хәтле дәвам итәр?..

Бер нәрсәне ачыклап китү кирәк. Казан мех берләшмәсендә начар чимал килүдән зарланалар. Бирედә — юк. Баксан мехчылары түбән сортлы тиредән дә зыян китермиләр, файдага эшлиләр икән. Бу урында Владимир Ильич Ленин сүзләрен куллану урынлы булыр. Ул әйткән, билгеле бер шартларда кечерәк предприятиеләр зур предприятиеләргә караганда рентабельлерәк эшли алалар, дигән. Бик күптән әйтелгән, әмма бүгенге шартларга тулысынча туры килә торган фикер.

Партиянең XXVII съезды мәсьәләне нәкъ шулай куя да — уртача, кечкенә предприятиеләрнең һәркайсыннан акыллы файдалана белергә кирәк. Тәҗрибә шуны күрсәтә — яхшы җиһазлы кечерәк предприятиеләрнең үз өстенлекләре бар: алар технологик яңалыкларны, халык таләбен тиз тотып алалар. Баксан фабрикасы — моның бер мисалы.

Төньяк Кавказ — борын-борыннан сарык үрчетү төбәге санала. Аерым колхоз һәм совхозларда әле дә егермешәр-утызар мең сарык асрыйлар, әмма тун монда да юк. Күңелгә тия торган рәнҗешле хәл! Чарасына да керешеп карар идең — бөтен нәрсә Госпланга барып терәлә. Шулай да эзләнүчән кешеләр юлын таба!

Ставропольдәге Исправная станицасында үзләренең мех фабрикаларын булдыру хакында элегрәк уйлаган кеше дә юк иде. Унберенче бишьеллыкның азагында, һич көтмәгәндә, сыер абзарына дип төзелгән каралтыда... тире эшкәртү, тун тегү машиналары пәйда булды. Аларга кем ярдәм итте — хода белсен!

«Хезмәт могҗизалар тудыра» дигән сүз шигърияттән түгел, тормыш чынбарлыгыннан килеп туган. Тире-күн остасы Давид Бакшеев Исправная станицасына килеп чыкканда, завод әле хыялда гына була. Әтисе, бабасы, бабасының бабасы тиречe-күнче икән. Бу кешедә эшкә, оештыруга сәләт тә бар. Башта бина коралар, аннары җиһазларын эзли башлыйлар. Кыю адымны XX партсъезд исемендәге колхоз, аның председателе Форостянов ясый, өлкә агропромы алар фикерен яклап чыга. Тынгы белмәс Давид Бакшеев, аргонавтлар Ясоныннан да хәйләкәррәк кеше, Госснабның хәтта үзеннән немец машиналарын табып кайтара. Бик тиз арада курслар ачып җибәрәләр.

Чимал да табалар, осталар өлгерә: предприятиене эш белән күмеп ташлыйлар. Эшләп чыгарган киемне сатып алучылар гына түгел, заказчылары да табыла: ерак Сахалин, Себер, кәлсу туфраклы өлкәләрдән заказлар ява башлый. Әкәмәт! Колхоз председателе Форостянов эшләре никадәр генә күп булмасын, өч мәртәбә Мәскәүгә барып кайта, станица осталарының эшен РСФСР Авыл хуҗалыгы министрлыгы коллегиясендә күрсәтергә өлгерә.

Колхоз туннарыннан беренче әйләнешне тиз ясыйлар. Кешеләр, бигрәк тә станицаларда эшсез утырган хатын-кызлар яңа һөнәр табылуга шатланалар, предприятиенең булдыклы җитәкчесе Бакшеев, уңышлардан күңеле үсеп, тагын ике цех ача: җылы бүрек тегә торган цех һәм тау көтүлекләрендә эшләүче чабаннар өчен тире чикмән тегү цехы. Менә монда инде мактау сүзләре, күңелне күтәрү генә җитми, агрегат, станок, аппаратлар белән ярдәм итәргә кирәк.

Беренче кайры тунның бәясе — 400 сум. Нишләп арзан? Затлысы 800 сум бит. Болар бик үк затлы түгел шул. Рентабельлелек юк, бернинди табыш та алып булмый!

Заводны бер ачалар, бер ябалар.

Безнең «Советская Россия» хәбәрчеләре бригадасы килеп төшкәндә, заводны өченче мәртәбә япканнар иде. Колхоз аргонавтларының дөнья базарларында дан тотарга исәпләгән хыяллары җилгә оча.

Ләкин җәнҗал колхоз эчендә, Ставрополь төбәгендә генә торып калмый. Кем инде бер миллион сум акча тотып төзегән заводны чүплеккә атсын? Аны кооператорларга тапшыралар. Күңелсез хәл. Ә ник болай килеп чыга соң?

— Беренче сәбәбе,— дип аңлатты Карачай-Черкесия өлкә агрономының председателе Василий Глазко.— Исправная станицасындагы завод — никахсыз туган бала. Сарык тиресен эшкәртү — дәүләт кулында, башкаларга бу эш белән шөгыльләнү тыела. Икенчедән, өлкәнең тире хәзерләү планы бар, ә колхоз заводы ул планны өзә. Өченчедән, тегелгән киемнәрнең үзкыйммәте югары...

Глазко хәйләгә керешкән! Дәүләт монополиясе хакында ул алданрак сүз кузгатырга

тиеш иде бит! Белоруссиядә исә эш моңа капма-каршы нәтиҗә бирде. Владимир Васильевич Пестель Брест өлкәсенең Барановичи районы «Октябрьнең 40 еллыгы» колхозын җитәкли башлаган чакта анда «тун промыселы» була инде. Яшь председательнең казанышы — бу промыселга ул киң колачлап һәм уйлап эшләү юнәлеше бирә.

Бу колхозда да сарык үрчетәләр. Эшләре, һәммә төштәге кебек үк, авыр бара. Җир күп түгел, ике мең гектар чамасы гына. Иген үстерер өчен бу җирләр кайчандыр бөтенләй яраксыз дип саналган. Колхозга барлык сарыкларны һәм район буенча йон планын йөкләгәч, районның башка колхоз-совхозлары, сарык көтүләреннән котылу шатлыгыннан, сарык үрчетүчеләргә фураж бирергә дә риза була. Хәзер «Октябрьнең 40 еллыгы» исемендәге колхоз күршеләренә фуражны үзе бирә, хезмәт нәтиҗәләре буенча беренчеләр рәтенә чыккан, дәүләткә итне элекке еллардагы төсле, 60 тонна гына түгел, 280 тонна сата, ә иген уңышы 40 центнерга кадәр күтәрелгән. Ел саен — 600 мең саф табыш! Гектарыннан 300 сум дигән сүз!

Эшли белеп эшләсәң, баеп була. Уникe авылга таралган сарык фермаларын ике авылга җыялар. Су белән тәэмин итү өчен дүрт кое казыйлар, печәнне ябык лапасларда тотарга өйрәнәләр. Терлек-туарның кырылуы кими, йон арта. Көтүләр зурайган саен, кешеләргә эш тә арта бара — тире иләп тун тегүне оештыра. Беренче елны үк тотылган чыгымны капларлык эш башкарыла. Икенче елны 111 мең сумлык табыш алалар. Хәзер колхоз осталары ел саен ике мең тире эшкәртәләр, заказлар явып кына тора. Бер тәмен белеп алгач, тагын да тырышыбрак тотыналар — тиредән хром ясыйлар, күн курткалар тегүне җайга салалар. Хәзер инде ирешелгәннәр генә канәгатьләндерми, колхоз җитәкчеләре мех һәм күн һөнәрчелегеннән миллион сум табыш алырга хыяллана. Монда үз чималыңнан файдалану отышлы. Ничек ирешергә моңа? Тунга яраклы сарыклар санын ишәйтергә! Махсус әзерләнгән чимал чит ил базарларына да чыгарга мөмкинлек тудырыр. Күрәсез, биредә һәр нәрсә уйлап, нигезләнеп, алдан күреп эшләнә.

Әйдәгез, инде хәзер Исправная станицасында килеп чыккан күңелсезлекне тикшереп карыйк. Беләсезме, хәтта мөстәкыйльлек тыелган заманнарда да авылның үз тиреләре белән эш итү шактый иркен иде, чөнки махсус директив карарда: «Колхозларга сарык тиресен потребительләр кооперациясе аркылы сатарга тәкъдим ителә»,— диелгән иде.

Шул да мәгълүм булсын: Ставрополь краеның колхоз һәм совхозлары илдә беренчеләрдән булып үзе идарә итү, үз-үзеңне финанслау белән шөгыльләнә башладылар, дәүләт акчасыннан баш тарттылар. Шунлыктан тирене чимал хәлендә түгел, эшкәртеп, кыйммәтрәк бәягә сату алар алып барган политикага туры килә иде. Һәр тиредән өстәмә акча алу колхозның экономикасын ныгыта иде.

Әмма колхозлар бит иң әүвәл чимал белән дәүләтне тәэмин итәргә, шуннан соң гына үз производстволарын кайгыртырга тиешләр. Ә үз заводың булу исә колхоз чималы белән теләгән кадәрле мөстәкыйль эш итәргә ирек бирә, кооператорлар аз гына йоклап йөрдеме — яхшы сортлы тиреләр колхоз заводына китеп бара.

Шул рәвешле колхозларның үз заводлары булу хуҗалыкларда сарык үрчетүгә югарырак таләпләр китереп куйды, әгәр шул таләпләр үтәлсә, чимал колхоз мехчыларына да, дәүләткә дә җитәргә тиеш иде. Ләкин бу авыр эш Карачай-Черкесия автономияле өлкәсе көченнән килмәде. Колхоз-совхоз чабаннары йөз баш сарыктан 85 бәрән алып торганда, тире җыючылар үз эшләрен үрнәк төстә башкармаган чакта, мех производствосы сүнә. Шуларның барысына өстәмә итеп, Исправная станицасы тиреченүнчеләренең профессиональ осталыклары, тәҗрибәләре җитмәвен дә кушсак, бу станицада уңышсызлык килеп чыгуның сәбәпләре аңлашыла торгандыр дип уйлыйм.

Әлеге җәнҗаллы заводтан берничә йөз генә километрда кооператорлар Кабарда-Балкариянең Чегем үзәнлегендә үзләренең мех эшкәртү предприятиесен төзергә тотыналар: база булдыралар, 400 мең сумга җиһаз сатып алалар. 1987 елны кооператорларның мех конвейеры беренче 10 мең тирене эшкәртеп чыгарырга, бишьеллык азагына производство куәтләрен биш мәртәбә арттырырга карар кылалар. «Центросоюз» шундый ук предприятиеләрне Чечен-Ингушетиядә, Калуга өлкәсендә, Мәскәү янындагы Мытищида, Краснодар краенда, Киров өлкәсендә, тагын башка төбәкләрдә төзергә карар кабул итә. Ул предприятиеләр «Союзмехпром»ны стандарт булмаган чималдан коткарырга исәп тотып төзеләләр. Бәлкем, алар сафка баскач, стандарт булмаган тиреләр азаер, югары сортлы тиреләр арта төшәр? Анысы эшкә никадәрле намуслы каравыбызга бәйләнгән.

Шулай да бу өлкәдә хакыйкатьне табу кыен. Халык әйтмешли, һәр сөйләшүебез «эт — эткә, эт — койрыкка» булып чыга. Шунлыктан «Советская Россия» редакциясе һәм партиянең Татарстан өлкә комитеты киңәшмә уздырырга булды. Мәсьәләне уртага салып, ачыктан-ачык сөйләшергә кирәк иде.

Билгеләнгән вакытта Казан мехчыларының культура сарае тум-тулы иде. Арада бик абруйлы кунаклар бар, хәзер без алар белән танышырбыз.

Киңәшмәне Татарстан АССР Министрлар Советы Председателе урынбасары Наталья Дмитриевна Данилевская алып барды.

Сүзләр кайнар булды. Бәхәс купты. Берни эшләр хәлең юк — демократия, ачыктан-ачык сөйләшү заманы! «Советская Россия» газетасының промышленность бүлеге мөдире Евгений Хохлов белән сүзләрне, мәгълүматларны, фикерләрне көч-хәл белән язып өлгердек.

**М. Медведев**, Алтай крае, Целинное авылы:

— Мех тирәсендә җилкуарлар, бюрократлар чамасыз күп. Аларны эшләтергә вакыт. Туннар да, кыска туннар да, җылы киемнәрнең башка төрләре дә безнең кибетләрдә җитәрлек булырга тиеш!..

Беренче очкын кабынуга, залдан мех кисүче Л. Романова трибунага күтәрелде:

— Ә сез безнең эшнең нинди кыен икәнен беләсезме? Хатын-кызлар башкара бит аны. Өлкәннәр ялга китә, яшьләр урынның җайлырагын сайлый. Фатирны тизрәк алып була торган җирне! Күптән түгел ике сменаны бергә куштык, икесеннән берәү чыкмады. Без бит инде болай да һәр шимбәне станок янында үткәрәбез, кайчагында якшәмбеләребез дә китеп бара... План буенча бирелгән нормага меңнән артык мехчы җитми. Соңгы вакытта коллектив өч мең кешесен югалтты. Хезмәт урыннарындагы бушлыкны нигә машиналар алмый?

Китте шуннан: сорау — җавап, тәнкыйть — тәкъдим.

**Беренче һәм икенче фабрика эшчеләренең бердәм таләбе:**

— Грибановск заводы ясаган машиналар бер нәрсәгә дә ярамый: яңалары тышкы кыяфәте һәм кыйммәт булуы белән генә алдагысыннан аерылып тора. Завод кайчан югары сыйфатлы машиналар бирер?

**Н. Ищенко**, Грибановск машина төзү заводының баш инженеры:— Без машиналарны сезнең заказ буенча ясыйбыз. Модельләрне, сызымнарны институтлар һәм проект-конструкторлык оешмалары әзерли. Документларда Минлегпромның да, «Союзмехпром»ның да имзалары бар. Алар, кагыйдә буларак, ведомстволарның комиссияләрен җитәкли, ә ул комиссияләр яңа үрнәкләрне кабул итә.

— Импортный машиналар, кую белән, эшли башлый, ә сезнекеләр, сүтеп, яңадан җыймыйча, селкенми дә...

**К. Сергеев**, Җиңел һәм азык промышленносте машиналарын төзү министрлыгының баш технологы:

— Грибановск заводыннан килгән коллегамның сүзенә төзәтмә кертергә уйлыйм: аның позициясе заманча түгел. Завод үзенең продукциясе өчен тулысынча җавап бирергә тиеш. Мехчылар киңәшмәсенә килгән барлык белгечләр цехларда йөрде, һәммәсен үз күзләре белән күрделәр. Нәрсә таләп ителгәнне белделәр. Шушы мөмкинлектән файдаланып, мех производствосын тагын да югарырак техник баскычка күтәрү өчен иҗади хезмәттәшлек булдырырга тәкъдим итәм.

Киңәшмәдәгеләр тәкъдимне якладылар: тармак-ара иҗат коллективлары булдырылсын, аңа Казан мехчыларыннан да вәкилләр кертелсен, ә Татарстан мех берләшмәсе фабрикалары һәр яңалыкны сынау полигонына әверелсен!

**Е. Симонов**, «Союзмехпром» начальнигының вазифаларын үтәүче:

— Фабрикалар тулы көченә эшләми. Хәтта Татарстан мех берләшмәсе дә 65 процентка гына йөк тарта. Үзебезне үзебез карарга тиешле бер заманда производство күләмен киметү хезмәт хакы фондын өлешчә азайтуга, башка төрле кызыксындыру чараларын да кечерәйтүгә китерә. Болар исә коллективта ризасызлык тудырачак. Бүгенге көндә бу бәладән чыгуның юлы бер генә: тулы көчкә эшләү өчен шартлар булдырырга кирәк. Без югары җитештерүчәнлекле машиналар һәм чимал белән ярдәм итәргә әзер...

Киңәшмә барган зал белән янәшә зур бүлмәдә Татарстан мехчылары күргәзмә оештырдылар. Һәйбәт туннар, елкылдап торган матур якалы пальтолар, леопард, юлбарыс кебек киек җәнлекләрнең тиреләренә охшатып бизәлгән, космик сурәтләр төшерелгән мехлар, кайры туннар! Мондый товар белән теләсәң кайсы чит ил ярминкәләренә барырга, аяк терәп сәүдә итәргә була!

Шул уңайдан — файдалы ике тәкъдим. Затлы туннар белән бергә шактый ук тупас эш киемнәре — тышлы кыска туннар да тегәләр Казан мехчылары. Аларның бер өлешен икенче бер урындагы мехчыларга тапшырып, Казан мехчыларын затлы киемнәр тегү өчен бераз бушатып булмый микән? Бусы — бер. Икенчедән, затлы туннарыбыз чит илләргә валютага сатыла. Валютаның бер өлеше үзебезгә дә кайтырга тиеш. Тик алар дәүләт банкында «үзәкләшә». Хәзерге кагыйдәләр буенча, валютага килгән табышларның дүрттән бер өлеше предприятиегә бирелергә тиеш бит. Әгәр мехчы-күнчеләребезнең чит илләр белән ирекле хезмәттәшлеге юлга салынса, экспорт буенча ирекле маневр ясый алсалар, арадашчыларның йоклап ятканнарын көтмичә үк, алар валютага үзләренә кирәкле җиһазларны, химикат-препаратларны да ала алырлар иде. Табигый ки, ирекле ярышта җиңеп чыга ала торган затлы киемнәрне дә күбрәк тегәрләр иде.

**Л. Семенова,** чимал сортлаучы, бәя бирүче:

— Безгә чимал җибәреп торучы Куйбышев, Оренбург, Воронеж, Саратов, Дагстан, Башкортстан агропромы предприятиеләре даими рәвештә түбән сыйфатлы тире җибәрәләр. Соңгы елларда безнең базага беренче һәм икенче сорт сарык тиреләре керми диярлек. Өченче, дүртенче сортлары да 28 проценттан артмый. Алардан затлы кием тегеп буламыни?

**К. Асылкаҗаев,** СССР Дәүләт агропромының баш белгече:

— Безнең хәлгә дә керегез: ит комбинатларында хәзерләүләрнең иң кызган чорында тиреләрне тозлап өлгертә алмыйлар. Шуңа күрә тиреләрне эшкәртеп бетермәгән килеш җибәрергә туры килә. Эшчеләр юк.

**Р. Алиева,** чимал сортлаучы:

— Ә мехчылар нишләсен?! Беренче сортлы 6 процент сарык тиресеннән без 30 процент беренче сорт кием тегәргә тиеш. Сарык тиреләре ит комбинатларында, яртышар ел ятып, бозылып бетә. Тирегә тоз сибеп торуны проблемага әйләндерәсез. Конвейерга бер өстәл куегыз, тоз сибүче табыгыз!

**В. Павлова,** Татарстан мех берләшмәсе идарәсенең бүлек начальнигы:

— Стандартлар мәсьәләсендә дә буталчыклар күп. Хәзер чималга, ярымфабрикатларга, әзер әйберләргә куела торган таләпләр тигез түгел. Без начар чималдан яхшы әйбер әзерләргә тиеш булабыз. Таләп барлык өлкәгә бер булсын, бер ГОСТ карасын. Кая гына мөрәҗәгать итмәдек — «Союзмехпром»га, министрлыкка, Дәүләт стандартына — колакларына да элмиләр...

Барлык таләпләргә, тәнкыйть сүзенә җавап булды. ГОСТ кына җавапсыз калды. Дәүләт стандартының җиңел промышленность бүлеге начальнигы урынбасары Г. Лаврентьев Казанга килеп җитә алмады. Кызганыч.

**Н. Калашников,** «Главтатстрой» начальнигы:

— Нишләп җиңел промышленность министрлыгы ярдәм итми? Цехлар юеш, формалиннан күзләр әчетә, хатын-кызлар авыр-авыр арбаларны кул белән этеп йөртәләр. Без реконструкцияләүне тизләтә алабыз, тик акча да, материал да аз бирелә. Көч-куәт җитәрлек безнең, әйдәгез, берьюлы берничә объектта эшлик?

**В. Тарасов,** «Союзмехпром» начальнигы урынбасары:

— Бер объектта эш бара икән, Госплан икенчесен башларга рөхсәт итми.

**М. Теркулов,** Татарстан мех берләшмәсенең капиталь төзелеш бүлеге начальнигы:

— СССР Җиңел промышленность министрлыгында бер кабинетта нәрсә эшләгәнне икенчесе белми. Бер җаваплы хезмәткәр, буяу цехы 1988 елда төзеләчәк, ди, икенчесе, 1989 елда булачак, ди. Документация юк, беркетмәләр язылмый, киләсе елга да акча бирмәүләре бик ихтимал.

**В. Орлов,** СССР Госпланының җиңел промышленность бүлеге начальнигы урынбасары:

— Госплан илдәге мех предприятиеләрен яңабаштан җиһазландыруның комплекслы планын төзеде, көтүлекләрдән башлап, келәтләргә чаклы — һәммәсе яңартылырга тиеш. Ләкин әле берни дә эшләнмәгән. Сүздән эшкә күчәргә вакыт...

Барлык ишеткәннәрне тикшереп карасаң, чын-чынлап борчуга калырлык. Сөйләделәр, бәхәсләштеләр, баш ваттылар, чынында исә бу җыелыш сукырларның чукраклар белән сөйләшүе төсле булып калды.

Көрәш бар, җиңү булмаячак. Бу — көн кебек ачык. Такташыбызның моннан 50—60 еллар элек язган тәнкыйте бүген дә урынлы булып кала бирә. Хәер, алай гынамы соң? Мәсьәлә тагын да катлауланган, тәмам каешланган.

Кайры тун кайгысына кагылышлы беренче язмаларны «Советская Россия» 1970 елны бастырып чыгарган иде. Әнә күпме вакыт узып киткән! Үзгәрешләр — юк дәрәҗәсендә.

«Тунсыз» сарыклар үсә бирә. Бәрән китерүләре дә артмаган. Шул хәтле тырышлыклар белән җыйган тиреләрне дә һаман черетәбез. Еллар, дистә еллар, гасырлар буе туплаган тәҗрибәбезне югалтып, онытып барабыз. Үз кыенлыкларыннан матур риваять калдыручы аргонавтлар көнләштерә. Безнең хакта ни сөйләрләр? Юк, киләчәк алдында оятка каласы килми. Димәк, яңадан «алтын тире» экспедициясен җыярга, аны, аргонавтлар ирешкән уңышларга ирешкәнче, дәвам иттерергә кирәк. Әкияттә түгел, тормышта. Башка юл юк. Булмаячак!

*Бәхәс дәвам итә: «Заман һәм шигырь»*

**Нури Арсланов**

# АЧЫКТАН-АЧЫК ӘЙТСӘК

Шигъррият турында сүз ачканда, башта аның иң борынгы, иң өлкән әдәби жанр булуын искә төшереп үтәсем килә. Әйе, ул — әдәбиятның аксакалы, аның тарихы борынгы кешеләрнең музыкасы, сынлы сәнгате, биюе белән яшьтәш.

Ләкин моның бер кызыклы ягы бар. Безнең төрки телләрдә әдәбият белән шөгыльләнүче — язучы дип атала. Ә бит хат язучы да яза — кулына каләм тоткан барлык кеше дә яза. Шулай итеп, «язучы» сүзенең мәгънәсе бик таркалып, кечерәеп кала. Язучылыкның төп мәгънәсен әйтеп җиткерә алмый. Ул Көнбатыш илләрендә дә шулай. Литература — кулъязмалар, басма сүзле кәгазьләр җыелмасы дигәнне аңлата. Андый җыелмага, әлбәттә, барлык архив материаллары да керә ала. Димәк, литература сүзенең дә мәгънәсе бик тар, без аңлаган мәгънәне әйтеп бирә алмый икән.

Ә менә гарәпләрдә бу әйбергә бик тирән һәм киң мәгънә бирелгән: Әдәбият — әдәпләр фәне, әдәп-әхлакка өйрәтә торган фән, укырга-язарга өйрәтә торган, кыргыйлык-вәхшилектән чыгарга ярдәм итә торган, кешеләрдән зыялылар тәрбияли торган, кешене кеше итә торган сыйфатлар барлыкка китерүче тылсымлы белем дигән фикерне аңлата.

Әдәбият Көнчыгыш илләрендә бик борынгы заманнардан бирле мәктәп-мәдрәсәләрдә нигез ташы булып — төп дәресләрнең берсе булып укытыла торган булган. Ә без исә аны үзебезгә төгәл килеш шул мәгънәдә кабул иткәнбез.

Менә шул әдәбиятның аксакалы шигърият турында сүз барганда мин бераз сәерсенеп калдым: шигырьнең вазифасы ачык, ул кешеләр күңелендә яхшы хисләр уятырга, халкына-иленә хадим булырлык ватандарлар тәрбияләргә тиеш. Бу — көн кебек ачык! Шигъриятнең кешелек дөньясын бер вакытта да начарлыкка өндәгәне юк! Бу — бәхәссез.

Шулай да, җыелышларда сөйләнгән һәм «Казан утлары» журналында басылган мәкаләләрне укыгач, шигъриятнең һәм аңа кагылышлы башка әйберләрнең телгә алып сөйләшерлек әле тышкы ягы да бар икән дигән уйга килдем.

Беренче туктала торган әйберем — тәнкыйтьче һәм шагыйрь арасындагы мөнәсәбәтләр. Югарыда әйтелгәннәргә ирешү өчен, әлбәттә, әдәбиятта демократия кирәк, кирәк кенә түгел — зарур! Ә ул бездә җитеп бетәме?

Бу урында, мисал өчен, тәнкыйтьче Мансур Вәлиевнең «Шигъри бушлык» дигән мәкаләсен искә төшереп үтәргә кирәк. Тәнкыйтьче үзенең бу әсәрендә шактый күп авторның иҗатына кагылып үтә: аларның уңышлы якларын күрсәтә, җитешсез якларын тәнкыйтьли. Мансур Вәлиевнең бу мәкаләсен мин бик зур игътибар белән укып чыктым. Аның миңа ошаган ягы — кыюлыгында, кәеф-хәтергә карамыйча, чын күңелдән шигъриятебез өчен борчылып, кыйналып язуында. Ул үзенең мәкаләсендә кемнең кем булуына карамыйча, үзе аңлаганча, үз йөрәге кабул иткәнчә фикерләрен ачыктан-ачык әйтеп бирә. Дөрес, аның хәзерге шигъриятебезгә биргән бәясендә, ачы тәнкыйтендә бәлки чамадан чыгыбрак киткән урыннары да юк түгелдер. «Дүрт аяклы ат та сөрлегә» дигәндәй, сөрлегеп киткән чаклары да бәлки бардыр. Ә тәнкыйтьче бер дә ялгышмаска, ул әйткән сүзләр коръән сүзләре кебек «фәкать дөрес» булырга тиеш дигән караш үзе дөресме? Бездә берәү басма сүздә берәр фикер әйтә икән, аның турында борынгыча: «Каләм белән язганны балта

белән дә юньш бетереп булмый» дигәнрәк караш әле һаман яшәп килә, ул, күрәсең, гадәткә кергән. Гүя аңа беркем дә каршы килергә тиеш түгел. Тагын бездә пародия, эпиграмма, шаржларга үпкәләү, ачулану кебек хәлләр дә әле һаман яши. Бу мәсьәләдә дә безгә Европа культурасына бер кадәр якынаерга вакыт дияр идем мин.

Инде баягы без башлаган мәсьәләгә яңадан кайтып, язучылар җыелышындагы бер күренешкә тукталасым килә. Мәкаләдә телгә алынып киткәннәрдән шагыйрь Рәдиф Гатауллин трибунага чыга. Ул үзенең килешле буе-сыны белән, ике кулын күкрәгенә куеп, Наполеоннарча поза ала. Тавышы көр, әйтер фикере, һәрвакыттагыдай, сүзләрен тапкан — ул язучыларыбыз арасында оста ораторлардан берсе. Әлбәттә, ул берни белән дә килешми. Тәнкыйтьченең тетмәсен тетә, вакарь белән, ашыкмый гына, суд хөкеме укыган судья төсле, авторга тәнбиһләр ясый да, эре генә үз урынына барып утыра. Мондый чыгышлардан соң, әлбәттә, язар җиреңнән язмый башларсың дигәндәй тәэсир кала. Ә нигә соң бу кадәр төстә кеше фикереннән йөз чөерү?! Демократияне кысу түгелме соң бу?

Шушы хәлдән соң мин Рәдиф Гатауллинның күптән түгел «Шигырь китапханәсе» сериясеннән чыккан «Мәхәббәткә мәрхәмәт» китабын тагын бер җентекләп карап чыктым. Һәм мин, Мансур Вәлиев мәкаләсен алкышлап каршы алсам да, шагыйрь Рәдиф Гатауллин шигырьләренә булган ихтирамымны югалтмадым. Заманында Писарев та, Пушкин иҗатына бәя биргәндә, аның әһәмиятен шигъри формадагы уңышлары белән генә чикли. Моңа карап Пушкинның Пушкинлыгы югалмый, ә гомум шигърият өчен файдалы фикерләр әйтелеп кала.

Әйе, шагыйрьдә, һәр сәнгать кешесендәге кебек үк, эзләнүләр, эзләнүләр... Алар кайчак уңышсызлыклар да тудыра, төрле кысалар да китереп чыгара. Шул эзләнүләрнең әлеге тәнкыйтьче күргән кимчелекләрне калкытыбрак күрсәтүләре дә мөмкин. Ул эзләнүләр бик озакка китте диючеләр дә булыр. Әйе, шулай булуы да табигый,— шагыйрь гомер буе эзләнергә мәҗбүр.

Җыелышта бердәнбер тәпле чыгыш профессор Ибраһим Нуруллин тарафыннан ясалды. Ул тәнкыйтьчене яклап бик дөрес фикерләр әйтте. Ләкин башкалар, авызларына су капкан шикелле, бер сүз дә катмадылар. Һаман шул тыныч яшәү өчен саклык галәмәте түгел идеме соң бу?

«Шигъри бушлык» мәкаләсендә, гомумән, безнең хәзерге шигъриятебездәге тыңкы купшылык, фикри бушлык, күп әйтелгән-тапталган сүзләрне, әйтемнәрне куллану, рифмалардагы ярлылык, ритмнарның аксаклыгы, «өф» дип өрсәң тузганак шикелле очып тарала торган альбом шигырьләре... барсы да, барсы да күздән кичерелгән. Алар бармы соң безнең шигъриятгә? Кызганычка каршы — кирәгеннән артык. Алар белән көрәш ачар өчен шигърият һәм тәнкыйть игезәкләрдәй бергә үсәргә, үпкәләшә-үпкәләшә, кайчакта төрткәләшә-төрткәләшә бергә яшәргә тиеш. Шунда гына кирәкмәс «бушлык»лардан котыла төшәргә мөмкин.

Гомумән, тәнкыйтьтә, кәефкә карап, иплән, сылап-сыйпап, кемгә дә булса ярақлашып, каушап-калтырап язу «стилен» тамырыннан бетерергә вакыт. Мансур Вәлиевнең кыюлыгы безнең күп коллегаларга үрнәк булырга тиеш. Мондый кыюлык шигъриятгә яңаны тудырырга, туган кадәресен камилләштерергә зур ярдәм итәчәк.

Бер вакыт, моннан күп еллар элек, тәнкыйтьче Нил Юзиев миңа: «Журналда Сезнең шигырьләрегезне укыдым, кат-кат укыдым, әйбәт шигырьләр!» — дигән иде. Шигырьләрем турында фикер алышу шуның белән тәмамланды. Матбугатта берике сүз әйтер әле дип көткән идем, ләкин ләм-мим, бер чыгыш та булмады. Шуннан бирле егерме ел узды. Тик бу тәнкыйтьче минем шигъриятемә кагылмады. Шул кадәр вакыт эчендә күпме язылган: аның игътибарына лаек әсәрләр дә бәлки булгандыр. Ләкин боз кузгалмады. Хәзер коридорда әйтелгән теге мактау сүзләре генә колакта калган. Бу нәрсә турында сөйли соң? Хәер, мин үземә карата мондый мөнәсәбәткә бик артык пошынмыйм: үз шигырьләремнең ни дәрәҗәдә икәнен болай да беләм. Начар язарга теләмим, яхшы язарга тырышам. Ләкин бит кеше иҗаты турында коридор белән генә чикләнмичә, матбугатка чыгару тәнкыйтьченең төп вазифасы лабаса. Ул бу очракта бер минем өчен генә түгел, ә әдәбиятыбыз өчен кирәк.

Мондый мөнәсәбәт миңа карата гына булса, югарыда әйтмешли, бер хәл иде, мин бу турыда язып та тормас идем. Ул бит безнең әдәбият өлкәсендә башкаларга карата да яшәп килә. Мондый тәнкыйтьчеләрне мин сайлап алган аерым шәхесләр файдасына гына хезмәт итүче, әгәр шулай әйтергә мөмкин булса, «ведомственный» тәнкыйтьчеләр дип әйтер идем.

Кай чакта, үзара сүз чыгып, «яңа шигырь» турында сәер карашларга очрарга туры килә. Минемчә, шигырь, нинди генә булмасын, кешегә аңлаешлы булырга тиеш. Юкса аның башкалар йөрәгенә үтеп керә алмавы, аларда яхшы хисләр уята алмавы, димәк, үз максатына ирешә алмавы бар. «Юк,— диләр кайбер шагыйрьләр,— шигырь проза түгел, ул һәр укучыга да аңлашылырга тиеш түгел»,— диләр.

Лəкин монда бер төп шартны онытырга ярамый. Югарыдагы карашлы шагыйрьлəр сүзлəрдəн табышмак ясап, аларны җайсыз, урынсыз тезеп шигырьне аңлауны юри кыенлаштыралар. Шигырьнең тышкы төзелешеннəн хикмəт эзлəп, җиңел акыллылык күрсəтəлəр. Чөнки шигырьнең, юри кыенлык ясамасак та, һəрбер укучыга да тиз генə, ансат кына аңлашылмавы бик мөмкин. Монда сер — аның тирəн, фəлсəфи фикерендə. Лəкин мондый серне укучы тояр һəм аңлар өчен кат-кат укый, ниһаять шагыйрьнең əйтергə телəгəнен аңлауга ирешə. Мондый шигырь аңа рухи азык бирə. Ə теге: «шигырь аңлашылмаска тиеш», дип ясалма буталчыклык тудыру исə беркемгə дə берни дə бирми, аның файдасы юк кына түгел, хəтта зарарлы да.

Халыкчанлык турында да эшлəр бик үк шомадан түгел. Халык əдəбиятыннан файдалану, иҗат иткəндə аны һəрвакыт янында тою язучы өчен һава төсле кирəкле əйбер. Лəкин «һəр ялтыраган — алтын түгел» дигəндəй, халык авыз иҗатыннан эзəргеч алганда сак булырга да кирəк. Мисал өчен 1985 елда Татарстан китап нəшрияты тарафыннан чыгарылган «Сандугачым-былбылым» китабын алыйк. Төзүчесе — драматург Туфан Миңнуллин. Бу китапка ул халык җырларын, кулга ни төшсə шунысын (фəкать сандугач турында гына булсын) туплаган. Бер дə шиклəнеп-нитеп тормаган, саклыкны уйламаган. Халыкныкы бит, аңа кул тидерергə — төзəтергə ярамый. Анысы дөрес. Лəкин аның уңышлы үрнəклəрен эзлəргə, сайларга ярый. Ярый гына түгел, кирəк тə. Үз вакытында халык шагыйре Габдулла Тукай да халык җырларын җыйганда бик талəпчəнлек күрсəткəн. Бу аның хезмəтлəреннəн күренеп тора. Халык җырлары гасырларча эшкəртелə килсə дə, кайберлəре, вакыт үзган саен, төрле исемсез «редакторлар» тарафыннан бозыла килə. Килə-килə алары телдəн төшеп тə кала. Ə шуларның кайберлəре безнең заманга да үтеп керə. Халык иҗаты белəн эш иткəндə аның мондый якларына да игътибар итəргə кирəк.

Менə ичмасам шул ук Туфан Миңнуллинның халыкчанлыкны бик оста файдаланып иҗат иткəн Əлмəндəр карт образы — гаҗəп образ! Мин аның һəр хəрəкəтен күз алдыма китерəм, һəр сүзен хикмəтле сүз дип саныйм, тормышка мəхəббəтен яратам, аның бөтен тамыры белəн шушы гади яшəешкə тоташтан үлмəс җанлы булуын яратам. Ниһаять, мин аның җан алучы Газраил янына баргач та, кабул итү бүлмəсендəге фəрештəне гади кыз дип уйлап кысырыклавын яратам. Əлмəндəр бөтен барлыгы белəн үлемсез, классик образ. Менə шул инде ул əлеге халыкчанлык дигəннең якты үрнəге. Мин шигъриятебездə дə Əлмəндəр кебек образның туууын бик телəр идем.

Халыкчанлыкны дөрес аңламау һəм аңа дөрес бəя бирə алмау əле һаман яшəп килə. Шушы урында бик гыйбрəтле бер эпизодны сөйлəп үтү артык булмас дип уйлыйм.

Моннан күп еллар элек, без өч язучы, районга, халык белəн очрашуларга чыгып киттек. Ул чакта əле без өчебез дə урта буын язучылар идек. Кичкырын бер авылга килеп төштек. Авыл советы йортына кердек. Анда дежур кыз һəм берничə авыл егетеннəн башка кеше юк иде. Безгə рəиснең тиздəн килəчəген белдерделəр. мондагы егетлəр дə аны көтеп утыралар икəн.

Безнең беребез, шагыйрь кеше, əлеге егетлəр белəн əңгəмəгə кереште. Үзенең халыкчанлыгын күрсəтергə телəптер инде, нəкъ авыл кешелəренчə, бик тиягенə тидереп, провинция жаргонында сөйлəшə башлады. Мин, беркадəр уңайсызлансам да, иптəшемə искəрмə ясый алмадым, чөнки гəп башланган һəм аны бүлдерергə ярамый иде инде...

Бераз сөйлəшкəннəн соң, шагыйрь, ниндидер ихтыяҗ белəн, ишегалдына чыгып китте. Егетлəрдəн берсе, иптəшемə түгел, ə миңа төбəлеп:

— Абый, бу кеше кем була? — дип сорады. Мин иптəшебезнең исем, фамилиясен һəм шагыйрь икəнлеген əйттем. Егет исə, никтер көрсенеп:

— Шулай да бу бездəн əллə ни ерак китмəгəн икəн...— дип куйды. Башкалар да, аның сүзен җөплəгəндəй, урыннарында кузгалышып алдылар.

Менə сезгə «тели белсəң — телəк, тели белмəсəң — имгəк!» Менə теге, мин башта əйтеп үткəн, əдəбият сүзенең зур мəгънəгə ия булуын күрсəткəн бер дəлил.

Əлбəттə, гади кешене аның үзенчə сөйлəп шаккатырып булмый. Ул синнəн башка да үз телендə бик төгəл сөйлəшə ала. Аның язучы кешедəн — сүз остасыннан матур əдəби тел ишетəсе килə. Ул аңа кызыксынып кына карамый, ул аңа мохтаҗ. Ул аннан өйрəнергə, сүзлəрен отып алырга, кыска вакытлы шул мəктəп белемен алып калырга тели. Моңа тагын нəрсə өстəп була?!

Аннан бездə, əсəрлəргə бəя биргəндə, күп вакытта беряклылык, ашык-пошык, əллə ни баш ватмыйча гына, мөһер басып раслап куюлар күзгə чалына. Мəсəлəн, Марс Шабаевның «Казан утлары» журналында чыккан «Ачыктан-ачык» дигəн əйберен кая теркəп була? Ул үзе аны публицистик поэма дип атаган. Редакция аңа «хат башыннан» урын биргəн һəм җыелышта безнең тагын бер ораторыбыз Барлас

Камал аны яхшы поэма дип мактап үтте. Ләкин бу — берниндә дә поэма түгел, йомшак итеп-җайлап әйтсәк — ритмлы репортаж, яки яңадан корылуга яраклаштырылган көйле мәкалә генә. Аның белән журналны ачып җибәрү дә шул яңадан корылу хәрәкәтенә бәйләнешле булганга гына дип уйларга мәҗбүр итә.

Шагыйрь Илдар Юзеевның шул ук журналда әлегрәк чыккан «Сез кабызган утлар» поэмасын күздән кичерик. Поэма гадәттәгечә оста язылган, сүз дә юк. Шагыйре әйбәт, поэмасы шома, ә эсәрнең эчтәлеге нәрсә турында сөйли соң? Поэма кадәр поэманың эчтәлеге шәхси теләктән ары китә алмаган бит. Ачыктан-ачык әйткәндә, шагыйрь үзенә, яки Юзеевләргә музей-йорт ачуның кирәклеге турында борчылып яза. Ул бу юлда хәтта физик бәрелешкә дә барырга әзер. Моны да «Илдар шәп поэма язган» дип әйтүчеләр булды. Нәрсәсе белән шәп соң поэма? Авторның тыйнаксызлыгы беләнме? Бу әйбердә, без көрәш ачарга тиеш булган, данга ымсыну һәм карьерага омтылу ярылып ятмыймы соң?

Мин монда мисалга юри укучыга танылган шагыйрьләрне алдым. Аларның тәнкыйтьтән түбәннәренә кагылмадым. Кызганычка каршы алар бездә гадәттән тыш күп. Шулар арасында, яңа шигырь диген булып, рифмасыз, ритмсыз-көйсез әйберләр язып шигъриятта ансат юл сайлаучылар да юк түгел. Болай дигәч, тагы миңа каршы Равил Фәйзуллиннар буыны күсәк күтәрмәсен. Мин, күпчелек шагыйрьләр белгәнчә, ак шигырьгә дә, иркен шигырьгә дә һич каршы түгел. Минем өчен нинди генә булмасын — шигырь булсын, ә монда мин бары тик рифмасы да, ритмы да һәм фикере дә булмаган тезмәләр турында әйтәм. Ләкин шунысы да бар, болар берсе дә яңа форма түгел, ак шигыре элекке язмаларда ук булса, иреклесе дә аннан әллә ни калышмый.

Язучыларыбызда дәрт тә, дәрман да бар. Өлгерлек тә юк түгел. Ләкин шушы яхшы сыйфатлар белән бергә үзенә зур бәя бирү дә, аны кирәгеннән артык кабартып җибәрүләр дә бар. Бусы — иң куркынычлы, иң түбән сыйфат. Кайберәүләр: «Галимҗан Ибраһимов, Һади Такташлар... үтелгән этап» кына дип җибәрәләр. Бу исә үзең утырган ботакка балта чабудан башка берни дә түгел. Бу кешеләр Тукайларны, Дәрдмәндләрне, Сәгыйть Рәмиевләр һәм Такташларны, Галимҗан Ибраһимов, Шәриф Камалларны укып телләрен бераз шомартсалар бер дә артык булмас иде. Әлеге дә баягы Тукайлар заманы әдәби телен яхшы өйрәнү хәзерге бездәге кирәк прозада булсын, кирәк шигъриятта булсын бик киң таралган провинция телен бер кадәр чикләр иде, кысрыклар иде. Әдәби телебез ачыла төшәр, мәдәниләшә төшәр иде. Бит бер авыл теле генә әдәби тел була алмый. Әдәби тел шәһәр, авыл, эшче, игенче, зыялылар теленнән үрелеп үсәргә тиеш. Бу хакыйкатьне партада утыручы мәктәп балалары да яхшы белә.

Мәкаләм озынгарак китте бугай. Киләчәктә тел мәсьәләсе хакында махсус мәкалә язмыйча булмас ахрысы диген карарга килеп, шушында тәмамларга уйлыйм. Тел турында сөйләшүләрнең, бигрәк тә безнең өчен, беркайчан да артыгы булмас. Чөнки шигърият турындагы аңгәмәләрнең күбесе нигездә шул телнең төгәлсезлеге аркасында килеп чыга.

Бу — бәхәссез!

# КАЯ КИТКӘН ТЫЙНАКЛЫК?

Бүгенге татар поэзиясе турында бәхәс бара. Шагыйрьләр, укучылар һәм тәнкыйтьчеләр әдәбиятыбызда шигъри бушлыкка зарланалар, поэзиядә чикләвекләр бармы-юкмы, әгәр булса — төшлеме-төшсезме диген бәхәсне чишәргә тырышалар. Казан шагыйрьләре, күрәсең, чикләвекне бик яраталар: Әхсән Баяновның да поэзия турындагы мәкаләсе «Юкәдәге чикләвекләр» исеме белән басылган («Казан утлары», 7 сан, 1988 ел).

Мәкаләнең публицистик пафосы югары, теле үткен. Шуңа күрәдер, мин аны кызыксынып, дикъкать белән укыдым. Анда таләпләр бик кискен, ясалган нәтиҗәләр, чыгарган карарлар бик катгый...

Ә. Баянов татар әдәбиятында «тәртип урнаштырырга» чакыра. Мәкаләнең төп фикере: «Тәртип урнаштыру өчен беренче шарт — соңгы ярты гасырлык әдәби материалны күздән үткәрергә һәм барысын яңача куеп өйрәнергә, ныклап тикшерергә, өр-яңадан бәя бирергә кирәк булачак». Автор — эш кешесе, мәкаләсендә җиң сызга-

нып «тәртип урнаштыруны», «өр-яңадан бәя бирүне» эшкә ашыра да башлый.

Беренчедән, сугыштан соңгы татар совет поэзиясендә Гулливерлар юк, ә лилипутлар гына тулып ята икән. Шул ук вакытта автор, үзенең бу фикеренә капма-каршы буларак, безнең поэзиядә «бөркетләр» һәм «күбәләкләр» очуын, бөркетләрнең «тыйнак» булуын, күбәләкләр белән көрәшми аларга юл бирүен, рәнҗетмәвен тасвирлый.

Икенчедән, автор «бөркетләр — күбәләкләр» классификациясе буенча татар шагыйрьләрен исемләп бүлә дә башлый. Әгәр мәкаләне җентекләп укысаң, «күбәләкләр» төркеменә Хәсән Туфан да, Сибгат Хәким дә, И. Юзеев белән Ш. Галиев та кергәнен күрәсең. Чөнки, Ә. Баянов ревизия ясаганнан соң, Х. Туфанның «теге яки бу вакыйга уңае белән көндәлек мәсьәләләргә багышланган кайбер йомышлы шигырьләре коелып төшүе» бик мөмкин. «...С. Хәким иҗаты да шундыйрак сайлану кичерер әле мөгаен»,— дип өсти Ә. Баянов. Шәүкәт Галиев белән Илдар Юзеев өчен автор укларының иң очлысын, эпитетларның иң тозлысын сайлаган, аларның уңышлары, укучылар арасындагы популярлыгы, аларның әдәби даны авторга һич тынычлык бирми, күрәсең...

Ш. Галиев белән И. Юзеев мактауга да, яклауга да мохтаҗ түгел, билгеле. Аларның поэзиясе татар укучысы булган бөтен төбәкләрдә яңгырады, дистәләрчә шигырьләре халыкның яраткан җырлары булып җырлана. Ш. Галиев поэзиясе тау чишмәсе кебек табигый, матур һәм садә. И. Юзеевның һәр сүзе җаны һәм каны аша уздырылган, шуңа күрәдер укучылар аны үз шагыйре итеп кабул итә.

Әгәр кайбер шагыйрьләребез яңа форма артыннан куып, яңа «юнәлешләр» эзләп, йөрәк җылысы турында оныталар икән — үзләренә үкенсеннәр. Әллә шагыйрь боз өстендә шәрә утырып язган, әллә башын суыткычка тыгып илһам алган — аның шигыре синең бер генә йөрәк кылын да селкетми... Чөнки хикмәт формада да түгел, «юнәлештә» дә түгел, ә талантта. Ә талантны, табигать йә бирә, йә бирми, бигайбә!

«Башка юнәлештә иҗат ителгән әсәрләрне һәм авторларны танымадылар» дип зарлана Ә. Баянов. Теләсә нинди юнәлештә дә талантлы әсәр дә, төссез халтура да чыгарга мөмкин. Һәр чорның әдәбият тарихында моңа мисаллар бихисап.

Онытмыйк әле, Ә. Баянов классификациясендә бөркетләр дә бар бит, кемнәр соң ул «бөркетләр»? Бәрәкалла, машалла, иң зур бөркет Ә. Баянов үзе икән ләбаса! Ул илленче елларның ахырында зур фидакарьлек белән батыр мәкалә язган, ләкин аны әллә онытканнар, әллә аның кирәге калмаган. Алтмышынчы елларда бөркетебез тагын бер поэма язган, аны да күрмәмешкә салышалар. «Сахарин» кушып язган шигырьләрне яратып укыйлар, ә «бөркетләрнең» иҗатын белмиләр! Мәчеләрне мактыйлар, ә арысланнарны күрмиләр!

Ярар, аңлашылды, менә нинди юкәдә икән чикләвек...

«Мине белмиләр, мине күрмиләр, мине мактамыйлар» дигән позициядән чыгып әдип объектив тәнкыйть әсәре яза алмый, билгеле.

Ә. Баяновның һәм кайбер башка әдипләрнең «бүген татар поэзиясендә — бушлык», янсә анда «лилипутлар гына кайнаша» дигән фикере белән һич тә килешеп булмый! Исән булмаган зур талант иярәре турында язып тормыйк,— аларның урыны беркайчан да югалмас. Исән шагыйрьләр И. Юзеев, Ш. Галиев, Р. Фәйзуллин бар, Г. Рәхим, Р. Вәлиев, Р. Миңнуллин бар. Алар лилипутлар да, игезәк балалар да түгел, аларның үз моңнары бар...

Мәкаләдә искә алынган Р. Гатауллин бар, аның иҗатын нинди калыпка салып та үлчәргә була, мәхәббәт, дуслык темасына басылган лирикасын рәхәтләнеп укыйбыз без. Р. Мингалимовның тирән фикерләр һәм күркәм хисләр белән сугарылган поэзиясе, Зөлфәт һәм М. Әгъләмовның укучыны һич битараф калдырмый торган шигырьләре, Н. Арслановның шәрык классик поэзиясе традициясен дәвам иткән иҗаты һәм ифрат уңышлы тәрҗемәләре («Гомәр Хәйям» робагыйларын гына искә алыйк!)— болар барысы да «юкәдәге чикләвекләр», «төшсез чикләвек», «шигъри бушлык»-мыни? Әгәр санап китсәң (сокланырлык шигъри үрнәкләр биргән шагыйрьләребезне дә онытмыйк), тагын да ярыйсы гына шигъри аһәңле каләм осталарыбыз бар әле безнең! Шөкер, башка милләтләр поэзиясе белән чагыштырганда бер дә ким-хур булырлык түгел!

«Безнең поэзиядә — бушлык, анда лилипутлар гына кайнаша» дигән фикер белән һич тә килешә алмыйм мин. Укучылар күптән яратып укый торган шагыйрьләрне инкарь итеп алган данның бәясе арзан, гомере кыска булыр. «Хакыйкатьне ачыкларга телисең икән, риторика белән котыла алмыйсың». Үпкәдән, рәнҗүдән өскә менеп, укучылар фикерен, башка тәнкыйтьчеләр карашын үлчәп, һәръяклап бәя биреп кенә объектив мәкалә язып буладыр, минемчә.

**Вахит ЮНЫСОВ.**

Мәскәү.

Библио-графия

# ТУКАЙ ЯЛКЫНЫ ЯҢАРА!

Сыйныфлар якалашкан кайнар бер чорда мәйданга чыгу Г. Тукай публицистикасын сугышчан рух белән сугара, аны заманның алдынгы идеаллары өчен үткен көрәш коралына әверелдерә. Әмма шагыйрь иҗатының яртысын диярлек тәшкил иткән, үз чорының сыйнфый, идеологик, әдәби-эстетик көрәшләрен иң җитез гәүдәләндергән публицистика әсәрләре чагыштырмача аз өйрәнелгән әле. Шуңа күрә Флорид Әгъзамовның «Тукай — журналист» исемле монографиясе бу юнәлештәге җитди адымнарның берсе булып исәпләнергә тиеш.

Биш бүлектән торган бу китапта Габдулла Тукайның вакытлы матбугат турындагы карашлары анализлана, аның демократик һәм революцион-демократик журналистиканы тудыру, үстерү өсен армый-талмый алып барган эшчәнлеге тасвирлана.

Китапның үзәгенә салынган фикер — Тукай публицистикасының халык мәнфәгатьләрен яклауга, халыкка хезмәт итүгә юнәлдерелгән булуы. Шагыйрь үзе дә публицистиканы иҗтимагый-политик эшчәнлекнең әһәмиятле бер өлкәсе итеп саный. Шуңа күрә дә романтик дусты Сәгыйт Рәмиевкә язган хатында: «Мин синең кебек саф, коеп куйган поэт кына түгел, мин дипломат, политик, общественный деятель дә»,— дип искәртүе очраклы хәл түгел анын.

Китапның тәнкыйди публицистиканы тикшерүгә багышланган бүлеге аеруча уңышлы башкарылган. Автор Тукайның публицистик теле, тәнкыйть сүзе, сатира белән ачылып китүен һәм гомеренең азагына кадәр аларның ташкын кебек агуы турында яза. Шагыйрь Көнбатыш империализмын да, Көнчыгыш деспотизмын да, патша хөкүмәтенең полициягә таянган аппаратын, бюрократиясен, колониаль һәм милли изү политикасын да фаш итә. Шәхесне физик һәм рухи изгән буржуаз җәмгыять, капитал хакимлеге, буржуаз партияләр, һәртөрле милләтчеләр Тукай сатирасы укларыннан котыла алмый. Татар тормышындагы феодализм калдыкларын тәнкыйтьләгәндә, кадимчелекне, искелек, торгынлык тарафдарлары булган мулла-мунтагайларны, доносчы ишаннарны, хатын-кыз азатлыгы дошманнарын камчылаганда Тукай чын мәгънәсендә яшен утлары уйната, көлүнең гаять күп алымнарына мөрәҗәгать итә.

Ф. Әгъзамов шагыйрь публицистикасында уңай идеалларны раслауга да зур урын бирелүен, фаш итүенең нигезендә позитив программа ятуын билгеләп үтә. Авторның: өстен сыйныфларны тәнкыйтьләгән, халыкның авыр хәлен чагылдырган, социаль, экономик, политик, милли, рухи изүне ачык күрсәткән Тукай публицистикасы халык массаларының аңын революционлаштыруга хезмәт итте, дигән нәтиҗәсе белән килешми мөмкин түгел.

Китапның барлык бүлекләрендә дә диярлек теге яки бу проблемага мөнәсәбәттә Тукайның дөньяга карашлары тикшерелә, шагыйрьнең тарихи прогресс идеяләре белән сугарылган мәгърифәтчелеге хакында игътибарны җәлеп итәрлек фикерләр әйтелә.

Егерме елдан артык инде революцион-демократ Тукайның марксизмга мөнәсәбәте хакында бәхәсләр бара. Берәүләр шагыйрь революцион демократизмының пролетар идеология белән тыгыз мөнәсәбәттә булуын кайнар яклый, икенче берәүләр исә, моны шик астына ала, шагыйрьне «кызарту» дип исәпли.

Пролетар революцияләр чорында әдәби һәм журналистлык эшчәнлеген башлап җибәргән Тукай, билгеле, XIX йөз рус революцион демократлары кебек, крестьян шагыйре, крестьяннар революциясе тарафдары гына булып кала алмады. Иҗатының һәм Уральск, һәм Казан чорында эшче-крестьяннарның социаль һәм милли азатлык көрәшенең үзәгендә кайнады, большевистик идеологиянең дә көчле тәэсирен тоеп иҗат итте. Шагыйрьнең революцион хәрәкәттә актив катнашуы, марксистик әдәбият үрнәкләрен татарчага тәрҗемә итү һәм пропагандалау, поэзия һәм публицистикада турыдан-туры социалистик идеяләргә теләктәшлек белдерү, Думага мөнәсәбәт, капитал дөньясының чын асылын аңлау һәм аны фаш итү, «хөр мәмләкәт, хөр Русия» идеалларын күтәрү, руслар белән татарларның тарихи биргәләек идеясен яклау — болар барысы да, Ф. Әгъзамов язганча, «объектив рәвештә социал-демократиянең тактикасына туры килгән» һәм «Тукайның политик җитлеккәнлеген, пролетар интернационализмны аңлау дәрәҗәсенә якын ук килгәнлеген раслаган» фактлар. XX гасыр башындагы революцион демократизмның социал-демократик идеология белән тыгыз бәйләнгән булуына В. И. Ленин да басым ясап язган иде. Кыскасы, ша-

гыйрьнең революцион-демократик карашларын социал-демократик идеологиядән араларга тырышу, иә булмаса каршы куярга маташу — тарихи чынбарлыкка туры килми, татар әдәбиятындагы Тукай феноменын ачуга да комачаулык кына итә.

Монографиядә Тукайның әдәби-тәнкыйть өлкәсендәге эшчәнлеген яктырту үзгә урын алып тора. Тукай иҗатын өйрәнүче башка галимнәр кебек Ф. Әгъзамов та шагыйрьнең реалистик әдәбият белемен һәм әдәби тәнкыйтен нигезләүчеләр арасында иң күренеклесе булуы турында яза. Ләкин автор бу хактагы мәгълүм фикерләр белән генә чикләнеп калмыйча, Тукайның әдәбият һәм сәнгать мәсьәләләрен күтәргән мәкаләләрендә шул чор рус марксистик эстетикасы белән уртак моментлар булуга да игътибар итә. Шагыйрьнең изелгәннәр мәнфәгатен яклап Меньшиковлар, Гучковлар, Пуришкевичлар, пантюркистлар, буржуаз милләтчеләр, клерикаллар культурасына каршы алып барган көрәшен бу эшчәнлекнең «һәр милләттә ике культура бар» дигән ленинчыл тәгълиматка бик тә аваздаш икәнлеген кат-кат искәртеп үтә. Әйтергә кирәк, тирән бәйләнешләрне ачыклау — Ф. Әгъзамов фәнни эзләнүләренең бик тә отышлы һәм уңай ягы. Китапта Тукайның үз халкын, үз милләтен өзелеп яратучы шагыйрь һәм интернациональ табигатьле публицист икәнлеге күп санлы мисаллар белән раслана. Анда татар шагыйренең гомумкешелек культурасы белән күпкырлы бәйләнешләре хакында да, Крылов, Пушкин, Толстой, Байрон кебек язучыларның гуманистик карашларын иҗади кабул итүе һәм пропагандалавы хакында да тәфсилле сөйләнә.

Тукай публицистикасында әдәби мирасыбызга мөнәсәбәтнең тарихилык һәм халыкчанлык принципларының ничек гәүдәләнүен анализлаганда, Ф. Әгъзамов шагыйрьнең фольклор, урта гасыр, XIX, XX гасыр башы татар әдәбияты турындагы фикер-карашларын системага салып, киң контекстта карый. Бу системада Тукайның политик һәм сыйнфый сизгерлеге, әдәбият һәм сәнгатьнең үсеш юлларын аңлый һәм алдан күрә белү сәләте, художникның зирәклеге аеруча калку булып ачыла. М. Гафури, Г. Камал, Г. Ибраһимов, С. Рәмиев, С. Сүнчәләй, З. Бәшири кебек замандашлары иҗатына Тукайның мөнәсәбәте, аларның эшчәнлеген халыкның социаль һәм әдәби эстетик тәҗрибәсе күзлегеннән чыгып бәяләве автор тарафыннан бәйнә-бәйнә тасвирлана.

Хезмәттә Тукай иҗатындагы публицистик жанрларны өйрәнүгә махсус бүлек багышлауны да хупларга кирәк. Автор Тукайның XX гасыр башы татар публицистикасындагы жанрларның табигатен үзгәртү һәм баету юлында гаять зур эш башкаруын конкрет мисаллар ярдәмендә раслый.

Иөгерек һәм җиңел тел белән язылган «Тукай — журналист» исемле хезмәттә нинди кимчелекләр бар? Әйтик, иң әүвәл «руханиларның суалчанлык сыйфатлары» (73 бит), «Толстойның табигый бөеклеге» (252 бит) кебек урынсызрак кулланылган сүзләр күзгә чалына. Әдәбият галимнәре хезмәтләрендә еш очрый торган «сәнгатьчә фикерләүнең ике тибы» (реалистик һәм романтик) дигән төшенчәнең журналистикага карата кулланылуы да уңышлы түгел дияргә кирәк. Китапта тагын шундый момент ризасызлык хисе уята: мәгърифәтчелек идеаллары күзләгеннән клерикализмны кискен тәнкыйтьләгән кайбер мәкаләләр революцион демократик эчтәлекле дип карала; Г. Камалның мәгърифәтчелек реализмы ысулы белән иҗат ителгән кайбер пьесалары революцион демократик карашларга нигезләнгән критик реализм әсәре итеп яктыртыла. Күренә ки, автор феодализм калдыкларын фаш итүдә зур роль уйнаган мәгърифәтчелек тәнкыйте һәм сатирасы мөмкинлекләрен бәяләп җиткермәми, аны революцион демократик тәнкыйть һәм сатира дәрәҗәсенә күтәрергә тырыша.

Тукай башка милләтләрдән өйрәнү кебек «мөһим закончалыкны эмпирик югарылыкта булса да яхшы аңлаган» (184 бит) дигән фикер белән дә килешәсе килми. Феодаль-буржуаз җәмгыять шартларында халыклар һәм әдәбиятлар дуслыгын җырлаган Тукайны дөньяны танып-белүнең эмпирик баскычында гына калган дип әйтү чынбарлыкка туры килми. Бу очраклы рәвештә генә әйтеп ташланган фикер булса кирәк. Чөнки хезмәтнең бөтен эчтәлеге, бөтен рухы да моның киресен сөйли.

«Казанга кайтыш» юлъязма очеркындагы тимерчелек белән шөгыльләнүче, сәгать төзәтүче, ә элегрәк музыка кораллары да ремонтлаган, ә хәзер кибет тотучы крестьян агайның киләчәктә «авыл буржуазиясен — кулакка әверелеп, халык канын эчеп ятачагын алдан күрә алмавда» (240 бит) Тукайны гаепләү дә сәер тойгы калдыра. Бу — без әле дә булса котылып бетә алмаган вульгар социологизм шаукымы кулыннан эш килә торган крестьян агайны һаман да шул сыйнфый дошман итеп күзалларга тырышу чире ләбаса...

Сүзне йомгаклап шуны әйтергә кирәк: Ф. Әгъзамов Тукайның гаять кызыклы публицистик мирасын билгеле бер системага салган, аерым вакыйга һәм шәхесләрне тәгаенләү җәһәтеннән дә шактый зур эш башкарган, фактларны концептуаль эзлеклелектә өйрәнеп, игътибарны җәлеп итәрлек теоретик фикерләр тәкъдим иткән. Илебездә зур яңарыш һәм үзгәреш барган чакта Тукайның журналистлык осталыгын өйрәнү гаять зур әһәмияткә ия, һәм шундый изге максат белән язылган бу хезмәтне һичшиксез хупларга кирәк.

**Резеда ГАНИЕВА.**



*Күренекле татар галиме, язучы һәм мәгърифәтче Ризаэтдин Фәхретдинев — катлаулы тормыш юлы узып гаять зур иҗат мирасы калдырган шәхес. Киң карашлы галим буларак ул туган халкының гыйбрәтле һәм катлаулы тарихын өйрәнүгә дә зур игътибар бирә. Фидакарь галим гомере буе милли тарихыбызның нигез ташларын тәшкил итүче чыганаклар туплый, китапларында һәм газета-журнал битләрендә дөнья күргән күп санлы мәкаләләрендә татар халкының мәдәни мирасын пропагандалый.*

*Мәгълүм булганча, Р. Фәхретдиневнең берничә дистә томлык хезмәтләре кулъязма хәлендә калган, кайберләре югалган да. Бу санда журнал укучылар игътибарына галимнең моңа кадәр дөнья күрмәгән бер тарихи хезмәте тәкъдим ителә. «Болгар һәм Казан төрекләре» дип аталган бу хезмәт 30 нчы елларның беренче яртысында язылган. Аның кулъязмасы хәзерге вакытта Уфада Тарих, тел һәм әдәбият институты архивында саклана. Әлеге хезмәт журнал мөмкинлекләрен исәпкә алып һәм кайбер кабатлаулардан котылу өчен беркадәр кыскартып басыла. Кыскартылган урыннар күп ноктлалар (...) белән күрсәтелде. Аны басмага СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты фәнни хезмәткәре Әнвәр Хәйруллин әзерләде.*

## Ризаэтдин Фәхретдинев

# БОЛГАР ҺӘМ КАЗАН ТӨРЕКЛӘРЕ

### Болгарларның мәмләкәтләре һәм хөкүмәтләре

...Болгарлар, гыйлем һәм сәнгать, иҗтимагый тормыш ысуллары һәм дә гомумән мәдәниятне иранлылардан алганлыклары һәм алар белән көчле рәвештә аралашулары булып, күп эшләрдә, гореф һәм гадәтләрдә аларга ярашулары мәгълүм.

Болгарлар — бу көндәге Германия кебек күп җөмһүриятләрдән (республикалардан — Ә. Х.) гыйбарәт бер хөкүмәт булып, бөтенесе бер хан идарәсенә буйсына иде. Спасс Төбәгендә (Казан губернасы) Иделнең сул ягында кайбер тарихи исталекләре бу көнгә кадәр сәламәт булган Болгар шәһәре — болгарларның ханнары тору өчен махсус башкала шәһәре иде.

Болгарлар хакында башлап хәбәрләр язучылар, тарихларга керүләренә сәбәп булучылар — гарәп тарихчылары булды. (...) Гарәпләр тарафыннан болгарлар (безнең бабаларыбыз) хакында язылган хәбәрләр бер урынга җыелганда озын бер чылбыр тәшкил итәләктер.

Шушы гарәп галимнәре үзләре Урал һәм Идел буйларында йөргәннәр, болгар төрекләре (төркиләре—Ә. Х.) белән аралашканнар, хәлләрен тикшереп мәгълүмат җыйган-

нар һәм шул мәгълүматларны язганнар. Боларның болгар төрекләре хакында биргән хәбәрләре һиҗри белән 310 һәм милади белән 922 елдан башлана һәм күп елларга кадәр дәвам итәдер. Дөрес, гарәп тарихчыларының болар хакында кайсыбер кешеләрне адаштырырлык рәвештә ялгыш хәбәрләр бирүләре дә бар. Моның сәбәбе — үзләренең адаштырылулары һәм ялгыштырылулары (адаштыру һәм хакыйкатьне яшерү теләге белән сөйләнгән хәбәрләргә ышанулары)дыр. Шулай булса да, болгарларның төрек кавеменнән булулары хакында биргән хәбәрләре дөрес булуда һич шөбһә юк. Ул эш — хакыйкать һәм булган эштер.

Гарәп тарихчылары: «Болгар мәмләкәте — Бортас җире белән күрше булып, бортаслар[1] болгарлар белән хәзәрләр (түбән болгарлар) җирләренең уртасындалар, слау (славян) җиреннән чыгып Хәзәр диңгезенә коела торган Идел-Ител елгасы буенда»,— диләр. Болар болгарны Олуг Болгар һәм дә Кара Болгар исемнәре белән дә йөреттеләр. Олуг Болгар диюләре Дунай елгасы буена күчеп киткән болгарларны, Кече Болгар дип игътибар кыйлулары һәм дә Кара Болгар диюләре — болгарларның ислам кабул итүләреннән соң Габбаси хәлифәләргә ярашуларыннан, хөкүмәт билгесе итеп кара төсне ихтыяр итүләреннән иде,— диләр.

Гарәпләр Болгар мәмләкәтен Бәрсула, Әсгаль, Болгар исемнәрендә бүлемләргә дә бүләләр, боларның бер-беренә күрше булуларын сөйлиләр. Ләкин, бу рәвештәге бүленүләр, бер мәмләкәтнең өлкәләргә, төбәкләргә бүленүләре кебек кенә булачагы мәгълүм[2].

Болгарларның бөек хөкүмәтләре (мәркәзләре) һәм мөстәкыйль бер хөкемдарлары булып, шул хөкемдар (хан һәм падишаһ) кул астында вак хөкүмәтләр һәм ханнар бүганлык югарыда телгә алынды. (...)

Милади белән 631 елларда бер мең кадәр болгарлар үзләренең хатыннары һәм бала-чагалары белән шушындый бер фетнәдән котылу теләге белән мәмләкәтләрен ташлап киттеләр һәм көнбатыш тарафына сәфәр итеп Франция өлкәсенә барып кердeләр. Шунда җирләшеп, французларга аралаштылар һәм французлаштылар[3].

Һиҗри белән 287, милади белән 907 елларда булган фетнәдә Болгар төрекләреннән олуг бер җәмәгать көнбаеш тарафына китеп Маҗарстан мәмләкәтенә нигез салулары һәм үзләре белән берлектә булган бер шаһзадәне хан итеп куюлары риваять ителә[4]. Болар да җирле халыкларга аралашулары сәбәбеннән үзләренең ата-бабаларының (һун һәм болгарларның) телләрен оныттылар, төрле кавемнәргә аралашулары сәбәбеннән төсләрен һәм кыяфәтләрен үзгәрттеләр,— диләр.

Гарәп сәяхәтчеләренең хәбәрләренә карaганда, Болгар мәмләкәте сазлык һәм кара урманлык булып, урманнарда чикләвек агачы күп үсәдер һәм бу агач унар фәрсәх[5] кадәр урыннарны билидер.

Болгар мәмләкәтенең бик зурайган һәм кечерәйгән вакытлары да булды. Күбрәк вакытта үз идарәсендә булган милекләре Урал таулары, Ока һәм Сура сулары, Дон буйларыннан гыйбарәт буладыр иде.

Болгар — мәдәниятле һәм үз күршеләренә караганда гыйлемле мәмләкәт иде. Рус кнәзьләреннән Владимир беренче тапкыр болгарлар белән сугышырга булганда гаскәренең башлыгы моңа: «Болгарларның аяклары итекле, без аларны җиңә алмабыз, бәлки безнең өчен үзебез кебек аяклары чабаталы булган халыклар белән генә сугышырга кирәк»,— дип киңәш биргән иде[6]. Моннан максат: «Болгарлар гыйлемле һәм мәдәниятле, өс-башлары бөтен һәм әсбаблары камил, әмма без алар дәрәҗәсендә түгелбез»,— диюдер. Соңгы вакытларда рус падишаһлары татарларны җиңеп, дәрәҗәләрен бетергәннән соң да болгар кнәзе дигән дәрәҗәле исемнәрен һаман дәвам иттерделәр һәм моның белән бер мәмләкәттә булган бөтен төрек кавеменә һәм ислам милләтенә хаким булуларын мактану урынында кулландылар.

---

[1] Бортас исемле кавемнәрнең кемнәр булганлыгы ачык рәвештә мәгълүм түгел. Боларның бер вакытларда мөстәкыйль булып торганлыклары һәм икенче бер вакытта Болгарга иярүләре һәм дә кайбер төркемнәренең ислам кабул иткәнлекләре риваять ителәдер. Боларның мордвалар (мукшылар) булачагын да уйлаучылар бар. Әгәр дә мордвалар булса, болар татарлар һөҗүм иткән вакытларда һәлак булып беткәннәрдер.

[2] Казан төбәгендә Сивиль (Чивиль) шәһәренең исеме мондагы Әсгаль сүзеннән хәрефләре үзгәртелгән һәм яки Әсгаль сүзе үзе Сивильдән гарәпчәләштерелгән булуы мөмкин. Һәрхәлдә Әсгаль исемендәге болгар төрекләре бу көндәге Цивиль шәһәре тирәсендәге мөселманнарның бабалары булуы уйланыладыр.

[3] Р. Фәхретдинев борынгыдан килгән традиция буенча Көнбатыш Европа халыкларын «Әфрангиләр» дип атаудан чыгып «французлар» дип сүз алып бара булса кирәк — Ә. Х.

[4] Мәмләкәтебездәге мишәр белән маҗар кавемнәренең арасында мөнәсәбәт бар. Шуңардан һәм дә башка дәлилләрдән нәтиҗә чыгарып, бу ике төркемнең бер нигездән таралганлыгын уйлаучы галимнәр бар. Маҗарлар иске бер кавем булган кебек, мишәрләр дә иске бер кавем. Татарлар килмәстән элек бу өлкәдә Михар исемле кавем булганлыгы мәгълүм (Карамзин тарихы, I кисәк, 39 бит). Ибне Баттута, Болгар өлкәсенә булган сәфәрендә Маҗар исемендә бер шәһәрдә булганын сөйли. Әлеге шәһәр хакында: «Төрекләрнең иң гүзәл һәм дә олуг шәһәрләреннән булып, бакчалар, җимешләр күп»,— ди. Соңыннан бу шәһәрне Аксак Тимер харап итте. «Маҗарстан белән Маҗар шәһәре исемнәрендә мөнәсәбәт барлык мәгълүм. (Маҗарстан — Венгриянең борынгы атамасы — Ә. Х.).

[5] Фәрсәх — ераклык үлчәве (6-7 км. чамасында — Ә. Х.)

[6] Карамзин тарихы. I кисәк, 18 бит.

Болгар хөкүмәте үзе акча сугадыр иде. Шуның белән берлектә Болгар мәмләкәтендә гарәп хөкүмәтләре һәм дә Иран һәм Европа хөкүмәтләре тарафыннан сугылган да кулланыладыр иде. Ул вакытларда бу гадәт бер Болгарда гына түгел, бәлки бөтен дөньяда гомуми булып, һәр урында һәм төрле алтын, көмеш һәм бакыр акчалар кабул ителәләр һәм кулланылалар иде.

## Болгарларның нәселләре һәм телләре

Болгар кавеменең төрек нәселеннән булып, төркичә сөйләшүләрендә шөбһә юк. Боларның мәдәниятләре югары дәрәҗәдә булган чакларында, araларында катнашып йөргән гарәпләр моның төрек кавеменнән булулары һәм төркичә сөйләшүләрен (телләре төркичә булуны) бәян кылалар.

«Болгар» дигән кавем нинди халык буладыр?» — дип сорауга каршы һиҗри белән 433 (милади белән 1041 елда—Ә. Х.) елда Багдад шәһәрендә булган Болгар хаҗиларының: «Төрек белән сәкълаб (яки сакълаб)лар катнашыннан һәм аралашуларыннан хасыйл булган кавем»,— дип җавап бирде[7]. Бу — дәгъваны исбат итәдер. Чөнки «сәкълаб» — чынбарлыкта үзе дә төрек иде[8].

Төрек кавеменнән булган болгарларның сүзләре төркичә булачагы үз-үзеннән мәгълүм. Дөрес, кайбер иске каберләрнең ташларындагы язуларның безнең бу көндәге телебезгә нисбәт белән чуаш теленә (җирле сөйләменә) якын булганлыгы инкяр ителми. Ләкин бу эштән болгарларның телләре төркичә булмавы түгел, бәлки кайбер мөселманнарның чуаш телен кулланган булулары гына аңлашыладыр. Чуаш теле — үзе дә төркичә телләрнең бер тармагы гына булса кирәк. Һәрхәлдә әлеге кабер ташларындагы язулардан мөселман чуашлар булганлык һәм кабер ташлары да үз җирле сөйләм телендә язылганлыгы аңлашыла. Болгарлар арасында чуаш һәм мордва мөселманнары булу мөмкин[9].

Дунай буена барып урнашкан болгарлар — җан хисабы белән үзләреннән күп булган славян кавемнәренә аралашулары сәбәбеннән үзләренең тарихын һәм милләтләрен онытып, славян булып киттеләр. Бары ыругларының исеме булган болгар сүзен генә үзләренә исем итеп шуны саклап калдылар. Юкса, алар Казан һәм Урал буйларындагы мөселманнар рәвешендә чын болгарлар һәм чын төрекләр. Болгар сүзе — төркичә булган кебек, үзләренең сүзләрендә төркичәдән үзгәргән, яки сәламәт хәлендә төркичә сүзләр күп,— дип тел тикшерүче белгечләр риваять итәләр[10].

## Болгарларның мәдәниятләре. Кәсеп һәм һөнәрләре

Гарәп язучылары болгар төрекләре хакында: «Мәдәни һәм көчле бер милләт булып, күбесенчә шәһәрләрдә һәм авылларда яшиләр, иген эшләре белән дә шөгыльләнәләр, сату-алу белән кәсеп итәләр»,— диләр. Болгарларның биналарын тасвирлаганда бер язучы: «Бүрәнә өстенә бүрәнә салу юлы белән төзиләр һәм бүрәнәләрне агач кадаклар белән бер-беренә беркетеп баралар»,— ди[11].

Дөрес, болгар төрекләре иген эшләре белән шөгыльләнәләр, бодай, арпа кебек орлыклар чәчеп азык хәзерлиләр һәм озын кышларны рәхәтлектә уздыралар иде. Шулай булса да артык дәрәҗәдә күңел куйган эшләре — сәүдәгәрлек иде.

Греклар белән кайчакта сугыш һәм кайчакта солых хәлендә яшәгән иранлылар яу вакытларында да, тыныч вакытларында да болгарларга күрше урыннардан, күбесенчә үзләренең өсләреннән йөргәнлекләре һәм дә Европа белән булган сәүдәләре бөтенләй болгарлар өстеннән үтүләре белән булганлыктан, болгар төрекләре мәдәният юлына иртә кергәннәр, хәтта Иран белән Греция мәмләкәтләреннән соң өченче булып саналырга лаеклы булып кәсеп иткәннәр.

7 Тарихел-кәмил. 9 кисәк, 173 бит. Әлеге сүзнең мәгънәсе: «Шарык тарафыннан килүче төрекләр (һуннар) белән җирле төрекләр катнашкан кавемнәр «болгар» дип аталдылар.»— диюдер.

8 Унсигезенче гасыр милади урталарында: «Ибне Фазлан болгарларны славян кавеменнән дип хәбәр бирә, шуның өчен болгарлар — славян кавемнәре булыр»,— дигән бер фикер таралган иде. Соңгы вакытларда шушы фикернең ялгыш иканлеге ачык мәгълүм булды. Ялгышуның сәбәбе — әлеге кешеләрнең Ибне Фазлан гыйбарәсендәге «сакълаб» (сакълаб) сүзен «славян» дип тәрҗемә итүләредер. Бу кешеләр — бу көннәрдәге Мисыр һәм Сүрия гарәп язучылары теленнән «сәкълаб» сүзе «саклау» сүзеннән гарәпчәләштерелгән дип фикерләгәннәр дә «сәклау» белән «сәкълаб» бер нәрсә, шуңа күрә болгарларның славян булулары белән хөкем йөрткәннәр. Әмма чынлыкта Ибне Фазланның «сакълаб» дип сөйләгән кавеме славян түгел, бәлки «фин»дыр. Бу — югарыда да сөйләнде.

9 Болгарларның төрки нәселдән булулары һәм төркичә сөйләшүләре соңгы галимнәр тарафыннан кабул ителгән бер хакыйкатьтер. Шуның өчен бу турыда сүз озайтуга ихтыяҗ юк.

10 Дунай болгарлары хакында «Камусел-агълам»да («Галәм сүзлеге») бер кадәр җентекле аңлатулар бар. «Болгар» бүлегендә.

11 «Мөгъҗамел-бөлдан» (Илләр сүзлеге»— Ә. Х.), I кисәк, 272 б.

Иранлылар белән европалыларның сәүдәләренә арадаш булыр өчен сәүдә әһелләрен иртә өйрәнгәннәр, хәтта ике милләтнең сәүдәсенең үзәге булу өчен Болгар шәһәрен төзеп сәүдә үзәге ясаганнар иде. Европа, Греция, Иран һәм Төркстан, Кытай һәм Һиндстан кәрваннары Болгарга килеп актарылалар һәм шунда да дөньяның һәр тарафына мал төяп китәләр иде. Бу эшләр бигрәк тә моннан тугыз-ун гасырлар элек аз һөнәр булып саналмаса кирәк.

Бу тарафтагы халыклар тирмәләр белән күчеп һәм мал көтеп йөргән булсалар, икенче якларындагы күршеләре урманнарда куышлар ясап һәм базлар казып, шуларда гомер сөргән булсалар, болгар төрекләре — бүрәнәләрдән бурап өйләр салалар, кирпечләрдән морҗалар чыгаралар, тәрәзәләр куялар һәм кышкы салкыннарда рәхәт гомер сөрәләр иде.

Болгарлар, читләрдән килгән нәрсәләрне алып һәм озатып торуга канәгать итми, бәлки сәүдә белән үзләре йөри башладылар, Иран һәм дә Кытай һәм башка мәмләкәтләр сәүдәсе белән ярышу юлына керделәр. Болар сәүдә белән ерак өлкәләргә баралар иде. Идел, Ока, Чулман (Кама—Ә. Х.), Вятка елгалары—боларның сату белән йөри торган юллары иде. Харәзм, Кытай һәм Хорасан, Иран һәм Һиндстан кебек ерак өлкәләргә сату кәрваннары йөреп торадыр иде.

Болгарлардан читләргә китә торган маллардан күбрәк шушы нәрсәләр буладыр иде: кеш, тиен, ятчә, сусар, төлке, кама, куян мехлары, кәҗә күне, балавыз, ук, эре балык, балык җилеме, балык теше (мамонт яки морж теше), гәрәбә, чикләвек, кылыч, калкан, каен агачы, ислам әсирләре[12], сарык, куй һәм мөгезле хайваннар.

Бу малларның күбесе болгарларның үзләренеке булып, кайберләре руслар, пирманнар (Пермь өлкәсендә торучы кавемнәр), вотяклар (удмуртлар—Ә. Х.) тарафыннан Болгарга китерелгән буладыр иде.

Сату турысында үзләре үзәк булып тору, сәүдә галәмендә хөкем сөрү теләге белән чит мәмләкәтләрнең сәүдәгәрләрен үзләреннән уздырмау өчен һәртөрле чараларны күрәләр һәм куркыныч хәбәрләр сөйләп өркетәләр иде. Гарәп галимнәре тарафыннан болгарлар хакында кайбер ялгыш хәбәрләр таралуга сәбәп — шул рәвештәге хәйләләр һәм уйдырма хәбәрләр булды,— диләр.

Болгар төрекләрен башкалардан өстен иткән урыннары — күн эшләү турысында иде. Болгарлар тарафыннан эшләнә торган болгар күне шәрык тарафында да, гарәб (көнбатыш — Ә. Х.) тарафында да яхшы кабул ителә иде.

Моннан башка бакырчылык һәм тимер сугу һөнәрләрен яхшы белгәнлекләре, бакырдан һәр төрле савытлар һәм казаннар һәм дә агачтан бадиян һәм кәндиләр ясаулары мәгълүм. Тимер эретү учакларының эзләре хәтта бу көнебезгә кадәр калганлыгы риваять ителәдер.

Һәрхәлдә болгар төрекләре мәдәниятле һәм гыйлемле булып, араларында хәтта тарихчылар булганлыгы да риваять ителәдер. Болгар шәһәрендәге казыйлардан берсе: «Болгар тарихын» язган иде. Ләкин бу әсәр бу көндә дә табылмый. Алла белә, татарлар һөҗүм иткәндә гыйльми әсәрләрне һәлак итеп, юкка чыгарып бетерүләре вакытында бу әсәр дә юкка чыккандыр. «Нәсыйхәтес-салихин», «Башлагали», «Нәһҗел-фәрадис», «Бәдәвам» кебек әсәрләрне дә шушы болгарларга нисбәт итәләр[13].

## Болгарларның мәшһүр шәһәрләре

Болгар төрекләре сәүдәгәр һәм һөнәрле һәм дә шул заманга күрә мәдәниятле булганлыкларыннан шәһәрләре һәм авыллары күп буладыр иде. Боларның шәһәрләреннән һәм кальгаларыннан кайберләре бу көндәге шәһәрләр урыннарында булырлар һәм кайберләре сугыш вакытларында дошманнары тарафыннан җимерелделәр һәм ватылдылар, хәтта урыннары да югалды.

Бу көнгә кадәр исемнәре калган шәһәрләрдән боларны күрсәтергә була: Арнас, Ибраһим (Бряхимов), Уйшил (Ашлы — Ә. Х.), Басув, Биләр, Болгар, Тухчин, Саксыйн, Суар, Кирмәнчек, Җүкәтау.

---

[12] Болгар шәһәрендә әсирләр сатыла торган бер базар булып, руслар үзләренең әсирләрен шунда китереп саталар иде. Шул әсирләр — Иран, Гыйрак, Төркстан һәм Һиндстан, хәтта Әндәлес (Испания — Ә. Х.) өлкәләренә кадәр таралганлыгы риваять ителәдер. Славян кавеменнән бу әсирләр Болгардан таралу мөнәсәбәте белән чит мәмләкәтләрдә күбесенчә болгар әсирләре һәм болгар кызлары исемнәрендә йөртеләләр иде. гарәп һәм фарсы шагыйрьләре тарафыннан шигырьләрендә мактала торган болгар кызлары һәм болгар мөслимәләре (мөселман кызлары) чынбарлыкта руслар тарафыннан Болгарга китерелеп сатылган славян кызлары буладыр иде.

[13] «Мөстәфадел-әхбар...» I кисәк, 15 бит. «Нәһҗел-фәрадис» иясе Мөхәммәд шәех Ясир 761 нче һиҗридә вафат булган иде. Бу китап Истанбулда «Яңа җамигъ (мәчет — Ә. Х.) китапханәсендә» иде, 879 нчы санда саклана.

## *Суар*

Бу шәһәр хакында гарәп тарихчылары болай дип язалар: «Бу шәһәр — мәшһүр Болгар шәһәренә бик ерак түгел. Үзендә зур мәчет бар, йортлары — нарат һәм чыршы бүрәнәләреннән төзелгән. Кешеләре кыш көнендә шул йортларында торалар. Әмма җәй көннәрендә җәйләүләренә чыгалар.

Бу шәһәрнең урынында бу көндә бер рус авылы бар, диләр. Кятиб Чәләби «Бәһҗәтел — әнвар мин хакыйкатид-әсрар» (Нурларның матурлыгы — серләрнең дөреслегеннән— Ә. Х.) исемле әсәрнең язучысы — Сөләйман бине Дауд әс-Суари дип сөйли[14]. Болгар шәһәре булган шушы Суар шәһәренә мөнәсәбәтле түгелме? Суарның бу көндәге Сакмар шәһәре булуын уйлаучылар да бар[15].

## *Җукәтау*

Русларның «Жукотин»[16] дип йөртә торган шәһәрләре шушы Җукәтау булса кирәк. Бу шәһәрнең үзе бу көндә Чистай төбәгендә Танавир исемле рус авылы янында,— диләр.

## *Саксыйн*

Бу шәһәр хакында тарихларда болай язылган сүзләр бар: «Төркстан өлешендә олуг бер шәһәр булып Иделдән ерып кертелгән судан башка суы юк. Тирә-якларындагы халыклар тирмәләрдә торалар, үзләре — ислам динен тоталар. Татарларның Болгар белән сугышу өчен хәрәкәт итүләрен ишетү белән, бу шәһәрдә торучы болгар сакчылары качып Болгарга кайттылар һәм вакыйгадан хәбәр бирделәр. Бу шәһәр — шушы тирә-якта үзәк шәһәр булып торадыр иде. Соңыннан су астында калып һәлак булды, эзе дә калмады.

Соңгы тарихчылар «Иделдән ерып кертелгән су» сүзеннән Иделгә яки диңгезгә түгелә торган су һәм елга булуын аңлыйлар һәм шуңа нигезләнеп, бу шәһәр — Җаек елгасы буенда булгандыр,— диләр. Бигрәк тә Карамзинның «Саксыйн каveме һәм Болгар сакчылары, татарларның кузгалуларыннан хәбәрдар булып, Җаек буеннан качып Болгарга бардылар»,— диган сүзе шушы фикерне куәтлидер[17].

## *Биләр*

Бу шәһәр Биләркә исемле елганың Чирмешән елгасына коелган урынында иде диләр. Болгар тарихчысы Ягъкуб бине Ногманның Әндәлесигә[18] сөйләвенә караганда, Болгар халыклары үзләренә башлап ислам динен кертүче һәм өйрәтүче Биләр исемендәге кешене ихтирам итү һәм исемен калдыру теләге белән исемен шушы шәһәргә биргәннәр һәм Биләр дип атаганнар[19].

## *Болгар*[20]

Болгар шәһәре Идел елгасыннан дүрт чакрым арада булып, шәһәрнең читләре имән бүрәнәләрдән буралган буралар эчләренә таш белән ком тутырган ныгытма төзеп уратылган иде. Ныгытманың эче 3,5 квадрат чакрым киңлектә булып, агачтан төзелгән. 520 ләп йорт һәм хисапсыз күп тирмәләр һәм чатырлар урнашкан иде[21]. Ныгытманың көньяк тарафында һәм почмак булып килгән урында сугыш өчен ясалган тагын бер ныгытма

---

[14] «Кәшфез-зөнун» («Уйларны ачу»— Ә. Х.), I кисак, 204 бит.

[15] Суар шәһәре — Татарстанның хәзерге Куйбышев районындагы Утка елгасының сул ягында, Кузнечиха авылының көньягында урнашкан шәһәр булган.

[16] Жукотин шәһәре — Татарстанның хәзерге Чистай районындагы Данауровка авылыннан (Кама елгасының сул ягы) 0,7 км. төньяк-көнчыгыш тарафында урнашкан шәһәр булган.

[17] Саксыйнның дөресе Сакъчин булса кирәк.

[18] Әндәлеси — Әбу Хәмид Мөхәммәд ибне Габдеррәхим әл-Гарнатый әл-Әндәлеси. 1080-1169 елларда яшәгән испан-гарәп сәяхәтчесе һәм географы — Ә. Х

[19] Биләр сүзе төрки булганлыктан, әлеге кешенең үз араларыннан ислам йортына барып, дин өйрәнеп кайткан булуы да мөмкин. Биләр-бик һәм бәкнең кыскартмасы булган бинең җыелмасы, күплеге, яки ия, хуҗа һәм патша, хөкемдар мәгънәләрендәге биләүдән килачак заман һәм яки белүнең килачак заманы булган белер булуы да ихтимал.

[20] «Болгар» сүзе — төрекләрнең олуг бер тармакларына исем булып йөргән кебек, шушы каveмнең хөкүмәт үзәге һәм ханнары торган мәшһүр шәһәрләренә дә исем булып йөрндер.

[21] Иске Болгар шәһәре хакында ясалган карталарда Болгар шәһәрен ураган Иске Иделдән башлап бер ур күрсәтеләдер. Бу урның икенче башы уралып, янәдән шул Иделгә килеп тоташадыр. Бу ур — бурап ясалган ныгытманың тышында идеме, әллә эчендә идеме, моны бик ачык белеп булмады. Урның бөтен буе сигез чакрым микъдарында.

бар иде. Бу ныгытма — бу көндә дә сәламәт булып, руслар ничә гасырлардан бирле җимерсәләр дә, һаман да башына җиткәннәре юк. Үзләре моны Городище,— дип йөртәләр.

Багдадтан илчеләр һәйәте (делегация — Ә. Х.) килгәндә Болгар шәһәрендә ун мең микъдарында җан хисабы бар иде, базарлары һәм урамнары бик җанлы иде. Таш йортлар һәм бүрәнәләрдән салынган биналар, бакчалар һәм күңел ачу урыннары һәм дә хөкүмәт биналары шәһәрне зиннәтләп торалар иде.

Болгар шәһәренең иске һәм олуг һәм дә шөһрәтле вакытыннан ядкяр булып калган тарихи истәлекләрдән Кара сарай һәм Ак сарай исемендәге биналар һәм кечкенә бер манара бар.

Кара сарай — үзенең фасады һәм матурлыгы белән Россиядә булган борынгы истәлекләрнең иң-иң яхшыларыннан саналадыр. Ләкин бу йортның нинди урын булганлыгы һәм нинди вазифа белән биләнгәнлеге мәгълүм түгел. Моның хакында халык арасында: «Бу йортта явыз һәм усал адәмнәрне хөкем иткәннәр һәм җәза биргәннәр»,— диган бер хәбәр бар. Шул мөнәсәбәт белән моңар «Хөкем сарае»,— дип тә әйтәләр. Тышыннан кара булып күренүе сәбәпле Кара сарай,— дип танылган.

Бу сарай дүрт катлы булып, өстендә купол (гөмбәз — Ә. Х.) бар, аның уртасы тишекле. Түбән каты квадрат кебек һәм өйнең нигезе хөкемендә булып, һәр тараф дивары 17 аршын озынлыгында һәм 3 аршын биеклегендә, бер кадәр җиргә батып торадыр. Бу бату заман үтү тәэсире белән булганлык мәгълүм. (...)

Ак сарай да шушы Кара сарай рәвешендә. Формасы ягыннан әһәмиятле мөлкәт булган бу сарай — бу көндә харап булу алдында. Моңа Ак сарай диюнең сәбәбе — төсе ак булудыр. Бу өй дә квадрат формасында булып купол (гөмбәз — Ә. Х.) белән ябылган. Почмакларында үзе төсле куполлар белән капланган бәләкәй-бәләкәй өйләр бар. Бу өйләр — шул уртадагы өйгә ишекләр белән тоташтырылганнар. Моның астында су юллары-мы, яки кешеләр йөрер өченме — ниндидер юллар булганлык риваять ителәдер.

Элек шәһәр булып торган урыннарда зур-зур чокырлар бар. Боларны камалу вакытында һәм яки башка берәр сәбәп белән су кытлыгы вакытында хәзер булып торсын өчен су белән тутырылган чокырлар булганлыкларын уйлыйлар.

Зур мәчет хәрабәсе янында калган манарасы — Олуг Петрның әмеренә күрә тимер кыршау белән ныгытылган булса да, заман үтә-үтә һаман зәгыйфьләнеп барган һәм ниһаять һиҗри белән 1260, милади белән 1844 елда рамазан аенда — ноябрьдә җимерелгән[22]. Бу манараның ишеге көньяк тарафыннан булып, эченнән бормалы 73 баскыч белән менә торган булганнар.

Бу көндә сәламәт булган кече манараның төбе (асты) квадрат формасында һәм һәр тарафы 6 аршын озынлыкта һәм 4 аршын биеклектәдер. Шушы төп өстенә түгәрәк итеп манара салынган. Манара өскә күтәрелү сәбәбендә нечкәрә барадыр. Түбәсе очлы итеп тимер белән ябылган һәм аның өстендә, иң очында матурланып торган ае бар. Манараның биеклеге — 28 метр. Манараның эчендә бормалы баскыч булып, аңа төн ягыннан кереләдер. Эченә керелгәннән соң 48 баскыч белән югары менеләдер.

Шушы манарадан ерак түгел урында иске каберләр бар. Халыклар боларны сәхабәләр каберләре,— дип йөртәләр. (Беренче мәртәбәдә ислам кабул иткән — сабкун каберләре булуы мөмкин).

Европа белән Азия, Иран белән Кытай һәм Греция сәүдәгәрләренә үзәк булып, никадәр вакытлар гомер сөргән, капкасы төбенә маллар төялгән Харәзм һәм һиндстан, Фирганә һәм Бохара, Чуд һәм Кавказ кәрваннары килеп туктаган, самәвидләргә кадәр кавемнәр җыелып алыш-биреш иткән бу шәһәр аллаһы тәгаләнең хөкеме белән бу көн һәлак булган, бары үзе белән исеме һәм дә хәрабәләре генә калган...

Бөтен шәһәрне яңгыратып торган азан тавышлары, мөнбәрендә сөйләгән хотбәләр һәм вәгазьләр, галимнәр һәм хафизлар (Коръәнне яттан белүчеләр — Ә. Х.), дин юлында көрәшүчеләр һәм исламны саклаучылар — кайсы урыннарга киттеләр һәм кайсы төрле җирләргә таралып беттеләр.

Болгар шәһәре бигрәк тә милади белән ундүртенче гасырда бозылды һәм аннан соң да һаман бозылуда дәвам итте. Һич төзекләндерелү күрмәде, бу шәһәр урынын һәм шәһәрнең борынгы истәлекләрен руслар Успен исемле монастырьларына бүләк иттеләр һәм шул исем белән бер рус авылына нигез салдылар. Әлеге рус авылы — ике йөз елларга якын була, Болгар шәһәрен җимерүдә дәвам итте, ташларыннан чиркәү дә төзеде, кабер ташлары һаман һәлак ителде.

Болгар шәһәре харап булса да, болгар төрекләре бу көннәргә кадәр һаман яшәп килгәннәр, диннәрен һәм миллилекләрен, гореф һәм гадәтләрен, телләрен һәм язуларын саклаганнар иде. Моннан соң индениләр булыр?..

---

[22] Спасс өязе Олы Чаллы авылының Фазлулла Бохарач бу манара хакында: «1260 ел, рамазан аеның 19 нчы кичәсе — сишәмбе көн кичәсе — ярты төндә аудым»,— дип үзенең җыентыгына язып куйган. Мөстәфадел-әхбар... I кисәк, 94 б.

Болгар кавеменең хөкүмәт үзәкләре һәм башкалалары Болгар шәһәре булганлыгы сөйләнде. Монгол һәм татарлар боларның өсләренә килеп һөҗүм иттеләр һәм сугыштылар һәм болар соңгы чиктә згыйфьләнделәр. Шуннан соң Болгар төрекләренең бер өлеше үзләренең хөкүмәтләрен Казанга күчереп беркадәр еллар дәвам иттерә алсалар да, татарлар тарафыннан ясалган җәрәхәт төзәлә алмады, ахырында руслар тарафыннан басып алындылар.

Болгарларның соңгы башкалалары Казан шәһәре булганлыктан һәм Идел буйларындагы мөселманнар — гомумән болгар төрекләреннән булганлыкларыннан, Казан мәмләкәтен Россиягә кушканнан соң, Мәскәү падишаһы Иван Грозный үзенә «Болгар падишаһы» дигән дәрәҗәле исемне биргән иде. Шуннан соң бу дәрәҗәле исем рус падишаһларына һәм императорларның һәммәсенә бирелеп килде. Хәтта иң соңгы императорлары булган Николайның дәрәҗәле исемендә «Болгар падишаһы» дигән җөмлә бар иде. 1675 миладиелдан 1686 елга кадәр Казан шәһәрендә торган митрополит Иосаф та «Казан һәм Болгар митрополиты»,— дип аталган иде.

Казан өлкәсе Россиягә кушылганнан соң барлыкка килгән ислам галимнәре үзләрен һәрвакыт «әл-Болгари» дип язалар һәм бу нисбәтне үзләренең әсәрләрендә дә искә алалар иде. Хәлбуки, болар үзләре Болгар шәһәре харап булганнан соң дөньяга килгән һәм күбесе дә, хәтта Болгар хәрабәләрен күрү өчен генә булсын, бармаган кешеләрдер. Шуннан аңларга мөмкин: болар үзләрен Болгар шәһәренә түгел, бәлки болгар кавеменә нисбәт италәр.

Болгар кавеме өстенә һөҗүм иткән монгол ханнары кул астында татар исемендә бер төркем гаскәр булса да, монголлар үзләрен татар санамыйлар һәм татар исемен күтәрергә риза булмыйлар иде. Монгол ханнарының гаскәрләренең күбесе уйгур, Фиргана һәм Төркстан төрекләре иде. Татар ханнарының иң шөһрәтле вакытларында бу мәмләкәттә сәяхәт итүче Ибне Баттута, бу мәмләкәт халыкларын һәрвакыт: «Төрекләр шулай һәм төрекләр болай, төрекләрнең гадәтләре шундый, төрекләрнең горефләре мондый»,— дип сөйли, килеп кергән көненнән башлап, чыгып киткән сәгатенә кадәр үзе араларында йөргән кешеләрне төрек сүзе белән тәгъбир итә һәм татар дигән сүзне бер генә мәртәбә булсын, искә алмый.

Шулай булгач, безнең заманыбыздагы татарлар кайдан килеп чыктылар да, нинди юллар белән барлыкка килеп ныгып калдылар? Хәлбуки, татар хөкүмәте вакытындагы морзалар һәм түрәләрнең күбесе рус хөкүмәте вакытында чукынып, руслашканнар иде. Шималь (төньяк) төрекләре арасында татар каны табылу — шөбһәле булганы хәлдә, русларда татар каны күп булуда шөбһә юк. «Русны казысаң — татар чыгар»,— дигән дөрес мәкаль — бик мәшһүр. (...).

Рус монахлары һәм монастырь хезмәтчеләре монгол хөкүмәтенең алдан килүче гаскәрен татар дип яздылар. Рус тарихчыларының чыганаклары бөтенләй булмаса да, күбесе монахлар тарафыннан язылган нәрсәләрдер. Унтугызынчы милади гасырда безнең гыйлем сөючеләребез Көнчыгышны өйрәнүче галимнәргә катнашып йөри һәм рус әсәрләрен укый башладылар. Рус тарихларында күренгән тикшерүчесез һәм тәнкыйтьсез татар исемен алып яман ат чыгардылар. Югарыдагы сорауның кыскача җавабы шушы.

Болгар төрекләренең өч башкала шәһәрләре булды. Берсе — үз вакытында бик мәшһүр һәм бу көндә харап булган Болгар шәһәре. Икенчесе — Казан елгасы өстендә, бу көндә харап булган Казан шәһәре. Өченчесе — бу көндә сәламәт булган Казан шәһәре.

Болгар төрекләренең шушы башкалаларында хөкем сөргән ханнары (хөкемдарлары һәм падишаһлары) бер кадәр ышану мөмкин булган хәбәрләргә караганда шушы затлар иде:

**1. Сулки.**

**2. Моның улы Алмас.**

Моның заманында һәм моның үтенүенә күрә Багдадтан Габбаси хәлифә тарафыннан Болгарга илчеләр делегациясе килде һәм Болгар төрекләренең ислам кабул итүләре һәм хөкүмәт дине ислам булуы рәсми суратта игълан ителде[23].

**3. Моның улы Әхмәд.**

Мөкътәдир биллаһи хәлифә заманында Багдад аркылы хаҗга барганлыгы һәм үзенә

[23] Алмас сүзе үлмәс (үлмәз)дән җиңелайтелгән булуы мөмкин. Үлмәс исемендә кешеләр бу көндә дә буладыр. Алмас мәшһүр казылма исеме булуы да мөмкин. Иске төрекләрдә тимер, таш кебек казылма исемнәрен балаларга бирү — сөекле бер гадәт иде. Алмас сүзе — хан, падишаһ кебек саф дәүләт хезмәтендә булучының дәрәҗәле исеме булу да мөмкин. Маҗар мәмләкәтендә Алмас исемендә иске шәһәрләр һәм кышлакларның бу мәмләкәттән күчеп килгән болгарлар тарафыннан кушылганлыгы уйланыладыр. Элек заманнарда төркичә исемнәрдә тавышлы хәрефләр язылмау гадәте дә бар иде. Бездәге олуг сүзе элеге һәм болгар сүзе Белгар, күк сүзе көк кебек языладыр иде. Күк бүре дип танылган падишаһны Көкбөре кебек язалар. Мишәр халкы бу көндә элег, әлмес, көк рәвешендә үк сөйләшәләр.

дә хәлифә тарафыннан байрак, әләм һәм дә башка рәсми бүләкләр бирелгәнлеге риваять ителә. Бу сәфәре — падишаһ булуыннан элек, шаһзадә вакытында булса кирәк.

**4. Моның углы Талиб.**

Моның исеменә 338 һиҗри (949 милади — Ә. Х.) елда Болгар шәһәрендә сугылган тәңкә бар.

**5. Моның углы Мөэмин.**

Моның заманында 358 һиҗри, (968 милади — Ә. Х.) елда рус падишаһы Владимир, кыпчак төрекләре белән берләшеп Болгар мәмләкәтенә һөҗүм ясады һәм күп зарар итте.

**6. Хәйдәр.**

**7. Моның углы Мөхәммәд.**

**8 Моның туганы Сәгыйд бине Хәйдәр.**

**9. Бараҗ.**

**10. Ибраһим.**

Бу кеше 560—561 һиҗри (1164—1165 милади — Ә. Х.) елларда сәламәт иде.

**11. Моның углы Сәлим.**

Бу Сәлим бине Ибраһим тарафыннан Болгар шәһәрендә сугылган тәңкәләрдә Габбаси хәлифәләрдән «ән-Насыйред-дин лиллаһи әмирел-мөэминин» дип язылган язу бар (ән-Насыйред-дин лиллаһи кырык җиде ел хәлифәлек урынында булып, һиҗри белән 622, милади белән 1225 елда вафат булган иде).

**12. Моның углы Илһам.**

Илһам хан заманында һиҗри белән 620, (милади белән 1223 елларда — Ә. Х.) татарлар болгарлар өстенә килеп сугыштылар һәм тәмам тар-мар ителеп кайтып киттеләр. Шушы Илһам хан заманындагы яки аннан соңгы 1237 милади елда татарлар икенче мәртәбә Болгар өстенә зур көч белән килделәр һәм болгарларны җиңделәр, зур түләүләр салдылар һәм күп байлык алдылар. Шулай булса да, болгарларның үзләренең эчке эшләрендә беркадәр бәйсезлекләре калды.

**13. Габдулла.**

**14. Хәсән.**

Моның иseme белән 770, 776, 778 һиҗри елларда (милади белән 1368, 1374, 1376), Болгар шәһәрендә сугылган тәңкәләр бар. Рус кнәзе (һиҗри белән) 778, (милади белән — Ә. Х.) 1376 елда Казан өстенә гаскәр җибәргән иде. Шул вакытта әмир Хәсән белән Мәхмүд руслар кулына әсир төштеләр һәм зур шартлар һәм күп түләүләр бәрабәренә азат ителделәр. Казан шәһәрендә кул башында архирей йорты капкасы тышында булган зур кабер ташының шушы Хәсән каберенә куелган булуын уйлыйлар[24].

Бу Хәсән хан заманында татарлардан Мамай морза котыртуы сәбәпле рус кнәзе Дмитрий Константин углы Болгарга килеп, күп хәраблык (җимереклек) ясаганлыгы риваять ителә. Алла белә, бу вакыйга югарыда искә алынган (һиҗри белән) 778, (милади белән — Ә. Х.) 1376 елның азагында булса кирәк.

**15. Мәхмүд.**

**16. Габдулла.**

Моның заманында татарлар Тимур исемендәге бер гаскәр башлыгы кул астында Болгарга килеп сугыштылар һәм шушы әмир Габдулланы шәһит иттеләр. Шуннан соң әмир Габдулланың якыннары әмирнең 9 яшендәге углы Алтынбик белән 7 яшьлек углы Галимбикне Казан шәһәренә алып килгәннәр.

**17. Алтынбик.**

Габдулла әмирнең шушы углы гүя Иске Казан шәһәрендә әмир һәм хан булып торган.

**18. Моның туганы Галимбик.**

Моның заманында Болгарның хөкүмәт үзәге Иске Казаннан яңа (хәзерге) Казанга күчкән,— диләр. Рус тарихларының «1429 елда болгарлар һәм казанлылар Галич, Кострома шәһәрләренә кадәр сугышып килделәр, ләкин шәһәрне ала алмый кире кайтып киттеләр, рус гаскәре аларның артларыннан куа барды һәм Али бабаның артыннан аз гына җитмәделәр» дигән хәбәрләрендәге Али баба — шушы Болгар әмире Галимбик булуы уйланыла.

Һәрхәлдә һиҗри белән 834, милади белән 1431 елларда руслар Болгар дәүләтен тәмам туздырдылар. Болгар шәһәре үзе дә шушы вакытларда харап ителгән булса кирәк.

Шушы әмир Галимбик (һиҗри белән) 842 — (милади белән — Ә. Х.) 1438 елда Олуг Мөхәммәд хан Сарайдан куылып Казан мәмләкәтенә килгәннән соң һәм Казан хөкүмәтен басып алганнан соң, Казанда югары дәрәҗәле дәүләт (бикләр) сыйныфыннан булып калган иде. Олуг Мөхәммәд хан соңыннан тегеләрнең тәхеткә менүеннән

---

[24] Бу кабер ташындагы язу — «Мөстәфадел-әхбар...» да бирелгән. 1 кисәк, 30 б.

саклану өчен Олуг Мөхәммәд ханның углы Мәхмүд хан утырды диләр.

**19. Олуг Мөхәммәд хан.**

Сарайдан сөрелгән бу татар ханы Казан һәм Болгар мәмләкәтенә барып чыкты һәм Казан тәхетендәге әмир Галимбикне урыныннан төшереп үзе хан булды. Русларның талауларыннан һәм сугышларыннан йөдәгән болгар төрекләре Олуг Мөхәммәд ханның шушы сәфәрендә русларны җиңеп килүеннән — бәлки безне дә руслардан яклап кала алыр,— дип Олуг Мөхәммәд ханны кабул иттеләр һәм үзләренең әмирләрен урыныннан төшереп бу кешене тәхеткә чыгардылар.

Моннан соң бу мәмләкәттә татар ханнары нәселеннән ханнар дәвам итәләр (...).

Моннан соң бу мәмләкәт Казан мәмләкәте дип шөһрәт тотты, Болгар исеме онытылуга якын калды.

Олуг Мөхәммәд хан, төрле вакытларда руслар белән сугышып, кайбер вакытларда русларны җиңсә дә, бу җиңүләреннән күзгә күренерлек яхшы нәтиҗә чыкмады. (һиҗри белән) 849, (милади белән — Ә. Х.) 1445 елның җөмадиел-әүвәл (август) аеннан соң бу Олуг Мөхәммәд ханның хәбәре беленми. Углы Мәхмүд тарафыннан үтерелде,— дигән хәбәрләр дә бар.

**20. Моның углы Мәхмүд хан.**

(һиҗри белән) 849, (милади белән — Ә. Х.) 1445 ел көз көнендә хан булды һәм (һиҗри белән) 868, (милади белән — Ә. Х.) 1464 елда вафат булды. Моның заманында электе Болгарда булган сәүдә кәсебе Казан шәһәрендә күчәя башлады. Казанның шөһрәте дә артты.

**21. Моның углы Хәлил хан.**

Атасы вафат булганнан соң (һиҗри белән) 868, (милади белән — Ә. Х.) 1464 елда хан булды. Хатыны нугай хөкемдары Тимер кызы — Нурсолтан иде. (һиҗри белән) 872, (милади белән — Ә. Х.) 1467 елда үзенең туганы Ибраһим хан тарафыннан төшерелде. Шуннан соңгы хәле мәгълүм түгел.

**22. Моның туганы Ибраһим хан.**

Агасы Хәлил ханны төшереп, аның урынына хан булды һәм агасыннан калган җиңгәсе Нурсолтанга никахланды[25]. Вафаты (һиҗри белән) 884, (милади белән — Ә. Х.) 1479 елдадыр. Фатыйма Солтан (Суфия), Нурсолтан исемендәге ике хатыны һәм дә Илһам, Ходай Колы, Миңле Таһир, Мөхәммәд Әмин, Габделлатыйф исемнәрендә биш углы, Мөршид исемендә кызы калды. Угылларының әүвәлге өчесе — Фатыйма Солтаннан булып, калган икесе — Нурсолтаннан иде.

**23. Моның углы Гали Илһам хан.**

Ибраһим хан вафат булганнан соң Сарай әдәмнәреннән кайберләре карт хатын углы Илһамны һәм кайберләре яшь хатын углы Мөхәммәд Әминне хан итү юлына кердeләр һәм шул сәбәптән араларында низаг чыкты. Ахырында беренче төркем җиңеп чыгып, Илһам хан булды.

Казанда Сарай әдәмнәре һәм хөкүмәт әгъзалары арасында мәйданга килгән бу низагны уңышлы һәм уңайлы хәл итеп, Мәскәү князе шайтанлык вазифасын үз өстенә алды, ханлык мәсьәләсендә икегә аерылган төркемнәрне бер-берсенә каршы кыздырды. (...) Болар тәмам кызышып җиттеләр, бер-берсенә һөҗүм итәргә хәзерләнеп җиттеләр. Шул сәгатьтә Мәскәү князе (һиҗри белән) 893, (милади белән — Ә. Х.) 1487 елда Казан өстенә үзенең гаскәрен җибәрде. Гаскәр Казанга килеп җитте һәм 9 нчы июньдә Казанга керде һәм Илһам ханны әсир алды һәм князьнең әмеренә күрә Мөхәммәд Әминне хан итте.

Русларның Казанның эчке эшләренә катнаша башлауларының башы шушы вакыйга, дөресрәге татар түрәләре — үзләредер. Рус гаскәре Илһам ханны, анасы Фатыйма Солтанны һәм дә хатынын һәм ике туганын, аны хан итү тарафында булган морзаларны һәм князьләрне әсир итеп, Мәскәүгә алып киттеләр. Шушы вакыйгадан соң Мәскәү князе үзенең князь дигән дәрәҗәле исеменә Болгар падишаһы дигән дәрәҗәле исемне дә кушты.

Илһам хан үзе, анасы һәм бер туганы әсир хәлләрендә Мәскәүдә үлделәр, яки үтерелделәр. Икенче туганы Ходай Кол — чукындырылды. Шуннан соң князь аңа үзенең Евдокия исемле кызын хатын итеп бирде. Чукынганнан соңгы исеме — Петрдыр[26]. Миңле Таһир вафат булганнан соң, хатыны һәм балалары чукындырылдылар. Илһам ханның ханлык итү вакыты — сигез еллар кадәрдер.

**24. Моның туганы Мөхәммәд Әмин хан.**

Мөхәммәд Әмин (һиҗри белән) 892, (милади белән — Ә. Х.) 1487 елның 14 июлендә ханлык урынына утырды. Мәскәү князе ярдәме белән хан булганлыгыннан, аңа итагатьле булу һәм аның яшеренлек белән хәрәкәт кылу хакында анда әйткән иде. Бу

[25] Ибраһим хан вафатыннан соң бу Нурсолтан Кырым ханы Миңлегәрайга никахланды һәм аннан Сахибгәрай хан дөньяга килде.

көннән башлап Мәскәү князе Казан һәм Болгар мәмләкәтен үз мәмләкәтеннән итеп саный башлады. Чынлыкта Мөхәммәд Әмин хан бөтен эшен Мәскәү князенең киңәше белән башкарадыр һәм аңа ярау өчен үзенә буйсынучыларны җәберләүдән дә сакланмыйдыр иде.

Шул сәбәптән Казан төрекләре һәрвакыт моның мөселманнарны җәберләвеннән һәм русларга артык хөрмәт күрсәтеп торуыннан риза булмадылар, үзен яратмадылар, эше белән кайгыртучанлык күрсәтмәве һәм яклаучан кеше булмавы белән хөкем йөрттеләр, мәмләкәтне бу залимнән коткару чарасын күрергә керештеләр. Ахырда Мамык ханны чакырып китерделәр дә, Мөхәммәд Әминне (һиҗри белән) 902, (милади белән — Ә. Х.) 1496 елның көзендә иярченнәре белән берлектә Казаннан кудылар. Ул, үзенең ашарга, эчәргә бирүчесе булган Великий князь хозурына Мәскәүгә китте. Бу тапкырда моның ханлык вакыты 9 ел булды.

**25. Мамык хан.**

Мөхәммәд Әмин куылганнан соң Нугай урдасыннан Мамык хан килеп, Казанга хан булды. Ләкин, бәхетсезлегенә каршы, кешеләрне җәберләү һәм халыкның байлыкларын талау юлына керде һәм Мөхәммәд Әмин ханга караганда да фаҗигале булды. Ниһаять, моның бозык холыкларына түзә алмыйча: «Безгә халыкны талаучы хан кирәк түгел»,— дип 1497 елда моны Казаннан кудылар.

**26. Габделлатыйф хан.**

Мамыкны куып җибәргәннәреннән соң, Казан халыклары Өченче Иванга илче җибәреп, үзләренә хан булыр өчен Ибраһим ханның Мәскәү князьлеге хозурында торучы өченче углы Габделлатыйфны сорадылар. Иван аны Казанга җибәрде һәм дә ханлык урынына утырту һәм халыкны ант иттерү өчен үз тарафыннан вәкилләр делегациясе күндерде. Вәкилләр делегациясе Габделлатыйфны (һиҗри белән) 902, (милади белән — Ә. Х.) 1497 елның май аенда Казан тәхетенә утырттылар. Ләкин, Казанда татар морзалары һәм князьләре арасында кызган дошманлык һәм дәгъвалар Габделлатыйфның хан булуы белән генә сүнмәде. Бәлки моның утыруы сәбәбеннән тагын да арттыһәм ялкынланырга тотынды. Шул сәбәптән Великий князь, Габделлатыйфны Казаннан Мәскәүгә кайтарды да, аның урынына элек тә хан булып торган Мөхәммәд Әмин ханны Казанга җибәрде һәм аның ярдәме белән соңгысы ханлык урынына утырды[27].

**27. Мөхәммәд Әмин хан (икенче мәртәбә).**

(һиҗри белән) 908, (милади белән — Ә. Х.) 1502 елда Мөхәммәд Әмин икенче мәртәбә Казан ханы булды. Беренче мәртәбә ханлыгыннан куылып киткәннән соң Вологда төрмәсендә ятучы җиңгәсен (агасы Илһам хан хатынын) Өченче Иваннан үтенеп төрмәдән чыгартты да, үзе аңа никахланды. Гайрәтле, тырыш булган бу хатын, Казанга килгәннәреннән соң, Мөхәммәд Әмин ханны Мәскәү князьлеге һәм Иванга каршы кыздырырга кереште һәм бу эшкә яхшы гына ирешә алды. Мөхәммәд Әмин русларга дошман булды. Бу хатын һәрвакыт Мөхәммәд Әмин ханга: «Русларга кара кол һәм Иванга ялчы булып торуыңа күрә кешеләргә хезмәт итүең һәм аларның күңелләрен табу юлында җан корбан кылуың артык!» — дип ирен хәрәкәтләндерәдер. Яратканлыгы сәбәбеннән ире һәрвакыт моның сүзенә колак салырга мәҗбүр буладыр иде»,— диләр.

Әлеге хатынның тырышлыгы сәбәбеннән Мөхәммәд Әмин хан бу мәртәбә ханлыгында руслар белән сугышты һәм аларга күп зарарлар китерде. (һиҗри белән) 911, (милади белән — Ә. Х.) 1506 елның 22 нче маенда Казан өстенә килгән рус гаскәре тәмам диярлек дәрәҗәдә Мөхәммәд Әмин хан тарафыннан кырылды.

Өченче Василийның ахирәт дусты булган Миңлегәрәй ханның хатыны Нурсолтан үзенең углы Мөхәммәд Әмингә Мәскәү князе белән дус тору хакында үгет-нәсыйхәт иткәне соңында гына Мөхәммәд Әмин хан Мәскәү князе белән солых төзеде һәм үлгәненә кадәр сугышмады.

Мөхәммәд Әмин хан (һиҗри белән) 924, (милади белән — Ә. Х.) 1518 елның декабрендә вафат булды. Кабере Казан шәһәрендә булса кирәк. Бу нәүбәтендәге ханлык вакыты 16 ел булды.

**28. Шаһгали хан.**

Шаһгали хан — Алтын Урда ханнары нәселеннән Улъяр углы булып, Мәскәү князе хозурында рус хөкүмәтенә хезмәт итәдер иде. Мөхәммәд Әмин хан вафат булуы белән Мәскәү князе үзенең вәкилләре белән моны Казанга җибәрде. Өченче Василий тарафыннан җибәрелгән вәкилләр делегациясе белән Шаһ Гали (һиҗри белән) 925,

---

[26] Ходай колы (Петрның) Аристасия исемле беренче кызы 1529 елда князь Федор Мстиславка барды һәм иреннән 6 айдан соң 1540 елның 17 нче декабрендә үлде. Анастасия исемле икенче кызы Василий Шуйский хатыны иде. Ивана исемле өченче кызы Семен Бикбулатич (Ханкирмәндә 9 нчы хөкемдар — Саин Пулад)ка барган иде. Илһам хан белән берлектә әсир ителгән князьләр үз ихтыярлары белән чукынганнары князь әмере белән шәһид ителделәр (үтерелделәр).

[27] Габделлатыйф хан Россиянең Белоозер исемле кальгасында дөньядан үтте.

(милади белән — Ә. Х.) 1519 елның апрель аенда Казанга килделәр. Рус түрәләре Шаһгалине ханлык урынына утырттылар.

Рус арасында тәрбияләнгән һәм рус әхлагы нигезендә табигать булып урынлашкан бу адәмнең бөтен хәрәкәте һәм мөгамәләсе Великий князьнең яхшы мөнәсәбәтенә ирешүдән һәм аңа яраудан гыйбарәт булды. Мәмләкәтне үзгәртеп кору, ханлыкка һәм дә ватанга хезмәт итү белән эше дә булмады. Шул сәбәптән кешеләр арасында игътибар казана алмады һәм абруйлы булмады.

Моннан хәерле эш чыкмаслыгы ачык беленгәннән соң, Казанның олы кешеләре Кырым ханы Мөхәммәдгәрәйдән үзенең туганы Сәхипгәрәйне хан булу өчен Казанга җибәрүне сорадылар. Мөхәммәдгәрәй үз туганы Сәхипгәрәйне Кырым морзаларыннан бер төркем һәм дә Кырым чирүсе (чирик) гаскәре — Ә. Х.) белән Казанга җибәрде. (һиҗри белән) 927, (милади белән — Ә. Х.) 1521 елның яз көнендә һичбер каршылыкка очрамыйча Казанга барып керделәр. Шаһгали аннан чыгып китте. Шаһгалинең бу мәртәбәдә ханлыгы 2 ел булды.

**29. Сәхипгәрәй хан.**

Казанга керүе белән (һиҗри белән) 927, (милади белән — Ә. Х.) 1521 елда хан булды. Рус гаскәре Казан өстенә килгән вакытта, (һиҗри белән) 930, (милади белән — Ә. Х.) 1524 елда гаскәр белән ярдәм итүен сорау өчен, үз урынына туганы Мөхәммәдгәрәй углы Сафагәрәйне куеп Истанбулга китте. Ярдәм биреп, Казан һәм Болгар мәмләкәтен руслардан саклау һәм коткару урынында солтан Сөләйман бине Сәлим Сәхипгәрәйнең үзен Кырымга хан итеп җибәрде. Казан һәм Болгар мәмләкәте ярдәмнән мәхрүм булып калды. Сәхипгәрәйнең ханлык вакыты 3 ел кадәр булды.

**30. Сафагәрәй хан.**

Сафагәрәй бине Мөхәммәдгәрәй бине Миңлегәрәй хан — рус гаскәре белән Казан гаскәре сугышкан (һиҗри белән) 927, (милади белән — Ә. Х.) 1521 елда Казан ханы булды. Яше — 13 тә иде. Җиде ел торганнан соң түрәләр һәм морзалар арасындагы фетнәләр сәбәбеннән (һиҗри белән) 937, (милади белән — Ә. Х.) 1532 елда урыныннан төшерелде һәм Кырымга кайтып китте.

**31. Җангали хан бине Ульяр.**

Сафагәрәй хан Казаннан куылганнан соң, Казан кешеләре Шаһгали ханның русларда хезмәт итеп торучы 15 яшьлек энесе Җангалине чакырып (һиҗри белән) 937, (милади белән — Ә. Х.) 1531 елның 29 нчы июнендә тәхеткә утырттылар. Бу вакытта Казан мәмләкәтенең тышкы эшләренә генә түгел, хәтта эчке эшләренә дә Мәскәү кнәзе катнашадыр һәм зур эшләр аның теләгенчә башкарыладыр иде.

Мәскәү кнәзенең рөхсәт итүенә күрә, Җангали хан нугай кнәзе — Йосыф Морза кызы Сөембикәгә никахланды һәм шушы урында дүрт ел кадәр торганнан соң, 20 яшендә вакытында Хөршид ана[28] белән Булат исемле кнәзьләр тырышлыгында үтерелде.

**32. Сафагәрәй хан (икенче мәртәбә).**

Җангали хан үтерелгәннән соң Россиянең дәрәҗәсен сындыру һәм Казан өлкәсен рус хакимиятеннән коткарып, мөстәкыйль хөкүмәт итеп калдыру нияте белән, морзаларның бер төркеме Кырымнан Сафагәрәйне чакырып, Казан тәхетенә утырттылар. Бу вакытта Сафагәрәй хан Җангалинең тол калган хатыны Сөембикәгә никахланды.

Сафагәрәй хан — бердән руслар белән сугышуга мәҗбүр булганлыктан һәм икенчедән татар морзаларының бер төркеме рус тарафында, икенче төркеме Россия белән дошманлыкта булып үз араларында өзлексез дәгъвада булуларыннан тәмам бизәр булды. Берәр төрле ярдәм табу өмете белән булса кирәк, (һиҗри белән) 953, (милади белән — Ә. Х.) 1546 елда Сафагәрәй хан Җаек буенда Нугай йортындагы каенатасы Йосыф морза янына качып китте һәм Казан мәмләкәте хансыз калды. Сафагәрәйнең бу мәртәбәдә ханлык вакыты 11 ел кадәр булды.

**33. Шаһгали хан (икенче мәртәбә).**

Казан мәмләкәте хансыз калганлыгында, руслар килеп (һиҗри белән) 953, (милади белән — Ә. Х.) 1546 елда Шаһгалине икенче мәртәбә Казан мәмләкәтенә хан итеп куйдылар. Ләкин тәхеткә утырту бәйрәмнәре бетеп җитмәде, Казанда үзен тәхеттән төшерү чарасы күреле башлады. Шуны сизеп, Шаһгали хан үзе Казаннан качты. Бу мәртәбәдә ханлык вакыты күп булса бер ай булгандыр.

**34. Сафагәрәй хан (өченче мәртәбә).**

Шаһгали хан качканнан соң Сафагәрәй Казанга кайтты һәм ханлык урынына утырды. 38 яшендә вакытында (һиҗри белән) 956, (милади белән — Ә. Х.) 1549 елның март аенда Казанда вафат булды. Кабере — Казандадыр. Бу мәртәбәдәге ханлык вакыты 3 кенә ел булды.

**35. Үтәмешгәрәй хан.**

Сафагәрәйнең вафаты соңында углы Үтәмешгәрәй Казан ханы булды. Бары ике

---

[28] Бу жылан хатын — Ибраһим ханның кызы булса кирәк.

генә яшендә иде. Казан халкы шул балага турылыклы булу турында ант итте. һәм ханлык урынына утыртты. Анасы Сөембикәне васый[29] итеп куйдылар.

Бу хәлдән форсат табып, 4 нче Иван Казан мәмләкәтен алырга хәзерләнде. Казан халкы моны белеп, Иван белән килешү төзү юлын тоттылар һәм теләр-теләмәс аның шартларына риза булдылар. Сөембикә белән углы Үтәмешгәрәйне Мәскәү князе кулына тапшыру һәм Шаһгалине Казан мәмләкәтенә хан итеп кую — шул шартлар җөмләсеннән иде.

Татар морзалары һәм князьләре (мәмләкәтнең байлары) үзләренең дүрт яшьлек ханнары Үтәмешгәрәй белән аның анасы Сөембикәне (һиҗри белән) 959, (милади белән — Ә. Х.) 1551 елның шәгъбан аеның 8 ендә, җомга көн (11 нче август) русларга тапшырдылар. Руслар 6 яшендә һәм гөнаһсыз сабый вакытында Үтәмешгәрәйне (һиҗри белән) 960, (милади белән — Ә. Х.) 1553 елның гыйнварында Мәскәүдә чукындырдылар һәм Александр дип исем бирделәр. Бу адәм 19 яшенә җиткәндә, 1566 елның июнь аенда Мәскәүдә вафат булды һәм Архангел чиркәвенә күмелде. Сөембикәнең моннан калып бер кадәр вакытлар сәламәт булганлыгы мәгълүм.

**36. Шаһгали хан (өченче мәртәбә).**

Шушы (һиҗри белән) 959, (милади белән — Ә. Х.) 1551 елда августның 14 нче көнендә Казан халкы Идел белән Бишбалта арасында яңа хан Шаһгалине хан итеп, ант иттеләр һәм 16 нчы августта Шаһгали үзенә тарафдар булган татар һәм монгол морзалары һәм князьләре һәм дә биш йөз кадәр рус боярлары белән берлектә Казан шәһәренә керде. Шаһгали ханны саклау өчен хан сараена рус солдатлары куелды.

Тыштан Шаһгали — хан булып күренсә дә, чынлыкта бөтен эш Иван теләгенә яраклы рәвештә йөридер. Шаһгали бары сурәт хезмәтен генә үтәп торадыр иде. Бу мәртәбәсендә дә үз урынында яхшы эш күрсәтә алмады. Татар һәм монгол морзалары белән арасы да төзек булмады. Шушы хәлдән үзенең монда төпләнеп кала алмаслыгын белеп, үз иярченнәре белән Казаннан качып чыкты да, үзенең әфәндесе — Иван янына, Мәскәүгә китте. Шушы вакытта Шаһгали хан үз кешеләреннән, Казан мәхзәннәрендә (склад, амбар — Ә. Х.) булган дарыдан һәм башка сугыш әсбабларыннан бер кадәресен Зөя кальгасында торучы рус гаскәренә озатты. Сугыш тупларын да боздырды, диләр.

Иванның Казанны алуга хәзерләнүен белүләреннән соң, Казан халкы үзләренә бер хан куюны тиеш күргәннәр һәм Әстерхан князьләреннән Ядкяр Мөхәммәдне үзләренә чакырганнар. Шаһгали хан Касыйм шәһәрендә (һиҗри белән) 975, (милади белән — Ә. Х.) 1567 елның август аенда дөньядан китте.

**37. Ядкяр Мөхәммәд хан ибне Касыйм хан бине Сәед Әхмәд хан.**

Казан морзаларының чакыруларына күрә (һиҗри белән) 959, (милади белән — Ә. Х.) 1552 елның апрель аенда Ядкяр Мөхәммәд Казанга килеп хан булды. Яше 19 да иде. Казанның эче тынычсыз һәм Казан үзе руслар белән сугыш хәлендә иде.

Великий князь 4 нче Иван 190 мең чамасы гаскәр хәзерләп 30 нчы августта Казан шәһәрен камап алды. Немец инженерының өйрәтүенә күрә кальга астын казып дары куйдылар, ут җибәреп кальганы күтәрттеләр һәм 2 нче октябрь, якшәмбе көн (13 нче шәвваль) руслар Казан шәһәренә керделәр һәм Ядкяр ханны әсир алдылар.

Казан шәһәрендәге 30 мең гаскәрдән сәламәт калганнары 2 мең кадәр генә булып, болар шәһәр эченә кергән рус гаскәре белән соңгы чиккә кадәр сугыштылар һәм күбесе шәһид булдылар. Калганнары урман арасына кереп югалдылар. Бу югалган баһадирларны киләчәк заманда роман язучы бер мөселман мәйданга китереп чыгарыр, яки заман үзе калкытып дөньяга күрсәтер.

Казан алынганнан соң арлар һәм чирмешләр дә русларга бирелергә мәҗбүр булдылар. Бер-ике елдан соң башкортлар да баш салдылар. Шулай итеп, Олуг Болгар төрекләре рус кул астына керделәр.

Руслар Ядкяр ханны Мәскәүгә алып китеп чукындырдылар һәм Семен диган исем бирделәр. Бу Семенның гомере озын булмады. (һиҗри белән) 973, (милади белән — Ә. Х.) 1565 елда Мәскәүдә дөньядан үтте. Ядкярдән исталек булырлык бер эш тә калмады[30].

## Болгар төрекләренең дин һәм мәзһәбләре[31]

Болгарлар төрек кавеменнән булганлыкларыннан, иске төрекләр иярган диннәрдән

[29] Васый — биреда регентша — Ә. Х.

[30] Болгар башкаласы Казанга күчкәннән соң 115 ел вакытта 14 татар морзасы 19 мәртәба ханлык иттеләр. Мөхәммәд Әмин ике мәртәбә, Сафагәрәй белән Шаһгали өчәр мәртәбә тәхеткә чыктылар.

[31] Мәзһәб — дини юнәлеш, тоткан юл — Ә. Х.

һәм мәзһәбләрдән берәрсенә ияргән булуы табигый. Ислам барлыкка килүдән соң кайсы еллардадыр Болгар мәмләкәтенә һәм болгар кавеме арасына ислам дине керде һәм яхшы гына таралды. Чөнки боларның рухи халәтләренә ислам дине яраклы һәм туры килә торган иде.

Башлап ислам динен кабул итүләренә тышкы сәбәпләрне баян итүчеләр дә бар. Ләкин, шул төрле сәбәпләр арасыннан җиңелен һәм дөресен табу — беркадәр авыр. Аны белүгә зур ихтыяҗ да юк.

Һәрхәлдә үзләре белән сәүдә мөнәсәбәтендә һәм солык хәлендә яшәүче иранлылар аркылы, Болгар төрекләре Гарәбстан җирендә барлыкка килгән ислам хәбәрен бик иртә белгәннәр булса кирәк. Боларга Габделмәлик бине Мәрдан заманында ислам кабул иткән хәзәр төрекләре арадашлыгы белән ислам дине кергән булуы да мөмкин.

Болгар төрекләренең ислам динендә булуы рәсми рәвештә (һиҗри белән) 310, (милади белән — Ә. Х.) 922 елның 12 нче мөхәррәм һәм 12 нче май, якшәмбе көннән игътибар ителергә тиешле (һиҗри белән өч йөз унынчы елның уникенче мөхәррәме, якшәмбе көн).

Бу көнгә кадәр дә Болгарда ислам дине ачыктан-ачык һәм җиренә җиткерелеп тотылуы, хәтта мәчеттә дә җомга намазы укылу һәм хотбәдә Болгар ханы телгә алынып, хәер-дога кылыну — Ибне Фазланның: «Без барганга кадәр Болгар падишаһы өчен мөнбәрдә «Аллаһеммә әслихел-мәликә Бәлтуар-мәликә Болгар»[32], («Аллам, Болгар хөкемдары булган хөкемдар Бәлтуарның эшләрен яхшы кыл»), дип хәер-дога кылына торган булган»,— дигән сүзләреннән[33] мәгълүм. Мәчетләр һәм мөнбәрләр төзелү, җомга намазы укылу һәм җомга хотбәсендә падишаһка дога кылыну — бу мәмләкәттә күп заманнар элек ислам дине тамыр җәйгән булуга дәлил.

Ибне әл-Әсирнең (һиҗри белән) 433, (милади белән 1041 — Ә. Х.) ел вакыйгаларыннан итеп: «Болгар кавеме — төрек һәм сакълаблар арасында туган. Аларның шәһәрләре — төрекләрнең иң ерак шәһәре. Алар кяферләр иделәр һәм алар якыннарыннан (күршеләреннән) ислам динен кабул иттеләр. Алар — Әбү Хәнифә (алланың аңа ризалыгы булсын) мәзһәбендә» дигән сүзендәге[34] карибне бер кадәр еллардан гына гыйбадәт белү — яраклы түгел, бәлки ул сүздән максат — болгарлар — Сәмәрканд, Аму-Дәрья һәм Сыр-Дәрья далаларындагы төрекләргә нисбәт иteләдер.

Мәсгуди, Болгар хакында: «Болгар шәһәре Мантыш диңгезе ярына урнашкан. Мин аларның җирнең җиденче кисәгендә урнашканнарын күрәм. Алар — төрекләрнең бер төре. Харәзм һәм алар арасында һәм Хорасан һәм Харәзм җирләреннән һәм башка җирләрдән анда кәрваннар йөриләр. Ә инде, әгәр теге — башка тигезлекләрдә төрекләрдән кәрваннар йөрсә — алар һәм болгарларның милке саклана. Безнең хәзерге вакытыбыз — 332 (милади белән 943 — Ә. Х.) ел иде. Мөселман диненә әл-Мөкътәдир көннәрендә, 310 елда керделәр. Теге күрүче аны күрде һәм ул хаҗга барып, тынычлык шәһәрендә догалар укыды. Аның белән әл-Мөкътәдир байрак күтәрде һәм аларны мәчеткә алып барды» — ди[35].

Якут Хәмәви: «Болгар хөкемдары һәм аның кешеләре әл-Мөкътәдир биллаһи көннәрендә ислам динен кабул иттеләр һәм Багдадка илче җибәрделәр, теге әл-Мөкътәдирне белделәр һәм аннан намазлар укырга һәм шәригать кануннарына өйрәтүен сорадылар. Ләкин алар исламга бу сәбәпләр белән кермәделәр» — ди[36].

Хәмәвинең бу сүзеннән болгарлар электән ислам кабул иткәннәр дә, шуннан соң хәлифәгә илче күндереп, дин өйрәтүчеләр җибәрүен сораганнары аңлашыладыр.

Һәрхәлдә болгар төрекләренең ислам кабул итүләренең сәбәбе ачык беленми. Төрле сәбәпләр булырга ихтимал тота. Болгар сәүдәгәрләренең Багдадта ислам диненнән хәбәрдар булып, кызыксынып кайткан булулары, Багдадта төрекләрнең дәрәҗә яулаулары һәм шуларның тәэсирләре булуы кебек эшләр — һәммәсе болгар төрекләренең ислам кабул итүләренә сәбәп булырга мөмкин.

Ибне Фазланның: «Сакълабларның хөкемдары Алмас бине Сулки Бәлтуарның мөэмин-мөселманнарның әмире әл-Мөкътәдир биллаһига хаты иреште. Анда ул ислам шәригатен кабул итеп, диннең кануннарын өйрәнеп, аңа тугрылыклы булулары турында ант итүләре хакында һәм үзләре өчен мәчетләр һәм мөнбәрләр төзүне сорап яза.

---

[32] Бәлтуарны Кәсирел-мәваши мәгънәсендәге Бул туар — дип аңлатучылар бар. «Бул»ның «күп» мәгънәсендә «туар»ның «мәваши» мәгънәсендә икенчесе мәгълүм. Бу сүз — сәдави (күчмә тормыш белән яшәгән) вакытларындагы мактаулы, дәрәҗәле исем булып, мәдәниятка ирешкәч һаман да дәвам иткән булыр,— диләр.

[33] «Мөгъҗәмел-бөлдан» («Илләр сүзлеге» — Ә. Х.) 2 кисәк, 273 б.

[34] «Кямилет-тәварих» («Тарихларның камиле» — Ә. Х.). 2 кисәк, 172 б. (Гарәпчәдән тәрҗемә безнеке — Ә. Х.)

[35] Әл-Мәсгуди. 2 кисәк. 11—12 битләр. (Гарәпчәдән тәрҗемә безнеке — Ә. Х.) Мәсгуди гыйбарәсендәге «Мантыш диңгезе» — Азов диңгезе итеп бирелә. Һун төрекләре башта Азов диңгезе тирәсенә урнашканнар иде. Соңыннан Чулман (Кама — Ә. Х.) һәм Идел буйларына күчтеләр. Мәсгуди шул вакытны хикәят итсә кирәк. Шунда Болгар исемендә берәр шәһәрләре булу да мөмкин. Шуның өчен Хвольсон һәм башкаларның бу урында Мәсгудине ялгыша дигәннәре бик урынлы булмас.

[36] «Мөгъҗәмел-бөлдан» («Илләр сүзлеге» — Ә. Х.). 2 кисәк, 272 б. (Гарәпчәдән тәрҗемә безнеке — Ә. Х.)

Мәмләкәтнең бөтен шәһәрләрендә төрле хөкемдарларның һөҗүмнәреннән саклану өчен крепостьлар төзүне сорый...»[37] — дигән сүзеннән төп максат — ислам динен кабул итеп тә, шул динне мәмләкәт эченә кертү булып, кальга (крепость — Ә. Х.) төзү — бары тик нәртеп кенә искә алынуы аңлашыладыр.

Һәрхәлдә болгар төрекләренә ислам дине ныклы рәвештә урнашты, хәлифәлек үзегеннән һәм ислам бишегеннән ерак булуга карамастан, аллаһы тәгаләнең өстенлеге һәм мәрхәмәте белән дини гадәтләр үтәлеп торды. Бу эш — болгар төрекләренең ислам кабул итүләре дөньяви бер киңлек өчен генә булмыйча, бәлки хаклыкны аңлаулары сәбәбеннән ихлас белән кабул иткән булуларына дәлил. Юкса, җилдән килгән мәхәббәт, төш һәм кәрамәт исемнәрендәге эшләр сәбәбеннән генә хасил булган ихлас — шул эшнең киресенә булган икенче төрле җил һәм икенче төрле кәрамәт сәбәбеннән югалуы һәм һәрхәлдә ныклы булмавы һәм гомумиләшмәве мәгълүм.

Өч йөз еллардан артык вакытлар үтте. Болгар төрекләре әхлаклары соңгы дәрәҗәдә бозык, мөгамәләләре — җәбер һәм золым булган рус түрәләренең истибдадлары (деспотизм — Ә. Х.) астында яшәп тә үзләренең әхлакларын, гореф һәм гадәтләрен саклап килделәр, дингә ышануларында ныклы һәм какшамас булдылар. Руслар арасында торган хәлдә сакланган дин һәм дөньяга караш, алла теләсә дәҗҗал[38] көненә кадәр сакланыр.

## Болгар төрекләренең татарлар белән руслар кул астында калулары

(...) «Татар» сүзе — Чыңгыз гаскәрендә алда йөрүче бер төркем монгол гаскәренә махсус исем булып, этнографик (нәсел-нәсәб һәм кабилә-ыругка әйтелә торган) исем түгел, бәлки русларның казачийлары урынында, Чыңгызның татар исемле гаскәри бүлегедер. Татар белән монгол арасында гомуми үзенчәлек шиксез булып, татар — җәмгыятьнең югары катлавы булып, монгол — гади, кара халык мәгънәсендә йөри. Шуның өчен бу мәмләкәттә Нух пәйгамбәрнең иярченнәре заманнарыннан бирле яшәгән кавемне «татар» дип йөртү — фарсыларны — рус, гарәпләрне итальян, чирмешләрне — көтүче һәм чуашларны — йөн тетүче,— дип йөретү кебек бер эш. Монголстанда, ихтимал, татар исемендә берәр нәсел һәм кабилә дә бардыр. Ләкин Монголстан — кайда да, Болгар — кайда?.. Һәрхәлдә без инде ялгыш булса да татар сүзен кулланырга мәҗбүрбез.

Монголлар (татарлар) Хорасан һәм Мәвараэннәһердә булган ислам дөньясын, мөселманнар тарафыннан төзелгән мәдәниятне харап иткәннәреннән соң, шәһәрләрне һәм авылларны җир белән тигезләп киткәннәреннән соң, дөнья байлыгын кәрваннар белән дә үз йортларына илткәннәреннән соң, һәр төрле байлыкларның чыганагы һәм дәүләтләрнең хәзинәсе булган болгар төрекләренең өсләренә бардылар (һиҗри белән 620, милади белән 1223 еллар). Чөнки хәзер байлык белән көч куруңнең ләззәтен татыганнар һәм моны да иярләреннән тартып алуның юлларын өйрәнгәннәр иде.

Болгар төрекләре — монголлар кебек сугыш чукмары, кан түгү белән рәхәт табучы кавем түгел, бәлки йорт караучы, иген игүче, сәүдә һәм гомумән мәдәни һәм төзеклелек эшләренә бирелеп, дөньяны тынычлык белән уздырырга теләүче бер халык иде. Шул сәбәптән, ат өстендә дөньяга килеп, ат өстендә дөньядан китүче шушы ике арадагы гомерен сугыш чукмары ташып йөрүче татарларга каршы тора алмадылар һәм көннәрнең берендә татарлар хөкеменә калдылар, үзләренең бәйсезлекләрен һәм хакимлекләрен югалттылар.

Татарлар басып алганнарыннан соң Болгар шәһәрендәге кәсеп һәм сәүдә тукталды, чит мәмләкәтләр белән тоташтан йөргән кәрваннарның юллары киселде. Шул сәбәптән Болгар шәһәрендәге кешеләр төшлек тарафына күчәргә һәм шул чара белән күрше мәмләкәтләр белән мөнәсәбәтләрен яңартырга мәҗбүр булдылар. Сарай шәһәре — шул сәбәптән һәм икътисади (экономик — Ә. Х.) файда юлында мәйданга килде.

Сарайны төзүгә татар ханының рөхсәте һәм ярдәме булса булгандыр, күпләр тарафыннан: «Татарлар үзләренә башкала булсын өчен Сарайны төзеделәр» — дип сөйләсәләр сөйләгәннәрдер. Ләкин чынлыкта бу шәһәрне төзүчеләр — болгар төрекләре белән монголлар тарафыннан сөрелеп китерелгән Төркстан төрекләре иде. Бу шәһәр сәүдә үзәге булсын өчен, Болгар шәһәре вазифасын үтәсен өчен төзелгән иде.

Татарлар Болгар мәмләкәтен җимереп, эштән чыгаруларыннан башка, файдалы бер эш тә мәйданга китерә алмадылар. Киресенчә, үзләре тел һәм мәзһәб һәм дә гореф-гадәт турыларында болгар төрекләреннән җиңелделәр һәм аларга нярделәр. Чыңгыз

---

[37] Гарәпчәдән тәрҗемә безнеке — Ә. Х.

[38] Дәҗҗал — кыямәт булыр алдыннан чыгачак бер алдакчы — Ә. Х.

гамәле белән гамәл кылуда гына тәгассыблары (фанатизмнары — Ә. Х.) йомшармады,— диләр.

Һәрхәлдә монголлар (татарлар) тарафыннан хөкүмәтләре җимерелгәннән һәм җәмгыятьләре таратылганнан соң болгар төрекләре зәгыйфьләнделәр һәм түбән хәлгә төштеләр, моңлы маҗараларга һәм зур фаҗигаларга очрадылар һәм ахырда руслар хөкемендә калдылар. (...)

Кешеләр игътибарынча, руслар — болгар төрекләреннән күп түгел иделәр. Әмма өлкә зурлыгы һәм дә гыйлем һәм мәдәният җиһәтеннән болгар төрекләре руслардан югары иделәр. Шулай булса да руслар болгар төрекләрен җиңделәр, руслар Олуг Россия булганнары хәлдә, болгар төрекләре дәвылдагы ком кебек таралып беттеләр, иҗтимагый хәлләре сүтелде. Моның сәбәбе нинди нәрсә иде, тәкъдирме?..

Дөрес, тәкъдир шулай булды. Тышкы сәбәпләр хәзерләнеп беткәннән соң гына тәкъдир шулай булды. Тышкы сәбәпләр югарыдан бирле сөйләнеп килде, аны кабатлауда ихтыяҗ юк.

Казан шәһәрен татарлар төзеделәр диелгән сүз — дөрес түгел. Казан мәмләкәтендә Сарайдан килгән татарлар хөкем сөрсәләр дә, монда Чыңгыз кануннары кагыйдә буларак тотылмады, гомуми фикерләр болгар төрекләрендә булганлыктан ул кануннарны гамәлгә куя алмадылар. Хөкүмәт башындагы татар морзалары һәм князьләр үз араларында тоташтан дәгъвалашып торулары сәбәбеннән хөкүмәт файдасы күзәтелмәде, ханнары да тынычлап хөкем сөрә алмады, бер-беренең зарарына руслардан ярдәм сораулары ахырында бөтенләй русларның басып алуларына сәбәп булды. (...)

Болгар төрекләренең игътибардан төшүләре, хөррияtләре бетү — руслар тарафыннан Казан шәһәре алынган көндә булды. (Бу тарих — Ядкяр Мөхәммәд хан сөйләнгән урында бәян ителде.) Шәһәргә керү белән руслар ирләрне һәммәсен кылычтан үткәрделәр, хатыннарны, бала-чагаларны хайван көтүе урынына көтеп, Мәскәүгә алып киттеләр һәм алпавытларга бүләшеп бирделәр. Хан үзе һәм сарай хезмәтчеләре — һәммәсе Мәскәүдә чукындырылдылар. Шәһәрдә булган йортлар, биналар, күчемле һәм күчемсез әйберләр русларга бүлеп бирелде.

Өлкәне басып алганнарыннан һәм тырнакларын батырганнарыннан соң, руслар мәчетләрне, мәктәп һәм мәдрәсәләрне ваттылар, җимерделәр, изге Коръән һәм башка китапларны яндырдылар. Язулы кәгазь һәм дәфтәрләр, язмалар кебек бер нәрсә дә калмады.

Мөхәммәд пәйгамбәрнең дөньяга килүеннән элек Гарәп ярымутравы, Гыйрак, Азия һәм Африкада язылган язулардан үрнәкләр бу көннәргә кадәр сәламәт сакланган хәлдә, Казан алынмастан элек Болгар мәмләкәтендә һәм Казан тирә-ягында язылган язуларның табылмавындагы сәбәп — шушыдыр.

«Дөньяда яшәргә һәм башкалар рәтендә гомер сөрергә теләгән милләт, үзенең үткән көннәрен белсен һәм үзләренең тарихлары белән дус булсын!» — диләр. Бу сүз — бик дөрес. Һәр кавем үзенең тарихын, язуын үз халыкларына белдерү кирәк (...) Башкалар хакимияте астында яшәүче милләтләр өчен тарих белән шөгыльләнүгә мөмкинлек юк (...)

Тарихыбыз булмауның, ата-бабаларыбызның, кавем һәм кабиләбезнең хәлләре һәм гомер сөрүләре яхшы беленмәвенең сәбәбе — үткәндәге галимнәрнең тик торулары, халкыбызның тарих гыйлеменә бәя бирмәүләре түгел, бәлки бу эшкә мөмкинлек булмау һәм заман тарафыннан ярдәм ителмәүдер. Бу мәсьәләнең итәге бик озын, шуның өчен кисеп туктатырга ихтыяҗ бар.

Казанга руслар кергәннән соң кайтарылган мөселманнар казакълар, кыргызлар арасына, Төркстан һәм Кавказ өлкәләренә, Фиргянә һәм Әфган мәмләкәтләренә качтылар, кайберләре Урал итәкләренә, Чулман (Кама — Ә. Х.) һәм Идел буйларына сыендылар. Типтәр дип йөртелә торган халыкларның шул качучылар булуы уйланыладыр.

## Миссионерларның хакимлек итүләре, рус хөкүмәте тарафыннан мөселманнарның чукындырылуы

(...) Рус падишаһларның бу мәмләкәттә булган мөселманнарны чукындыру хакында тырышулары ис китәрлек дәрәҗәдә булды. Бу маҗараны тәфсилләп язу берничә кисәкләрдән торган китап язу белән бер. Безнең моңа көчебез җитми. Боларның шушы дәрәҗәләрдә тырышуларына карaганда бу мәмләкәттә мөселман токымы югалмавы — аллаһы тәгаләнең ярдәме булса кирәк.

Дөрес, әгәр дә русларның мөселманнарны чукындырырга тырышулары беркадәр йомшак һәм уртачарак булса иде — рус халкы бу дәрәҗәдә үрчемәс һәм күбәймәс,

ислам халкы да Болгар хөкүмәте вакытына караганда бу мәртәбәдә кимемәс иде. Болар мөселманнарны көчләп чукындыру юлына керделәр һәм шул сәбәптән ифрат дәрәҗәдә кубәйделәр. Бу көндә керәшен дип йөртелә торган бер милләт — көчләп чукындырылган мөселманнардан таралган халыклардыр. Боларны Казан алынганнан соң Иван Грозный шулай бик чиркәнеч ясады.

Русларның бу эшләренә мисал итеп бу урында кайбер вакыйгаларны күрсәтү дә зарар булмас. Ләкин болар — диңгездән бер тамчы кебек кенәдер.

1. Князь Василий үз кулына төшкән мөселманнардан ирләр һәм хатыннардан ике йөз әсирне 1536 елда дингә көчләде, риза булмаганнарын үтертте.

2. Ярославль шәһәрендә тоткын булып торучы Күчем хан гаиләсен (һиҗри белән) 1048, (милади белән — Ә. Х.) 1638 елда көчләп чукындырдылар.

3. Ханкирмән шәһәрендә хан булып торучы Сәед Борһан бине Алып Арыслан бине Гали хан бине Күчем ханны (һиҗри белән) 1065, (милади белән — Ә. Х.) 1655 елда, бер нәрсә дә белмәгән сабый вакытында чукындырдылар.

4. 1732 елда Казан һәм Нижний мөселманнарын чукындыру өчен Свияжская богородица — монастырьда рәсми рәвештә идарә оештырылды.

5. Чукындырылганнарны ислам диненә кайтырга өндәүчеләрдән 1867 елның 28 нче гыйнварында 47 мөселманны Себердәге Турхан якларына сөргенгә җибәрү белән хөкем иттеләр.

6. Берәр төрле эш хакында гаепләнүче һәм өсләренә түләүләр төшкән мөселманнар чукынсалар — гаепләреннән котылулары, түләүдән азат булуы хакында кануннар игълан кылынды. Чукыну сәбәпле мөселманнар гаскәрлек хезмәтләреннән азат ителәләр иде.

7. Бик күп вакытларда базарларда һәм халык күп җыела торган җирләрдә җыелып торучылар өсләренә поплар тарафыннан үзләренең «изге су»лары бөркеләдер иде дә шуның белән шул җыелган урында, җыенда булганнар христианлык кабул иткән булып хисапланалар иде. Моннан соң шул кешеләрнең: «Минем христиан булганым юк, үз мәзһәбемнән һәм динемнән чыкканым юк!» — дигән дәгъвалары ишетелмидер иде.

8. Русларның талауларыннан, җәфалау һәм газаплауларыннан һәм үз диннәренә кертү хакында көчләүләреннән йөдәгән мөселманнар берникадәр булса да тынычлык табу, дөньяларын һәм диннәрен төзәтү һәм саклау өмете белән башкорт сахраларына күчә һәм авыллар корып гомер сөрә башлаганнар иде. Бу эшләре белән мөселманнар шул җирләрдә берләшерләр, ихтимал Төркстан һәм Фиргānә мөселманнары белән мөнәсәбәт ясарлар да, чукындырып булмый башлар,— дип Романовлардан Алексей Михайлович (һиҗри белән) 1059, (милади белән — Ә. Х.) 1649 елда: «Христиан булмаган халыкларның башкорт сахраларында торуларын тыеп» фәрман игълан итте.

9. 1713 елда «җирләрендә православный крестьяннар булган мөселман җир хуҗалары алты ай эчендә православный мәзһәбкә керсеннәр, шуңа риза булмаган мөселманнарның җирләре, йортлары һәм бөтен мөлкәтләре көчләп алыныр»,— дип фәрман чыкты. Бу фәрман 1729 елның 1 нче мартында, 1743 елның 28 нче сентябрендә тагын кабатланды.

10. Чукынырга риза булмаган мөселман алпавытлар үзләренең җирләрен һәм мөлкәтләрен сатып яки залогка салып акчалы булып калмасыннар һәм чукынудан котылмасыннар өчен, 1737 елның 21 нче октябрендә «мөселманнарның русларга җир сатулары тыеладыр»,— дигән фәрман игълан ителде.

11. 1754 елда: «Чукынмаган мөселманнар тарафыннан русларга сатылган яки залогка салынган җирләрнең документлары һәм килешү кәгазьләре игътибарсыз калыр һәм җирләре көчләп алыныр» — дигән аерым фәрман игълан ителде.

12. 1749 елда Казанда мөселман балаларын көчләп христиан дин мәктәпләрендә укыту юлына кергәннәр иде. Ләкин бу дәрәҗә хурлыкка һәм җәберләргә мөселманнар түзә алмадылар: «Файдалы булса да, булмаса да»,— дип шул вакыттагы хөкүмәткә каты сүзләр белән гаризалар бирделәр. Хәтта бу эш чит мәмләкәтләргә дә иреште, яхшы гына тавыш күтәрелде. Ахырда хөкүмәт мәчетләрне ваттыру һәм җимертү һәм дә сабый балаларны христиан диненә көчләп кертү һәм мәктәпләрдә укытуга көчләү хакындагы законын алмаштырырга мәҗбүр булды.

13. Россиядә булган рус князьләре һәм алпавытларның, дворяннарның күбесе — крестьяннарыннан, яки җир-суларыннан һәм дөньяда тоткан урыннарыннан аерыласы килмичә чукынучы мөселман морзаларының бер өлеше икәнлекләре мәгълүм. Боларның күбесе үзләренең мөселман вакытларындагы фамилияләрен ташлап, рус фамилияләре алган булсалар да, кайсыберләре әүвәлдәге мөселман вакытларындагы фамилияләре белән калганнар, рус фамилиясе алмаганнар. Бу соңгы бүлем җөмләсендә шундый фамилияләр бар: Абдуллин, Абдеев, Апраксин, Ахмаметов, Астанков, Аксаков, Аструганов, Ахметов, Измайлов, Удеевский (Уфа шәһәрендә мәшһүр), Ураков, Урысов, Батурмин, Башкиров, Балашов, Поливанов (пәһлеван), Богданов, Бикбулатов, Башов, Па-

шин, Палванов, Татаринов, Татищев, Тимашов, Тимошкин, Чибиш, Чичаков, Черкасов, Дадашев, Дашков, Дәүләтгилдиев, Денисов, Родаль, Рузаев, Шаховский, Шулашкин, Шихалеев, Ширинский, Сорокин, Салашников, Сукуров, Годунов (Борис), Котков, Кадушев, Карамзин (тарихчы), Каришев, Карилин, Кантилеев, Калпаковский, Кугушев, Казембек, Клянчин, Мамин, Мартин (Мортаза исемле морза балалары), Максудов, Мансуров, Мирзаликин, Нахимов, Ермолаев, Языков, Янгаличев, Юсупов. Боларның күбесе — зур мөлкәтләргә ия булган алпавытлар, князьләр һәм морзалардыр.

14. Көчләп чукындырылган мөселманнар — әһле ислам каршында керәшеннәр һәм мәкруһлар[39] исемнәре белән йөртеләдер. Рус хөкүмәте тарафыннан Новокрещенская контора ачылганнан соң чукындырылганнар — мәкруһлар дип, аннан элек чукындырылганнар — керәшеннәр дип аталалар. Бу ике төркем арасында аерма зур. Керәшеннәр үзләренең иске төрек телен, гореф-гадәтләрен саклап килсәләр дә ислам диненнән һәм мөселманнардан ераклашканнар, христианлыкта торуларына артык пошынмыйлар. Әмма мәкруһлар — үзләрен чын мөселман саныйлар, әгәр дә аз гына форсат тапсалар, үзләренең мөселманлыкларын күрсәтәләр. Бу турыда күреләчәк авырлыкларга түзүгә дә хәзерләр. Моның хакында (һиҗри белән) 1271, (милади белән — Ә. Х.) 1855 елның 29 нчы маенда императорның: «Ислам диненнән христиан диненә мөраҗәгать итмәгән мәкруһлар Казан духовная концесториясе хөкеменә җибәрелсеннәр, бармасалар — балалары ата-аналарыннан полиция көче белән алынып чукындырылсыннар, христиан диненчә яшәмәгән мәкруһлар яңадан чиркәүләрдә христиан руханилары тарафыннан йөретелсеннәр, әгәр дә бу эшкә риза булмасалар, ата-аналары аерылсын, ирлехатынлы булып тормасыннар!» — дип указ игълан ителде.

15. Шушы елларда мәкруһлар руслашсыннар, чын христиан булсыннар өчен, берәр-берәр гаиләләрне рус авылларына таратып утырттылар, руслар белән аралашырга һәм барлык хәлләре русларның күз алларында булып торуга мәҗбүр иттеләр.

16. Мәкруһларның үзләренең ислам диннәрендә көчле һәм ныклы булуларын муллалар һәм мәчетләр тәэсиреннән күреп, рус хөкүмәте мәчет салу эшләрен христиан руханиларына тапшырды. Болар риза булсалар — мәчет салуга рөхсәт бирелә, әмма алар яраклы күрмәсәләр — рөхсәт бирелми торган булды. Бу закон (һиҗри белән) 1188, (милади белән — Ә. Х.) 1774 елда гына үзгәрде. Ләкин бу үзгәрү — нигезеннән түгел, бәлки мәкруһлар тормаган һәм гомумән христианнарга тәэсир итү куркынычлары булмаган урыннар хакында гына иде. Әмма христианнардан, яки мәкруһлардан бер генә гаилә булса да, ул урында мәчет салуга рөхсәт бирү һәм бирмәү — христиан руханилары ихтыярында иде. Бу закон Икенче Николайның тәхеттән төшкән көненә кадәр дәвам итте (...)

18. Чукындырылу хакында мөселманнарның күргән бәлаләренең иге-чиге юк. Төрмәдә ятучылар, ватаннарыннан сөрелүчеләр, үтерелүчеләрнең хисапларын бер аллаһы тәгалә генә белер. Бу турыда иске һәм зур архивлар түгел, хәтта Уфа шәһәрләрендәге Дини нәзараты архивында булган эшләр генә дә гакылларны хәйран калдырырлык дәрәҗәдәдер. Көчләп чукындыру хакындагы законнар императрица Екатерина тарафыннан юкка чыгарылган һәм алмаштырылган булса да, бу юкка чыгару һәм алмаштырулар кәгазьдә генә булып, гамәлдә һаман да үтәлеп торды.

19. Кырым ханы Морадгәрәй бине Мөбарәкгәрәй тарафыннан Мәскәү князе Федор Алексеевичка (һиҗри белән) 1093, (милади белән — Ә. Х.) 1682 елның рәбигыль-әүвәл (март) аенда язылган хатта шундый җөмләләр бар: «Мәмләкәтегездә булган мөселманнарны көчләп һәм кыстап христиан мәзһәбенә кертәсез икән. Мондый эшләр падишаһлар дәрәҗәсенә лаек түгел. Бу бик яман эш. Бездә һәм дә бәхетле солтан кул астында хисапсыз дәрәҗәдә күп христианнар бар, безнең тарафыбыздан алар турында шундый бер эш булганы юк. Сез мөселманнарны дин мәсьәләсендә кыстамагыз, мөселманнар үз диннәрендә тыныч торсыннар[40].»

20. Кырым ханы Мөхәммәдгәрәй ханның вәзире Сәфәргази Ака тарафыннан Мәскәү князе Алексей Михайлович вәзире исеменә язылган хатта шундый сүзләр бар: «Падишаһыгыз мөселманнарның мәчетләрен һәм мәдрәсәләрен ваттырып, аллаһы тәгаләнең сүзләре булган изге Коръәннәрне утка яктырды. Тотсакларны (әсир төшкән кешеләр) йолып алырга биреп, аларны кыйнап христиан итәсез. Андый эшләр белән генә христиан күбәймәс. Бездә дә христианнар күп. Ләкин без аларның диннәренә тыкшынмыйбыз. Кешеләрне көчләп христиан һәм көчләп мөселман итү — лаек эш түгел. Ханкирмән солтанын да көчләп христиан иттегез!»[41] (...)

---

[39] Мәкруһ — начар күрелгән, сөйкемсез, дин тарафыннан кискен тыелмаган, ләкин җиңелчә читкә кагылган эш — Ә. Х.

[40] Кырым ханнарының ярлык һәм хатлары. 680—681 бб.

[41] Кырым ханнарының ярлык һәм хатлары. 874—875 бб.



# Гарәп әлифбасы нигезендә татарча уку-язу

## Бишенче дәрес

Иске татар язуында сузыкларның язмада бирелеше бик якынча. Татар телендәге 10 сузык авазны билгеләү өчен бары тик өч хәреф ( ا ، و ، ی ) кулланылган. Шушы өч ярым тартык үзара төрле комбинацияләрдә һәм хәрәкәләр ярдәмендә ун сузык авазны белдерү өчен хезмәт иткән. Бу хәл, үз чиратында, күп авазлылык күренешен тудырган. Шуңа күрә сузыклар иске язуыбызда бик якынча гына билгеләнгән һәм күп кенә очракта, бигрәк тә сүз эчендә, бөтенләй язылмаган да. Бу иске имлабызның мөһим бер үзенчәлеге һәм шул ук вакытта иң зур кимчелекләреннән берсе дә. Нәтиҗәдә, укырга-язарга өйрәнү читенләшкән, язудагы берәмлек җимерелгән, орфографик чуарлыкка юл ачылган. Кайвакытта бер сүз бер үк кеше тарафыннан төрлечә язылган, газета-журнал, нәшриятләр эшендә дә шундый ук хәл күзәтелгән. Бу хәл, әлбәттә, каләм ияләрен борчымый калмаган. Каюм Насыйрилардан башлап иске татар язуының читенлекләрен, буталчыкларын бетерү буенча эш башланган, төрле проектлар төзелгән, кагыйдәләр иҗат ителгән. Әмма патша Россиясе шартларында бу эшне ахырынача җиткерү мөмкин булмаган. Бу, әлбәттә, язуда бернинди кагыйдәсез эш иткәннәр дигән сүз түгел. Гамәлдә кайбер кагыйдәләрне, аерым таләпләрне бөтенләй искә алмый мөмкин булмаган.

Хәзер сузык авазларның язылышына күчик. Татар телендәге 10 сузык аваз калын һәм нечкә сузыкларга бүленәләр. Калын сузыклар: а, о, у, ы, ый. Нечкә сузыклар: ә, ө, ү, е, и.

Әлиф хәрефе сузык аваз а ны белдерә. Мәсәлән: ат — آت ; тай — تای ; кар — قار ; бал — بال ; бай — بای ; татар — تاتار һ. б. Беренче мисалдан күренгәнчә, әлиф сүз башында булып, а авазын белдергәндә, кагыйдә буларак әлиф өстенә мәдд (маддә) — ( ~ ) билгесе куелып языла. Мәсәлән: ата — آتا ; ана — آنا ; агач — آغاچ ; ак — آق һ. б.

Нечкә әйтелешле сүзләрдә әлиф а ның нечкә пары ә авазын белдерә. Мәсәлән: әрем — ارم ; әрлән — ارلن ; әби — ابی ; әдрәс — ادرس һ. б.

Озак вакытлар — фәндә иске имла дәвере дип аталган һәм борынгы болгар заманнарыннан алып XIX йөз ахырынача вакытны үз эченә алган дәвердә — әлиф сүз уртасында һәм азагында килгән ә авазын белдерү өчен дә кулланылган. Мәсәлән: гүзәл — گوزال ; түбән — توبان ; илдә — ایلدا ; чүлдә — چولدا һ. б.

Гасырлар узу белән, гарәп алфавитын акрынлап саф төрки-татар авазларына җайлаштыру процессында ә авазын белдерү өчен махсус хәреф-билге барлыкка килә. Ул гарәп әлифбасының 26 нчы хәрефенең бер варианты булып, өстенә ике нокта куелган һәм «т» кебек укылган «таи мәрбүтә»дән ( ة ، ـة ) ясалган хәреф — ـهٔ ، ه ، ـه . Аны «һаи рәсмия» дип атаганнар. Бу хәреф язмада XX гасыр башларында (бигрәк тә сүз башында һәм уртасында килгән ә не белдерү өчен) актив кулланыла башлый. Мәсәлән: әни — ئهنی ; әти — ئهتی ; җәйге — جهیگی ; көлтә — کولته һ. б.

Иске имла дәверендә әлиф сүз башында килгәндә үзе генә дә и, э (е), ы авазларын белдергән.

и — исем — اسم ; ихлас — اخلاص ; исбат — اثبات ; иблис — ابلیس ; ихтыяр — اختیار һ. б.

э — эч — اچ ; эш — اش ; эз — از ; эт — ات һ. б.

ы — ындыр — اندر ; ырмау — ارماو ; ыргак — ارغاق һ. б.

Шуны да искәртеп үтәргә кирәк, ы авазын белдерү өчен башка аваз белән башланган беренче иҗектә һәм ябык иҗекләрдә бернинди хәреф тә язылмый.

Мәсәлән: тыз-быз — تز بز ; тырыш — ترش ; кыз — قز ; кымыз — قمز ; кызыл — قزل ; кыр — قر ; кылыч — قلچ һ. б. Сүз ахырындагы ы авазын белдерү өчен йай кулланыла. Мәсәлән: тулды — تولدی ; калды — قالدی ; карады — قارادی ; булды — بولدی һ. б.
Татар алфавитының 1923 елда кабул ителгән варианты буенча сүз башындагы һәм уртасындагы ы авазын белдерү өчен ـُ ئُ галәмәтен куллану кагыйдә төсен алган. Мәсәлән: ышкы — ئشقی ; ызан ئزان ; ыргак ئرغاق ; кызыл — قزئل ; ыргаклысы — ئرغاقلئسی һ. б.

Сүз башында әлиф уау ( و ) белән комбинациядә у, ү, о, ө хәрефләрен белдерә. у — ул — اول ; урам — اورام ; урак — اوراق ; утын — اوتن һ. б.

ү — үлчәү — اولچاو ; үзәк — اوزاك ; үкчә — اوکچه ; үги — اوگی һ. б.

о — озын — اوزون ; олуг — اولوغ ; олау — اولاو һ. б.

ө — өлкә — اولکه ; өлгер — اولگور ; өлкән — اولکه‌ن һ. б.

Әлиф йай ( ی ) белән комбинациядә сүз башында килгән и хәрефен белдерә. Мәсәлән: ил — ایل ; ике — ایکی ; ис — ایس һ. б.

Уау ( و ) хәрефе дә берничә авазны белдерә: у-ү, о-ө.

Алда әйтеп узылганча, әлиф белән комбинациядә уау сүз башында килгән у-ү, о-ө авазларын белдерә. Мәсәлән: урман — اورمان ; үрдәк — اورداک ; орлык — اورلق ; өстәл — اوستال һ. б. Калын әйтелешле сүзләрдә уау у, о; нечкә әйтелешле сүзләрдә ү, ө рәвешендә укыла. Мәсәлән: тук — طوق ; кул — قول ; булган — بولغان ; суз — صوز һ. б.

түк — توک ; күл — کول ; бүлгән بولگه‌ن ; сүз — سوز һ. б.

Мондый сүзләрнең калын әйтелеше ط، ص، ق، غ хәрефләреннән, ә нечкә әйтелеше ت، س، ک، گ хәрефләреннән беленә.

Сүз уртасында һәм азагында килгәндә уау үзе генә дә у-ү, о-ө авазларын белдерә. Мәсәлән: рух — روح ; чулпан — چولپان ; күз — کوز ; чүлмәкче — چولماکچی ; торма — تورما ; көн — کون ; төн — تون ; ырмау — ارماو ; авыру — آورو һ. б.

Гасыр башында, уау о, ө сузыкларын белдергән очракта, аны у, ү сузыкларыннан аеру өчен уау өстенә өтер куйю гамәлгә кертә башлаган. Мәсәлән: төз (тоз) — توُز ; көз — بوُز ; боз — کوُز ; ор — اوُر һ. б.

Сүз яки иҗек башында килгәндә уау үзе генә дә уа-үә дифтонгларын белдерә. Мәсәлән: وقت — уакыт (хәзерге язылышта вакыт); وطن — уатан (ватан); وعده — уәгъдә (вәгъдә); وزير — үәзир (вәзир); وكيل — үәкил (вәкил) һ. б.

Йай ى (ي) хәрефе и-ый, й, е, ы авазларын белдерә.

Сүз башында йай әлиф белән комбинациядә и хәрефен белдерә. Мәсәлән: Идел — ايدل; ил — ايل; ич — ايچ һ. б.

Сүз башында, уртасында һәм азагында йай үзе генә килгәндә дә и-ый, й, е, ы авазларын белдерә. Мәсәлән: кисәк — كيسهک; кинәт — كينهت; кизү — كيزو; каеш — قايش; каек — قايق; муен — موين; куен — قوين; керде — كردى; күрде — كوردى; түзде — توزدى; күчте — كوچتى; чумды — چومدى; булды — بولدى; тулды — طولدى; куйды — قويدى һ. б.

Урта гасыр татар кульязмаларында ике тәрткеле йай ( ي ) эпизодик рәвештә генә күзәтелгән.

Егерменче гасыр башында йай сүз ахырында килеп ы, е тартыкларын белдергән очракта аның өстенә өтер кую кагыйдә рәвешен ала башлаган. Мәсәлән: булды — بولدىٔ; тулды — تولدىٔ; күрде — كوردىٔ; төшке — توشكىٔ һ. б.

Сүз башында йай йа-йә, йу-йү, йы-йе аваз кушылмаларын да белдерергә мөмкин.

йа — ялкын (йалкын) — يالقن; чаян (чайан) — چايان; таяк (тайак) — تاياق һ. б.

йә — яшел (йәшел) — ياشل; ямьле (йәмле) — ياملى; яшәү (йәшәү) — ياشهو һ. б.

йу — юл (йул) — يول; юк (йук) — يوق; аю (айу) — ايو; юрган (йурган) — يورغان һ. б.

йү — ютәл (йүтәл) — يوتهل; юкә (йүкә) — يوكه; сөю (сөйү) — سويو һ. б.

йы — ел (йыл) — يل; каен (кайын) — قاين һ. б.

йе — ефәк (йефәк) — يفهک; егет (йегет) — يگت; егерме (йегерме) — يگرمى һ. б.

Иске татар язуында сузык авазларның бирелеше, мәгълүм сәбәпләр аркасында, катлаулы һәм буталчык булганлыгын истән чыгармаска кирәк. Шуңа күрә иске басма китапларны, аеруча кульязмаларны дөрес уку зур тырышлык, даими күнегүләр таләп итә һәм телебез тарихына караган махсус хезмәтләр белән танышуны сорый, торган эш. Андый хезмәтләрнең кыскача исемлеге соңгы дәрестә тәкъдим ителәчәк.

*Дәресләрне Җәүдәт Миңнуллин һәм Рәшит Кадыйров алып бара.*

Бу санда укучыларга Г. Тукайның «Туган тел» һәм М. Җәлилнең «Катыйльгә» исемле шигырьләре тәкъдим ителә.

## توغان تل

ای توغان تل، ای ماتور تل، ئەتكەم-ئەنكەمنڭ تلی!
دُنیادا كوب نەرسە بلدم سین توغان تل آرقلی.
ایڭ اللك بو تل بلەن ئەنكەم بیشكتە كویلەگەن،
آنناری تونلەر بویی ئەبكەم حِكایت سویلەگەن.
ای توغان تل! هَر وَقتتا یاردەملڭ برلەن سینڭ
كچكنەدەن آڭلاشلغان شادلغم، قایغم مینم.
ای توغان تل! سینده بولغان ایڭ اللك قلغان دُعام:
یارلقاغل، دیب، اوزم هَم ئەتكەم-ئەنكەمنی، خُدام!

ع. توقای

## قاتیلگە

مین تز چوكمەم، قاتیل، سینڭ آلدا،
قوُل ایتسەكڭ دە، توتقن ایتسەكڭ دە،
كیرەك ایكەن، اولەم آیاغوره،
بالتا بلەن باشم كیسسەكڭ دە.
مڭن توگل، باری یوزن گنە
یوق ایتەلدم سینڭ سڭارنڭ.
هەم حالقمنان، قایتقاچ، شونڭ اوُچن
مین تزلەنب عافو سورارمن.

م. جەلیل

# КӨТЕЛМӘГӘН ХАТ

Көнбатыш Германиядән (ГФРдан) минем исемгә көтелмәгән хат килде. Хат «Казан утлары»на җибәрелгән булган — шуннан миңа тапшырдылар. Язган кешесе Минһаҗ атлы, үзем кебек олы яшьтәге бер абзый. Каян белгән ул мине, ни өчен язарга уйлаган? Баксаң безнең «Вечерняя Казань» газетасында туган тел турында язган мәкаләмне укыган икән. (Безнең «Вечерка» Көнбатыш Германиягә дә бара, димәк!) Менә шул мәкалә тәэсирендә Минһаҗ әфәнде үзенең дә фикерләрен язып җибәргән.

Беренче хатыннан соң озак та тормыйча, шул ук журнал адресы белән икенче хаты да килде. Бу хаты эченә ул Әнкарәдән (Төркиядән) үз исеменә килгән Мәхмүт исемле бер инженерның да хатын махсус минем өчен салып җибәргән. Хат шактый кызыклы.

Мин, билгеле, Минһаҗ әфәндегенең хатларын җавапсыз калдырмадым, форсат табу белән үзем дә яздым. Һәм менә яңарак кына аңардан, инде үз адресыма, өченче һәм дүртенче хат та килеп җитте.

Азрак уйланганнан соң, мин, хәзерге хәбәрдарлыктан файдаланып, ул хатларның эчтәлеге белән журнал укучыларын да кыскача таныштыруны кирәк таптым. Без бит күпне белергә тиешле бер заманда яшибез.

...Төрле вакытта, төрле сәбәпләр аркасында киткән яки торып калган татар кешеләренең чит илләрдә шактый ук булуын без бераз ишетеп белә идек. (Минһаҗ әфәндегенең язуына караганда, читтәге татарларның саны ярты миллионга җитә икән). Мәгәр безнең моңарчыга кадәр алар белән бер төрле дә бәйләнешебез юк иде. Булса да аерым кешеләрнең үзара сирәк кенә хат язышуларыннан узмагандыр. (Мәсәлән, элегрәк елларны Минһаҗ әфәнде безнең Мөхәммәт ага Гайнуллин белән язышкан булган). Хәлбуки, читтәге татарлар бөтенләй югалган кешеләр түгел. Алар төпләнеп калган җирләрендә һаман яшиләр, эшлиләр, араларында шактый зур дәрәҗәгә ирешкәннәре дә бар. Шуның өстенә алар, төрле илләргә сибелгән булсалар да, үзара даими бәйләнеш тоталар икән. Һәм, иң мөһиме, үзләрен милләт буларак саклап, туган телләре, культуралары өчен нидер эшләргә дә тырышалар икән әле... Минһаҗ әфәнде хатларында әнә шулар хакында күп кенә мәгълүматлар да китерелә.

Мин инде аңардан күчереп, күптән киткән һәм күптән үлгән эмигрантлар турында язып тормыйм. Ә менә алардан калган буыннарның язмышы турында берничә мисал китерү артык булмас дип уйлыйм. Мәсәлән, язучы Гаяз Исхакыйның кызы Сәгадәт ханым исән икән әле. Танылган галим, гомере буе диярлек Әнкарә университетының профессоры булган. Әмма ул да инде картайган. Яки менә Садри Максудиның кызы Адилә ханым — Төркия милләт мәҗлесенең (парламентының) депутаты... Янә Төркиянең хәрби академиясендә эшләүче Мәҗит Сакмар дигән бер татар генералы да бар икән. Аның улы — физика галиме, Канада университетының профессоры, имеш. Тагын бер Шамил исемле татар кешесе Каракас университетының профессоры дип яза Минһаҗ әфәнде үзенең хатында.

Әйе, болар барысы да хатлардан чүпләп алган исемнәр — укучыга уйланыр өчен белешмә! Ләкин болардан да әһәмиятлерәге, миңа калса, читтә чыккан китаплар. Бу хакта Әнкарәдә яшәүче Мәхмүт әфәнде менә ниләр хәбәр итә: анда «Кардәш әдәбиятлар» дигән мәҗмуганың 16 саны тулысынча Тукайга багышланып чыккан. Төрекләр шулай ук Йосыф Акчура турында да китап чыгарганнар. (Йосыф Акчура — күренекле җәмәгать эшлеклесе, революциягә чаклы ук Төркиягә китә, соңрак анда Мостафа Кемаль хәрәкәтенә якыннан катнаша. Галимҗан Ибраһимов үзенең беренче зур әсәре — «Яшь йөрәкләр» романын шушы кешегә багышлый.) Японияда Солтангалиев турында 400 битлек китап басылып чыккан. Янә килеп, Англиянең Оксфорд университеты инглиз һәм рус телләрендә татарларга кагылышлы китапларны бастырып чыгара икән. Мәсәлән, соңгы вакытта «Җәдидчелек хәрәкәте» турында китап һәм Җамал Вәлиди әсәрләре басылып чыккан булган... Әнә шундый кызыклы мәгълүматлар китерелә миңа килгән хатларда.

Әмма безнең өчен тагы да мөһимрәге — ул хатларның Гаяз Исхакыйга кагылган юллары. Монда шунысы игътибарга лаек, алар бездә Гаяз Исхакый турында кызу бәхәс барганын ничектер ишетеп белгәннәр. Һәм шушы уңай белән инде Гаяз турында үзләре белгәнне дә хәбәр итәләр. Мәсәлән, Әнкарәдә яшәүче Мәхмүт әфәнде үзенең хатында:

«Г. Исхакый Гитлер Алманиясе белән эш берлегендә булмады, «Идел-Урал легионы» эшенә дә катнашмады, икенче дөнья сугышы елларында Алманиядә дә булмады»,— дип яза. (Алмания дигәне — Германия). Ниһаять, Минһаҗ әфәнде дә үзенең җавап хатында шуны ук кабатлый: «Гаяз ага Гитлерга катнашмады, ул Гитлерны танымады. Бу хакыйкать, моны беркем инкарь итә алмас!»— ди.

Минһаҗ әфәнде сугыштан соң Төркиягә баргач, Г. Исхакыйның үзен дә күргән, сөйләшеп тә утырган, хәзерге көндә дә Гаязның кызы Сәгадәт ханым белән даими бәйләнеш тота.

Берсе Төркиядән, икенчесе Германиядән торып язган бу ике кешенең сүзләренә ышанырга буламы? Минемчә, була. Чөнки алар Г. Исхакый турындагы чын дөреслекне ерактан фараз кылып кына түгел, ә бик якыннан күреп яки ишетеп белүчеләр. Бу — бер, икенчедән, алар язганны кире кагарлык бер дәлил дә безнең кулыбызда юк. Бездә кайберәүләр Г. Исхакый сугыш вакытында Германиядә булган, Гитлерга хезмәт иткән дип язып чыксалар да, моны фактлар белән шулай ук исбат иткәннәре юк әле. Мәгәр, кызганычка каршы, дәлилләнмәгән шундый сүзләр «Гаяз мәсьәләсен» хәл итүне һаман да булса тоткарлап килә дә. Җитмәс микән инде... Булмаса, янә бер дәлил итеп, дүртенче хат эчендә килгән махсус белешмәне дә монда китерергә кирәктер, ниһаять! Менә ул:

*23 июнь. 1988*

*БЕЛЕШМӘ*

*Мин, Али Акыш[1], мәрхүм язучыбыз Гаяз Исхакыйның икенче дөнья сугышы вакытында бер генә көн дә немец илбасарлары белән эшләмәгәнлеген, ә, киресенчә, немец илбасарларына дошман булуын намусым белән тәсдыйк итәм. Бу турыда Сезгә мәгълүмат бирүче ике кеше тагын да бар. Аларның исемнәре: профессор Саадат Чагатай, икенчесе — Хәсән Агай.*

*Шулай ук, Сезгә кирәкле кайбер китаплар җибәрә алырмын дип ышанам. Мин Республикабызның башкаласы Казанда милли мирасны тикшерүгә зур әһәмият бирелә дип ишеттем вә укыдым. Мин җитмеш яшен тутырган бер илдәшегез булам.*

*Сезгә сәламәтлек, киң бәхетләр һәм барлык эшләрегездә уңышлар теләп калам.*

*Сәлам һәм изге теләкләр белән: Али Акыш.*

*P. S. 1979 елда, Әнкарәдә Гаяз Исхакыйның тууына йөз ел тулу уңае белән бер китап чыккан иде. Ул китапның 18 нче һәм 19 нчы битләрендә Гаяз Исхакыйның немецлар белән бер генә көн дә эшләмәве турында киң мәгълүмат бар.*

*Сәлам. Али.*

Иң ахырдан белешмәне җибәрүче русча «Татар халкының культура мирасын өйрәнү комиссиясе»нә дип тә өстәгән. Димәк, автор үзенең белешмәсенә рәсми төс бирергә теләгән.

Бу өч кешенең язганнарын мин шаһитлек итү дип карыйм. Шаһитлек итү — кеше үзе белгән хакыйкатьне әйтү — раслау дигән сүз. Мәсәлән, хөкем алдында раслаган шикелле. Шуңа күрә, аларның язганнарына колак салмыйча һич тә мөмкин түгел. Германиянең үзендә һәм Төркиядә торучы өч кешенең хат аша шаһитлеге Гаяз Исхакый өстеннән иң авыр гаепне алып ташлый: юк, Исхакый фашистларга хезмәт итмәгән!.. Аларның бу раславын кире кагарлык документаль дәлилләр бездә бармы? Хәзергә кадәр әле күргәнебез юк. Бар икән — күрсәтергә кирәк!

Ихтимал, читтән килгән «ятлар» хатына ышанырга ярамый дип әйтүчеләр табылыр. Беренчедән, шаһитләрнең «ятлары» булмый; икенчедән, дәлилсез ышанмау — дөреслектән качу гына бит ул! Һәм, гомумән, ни өчен әле без читтәге «ятлар»дан йөз чөерергә тиешбез? Хәзерге көндә төрле илләрдә яшәүче исән татарларның күбесе, Гитлер лагерьларыннан соң Сталин лагерьларына эләгүдән куркып, кайтмый калган элекке әсирләр. Алар үзләренең хатларында туган илләрен сагынулары турында язалар, безнең мондагы хәлләр белән кызыксыналар, китаплар сорыйлар, хәбәрләшеп торырга телиләр... Ә без аларга карата әүвәлгечә шикләнеп, сагаеп, куркып торыйкмыни инде?! Заман күзгә күренеп үзгәрә, безгә дә үзгәрергә вакыттыр, шәт!.. Ягъни яңача уйларга, дөньяга да башкачарак карарга!.. Шуңа күрә дә мин читтә яшәүче милләттәшләр белән язышуны һәм аңлашуны заман таләбенә туры килгән мөһим бер эштән саныйм. Бу фикер белән укучыларыбыз да һичшиксез килешер дип ышанам.

**Әмирхан ЕНИКИ.**

---

[1] Али Акыш — партиянең милли политикасына уң карашлары белән билгеле буржуаз тарихчы. 1963 елда Әнкарада чыккан «Идел-Урал дәгъвасы вә совет империализмы» дигән китап авторы.

## ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ПАРТИЯ ОЕШМАСЫНДА

Үткән елның 21 ноябрендә Татарстан Язучылар союзы партия оешмасының ачык җыелышы булды. Җыелыш язучыларның көнкүреш шартларын кайгырту мәсьәләләренә багышланды.

Көн тәртибендәге мәсьәлә буенча Язучылар союзының тормыш-көнкүреш комиссиясе председателе Р. Ишморатова һәм Язучылар союзы идарәсенең җаваплы секретаре М. Хәбибуллин чыгышлары тыңланды.

Фикер алышуларда Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе Т. Миңнуллин, партия оешмасы секретаре Р. Кәрами, әдипләр Ә. Еники, Г. Ахунов, Л. Ихсанова, К. Тимбикова, М. Маликова, Р. Хафизова, Л. Хәмидуллин, М. Галиев һ. б. катнашты.

## РЕСПУБЛИКА СЕМИНАРЫ

2-3 ноябрьдә балалар өчен иҗат итүче яшь язучыларның республика семинары булып узды. Ул әдәбиятыбызның аксакалы Гомәр Бәширов чыгышы белән башланып китте. Аннары семинар поэзия һәм проза секцияләренә бүленде. Яшь әдипләрнең әсәрләренә җентекле анализ ясалды, файдалы киңәшләр бирелде. Л. Лерон, Ф. Зыятдинов, Г. Гатауллин, Р. Корбанов СССР Язучылар союзына тәкъдим ителде, ә И. Гыйбадуллин, В. Нуриев һәм башка яшьләрнең кулъязмалары Татарстан китап нәшриятына тәкъдим ителде.

## МУЗЫКА ФЕСТИВАЛЕ

2-7 декабрьдә Казанда Идел буе һәм Урал яны автономияле республикалары композиторларының VII музыка фестивале булып узды.

КПССның Татарстан өлкә комитетында булган җылы очрашу вакытында Идел буе һәм Урал яны автономияле республикалары композиторларының матур традициясенә әверелгән музыка фестиваленең халыклар дуслыгын тагын да ныгытуга зур өлеш кертүе ассызыклап күрсәтелде.

Фестивальдә композиторларның соңгы 3 елда язылган симфоник әсәрләре, төрле уен кораллары өчен язылган хезмәтләре башкарылды, яңа җырлар яңгырады.

Фестиваль йомгаклары турында 7 декабрьдә фикер алышу булды. РСФСР Композиторлар союзы идарәсе секретариатының күчмә утырышында ТАССР Министрлар Советы Председателенең беренче урынбасары М. Х. Хәсәнов катнашты.

## ОЛЫ БӘЙРӘМ

Республикабыз җәмәгатьчелеге тантаналы шартларда Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле оешуга 50 ел тулуны билгеләп үтте. Шушы уңай белән Казанның Актерлар йортында фәнни-практик конференция һәм башка чаралар уздырылды.

14 ноябрьдә М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театрында Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле оешуга 50 ел тулу хөрмәтенә тантаналы җыелыш булды.

Совет музыка сәнгатен үстерүдәге хезмәтләре өчен Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле хөкүмәтебезнең олы бүләгенә — Халыклар Дуслыгы орденына лаек булган иде. ТАССР Верховный Советы Президиумы Председателе Ш. Ә. Мостаев коллективка әлеге бүләкне тапшырды һәм аларга тагын да зуррак иҗат уңышлары теләде.

Тантанада шулай ук ТАССР Министрлар Советы Председателенең беренче урынбасары М. Х. Хәсәнов, иҗат союзлары җитәкчеләре һәм башка җаваплы иптәшләр катнашты.

Тантаналы җыелыш Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле концерты белән тәгәлләнде.

## ФӘННИ КОНФЕРЕНЦИЯ

22-24 ноябрьдә В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетында Казан университеты археография экспедициясенең 25 еллыгына багышланган «Идел буе һәм Урал алды кыр һәм бина шартларында үткәрелә торган археография экспедицияләре йомгаклары һәм перспективалары» дигән фәнни конференция булып узды.

Аны кереш сүз белән университетның тарих факультеты деканы профессор И. Р. Таһиров ачты. Археографик эзләнүләр тарихы һәм нәтиҗәләре турында профессор М. Г. Госманов доклад белән чыкты. Конференция эшендә Мәскәү, Ташкент, Махачкала, Пермь, Куйбышев галимнәре катнашты.

## ТОТКЫНЛЫКТА ЯТКАН КИТАПЛАР КҮРГӘЗМӘСЕ

Ноябрь-декабрь айларында В. И. Ленин Үзәк музееның Казан филиалында 30-40 нчы елларда репрессияләнгән, ягъни халык күзеннән яшерелгән китаплар, брошюралар, партия документлары, элеккеге газета-журналлар күргәзмәсе эшләде.

Анда күренекле партия эшлеклеләре Н. Бухарин, А. Рыков, татар язучылары Фатыйх Сәйфи-Казанлы, Гаяз Исхакый, Хәсән Туфан һәм башка әдипләрнең тыелган китаплары бар. Күргәзмә ачылган көнне, әлеге китапларның ничек итеп махсус фондларга салынуы, авторларының фаҗигале язмышы турында филиал директоры Р. Закиров, КХТИ профессоры У. Белялов, ТАССР Язучылар союзы идарәсе председателе Т. Миңнуллин, Н. И. Лобачевский исемендәге фәнни китапханәнең өлкән библиографы Е. Мишина сөйләде.

## МУЗЕЙ ЯҢАДАН АЧЫЛДЫ

Мәгълүм булганча, Казандагы А. М. Горький музее моннан берничә ел элек капиталь ремонтка ябылган иде. 3 ноябрьдә А. М. Горький музеен ачу тантанасы булды. Яңа бинада 15 ләп экспозиция залы, фәнни хезмәткәрләр залы бар. Әлеге тантанада ТАССР Министрлар Советы Председателенең беренче урынбасары М. Х. Хәсәнов, ТАССР культура министры М. М. Таишев, Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе Т. Миңнуллин һәм башка иптәшләр катнашты.

Музейны ачканда ал тасма кисү хокукы музей ветераны, язучы М. Н. Елизаровага бирелде.

## ИҖАТ КИЧӘЛӘРЕ

29 октябрьдә Татар дәүләт академия театрының М. Горький урамындагы бинасында драматург һәм театр эшлеклесе Риза ага Ишморатның иҗат кичәсе булды. Әлеге бәйрәм әдипкә 85 яшь тулу хөрмәтенә уздырылды.

Аксакал әдипнең тормыш һәм иҗат юлы турында язучы Г. Ахунов сөйләде, юбилярны замандашлары һәм яшьләр котлады.

Соңыннан РСФСРның халык артисты А. Арсланов, РСФСРның атказанган артисты Э. Җәләлетдинов һәм республикабызның яшь сәнгать көчләре катнашында Р. Ишморат иҗатына багышланган концерт күрсәтелде.

Ноябрь ае юбилейларга бай булды. Әдәбият сөючеләр 11 ноябрьдә язучы Нурихан Фәттахка 60 яшь тулуын, 20 ноябрьдә шагыйрь Шәүкәт Галиевкә 60 яшь, 15 ноябрьдә драматург Диас Вәлиевкә 50 яшь тулу көннәрен зур әдәби бәйрәмнәр итеп уздырдылар.

## Р. ВАҺАПОВ ИСТӘЛЕГЕНӘ

4 ноябрьдә Казанда Татар дәүләт академия театрының М. Горький урамындагы бинасында халкыбызның мәшһүр җырчысы, Татарстанның халык артисты Рәшит Ваһаповның тууына 80 ел тулуга багышланган юбилей кичәсе үткәрелде.

Р. Ваһаповның иҗат һәм тормыш юлы хакында журналист Р. Фәттахов сөйләде. ТАССРның атказанган артистлары Д. Сираҗетдинова һәм Э. Яһудин җырчы турында истәлекләре белән уртаклашты.

Соңыннан Татарстанның сәнгать осталары катнашында зур концерт булды.

## ТАТАРЧА ӨЙРӘНӘЛӘР

КПССның Чаллы шәһәр комитетында татар телен өйрәнү курслары ачылды. Анда шәһәр партия комитетының рус милләтеннән булган секретарьлары, бүлек мөдирләре һәм башка җаваплы хезмәткәрләре атнаның бер көнендә ике сәгать татар теле кануннарын, сөйләшү культурасын өйрәнәләр.

Дәресләрне тәҗрибәле педагог, РСФСРның атказанган укытучысы Гөлшат Нуровна Шамматова алып бара.

## ЯҢА БИНАГА

Татар дәүләт академия театрының М. Горький урамындагы бинасы, Татарстан культура министрлыгы карары белән, К. Тинчурин исемендәге драма һәм комедия театрына бирелде.

## ТАТАРСТАН КОМСОМОЛЫНЫҢ М. ҖӘЛИЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ПРЕМИЯСЕ ЛАУРЕАТЛАРЫ

ВЛКСМның Татарстан өлкә комитеты бюросы, республика комсомолының Муса Җәлил исемендәге премияләре комиссияләренең тәкъдимнәрен тикшергәннән соң, әдәбият һәм сәнгать өлкәсендә түбәндәге кандидатларга лауреат исемнәрен бирде:

Р. К. Абдуллин — Казан дәүләт консерваториясе доценты, органчы.

К. А. Васильев — рәссам (үлгәннән соң).

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының «Ахырзаман» спектаклен иҗат итүчеләр коллективы (режиссеры — Д. Р. Сираҗиев, рәссамы С. Г. Скоморохов, рольләрне башкаручылар — И. Х. Әхмәтҗанов, Ш. М. Бариев, Н. Г. Гарифуллин һәм З. С. Зарипова).

Д. Г. Маликов (Зөлфәт) — шагыйрь.

Татарстан комсомолының Муса Җәлил исемендәге премиясенә лаек булучылар арасында шулай ук Түбән Кама шәһәренең «Җидегән чишмә» әдәби-музыкаль берләшмәсе һәм җырчы Г. Сафиуллина белән композитор Р. Гатауллин да бар.

# ТАМБУР БЕЛӘН ЧИГҮ

Татарстан сынлы сәнгать музеенда татар халкының гамәли сәнгатендә киң урын тоткан тамбурлап чигү үрнәкләре күпләп саклана. Шундыйларның берсе — XIX гасыр азакларында яки XX гасыр башларында чигелгән зур гына япма — күргәзмә залында даими куелып килә, үзенчәлекле бизәкләргә һәм төсләргә гаҗәеп дәрәҗәдә байлыгы белән тамашачыларның зур кызыксынуын уята.

Миләүшә төстәге ефәк өслеккә бер-береннән тигез ара калдырып пар мәк чәчәкләре төшерелгән. Аларның һәр икесен төрле төстәге яфраклар белән бизәлгән ак чәчәкләр урап алган. Һәрбер чәчәк арасында төрледән-төрле үсентеләр, үләннәр, лалә һәм күгәрчен күзе чәчәкләре сызылып-сызылып китә; сары, яшел, зәңгәрсу һәм алсу төсләр белән балкыган бу үсемлекләр төс-бизәкләр балкышын тудыра.

Җәймәнең кырые буйлап шул ук үсемлекләрдән — яфрак, үлән, чәчәкләрдән торган, әмма зуррак итеп ясалган сурәт-бизәкләр уза, алар инде тулаем күренешкә билгеле бер бөтенлек, камиллек бирә.

Тамбур белән чигү ысулы Казан татарларында борынгы чорлардан ук, төрки бабаларыбыздан ук килә. Тамбур энәсе татар хатын-кызлары кулында бер дә тик тормаган; осталарның эше, хезмәт җимеше чын сәнгать дәрәҗәсенә күтәрелгән. Мондый чигүнең төсләргә байлыгы, уңайлы һәм күп төрле мөмкинлекләр бирүе тамбурлап чигүнең тагы да үсүенә, камилләшүенә илтә.

Узган гасырның алтмышынчы елларында, техника үсешенә бәйле рәвештә, тегү машиналары күпләп тарала башлый, кулдан тегү әкренләп кысрыклана бара. Әмма, шуңа да карамастан, тамбур белән чигүгә игътибар кимеми, киресенчә, яңадан-яңа мөмкинлекләр туа. Башта — шәһәр, аннан соң авыл хатын-кызлары тамбур белән чигү машинасында эш итәргә күнегәләр. Хәзер инде зуррак мәйданлы тукымаларны чигү мөмкинлеге туа. Әйтик, киң мәйданлы япмаларны, җәймәләрне, пәрдә һәм намазлыкларны бизәкләп чигеп чыгу азрак вакыт таләп итә башлый. Шул ук вакытта ваграк әйберләр — савыт-саба һәм китап киштәсе япмалары, сөлге, күкрәкчә кебек әйберләрне дә тамбурлап чигү ешая.

Ата-бабадан калган төсмерләрне һәр буын үзенчә баеткан, һәр хатын-кыз үзе чиккән әйбергә күңел җылысын салган. Шуңа да музейда тупланган әйберләр арасында бер-берсен кабатлаган яисә бер-беренә тәңгәл килгән үрнәкләр бөтенләй юк.

Тамбур белән чигүнең нигезендә, әйткәнебезчә, чәчәк һәм үсемлек сурәтләрен бизәкләп тудыру ята. Һәм әлеге сурәтләрне тудырган хатын- кызлар чын мәгънәсендә үз эшенең бөек осталары, сизгер күңелле рәссамнар булганнар. Халык, бәлки, нәкъ менә шуңадыр, тамбурлап чигүне «энә белән рәсем ясау» дип тә атап йөртә.

**В. ЦОИ,**
Татарстан сынлы сәнгать музее хезмәткәре.

**Ю. ФИЛИМОНОВ** фотосы.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** Казан Кремле. XIX гасыр. Инглиз рәссамы Э. Турнерелли эшеннән репродукция.

# Журналыбызда 1988 елда басылган кайбер әсәрләр

ӘДӘБИ МИРАС

Кол Гали. **Кыйссаи Йосыф.** № 3.
Мәрҗани Ш. **Казан һәм болгар хәлләреннән файдаланылган хәбәрләр.** № 1.
**Мәҗмугы-л-хикаят.** № 9, 10.

ПРОЗА

Батулла Р. **Юл буенда зәңгәр чәчәк.** Повесть. № 4, 5.
Галиев М. **Алтын тотка.** Повесть. № 11.
Гыйматдинова Н. **Ханым-солтаным.** Повесть. № 7.
Зәнкиев Я. **Иртеш таңнары.** Роман. № 1, 2, 3.
Имамов В. **Күке.** Повесть. № 8.
Камалов Х. **Үлгәннән соң яздым.** Роман. № 8, 9, 10.
Низамиев Р. **Язмыштан көчлерәк.** Роман-хроника. № 11, 12.
Рәхимов Җ. **Кыядагы чәчәкләр.** Роман № 6, 7.
Салахов И. **Тайгак кичү.** Роман-хроника. № 4, 5, 6.
Шәйдуллин Ш. **Бүре өендә.** Повесть. № 8.

ПУБЛИЦИСТИКА

Мостафин Р. **Кабан күле серләре.** Тарихи-документаль повесть. № 9, 10.
Мәһдиев М., Гыйләҗев А., Галиев М. **Илгә — игелек.** Документаль повесть. № 7.

* * *

Галиев Ш. **Халкыбызга ышанам.** № 11.
Гыйләҗев А. **Ил кайгысы, фикер көрәше.** № 1.
Еники Ә. **Чынбарлык һәм туган тел.** № 9.
Сафаров Р. **Нәтиҗә булырмы?** № 12.

* * *

**Татарстан — туган төбәгем:** Минзәлә районы — № 1; Түбән Кама районы — № 2; Питрәч районы — № 3; Яңа Чишмә районы — № 4; Алабуга районы — № 5; Менделеев районы — № 6; Югары Ослан районы — № 7; Куйбышев районы — № 8.

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

**«Заман һәм шигырь» дискуссиясе материаллары.**

КУЛЬТУРАБЫЗ ТАРИХЫНА

Булатова К. **Туфан турында истәлек.** № 8.
Мостафин Р. **Хәсән Туфан хаты.** № 2.
Мәһдиев М. **Туган як авазы.** № 6.
Нуруллин И. **Максим Горькийның ике хаты.** № 8.
Хәким С. **Редакциягә хатлардан.** № 4.

* * *


Миңнуллин Җ., Кадыйров Р. **Гарәп әлифбасы нигезендә татарча уку-язу.** № 9—12.

Гарипова Ф. **Борынгы болгар шәһәрләре:** Шәһре Болгар — № 1; Биләр — № 2; Шәм Суар — № 4; Кашан — № 5; Җүкәтау — № 6; Тубылгытау — № 7; Кирмәнчек — № 8; Ашлы — № 9; Тәтеш — № 10; Арча — № 11; Казан — № 12.

**Уфада культурабыз истәлекләре:** Тукай Уфада — № 1; «Галия» мәдрәсәсе — № 2; «Дворяннар собраниесе» бинасы — № 3; Сәгыйт Рәмиев Уфада — № 4; «Хәсәния» мәдрәсәсе — № 5; «Кымыз дачасы» — № 6; «Шәрык» матбагасы — № 7; Уфа татар гимназиясе — № 8; «Аксаков йорты» — № 9; «Госмания» мәдрәсәсе — № 10; Җәйге театр — № 11; Риза Фәхретдинев Уфада — № 12.

Бәясе 90 тиен.
Цена 90 коп.

Индекс 73210



КАЗАН УТЛАРЫ
(ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ
(на татарском языке)